ISSN 0206—418

# КАЗАН УТЛАРЫ

2.1988



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1988

2

(784)

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда*

ПРОЗА ҺӘМ ПОЭЗИЯ


Я. ЗӘНКИЕВ. **Иртеш таңнары.** *Роман* . . . 3
Э. МОСТАФИН. **Чулман төбәге.** *Этюдлар* . . 82

Ф. ГАЛИМУЛЛИН. **Иҗат биеклеге.** *Фатих Хөснигә 80 яшь* 124
Ф. ХӨСНИ. **Куркыныч йорт.** *Хикәя* . . . . 125


ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ


Н. НӘҖМИ. **Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям.** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . 131

Ф. ЯРУЛЛИН. **Бәхет турында уйлану.** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . . 134


СОВЕТ АРМИЯСЕНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА


Я. ЧАНЫШЕВ. **Безне яшьлек үзе чакырды.** *Документаль повесть* . . . . . . . . . 86
Х. ХӨСНУЛЛИН. **Дусай-кичү.** *Шигырь* . . . 115
Р. САФАРОВ. **Һәлак булган солдат язмалары.** *Истәлек* . . . . . . . . . . . . . . . 117


УФАДА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ


А. ТИМЕРГАЛИНА. **«Галия» мәдрәсәсе урнашкан бина** . . . . . . . . . . . . . 140
Х. ГОБӘЙДУЛЛИН, Ж. МИҢНУЛЛИН. **«Галия» мәдрәсәсе** . . . . . . . . . . . . . 141


ПУБЛИЦИСТИКА


М. ЗАРИПОВ. **Тагын карабодай турында** . . 142


ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ


Р. ШӘМГУНОВ. **Борынгы Чулман буенда** *(Түбән Кама районы)* . . . . . . . . . . . 154

Ф. ӘГЪЗАМОВ. **Авыл хәбәрчесеннән башланган юл** . . . . . . . . . . . . . . . 158

БӘХӘС ДӘВАМ ИТӘ: «ЗАМАН ҺӘМ ШИГЫРЬ»

М. ШАБАЕВ. Төшсез чикләвекләр . . . . . 164

Р. ЮСУПОВ. Сөйләшү әдәбе . . . . . . . 172

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Х. Туфан хаты . . . . . . . . . . . . 177

К. ТИМБИКОВА. Тырышлык канатларында
*(С. Ибраһимовага 60 яшь)* . . . . . . . 186

БОРЫНГЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЛӘРЕ

Ф. ГАРИПОВА. Биләр . . . . . . . . . 188

Культура тормышы көндәлеге . . . . . . 191

Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(баш редактор урынбасары)*
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60.
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-65.
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61.
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Продолжение романа Я. ЗАНКИЕВА «Зори Иртыша», рассказ Ф. ХУСНИ «Страшный дом». Стихи Э. МУСТАФИНА, Х. ХУСНУЛЛИНА, Ф. ЯРУЛЛИНА.
«К 70-летию Советской Армии»: документальная повесть Я. ЧАНЫШЕВА «Нас водила молодость». Воспоминание Р. САФАРОВА «Записки погибшего солдата».
«Дружба литератур — дружба народов»: стихи Н. НАДЖМИ.
«Публицистика»: очерк М. ЗАРИПОВА «Еще раз о гречихе».
«Татарстан — родной мой край»: выступление первого секретаря Нижнекамского горкома КПСС Р. ШАМГУНОВА.
Статья Ф. АГЗАМОВА. «Путь пройденный селькором».
Продолжение дискуссии «Время и поэзия»: статья М. ШАБАЕВА «Орехи без ядра».
Материалы к истории литературы: письмо Х. ТУФАНА.
«Культура речи». Выступление доктора филологических наук Р. ЮСУПОВА.
В номере отмечаются юбилеи Ф. Хусни, Ф. Яруллина, С. Ибрагимовой.
«Города древней Булгарии»: «Биляр» — статья Ф. ГАРИПОВОЙ. Дневник культурной жизни. На наших обложках: шедевры татарского прикладного искусства — покрывало для книг (XVIII-XIX вв.) Дом актеров в Казани.

Җаваплы секретарь *Флүс ЛАТЫЙПОВ*
Техник редактор *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Т. Сибгатуллина*, *Г. Салихҗанова*.

Производствога бирелде 1.12.1987 ел. Басарга кул куелды 28.01.1988 ел. ПФ 05035 Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 66049. Заказ М-518. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1988 ел.

Якуб Зәнкиев

# ИРТЕШ ТАҢНАРЫ

РОМАН

Бар Рәхмәтулланың аю белән очрашканы, иптәшләре белән дә, япа-ялгызы да аюга каршы төшкәне аз түгел, үз гомерендә егермедән артык аюны ботарлаган кеше, алай да ишегенә кысылып торган урман патшасын күргәч бу юлы каушады. Мылтыгы тышта, аю ярсып үкерепме үкерә, ишектән башы узган ерткыч белән алышырга бүтән чара калмагач, Рәхмәтулла учактагы утлы күмерләрне яланкул кушучлап алды да аюга бәрә башлады. Аю бер мәлгә аптырап калды, йон көйгән ис таралды. Рәхмәтулла утлы күмер белән аюның күзенә бәрергә тырыша иде. Тик күз кечкенә, Рәхмәтулла каушаган — туры тидерә генә алмый!

Шул чагында баудан ычкынган этләр хуҗаларына ярдәмгә килеп життеләр. Берсе аюның артына ябышты, икенчесе санын тешләде. Аю акырып этләргә борылганда Рәхмәтулла атылып чыгып мылтыгына ябышырга өлгерде, ләкин сөягенә кадәр чиләнеп пешкән бармаклар хуҗасына буйсынмадылар. Ачудан тилергән тайга хуҗасы мылтыкны күреп тәмам шашынды, этләрдән аерылып Рәхмәтуллага ябышты. Ике пәһлеван арасында, үлем яки яшәү өчен, тартыш, көрәш башланды. Аю дәү, теге вак-төяк кырмыска аюы түгел, җирән аю, көчле, усал, дәһшәтле Рәхмәтулланың хәле китте, курыкты. Ул арада ак күзле хатын да кысыла-кысыла ишектән килеп чыкты, җирдә аунап яткан мылтыкка ябышты. Рәхмәтулла белән аю кочаклашып җирдә әүмәкләшәләр, тәгәриләр, әгәр атса, аюга төбәлгән укның Рәхмәтуллага тиюе бар. Аю астыннан Рәхмәтулланың: «Балта, балта!»— дип кычкырганы көчкә генә ишетелде. Хатын бераздан гына аңына килеп аяк астында яткан балтаны күрә һәм Рәхмәтулла өстендә аны изеп-сытып яткан иләмсез аюның умырткасын чабып өзә...

Шашкан аю бер читкә тәгәрәп китеп җан бирә.

Көз-кышны урын өстендә үткәрде Рәхмәтулла, яралары чиләнеп-чиләнеп үлекләнделәр, имче-шаман да чакыртмады ул, үзе белгәнчә дәваланды... Бите ямьсезләнеп бөреште, ертык иреннәреннән сап-сары тешләре күренеп тора башлады, куллары кипкән-корыган агач тармаклары кебек кәкрәеп каттылар... Язын, Чүпле күл боздан арчылып, көннәр җылынгач ул күл ярына килде, тезләнде һәм ятып суга карады.

---

Дәвамы. Башы 1 нче санда.

Рәхмәтулланы тапкан әнкәсе дә танырлык түгел иде! Һәм ул хатын янында тора башлаганнан бирле беренче тапкыр хихылдап көлә башлады, иелеп суга карый да шаркылдый, борылып күккә бага да хихылдый.

Зур кедрачның эче аркылы балта-бәлҗә белән чокып ясалган җиңел көймәсен ул берүзе суга төшерде, ау салды, ишеп карады: кул-аяклар исән, күз күрә, баш эшли, чырай бозылган икән — бәхеткә генә! Тагын ни кирәк Рәхмәтуллага?!

Шулай да аю кочагыннан чыкканнан бирле, әҗәле белән күзгә-күз очрашкач, аның тынычлыгы югалды, төннәрен уянып чыгып китә, исәнгерәп кул буенда йөри, күлдә чупырдаган эре балыкларга боткасатак ыргыта. Аю башын көймәсенә салып кедрачка алып барды, кырмыска оясына салды һәм баш ап-ак сөяккә калгач скелетны алып кайтып йорт түбәсенә бәйләп куйды... Кайчан карасаң да аюның ыржайган тешләре, күз урыннары сиңа таба текәлеп тора иде. Рәхмәтулла йокысыз төннәрдә аңа кәкрәеп каткан бармагы белән яный:

— Шалиш! Рәхмәтулланы тиз генә үтерә торган түгел!

Көн тоташ болытлы булганга бүген кич тиз килде, караңгыланды. Тып-тып яңгыр тамчылары төшкәләп торса да яумады үзе тагын, һавадагы дымны арттырып, яңгыр исе таратып йөргән болытлар таң алдыннан таралып юкка чыктылар. Рәхмәтулла әллә кайчан уянган булса да торырга иренеп суйлакланып, иренеп ята иде, кемдер ишеккә килеп кагылды. Дерт итеп сикереп торды хуҗа, баш очына эленгән мылтыгын алып, тезенә салды. Этләр нигә өрмәде соң? Ишек артында кыштырдау кабатланды, кемдер ачарга маташып тоткаsuccessfully эзли иде булса кирәк. Рәхмәтулла, мылтыгын ике кулына тотып, ак ыштанының балак очындагы тасмаларына баса-баса ишеккә якынайды. Теге яктан сак кына ишек шакыдылар. Кеше белән очрашуга караганда урман патшасы белән очрашуның хәерлерәк буласын белгән хуҗа сагаеп кына ишекне ачып җибәрде. Эчкә баткан яңаклары эре-эре куе төк белән капланган, колга кебек озын, ябык кеше көч-хәл белән иелеп ишектән керде дә лып итеп идәнгә утырды. Өй эчендә бер чакта да өч кешене берьюлы күрмәгәнгәме, Рәхмәтулла бу ят кеше керүгә тарсынды, нигәдер сулышы кысылды, чигәләре сыкрап сулкылдады.

Мосафирның таланган өс-башы, сукбай кыяфәте шиккә чумып яшәгән хуҗаны бераз тынычландырса да, кинәт килеп кергән кеше аның өнен алды... Сорашырга да ярамый, тайга гадәте, сабыр булырга да кирәк, кешене, бит-күзен юындырып, чәйгә утырттылар. Юлаучының комсызланып ашавын, чәйнәми-нитми генә голт-голт йотуын күргәч, аның нинди юллар узып килүен чамалау кыен түгел иде. Тагын бер нәрсәгә игътибар итте Рәхмәтулла: муенына сүс бау белән асылган, кыршылып беткән күн букчасын юлаучы бер дә кулыннан ычкындырмый, ике куллап ризыкка тотынганда да аны тезе өстендә тота, кычеп утырса, бер ягыннан икенче ягына чыгарып куя иде. «Алтынмы?! — дип кызыксынып уйлады Рәхмәтулла, — алтын юа торган яклардан качканмы?»

Сүзсез-өнсез бу кеше, колга сыман сөякчел өрәк, боларда торып калды. «Каян киләсең?» — дип сорагач, иңе аша артка күрсәтте. «Кая юл тотасың?» — дигәч, кулын алга сузып куйды: «Тегендә!» Артыгын сорашмадылар, файдасыз икәнлеге күренеп тора. Өрәк кеше үзе дә берни төпченмәде, атна чамасы яшәгәч: «Исемем Мишка минем!» — дип куйды да тагын үз уйларына йотылды. Комсызланып ике куллап ашады, голт-голт йотты, тәмсез исләр таратып кикерде, ишекне атлап чыгуга шатыр-шотыр җил җибәрә башлады. Рәхмәтулла аннан котылырга вакыт җиткәнлеген аңлады. Ике кеше яшәп ятканда читләр күзенә күренмәскә дә мөмкин, өч җан — игътибарны ала, монда өченче кеше бар. Өчәү икән — шикле! Тракторчы урысны яндырган, авылдашы Эссәтне терәп аткан Рәхмәтуллага йортсыз-җирсез, нәсел-нәсәп-

сез Мишканы чөеп ыргыту бер нәрсә дә түгел иде. Аны ике нәрсә тоткарлады: беренчедән, ак күзле хатын алдында җан кыючы булып күренәсе килмәде. Икенчедән, кыршалган күн букчаның серен беләсе килә иде аның... Юк, анда алтын түгел, бакыр да юклыгын Рәхмәтулла әллә кайчан белә, букчада ниндидер иске-москы кәгазьләр, сызымнар, төрткеләр, билгеләр... Алтын сумкада юк икән, аның кайдадыр булуы ихтимал ич! Таушалган кәгазьләрдә әнә шул кайдадыр оялап яткан хәзинәнең урыны күрсәтелгән булса? Шул кадәр дә ябышып ятар идеме өрәк буш кәгазьләргә?!

Ауга бара Рәхмәтулла, өрәк аны каш җыерып озатып кала. Кулга ау сала Рәхмәтулла, өрәк аны иренен тешләп карап-күзәтеп тора. Булышмый да, ярдәмләшми дә. Ярга килеп җиткән көймәне дә тартып чыгарышмый! Әле Рәхмәтулла алып кайтканны ашый, тыгына, кикерә һәм гөрләтеп җил җибәрә... Бер көнне хуҗа түзмәде:

— Син минем үгәй малай булдың бит әле?— диде.

Өрәкнең чәбәләнгән кашлары өскә күтәрелде.

— Нигә?

— Кайчанга кадәр минем җилкәне кимереп ятырсың?!

Өрәк кеше бер мәлгә тынсыз калды һәм кинәт күзләрен акайтып сүз ташкынын башлап җибәрде:

— Син — ахмак! Тиле! Җүләр! Исәр! Ахмак улы тиле! Кабакбаш! Чергән ми!..

Озак сүгенде колга, Рәхмәтулла башта көлемсерәп тыңлаган иде, соңыннан ачуы килә башлады, кызып бер ырлап алды.

— Йә, йә, булды!

— Шушы эт алачыгында яшәп, корсак тутыруны яшәү дип атыйсыңмы? Җилкәсен кимерәм, имеш, я алла, балыгын ашаганмын икән, итен! Шуны сүз итеп сөйләп торуын кара син аның. Йолкыш! Бичара байгыш!

— Әле синең анысы да юк,— диде гарьләнеп Рәхмәтулла һәм күзен ялтыратып почмакка сөяп куелган мылтыгына карап алды. Кулы кычыта башлады хуҗаның, беләгенең бала йоннары кабарды.

— Бүген юк икән, иртәгә булыр!— диде һич көтмәгәндә өрәк кеше.

— Синең иртәгәң дә юк шул,— дип карулашты Рәхмәтулла, шактый ук кызыксынып.

— Бар!— диде колга-өрәк ышаныч белән.— Иртәгәгә ышанычым булмаса, мин мең бәлаләр күреп болай нужа кумас идем.

— Кемне эзлисең соң син? Нине?

Һәм колга кеше, авызыннан төкерекләрен чәчә-чәчә, Рәхмәтуллага менә нәрсәләр сөйләде...

## 24

— Н... авылыннан мин.— һәм ят кеше Рәхмәтуллага бик таныш авыл исемен атады.— Гәрчә ул авылда торганым юк диярлек. Атлы-тунлы кешеләр идек без, абруйлы фамилия. Тегермән тота идек. Мин Петербургта укыдым. Офицер идем. Мине матур киләчәк көтә иде. Байлык, дәрәҗә! Совет власте безне чәнчелдерде. Әтине сөрделәр, мин, тибелеп, читтә исән калдым... Әтинең үчен алырга дип туган якка кайттым. Бар минем хәтердә торган кешеләрем!— Колга-өрәк бер мәлгә тын калды, кансыз каткан иреннәре генә кыймылдады, ул үзе кайчандыр үч аласы кешеләрнең исемнәрен барлап чыкты бугай. «Алай икән, исемлегең шактый озын икән!»— дип уйлады Рәхмәтулла, үзе дә Ялан кешеләрен хәтере аша уздырып.— Бар! Мин аларны онытырга да уйламыйм... Кайттым, өч көн авыл тирәли йөрдем. Урман уртасында безнең авыл! Өченче көнне, кичкырын, урман күле читендә авылдашымны очраттым. Очраштык, белештек, ул безгә ерак кардәш

тиеш кеше икән. «Кая бардың?— дип сорыйм, әйтми. «Каян кайтасың?»— дип сорашам, җавап бирми. Күзен читкә бора бу, нидер яшерә. Әйләнә-тулгана торгач, көймә төбендәге дәү җиз бөҗраны күреп алдым. Бизәкләп эшләнгән алагаем зур бөҗра! Төпченергә тотындым. Каян кулга төшергән ул мондый малны! Беләм ич, ул кайткан якта урман, сазлыклар, авыллар юк. Бөҗра уртасында ике җылан башы берләшкән. «Әйтмәсәң, кайту юк!»— димен. Ачу килде! Теге төне буе серне ачмады. «Бетердең башымны!»— дип, иртән генә чишелеп китте.— Колга кеше, таушалган букчасын ачып, аннан почмакчитләре кителеп беткән саргылт кәгазьләр чыгарды.— Сазлыкка Күчем хан хәзинәсен эзләп барган икән ул!

— Күчем хан хәзинәсен?!— дип кычкырганын Рәхмәтулла сизми дә калды.

— Өченче җәен эзли икән инде.

— Ханның хәзинәсе калганмыни?

— Калмыйча! Хан булсын да, хәзинәсез яшәсен ди, имеш!

Һәм сәер юлаучы Рәхмәтулланың комсыз күңелен вәсвәсә белән тутырып тагын әллә ниләр сөйләде.

— 1555 елда Себер ханлыгы Эдигәр кулына төшә, ул 1563 елда үтерелә. Властьны Күчем хан ала. 1582 елның 26 октябрендә Себер ханлыгы башкаласы Эскер шәһәре Ермакка бирелә, Күчем җиңелә... Ничә ел тәхеттә утырган Күчем хан?..— Колга-өрәк санын әйтеп тормады, очлы ияген алгарак чыгарып, күзен йомып санап торды да дәвам итте.— Шактый утырган! Бакчадан бәрәңге җыймаган хан, алтын җыйган, көмеш, кыйммәтле ташлар!

— Кайда соң ул хәзинә?— диде корып киткән иреннәрен ялап Карун Рәхмәтулла.

— Теге бәндә шуны өченче елын эзли икән!.. Татар картларының сүзләренә караганда, Тобольск шәһәреннән еракта түгел, кап-кара урманнар уртасында, мүкле сазлыклар эчендә Алтын мөгез дигән утрау бар икән. Утрауга адәм башы керерлек түгел, ул тоташтан куе агачлар белән капланган ди. Карт агачлар череп ауган, яшьләрен җил сындырган, алар берсе өстенә берсе егылып юл-сукмакларны каплаганнар ди. Алтын Мөгез уртасында авызы кирпеч белән эчләнгән җир асты юлы бар икән. Җир астының әллә кай төшләренә кереп югала икән ул юл! Үзе текә, кое кебек, имеш. Кешеләр таш ыргытып караганнар, таш югала, шактый торгач кына төпкә җитеп аваз бирә икән. Йөрәкле бәндәләр төшеп-төшеп караганнар, азрак төшүгә, тыннары бетеп, үләр хәлгә җитеп, кире чыкканнар. Җитмәсә, аста мыжлап торган кара җыланнар хәзинәне саклыйлар икән!.. Бу коедан ерак та түгел, Күчемнең корал ясый торган остаханәләре дә булган. Теге бәндә тапкан җиз бөҗра шуның ишегеннән алынган икән!

— Эчкә керә алганнармы соң?— диде теш арасыннан ысылдап Рәхмәтулла.

— Бераз кергәннәр. Ишек череп таркалган икән, тоткасы — бөҗра гына калган. Керсәләр, почмакка тимер кыршаулар суккан олы бер сандык тора икән. Кагылуга, сандык таралган да киткән, эче буп-буш икән!

— Кемдер чистарткан аны!— дип кычкырып җибәрде Рәхмәтулла.

— Бик ихтимал, бик,— диде колга һәм чүмеч белән салкын су тутырып, голт-голт итеп эчеп тә бетерде.— Авылдашны җибәрдем, очрашуыбызны кемгә дә әйтмәм! дип ант итте... Шуннан мин белешә, тикшерә башладым, борынгырак картларны эзләп таптым, үземне Мәскәүдән килгән галим дип таныттым... Тоболдан илле чакрымда Худяково авылы бар, шуның кешеләре Алтын Мөгез утравында булганнар икән дип ишеттем. Татарлар белсә дә әйтми, ханның үченнән куркалар. Теге дөньяда очрап, сакалларына ут төртер, дип шүрлиләр!.. Бардым Худяковога. Кешеләрен таптым. Башта әйтмәделәр, яхшы

гына сыйландык... Барганнар, балта-көрәкләр белән көчкә-көчкә юл ярып теге юл-коены тапканнар... Бауларын чишеп төшәргә әзерләнгәндә генә кап-карадан киенгән бер җан иясе чыгып боларның котын алган! Кирәк-яракларын чәчеп калдырып качканнар... Менә шулар сөйләде. Бу кое хәзинәгә бара торган төп юл түгел икән, керү башка урында, ә бу юл-кое җир астыннан агулы газлар, авырсы һава чыгып торсын өчен генә эшләнгән төннек икән! Менә чын юлны табасы иде! Тахтаир татарлары ялгышып кына шул ишеккә барып чыкканнар! Тоташтан корычтан койган авыр, дәү ишек ди! Йозагы җиргә тиеп тора икән... Тахтаир татарлары куркып качканнар. Алтын Мөгездә булган берничә бәндәне очраттым мин.

— Шуннан, шуннан...

— Теге авылдашым, кардәш тиешле кеше телен тыя алмаган, кайтып сөйләгән... Мине әзәрлекли башладылар, ике-өч тапкыр чак кына тотып алмадылар. Курай кабып тәүлек буе саз эчендә яттым, үпкәмә суык тидердем, өч ай буе урын өстендә аунадым, кутыр басты үземне, тавык күкәе чаклы чуан чыкты... Терелгәч, тагын Алтын Мөгезне эзләп карадым. Тагын милициягә юлыктым... Тик мин аны барыбер табачакмын! Табачакмын!

— Әкият бу! — диде көрсенеп Рәхмәтулла. Ул бу сәер кешенең акылы җиңеләя башлаганын шул әңгәмәдән генә аңлап алды.

— Түгел! Түгел! — Колга-өрәк ике кулы белән һаваны бутады. — Ахманай авылында булдым, Алтын мөгез алардан егерме чакрымда гына икән! Алар кирпеч белән эчләнгән торбаны да, аны җыланнар саклавын да бик яхшы беләләр.

Аю тырнагыннан калган җөйләрен тагын да тирәнәйтеп, хуҗаның маңгаена яңа уй ятты... «Хәзинә!»

— Нигә сөйләдең син миңа боларны?

— Беренчедән, син көчле. Икенчедән, икенчедән...

— Йә, шуннан?

— Син карун, комсыз.

Үзенең авылдагы кушаматын ят кеше авызыннан ишетеп, Рәхмәтулла башта сискәнеп китте, аннан җимерек иреннәре елмайгандай булды.

— Үзең кем?

— Шул, шул... Мин сине иптәшлеккә чакырам. Хәзинәне без бергәләшеп кенә таба алабыз!..

Ике-өч тапкыр гәпләшкәннән соң, чите китек кәгазьләрне кат-кат актарганнан соң, Рәхмәтулла белән Мишка Алтын Мөгез утравын эзләп сәфәр чыгарга булдылар. Ак күзле хатынның исән күзеннән тонык кына бер тамчы күз яше тәгәрәп чыкты, аркылы балта белән эче алынган кедр кәүсәсе күздән югалгач, ул нигәдер җиңел сулап куйды һәм, хуҗаларын озатып, ярда басып торган этләргә берәр калҗа ит ыргытты...

## 25

«Айсетдин Чырык Абдрахманга чәйгә кергән икән!» «Айсетдинне Чырык балыкка алып барган». «Икәүләшеп тора юлыннан кайтып киләләр иде...» «Айсетдин белән Чырык...»

Авылның авызы зур, бер сүз килеп керсә, талкымыйча чыгармыйлар. Дипломлы яшь укытучының гомере буе алдап-йолдап яшәгән, им-том белән көн күргән бәндәгә тагылып йөрүе ялганлыларга сәер тоелгандыр инде, югыйсә кем белән кем йөрешми, аңа артык исләре китми, ә монда Айсетдиннең Чырыкка тагылып йөрүе телгә керде. Сания кайтып сөйләде моны Мөхәммәткә. Үзе гел авыл арасында булгач, андый-мондый сүз аның колагына кагылмый калмый иде...

Саниянең иртәдән кичкә кадәр чаба торган ыгы-зыгылы көннәре

иде: өч көннән Омскига, медицина институтына җәйге сессиягә чыгып китәргә тиеш. Өй арасында эш муеннан! Иренең, улы Шамилнең һәм кызы Фаягөлнең өс-башын карыйсы бар, өйне дә ныклап җыештырыргa кирәк, авыл арасында да кереп чыгасы йортлары, киңәш-табыш итәсе авырулары бар. «Мәфтүхә апа, син калага больницага бар инде!» Язу кулдан-кулга күчә, Саниянең ягымлы сүзләреннән авыру карчык-корчыкларның да йөзенә ал йөгерә. Тегесенә дару, бусына җылы сүз, ә Чырык Абдрахманга кычыткан кирәк. Тагын им-том итә башлаган! Аның капкасын кагарга да туры килде Саниягә... Этләрен ырылдатып, йортка узды, ишекне ачты һәм түрдә тирләп-пешеп чәй эчеп утырган Айсетдинне күреп, соң дәрәҗәдә гаҗәпләнде. Сәгъдетдинне төрмәгә озаттырган, бәлаче Сәмукның якын дусты булган бу кара йөрәк белән авыл укытучысының ни якынлыгы бар?! Пар күгәрченнәр кебек гөрләшеп, чәй чөмерәләр. Саниянең ишек шакыганын да ишетмәделәр, барып кергәч, яман эш өстендә тотылган балалар кебек, кызарындылар.

Чырык дәшмәде, кашларын салындырды. Айсетдин кыбырсырга тотынды, күлмәк җиңе белән сөртә-сөртә, урындыкны керүчегә этәрде.

— Сания ханым... утырыгыз... Без менә... Абдрахман ага белән... ни... ни...

Сания, чит кеше алдында өлкән яшьтәге Абдрахманга кисәтү ясарга читенсенеп, йомыш юлын икенчегә борды.

— Ерак сәфәргә китеп барышым, Абдрахман әкә... Хәлегезне белергә кердем. Авырмыйсыздыр ла?

— Нишләп авырыйм ди? Авырырга җыенмыйм да!

— Алай да...

Кызарырга чират Саниягә житте. Ике-өч сүздән әңгәмәне шома гына тәмамлап чыгып китәргә туры килде. Әмма ул нидер сизде, нигәдер шикләнде. Айсетдинне электән дә яратмый иде, хәзер бу хисе көчәйде, ныгыды... Үзенең айдан артыкка авылдан китүен, Чырык белән Айсетдиннең авылда, ире, балалары янында каласын шикләнеп уйлады. Кедрачта булып үткән фаҗигадан соң шактый гомер узса да, шаһит Саниянең күңеле хәзер юктан да шикләнә иде инде.

Аның шулай шикчеллеген өйрәнеп өлгергән Мөхәммәтнең яңа хәбәрләргә исе китмәде.

— Утырсалар соң,— дип кенә куйды. Иренең ваемсызлыгы Саниягә ошамады, ул кабынырга әзерләнеп:

— Ничек алай «утырсалар соң!» дия аласың?— дип сорау алырга ук тотынды.

— Кырык эшең кырылып ята,— диде сабыр Мөхәммәт кызмыйча гына.— Юк-бар белән көчеңне алып, минем башны катырмасана!

Иреннән мондый сүзләр ишетеп гадәтләнмәгән Сания еламсырый башлады:

— Шул кара йөз Айсетдинне сыендырдың инде. Әллә кайчан авылдан җибәрәсе дә бит...

Сүз әллә кая кереп китә алыр иде, «Кешесен каян табасың аның?», «Кадрлар мәсьәләсендә кыенлыкны белмисеңмени?»— дип, Саниянең сүзен бердән кире кага алыр иде Мөхәммәт, әмма ул, гадәтенчә, бозау имездереп тормады, елмаеп, кулын гына селкеде. Ул арада кече яктан Фаягөл килеп чыкты, «Әнкәй, кайттыңмыни?»— дип, әнисенең кочагына атылды, әти-әнисенең чамасыз куанычы булган кыз ике араны тоташтырды, гауганы туктатты. Алар Айсетдинне, хәтәр ияртеп йөри торган Чырыкны онытып, имтиханнар турында, монда калганнар турында сөйләшә-сөйләшә, кичне җиткерделәр...

Өч көннән Мөхәммәт Санияне торага илтеп кайтты.

Сания китергән соңгы хәбәрне Мөхәммәт, бәлки, онытып да булыр иде, һич уйламаганда, көтмәгәндә Айсетдин белән Чырыкның күңеле уртаклыгы сизелде. Санияне озатып кайтканның иртәгәсендә Мөхәммәт мәктәп бакчасында урала иде. Узган язларда алар мәктәп

тирәсенә «Эссәт әкә бакчасы» утырттылар, урман ягасыннан байтак шомырт, юкәләр авыл урамына күчеп, тёрелеп, ныгып киттеләр, менә күзне иркәләп быел да яшелләнәләр. Балалар — аерата Йосыф, Сәрвәр, Маннур, Сәлимәләр — бакчаны яраттылар, иртәләрен генә түгел, кичләрен дә шунда уралалар, вакытлары буш булса, көндезләрен дә бер кереп чыгалар. Яңгыр яумый торса, су сибәләр, агач төпләрен йомшарталар, кәүсәләреннән күбәләк кортларын чүплиләр, болай кояшлы көннәрдә агач күләгәсендә ятып гәп сугарга да кереп чыккалыйлар. «Эссәт әкә бакчасы» дип атау дөрес булып чыкты, башка урыннарда шукланырга, ара-тирә бер-берсе белән чәкәләшеп алырга да яраткан егетләр, кызлар үзләре, шундый зур исем биргән бакчага кергәч, олыгаеп, җитдиләнеп калалар. Моны сизеп, Уразаев сөенеп бетә алмый.

Бүген бакча буш. Иртештә ак корт ява, малайлар балыкка киткәннәрдер. Мөхәммәткә дә төшәргә кирәк иде, әмма нигәдер аягы тартмады, ул иртән балаларны ашатты да Эссәт бакчасына юл тотты. Саниянең укуы сөенеч булса да, аерым тору олыгаеп барган ир өчен көенеч иде. Гадәтләнгән тормыш үзгәрә, ашау-эчү ягын да үзең карарга тиеш, авыл арасында да эш бетми. Кызу эш өстендә укучылар да, укытучылар да колхоз кырыннан кайтып кермиләр.

Эссәт юк, Сәгъдетдин ерак җирләрдә Ак диңгез — Балтыйк каналын казый... Аның азат итүләрен сорап, Михаил Иванович Калининга ике тапкыр хат язды инде Уразаев, җавап һаман юк, өченче кат язып караргамы әллә?.. Ах, Иосиф Белкин исән булса! Әллә кайларда яшеренеп ятса да, хаклыкны казып чыгарыр иде!

Кайчан, ничек шулай шыпырт килеп житкәндер, Мөхәммәт кыштырдаган тавышка борылып караса, үзеннән ерак та түгел яшь юкә төбендә Айсетдин басып тора. Башында кардай ак фуражка, өстендә ап-ак җитен костюм-чалбар, аягындагы ак ботинкага да кер кунарга өлгермәгән. Кияү егете диярсең!

Фуражкасын чак кына калкытып сәлам бирде дә Айсетдин берике атлап куйды. Утырмады, бер җиргә, бер ак чалбарына карап тынлып калды, китмәде, сүзе бар икәне чыраена чыккан иде.

— Эссе бүген,— диде ул.

— Эссе,— дип хуплады Мөхәммәт.

— Нигә балыкта түгел?

— Ә үзең?

— Балык ашамыйм мин. Һич күнегә алмыйм...

Уразаев җавап кайтармады, монда Эссәт бакчасында нинди уйлар белән утыруын иптәшенә сиздерәсе килмәде. Кинәт:

— Чырыктан кайтып килешме?— дип сорады.

Капылт атылган укның туры тиюеннән Айсетдин сискәнеп алды.

— Шуннан...

— Алай,— дип сузды Уразаев.

Ниһаять, Айсетдин йөрәксенде, җиргә ак кулъяулыгын җәеп, Мөхәммәт янына килеп утырды.

— Нигә яратмыйсыз сез аны?

— Бал түгел ич ул, яратырга... Кәреш балыгы да түгел.

— Алай да ул күпне белә...

— Мәсәлән...

— Бүген шундый хәлләрне сөйләде, исең китәр...

— Чырыкта әкият бетмәс. Кирәк дисә, үзеннән дә чыгара ул.

— Нинди әкият булсын! Ахманай авылы кешеләрен үзе күргән. Алтын Мөгез турында шулардан ишеткән! Алтын Мөгез утравы аларга якын гына икән!..

— Тукта, тукта! Алтын Мөгез дисеңме?

— Әйе, Алтын Мөгез. Күчем ханның бар байлыгы шунда яшерелгән икән.

Уразаевның элегрәк тә Күчем ханның алтын-көмешләре турында ишеткәне бар иде. Партизанда йөргәндә дә әкият итеп сөйлиләр иде ул хакта. Әллә Мөкә бай авызыннан да ишеткәне бар идеме? Ә-ә, әйе бит, Миңлекалыш: «Безнең этидә Күчем хан байлыгы бар, бер дә Алтын Мөгез хәзинәсеннән ким түгел!» — дип әйтә иде түгелме соң?!

Уйлары чәчелеп, әллә кайларга кереп китте. Айсетдин исә Чырыктан ишеткәннәрен, бераз өстәп, чак кына арттырып һәм бизәп һаман сөйләп тора иде.

— Кирпеч белән эчләгән кое авызында кара җыланнар мыжлап тора икән. Хәзинәне саклау җыланнарга нәселдән-нәселгә күчә ди... Ахманай авылы кешеләре барып караганнар, җылан телен белмиләр икән! Җылан телен белер өчен йөз яшьтән узарга кирәк икән. Менә Абдрахман әкә йөздән дә ары яшәргә тели. Шул чагында Алтын Мөгез хәзинәсе минеке була, ди...

Уразаев уйларын бүлеп көлеп куйды:

— Йөздән дә ашып яшәргәме нияте?

— Хәзинәгә хуҗа булырга теләсәң, ике йөзне дә яшәрсең!

Айсетдиннең бу хикмәтле әкиятләренә тулысынча ышанганы күренеп тора, әкият сатарга оста Чырыкка тәмам гашыйк булып кайткан иде егет. Димәк, авыл арасында аларның якынлыгы турында юкка гына гәп куертмыйлар. Айсетдиннең юк-барга, хорафатларга ышангалавы, ашаганнан соң кеше күрмәгәндә генә «әппәр» итеп куюы Мөхәммәткә бик мәгълүм, инде Сәмук кулга төшеп, Эссәт әкә кабере өстендә «кемнең ут уйнатканы» һәркемгә ачык булса да, Айсетдин, авыл арасында таралган гайбәткә ияреп, һаман шиген бетермәде. «Юк, юк! Беренчесендә ут гүрдән чыккан!» — дип, Мөхәммәткә үз авызыннан ишеттерде.

«Димәк, кулында диплом булса да, күңелендә икеләнү, акылында житлекмәгәнлек!» — дип ачынып уйлады Уразаев.

— Күчем хан хәзинәсенә ия булырга дип, синең дә йөздән ары яшәргә ниятең бармы?

— Сез гел уенга аласыз, Мөхәммәт ага! — диде нык җәберсенеп егет. — Ә мин житди сүз сөйлим...

Һәм ул, авылда көннән-көн ныграк йөргән күп санлы хәбәрләргә таянып, Мөхәммәтне ышандырырга тырышты, тегесе ышанмагач, гарьләнеп ызгыша ук башлады.

Чыннан да, Ялан авылы гөр килеп тора иде.

Авыл гайбәтен иң күбе кем тарата? Әби-сәбиләр, хатын-кызлар түгел, хәбәргә тизлек бирүче балалар, үсмерләр! Балалар теленә кергән хәбәр йокламый инде, ул һәрвакыт уяу, көзен агачтан-агачка сикергән тиен кебек телдән-телгә сикергәләп кенә йөри, йокымсыраган колакларга туп-туры барып керә. Сүзләрнең ишәюе, аларның Уразаев өчен ифрат кадерле Эссәт әкә исеменә кара яулык булып уралуы Мөхәммәт Уразаевны соң дәрәҗәдә рәнҗетә, җәберли иде. Утыз авызны бияләй тыгып томалап булмый, инде авыл тоташтан гайбәткә, имеш-мимешләргә уралган икән, монда нииндидер үткен бер чарасын табарга гына кала.

Нишләргә? Ни кылырга? Айсетдин укытучыны ничек акылга китерергә дә, моңарчы әйбәт кенә ныгып килгән укучыларны, мәктәпнең абруен каты ялгышлардан ничек коткарырга?

Иң гаҗәбе — Мөхәммәт Уразаевның үз күңеленә дә икеле-микеле уйлар килеп киткәли иде...

Күчем хан булганмы? Булган! Хан булган, тегенди-мондый кеше генә түгел, Алтын-көмеш чыга торган чокырлары булмаса да, казнасы бөтенләй үк буш тормагандыр әле! Читтән килгән яулар да казнаның төбенә үк төшеп җитә алмаганнардыр... Кайдадыр, нидер сакланып калган булса? Сызгырып-ыжгырап торган еланнар, төпсез мәкерле коелар кызыклы бер әкият-йомак кына булса да, сүзнең

төбендә реаль хәлләр урын алганнардыр, мөгаен?

Фу!..

Мөхәммәт Уразаев ярты төндә сискәнеп уяна да, юеш маңгаен ышкып, сыек шәүләләр уйнаган түшәмгә карап ята. Кайдадыр еракта яшенле яңгыр ява ахрысы, монда кадәр әнә шул сыек шәүләләр белән кинәт-кинәт калкынып куйган җиле генә килеп житә. Мөхәммәтнең тынгысыз җаны икегә ярылып тарткалаша башлый. «Юк, юк!— дип йолыккалый беренче яртысы.— Үзең коммунист, үзең укытучы, авылда аң-белемгә өндәүче зат, әби-сәбиләр әкиятенә баш биреп, җебеп төштең!» Ә икенче яртысы, күләгәдәгесе, читтән генә карап аны үчекли: «Ә булса? Черек сандыклар арасында алтын-көмеш саклана?.. Сез, шуны табып алып совет хөкүмәтенә тапшырсагыз?»

Һәм Мөхәммәт Уразаев Күчем хан хәзинәсен эзләргә поход оештырырга карар кылды. Әлбәттә, бу эшне хатыны өйдә юкта. Сания җәйге сессиягә имтиханнар тапшырырга Омскига киткәч кенә башкарып була иде. Беренчедән, Сания нәни кызы Фаягөлне бүтән кешедә калдырырга риза булмаячак (әнкәсе соңгы елларда саулыкка туймый башлады, аның үзен карарга кеше кирәк!), икенчедән, күпне күргән, күпне кичергән хатын ирен ирекле баштан хәтәр сәфәргә чыгарып җибәрмәячәк. Иртеш-Тобол тирәсендә болай да имеш-мимешләр байтак йөри, урманнарда качкыннар һаман бетмәгән икән, фәлән авыл көтүчеләре шикле бәндәләрне абайлап калган, фәлән авылда кемнеңдер сарык-казларын урлап суйганнар, дигән шикле хәбәрләр анда да, монда да гел кабынып, көйрәп тора иде.

Уйлаганыннан кире кайта торган кеше түгел иде Уразаев, Саниясен торага кадәр озатып барды да, кайта-кайтышлый Айсетдин яшәгән фатирга кагылды. Мөхәммәтнең беренче сүзеннән үк куркып-каушап төшкән яшь укытучыга тын алырга да ирек бирмәде: «Поход оештырабыз, комсомолларны җыябыз, имеш-мимешләргә чик куябыз, дөрес икән хәбәр — раслыйбыз, ялган икән — ачыклыйбыз!»— дип, сүзне ифрат кискен китереп куйды. Нишләсен, җиңелдә Айсетдин, тотлыга-тотлыга, кара тиргә батып, Уразаевка ризалыгын бирде, агарып-күгәренеп:

— Кайчан?— дип сорады.

— Ике көннән!— диде Мөхәммәт.

Тагын бер, үзе генә белгән максаты да бар иде өлкәнәеп килгән укытучының... Ул, шушы Ялан авылына кайтып, мәктәп ачып җибәрде, ничә айлар берүзе укытып йөрде. Белеме дә, әзерлеге дә чамалы иде югыйсә, күңелен төшермәде, бирешмәде, җәйләрен курсларга барды, кочак-кочак китап төяп кайтты, төннәрен аның тәрәзәсендә ут сүнмәде диярлек. Башта мәктәп башлангыч класслардан иде, тора-бара Яланда тулы булмаган урта мәктәп — ТБУМ ачылды, төрле яклардан укытучылар килде, берәүләре шунда ныгып калды, өйләнде, кияүгә чыкты, Ялан кешесенә әйләнде. Берәүләр «җәһәннәм астындагы авыл»ны сөймичә, күңелләрен әсәрендереп, мәктәпне ташлап киттеләр. Хәзер авылда тәүгеләрдән Мөхәммәт Уразаев белән Айсетдин генә калды. Укучыларның да күпчелеге кайсы кая таралды. Берәүләрне Якты Күл авылындагы ШКМга үзе илтеп урнаштырды Уразаев, берничә кеше Тобольскида педтехникумда белем алалар, Шамил Төмәнгә пединститутка укырга керде, Уразаев ярдәме белән Мәүлия дә шунда урнашты. Йосыф та студент.

Җәйләрен авылга кайтып, каникул көннәренең күпчелеген Яланда үткәрсәләр дә, беренче укучыларын сирәк күрә хәзер Мөхәммәт Уразаев, сирәк күргән саен ешрак очрашасы килә, Шамилен сагына, Мәүлиясен, Йосыфны уйлап тилмерә... Ятим бала, тормышы ничек икән, ашауэчүе, кием-салымы... Кичен, көндәлек эшләр тәмамланып, арган гәүдәсенә йокы кереп маташкан мизгелләрдә ул күңел күзе аша бик күп кешеләрне үткәрә. Ләкин аралар ераклашкан, күрешүләр сирәк, яшь-

ләр ел саен үзгәреп, яңарып, олыгаеп кайталар, элеккеге укытучылары белән сөйләшү-аңлашу укытучыга елдан-ел кыенлаша бара.

Менә шул Күчем хан хәзинәсенә сәяхәткә ул үзенең беренче укучыларын да чакырырга ниятләп куйган иде. Күрсеннәр бер-берсен, күрсәтсеннәр үзләрен...

Тәвәккәлләгән — таш йоткан, студентлар Мөхәммәт абыйларының тәкъдимен «ур-ра!» кычкырып каршыладылар. Башта кызларны ияртмәскәрәк ниятләп икеләнеп торганнар иде. Мәүлия белән Сәлимә, балалар кебек турсаеп, еларга житешеп сукрана башлагач, Уразаев, аркаларыннан кагып, аларны тынычландырды, кызларның да барасын белгәч, егетләр алардан битәр сөенештеләр, биеп үк жибәрделәр. Бигрәк тә Шамил сөенде, бу да Мөхәммәтнең тәжрибәле күзләреннән читтә калмады...

Мәүлия, этиләре белән Обдорскига барып, ел ярым чамасы гына яшәде. Йомабикә абыстай, тизгә генә авылга кайтып, кызын ерак кардәшләрендә калдырып китте. Мөхәммәт Уразаев янына да ашыгып-каударланып кына кереп чыкты. «Ичмасам соңгы елларында элек укыган мәктәбендә булсын иде!»— диде ул, ишек катына баскан килеш кенә. Мөхәммәт ул чагында, әдәп саклап, юл мәшәкатьләрен, каладагы тормыш хәлләрен сорашмакчы иде, Йомабикә сүзне кыска тотты, бер-ике авыз сүз белән көнкүрешен сөйләп бирде дә жәһәт кенә борылып чыгып та китте. Алай да ишек катында тукталып борылып карады, нечкә генә жыерчыклар йөгергән күз төбеннән ике бөртек болганчык яше кысылып чыккан иде.

Бу очрашудан нигәдер әнә шул ике тамчы яшь аерата күңелдә калды...

Мәүлиянең авыл-күрше күз алдыннан югалып торуы, бер яктан караганда, бәхет булган иде. Үзе юк чакта сүзе дә булмады, Мөхәммәтнең Ырсытдин хатыны белән булган яшьлек «мажараларын» Ялан авылы оныта да башлаган иде. Мәүлия кайтты, сүз дә аңа ияргән иде, чөнки кыз үскән, житкән саен һаман Мөхәммәт Уразаевка ныграк охшый бара иде.

Иң хәвефлесе, Мөхәммәтне иң куркытканы алдарак булып чыкты һәм ул күңелсезлек һич көтмәгән, уйламаган яктан килеп чыкты.

Яштән үк Мәүлия белән Шамилнең бер-берсенә дусларча житди караш ташлап-ташлап алуларын Мөхәммәт сизенеп йөри иде... Икесе бер тирәдә урнашып укый башлагач, бу арадашлыкның тагын да тирәнгәрәк кереп китүеннән курыкса да, ул Шамилне Мәүлиядән аерып алырга ашыкмады, яшь күңелләргә ялгыш кагылып китеп, аларга җуелмас хәсрәт китерүдән курыкты. Мәүлиянең акылына, улының сабырлыгына да ышана иде ул...

Менә бу сәфәр улы белән Мәүлия арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыкларга да ярдәм итәргә тиеш!

Мәүлиянең дә кызыклы ерак сәфәргә катнашасын ишеткәч, Шамилнең чамасыз шатланганын сизгер жанлы ата гына түгел, бүтәннәр дә сизенде. Урам яңгыратып, тиктомалга кычкырып көлә башлаган егет шып тыелды, кызарынып, әтисенә карады?

— Ялгыш сүз әйттемме әллә?— дип сорады.

— Юк, улым,— дип, аны тынычландырырга тырышты Мөхәммәт.

Иртәнге караңгылы-яктылыда мәктәп янына жыйналдылар. Төнге йокысызлыктан арганлыгын жиңәр өчен Иртештә су кереп менгән Уразаев, гимнастеркасын киеп, билен киң каеш белән буып алгач, бөтенләй яшәреп киткән, аның күңеле күтәренке икәнлеген бүтәннәр дә карап торырлык. Кызлар кочаклашып күрештеләр, егетләр исә бер-берсенең иңнәреннән төеп алдылар. Төрлесе төрле вакытта авылга кайтып төшкәнгә, аларның юньләп күрешә алганнары да юк иде әле. Студентны авылда ял түгел, күп очракта эш, мәшәкать көтә!

Айсетдин белән Маннурны гына шактый озак көттеләр, балкып кояш чыкты, тегеләр күренмәде. Йокы ярәткан мөгаллим янына Уразаев үзе китте, тегене печәнлектә изрәп йоклап яткан жиреннән уятып, кыдырып юл башына алып килде. Алар, шәп-шәп атлап, мәктәп янына барып житкәндә, тыкрыктан елаган тавыш ишетелде, чаттан Маннурны алырга киткән егетләр-кызлар бөселеп чыкты, аларга елый-елый Маннур ияргән, иң арттан теркелдәүче Рәукыя түти улының күлмәгенә чытырдатып ябышкан иде.

Елап килүче егетне күреп, Айсетдин төкеренеп алды:

— Бу нинди әкият тагын?

Маннур туктаусыз: «Барам дигәч барам!»— дип такмаклый, Рәукыя түти: «Жибәрмим дигәч жибәрмим!»— дип кабатлый. Көтү куарга халык кузгалганчы авылдан чыгып өлгерергә кирәк иде. Тоболга кадәр атта озатучы Дәүләтша әкә дә ашыгадыр, әнә кешеләр уянып чыгалар, анда да, монда да капкалар шыгырдый, ә Маннур белән әнкәсе һаман тарткалашалар. Чыннан да, әкият!

— Нигә алай карышасы иттең әле, Рәукыя түти?— дип гажәпсенеп сорады Мөхәммәт.

Бүтән чакта мөгаллим каршысында әдәп саклап, телен тыеп йөргән түти бүген аңа март ата казы сыман очып кунды.

— Анда барып, улымны елан чаксынмы? Убырга азык булсынмы аның тәне? Баламнан мәхрүм калыйммы? Дәжжал мәлгунь тынына туры килеп, гарип калсынмы?

Китте тезеп, китте тезеп, чыда гына!

Менә авылда нинди хәбәрләр таралган икән!

Ул арада Маннур, үзенең инде аттан биек булып үсеп житкәнен сиздерергә теләгәндәй, Сәрвәр белән Мәүлиягә күз кысып өлгерде. Йосыфка иелә төшеп пышылдады: «Я, ничек? Шәп жыладыммы? Ышанырлык булдымы?»— дип сорады. Балачактан әнисен елап кына жинә алган Маннур хәзер дә шулай шаярткалап ала икәнен Мөхәммәт тә, бүтәннәр дә тиз аңладылар, озак үгетләшеп торырга вакыт калмады. Мөхәммәт ике-өч сүз белән Рәукыя түтигә нинди максат белән юлга чыгуларын аңлатып бирде, юлның тәмам хәвефсезлегенә ышандырып өлгерде.

— «Хәзинә!»— дигәнне ишетүгә, Рәукыя түтинең колагы үрә торды, ул Маннурын йолыккалап бер читкә алып китте.

— Әгәр шунда кадәр барып, чулпыма тагарга алтын-көмеш таңкә алып кайтмасаң, өйгә кертмим, бел,— дип ныгытып та өлгерде. Әлерәк кенә усаллык шиге белән янган кысынкы күзләрендә теләктәшлек уты кабынды.

Тизрәк юлга чыгарга кирәк, арба тирәсен әби-сәбиләр сырып алды. Рәукыя түти, үзенең күп белүенә сөенеп, шуны күрсәтергә форсат барына шатланып, жыелганнарга, кычкырып-кычкырып, нидер сөйләргә керешге. Кузгалдылар.

Өчаяклар, кашык-аяк, жылырак өс киемнәре (сазлыкта төннең нинди булуын кем белми?!), балта-пычкылар, ризык-мазар тутырган арбага юлаучылар сыймадылар. Дилбегәсен ике куллап тотып, юка иреннәрен очлайтып чөмгерә-чөмгерә кола алашага дәрт өстәп барган юка Дәүләтша әкә янына кызлар гына менеп утырды. Малайлар алар янына үрмәләгән иде дә, Мөхәммәт абыйлары белән кырыс, сүзсез Айсетдиннең жәяүләгәнен күреп, алар да шыбырдап юлга коелдылар, өлкән абыйларга охшарга тырышып, кулларын артка кушлап, такыр юлдан әле ашыгып чабып, әле акрын гына атлап, чакрым санап бара башладылар. Болай ишле итеп сәфәр чыгулары беренче мәртәбә иде. Һәммәсе төрле-төрле уй йомгагын сүтәләр дә тагын бер серле эзгә төшәләр: ни көтә аларны алда? Зурлыкмы, хурлыкмы?.. Берни очрата алмыйча, берни тапмыйча, адәм көлкесенә калып кайтырлармы сәфәрдән? Айсетдин шулай гына уйлый. Әллә ни булса да табарлармы?..

Уразаев шулай өметләнә. Кызлар хәзинә табыласына ышаналар. Мөхәммәт абыйлары янәшәдә чакта тапмый калалармы соң?! Малайлар күңелендә уй бер генә: ничегрәк итеп хәзинәдән өйләренә өлеш алып кайту! Рәукыя апаның Маннурга биреп калган боерыгы бөтенесенең дә күңелен кузгатты. Әнкәләренә берәр генә алтын тәңкә алып кайтып бирә алсалармы?.. Һи-и, күңелле дә булачак. Алтын тәңкә бигрәк тә Йосыфка кирәк. Аның әнисе Казан ягыннан килгән, ул як хатыннары алтын-көмеш тәкыяләрнең тәмен беләләр, беләккә беләзек, бармакларга алтын балдак киеп йөриләр икән! Әнкәсенең сокланып, сагынып сөйләгәнен аның әллә ничә тапкыр ишеткәне бар... Ә хәзер әнкәсенең күңеле боек, ник боек булмасын, бер дә гаепсезгә ирен төрмәгә утыртып кайтарсыннар әле! Сәгъдетдин «Алла боерса, озакламам, кайтырмын»,— дип хат яза язуын. «Ристан язмышын хак тәгалә үзе дә белә алмый!»— дип кабатлый әнкәсе, әллә кайта, әллә юк әле, ә алтын тәңкә табып кайта алса, әнкәсенең күңеле күтәрелер!.. Тизрәк барып җитәсе иде дә, Күчем хан базарына чумып, бакыр йозаклы сандыкларны каерып ачасы иде. «Хәзинә — дәүләтнеке!»— ди Уразаев абыйлары, сансыз-исәпсез байлыктан бер-ике алтын тәңкә алалар икән, аннан кемгә ни зыян?.. Яхшылык белән бирмәсәләр, Йосыф әнкәсе өчен алтын тәңкәләрне урларга да әзер!.. Әнкәсенең күңеле күтәрелсен дә, кичләрен кояш баешына карап елап-такмаклап утырмасын...

Шәһәргә төш авышкач кына килеп җиттеләр, кереп тормадылар. Дәүләтша әкәне, рәхмәт әйтеп, үз юлына озаткач, сәфәрчеләр шәһәр янындагы бер әрәмәдә куна калдылар. Иртәгә таңнан Ахманай авылына барып җитәргә иде исәпләре.

## 26

Рәхмәтулланың болай да күп сөйләшкән чагы булмады, соңгы елларда телен тешләп кенә йөрде, инде хәзер, Тобол якларына кайтып төшкәч, бөтенләй сөйләшмәс булды. Нишлисең, туган яклар... Моны эшләрмен, болай булырмын, дип куанып йөргән җирләр... Җаны катып, үзәге череп бетсә дә, кайдадыр шушы якларны сагыну, шушы якларны ярату дәрте калган икән әле. Тәмам явыз кукял бүрегә әйләнеп бетсә дә, «күңеленең бер почмагында җылылык сүнмәгән икән! Аның улап, үкереп елап, шушы җылыкай якын җиргә лып капланасы, хуш ис аңкып торган куе үләннәрне күпме кешенең җанын кыйган кулы белән сыйпыйсы, кәкрәеп каткан, бирчәйгән тырнаксыз бармаклары белән гөлчәчәкләрне аралый-аралый үксеп елыйсы килде. Юлдашыннан яхшысынмады. Олы эшкә тәвәккәлләгәндә, йомшаклыкны күрсәтергә ярамый, колгасар Миша, Тоболга якынайган саен, Рәхмәтуллага текәлебрәк карый башлады, сүзен санга сукмаска тырышты, һәр адымда үз өстенлеген искәртергә ашыкты. «Шикләнә!»— дип усалланды Рәхмәтулла һәм ертык иреннәре белән елмайгандай итте: «Курка! Язуларны тартып алып, хәзинәне үзе генә табар дип шикләнә».

Дөресен әйткәндә, Рәхмәтулла тегендә, мүкле күл янындагы тәбәнәк йортта «Хәзинә, хәзинә!»— дип ярсыса да, монда килеп җиткәч, кача-поса үткәргән төннәрдә аның күңеленә яңа бер акыл иңде: «Ни-нәрсәгә миңа Күчем хан алтыннары?!— дип өзгәләнде ул.— Минем үз алтыным азмы?»

Бар иде. Рәхмәтулланың үзе генә белгән караңгы куышларда әле байтак малы саклана иде, алтын-көмеш тәңкәләр, кием-салым, кешмал тиреләре, төлке туннар, бизәнү әйберләре, йөзек-беләзекләр, тагын әллә нәрсәләре бар иде әле Рәхмәтулланың. Төрле-төрле патшаларның күкрәк киереп торган рәсемнәре басылган йөзекләре байтак иде аның, әмма Рәхмәтулла җүләр түгел, кыштырдавык кәгазьләрнең черек мунчалага әйләнүен ул хәзер яхшы аңлый, туннар, тиреләр дә әллә исән, әллә юк, мәгәр алтын-көмешләре саклана! Аларына пычак та булмый!

«Яхшы көнгә!»— дип яшереп куеп, киләчәккә дип саклый иде ул аларны.

Яшәгән саен, бу сүзләрнең мәгънәсе үзгәрә, тоныклана, элек күңелне жылыткан сүзләрнең мәгънәсезлеге генә кала бирә... «Яхшы көн»... «киләчәк»... Кайда алар? Бармы? Ичмасам берсе дә юк, өмет күптән өзелгән. Күчем хан хәзинәсен генә түгел, дөньяның бар байлыгын аның амбарына китереп өйсәләр дә, Рәхмәтуллага ни файда? Кайтачакмы аның егәре, төсе, саулыгы?! Берсе дә юк, дөнья фани, аның байлыгы — дуңгыз каны...

Күчем хан хәзинәсенә омтылу түгел, кылган гөнаһлары тартып кайтардымы әллә бүрегә әверелгән бу явызны? Койган кан авазы? Әҗәле чакырып китердеме әллә аны?.. Әллә шушы җирне үлеп сагынумы?

Колгасар Миша хәзер аннан күзен алмый, гел күзәтә, бер алдына, биш артына карый, югыйсә, ул булмаса, ялгыз калса, Рәхмәтулла җир тырный-тырный рәхәтләнеп бер елар иде...

Михаил Сорокин, элгәредә көяз ак офицер, баритон белән опера арияләрен җырлап, дәртле кызларның һушын алып яшәгән кеше, хәзерендә колгасар ябык адәм бер дә юкка шикләнә юлдашы Рәхмәтулладан! Хәзер аңа берни хаҗәт түгел, аның күңеле сүрән, бер дә кирәкмәгәнгә хәзинә кыдырып чыгуына ул хәзер үкенә дип әйтерлек. «Үз өемдә генә ятсамчы!»— дип, җан кыеп арган күңеле өзгәләнә, төшләрнең иң яманы кереп аны җәфалый, интектерә иде. Бер бәйләнгәч үз язмышына карыша алмый, карышырлык хәле юк, алдына куйсалар тыгына-тыгына ашый, бирсәләр, йотлыга-йотлыга уттай чәй эчә, бугаз төене ябык муенына сыя алмыйча пычкы яручы терсәге кебек гел йөреп тора, ятса йоклый, яман үкереп гырлый, саташып акырып җибәрә, төн карасыннан куркып сикереп тора. Бер таңда, сикереп торып, Мишаның бугазын эләктереп алды, ирен читеннән күбекләнеп, канлы сөләгәй акты, юлдашы — каян көч килгәндер арык колгасарга — Рәхмәтулланы, бер селтәнеп, әллә кая чөеп җибәрде.

— Уйнама минем белән!— дип пышылдады Сорокин.— Шаярма!

— Кичер... Яман төш күрдем.

— Нинди төш тагын?— Миша авырткан бугазын ышкыды.

— Бер адәмне очратканмын икән дим.

— Нинди адәм? Тереме, үлеме?

— Кем белгән анысын... Үле булса шәбрәк тә...

Бүре Рәхмәтулла төшендә Мөхәммәт Уразаевны күргән иде.

* * *

Алар да Тоболга кагылып тормадылар: «Сагынып торучылар юктыр, мөгаен!»— диде саргылт тешләрен ыржайтып Сорокин. «Ахманайдан кеше алыйк, юкса сазлыкта адашып харап булырбыз!»— диде Рәхмәтулла, Сорокин ризалашмады. «Артык кеше — артык өлеш!— дип кырт кисте.— Миңа бер имгәк тә җиткән».

«Имгәк» сүзе Рәхмәтулланың күңелен җәрәхәтләп-тырмап узса да, ул аны-моны белдермәде, «Югалырбыз без!»— дип кенә куйды.

— Ә син югалма! Моңарчы яшәгәнне, байлык-хәзинә тешеңне сындырып керәм дип торганда югалалармы? Хәзинәне табабыз, кап урталай бүләбез, сыендырганың өчен рәхмәтле буласым килә, аннан Урта Азия шәһәрләренә кереп югалырбыз. Син мине белмисең, мин — сине! Буламы?

Михаил Сорокин киләчәкне алсуга манып, гөлгә төреп, юлдашын алга өндәсә дә, Рәхмәтулла күкял бүре атлаган саен караңгырак чокырга төшкән кебек хис итә иде.

Бүген кояш чыкмыйча интектерде. Алар көндәгечә ут тергезеп тә тормадылар, чишмәгә ятып, салкын су эчтеләр, каклаган кәреш белән елкы маен ашадылар да, Алтын Мөгез утравының кай тирәдә булырга тиешлеген чамалап, барыр юлларын билгеләделәр.

— Ничек табарбыз без аны?— диде һаман шигәеп Рәхмәтулла.

— Көндез кояшка багып, төнлә ай-йолдызларга карап,— диде Сорокин.

Алда шомлы, куе һәм серле урман ишелеп ята иде. Урман — качкыннар бәхете, шундый карурманнар булмаса, Рәхмәтулланың аяк сөякләре әллә кайчан череп таралыр иде. Ә ул исән, ул туган җирендә дип әйтерлек, хәзинә эзләп, юлдашы артыннан калмаска тырышып, борын яфракларын киереп еш-еш сулап, иске сукмак өстенә аркылы-торкылы яткан ботак-сатакларга абына-сөртенә бара... Әллә язмышы чыннан да бер елмаерга уйлыймы аның? Алтын тәяп, казах-үзбәк арасына барып чыгып, соңгы гомерен рәхәттә үткәрә алырмы?

Әйләнеп-тулганып йөри-йөри, кайда эз яшереп, кайда урмандагы төрле куе исләрдән миңгерәүләнеп бара-бара, кичне җиткерделәр. Тәмам хәлдән тайдылар. Рәхмәтулланың киемнәре әллә ничә җирдән умырылып чыкты, сул аягы чокырга төшеп китеп каймыкты, авыз эче шытырдап кипте, теле аңкавына ябышты, әмма ул дәшмәде, зарланмады, иптәшеннән калмаска, адашмаска тырышып барды да барды. Хәзер алар бергә төйнәлгәннәр иде, калдың исә — беттең. Әңгер-меңгердә Сорокин маңгаена төшеп сибелгән юеш чәчләрен бер якка сыпырып куйды да түгәрәк алан уртасына кереп тукталды. Уңга атлады, сулга, артына чикте һәм җиргә аягы белән басып-басып карады, урманның аръягыннан вак чытырман куаклар, тирбәлеп торган сазлыклар башлана икән. Сорокин атлам-атлам йөреп үлчәде дә кинәт:

— Монда!— дип куйды.

— Күчем хан алтыннарымы?— диде Рәхмәтулла тез башларын уып.

— Хәзер күрерсең.

Миша аланның коры ягына үтте, ботак арасына кыстырып куйган, сабы чери башлаган күгәргән тимер көрәк тартып чыгарды, юеш чәчләрен кул аркасы белән сыпырды да, бөкрәеп, тиз-тиз казый башлады. Дымлы, кара җирдән чери башлаган пычрак агач тартма сөйрәп чыгарды. Тартмага ияреп, черегән чүпрәк кисәкләре дә өскә менде, борынга авырсу ис килеп бөркелде. Тартма бер-ике сугуга таралды, эчтән нык майланган чүпрәк төен, төен эченнән запас патроннары белән наган килеп чыкты. Наганны тотып карауга Миша Сорокин кинәт үзгәрде, гәүдәсе турайды, чәбәләнгән сирәк кашлары астыннан әлек барлыгы да юньләп беленмәгән елтыр, усал күзләр килеп чыкты.

— Нәрсәгә бу?— дип сорады Рәхмәтулла бөрешеп каткан иреннәрен төкереге белән юешләп.

— Киек атарга!— Сорокин, аланны яңгыратып, яшьләрчә җиңеллек белән көлеп җибәрде. Колгасар юлдашының көлүен беренче мәртәбә ишеткәч, Рәхмәтулла аңа гаҗәпсенеп карады, көлү тавышы ничектер эчтән, корсактан, үпкә-үңәчләр яныннан араланып чыга кебек тоелды — Эх син, чабата! Хәзинә артыннан йөрүчеләр бер син генә дип беләсеңме? Хәзинә һәркемгә кирәк. Көндәшләр очрый калса... момент юк итәбез!

Соңарып кына учак тергезделәр, ботаклар чи, утын дымлы иде, учак, кабына алмыйча, ачы ис чыгарып шактый чожлап утырды. Сүрән яктылыкка яны белән ятып, Миша Сорокин наганын чистарта башлады, аның хәрәкәтләре җитез, бармакларына күз иярми иде.

Рәхмәтулла шул сәгатьтән сәфәрдәге үз урынын бик ачык билгеләде: ул — кол, хезмәтче, хуҗа кулында корал бар, «ят!» дисә — ятасың, «йөгер!» дип боерса, йөгерек куянны куып тотарсың...

Дымлы җирдә иске кожанга уралып яткан Рәхмәтулла шомланып уйланды: «Нинди көндәшләр ди тагын? Каян килсеннәр алар, әкият! Хәер, бетәрмени безнең кебек саташып йөрүчеләр карурманда?»

Аның күз алдына явыз Капуш килеп китте. Ул кансыз бәндә кайда, кем үстергән ипине ашый икән? Ашыгып-ашыгып ай батты, агач башларыннан йомшак җил йөгерде, Рәхмәтулла, белгән догаларын укып, җанын җиңеләйтергә теләде, әмма күңеленә бер генә китап сүзе дә килмәде.

әлхәм сүрәсе дә онытылган, колһуалла да, бисмилланың да азагы барып чыкмады. Ул, ыңгырашып ята торгач, тирән чокырга чумды. Төшендә тагын Мөхәммәт Уразаевны күрде. Яшел френч, яшькелт галәфи чалбар киеп, аякларын киң ерып баскан да аңа карап тора. Кулында наган. Уйната гына наганның көпшәсен тегенең борын төбендә! Һич тынгы бирми! Ул дерт итеп уянып китте. Учак сүнгән, көл арасыннан жил үтеп киткәндә генә утлы күмерләр тимгел-тимгел яктыралар. Ул терсәкләренә таянып калкынды да юлдашына карады. Миша учак көлен бер якка эшереп жылы жиргә чалкан яткан, авызы әрлән тишеге булып ачылган, ачык авыздан сыеша алмыйча әллә нинди яман авазлар ышкылып чыга иде, гырлый, наганын сул учына кысып тоткан, уң кулы бизмән башы булып йомарланган.

Чир китә, гадәт кала, диләр. Рәхмәтулла кинәт айныды, йокысы качты, ул ә дигәнче үрмәләп барып житте, тезе утлы күмергә туры килеп пешсә дә, тукталып тормады, барып житеп, Мишаның наган сабын йомарлаган бармакларын берәм-берәм яза башлады. Миша уянды, торып утырды, сул кулы белән күз төбен уып як-ягына каранды.

— Нәрсә бар? Һаман шаярасыңмы?

— Юк ла!— диде карлыгып Рәхмәтулла.— Тыңла әле!

— Берни дә юк ич!— диде ачуланып Миша.

— Кемдер йөри... Аюмы?

Аның бәхетенә, чытырман арасында ботак шартлап сынды, югыйсә, котырган Миша аны шул мизгелдә үк юк итәчәк иде, хәзер ул котылып кала алачак. Рәхмәт тавыш иясенә!

Алар дәррәү сикереп тордылар, колакларын тавыш килгән якка куеп, тын тартырга да базмыйча тыңлый башладылар. Тавыш кабатланды, ботак сынды, кемдер, жан иясе, лыпыр-лыпыр атлап, алардан читкә таба китеп бара иде.

## 27

Аяк тавышлары аюныкы түгел, Ахманай авылы кешесе Закир агайныкы иде. Закир Алтын Мөгез утравын яхшы белә икән, яшьрәк чакта баргалап та йөргән, мәгәр андагы хәзинә турындагы сүзләрне чеп-чи әкият итеп кенә саный иде. Алай да олы кеше, мөгаллим, зинһарлап сорагач, каршы килмәде, безнең сәфәрчеләрне туры юлдан аларга кирәкле атауга озатырга риза булды. «Буш итмәбез, агай!»— диде Айсетдин, моны ишеткәч Закир кул гына селкеде:

— Куйсана! Мосафирлардан акча аламмы?

Якты көндә килергә чыксалар да, саз авызына алар шактый соң, кичке күлемдә генә килеп өлгәштеләр. Байтактан бу якларда булганы юк икән, Закир агай да туры сукмакны таба алмады, тирә-як танымаслык булып үзгәргән, тал әрәмәләре, зирекләр котырып үскән, юанрак агачлар берсе өстенә икенчесе ятып, юл-сукмакларны томалаганнар, элегрәк печән чапкан аланнарга да су төшеп, дерелдәвек сазламыкка әйләнгән, элек хәтердә калган билгеләр онытылган, юл югалган, хәтер чуалган иде. Егетләр-кызлар зур итеп учак кабыздылар, бергәләп жыр әйтешә башладылар, әмма Закир агайның күңеленнән борчу китмәде, нигә болай адаштылар әле алар? Әллә, чыннан да, иблис мәлгунь күз будымы? Урман ияләре алардан риза түгелме? Ул, юлдашларының йокысыннан файдаланып, иртән иртүк торды, бит-күзен салкын су белән юып йокысын качырды, озын таягы белән жирне капшый-капшый, якын-тирәдән бер әйләнеп килергә булды. Әйләнде, тулганды һәм барыр юлларын чамалады да сыман. Ниндидер үзе белгән билгеләр генә аңа кая барырга кирәклеген күрсәттеләр...

Шул чагында Рәхмәтулла белән Сорокин аның тавышын ишеттеләр, әле ярый, аю дип белделәр, югыйсә, кулына наган кергәч, гайрәтләнеп

киткән колгасар бәндә ике дә уйлап торачак түгел, туп-туры атып егачак иде.

Закир агай китеп, ботак-сатак тавышы тәмам тынгач та, Сорокин тынычлана алмады. Рәхмәтулла кайнаткан чәйне дә кабыл-тибел генә эчте, чалбар каешын тартыбрак буды, иңенә юл капчыгын салды һәм:

— Алай да бер әйләнеп килик әле без,— диде.

Закир агайның эзләрен табу бер дә кыен түгел, анда да, монда да куе чыклы үләннәр сытылып изелгән, аның бер эздән килүе дә, китүе дә ап-ачык иде. Эзләрне күрсәтеп, Сорокин сызгырып куйды һәм ауган агач кәүсәсе янына җиткәч, шып тукталып калды. Ботак-сатаклардан дәү ук ясалган һәм ул очлы башы белән нәкъ алар барасы якны — Алтын Мөгез утравын күрсәтеп тора иде. Рәхмәтулла әле берни дә аңышмыйча тора иде, Сорокинның яман сүгенә башлавы аның курку төшкән йөрәгенә тагын да шом өстәде.

— Нинди көндәшләр дисең син! Күр, томана, сукыр бәндә!.. Аю түгел, кеше үткән моннан! Кеше! Һәм Алтын Мөгез утравы ягына төбәп ук ясаган!

— Нишлибез соң?

— Хәзинәне табып алабыз да «мә!» дип, аңа китереп тоттырабыз, анасын...

— Әле аны табасы бар!— диде шикләреннән һаман ычкына алмаган Рәхмәтулла.

— Табарбыз! Тик иң әүвәл менә бу бәндәне юк итәргә кирәк! Аннан да элеграк, бу кеше барып җиткәнче, без утрауда булырга тиеш!

Шулай итеп, тыныч якшәмбе иртәсендә Күчем ханның яшеренеп яткан хәзинәсенә нәфес сузып, ике төркем юлга кузгалды. Уңнан — төньяктанрак Мөхәммәт Уразаев төркеме бара, сулдан, ашыгып-каударланып, Сорокин белән Рәхмәтулла атлый. Сорокинның кулында наган, Рәхмәтулланың билендәге үткер йөзле, җиңел саплы балта кулына күчте. Кем — кемне!..

* * *

Мәүлиянең Ялан авылына кайтып тора башлавына иң сөенгән кеше, мөгаен, Шамил булгандыр. Ятимлекне, кимлекләрне бик иртә татыган малайның күңеле артык дәрәҗәдә нечкә, артык сизгер иде.

Мәүлия дә авыр гаиләдә үсте. Әткәсе Ырсытдиннең әллә ничә мәртәбә: «Эттән туган нәмәрсә!»— дип, аңа барып ябышкан чаклары булды, әнкәсе генә аралап алып калды. Үзенең бу гаиләдә кирәксез, артык бала икәнен ул бик яшьли тойды. Әнкәсенең тирән, эчкерсез мәхәббәте генә кызга яшәү көче бирде, авырлыкларын җиңеләйтте. Әллә шуңа, Шамил белән Мәүлия беренче класстан диярлек бер-берсенә тартылдылар, тәнәфескә чыккач, артык күзгә бәрелеп сөйләшеп-аралашып тормасалар да, күзләре шыпырт кына бер-берсен эзләп таба, бер-берсенә текәлгән гөнаһсыз күзләрдән җылылык, якынлык ага иде.

Язмыш үзенекен эшләде — Мәүлия белән алар тагын бергә.

Мәхәббәт идеме бу, яратышумы, җырларда җырланган Галиябану белән Хәлил мәхәббәте идеме? Кем белсен...

Аларның бер-берсенә омтылуларын иптәшләре дә сизмәделәр түгел, ләкин, үсмер егет белән җитеп килгән кызның мөнәсәбәте шулкадәр керсез, саф иде ки, иптәшләре берчакта да кыен сүз әйтмәделәр, бүтән очраклардагы кебек атап, шаян җыр чыгармадылар, исемнәрен чәкәштереп бер-берсенә төрттермәделәр. Ялан балалары шулай булырга тиеш дип беләләр иде алар, һәм моңарчы Мәүлия белән Шамил дуслыгы хәвеф-хәтәргә очрамыйча, бәла-каза күрмичә һаман ныгыды, һаман дәвам итте.

Әтисенең генә бу дуслыкны өнәп бетермәгәнен сизенә иде Шамил. Башта ул моңа артык дикъкать итмәде. «Укысын, кеше булсын, аннан соң кызлар белән дуслашыр, дип ниятлидер минем әти»,— дип, башта үзен, соңра Мәүлияне тынычландырды. Тик кыз бала тизрәк өлгерә, күңеле сиземчәгрәк була. Мәүлиянең колагын кара хәбәрләр дә читләтеп үтмәгән, әткәсе Ырсытдин дә, ачуы чыкканда, аңа каргыш сүзләрен мул яудыра, әнкәсе белән Мөхәммәт абыйсы арасында нидер булгандыр дип тә уйлый, әмма күңеленә әнкәсенең аңлатуы мәңгелеккә сеңеп калган. Йомабикә абыстай Ырсытдин бик рәнҗеткән чакларда кызчыгын кочаклап елый торган иде. «Балам, мөгаллим абыең яшь чагында әткәңдә ялчылыкта торды. Шул чагында көнләшеп калды явыз!»

Көнләшкән генә, бары шул!

Ул көнләшкән, ә нигә Мөхәммәт абый кызның Шамил белән дуслыгына каршы? Каршылыкны һаман ныграк сизгән үсмерләр, ниһаять, моны телләренә кертеп, үзара сөйләшә дә башладылар, ләкин сәбәбен, күралмауның серен берсе дә аермачык кына әйтеп бирә алмадылар. Уразаев та бу хакта сүз кузгатырга кыймады.

— Улым,— диде ул көннәрдән бер көнне,— сине Мәүлия тирәсендә бөтереләсең дип сөйләүләре дөресме?

— Әйе,— Шамил кып-кызыл булды.— Мәүлия — бик мөлаем кыз. Без уенда гел аның белән бииебез. Кеше карамаслык кыз түгел лә!

— Син беләсең бит: ул — бай кызы, мин аның әтисендә батрак булып бил бөктем. Хәзер синең аркада кодалашырга туры киләме? Ул кыздан читтәрәк йөрсәң икән, улым!

— Бай кызын мәктәпкә кертергә өндәп, үзең барып йөрдең. Атаның балага зыяны тимәскә тиеш, дип әйткәнең дә бар...

— Шулай булса да, сиңа Мәүлия белән йөрергә һич тә ярамый. Башыңнан чыгарып ташла син аны!

— Мәүлиянең бер-бер бозыклык эшләвен беләсеңме әллә, әти!— диде үсмер егет, кинәт борчылып.— Белсәң, әйт.

Улыннан мондый сүз көтмәгән иде Уразаев, шундук телен тешләде. «Юк, юк, улым, Мәүлия — менә диган кыз!»— дип, аңгәмәне йомгаклап куярга ашыкты. Шамил белән Мәүлия арасын өзеп куярга дип сүз башлаган Уразаев җиңелдә дә калды. Инде хәзер сүз кузгату читенләште. Улы булып саналып йөргән Шамиле — үз улы түгел, Ырсытдиндә үскән Мәүлия аның үз кызы!

Ничек чишәргә бу төенне?

Шамилгә: «Мин синең әтиең түгел!»— дип әйтергәме?

Һич ярамый! Мондый сүзне әҗәл белән куркытсалар да әйтмәс Уразаев... Бүтәннәрдән дә әйттермәс!

Юл — кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне иң төгәл билгели торган нәрсә. Юл — кешеләрнең кемлеген, ни-нәрсәгә осталыгын ача да бирә. Моңарчы күренми йөргән җаннар да юлга чыккач, ачылып, үз төсләренә керәләр... Шамил белән Мәүлия бу юлы яшеренергә дә кирәк санамадылар. Иң әүвәл Шамилнең Мәүлиягә аз гына да йөк күтәртмәве һәркемгә күренеп торды. Суга ялгызын җибәрмәде, учак яктырмады, һәммәсенә үзе йөгерде, булышты, ярдәмләште, көлеп кенә сөйләште һәм... кичке кунуларда гел Мәүлия янына сырышты. О, юк, ямьсез, әрсез сырышу түгел иде бу! Шамил нәзакәтле егет иде, табигать аңа йомшаклык белән катылыкны бер чамада юмарт биргән, әлегә аның характерының кешеләргә йомшак ягы гына ачылып килә иде...

Эшнең тирәнгә үтеп керүен бүтәннәр сөенеп, Мөхәммәт куркып күзәтәләр иде. Дөрес, тагын бер кешенең бу вакыйгаларга үз мөнәсәбәте бар иде. Әмма без әлегә бу үсмер егетне арага кертми торабыз... Шамил белән Мәүлия артыннан ул да Мөхәммәттән ким күзәтми, кирәсенчә, төнлә уянгалап та алар ягына күз салып ала иде. Кызлар чак кына бер читкәрәк укмашып йоклыйлар, ул кырыйда гел Мөхәммәт белән Шамил була торган иде...

Ул көнне Алтын Мөгезгә барып житә алмадылар. Урман да, әрәмәләр дә, сазлык та бик нык үзгәргән иде.

— Әллә тирә-як үзгәргән инде, әллә үзем...— дип сукранды чал мыекларын сыпыра-сыпыра Закир агай.

Черки талаудан әчеткән битләрен төтенгә куя-куя тагын кечне каршыладылар. Корырак урынны сайлап кунарга калдылар. Ләм исе килеп торган су белән чәй кайнаттылар, юл капчыклары шактый жиңеләйгәнче ризыклар ашадылар. Черки яуларының һөжүмен искә алмаганда, төн тыныч үтте диярлек. Бигрәк тә Айсетдин газап чикте. Ул юлга чыкканнан бирле гел мыгырдап, гел зарланып йөри, юк эшкә үзләрен өндәгән Уразаевка кинаяләп тә, турыдан-туры да наразыйлыгын белдерә, ирек куйсаң, бер секунд тормыйча, сәяхәтне ярты юлда өзеп кайтып та китәчәк иде.

Бу төнне дә ул гел мыгырданып ятты.

— Саз суы эчеп, эч купертеп йөр инде. Микробларның саны юктыр монда! Балалар авырса... Үзебез чирләсәк... Берәребез үлсә... Юлга чыгар алдыннан район оешмалары белән киңәшергә, маршрутны тәгаенләргә иде. Әгәр бөтенебез кереп батсак? Әгәр югалсак? Эт белән дә эзләп таба торган түгел ич монда!

Әле ярый, арган-талган балалар, яту белән, йокыга киттеләр, аның туктаусыз мыгырдаганын бер Мөхәммәт кенә ишетеп ятты. Түзмәде, калкынып, Айсетдингә якынрак килде.

— Син, укытучы иптәш, бу сәфәрне ак чалбар киеп, кулны кесәгә тыгып, Тоболның таш урамында йөрү дип белгән идеңме әллә? Әйдә, юл авыр булсын! Егетләр ныгысын, күреп торасың ич, ил чикләре тыныч түгел! Егетләр армиягә барасы, өйрәнсеннәр.

— Ә кызлар? Ниемә кирәк аларга бу сынау?

— Сынаулар һәркемгә дә кирәк. Шул жөмләдән сиңа да... Хәтта миңа да.

— Ә сезгә ни өчен?

— Мин балаларны сыныйм. Онытма, арада улым да бар!

— Улың канәгать!— диде сузып кына Айсетдин. Ул кай яктан килеп Мөхәммәтне тешләргә белмичәрәк ята иде, хәзер жай чыкканга ачыктан-ачык сөенеп, кычкырыбрак сөйли башлады.

— Шулай булмыйча! Янында сөйгәне! Көт тә тор, сезне бабай исеме һәм кара борынлы малай белән бүләкләп тә куярлар әле!

— Кычкырма!— диде шашынып Мөхәммәт.— Яп авызыңны.

— Мин дәшмәм!— диде, шулай ук кызып Айсетдин.— Алар түзәрме?..

Болай да борчылып, төрле-төрле ямьсез уйлар богавында яткан Мөхәммәтне Айсетдин сүзләре тәмам ярсытты, йокы килмәскә качты, ул бик авырлык белән генә төнне үткәрде. «Бүгеннән дә калмый Шамил белән ныклап сөйләшергә кирәк»,— дип, үен беркетеп куйды.

Таң яралды, уяндылар, кечкенә арганлыклар, адашып, буталып йөрүләр онытылды, тиз-тиз генә ашап-эчеп алдылар да юлга кузгалдылар.

Иң алдан озын таягы белән адымнарны капшап, сакал-мыегы агарса да, һаман яшьләрчә житез адымлы Закир агай бара, аңа Шамил белән Мәүлия иярә, аларга Йосыф тагыла, аннан бүтәннәр кузгала. Уртада Мөхәммәт Уразаев, иң арттан, басар алдыннан сукмактагы эзләрне итек очы белән биш мәртәбә төртеп карый-карый, Айсетдин атлый. Ул гел артка кала, аны көтеп гажиз булалар. «Айсетдин абый!»— дип, авызларын зур ачып күмәкләшеп кычкыралар...

Бүген Мөхәммәт уртага керергә ашыкмады. Шамилне дә алга үткәрмәде, жиңеннән тартып, улын артка калырга чакырды.

— Улым, көт кенә.

Шамил, сүзнең кая таба барасын белгән сыман, Мәүлиягә күтәрелеп карап, бер көрсенде дә, уң иңенә салган биштәрле капчыгын сул иңенә күчерде...

Алар Айсетдиннән дә артта калдылар. Айсетдин теләр-теләмәс кенә аларны узды да, артына карый-карый тыңланып бара башлады. Кешеләргә яман хәбәрне җиткерергә яратучы бу астыртын кеше ата йөрәгендә нинди ут кабызганын чамалый иде... Мәүлия — кызлар арасында иң җиткәне, яшькә дә иң зурысы, сыны-гәүдәсе тулып-тупырдап тора. әгәр Шамил сагыз кебек ябышмаса, шушы урман сукмакларында Айсетдин Мәүлия белән юаныр иде... Капшап-капшап карыйсы килә әрсез егетнең, мәгәр кызны ялгызын очрата алмый, гел бергә алар, кичен-көндезен дә, төнлә дә янәшә генә... Эх, шуышып кына барасы иде дә сулыш алган саен әллә кая күтәрелеп киткән алма-алма күкрәкләрен умырып тотасы иде...

Мөхәммәт белән Шамил, уйга батып, арттан киләләр. Айсетдин исә көлүен учына яшереп, алар алдыннан атлый... Сөйләшәләр, мәгәр ишетелми. Аяк астында лайлы су чыпырдый, әллә нинди кошлар сайрашалар. Мөхәммәт сүзне туп-турыдан алып китте.

— Улым, син инде балигъ булдың, акны карадан аерыр чагың. Ачыктан-ачык сөйләшмәсәк, эшнең начарга китүе мөмкин.

— Тыңлыйм мин сине, әти. Әйт.

— Улым, беләсең килсә, Мәүлия синең бертуган апаң була. Менә шул. Үпкәләмә миңа, гаепләмә дә.

Уразаев авыр көрсенеп, исерек кеше кебек чайкала-чайкала алга ашыкты...

Шамилнең баш түбәсенә чукмар белән китереп ордылармыни, күз аллары караңгыланды, хәле бетте, кулларының көче калмады, иртән җинел генә кебек күренгән биштәрле капчык аны аска, җиргә сөйрәде. «Утырып торыргамы әллә?» — дип, ул күзе белән корырак урын эзләде һәм уң якка күтәрелеп карады.

Имәнеп китте! Тәнендәге изрәү тоташ курку белән алышынды, кычкырырга теләде, тавышы чыкмады...

Алар үткән сукмак янәшәсеннән диярлек ике карачкы бара иде. Кеше дип атарга базмады аларны Шамил, хайван да түгел, икесе дә икешәр аяклы, берсенең гәүдәсе төп-төз, икенчесенең иңе алга сөрлеккән, битендәге тирән яра ызаннары арасыннан учма-учма йон бөртекләре тырпаеп тора... Икенчесе арык тәнен чикмәнгә охшаган кием белән төргән дә билен ике-өч тапкыр бау белән кысып ураган... Кулында наган! Наганны да күрде Шамил... Алар бик мавыгып, онытылып, алга текәлгәннәр иде, агачка сөялеп өлгергән Шамилне абайламадылар.

Кешеләр түгел, өрәкләр ич болар!

Егетнең чәче урә торды, күзләре куркудан акайды. Мәүлия дә, әтисе дә әле генә әйткән куркыныч сүзләр дә онытылды. Нишләргә? Ничек хәбәр итәргә? Пөгерергә хәле-көче юк, кычкырыр иде, авазы бетте, ә нидер эшләргә кирәк! Бу өрәкләр сиздермәстән арттан килеп, нинди-дер явызлык эшләргә ниятләнәләр! Күр инде, ничек сагаеп баралар алар, аяк асларында ник бер ботак чожтырдасын... Шамил дә алар белән янәшә бара башлады, өрәкләр аның ягына күз дә салмыйлар, алда сөйләшкән, көлешкән тавышларга авышып йотылганнар...

Күчем хан хәзинәсен саклаучы өрәкләрме әллә болар? Әллә Алтын Мөгез утравына килеп тә җиттеләрме? «Сал ясарга туры килмәгәе, сулы чокырларны, кулларне үтә алмабыз», — дигән иде ич Закир агай. Болар өрәктер, кара, ничек тиз һәм житез баралар, әллә аяклары белән җиргә дә басмыйлар инде?

Менә алда Айсетдиннең тиргә баткан җилкәсе күренде. Шамил үзенүзе белештермичә: «Айсетдин әкә!» — дип кычкырды да алга томырылды. Аның янәшәсендә атлаган өрәкләр бердән җиргә сеңделәр һәм юк булдылар.

Шамил бик каты кычкырам дип уйлаган иде, аның тавышы чебеш тавышы кебек кенә зәгыйфь чыкты. Айсетдин барыбер аны ишетте. Атасы белән улы арасында булган сүзнең тамырын белергә теләп ярсып

бара иде ул. Уразаевтан сүз алырмын димә, аның теле тирәндә, бигрәк тә Айсетдингә, чишелеп, аны-моны әйтәчәк түгел, ә менә Шамилнең кызган чагы, ачулы чагы, җүләр чагы... Мондый чакта хәйләкәр балык та кармакка килеп каба! Ашыкмый егет, исен югалткандыр, әйдә, атласын, барсын, хәзер аның кем беләндер сөйләшәсе, серен уртаклашасы киләчәк, Айсетдин аны көтеп алыр да һәммәсен ачыклар... Мәүлия сылу ягына юл ачылганмы, юкмы? Мәүлиянең Мөхәммәт кызы булуы турында аңа читләтеп кенә Чырык Абдрахман сөйләштергән иде инде. Айсетдиннең моңа һич тә исе китмәде... Кайдадыр укыган иде ул, имеш, французларда шундый сүз йөри: «Карт кеше күрсәң — сәдакаңны җәлләмә, бир — атаң булуы бар... Сабый күрсәң — башыннан сыйпа, үз балаң булуы ихтимал!» Айсетдиннең дә үз балалары булуы мөмкин ич? Укыган чакта ул чибәр апаларның куенында аз йокламады...

Шамилне танырлык түгел, ул, арттан килеп, Айсетдинне кочаклады.

— Анда... анда!

— Нәрсә «анда»? Кайда?

— Өрәкләр... Ике өрәк! Әллә убырлылармы? Киләләр!

«Акылыннан язган!— дип күңеленнән көлемсерәде явыз Айсетдин.— Димәк, атасының сүзе каты булган! Егет яңадан кыз катына барачак түгел!»

— Анда... анда!— дип кабатлады Шамил.

Уралып-уралып йөри торгач, Рәхмәтулла белән Сорокин Мөхәммәт Уразаев төркеме белән бер юнәлешкә чыкты. Рәхмәтулланы да, Сорокинны да иң гаҗәпләндергәне — Уразаев төркемендәге кызлар булды. Әгәр бу кешеләр хәзинә артыннан йөри дисәң, ни пычагыма кызлар ияртканнәр? Бала-чага төяп, кыз-кыркын ияртеп, мал артыннан каулыйлармы? Инде хәзинә артыннан йөрмиләр дисәң, бу сазлы урманнарда аларга ни калган?

— Бәлки дару үләннәре җыялардыр?— дип карады Сорокин.

Рәхмәтулла кулын гына селкеде.

— Бу җәһәннәм сазлыгына кермәсәләр, бүтән урын беткәнме аларга?

Аның сүзендә акыл бар иде.

Нәрсә югалтканнар алар? Көлешә-көлешә, шау-гөр килеп, урман-сазны яңгыратып ни тилереп йөриләр?

— Әгәр хәзинә эзләсәләр, бу кадәр үк акырышмаслар иде,— диде Сорокин.

Ул да үзенчә хаклы иде...

Алар әле Уразаевны күрмәделәр. Сәфәрчеләрнең татарча сөйләшүләрен аңлаган Сорокин Рәхмәтулланы кытырдатты:

— Тыңла! Ни сөйләүләрен тәрҗемә ит әле миңа! Тизрәк бул!

Туктап тыңланып тордылар, сүзләр күп булса да, мәгънәсе әллә ни юк иде.

— Йә, нәрсә?

Сорокинның тавышы шул кадәр коры, таләпчән иде, Рәхмәтулла ирексездән арткарак чигенде:

— Аңлап булмый, саескан өере сыман такылдыйлар.

— Ну!— дип җикеренде колгасар Миша.

— Аңлашылмый, ваше благородие.

Ул беренче мәртәбә Сорокинга шулай олылап эндәште.

— Берәрсен аерып алырга да сораштырырга!..

Шамилне алар берьюлы күреп алдылар. Ләкин үсмер егет алар көткәнгә караганда елгыррак булып чыкты, борын астыннан ычкынып китте, артта баручыны куып җитеп, аңа күргәннәрен җиткерде. Хәзер алар икәү булдылар. Икәү... Хәзер аларны тотып алу хәтәррәк иде, икәү янына теге төркемнән берәрсе килеп җитмәс дип кем уйлаган... Хәзер бүтән бер әмәл табарга, качып торырга да берәрсенең аерылып

калуын сагаларга гына кала иде. Ә бу исәрләрнең сазлыкта ни эзләүләрен белергә кирәк!

— Белергә, белергә!— дип пышылдады Сорокин яткан жиреннән.— Бәлки, аларда яңа мәгълүматлар бардыр? Без белмәгәнне беләләрдер. Хәзинә эзләп килгәннәр алар монда, бүтәнчә түгел.

— Бала-чагалармы?— дип шигәеп сорады Рәхмәтулла.

— Алар күз буяр өчен генә!

Шул чакта һич көтелмәгән бер хәл булды: Шамил белән Айсетдиннең юклыгын абайлап Уразаев артка борылып килә башлады. Каракучкыл болытлар тагын да түбәнәйделәр, агач яфракларын шомлы шыбырдатып урман өстенә беренче эре тамчылар кадалды, кайдадыр ерактарак күк күкрәде.

— Шамил! Айсетдин!— дип эндәште Мөхәммәт һәм ачыграк урынга чыкты. Ул куркудан агарынган яшь укытучы белән улын күрде. Рәхмәтулла да, Сорокин да аны күреп алдылар һәм... таныдылар.

Теге чакта, паромны аклар кулыннан тартып алырга жөрьәт иткән кызыл солдатны, үз кәефе өчен генә Канталыев азат итеп жибәргән солдатны, никадәр еллар үткән булса да таныды Сорокин. Рәхмәтулла исә шашып-шашынып шаркылдый башлады:

— Уразай! Үзе килеп капты!

Мөхәммәт, әлбәттә, Рәхмәтулланы танымады, жимерек авыздан — сынган тешләр, китек иреннәр арасыннан чыккан тавышны да аермады, мәгәр, урман өрәге авызыннан үз исемен ишеткәч, бер мәлгә тәмам югалып калды. Сорокинда да элекке елгырлык юк иде, каушаудан уң кулындагы наганы жиргә төште. Рәхмәтулла мәче житезлеге белән сикереп наганны эләктерде дә тантана белән баш очында болгады:

— Уразай! Үзе килеп капты!

— Я сам! Я сам!— дип акырды Миша бишкә бөкләнеп.

— Нет уж, үзем! Үзем!— дип карулашты Рәхмәтулла һәм кыеклап дошманы Мөхәммәт Уразаев каршысына чыга башлады.

Үзенә төбәлгән наганнан бигрәк урман өрәге гажәпләндерде Мөхәммәтне. Кеше дисәң — кеше түгел, нинди жан иясе булыр бу шөкәтсез!? Кеше сыйфаты бик бәләкәй генә эләгеп торган бу гарипнең Рәхмәтулла каруи булуы турында ул уйлап та карамады. Аны таныган өрәкне ул да аерырга, танырга тиеш ләбаса! Кем булыр? Шул гомерләрдән бирле тайгада качып яткан качкыннарның берәрсеме?

Дошманының ике каш арасына төбәргә тырышып, Рәхмәтулла һаман Уразаевка якынайды, аның куркуын, ялварулы сүзләрен көтте, ашыкмады, аның мондый рәхәт минут кичергәне бик күптәннән юк иде, бәлки, гомерендә дә булмагандыр... Уразай Мөхәммәте — Эссәт Фәтхуллин гына түгел, ул аның кан дошманы! Рәхмәтулла бәхетле, татлы минутларның озаккарак сузылуын теләде һәм әнә шул комсызлыгы аны харап та итте. Дошманына текәлеп, ул аяк астына карарга онытып жибәрде, саксыз аяклары, сасы ис чәчеп быкырдап утырган баткак урынга туры килде, аягы тубыктан батты, алга ыргылуы булды, биленнән кереп чумды. «Ай-яй!»— дип яман акырып, кулларын бутады, хәрәкәт исә батуны тизләтте генә: саз өстендә башы һәм терсәкләре таянган ике кулы гына калды, жимерек авызына жылы лай кереп тулды, тагын бер тапкыр жан авазы белән «ай!» дип кычкырырга уйлаган иде, тын юлына ләм кереп китте. Саз күз ачып йомганчы Рәхмәтулла каруины кабып йотты, өстә быкырдашкан кара күбекләр арасында күгәргән, ярык козыреклы картузы гына торып калды.

Икенче өрәк — Михаил Сорокин: «Наган! Наганым!»— дип акырып Рәхмәтулла баткан кара чокырга ташланды да исенә килеп туктап, тыелып калды, кулларын сузып, наганын үзенә тартып китерергә ашкынып, яман тавыш белән сүгенеп жибәрде. Аннан муенына асылынган күн букчасын бер якка чөеп, ачудан күлмәк изүен аерып төшерде дә тагын бер тапкыр баткан шәүлә янына талпынды. Аннан сөякчел йодрыклары

белән күкрәгеп төя-төя җыларга керепте. Мөхәммәт Уразаев аңа таба атлады. Тәмам аптыраган, аңгырайган Шамил дә, исенә килеп, этисенә иярде, юл уңаенда саллы гына бер ботакны сындырып алды.

Нагансыз калганына ышанып житкән Михаил Сорокин, эз югалтырга теләп, сулга, куаклыкка ташланды, аның маңгаеннан кара тир, авызыннан сары селәгәе ага иде. Ул чытырман арасында бераз бәргәләнеп торды да күздән югалды. Тайга озакламыйча аның аяк тавышларын да йотты.

Мөхәммәт Уразаев борылып, улын кочагына алды, бүтәннәр дә ап-ак агарынып, куркып-каушап, аларга таба якынлашалар иде инде. Исләренә килеп як-ягына карансалар, Айсетдин беркайда да күренмәде.

— Баттымы әллә?— диде куркынып Мөхәммәт.

— Юк ла, сукмакта басып торганын үзем күрдем,— диде Закир агай.

Кычкырып, һау-һаулап эзләп карадылар, яшь мөгаллимнең үзе дә, тавышы да юк иде.

Бераз эзләнгәч кенә Мөхәммәт Йосыфны дәшеп алды:

— Теге кешенең күн букчасын табып алырга кирәк. Тик бик сак бул, Йосыф. Монда баткакның төбе юк икән, үзең күрдең.

Мөхәммәт Уразаев бик нык хафалана башлаган иде инде...

## 28

Айсетдин заманы өчен ару гына гаиләдә үсеп, хезмәт урыны итеп мәктәпне сайласа да, чуар күңелле егет иде! Ялан авылында ул «Алласызлар» түгәрәге оештырып җибәрде, килә алганнарны җомга көннәрне мәктәпкә җыеп, аларга галәм, су киңлекләре, оҗмах-тәмуглар турында кызып-кызып лекцияләр укыды... Үзе укыды, үзе: «Әгәр булсаң, кичер мине, ходам!»— дип ялварырга да онытмады. Аның аллага ышануын да, өй ияләре, бичуралардан куркуын да авылда беркем дә белми иде. Төн карасы җирне япкач, зират тирәсенә барырга курка иде ул, лапас-кура арасына да чыкмаска тырыша, мунчага берчакта да ялгыз керми, күршетирә егет-җиләнне үз янына дәшә торган иде.

Мөхәммәт Уразаев кына күңеленең бер почмагы белән егетнең икеле-микеле уйларын сизә. Айсетдиннең Чырык Абдрахман янына барып йөрүенең дә тикмәскә түгеллеген аңлый, аңласа да, аның хәтерен саклап, аны-моны әйтмичәрәк йөри иде. Алтын Мөгез утравына Айсетдинне ияртмәгәндә була идеме? Була иде, әлбәттә. Эш шунда ки, Мөхәммәт Айсетдиннең ныклыгын тикшереп карарга теләде, әйдә, эштә, юлда, кыенлыкта күрсәтсен әле бер, дип уйлады. Егетнең Мәүлия ягына сузылган күз карашларын күрмәде түгел, күрде Мөхәммәт, бу инде Шамилнең сабыйлык мәхәббәте тудырган эчкерсез караш түгел! Түгел! Айсетдиннең күзе Мәүлияне оятсызларча капшый, кыз күлмәгенең һәр сырын, һәр җөен тикшерә, сүтә, чишендерә. Мәүлия парта өстенә иелеп яза башласа, Айсетдин аның янына барып җитә һәм өстән күлмәк изүе аша аның күкрәк йомрыларын карарга тырыша. Әрсез бәхетенә, Ялан кызлары кияүгә китмичә күкрәкчә кимиләр иде.

Сазлы урманда көтелмәгән бәндәләр белән очрашу, аларның Мөхәммәтне танып алулары, шүрәлегә охшаган бер гарибенең: «Әһә, Уразай килеп капты!»— дип яман акырып кычкыруы Айсетдингә соң дәрәҗәдә көчле тәэсир ясады. Ул, чыннан да, аларны хәзинә сакчылары, явыз убырлар дип белде. (Әле Ялан авылына кайтып җиткәч, Чырык Абдрахманга ул кат-кат әйтәчәк: «Берсе юка таяк кебек, икенчесе шар булып түмгәктән-түмгәккә тәгәри... Берсенең авызы бар — тешләре юк, икенчесенең авыз урынын тегәрҗеп белән чәлмәштереп теккәннәр»,— дип сөйләячәк. Сорокинның пычрак, сары мыеклары ирен өстенә чәбәләнеп ябышкан иде, ул аларны «тегәрҗеп» дип белгәндер ахрысы!)

Уразаевның актыккы сәгате җитте дип уйлады куян йөрәкле мөгал-

лим һәм куркыныч урыннанераграк китәр өчен томырылып чаба башлады. Агач, баткак сазлар арасыннан ничаклы томырылып буладыр, әмма аңа күз дә иярми торды, озакламый ул артта кычкырган тавышларны да ишетмәс булды. Уразаев бетте дип ышанды, Закир агай ничек булса да балаларны алып чыгар, ул гади авыл кешесе, убыр-җеннәр Уразайны таныганны, ни өчен аны танымасыннар ди, аны кичерерләр, көчләп юлга чакырылган бәхетсез бичара икәнен аңларлар, ә Айсетдингә көн күрсәтмәсләр. Беренче — Уразайны, икенче аны бетерәчәкләр...

Чырык Абдрахманга ул шулай дип сөйләячәк...

Әле ул уңны-сулны аермыйча чаба да чаба. Егетнең бер ягын ныгытып әйтеп китмичә булмый: хәтер шәп иде Айсетдиннең, бигрәк тә күз хәтере. Бер кешене бүген күрә икән, ун елдан соң да аны ап-ачык хәтерли, йөзен генә түгел, кием-салымын, гадәтләрен онытмый. Авылларга чыгарга туры килсә, юлын, кайда кунарга туктаганын, хуҗаларның исемен, йөзләрен берчакта да хәтереннән җуймый иде. Бу сәфәрдә шактый болганып йөрсәләр дә, ул юлны хәтеренә сеңдереп барды, артка калуыннан файдаланып, агач кәүсәләренә үзе генә танырлык билгеләр дә ясаштырган иде, хәзер шуларның файдасы тиде, көне буе чаба, эзли торгач, ул коры юлга чыкты, өс-башын каккалап, аз-маз адәм кыяфәтенә керде дә Ялан ягына юнәлде. Кайда җәяүләп, кайда атлы олауларга утырып, икенче көнне Ялан авылына кайтып житте, караңгы төшкәнче авылга кермәде, сәфәргә киткән балаларның ата-аналары бөркет күзләре белән юлны күзәтәләрдер дип уйлады, ялгышмады, алар күзенә күренсә, аны тәмам тотып ашаячакларын ул бик ачык чамалый иде.

Караңгы төшкәч кенә, анда да ындыр артлатып Чырык Абдрахманнарга кайтып керде, ул койма аша сикергәндә абалап өрә башлаган Сарбай танып тыелды, көлтә койрыгын болгап, аның сазда пычранып-ертылып беткән чалбар балагына килеп сыенды...

Урман юлында өрәк-бәндәләрне күреп, Айсетдин ничаклы курыккан булса, кинәт килеп кергән укытучының кыяфәтеннән Чырык Абдрахман да куркып китте.

— Кем йөри алай?— диде ул кулын каш өстенә күтәреп.

— Мин бу, Абдрахман әкә... Айсетдин.

— Айсетдин? Әллә алыштырдылармы сине?

— Булгандыр, Абдрахман әкә, мине алыштырдылар гына, ә Уразайны юк иттеләр!

— Ә?

— Эшләр менә шуңа китте. Синең катыңа килдем, коткарсаң, син коткарырсың... Минем фатирга кереп, әйбер-караларны ал да сездермичә генә мине озат. Ак эт бәласе кара эткә булмасын, яхшы чакта табанны кыздырырга һәм әллүр! Китәргә кирәк.

— Кая?

— Безнең заман сукбайларын кайсы як йота? Урта Азиягә инде...

Асылында Айсетдин Омск якларына китәрмен дип уйлап куйган иде, серен Чырыкка ачып бетермәде.

— Ни булды соң? Балалар кайда?

— Балалармы? Белмим... Өрәк тоткынынннан исән-аман котылырлармы, белмим, мәгәр Уразай килеп капты. «Уразай бетте!»— дип кычкырганны үзем ишеттем.

— Өрәк сөйләшә белә диме, әстәгыфирулла тәүбә, ни сөйлисең син, кем, Айсетдин?

«Мотлак, егетнең акылына зәгыйфьлек килгән, өшкерергә кирәк булыр!»— дип уйлады Чырык.

Айсетдин эшне болай гына тәмамларга ярамавын, Чырыкка кайбер нәрсәләрне ачарга туры киләчәген уйлады һәм... китте тезеп!.. Шар өрәк тә, таяк өрәк тә калмады... Берсенең авызыннан ут, икенчесенең колагыннан төтен бөркелә дип ычкындырды. (Кайнарланган җилкәләрдән пар күтәрелә иде, шуны чамалагандыр инде!)

— Мин кайтканны авылда әйтмә инде син, Абдрахман әкә!— дип ялынды Айсетдин.

Һәм әйтмәде дә! Сүзендә торыр өчен түгел, әгәр ата-аналар аның Айсетдинне кабул итүен, түренә утыртып чәй белән сыйлавын, ике чәшке самогон да коеп бирүен белсәләр... ай-һай, рәхмәт укымаслар! «Шул явызны якасыннан тотып сәвиткә ник илтмәдең?»— дип боргычлап алачаклар...

Әйбер-караларын алырга да бармады.

— Юк,— диде ул кырт кисеп.— Син качасы, мин монда каласы! Ничек дип синең әйбер-караңны юллап йөрим? Актыктан исе чыкмас дисеңме? Болай да хәзер күпчелек миңа кырын карый. Бәддога укысыннармы? Юк, Айсетдин энем, алтын-көмешләрең юк, булса әгәр, хәзинә эзләп Күчем хан сөякләрен кузгатып йөрмәс идең... Ходай бар ул, үткәннәрне дә ул саклый, киләчәкне дә ул кайгырта. Әйттем мин сиңа, йөрмә дидем, ходай орыр дидем!

Алай димәгән иде Чырык, Айсетдинне турыдан-туры котырткан, өндәгән иде! Уразаевка әйтергә ул киңәш иткән иде. Менә хәзер ни сөйли!..

Ләкин карышып, әрепләшеп торырга һич ярамый иде, Айсетдин, Чырыкның чоланына чыгып, бераз йоклап алды да, таң яралганчы юлга чыгып китте.

— Берәр бөтен ипи бир инде, Абдрахман әкә.

Ипине сыкранып булса да бирде Чырык... Әйдә, алсын да китә бирсен. Бәладән баш-аяк; кеше-кара сизенгәнче, авылдан читкәрәк китсен, ераккарак. Бу тирәдә тотыла калсамы...

— Син инде, Айсетдин энем, кемгә дә мине сата күрмә. Болай да, беләсең, тешләргә генә торалар... җәллә!— дип ялынды ул.

— Дәшмәм. Адресымны салырмын, аяк эзе тынгач, әйберләрне җибәрерсең,— диде Айсетдин хушлашып.

— Җибәрмимме соң!— диде Чырык, үзе күңеленнән генә: »Тот, җибәргәннәр иде ди!»— дип уйлап алды.

Айсетдин: «Иң хәерлесе Омскига чыгып сызу булыр!»— дип уйлады. Бердән, анда апасы яши, икенчедән, аны белгән-күргән кеше ул якларда юк диярлек, һәр тарафтан тыныч булачак. Җәйгә апалары сыендырса, кышка кая да булса эшкә урнашыр, өрәк кулыннан ычкынганны, Мөхәммәт Уразаевны төп башына утыртып калдырганны, Омск кебек атаклы шәһәрдә үз сукмагын салмаслык егетме әллә Айсетдин? Уразай күләгәсендә генә аңа юньле урын булмады. Бәлки, урман өрәкләренең килеп чыгуы аның бәхетенә генә булгандыр?

Уйларын төяп бара-бара, Кызлар Убасына җитәрәк, ул кыпылт кына артына борылып карады. Яктырып килә икән. Юк, тавыш, арба шыгырдавы иртәнге тынлыкны тишеп арттан түгел, алдан ишетелде, Тобол ягыннан килүче юл бормасында атлы күренде. Айсетдин юл читендәге чокырга сикерде һәм ике күзен бер итеп атта утыручыларны гаҗәпсенеп карап калды. Кабык арбага ике якка аякларын салындырып биш кеше утырган. Берсе олаучы булса кирәк, Айсетдин анысын танымады... Ә өчесен аергач, гаҗәпләнмәслек тә түгел иде: юлаучыларның берсе Ырсытдин, хатыны Йомабикә белән улы Ташкәй аңа кысылып диярлек утырганнар, аларга аркасын куеп утырган ябык кеше, һичшиксез Һади бабайның төрмәдәге улы Сәгъдетдин иде.

Ничек юллары табышкан да ничек бер арбага туры килгәннәр алар, монысын Айсетдин белә алмады, мәгәр, берсенең төрмәдән, икенчесенең сөргеннән Ялан авылына кайтып барулары шиксез иде...

## 29

Йомабикә абыстай гомере буе үкенеп яшәде. Ырсытдингә кияүгә чыгуына да үкенде, Мөхәммәт Уразаевны яр итүенә дә үкенгәләгән

чаклары булды... Шуның аркасында иреннән яхшы сүз ишетмәде, гомере буе кыен ашады. Ташкәйне табуына да үкенде, әгәр ул булмаса Ырсытдинне ташлап киткән булыр иде. Ә болай ике бала белән кая барсын татар хатыны?!

Бәхетсез мәхәббәткә дучар булган хатын Мөхәммәтне һич тә оныта алмый иде. «Әйдә, аерым башка чыгып яшик!»— дигәнгә риза булмавына да гомере буе үкенде. Ул чагындагы бай тормышны ташлый алмады шул... Ырсытдиннең тормышы әле дә бик житешле, авылдан сөрделәр дип, кулыннан эшен ташламады, төнен йокламады, көндезен тынмады, анысын юнәтте, монысын тапты, булышырга Ташкәе үсеп житте. Киң жилкәле, олы башлы, озын куллы бу көчле егетне әтисе хәзер өйдә хужа булырга әзерли, аны төрле эшкә ияртеп йөртә, хужа булырга күнектерә. Ике сүзнең берендә:

— Болар һәммәсе синеке! Каты тот! Син хужа,— дип кабатлый.

Йомабикә шыпырт кына, мич арасыннан:

— Ә Мәулия кызыбызга нәрсә!— дип сорап куйса, Ырсытдиннең аңа да жавабы әзерләнгән:

— Аңа әнә йомран башы!— дип кенә кычкыра.

Мескен Йомабикә гомере буе рәхәт күрмәде, үзен бәхетле итеп тойган чакларын да хәтергә алырга курка... Аннары, хатын-кыз үзе татыган бәхетне кем белән булса да уртаклашмаса, уртаклашыр кешесе булмаса, бәхет тулымыни ул? Йомабикә абыстайның бәхете гөнаһлы бәхет булды, чит ир белән, ялчысы белән булды. Кемгә сөйләсен ул бу хакта? Кем белән серен уртаклашсын?! Шуңа ихтыяри-мәжбүри басымчак итте, Ырсытдиннең «ә» дигәненә «жә» дип, карышусыз буйсынды, мунчада аркасын ышкыды, аягын юды, өс-башын таза йөртте, ашына таракан төшермәде, кыйнаганда түзде, кочканда билен бирде. Ә кыйналган чаклары булды аның! Туган иленнән куылып, мәсхәрәләп диярлек киткән ир кемгә өстен булып жанын юатсын?! Ир кеше кемгәдер өстен булырга тиеш ләбаса? Ялан авылына, Мөхәммәт Уразаевка, Сәгъдетдингә, тагын бик күп ярлы-ябагайларга булган үчен Ырсытдин бары тик хатынынннан гына ала иде. Ни ачулы чакларында да ул Ташкәйгә ормады-сукмады, улы әлләниләр кылса да аңа авыр сүз әйтмәде. Чөнки ул — булачак хужа, йорт-жирне, исем-фамилияне варис итәчәк кеше, кавырсыны нык, холкы кырыс, каты булсын, шул чагында гына ул әткәсенә охшар...

Улының үзенә охшавын бик нык тели иде Ырсытдин... «Мәулиягә, кызыбызга нәрсә?»— дип сорыймы теге ут итәк, сыбызгы? Уразай канына, Уразай кызына малмы? Әгәр Ташкәй белән бер-бер хәл булып, мал шул канчыкка каласы икән, ут төртеп яндырачак аны Ырсытдин, үз куллары белән юкка чыгарачак!..

Куанычы Ташкәй әнә егет булып килә. Утын түмәрләрен сынар кулы белән тәгәрәтеп чыгара, балтаны ике куллап тота, бер чабуда нинди кире бүкәннәрне дә чарт итеп кенә ярып ташлый... Кулы күнеккәч, башы да эшли башлар, башы күнеккәч, кулына жиңеллек килер,— Ырсытдиннең фәлсәфәсе шул, яшәр, бирешмәс... Гомере буе каршы сүз әйтмәгән, басымчак Йомабикә быел яздан өзми-куймый бер сүзне такылдый башлады.

— Ялан авылына кайтырга вакыт безгә. Ил-аяк тынды, хәзер без картайдык, кызыбыз анда, улыбызны өйләндерер чак житә, авыл кызын алып, башлы-күзле итеп китәсем килә бу дөньядан.

Ырсытдин күксел күз кабакларын калкытмыйча гына хатынының тупырдап торган түшенә, камырдан әвәләгән кебек ап-ак беләкләренә карап тора да жиргә төкерә, дәшми...

Бер эндәшеп карый Йомабикә, ике, иртән дә сорый, кичен дә кабатлый, мунчага баргач, Ырсытдиннең аркасын умый, кочагына алыйм дисә, борылып ята.

— Күңелем болгана, саруым кайный,— дип ялганлый.

Саруы кайнамый кәнтәйнең, белә Ырсытдин: һәммәсе хәйлә генә, күңеле болганса, сарык билдәмәсен шулай сыпырып куяр идеме? Кичә, гөнаһ шомлыгы, санап торды, чәй янында утыз ике коймак ашады! Сару кайнаса, шул кадәр камыр йотып буламы?! Әллә берәрне төшерәсе инде, җилкәсен камчы белән ярасы?.. Юк шул, элекке көч тә, егәр дә юк. Тәшкәй дә хәзер килеп җитә. Әткәсе кырысрак тавыш белән сөйләшә башлады исә арага керә:

— Җитәр сезгә!— дип кенә куя.

Әгәр хәзер ишетеп калып ул да әнкәсе сүзен каерса, ни эш кылырсың? Икегә каршы чыгып кара әле монда! Ташкәй сүзе сүз була башлады йортта, әнкәсе дә аны күтәреп кенә йөртә. Ишетеп кала күрмәсен...

Ырсытдин шулай уйлап, икеле-микеле фикерләр белән саташып йөргәндә, беркөн иртәнге чәйдән соң, Йомабикә, гадәтенчә, чәй чынаякларын юарга тотынмады, сыгылып, сәкегә ятты да уфылдарга тотынды.

— Җаным тәнемдә чагында кайтыйк без Яланга!— дип тәкрарларга кереште.

Ташкәй урамдагы урыс малайларына ияреп, тәмәке тартырга гадәтләнеп килә иде, хәзер дә курага чыгып, шыпырт кына суырырга ниятләп газета кисәге эзли иде, тукталды һәм бер сүз генә әйтеп куйды:

— Ни калган безгә анда?

— Ничек «ни калган»? Ялан — синең туган авылың!— Йомабикә авыртуларын онытып сикереп үк торды.

— Туган җирдә көтәләр. Ә безне кем анда көтә?

Ырсытдиннең эченә җылы йөгерде.

— Әйе, әйе,— диде ул ниндидер ачы су тулган тамагын кыргалап.— Этем көтәме анда безне?

Йомабикә абыстайның алай тиз генә бирешер исәбе юк иде:

— Язмышыбыз көтә безне анда, язмышыбыз,— дип кабатлады.

Ташкәй курага чыгып киткәч, сүз озайтып тормады, улын үзенә каршы килер дип уйламаган иде, бу көтелмәгән катнашу аны сискәндерде, сак булырга да кушты! Ташкәйне әзерләп тотынырга кирәк булган сүзгә! Ырсытдиннең икеләнә башлаганын ул ап-ачык тойган иде, аның да Яланга кайтасы килә, үзенең исәнлеген белдереп, улы белән мактанасы килә. Ташкәйнең сабан туйларында көрәшеп батыр калганын күрсәтәсе килә! Азмы куылган ирнең теләкләре бу дөньяда?!

Ташкәй әйткән икән — бетте, Ырсытдин ни ашкынса да, улы сүзен егачак түгел, хатын-кыз сүзе белән яшәмәскә кирәген ул күреп өйрәнә торсын, Йомабикәгә дә матур сабак булыр. Кырт кисте дә куйды әнә улың!..

Бу юлы Ырсытдин ялгышты, әгәр хатын-кыз бик нык теләсә, күңелә белән Урал тавын да күчереп куя, җирнең җиде катына төшә, күкнең җиде катына менеп җитә ала. Йомабикәне белми әле Ырсытдин, аның күңелендә сару кайнамый, ачу кайный, ачу! Кемгә ачу дисезме? Үз-үзенә! Бары тик үзе генә гаепле! Эх, «Әйдә, бергә яши башлыйбыз!»— дигәндә, Мөхәммәт Уразаевны тыңлаган булса!.. Хәзер менә таза, егәрле ирнең кайнар кочагы искә төшә дә кайнар күз яшьләрен сытып чыгара... Юк, юк, хәзер Яланга кайтып төшеп, Мөхәммәтнең кочагына яңадан хуҗа булырмын дип уйламый Йомабикә, аның ара-тирә булса да Мөхәммәтне күрәсе, аның дөньяда барлыгын һәм кайчандыр шундый ирнең үзенеке булуына ышанасы гына килә. Бары тик шул гына... Аннары кызы янында булсын иде, ул да кыз баланы ничек яшәргә кирәклегенә өйрәтергә тиеш ләбаса! Сүзгә саран Ырсытдиннең дә Ташкәй белән гәпләшә башласа, сүз бетми, гомердә әйтә алмаган әллә нинди сүзләр табып бетерә, кош булып сайрый... Ә ул? Кызы Мәүлиянең житеп килгән чагы, аны яман күзләрдән сакларга, яман сүзләрдән сакланырга өйрәтергә бик вакыт. И аллам! Кияве кем булыр да, аны кем яр итәр? Ирне янда тоту ысулларын анадан башка кызга кем өйрәтсен?.. Сайлап чыксын иде инде, белеп, күреп, Йомабикәнеке кебек, гомере суык түшәк-

тә үтмәсен иде! Йа, аллам! Моннан торып аңа ничек ярдәм итмәк, акыл бирмәк кирәк? Үз янында булса, кешесен күреп аңлашырлар иде... Йомабикә белмиме ирләрне? Белә, аяк атлауларыннан ук кем булуларын чамалый... Ырсытдин ирме, тьфү!

Мәүлия дә үкенеп гомер итәрлек булмасын!

Хатын-кызның уе йөгерек, теләге үткер пычак — теләсәң кая ярып керә, бу араларда ул Ырсытдинне юк-бар сүзләр белән борчымый, Яланга кайту турында авыз да ачмый. Ырсытдин эчтән генә куана, хатынын җинүе белән шатлана. Кысыр иргә шатлык аз килә, иртә картая башлаган Ырсытдингә тавык та бөркет булып күренә торган чак житкән... Ялгыша Ырсытдин, хатын-кыз — иблис ул, иблиснең анасы! Һәркайсында әнә шул Иблис мәлгунь гадәтләре калган. (Чырык Абдрахманның бу сүзләре каян хәтергә төште соң әле? Исән микән Чырык, ниләр кыйрата икән?!)

Ырсытдин үз-үзен сөеп, тынычланып йөргән арада Йомабикә улы Ташкәй белән көн туса шул хакта сөйләште. Иң әүвәл: «Улым, сиңа өйләнергә бик вакыт, чит-ят кызны, белмәгән кеше тамырын алганчы, үзебезнең Ялан кызына өйләнсәң иде!» — дип сүз башлады. Житкән, таза егетне кайсы яктан чәлмәштерергә белә хатын-кыз! Кызлар дигәч, Ташкәйнең ике колагы да ут булып яна башлады, күз алдыннан тезелешеп Ялан кызлары, яшьтәшләре үтте... Сәрвәр... Сәлимә...

Йомабикә татлы укның кая барып кергәнен күреп тора, иплән кенә тагын Ялан якларын, Кызлар убасында үтә торган күңелле уеннарны, кәз-кәз генә басып йөргән көяз кызларны, аларның зифалыгын, аларның назын, иркәләүләрен һич тайчынмыйча сөйли дә сөйли. Аратирә улына мактау сүзләре дә яудыра: «Авылның иң сылу кызы синеке булырга тиеш! Син үзең дә чибәр, сәламәт, көчле, акыллы!»

Кайсы егетнең таза, сәламәт булып, авылның беренче кызын аласы килмәсен?! Һәм кичләрнең берсендә, ясканып кына бәлеш ашап утырганда, Ташкәй әйтә куймасынмы:

— Әти, әни дөрес әйтә, безгә Яланга кайтырга кирәк...

Ырсытдиннең авызына китергән кашыгы идәнгә тәгәрәде, ул капкан ризыгын тамагыннан үткәрә алмыйча изаланды:

— Нәрсә, нәрсә? — диде ул бугазын ышкып.

— Кайтырга кирәк, менә шул! — дип күтәреп алды шунда ук Йомабикә. Бу арада авызына су кабып йөрүе тикмә генә булмаган икән, улының кем жырын жырлавын Ырсытдин тиз үк аңлап алды, мәгәр соң иде инде. Ташкәйне ике сөйләшмәскә үзе өйрәтте ләбаса! «Әйттең — бетте, кистең куйдың!» — дип, үзе көн туса сабак бирде... Хәзер карышып кара син аңа! Ныграк карыша башласаң, маңгаеңа берне кундырыр. Анысына да үзе өйрәтте: әгәр юл сапмыйча киреләнеп маташа икән, кундыр һәммәсенең ике каш арасына берне!.. Әлегә Ташкәйнең, вактөяк урам сугышларын искә алмаганда, алай-болай зур эшләр кылганы юк, мәгәр анын йодрыкларына тап булсанмы...

Улының йодрыкларына күзе төшкәч, Ырсытдиннең ябык җилкәләре чымырдап куйды һәм ул кайтырга ризалыгын бирде.

Шул төнне үк әзерләнә башладылар. Ырсытдин бик тырышып салган йортны яхшы гына бәягә сатып җибәрделәр, сатып алучы тиз табылды, сатулашып та тормады, еллар чуалчык иде, ул елларда Себернең тын шәһәрләренә Россиядән байтак кеше күчеп килде, арада акчалылар, таза тормышлылар да бар иде. Авыр елларда күп көч түгеп салган куышын жәлләде Ырсытдин, әмма Йомабикә монда да аны җиңде:

— Яландагы йортың начармы әллә? Үзе юкның күзе юк, ташып бетермәсеннәр тагын. Мондагы өчен уч тутырып акча алдың, бай булып кайтасың авылга! Мактана торган гадәтең бар, күпмегә сатуың турында лыгырдыйсы булма, ишетсен колагың! — дип түгләды. Һич көтмәгәндә Ташкәй дә әнкәсен хуплады:

— Акча кирәк булачак әле...

Ул инде өйләнү, туй уздыру хакында хыяллана башлаган иде, авылның иң сылу кызын алганда, туе да «кем туе!» дип әйтерлек булсын!

Бу акылны да улына әнкәсе биргән иде...

Һәммәсе мач килде, һәммәсе Йомабикә юраганча, ул алга куйганча булды. Обдорскидан Тоболга кайтып төштеләр, анда озак юанмадылар, иске танышларыннан ат белештеләр дә, төн кунып, иртәнге яраудa ук кайта чыктылар. Ташкәй йөгереп кенә кибетләрне йөреп чыкты, кайда нәрсә сатылуын белеште, туй кирәк-яракларына күп кирәк булачак, алдан белешеп торуың яхшы.

Бу фикерне дә аңа әнкәсе белдерде, әтисе карышып тормады...

Олаучы белән Ырсытдин элек таныш түгел иде. Шәһәр читендәрәк үз йорты белән яшәп яткан өшән генә бу татар әле ике ат асрый икән, кеше табылса, йомыш-юлга йөри, кышын калага балык ташый, хозмаг тирәсендә дә эшнәлеге бар икән. Олаучының сере ике-өч авызга сыеп бетте, әмма Ырсытдин чишелеп китмәде, «Каян?»— дип сорагач, чыраен сытып кына артына борылып карады һәм җилкә аша кулын изәде: «Тегеннән». Олаучы — юл йөргән кеше, юлда язмышларның төрлесен очрата, Ырсытдиннең кырыслыгыннан, Йомабикәнең авызын бөрештереп куюыннан, егетнең бер урында тик кенә утыра алмавыннан бу гаиләнең шактый авыр юлдан кайтып килүләрен төшенде. Авыр юлдан кайтучыларга сүз кирәкми, аларга атың шәп кенә барсын да, сораштырма! Казынма алар җанында!

— На, бахбай!

Кичәгенәк яңгыр явып үткән, көчле түгел, сибәләгән генә, һава саф, кырлар өстендә пыр да пыр кошлар оча, Ырсытдин берзаман сизә, хатыны иңе белән аңа елыша, азрак читкә тартылып утыра, тагын аның артыннан елыша Йомабикә, борылып караса, хатыны яшь коеп кайта икән, елышуы туган җиренә алып кайтканы өчен рәхмәт әйтүе... Ә тәне кайнар Йомабикәнең, яндырып үтерерлек, яндыра олыгая башлаган Ырсытдиннең тәнен, йөрәген дә көйдерә. Ырсытдин улына ялт кына карап алды да хатынының кайнар колагына:

— Анда кайткач... кара аны! Аны-моны сизсәм!— дип пышылдады.

Кая ул, әстәгъфирулла тәүбә, ана кеше җиткән кызы янына кайтып бара, янында җиткән улы, чит кешеләргә күз күтәреп карарга, авызың ачып сөйләшергә оялырсың...

Ташкәйнең уен аңлау кыен түгел, ул Ялан кызларын бер-бер артлы күз алдыннан үткәрә, аның саен авылга тизрәк кайтып җитәсе килә, олаучы кулыннан каеш камчыны тартып ала да үшәнләнә башлаган атның сыртына берне сыпыртып та җибәрә.

— Әйдә, атла!

Баралар, юл буенда чүгәләп кенә тәмәке тартып утырган бер ир янына килеп җиттеләр, тәмәкеле калкынды, танырга тырышып, нәзек муенын турайтып карады, таныды, әмма арбадагылар аңа юньләп күз дә салмадылар, үтеп киткәч кенә Ырсытдин хатынының янтыгына терсәге белән төртте:

— Бәй, Сәгъдетдин түгелме теге бәндә?.. Шул бит. Әй, кем, атыңны туктатчы!— Ат туктады. Ырсытдин арбадан төшеп юл читендә калган кеше янына атлады.— Сәгъдетдин, синме, түгелме?

— Мин,— диде теге кеше, фуражкасын салып, күзен каплады.— Мин йөрим, кадалгыры.

— Кая барышың?

— Барыш түгел, кайтыш.

— Каян кайтып киләсең?

— Беломор каналыннан!

Сәгъдетдиннең төрмәдән кайтып килүен хәзер генә аңлап алды Ырсытдин. Хәзер, бер эндәшкәч, ташлап китсәң дә уңайсыз, утыртыйм дисәң, үзләре дә ишле. Йомабикә абыстай да килеп җитте, мосафирны

юл читендә калдырып китсәләр, авылга кайткач, оятын кая куярга белмәс буласын аңлады һәм Сәгъдетдинне үзләре белән чакыра башлады. Ырсытдин бер җикеренергә уйлаган иде дә, кулын селкеде.

— Әйдә, утыр, сыярбыз әле,— дип Сәгъдетдинне кыстады.

— Рәхмәт, үзегез ишле.

— Үрдә җәяүләрбез,— диде Йомабикә нык итеп.

Кысылышып Сәгъдетдингә урын бирделәр. Олаучы: «Ат тарта алмас инде!»— дип сукрана башлаган иде, Йомабикә:

— Хакын азрак өстәрбез!— дигәч, тынды тагын.

Яңаклары эчкә кереп ябышкан, битендә туры, ябык борыны белән күмердәй янып торган кара күзләре генә калган Сәгъдетдин озак ялындырып тормады, менеп утырды, тезе өстенә кысыр сыер җиленә хәтле генә капчыгын куйды.

— Менә безнең дә кайтып барыш,— диде Ырсытдин байтак җир киткәч.

— Ялангамы?

— Шунда,— диде Йомабикә нык итеп.

— Алай,— дип сузып куйды Сәгъдетдин.

Тагын озак кына дәшми бардылар. «Алай!— дип сызланды Сәгъдетдиннең күңеле,— менә син совет властенең дошманы идең, атка утырып кайтып киләсең. Ә мин шул властьны гомерем буе яклаган ярлыябага, синең арбага утырдым... Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың, диләр... Нужәли, Ялангa кайткач, синең җырны җырларга кала инде, Ырсытдин?.. Канал казыганда да үз җырым булмады, була алмады, кешенең көн күргәненә карап үтте гомер...»

Сәгъдетдиннең сүзе бар иде: «Әгәр авыл ягына исән-яман кайтып егылсам, беренче очраган адәмне кузайтын[1] чәенә чакырыр идем, гомере буе аңа рәхмәтле булыр идем!»— дип адарынып куйган иде. Кем уйлаган беренче очраган кеше аның кан дошманы булыр дип! Хәзер сүздән кире кайтып кара инде менә! Антын бугазыңны буар...

Әтисенең вафат булуын, уллары Йосыфның әйбәт кенә укуын, инде житкән егет булуын аны Гыйззәтбану байтактан язган иде инде. Кайтасын хәбәр итеп тормады Сәгъдетдин, насыйп булса, капканы кергәч үзләре дә күрерләр, дип уйлады...

Кайда җәяүләп, кайда атка төялешеп, кайда юртып, кайда арбаны арттан этеп, ниһаять, Ялан авылына кайтып җиттеләр. Авылга кергәндә, Сәгъдетдин арбадан төшеп калды, юлдашларына рәхмәт укыды.

— Хәл китте,— диде ул,— аз гына хәл алыйм инде.

— Ихтыярың,— диде кырыс тавыш белән Ырсытдин. Сәгъдетдин бераз артта калгач, хатынына эндәште: — Безнең белән кайтасы килми, янәсе...

Авыл урамына кергәч, Ырсытдин дилбегәне үз кулына алды һәм озакламый алар чирәм баскан киң ишегалдына килеп керделәр. Тәрәзәләре такта белән кадакланган йортны, мал-туар абзарларын, кураны күргәч, Йомабикә җыламсырый башлаган иде, Ырсытдин каты гына итеп эндәшеп куйды:

— Шыңшыма! Күрше-колак әллә ни уйлар... Ә син, улым, бар, Йосыфны дәш, кул арбасы алып әткәсен барып алсын. Үлеп-нитеп китмәсен тагын. Бик бетәшкән Сәгъдетдин...

Ташкәй шунда ук чыгып йөгерде, өйгә кереп тын алырга да өлгермәделәр, Ялан авылының торага чыккан очына бәләкәй авылның мәчете хәтле булып Гыйззәтбану тути йөгерде, ул җип-җиңел, курач ирен кочагына алып, биләүдәге баланы йөрткән кебек тотып, өенә алып кайтты.

---

[1] Кузайтын — ерак юлдан кайтучы хөрмәтенә оештырылган сый. Күрше-күлән кузайтынга бәйрәм ашын күтәреп керә.

— Кайтып життеңме, җанашым? Рәхмәт төшкере, ризыгың киселмәгән икән әле!— дип туктаусыз такмаклады ул. Гыйззәтбану түтинең тавышы озак яңгырап торды. Ырсытдин тәрәзәләрне ачып җибәрде, олаучыны чәй эчертеп озатырга булдылар. Атка да хәл алдырырга, сугарып, ашатып алырга кирәк иде.

## 30

Көтелмәгән куркыныч очрашулар, алар күз алдында бер кешенең баткакка чумып үлүе, икенчесенең качып китүе яшьләрне генә түгел, юл күрсәтүче Закир агайны да, Мөхәммәт Уразаевны да тетрәндерде. Алар бер мәлгә шашып, югалып калдылар. Башта мышык-мышык җылаган кызлар, бер-берсенә сыенышып, кычкырып ук җыларга керештеләр, егетләр дә нишләргә белмичә катып басып тордылар. Әле алай гынамы, өченче кешенең дә үлгән булуы бик ихтимал, дуамалланып чабып киткән Айсетдиннең кая барып бәрелгәнен кем белсен?!

Арада үзен иң бәхетсез итеп сизгән кеше Шамил иде ахрысы... Гашыйк яшь күңел алдында берьюлы ничә һәлакәт! Бердән, урман өрәгенең: «Уразай килеп капты!»— дип сөенеп акыруы аның колак төбендә яңгырап тора. Димәк, ул өрәк түгел — кеше, һәм шул кеше аның этисен белгән дигән сүз! Кем ул, каян һәм ни өчен «килеп капты!» дип кычкырды. Аның этисен эзәрлекләүчеләр һаман калганмыни әле?

Икенчедән, бар халык Ырсытдин кызы дип йөргән Мәүлия, баксаң, аның үз апасы икән!.. Нигә шулай якын ул дисәң, кан тарткан икән ләбаса... Әйе, бала чактарак аның колагына шуңа охшашлы хәбәрләр килеп кергән иде, әмма үсә, исәя төшкәч, Шамил кайберәүләрнең авылда аның этисен яратмауларын, аның хакында теләсә нинди гайбәт таратырга әзер икәнлекләрен бик яхшы белә иде. Шул сәбәпле ул имешмимешләргә ышанмады, күңеле гел Мәүлиягә тартылды... Мәхәббәт булмаган икән ул! Нишләргә хәзер? Ике араны ничек көйләргә? Турыдан-туры әйтеп кызның хәтерен калдыруың бар. «Сабыр бул, әнкәсе белән арасы өзелүе бар, мин әйткәнне берүк Мәүлиягә белдермә!»— дип кисәтте бит әткәсе.

Мәүлия Шамилнең үзенә мөнәсәбәте үзгәрүен шул мизгелдә үк сизде, ләкин төс төшермәде, исе китмәгән булып кыланды. Шамилнең кинәт үзгәрүенә урмандагы булган хәлләр сәбәпче дип юрады.

Алтын Мөгез утравын эзләү шулай тәмамланды. Таптылармы алар утрауны, тапмадылармы — моны беркем, хәтта Закир агай да әйтә алмады. «Шунда иде ул, мөгаен, саз утрауны да суырып алгандыр!»— дип тәмамлады.

Шулай карар кылдылар: Күчем хан хәзинәсе сакланган утрауны саз йоткан!

«Кемнәр булды икән теге бәндәләр?»— дип баш ватты егетләр. «Эх, ычмасам берсен тотып ала алмадык!»— дип үкенеште алар. Мөхәммәт Уразаев колгасар өрәкнең саз өстеннән табылган иске күн букчасын үзеннән калдырмады. Кайтышлый аны тиешле органнарга кертеп биреп, саз арасындагы сәер очрашулар турында хәбәр итәргә кирәк иде.

Кәефе бик нык кырылды Мөхәммәтнең, юк, хәзинә табылмаганга түгел, хәзинәнең барлыгына ул берчакта да ышанмады, аның юклыгын раслар өчен балаларны сәяхәткә алып китте ләбаса. Әмма аның азагы шушы кадәр дә күңелсез, дәһшәтле һәм шикле тәмамланыр дип кем уйлаган?! Букча эчендәге кәгазьләрне кат-кат актарып караса да, ул бернәрсә дә ачыклый алмады. Бердән, су үтеп алар шактый җебегәннәр, чыланганнар, куен дәфтәрендәге язуларны аерырлык, кулдан гына сызып ясалган картадан берни белерлек түгел иде. Мөгаен, болар да Күчем хан хәзинәсен эзләгәннәрдер дип уйлады уйлавын Мөхәммәт. Балаларга:

— Качкыннар иде булса кирәк. Бәлки, безнең яктан качып киткәннәрнең берәрседер!— диде.

Йосыф:

— Капуштыр әле!— дип кычкырып җибәрде.

— Эз югалтучылар бер Капуш кына түгел,— диде Уразаев...

Кыскасы, шәһәргә кайтып җиткәч ул яшьләрне авылга озатып, үзе әлегә Тоболда калды, иң әүвәл РОНОга кагылды, мөдирнең киңәше белән НКВДга китте, күн букчаны тапшырып, бик озаклап аңлатма язуы язды. Бер сорауга җавап табуы аерата кыен иде: Айсетдин кайда? Үлеме? Тереме?

НКВД начальнигы каш җыерып аны озатып калды, сазлыкта табылган букчаны криминалистларга бирделәр...

* * *

Юк, Айсетдин исән, үлмәгән иде. Ул Ялан белән бик ансат аерылышты, дипломы үзендә, паспорты янында, аңа тагын ни кирәк? Укытучы кадрларга кайда да кытлык, бара да керә, кирәк икән, укыткан стажын юллап алачак. Аз гына җил басылсын да, дулкын туктасын. Алары югалмас!

Чырыкка: «Кара халык арасына чумам!»— дип алдаса да, ул туп-туры Омск шәһәренә юнәлде, чаялыгы бар, юк җирдән дә билетын тапты, поездга утырды һәм һич көтмәгәндә апаларына барып керде. Һәм шунда, апаларының ян бүлмәләрендә, соңгы көннәрдәге вакыйгалар белән исергән башын ап-ак йомшак мендәргә куйгач, аның хәтеренә кылт итеп бер нәрсә килеп төште: Мөхәммәтнең хатыны Сания Уразаева монда имтиханнар биреп ята бит! Шушы шәһәрдә. Һәм Айсетдиннең тиз үк, хәзер үк Санияне күрәсе килә башлады, нәфесе котырды. Ул яланаяк килеш кенә апасы йоклый торган якка чыкты һәм:

— Апа, медицина институтының тулай торагы моннан еракмы?— дип сорады. Апасының бу сорауга бер дә исе китмәде, энесе врачлыкка укырга керергә ниятлиме әллә дип кенә уйлады һәм йокы аралаш:

— Монда, күршедә генә,— дип куйды.

Иртәгә үк Санияне эзләп табарга карар кылып, Айсетдин йокыга китте. Күзләре шакмак булсын әле Саниянең!

* * *

Айсетдин үз юлында йөреп ятканда, Ялан авылында аны пыр тузып эзләргә керештеләр. «Качып берәрсендә эчеп ятамы әллә?»— дип Дәүләтша әкә белән Мөхәммәт Уразаев Чырык Абдрахман йортына бардылар.

— Ишеткәнсеңдер инде, Абдрахман әкә?

— Ишетмәгән кая!

— Нәрсә ишеттең?— Уразаев сагайды.

— Соң, бөтен авыл сөйли. Айсетдин мөгаллим сазга батып гаип булган диләр...

— Шулай сөйлиләрме?

— Алай гынамы әле...

Чырыкның соңгы сүзен тыңлап та тормады килүчеләр, аның ни әйтәсе мәгълүм, хәзер сәбәбен табып Уразаевны гаепле ясап куячак. Айсетдиннең фатир хуҗалары да: «Берни белмибез, әйбер-каралары тулы килеш бездә, үзе киткәндәге кебек!»— дип растадылар, тагын бер тәүлек көткәч, Уразаев: «Айсетдин авылга кайтмаган»,— дип, НКВДга хәбәр салды. Анда шулай килешенгәннәр иде. Тоболдан җавап та килде: «Беркая китмәгез, бездән хәбәр көтегез!»— диделәр аннан.

Мөхәммәт Уразаевның башына яңа кайгы төште. Дәүләтша әкә дә аның сәяхәтенең яхшыга булмаслыгын искәртеп:

— Ни шайтаныма шунда барып сөйрәлеп йөрергә иде? Менә хәзер бәласен җый инде. Ярый ла исән-аман булса!— дип куйды.

Нишләсен Мөхәммәт. Фаягөлен житәкли дә мәктәпкә бара. Фаягөлен житәкли дә өенә кайта. Урамда очраганнар аннан читкәрәк тайпылырга тырышалар. Шамиле юньләп сөйләшми дә диярлек, аның үз кайгысы кайгы. Фаягөл әле боларны аңламый. «Әттә, шунда барыйк! Әттә, шуны карыйк!»— дип, әтисен әле анда, әле монда йолыккалый. Эх, Саниясе янда булса! Юк шул, әле аның тагын ике атна чамасы укыйсы бар. Язар иде, аңа хәбәр салыр иде, ярамый, тыныч кына, өй турында хәсрәтләнмичә имтиханнарын биреп бетерсен инде. Фаягөл кайсы көнне йокысыннан җылап уяна, «Әннәм кайда? Әннәм кайда?»— дип әтисен кочаклап җылый. Мондый чакларда Мөхәммәтнең дә күңеле тула, ул да рәхәтләнеп бер җылар, бушанып калыр иде. Тик ир кешеләр җыламыйлар, җылап бушана алмыйлар, аларның хәсрәтләре, күңел түренә җыелып, күңелне ташка әйләндерә. Иртәнге чәйдән соң ул колхоз идарәсенә кагыла, Дәүләтша әкәдән:

— Ул-бу хәбәр юкмы?— дип сорый.

— Юк әлегә,— дип җавап бирә Дәүләтша әкә, күзләрен тәрәзәгә борып, һәм кинәт кычкырып җибәрә:— Җәмилә, бу тәрәзә пыялаларын юып чыгарсаң ни була? Тузанга батып беткәннәр ләбаса! Урамнан үткән кешене танырлык түгел!..

Мич арасыннан башына иләмсез зур яулык бәйләгән идарә җыештыручы Җәмилә килеп чыгып, борынын тарта-тарта, тәрәзә пыялаларын юарга керешә, председательнең кемгә ачуы килгәнен ул да белә, карышып тормый. Дәүләтша әкә дә хәбәр көтә, районнан я «Айсетдин табылды», я «Уразаевны тизлек белән безнең карамакка озатыгыз!» дигән сүз килергә тиеш...

Шулай өч-дүрт көн үткәч, авыл халкының Уразаев оештырган сәяхәтне бәйнә-бәйнә сөйләп, теле тәмам аргач, ничектер, тынычланып, онытылып йокларга ятты Уразаев. Балалар икесе олы якта, ул кече якта йоклый. Кече якта бакчага караган бер генә тәрәзә бар. Аңа муел агачлары терәлеп үк тора диярлек. Муел чәчәк аткан чакны ярата Мөхәммәт, муел чәчәк атканда, яшь чаклары исенә төшә. Сагынырлык әллә ние булмаса да, яшь чак һәркем өчен кадерле, газиз. Шамил белән Фаягөлнең тигез генә сулап йоклаганнарын тыңлана да алар яшьлегенең бәхетле бер чорга туры килүе белән куана... Алар яшьлеге матур хатирәләргә уралып уза... Моңарчы шулай иде. Моннан соң ни булыр? Мөхәммәтне чакырып алырлар... Айсетдин табылмаса? Аны гаепле санап утыртып куйсалар? Сания нишләр? Балалар ни әйтер? Сәгъдетдиннең улы Йосыфның ничек кыйналганы аның күз алдында лабаса! Юк, юк дигәндә дә ызгыш-талаш чыга башласа, кайбер әче телле балалар Йосыфка: «Ә синең әтиең карак, ул төрмәндә утыра!»— дип кычкырмыйлар идемени? Йосыфның да Мәүлиягә күзе төшкәләп йөргәнен, ләкин әнә шул, әтисенең төрмәдә утыруы аркасында гына кыюлыгы җитеп, сүз катарга базмаганын укытучы абыйлары күрмәдемени?! Һәммәсен күреп, әрнеп йөрде, җае килгәндә егетне тынычландырырга тырышты: «Синең әтиең искиткеч гадел кеше иде, Йосыф, яман телләр, ялā, ялган белән аны шулай гаепле ясадылар!»— дип кат-кат әйтте. Ә Шамил белән Фаягөлне кем тынычландырыр? Санияне? Дөресен әйткәндә, әгәр Айсетдин табылмаса, чыннан да, Уразаев гаепле булып чыга бит! НКВД начальнигы туп-туры әйтте түгелме: «Сез олы кеше, коммунист, укытучы, ничек шундый авантюрага тотындыгыз!»

«Авылда халык арасында киң таралган имеш-мимешләргә чик куясым килде. Балалар белеп, ышанып үссеннәр дип теләдем. Алласызлар түгәрәгенә йөртеп кенә аларны хак юлга чыгарып булмый, хак юлны эштә, көрәштә табарга кирәк!»— дип бик әтәчләнеп караган иде.

начальник: «Таптыңмы соң? Хак юл кайчагында төрмәгә китереп тыга ул!» — дип мыскыл итте.

Йокыга китәм дигәндә генә кемдер тәрткәләгән кебек сискәнеп уянды Уразаев, ачык тәрәзәне барып япты, ул яктан жил исә башлады, каты бәреп пыяланы ватып ташламасын тагын. Шул гына житмәгән иде... Тәрәзә ябып яткач, озак та тормады, кемдер шакы-шокы тәрәзәгә кага башлады. Әллә колакка гына ишетелдеме?

Уразаев торды, аяк очларына гына басып тәрәзәгә килде, ут кабызмады, бераз каранып торды, тирә-як тып-тын иде. Шаку тагын кабатланды һәм ул караңгыда тәрәзә янына килеп баскан хатын-кызны абайлады. Кем булыр бу?!

Төнге кунакның Йомабикә абыстай булуын ул тәрәзә ачканчы ук аерып алды.

— Тс-с,— диде хатын, бармагын иренәнә тидереп.— Балаларың йоклыймы?

— Йоклый...

— Монда чык.

Мөхәммәт тиз-тиз генә чалбарын киде, аягына резин галуш әлдерде һәм иңенә иске пиджагын салып бакчага чыкты.

— Йомабикә...

Элек ул аңа «апа» дип тә, «түти» дип тә дәшә торган иде, хәзер ни диярго дә белмәде, исемен атады да аптырап тыелып калды...

— Курыкма,— дип пышылдады хатын,— мин әзгә генә...

— Берәр хәбәр бармы әллә?

— Хәбәрләр бар,— диде жыламсырап Йомабикә.— Яман хәбәр йөри. Сине камыйлар да өтермәнгә ябалар дигән хәбәр бар. Расмы шул?

— Юк, юк, кем мине япсын? Нәрсә өчен?— дип, хатынны тынычландырырга теләде Мөхәммәт. Үзенең күкрәгенә салкын керде, калтырый, дерелди башлады.

— Менә шул, Мөхәммәт... Без — ят кешеләр түгел. Безнең балабыз бар, язмышыбыз уртак. Мин мең бәла, мең хәйлә белән сине төрмәгә алып китүләрен карап калыр өчен кайтмадым монда... Сирәк-мирәк булса да күрер өчен, юаныр өчен кайттым!

— Ырсытдин агай кайда?— дип сорады Мөхәммәт кинәт.

Йомабикә яшь чагындагы төсле итеп, кетердәтеп көлеп жибәрде, караңгыда тип-тигез энже тешләре ялтырады. «Ул бер дә картаймаган!»— дип уйлап алды Уразаев.

— Ырсытдин әкәң мәс булып йоклап калды. Әнә шул гөнаһ шомлыгы Чырык килгән иде, бал койган икән, чиреге белән шуны алып килгән...

— Бал гына алып килгәнме, әллә мине камыйлар дигән хәбәрне дә шул китердеме?

— Шул явыз!— Йомабикә тагын нидер хәтерләп кетердәтеп көлеп жибәрде.— Әчтеләр, и әчтеләр, чирекнең төбенә төштеләр. Ырсытдин әкәң мәс булып түнеп калды. Инде Чырык тизрәк китсен дә синең катыңа барыйм дип янып торам, ә ул, карт ишәк, миңа кулын сузып маташа... «Уян!»— дип теге мәхлукны жилтерәтә башладым, юк, уянмый, селкенми дә. «Юк,— дип Чырык миннән көлә,— бал эченә аз-маз аракы да тондырган идем!» Чыра агачын алдым да тегенең жилкәсенә берне кундырдым. Ничек чыгып киткәнен дә белмәде...

— Саклап тормадымы?— диде шикләнеп Уразаев.

— Мине кем дип белдең? Өенә кадәр үзенә сиздермичә озата бардым...

— Йомабикә...— Тагын кем дип атарга белмәде Мөхәммәт. Куркынып чак кына арткарак чигенде. Йомабикә кайнарланып кочагына алыр дип уйлады. Әмма хатын баскан урыныннан кымшанмады, башын ия төшеп кайнар пышылдады:

— Минем акчам бар... Тегеннән кайтты. Нәрсәгә ул миңа!

— Акча?

— Акча димә син, жаным, акча юл яра ул. Тегендә дим, кирәкле кешеләренә аз-маз төртсәң, йолып та калырлар үзеңне... Әллә безне монда майламыйча кайткан'ар дисеңме? Майлый-майлый, Ырсытдин әкәңә ударник дигән документ алып бирдем... Менә шулай. Ә син элеккечә һаман исәр икәнсең, акча дигәч, котың алынды. Элек тә миннән акча алмый торган идең бит.

— Сөйләшмик без бу хакта!

— Әгәр син йөрмәсәң, үзем юллыйм! Үзем барам, үзем табам!

Бу юлы Уразаев көлеп жибәрде.

— Кем дип белдерерсең үзеңне?

— Беренче хатыны диярмен. Балабыз бар диярмен. Шул бала хакына диярмен.

— Ышанмаслар.

— Ышанмасалар, Ырсытдинне житәкләп алып барырмын. Шаһитлыкка! Менә шул, мин моны әзерли башладым да инде.

— Ничек итеп?— диде коты чыгып Мөхәммәт.

— Мәүлиягә атасының кем икәнен аңлаттым.

— Ул ни диде? Ни әйтте?— диде Уразаев тотлыгып.

— Бик нык жылады. «Шамил минем энем буламыни инде?»— дип инәлде.

— Энең, дидем. Элеккечә якын дус булып калыгыз, шуннан арысы булмасын дип кисәттем. Шамилдә күңеле барын ул былтыр ук миңа сиздереп киткән иде.

Беразга тып-тын калдылар. Мөхәммәт ачык калган тәрәзәне томалап япты һәм Йомабикәгә якынрак килеп болай диде:

— Кайгыртуың өчен рәхмәт, Йомабикә. Ләкин минем хәлем алай ук аяныч түгел. Әгәр инде хәлем начарлана икән, анда да акчага атланып котылырга жыенмыйм. Ялгышым бар икән, төзәтсеннәр. Хатам зур икән, жәзаласыннар. Менә шул...

— Ә мин? Мин?— дип кычкырып жылап жибәрде Йомабикә.— Алладан кала син иkенче булдың, мин сиңа табындым. Безнең кызыбыз бар...

— Кычкырма ул хакта.

— Тәңрем, белмиләр дисеңме әллә? Теге чакта Сания, урамда туктатып, үзе миннән сорады.

— Сания? Ә син әйттеңме?

— Ниен яшереп торыйм?

Әгәр Мөхәммәт тотып калмаса, Йомабикә чайкалып егылып китәр иде. Уразаев аны ике куллап тотып өлгерде, Йомабикә яны белән торган жирдән кинәт йөзе белән аңа борылды, ике кулы белән аның иңнәренә чытырдап ябышты һәм иреннәре белән сөйгәненә суырылды... Озак кына үбештеләр.

— Әйдә, әйдә, өйгә,— дип пышылдады таза хатынның ут капкан иреннәре.

Уразаев аңына килеп өлгергән иде инде.

— Юк, юк... Син мине бәладән йолып алырга килеп, утка салып китәргә телисеңме? Бусы — беренчесе һәм соңгысы, бел! Нәфесеңне һәм телеңне тыя бел!

Йомабикә муел агачына аркасын терәп озак кына елады, аннан яулык почмагын кайтарып битен каплады да тиз-тиз атлап бер сүз дәшмичә бакчадан чыгып китте.

Кая ди ул йокы! Йокы бакчадан да, йорттан да качты. Мөхәммәт, ут кабызып, лампаның филтәсен кысып кына баш очындагы өстәлгә куйды, укырга дип китап алды, күзләр күрмәде, баш эшләмәде, фикере таркау, зиһене тәмам чуалган иде.

Димәк, хәбәрләрне тарататалар. Хәбәрләрне таратып кына калмас-

лар, тиешле органнарга да житкерәчәкләр. Әнә ич, гомергә ышанычлы дус булган Дәүләтша әкә дә бу юлы гаепләү сүзләрен әйтә башлады... Ничек булып бетәр? Ни булып?

Сания ни хәлдә икән? Саниясе...

Саниясе исенә төшкәч, ул аралыкка керде, почмактагы юынгычтан су агызып озаклап юынды, иреннәрен кат-кат чиста сөлге белән сөртте.

31

Көн жилсез, тыныч туды. Җанга рәхәтлек бирә торган җәйге бик хозур иртә. Чалт аяз. Шамил, Иртеш ярына басып, көзгедәй ялтырап яткан су өстенә озак карап торды. Әллә беренче тапкыр күрәме Иртеш буйларын? Беренче мәртәбә яңача карыймы?.. Канатларын җәеп тирбәлеп кенә очып килгән акчарлаклар кайчакта кинәт томырылып төшеп китәләр дә тын аккан суга башларын тыгып алалар. Тынычлыгын бозган кошка рәнҗегәндәй, Иртеш төсен җыерып куя һәм җыерчыклар су өстеннән бер-бер артлы ярга таба бөтерелеп киләләр дә юкка чыгалар. Елга тагын, елмайгандай, кояш нурларын чагылдырып, рәхәт җемелди башлый. Акчарлак тагын чума, тагын түгәрәк алкалар уймаклап су өстендә тәгәрәшәләр дә югалалар. Акчарлак елга белән уйный, шаяра кебек...

Куе әрәмәдә тоташтан кошлар сайрый. Иртеш ярын түгәрәк тишекләр белән чуарлап бетергән яр карлыгачлары, ояларыннан чыгып, зәңгәр күктә бөтереләләр... Әтисе: «Яр карлыгачлары бер чакта да җиргә кунмыйлар, куна да алмыйлар!» — дигән иде. Шулаймы икән? Яр карлыгачларына карап, яшь егетнең хисләре дә тулып таша... Шулар кебек ирекле, бәхетле буласы иде ул! Әнә ич, һәммәсе үз парларын, үз ярын тапкан... Эх, акчарлак булып күккә менәсе иде дә иртән су алырга төшкән Ялан сылуларын ак канат җилпеп сәламлисе иде! Сөйгәненең сөрмәле күзе өстендәге карлыгач канатыдай кашы булып әвереләсе иде дә, мәңге бергә күз белән каш кебек яшисе иде...

Сәер үтте бу көннәр. Мәүлиянең үз апасы икәнен белде, дөнья җимерелмәде, Иртеш кирегә ага башламады, һәммәсе элеккечә калды, искечә, бер мәлгә ул кыенсынып, читенсенеп йөрде дә кинәт җиңеләеп калды. Рәхәт, сәер рәхәт иде Шамилнең күңелендә. Кызык бу дөнья дигәнең! Яшь күңелгә кунган хәсрәт оча да югала икән... Җәйге ак болыт кебек! Мәүлия янында хәзер Йосыф йөри, үз сүзенә юл ачылганны ул да сизә. Ә Шамилнең күзе хәзер башкада — Сәрвәрдә... Әллә элек тә Сәрвәр ягында идеме аның күңеле? Шулай идеме? Иң гаҗәбе, Шамилгә нәкъ әнә шулай булгандыр кебек тоела, ул Мәүлияне кан кардәше булганы өчен генә якын күреп йөргән икән. Бәлки, шуңадыр ул берчакта да Мәүлияне кочагына алмады, аны үпмәде, нидер тоткан икән аны, нидер тыеп торган...

Ә Сәрвәргә мөнәсәбәте бөтенләй башка икән аның, бүтән якынлык, башкача тартылу!

Ул хыял дәрьясына чумып, бер көйне сызгыра-сызгыра Йосыфларга таба юнәлде. Сәрвәрләрнең йорты яныннан үткәндә йөрәге татлы сулкылдап алды. Егетнең муены ирексездән урам тәрәзәсенә таба борылды һәм ул ачык тәрәзә аша сузылган бизәкле яулыкның эчкә кереп яшеренүен күреп калды. «Көткән, юри күзәтеп торган!» — дип сөенеп уйлады ул. Сиздермәскә тели, баш бирми торган гадәте бар Сәрвәрнең. Гел шулай, читтән күз төшереп ала да, туры карадың исә, күз качыра. Шамилнең икәүдән-икәү генә аулакта калып барысы-барысы турында да ачыктан-ачык аңлашасы килә, әле җай чыкмый! Куркыта да... «Ә Мәүлияң?» — дип сорап куйса, ни диярсең?

Мәүлияне хурларга теле бармас, яманларга сәбәп юк, ничек булса да котылыр әле... Ахыр чиктә, әгәр инде Сәрвәр бер дә ышанмаса, сер-

не ачар. Эткәсе, бу хакта бик таралып йөрмә, дип кисәтсә дә, түзмәс. Сәрвәр дә аның хәлен аңлар. Аңларга тиеш.

Шамил килеп җиткәндә, Йосыф Актырнагы белән мәж килә иде. Ап-ак аяклы, текә колаклы овчарка нәселеннән булган Актырнак сырт йонын кабартып өрә дә башлады. Йосыф сискәнеп китте.

— Син йөрисең икән,— диде ул, кулын иптәшенә биреп.

— Кемне көтә идең?

— Болай гына... Ничек болай иртәләдең әле?— Ул Шамилнең ерык авызын күреп алды.— Нәрсә, ак җәймәле көнең туганмы әллә? Авызың колагыңа җиткән.

— Шулайрак бит, Йосыф пигамбәр. Пигамбәр булсаң, әйт, нигә минем авыз ерылган?

— Айсетдин табылганмы?

— Юк ла... Төкер әле шуңа бер! Беркая да китмәс, кайтыр да керер.

— Сөенечең нидә соң?

— Бүген мәктәптә кызлар өмәсе икән. Түшәм кыралар. Юалар. Эти дә шунда. Безне дә чакырды. «Сез пычак кайрап, су ташып торырсыз»,— диде.

— Пычак кайраганга ерылдымы авызың?

— Кызлар була дидем ич! Кызла-ар! Ишеттеңме?

Аның кычкырып әйткән үзенчә аңлап, Актырнак Шамилне ике аяклап кочып алды, уйный, шаяра башлады.

— Син түгел, эт тә аңлады инде... Анда син күрергә теләгән бер кеше булачак.

— Кем ул тагын?

— Мәүлия апа.

— Кайчаннан апа булды әле ул сиңа?

— Туа-туышыннан бирле. Әйдә, күп сорашып, җанымны кыйнама, киттек. Мәүлия синеке. Әй, Мәүлия апа...

Йосыф бераз аптыраштa калса да, «Мәүлия синеке!»— дигәч, аның да иреннәре җәелеп китте.

Иң элек алар Эссәт әкә Фәтхуллин хөрмәтенә утырткан яшь кедр агачлары арасында уйнап йөргән Фаягөлне күреп калдылар. Фаягөл күбәләк канаты төсле күлмәк итәген җилфердәтеп, сары күбәләк куып йөри иде. Шамилне күргәч, ул күбәләген онытып, аның каршысына килде:

— Абыем, әннәм кайчан кайта?— дип сорады.

Гаҗәп кыз бу Фаягөл, әнисен оныткан булып йөри-йөри дә кинәт бер сорау куеп аяктан ега.

— Озакламый кайта!— дип, Шамил кызчыкны ике куллап күтәреп алды һәм һавага чөйде. Бакча белән мәктәп арасындагы бушлыкта учак яна, учак өстенә аркылы таяк көйләп, зур чуен казан асканнар, казанда су быкырдый башлаган, өстеннән уйнаклап пар тарала, казан янында куллары белән бөеренә таянып, Ташкәй басып тора иде.

Авыл урамына кайтып аяк басуыннан ук егетләр Ташкәйдәге үзгәрешләрне сизделәр. Тәмәке тартуы, өс-башының көязлеге генә дә түгел, әллә нәрсәсе үзгәргән иде егетнең. Бу инде кайчандыр Мөхәммәт Уразаевка кыен килгәндә «Мөхәммәт абый әйбәт!»— дип кычкырган беркатлы малай түгел. Күкрәк алга чыккан, кулларын ике якка нык-нык ташлап дөп-дөп басып йөри, кирәктә-кирәкмәстә дә кычкырып көлеп җибәрә, кемнең исеме телгә керсә дә, аның атына берәр мыскыллау сүзе табып кыстыра. Кызларның берсен «кысыр кәҗә» дип атады, икенчесен «җыбыткы, чәчен дә тарый белми», өченчесен «кипкән балык» дип хурлады. Кызлар Убасына җыелган уен күңелсез таралды да куйды. Әле Шамилнең дә, Йосыфның да Ташкәй белән юньләп сөйләшә алганнары юк, уенда ул авыл егетләренә өстән генә карап йөрде, күбрәк кызлар

арасында буталды, мал базарында ат сайлаган сыман, кайсысын чеметеп карады, кайсының арт ягына учы белән шапылдатты.

— Һәй, куяннар, йомшаккайлар!— дип түшләреннән умырып та алгалады.

Ялан егетләре читтән кайтканнарга, кунакка килгәннәргә алай баш бирә торганнардан түгелләр, мәгәр Ташкәйнең кыланышларына әлегә күтәрелеп бәрелмәделәр, түздfestivalәр. Беренчедән, Ташкәй — эткәсе аркасында нужа ашаган кеше, авылдан куылып читтә йөргән бичара. Икенчедән, кызлар арасында абруе бик зур булган Мәүлиянең абыйсы. Ул да кызлар арасында иде, абыйсының йогышсыз кыланышларын, тәмсез сүзләрен ул да күреп, ишетеп торды һәм бертуктаусыз: «Абый, алай кирәкми... Ташкәй, алай ярамый!»— дип инәлде...

Шамил белән Йосыф Ташкәйне монда очратырбыз дип һич тә уйламаганнар иде, йөзләре сүрәнләнде, казан янына барып житмәстән тукталып калдылар.

— Озак йоклыйсыз, егетләр. Мин кызларга биш чиләк су кертеп өлгердем инде,— дип мактанды Ташкәй.— Хәзер пычак үткенләргә керешәбез.

Мәктәп завхозы, тезе ямаулы буй-буй чалбар кигән, тәбәнәк, пеләш башлы Чәләкә әкә (чыны Сәләхетдин була инде!) ишек катына бәләкәй эскәмия китереп, аңа чарны беркетте. Чар килгәнне күреп, мәктәптән кызлар бүселеп чыкты. Шамил белән Йосыфның төксе чырайлары бердән яктырып китте.

— Һи-и,— диде Ташкәй чарны зыр-зыр әйләндереп.— Менә кайда икән ул сылу кызлар!

Кызларга «сылу!» дип хет Дәҗҗал мәлгунь үзе әйтсен, барыбер авызлары ерыла, болдыр баскычында бөялешеп торган кызлар дәррәү чыркылдашып, ак казлар кебек, ак алъяпкычларын кайтара-кайтара ишегалдына төшә башладылар.

— Минем пычакны Шамил үткенли,— диде Сәрвәр.

— Ә минекен Йосыф!— диде Мәүлия.

— Нигә Шамил? Нигә Йосыф?— диде чарның тимер тоткасын кулыннан ычкындырмыйча гына Ташкәй.— Алар чар әйләндерә, мин үткенлим.

— Пычак үткенләргә осталык кирәк,— диде Сәрвәр.— Былтыр түшәм кырганда, һәммәбезнең пычагын Шамил үткенләп торды.

— Былтыр ул булса, быел мин кайттым!

— Әйем лә,— дип карышты Сәрвәр.— Әле сине белмибез, Ташкәй, кулыңнан киләме-юкмы?!

Ташкәйнең шактый калын колаклары бер агарды, бер күгәрде, ул тагын чарны зырылдатып җибәрде дә егетләр янына якын килеп:

— Сез дә шул! Килеп җиткәннәр күзләрен тасырайтып!

— Әле соңга калганнар дип үртәшкән идең...

Ташкәйнең кызган ташына суны Мәүлия өстәде.

— Чарласыннар, Ташкәй абый. Оста барда кулың тый, дигәннәр. Ашыкма, сиңа да чират житәр.

— Ә мин чиратны көтмим. Үзем чарлыйм,— дип карышты Ташкәй.

Шамил белән Йосыф бер авыздан:

— Чарласын әйдә!— диделәр.— Без су ташырбыз!

Арада түбәнрәк классларда укыган юантык кына Рәшидә исемле бер кыз бар иде, ул моңлы тавышы белән:

— Ташкәй абый чарласын, Ташкәй абый!— дип кычкырды.

Шамил күлмәген салып ташлады да, майкачан гына калып, пар атып утырган чуен казаннан классларга су кертә башлады. Йосыф, каш астыннан гына Мәүлияне карый-карый, чар әйләндерергә тотынды, Ташкәй ефәк күлмәгенең якасын чишеп җибәреп, кулларын төкерекләде һәм беренче пычакны, Сәрвәр пычагын, чар ташына куйды. Астан чәчрәп ут көлтәсе күренде, як-якка сибелде, кызлар тирә-якка сибелделәр.

— Пычагы булыр!— дип кычкырды Ташкәй.— Йосыф-Зөләйхадагы кебек бармак кисүчеләр булмасын.
— Зөләйхалар бар,— дип көлештеләр кызлар.— Йосыфлары кайда!
— Берсе әнә чар әйләндерә,— диде кыюланып Мәүлия.
— Икенчесе пычак кайрый!— диде Ташкәй. Әмма аның сүзен куәтләмәделәр. Шамил йөгерә-йөгерә су ташый, казандагы су быкыр-быкыр кайный, пычак тигән чар ташыннан төлке койрыгы булып ут көлтәләре сибелә. Ташкәй кинәт:
— Ах, черт!— дип кычкырып җибәрде.
Аның пычак йөзенә тиеп шуган юантык урта бармагыннан кан чәчрәп килеп чыкты. Чар шып туктады, кызлар аһ иттеләр.
— Юри кистерден син! Әйбәт әйләндермәдең!— дип бәйләнде Ташкәй Йосыфка.
— Нишләп әйбәт әйләндермим ди? Үзең чалыш тоткансыңдыр әле...
Ул арада Мәүлия бакчадан берничә бака яфрагы өзеп алып килеп, Ташкәйнең ярасына каплады һәм чиккән кулъяулыгы белән өстән бәйләп тә куйды. Тавышка Шамил дә килеп җитте, ул, буш чиләген куеп, Ташкәй җиргә ташлаган, кайралып бетмәгән пычакка тотынды. Ташкәйнең пычак кайраганы юк ахрысы, йөзен ташка аркылы тоткан, пычакның үткер йөзе ашалып беткән, шул чагында сикереп китеп, егетнең бармагын каптырып алган ахрысы.
Пычакны ипкә китергәнче шактый маташтылар.
Ниһаять, пычаклар әзер, су ташылган, Чәләкә әкә парталар өстенә калын такталар кертеп салган, эш кызларга тәрәлеп калды, алар бер-берсе белән үртәшеп, сөенешеп, түшәм кырырга тотындылар. Өмә башланды...
Егетләргә эчкә керергә ярамый, кызлар җиңелчә киемнәрдән калып, яланаяк эшлиләр. Егетләр сулы чиләкләрне болдырга китереп куялар да пычрак суларын читкә алып түгәләр. Шамил белән Йосыф алмаштилмәш бу эшне шәп кенә үтәп киләләр иде, арага тагын Ташкәй килеп кысылды. Ул сулы чиләкне баскыч төбенә алып бара да сузылып ишектән эчкә кararга тырыша, чиләк алырга чыккан кызларның шәрә ботларына су чәчрәтә. Бусына да түздeләр Шамил белән Йосыф. Бердән, нужа күргән егет, икенчедән, Мәүлиянең абыйсы... Ә Мәүлия аларның Шамиленә дә, Йосыфына да бик якын. Берсенең — апасы, икенчесенең... Юк, юк, бу сүзне әйтергә Йосыфның теле бармый. Кыюлыгы да юк... Менә Ташкәй сыман телчән булсаң икән ул! Юк, алай булырга да ярамый, әнә ич, кызларның берсе дә аның кыланышын яратмыйлар...
Озакламый, Фаягөлне җитәкләп, алар янына Мөхәммәт абыйлары килде, мәктәп ишегенә күз салгач:
— Кызлар тынычлап эшләсен, әйдә, без бераз хәл җыеп алыйк,— дип, егетләрне калкынып маташкан кедр агачлыгына чакырды.
Утырыштылар. Сүзнең җитди буласын аңлаган кебек Фаягөл дә тынып калган. Актырнак та чалгы янавычы озынлыгы телен көнгә чыгарып күләгәгә сузылып яткан...
— Менә күпме генә гомер үтте әле, сез утырткан кедр агачлары күзгә күренеп килә... Күркәләре генә юк. Кедр күркәне илле яшьтән соң гына бирә. Үзләре сигез йөз елга кадәр яши дигән сүзләр бар. Сигез йөз ел... Әле аларның җимешен сезнең балаларның балаларының балалары гына татый алачак... Менә сез барыгыз да Иртеш таңнарында туган минем агачларым... Сез дә җимешле булып җимешегезне бик күп буыннар татый алырлык булсын иде! Укытучы — җимешле агач белән бер ул... Арадан кемегездер укытучы булыр, кайсыгыз — доктор. Ир-егетләр барыннан бигрәк ил сакчылары булыр. Күрәсез, ишетәсез, ил чигендә хәтәр хәлләр кабатланып тора. Кедр агачы кебек җимешле, нык һәм озын гомерле булып үсегез!
Ни өчен әйтте ул бүген бу сүзләрне — аңлавы кыен иде. Улы Шамил өчен әйттеме? Әллә яраткан укучысы Йосыфка атадымы сүзләрен?

Әллә ерак сәфәрдән кайткан, бик нык үзгәргән Ташкәйгә адресладымы? Белеп булмый, моны Мөхәммәт Уразаев үзе дә аңлатып бирә алмас иде...

Эш тәмам. Мөхәммәт абый Фаягөлне житәкләп, кызларны туктаусыз мактый-мактый классларга кереп китте. Сәлимә өмәдән кайтышлый: «Кичкә Кызлар Убасына чыгыгыз!» — дип, егетләргә хәбәр салып үтте.



## 32

Былтыргы сайлауда Дәүләтша әкә үзен яңадан колхоз председателе итеп куймауларын үтенгән иде.

— Картайдым, яшьрәк кешене сайлыйк. Эше дә бик күп, язу-сызуы да мәшәкатьле. Миңа жиңелрәк бер эш, йә атлар карауны бирегез, йә ындыр табагына куегыз,— дип ялынып караган иде, жыелыштагылар дәррәү кубып, аның сүзенә каршы килделәр.

— Моңарчы эшләдең ич, эшләрсең әле!

— Ирләр картая диме?

— Без сиңа күнектек, син — колхоз эшенә.

Ай-ваена куймый, тагын Дәүләтша әкәне председательлеккә өндиләр... Шунда ул көтелмәгәнрәк бер сүз әйтте:

— Әгәр инде мине калдырабыз дисез икән, әйдә, шулай булсын, ил авызын иләк белән каплап булмас. Мәгәр миңа бер булышчы, ярдәмче бирәсез. Яшьрәк тә, житезрәк тә, сүзе үтә торган да булсын.

— Теләсә кемне сайлап ал!— дип кычкырды жыелган халык.

— Әгәр риза булсагыз, мин Гыйззәтбану киленне ярдәмчем итеп алыр идем. Чаялыгы да бар, язу-сызуга да оста, эшкә дә житез.

Гыйззәтбану түти исемен ишеткәч, жыелыштагылар бер мәлгә генә тынып калдылар. Алдагы рәтләр дәшмәде, арттагы рәттән тонык кына:

— Нигә, ярый...

— Булсын әйдә.

— Риза,— дигән тавышлар ишетелде. Бераздан алар да тынды.

— Нигә сүзегезне кычкырып әйтмисез?— дип сорады Дәүләтша әкә.

Тимерче Лотфый торып басты.

— Ни бит, Дәүләтша әкә, Гыйззәтбану жиңгинең ире... Сәгъдетдиннең кайда икәнен беләсең... Утыра лабаса ул!

— Утырса ни? Срогын тутыргач бер кайтыр. Гыйззәтбануның ни гаебе бар?

Бу юлы гөрләшеп үк Гыйззәтбануны колхоз председателенең ярдәмчесе итеп сайладылар. Ул үзе исә алдагы рәтләрнең берсендә, күзен кешеләргә күрсәтергә кыенсынып, мышык-мышык жылап утыра иде...

Колхоз активы, идарә әгъзасы булгач, Мөхәммәт Уразаев белән Гыйззәтбану жиңги еш кына очрашкалап тордылар. Мөхәммәт: «Йосыфның хәлен белешергә кердем»,— дигән булып, аларның йортына еш кына килеп чыга, йә бер нәрсәне сораша, йә шаярта, көлә, Сәгъдетдиннең хәлен белешә, хатларын укый, йорт өстенә килгән кайгыны жиңеләйтергә тырыша иде.

Һәркемнең үз хәле хәл. Сәгъдетдин кайтып житте, әле Мөхәммәт Уразаев алар бусагасы аша атлап кергәне юк. Гыйззәтбану укытучы Айсетдиннең хәбәрсез-өнсез югалганын бик яхшы белә, Мөхәммәтнең мәшәкатьле чагы икәнен дә аңлый, шуңа күрә ерак жирдән кайткан ире белән күрешергә керә алмавына да үпкәләми.

Бер көнне Гыйззәтбану түти бер каз, ике акбалык күтәреп үзе Уразаевларга килеп керде. Мөхәммәт нәни кызы Фаягөлгә ниндидер китап укып утыра иде.

Гыйззәтбану түти кулындагы күчтәнәчләрне өстәлгә үк китереп салды.

— Менә, яхшылыгың өчен рәхмәт йөзеннән, Уразай иптәш, Сәгъдетдинне коткаруларын сорап ике тапкыр югарыга яздың. Син язмасаң кайтармыйлар иде аны!— диде ул.

Уразаевның түсе карангыланып китте.

— Ник соң, Гыйззәтбану апа, мине алай кимсетәсең? Мин шулай түләү алыр өчен булышты дип беләсеңме? Беләсең килсә, кылган яхшылыкны акбалык белән генә түгел, алтын белән дә бәяләп булмый. Юк аның бәясе. Бу юлы хәлдән килгәнчә яхшылыкны мин эшләдем, кемдер мәнә синең ярдәмгә мохтаждыр, мин дә ярдәмгә бик мохтаж кеше. Әнә шулай түләнә ул!

Кызып килеп кергән Гыйззәтбану түти бүләкләрен өстәлдән җыештырып, авызын ачып аптырап калды. Аннан исенә төшеп хуҗаны кунакка чакырды.

— Сәгъдетдин абзагыз озын юлдан кайтты. Беломор канал дигән әйберне төзедек, ударник булдым, ди. Олы бәйрәм. Зур куаныч. Йосыфым да этиле булды. Иң олы куаныч минә, янымда ирем. Шул менә, бүген кичен кузайтынга килегез.

— Ай, менә монысына рәхмәт! Һичшиксез, килермен!— дип калды Уразаев.

Әйтүен әйтте, барыр чак җитә башлагач аптырашта калды: күчтәнәчкә ни алып барырга? Әле ярый, Мөхлисә апаның каклаган кәреше бар икән, шуны кереп алды. Фаягөлне дә әбисенә куанычка анда калдырды.

Гыйззәтбануның мөгаллимне дә кузайтынга чакырып кайтуын белгәч, Сәгъдетдин бик нык уңайсызланды, гомергә кызмаганны, хәтта бераз кызып та китте шикелле.

— Соң мин сиңа кат-кат әйттем ләбаса,— диде ул Гыйззәтбанута.— Күчтәнәчләреңне илт, рәхмәт әйт тә сүзеңне кыска тотып чыгып кит дидем!

— Күчтәнәчләремне алмады,— диде Гыйззәтбану түти дә югалып.— Нигә мине рәнҗетәсез, ди. Көчләп калдыра алмыйм ич мин.

— Өстәлендә калдыр да чыгып кит иден.

— Шундый кеше сүзенә хатын-кыз башым белән ничек каршы килим?

Хатынының бу сүзендә акыл өстенлек алганын тоеп, Сәгъдетдин уздыгына гына сукрана башлады.

— Хатыны өйдә булса бер хәл иде. Күчтәнәч эзләп интегәчәк... Ул намуслы кеше, күчтәнәчсез килергә яхшысынмас! Җитмәсә, теге явыз Ырсытдинне дәшкән идем шул! Хәзер аларның икесен бер түргә ничек утыртасың?.. Ике бүре баласы бер бүреккә сыямыни?

— Әллә Ырсытдинең килер дип беләсеңме? Авырып ята ич ул!

— Бушлай ашарга дигәндә Ырсытдин ләхетеннән калкынып килеп җитәр. Сур өргәнне көтеп тә тормас, кубарылыр!

Гыйззәтбану түти ирен артык борчырга теләмичә, казаны тирәсендә кайнаша башлады, майда гына кетердәтеп сөбер бавырсагы пешерергә тотынды. Көн кичегеп килә, кунаклар, шат-иншалла, көттермәсләр. Сәгъдетдин олы кеше, төрмәгә явызлык кылып эләкмәгән, кузайтынга җыелган халык, күрше-күлән тагын бер кат шуны ныгытып чыгарга тиешләр. Сые зурның — йөзе нур. Моны бик яхшы белә Гыйззәтбану түти.

Кайтканнан бирле артык мантымаган, ята-тора йөргән Сәгъдетдин дә торып утырды, бил каешын ишек янындагы чөйгә элеп, бритвасын чаж-чож үткенләп алды, сакал-мыегын тигезләде, каналда эшләгәндә, сакал-мыек үстереп җибәргән икән, килешә тагын үзенә. «Эткәнә, Һади бабайга охшый башладың тәмам!»—дип куандырды күршеләре. Гыйззәтбану да каенатасын искә төшереп почмакка кереп җылап алды...

Ак күлмәген киеп, камзулын иңенә салып, тәрәзә янына утыргач, Сәгъдетдин тагын бер көрсенеп алды һәм:

— Ырсытдин белән Мөхәммәтне бер табынга чакырып, хур булмасак кына ярар иде... Алар бит ут белән су!— дип зарланып куйды.

— Олы кешеләр аш янында талашып, сүгешеп, авыз тәмсезләп утырмаслар инде!— дип аваз салды Гыйззәтбану түти казан яныннан.

Ул арада гөрләшеп диярлек күршеләр килеп керде, алар артыннан ук аргы күршеләр кереп тулды. «Кунаклар килә башламадымы?»— дип баядан бирле тәрәзәдән күзәтеп торган карчык-корчык, алъяпкычларына бер әчмүхә таза чәй, кипкән шомырт, бал, капламыч белән яңа язган май тотып, кардәш-ырулар килде, бик мыштырдап кына, гыжлый-гыжлый тын алып, Ырсытдин да килеп керде, аның кулы буш иде, әмма аңа игътибар итеп тормадылар, үзе дә күптән түгел генә сәфәрдән кайткан кеше, әйдә, монда хәзер ризык-фәлән житәрлек. Акбалыкны Гыйззәтбану түти олы агач табак белән китереп утыртты:

— Кунаклар, хуш килдегез! Сәгъдетдинемне олылагансыз, рәхмәт.

Өстәл тирәсенә утырышканда, кунаклар кыюсыз гына күренгәннәр иде, ашарга дәшкәч, куллар бердән хәрәкәткә килде, һәркем тәртип белән генә үз алдына ризыкларны алып куярга тотынды, авызлар ачылды, тешләр әпипәгә бии башладылар, ризыклар тәмле, татлы исле, авызлардан су китереп кенә тора иде. Сәгъдетдин: «Әле ярый Уразай килмәде!»— дип уйларга да өлгермәде, өйалдында аяк тавышлары ишетелде һәм Мөхәммәтнең:

— Рөхсәтме керергә?— дигән сүзләре үзеннән алда килеп тә керде.

— Әй, туган, рәхим ит! Менә түрдән уз!..

Җыелганнар, кысылышып, Мөхәммәткә урын бирделәр. Түргә таба сырышкан Ырсытдин гына кузгалмады, бер кашы аска төште дә, икенчесе өскәрәк күтәрелде. Уразаевның аш-суларга йөрергә яратмавын ул бик яхшы белә иде.

Себердә аш мәҗлесләрендә әллә ни сүз сөйләргә яратмыйлар, монда тәртип-низам белән, ашны олылап, җыелганнарны кадерләп, ризыкка күбрәк игътибар бирәләр. Хуҗаның бавырсагын тоташтан мактадылар, акбалыкның авызга кергәч тә эреп китүенә сокландылар. Ара-тирә авызлар чапылдап куйды да: «Булган бу!», «Бавырсагы ла бавырсагы!», «Сумсаларын әйт син!»— дигән сүзләр яңгырады. Гыйззәтбану түти үзе табынга утырмады, ул килгән һәр кунакка игътибар итәргә тырышты, кемнеңдер алдына тастымал китереп бирде, кемгәдер, кыюсызрак утырганнарга, тәмлерәк һәм олырак кисәкләрне куярга тырышты, берәүләрнең тамагы кипкәнен чамалап, чынаягы белән чәй ясап китерде.

— Үзегез алып килгән көчтәнәчләрдән авыз итегез, үз көчтәнәчен ашаганнарның гомере озын була!— дип өндәде ул.

Сәгъдетдиннең Гобәйбә буйдактан алып кайттырган бер чирек көмешкәсе дә, Чырык Абдрахманнан алган балы да бар иде. Ырсытдиннең каш астыннан гына карап-карап алуыннан ул эчемлек чыгарырга бик вакыт икәнен аңлый, мәгәр, Уразаевның андый эшне өнәмәгәнен белгәнгә, өстәлгә исерткеч чыгарырга һаман базмый иде. Гыйззәтбану түти ризык китергән булып, кул арты белән аңа ике-өч тапкыр ышкынып китте, бу аның: «Кунакларың артык сабыр утыра, әз-мәз кыздырып җибәр!»— дигән ымы иде. Арадан кемдер:

— Тамак төбе дә кычытып тора иде бу араларда!— дип, бугазын да ышкып алды, Ырсытдин аны куәтләп ютәлләп куйды.

Ул арада ачык ишектән үзе белән җил иялтеп Чырык Абдрахман килеп керде, аны күргәч, өйдәгеләр дәррәү көлеп җибәрделәр. Моны көтмәгән Абдрахман бусага аша атлады да туктап калды, сакалы очлаеп алгарак чыкты, өскәрәк күтәрелде:

— Нигә шаркылдыйсыз алай?— диде Чырык.

— Болай гына!

— Болай гына түгел, мин килеп кергәч көлә башладыгыз. Аңынчы тып-тын утыра идегез.

Чырык ишектә күренүгә, үк кемдер: «Кайда аш — Чырык шунда баш!»— дип пышылдаган иде, шуңа көлеп җибәрделәр. Ник көлгәннәрен ачыкламыйча ук янә кунакны да табынга чакырдылар, күңелең киң икән, урын тарлыгы сизелми. Һади картның ярым җиргә чуккән өенә дә шулкадәр кеше сыйды...

Чырык Абдрахман баштa дога укыган кебек булды, битен сыпырып алды һәм Сәгъдетдинне авыр сәфәрдән исән-сау кайтуы белән котлагач, кыска гына итеп:

— Әллә ачы балны төпләдегез дә инде?— дип сорады.

— Төпләдек, төпләдек!— диде бераү аны үртәп.

Сәгъдетдин, җай табылуына сөенеп, ни арада мич арасына барып та житте Гобәйбә буйдактан алып кайттырган көмешкәне тартып та чыгарды:

— Сине көтә идек, Абдрахман әкә!

— Шулаймы? Ә, бәракалла! Бәй, Ырсытдин кордаш та монда икән, күрми дә торам!— Бераүгә дә кул бирмәгән Чырык, өстәл аша үрелеп, Ырсытдинга ике кулын бирде һәм шунда гына күргән сыман Уразаевка да эндәште:

— Мөгаллим дә зурлаган Сәгъдетдинне, рәхмәт инде, рәхмәт.

— Саумы, Абдрахман әкә!— дип шат кына сәлам бирде Уразаев.

Өстәлгә көмешкә чыккач, ул Йосыфның өйдә булмавына куанды. Эчемлек тирәсендә мавыгырга яратмаган Уразаев, яшьләр, балалар алдында эчүгә катгый каршы иде. «Начар йогынты ясыйбыз балаларга, мәҗлес саен өстәлгә исерткеч чыгарабыз, юкка да эчәбез, барга да чөмерәбез!»— дип ачу белән кабатларга ярата иде ул. Тик бу мәҗлестә Сәгъдетдингә каршы төшеп сүз әйтмәде, аның ак күлмәге аша төртеп торган үткер калак сөякләрен, бары тик кара төкләрдән һәм юан тамырлардан гына торган ябык кулын күргәч, ул аны ифрат дәрәҗәдә кызганды. Кемнәр белән хезмәт итәргә туры килмәгәндер бу намуслы, юаш татарга! Төрмәгә җыен әтрәк-әләмне, каракларны, бурларны, ришвәтчеләрне, фахишләрне, җан кыючыларны китереп тутырганнар, дип ишеткәне бар иде аның... Алар һәм шушы Сәгъдетдин!

Ул арада ике тустаганны каплап өлгергән Чырык Абдрахман тамагын кыра башлады, барысы да аңа таба текәлделәр, Чырыкның сүз әйтергә җыенганы күренеп тора һәм ул бик хәтәр сүз әйтергә җыенгандагы кебек тамагын чистарта иде.

Уразаев та күтәрелеп аңа карады, аларның күз карашлары очраштылар. «Картайса да, күзе тирән кое кебек әле моның!»— дип уйлады Уразаев.

* * *

Чырык Абдрахманның аш-суны, мәҗлесләрне, ачылган һәм ачылмаган шешәләрне яратуын без беләбез инде. Әмма бу хәйләкәр кешенең тагын бер ягын искәртеп узыйк: Абдрахман бер мәҗлескә дә әзерлексез килми иде. Мәҗлескә әзерләнә ул, нык әзерләнә, эзләнә, тыңлана, уйлый, үткәннәрне хәтерли, барыбер таба, җыелганнар аз-маз кызып китеп, колак тишекләре киңәя башлагач, ул утырдашларына бер-бер ят хәбәр ирештерә, я китап гыйбрәтләрен сөйли, оятсызрак мәзәкләр дә ычкындыра. Әмма аның максаты бер: мәҗлес халкының игътибарын үзенә юнәлтү! Һәм һәрдаим диярлек бу теләгенә ирешә дә ул.

Сәгъдетдиндә чуар халык буласын әллә кайчаннан чамалап куйды ул, Калининга ике тапкыр хат язган Уразаев та чакырылыр дип көтте, юлда беренче очраган Ырсытдиннең дә читтә калмаслыгын белде, буйдак Гобәйбә өеннән чыккан тоныкк көмешкәне дә Сәгъдетдин йортына кадәр күзе белән озата килде, күрше-күләннән кемнәр керәсен дә бөртекләп санап чыкты... Бу кадәр һәм төрле-төрле халыкның исен китерерлек бик җитди, мөһим сүз әйтергә кирәк иде аңа...

Ниһаять, кашыклар тукталды, авызлар йомылды, колаклар тырпайды, чүгез, Ялан авылының өлкәне Чырык Абдрахман сүз әйтә! Монда, табын тирәсендә ыбыр-чыбыр халык белән бергә, мөгаллим Уразаев та бар, әлерәк кенә сөргеннән кайтып егылган Ырсытдин чал да монда, житмәсә йорт хужасы Сәгъдетдин әллә кайдан жәһәннәмнән, Беломор каналы дигән урыннан кайткан зат, йорт хужасы Гыйззәтбану килен дә төшеп калганнардан түгел — колхоз рәисе Дәүләтша әкәнең ярдәмчесе, димәк, сүз дә эредән, зурдан булырга тиеш.

— Әле, килешли, мәрхүм Айсетдин торган йортка кагылдым... Жидесе үткәрмәгән, анысы каралмаган, монысы эшләнмәгән. Жаны сазлык өстендә каңгырып йөри торгандыр...

Бөтенесе көрсенеп куйдылар. Чырык бик тәкъвә кыяфәт белән жыламсырап дәвам итте:

— Исән булса, Айсетдин мөгаллим дә бу йортның түрендә утырыр иде дим... Яшь булса да, абруйлы, солтанатлы зат иде.

Хатын-кыз мышык-мышык жылап жибәрде, Уразаев уңайсызланып кына:

— Нишләп Айсетдинне мәрхүм дип атыйсыз, Абдрахман әкә?— дип сорады.

— Исән икән, кайда соң ул?— дип тиз үк эләп алды Чырык.— Жирдә юк, күккә ашмаган. Я суга баткан, я сазга. Суга батса, гәүдәсен күрер идек.

— Әле тикшерү бара, тәмамланмаган, алай сөйләп, халыкның күңеленә коткы салмагыз.

Дәү генә акбалыкны ике куллап тотып алган Ырсытдин дә теш арасыннан гына:

— Тикшерү аның жанына кагылмый... Гәүдәсен табарлар да, жанын кем кайгыртыр? Абдрахман әкә шул хакта гәпләде гуй.

Ни әйтсен Уразаев? Кулында төпле генә дәлиле юк, тәки Чырык Абдрахман мәжлесне үзенә каратты да куйды, күрше-күлән, карчыккорчык, Чырыкның моңарчы кылган этлекләрен, явызлыкларын, алдауларын онытып, «Булса да була икән изге кеше, югалган адәмнең адашкан жаннарын кайгыртып гомер уздыра!»— дип сокланып уйладылар. Карын тәмле ашлар белән шыплап тулганда, сине, кеше рәтенә кертеп кузайтынга чакырганда, күңелгә начар уйлар иңәмени? Шуны бик яхшы чамалый карт төлке Чырык Абдрахман! Нәкъ әнә шул мизгел килеп житкәч кенә, кунаклар тукланып, кәефләнеп алгач кына сүзен әйтә дә куя!

Чирек авызыннан күбекләнеп ачы бал акты, иреннәргә тустаганнар менеп төшкәләде, Мөхәммәт янадан эчемлеккә үрелмәде, иплән кенә урыныннан торды һәм Сәгъдетдиннең колагына иелеп:

— Сый-хөрмәтегез өчен бик рәхмәт, бушый төшкәч, керермен әле, я үзең килеп чык, Сәгъдетдин туган, ныгытып бер сөйләшеп утырасы бар,— диде.

Сәгъдетдин сөякчел куллары белән аның иңен кочып алды.

— Мәңгегә онытмам. Жаным тәнемнән чыкканда да сиңа рәхмәт укырмын!— дип пышылдады хужа.

Гыйззәтбану түти Уразаевны озата чыкты.

Мөгаллимнең аяк эзләре басылып та өлгермәде, Сәгъдетдин йортында Чырык Абдрахманның тавышы гөрләде.

— Төрмә ул берчакта да буш тормый, Сәгъдетдин дус! Суырып кына тора ул кешеләрне! Менә син чыктың, Ялан авылыннан тагын берәрсе барып кабачак.

— Син әллә төрттерәсең инде?— диде яратмыйча Ырсытдин.

— Әстагыйфируллла тәүбә, авызыңа жил кердеме әллә, Ырсытдин? Син болай да нужарган бәндә, юкка жәфа чиккән кеше. Сиңа булып ашкан! Бүтәннәр дә житәрлек әле... Төрмә буш тормый, буш торса, төрмә булмый ул.

Бөтен күзләр табындагы тәмле ризыклардан Чырыкның авызына күчте. Ә ул ашыкмый, ике бармагы белән чеметеп кенә каклаган кәрешне каба, кәреш артыннан ук сумсаны да тамагына шудырып җибәрә, чәйнәп-нитеп тә тормый, ара-тирә баллы тустаганына да үрелергә өлгерә. Ә мәҗлес халкы көтә! Ни әйтер? Ни булыр? Аның сүзе болай гына бетмәгәнне бөтенесе күреп торалар лабаса!

— Синнән бушаган урынга бу юлы, мөгаен генә, Уразай кереп утырыр!

Өйдә үле тынлык урнашты. Сәгъдетдин сикереп торып Чырыкның сакалын учлап алырга тели, ярамый, кунакны рәнҗетү олы гөнаһ! Казан тирәсендә Гыйззәтбану түти каударлана: «Каян килеп керде бу иблис, кузайтынның бөтен ямен җибәрде! Хәзер бу хәбәрне бөтен авылга таратачаклар... Кем йортында булды мондый сүз дип Мөхәммәт кызыксынмый калмас. Уллары Йосыф та моны ишетер. Мөгаллимгә сыңар сүз дә ишеттергәнне яратмый ич Йосыф. Үзенең дә укытучылыкка укып йөргән көне... И, аллам. Берәрсе, кулыннан килеп, шушы ярык барабанны туктата алмас микәнни?»

Юк шул, куркалар Чырыктан, каргышы төшәр дип шикләнәләр, бозым җибәреп, гомерлеккә сарыга сабыштырыр дип уйлыйлар. Һич уйламаганда Ырсытдиннең күгәргән тавышы ышкылып чыкты:

— Алай димә, кордаш! Төрмә капкасы сиңа да ачык.

Чырык чәчәде, тамагына ашы тыгылды, ул йодрыгы белән күкрәген төйде:

— Миңа нигә ачылсын икән ул? Ярты авылның язмыгын үземә алып, тормышларын җиңеләйтеп киләм! Минем ни гөнаһым бар?

— Төрмәгә гөнаһлылар гына керми,— диде кыюланып Сәгъдетдин.— Төрле кеше бар анда. Айсетдин югалса да, Уразайның ни гаебе булсын? Йосыф сөйләп торды, бүтәннәр дә ап-ачык күргәннәр, көпәкөндез ди бит, теге урман өрәкләре килеп чыккач та Айсетдин артка карап томылган! Егет булса, качмасын иде, анда егетләр җитәрлек ич, ике өрәкне генә бугазлап атырлык! Яман кешенең куркаклыгы яхшы кешегә бәла китерә! Монда да шулай булгандыр дип беләм.

Гыйззәтбану Сәгъдетдингә яратып, олылап карады. Кирәк чагында аның Сәгъдетдине дә сөйләшә ала икән лабаса! Ничек кенә сөйләшә әле, каплады да куйды Чырыкның тишек авызын. Ә аның авызын капларга бик күп кирәк! Менә, күпме яшәп, аңа каршы чыга алганнары юк иде, тәки адәм көлкесенә калдырды...

Тьфу, тьфу, сүз тыңлап йөреп өйалдына чыгарып куйган самавыры ташый башлаган түгелме? Кеше самавырының көен дә белмәссең, үзләренекенең борыны ага.

Мөхәммәт барында бисмилласын әйтергә базмаганнар иде, ул югында иркенләп, озаклап дога кылдылар.

Ырсытдин белән Абдрахман курадан бергә чыктылар. Капканы чыккач, Абдрахман юлдашына бер карап алды да:

— Үзгәреп кайткан дип әйтимме сине?— дип сорады.

— Дөнья үзгәртә ул,— диде Ырсытдин.— Әҗәл якаңнан алса, үзгәрми нишлисең...

— Өшкерергә бик вакыт сине, Ырсытдин,— диде Чырык.

— Өшкергәч, сине сыйларга симез казым юк шул әлегә. Көзгә инде, алла боерса,— дип Ырсытдин, бер яктан ымсындырып, икенче яктан нык кына төртгереп куйды.

* * *

Абдрахманның Айсетдин торган фатирга керүенең сәбәбе бөтенләй бүтән иде, яшь мөгаллим югалса ни дә, югалмаса ни, менә аннан калган кием-салым кемгә булыр да кем кулына төшәр, бу турыда әле ныгытып уйларга, алдан ук әзерлеген күреп куярга кирәк! Килешли, чыннан да,

ул Айсетдин фатирына кагылып үтте, чамасын белеп кенә сөйләште, ул-бу хәбәр юкмы? Тоболдан тикшерүче-мазар килмәдеме, дип белеште. Хәзер, Сәгъдетдиннең көмешкәсе, ачы балы белән шактый нык кыюлангач, тагын бер кат сөйләшеп куярга булды. Егетнең ак костюмын, ак ботинкаларын кия алмас киюен, мәгәр аларны менә дигән хакка сатып җибәрергә була! Өр-яңа эшләпәсе дә бар аның, тунын да былтыр кыш уртасында гына тектерде, пималары,— уһу, җыя башласаң, шактый мал табылачак әле анда! Югалдымы Айсетдин, югалды, бирсен ходай, табылмасын гына! Инде егетнең вакытын белеп кенә югалуы Мөхәммәт Уразайдан да коткарса... Аллага мең шөкерен укыр иде Чырык!.. Мең шөкерен! Әгәр Уразай булмаса, бүген Ялан авылында Чырыктан да абруйлы, димәк, аннан да аш-сулы, бай берәү дә булмас иде!

— Тагын мин йөрим әле монда,— диде ул юаш кына кыяфәт белән ишек катына басып. Кичке чәйдән әлерәк кенә купкан хуҗалар, күзе шомартылган калай кебек елтыраган Чырыкны күреп куркып калдылар, алай да түргә чакырдылар.

— Чәйдән генә торган идек...— диештеләр.

— Юк, юк. Сәгъдетдин бик каты сыйлады. Кунаклар да олыдан булды, Ырсытдин кордаш та килгән иде, Уразай да шунда, бүтәннәр дә шактый җыелган. Сүздән-сүз чыгып, Айсетдин турында да күп сүз сөйләштек.

— Ниләр сөйләштегез икән алай?— диештеләр тагын да куркынган хуҗалар.

— Җидесен үткәрергә бик вакыт!... Сазга китәр алдыннан аның миңа әйтеп калдырган сүзе бар иде. «Инде хәвефле сәфәргә чыгам, Абдрахман әкә, Яланда синнән дә якын кешем юк, әгәр ул-бу килеп чыгып, кайта алмасам, минем рухыма багышлап коръән чыгарсын, шуның барәбәренә үземнән калган һәр нәрсәне сиңа һиба кылам»,— диде. Аллаһ тәгаләм боерган булса, җидесен дә үткәрербез, кырыгы да килеп җитәр, гөнаһысына кермәм, анысын да башкарып чыгармын. Әле, дим, истә чагында Айсетдин мәрхүмнең әйбер-караларын җыештырып алып кайтып куйыйм, дим... Кеше вафатыннан соң малга ия табыла ул!

Хуҗалар, бик аптырашып, бер-берсенә караштылар, ир башын чайкап аска карады, хатын, юантык кына сипкелле абыстай:

— Нишләп мәрхүм дә мәрхүм дисең алай, Абдрахман әкә? Төшеңә шулай кердеме әллә?— дип сорады.

— Үлгән ул, тере булса, кайтып күренер иде. Уразай да шулай дип торды, Ырсытдин кордаш та шул фикердә, бүтәннәр дә шуны куәтләде. Җаны җир белән күк арасында адашып, тилмереп йөрмәсен дим...

Карый Чырык: хуҗалар кече якка, пәрдә артына кереп югалганнар. Чыш-пыш сөйләштеләр, бөтен сүзләре ап-ачык ишетелеп тора.

«Бирмә!»— ди хатын. «Кадалып китсен әйдә!» Хатын һаман карулаша: «Соңыннан сүзе булыр!» Ир: «Чит кеше алып китми лә!» «Кайтып килсә?» «Сиңа булыр, диган. Алсын да китсен!»

Абдрахман шыпырт кына елмая, эченнән генә көлә башлый, күз кырые белән генә караштыра: Айсетдиннең әйбер-карасы бер күтәрүдә алып китеп бетерерлек тә түгел!

## 33

Шәһәр җирендә яшәү авыл тормышына караганда күпкә җиңел саналса да, Сания шәһәр шартларына күнегеп бетә алмый, өнәми дә, авылдан чыгып китүгә үк Яланын сагына башлый.

Тулай торакта яшәүче курсташ кызлары белән дә ул күбрәк авылы, авыл кешеләре, кызы турында гына сөйләшә.

— Ялан авылын син шундый итеп сөйлисең!— ди аңа Омскиның үзеннән ерак та түгел бер авылда врач булып эшләүче кыз Галя.—

Барып күрәсе килә синең авылыңны! Әллә ожмахны Иртеш буена күчергәннәр инде.

— Чын! Ожмахның үзе инде бездә!— дип эчкерсез куана Сания.

Галя былтыр гына әле Сания кебек үк фельдшер булып эшли иде, хәзер медпунктларын «больницага» әйләндергәннәр, ике медсестра, бер санитарка биргәннәр дә дүртенче курс студенткасы Галяга врачлык вазифасын йөкләгәннәр.

— Алайса сине хәзер Галина Васильевна дип йөртергә кирәк икән?— дип шаярта Сания.

— Мине шулай дип йөртәләр дә!

Сания тагын Ялан авылын мактауга күчә, «Авылда урта мәктәп ачарбыз, менә Йосыф белән Мәүлия югары белемле укытучылар булып кайтыр. Урта мәктәпле авылда больница була да була инде. Син диплом алуга, больница да ачып җибәрербез. Тормышыбыз шул кадәр матурланыр!»— дип сөйли бит аның Мөхәммәте...

Әлбәттә, гел-гел авылың турында гына сөйләп имтиханнарны биреп булмый, Сания Галя белән гел бер бүлмәгә керергә тырыша, ипле кыз, иренә тугры, кайбер кыска итәкләр кебек табан кыздырып йөрми, укый, әзерләнә, укуны төп эше итеп саный. Сания татар авылында яшәгәч, ел дәвамында русчасы аксый, рус сүзләрен әйткәндә теле көрмәкләнә, аерым сүзләр йотылалар, «а» дип әйтәсе килә, «ә» килеп чыга, шуңа күрә ул Галяга русча сөйләп күрсәтә, тегесе иренмичә тыңлый, ялгышларын төзәтә, яшьтәш булсалар да берсе укытучыга, икенчесе укучыга әйләнә, моңа берсе дә рәнҗемиләр, икесенә дә рәхәт, күңелле.

Бүген Сания йокысыннан эче пошып уянды...

Уянды да тынычсызлыгы сәбәбен эзләнеп борсаланып ятты. Әле сәгать дүрт кенә, будильникны иртәнге алтыга куйганнар иде, ул ашыкмыйча гына иртәнге секундларны саный, бүлмәдәге дүрт кызның өчесе таралып йоклый, бер Сания гына уяу, һәм күкрәгенә авыр таш бастырганнармыни, кайсы якка борылып ятса да йөрәге типкәнен ишетә, йөрәк тибешен куанып тыңлап ята торган Сания, бүген йөрәк тибешен ишетүенә борчыла, сәламәт кеше йөрәк тибешен ишетергә тиеш түгел... Ни булды соң? Гистологиядән имтихан бирделәр. Белгән темасы туры килде, контроль эшенә дә «яхшы» билгесе куйганнар, анысы да бер куаныч... Өйдән хат юк дисәң, әле киткәненә кайчан гына, Мөхәммәт алай хат язарга яратып та бетерми, аны артык эш дип саный... Авылда бер-бер хәл булды дисәң, ни булсын, дөньялар, илләр тыныч, көтелмәгән хәл туса, телеграмма сугар иде. Фаягөл исән-сау йөрсен, әбисе йорты белән әтисе арасында тик чабып йөри торгандыр, балакаем... Саниянең кызын үзе кебек үк врач итеп тәрбиялисе килә, ул инде Сания сыман, олыгаеп барганда гистологияләр белән чиләнеп утырмас. Яландагы яңа ачылган урта мәктәпне тәмамлар да туп-туры институтка китәр, врач булып та туган авылына кайтыр...

Алар, Мөхәммәт белән икәү, әби-бабай булып аның бәбиләрен, оныкларын карарлар, ул әнисе сыман бер бала белән генә калмас, дөньялар бүтән булыр, мөмкинлекләр артыр, һәммәсе яхшыга таба бара ич!

Һәммәсе шулай, тик нигә шулай вакытсыз уянды ул? Элек тә иртә уянган чаклары була иде, торып сәгатькә карар иде дә, борылып, шунда ук тынычланып йокыга китәр иде. Бүген күзгә йокы әйләнеп кайтмас ахрысы, шулай тоела, нидер җанны кимерә, талый... Сания аяк очларына гына басып барып тәрәзәне ачып куйды, аннан бөркелеп иртәнге саф һава кереп тулды, кошлар чыркылдаша башладылар. Кайдадыр машина гөрләде, кемнәрдер кычкырып сөйләшә-сөйләшә урамнан үтеп киттеләр...

Аның шулай борсаланып таң каршылавын Галя да сизгән икән.

— Сиңа ни булды, җанашым Сания?— дип сорады ул.

— Үзем дә белмим.— дип җаваплады Сания.

— Яман төш кердеме әллә?
— Төшемдә мин авылымны гына күрәм. Анда нинди яманлык булсын, ди?
— Авырып торасыңмы әллә?— Галя йомшак учы белән Саниянең маңгаен тотып карады.— Юк шикелле.
Иртәнге чәйне, кичтән алып кайтып куйган ак булка белән өйдә генә эчтеләр. Чәйдән соң шунда ук көтепханәгә барырга җыендылар. Кызларның берсе вокзалга туганын каршыларга китте, икенчесе җөйчегә барырга булды, Галя белән Сания, икенче каттан төшеп, буш дип әйтерлек коридорны үтеп урамга чыктылар. Шунда, тулай торак каршындагы бәләкәй генә бакчадан бер кеше күтәрелде, аның шәүләсен генә күреп калса да, кеше Саниягә бик таныш кебек тоелды, иртәнгә хәтле тынычлана алмаган йөрәк сулкылдап алды.
— Һава үзгәрергә тора,— диде Галя күккә карап. Күктә, чыннан да, тоташ болытлар тартылган, иртәнге куанычлы зәңгәрлек йотылган, офык читенә каралҗым-кalын болытлар асылынган иде.— Шуны сизгән синең йөрәгең!— диде дә, тукталып Саниягә карады.— Агарып киткәнсең дип әйтимме, җанашым!
— Галя, син бара тор. Мин әз генә туктап хәл җыйыйм инде,— диде Сания.
— Ничек калдырып китим ди мин сине, җанашым?
— Юк, юк, бара тор. Мин хәзер куып җитәм!— дип Сания уңга борыласы урынга, туп-туры атлап китте һәм бая күзгә чалынган шәүлә, хәзер кеше кыяфәтенә кереп, аның каршысына килеп чыкты.
— Айсетдин иптәш? Сезме бу?
Айсетдин эндәшми, көлеп тик карап тора.
— Ничек килеп чыктыгыз монда?— дип сорады тагын да каушабрак Сания. Аның ике чигәсе дә сулкылдап сызларга тотынды.— Мине эзләп килдегезме, әллә мин сезгә бүген очраклы гына тап булдыммы?
Һаман эндәшми теге кире тәре, Саниянең газапланганын күреп, аның тагын да ныграк каушавын көтә, фикере чуалганын, зиһене буталуын тели.
Сания ачуланып кычкырып җибәрде:
— Әллә телегезне үк йоттыгызмы? Нигә газаплыйсыз мине? Өйдә бер-бер хәл булдымы әллә?
— Юк, юк, һәммәсе тәртиптә, Сания ханым,— диде Айсетдин.— Курыкмагыз.
— Курыкмыйча! Мин сезне очратасымны бүген таңда, сәгать дүрттә үк белдем. Һәм яман хәбәр китерәсегезне дә аңладым. Сөйләгез.
Ул Айсетдин утырган эскәмиянең икенче башына барып утырды, хәле киткән иде.
— Апаларда кунакта мин. Алар монда гына яши, Пионер урамында, унҗиденче йорт, үз хуҗалыклары белән торалар.
«Урамны һәм йорт номерын әйтергә кирәкми иде!»— дип шунда ук үкенде Айсетдин, әмма Сания ханымны тынычландырыр өчен чын дәлилләр, чын фактлар, урам исеме, йорт номеры бик кирәк иде, югыйсә, моннан ары булачак сүзнең кадере калмаячак, ул аның бер сүзенә дә ышанмаячак. Урам, йортларны бутәнне әйтәсе калган, хәер, бәлки дөреслек аны җиңүгә китерер? Әгәр Айсетдин уйлаган барып чыкса, Санияне барыбер апалары йортына алып бармыйча булмас бит, адресның дөреслеге Айсетдиннең сүзләренең кадерен арттырачак, үзенең абруен күтәрәчәк. Ә Айсетдин Саниянең үзенә ышануын бик нык тели иде...
Ялан ягында гел-гел җиңелеп килгән сынык күңеле, ниһаять, бер мәртәбә булса та тантана итә алырмы, юкмы?! Шушында, аулак шәһәрдә Айсетдин әллә кайчаннан күзе кызып йөргән Саниянең тәнен татып карармы, юкмы?.. Шул теләген тормышка ашырыр өчен Айсетдин әллә нинди этлеккә дә риза, ул илдарга әзер, ялганларга да, куркытырга да, кирәк икән, җанын сатарга да әзер!.. Бар иде бит, Сания менеке булыр,

дип өметләнгән чаклары да бар иде, ә кыз тотты да әнә шул карт тәкә Мөхәммәтне сайлады... Мәүлия үсеп җитеп, пешеп өлгергәндә генә аны да Айсетдин кулыннан тартып алдылар.

— Мин ялда, монда апаларда кунакта,— дип кабатлады Айсетдин.— Мин сезнең мондалыкны әйттем. Мәктәп мөдиребезнең хатыны Сания ханым да монда әле, дидем. Алар бик куанышып сезне кунакка чакырып калдылар.

— Әгәр мине көтеп торуыгыз шуның өчен генә булса, ихлас рәхмәт. Ләкин минем кунакка йөрер чагым түгел. Тагын ике имтихан бар, мин көтепханәгә ашыгам, иптәш кызым борчыла торгандыр.

Сания китә башлаган җиреннән тукталып, бераз гына көтеп торды, ул Айсетдиннең тел төбендә ниндидер сүзе барлыгын сизенде, ләкин кунакка килгән егет авызын ерып, тиле кеше сыман тик кенә аңа карап торды, артыгын сөйләшмәде. Инде шактый киткәч кенә Сания борылып кычкырды:

— Йорт-җир, күрше-күлән исәндер бит?

— Исән, исән... Ни булсын ул Ялан авылында!

Әнә шул «Ни булсын ул Ялан авылында!»— дигән мыскыллау сүзе Саниянең шиген арттырды, ул әллә ниләр уйлап бетерде, Галяның сорауларына кирле-мырлы җавап биреп шаккатырды, инде төштән соң, көтепханә буфетына кереп чәй эчеп чыккач, укырга алып торган китапларын күтәреп чыгып барганда, исенә килеп, чак кына «китап карагы» исеме алмыйча, көтепханә хадимәләреннән кат-кат гафу үтенеп кайтырга чыкты.

«Китап карагы!» Шул гына җитмәгән иде ди бүген...

Ул бик борчылып, түземсезләнеп кичне җиткерде. Айсетдин белән сүз куешмасалар да, ул әрсез егетнең үзен эзләп табачагын белә иде, шулай булды да, кайтып, өс-башын алыштырып, күрер-күзгә бик җыйнак кына киенеп, китабын тезенә алып утырганда, тулай торакның дежурные кереп:

— Уразаева, сезне чакыралар!— диде.

Айсетдинне көтеп утырса да, Сания коелып төште...

* * *

Айсетдин уйларының очы булмый иде еш кына, мәсәлән, бүген аннан: «Ник качып киттең инде син Алтын Мөгез утравы яныннан?»— дисәләр, ул анык кына җавап бирә дә алмас иде. «Ялан авылын нигә ташлап киттең?»— дигән сорауга да җавабы әзер түгел әле аның. Ул утырырга, йөрергә, бик ныгытып уйларга, кат-кат үлчәргә тиеш. Шунда гына, инде кирәге бөтенләй калмагач, аның җавабы әзер була, өлгерә... Омскига да тиктомалдан, алдан уйламыйча гына чыгып китте ул. Туганнарына бик ансат кына «Кунакка!»— дип әйтеп салды, Саниянең Омскида икәнлеген дә монда килгәч кенә исенә алды.

Иртән тулай торак ишеге төбендә көтеп торганда да аның башы буп-буш, анда иләс-миләс җилләр генә уйный, Яланда татыган ачу-үпкәләре генә өскә калыккан иде.

Көндез исә ул тирән уйга чумды...

Сания андый-мондый уенга ышана торган җилбәзәк ханым түгел, ул — ир хатыны, бала анасы, ятим Шамилне җанына сыйдыра алган тугры ханым. Дөньяга карашы киң булмаса да тирән, намус, вөҗдан дигән төшенчәләрне ул ана сөте белән гомерлеккә үзләштергән зат. Күңелдәге ачы төен, көнләшү, аңа ия булырга омтылу кебек хайвани хисләр белән генә аны яулап ала алмассың! Әмма бу юлы көлкегә калырга да ярамый. Алда гомер ничек булса булыр, иллә мәгәр бу юлы Айсетдин Саниянең ялгызлык форсатыннан файдаланып калырга, аны абындырырга, җиңәргә, аның аша мөртәт Уразаевтан да, Айсетдинне үз итеп бетермәгән караңгы Ялан авылыннан да үч алырга кирәк.

Бу — максат! Анысы ап-ачык һәм мәгълүм, әмма ул максатка ирешү юллары кайда?

Уйлары тыгызлыгыннан аның мие тәмам кайнады: ул ашын ашамады, ял итмәде, бер почмактан икенче почмакка йөрде дә йөрде...

Кинога чакырсаң — кермәс, «Берәр җирдә капкалап чыгабызмы әллә?»— дип, ресторанга-фәләнгә өндәсәң, бармас, аулак бакчага-мазарга хәйләләп кертсәң генә инде...

Ул аптырап урамга чыгып китте, аулак бакчаны да караштырды, ләкин кичке очрашуга үзен әзер дип исәпли алмады.

Кинога керде ди, ресторанга барды ди, аулак бакчага да чакыра алдың, ди... Ни әйтерсең аңа? Нинди ышандырырлык сүз белән авыз ачарсың? «Яратам»,— дисәң — көләчәк, кочагыңны җәйсәң — мыскыллаячак, үбәргә үрелсәң — яңагыңа чабып җибәрәчәк...

Нишләргә? Ничек һушын алырга, ничек аңын томаларга, ничек итеп өметен өзәргә?

Ишек ачыгына баскан Айсетдиннең сүзләре әле һаман әзер түгел иде. Әнә икенче кат баскычыннан, култыксаларга тотына-тотына, гади ситса күлмәк кигән, ак туфлядан, иңенә бөрчекле ал яулык япкан Сания төшеп килә. Бөтен гәүдәсендә, тотышында нидер көтү, борчылу сизелә...

Әнә шунда гына Айсетдиннең башында мәкерле бер план өлгерде... Бәлки шул сүзләр белән, шул хәбәр белән аны аяктан егып булыр?

— Хәерле кич!— Сәламе артык төче һәм мәгънәсез килеп чыкты бугай. Сания аны сизмәдеме, сизмәмешкә салыштымы, сәламне алмады:

— Айсетдин иптәш, мин бик азга гына. Безнекеләр ни хәлдә, авыл, шуларны сөйләгез дә, керәм. Мине иптәш кызым көтә, әзерләнәсе бар.

Сания күтәрелеп карады, икенче катның ачык тәрәзәсеннән Галя кул болгады һәм:

— Сания, озак йөрмә!— дип кычкырды.

Чыкканда ук шулай килешенгәннәр иде. Айсетдиннең комарлыгын, әрсезлеген чамалаган Сания, аның бүген дә сыткый сагыз кебек ябышып ятасын аңлый иде.

Айсетдин сүз башларга ашыкмады, хәзер сүзсезлек никадәр озакка сузылса, чат аның файдасына гына булачак. Иптәш кызының ашыктыруы да, төптән уйлаганда, егет файдасына гына. Ашык, гүзәлем, кабалан, ашыкканда кеше ашка пешә, ялгыша, үзенең ни кылганына исәп биреп бетерә алмый.

Хәзер ул үзе сораша башлаячак!

Дөрес чамалады Айсетдин, иртән очрашкан нәни бакчага кереп утырдылар, кеше йөри торган урын, аяк асты, әмма башта монда утырырга да була, Сания Айсетдиннең дәшмәвеннән гаҗиз булып үзе сорау бирә башлады.

— Исән-сау калдылармы?

— Исән.

— Дәүләтша әкә ни хәлдә?

— Әйбәт.

— Ят хәбәрләр юкмы?

— Ишетелмәде.

Сания көрсенеп Галя калган тәрәзәгә күз ташлады, юк, кыз күренми, куе яфраклы тупыл агачы каплаган.

Айсетдиннең хәтеренә төште, күңелле хәбәре дә бар ич әле аның! Менә ул аңа ярап куячак. Башта бик күңелле хәбәрне әйтәсең дә, аннары тегесенә сикерәсең... Дөресрәге, сикертәсең.

— Сәгъдетдин абый кайтты бит!— диде ул кинәт.

Саниянең йөзенә нур бөркелде:

— Сәгъдетдин әкәме? Менә сөенеч! Гыйззәтбану апа шатланган-

дыр инде. Ничек кайткан, сәламәтме? Ниләр сөйли?..

Айсетдин куанычыннан нишләргә дә белмәде, кайтып барганын очраклы гына күреп калуы файдага булды бит! Бара торгач төрмәдән кайткан Сәгъдетдин Айсетдингә тел ачкычына ярады.

— Сәламәт дип... Ите булмаса да сөяге кайткан. Хәзер авылга кайткач имтиханнарга әзерләнгәндә, сезгә, врач кешегә, файдалы әсбап бар хәзер Яланда.

— Нинди әсбап?

— Әйтәм ич, Сәгъдетдин абый тере скелет инде, сөякләре шакшок килеп тора.

— Алай ук булмас ла!

— Әллә канал казуны җиңел дип беләсеңме? Көне-төне эшләтәләр икән, ашау ягына килгәндә, бер кадак ипи дә бер кружка су, ди. Норманы үтәмәсәң, әле анысы да юк икән. Карцер дигән таш капчыкка утырталар икән. Себер ныклыгы, крестьян булуым белән генә котылып калдым, ди. Аннары, статьям да ул кадәр куркыныч түгел иде, ди... Миңа әйтә, «Синең кебек мөгаллимнәр анда, ди, чебен урынына кырылды, ди».

Сания ышанырга да ышанмаска да белмәде, әмма үтә дә сөйкемле Сәгъдетдин әкәнең коры сөяккә калуын күз алдына китереп, кулы белән күлмәк җиңен бөтергәли башлады, күз төпләре дымланды.

— Шуннан, шуннан...

— Арада угры-караклар да күп икән, алар бөтенләй эшләмиләр икән. Эшләүчеләргә бирелгән ипине талап ашап яталар, ди...

Боларын ул кайчандыр төрмәдә утырып кайткан ерак кардәшеннән ишеткән иде, инде бераз үзеннән өстәп тә җибәрде:

— Тыңламасаң, буйсынмасаң, каршы сүз әйтсәң, аяк-кулларыңа богау салып таш капчыкка кертеп ыргыталар икән. Анда күсе мыжлап тора икән, йокыга китсәң авыз-борыныңны кимерәләр, ди.

Сания чирканып читкәрәк тартылды.

— Нигә сөйлисез сез миңа боларны? Максатыгыз ни? Нишләп куркытырга уйлыйсыз? Мин сездән гаиләм, ирем турында бер-бер юньле сүз көтәм. Сез сөйләгән әкиятләрне мин Бастилия төрмәсе тарихларыннан да укыган инде. Әкият сатып утырасыз. Эш юктан эш табып.

Айсетдин кинәт җитдиләнде, йөрәге куырылып йомарланды, иреннәре ярсып кысылды да, ул көчләп диярлек үзен елмаерга мәҗбүр итте.

— Әкият түгел, Сания ханым. Сез һәрвакыттагыча ялгышасыз, тормыш кырыс чынбарлык ул, аның катылыгы белән очраша калсаңмы, ул беркемне дә аямый! «Төрмәдән һәм хәерче капчыгыннан берәү дә ерак йөрми!»— ди рус туганнарыбыз.

— Тагын төрмә турында!

— Әйе. Чөнки якын араларда сез бу сүз белән гел очрашып торачаксыз... Әйе... Сезнең якын кешегезне тагын кулга алдылар.

Сания көч-хәл белән:

— Кемне? Мөхәммәтнеме?— дия алды.

— Әлбәттә, шуны! Аннан да якын кешегез бармыни сезнең? Сания ханым, карамагыз алай итеп, илчегә үлем юк, мин бары тик хәбәр җиткерүче генә... Аңа калса, сезгә ярдәм итәргә теләүче дә. Һәрдаим миңа таяна аласыз...

Заманның катлаулы икәнен белә Сания, авыздан-авызларга шыпырт кына төрле хәбәрләр йөри, Ялан авылында Мөхәммәт Уразаевның дусларыннан тыш, сөймәүчеләре барлыгын да аңлый, әллә берәрсе булмаган гаеп табып тагын камадылармы бичараны? Теге чакта, аклар шпионы булгансың, дип җанын талаганнар иде, әллә шул калкып чыктымы? Айсетдин артыгын сөйләмәде, Саниянең сораштырыр хәле дә калмаган иде.

Байтак вакыт сүзсез утырдылар. Сания өмет белән тагын тулай

торак тәрәзәсен эзләде, тәрәзә күренмәде, көн караңгылана башлады, кич килде, урам фонарьларын кабыздылар, бакчада үтеп-сүтеп йөрүчеләр ишәйде. Ул кинәт көтелмәгән бер кыюлык белән очып урыныннан купты да Айсетдиннең якасыннан эләдереп алды.

— Сөйләгез! Дөресме бу хәбәр!

Айсетдин тартылды-йолкынды, күлмәк сәдәбе өзелеп чыкты, мәгәр Сания нык тоткан иде, егетне ычкындырмады.

— Сөйлә, сөйлә!

— Бу хәлдә... ничек сөйлим ди? Җибәрегез! Зинһар!

Сания яканы беразбушатты, мәгәр ычкындырмады, егетне арты белән эскәмиягә этеп китереп, лып итеп утыртты, үзе аның каршысына басты. Айсетдин аңа күтәрелеп карарга да базмады.

— Ну, ни инде... Мин гаепмеме? Яканы җибәрегез дим... Күчем хан хәзинәсен эзләргә баралар... Мөхәммәт абый балаларны алып бара, Шамилне, Маннурны, Йосыфны...

«Кызларның да исемен әйтсәм, бөтенләй ышанмас!» — дип Айсетдин бүтәннәрне әйтеп тормады. Сания болай да ышанмаска теләгән иде, китәр алдыннан кем авызыннандыр колагына кергән сүзләр хәтеренә төште: «Хәзинә... Алтын Мөгез утравында Күчем хан хәзинәсе саклана икән!»

— Сөйлә.

— Баралар болар. Мине дә кыстадылар, бармадым, бараммы соң? Электәге бандадан калган ике бандит тә нәкъ шул чакта хәзинә эзләргә килеп чыгалар. Берзаман эзләүчеләрнең юлы очраша, бандитларның берсе сазга батып үлә, икенчесен тотып алалар.

— Ә Мөхәммәтне нидә гаеплиләр?

— Банда белән бер сүздә булып хан хәзинәсенә хуҗа булырга омтылуда гаеплиләр. Шунда ук кулга алдылар үзен...

— Һәм сез аны аяп аласы урынга авылдан чыгып качтыгызмы?!

Кай арада ялган сүзгә дә дөреслек катышып китә, кай чагында кыек атып та туры китерәсең. Сазлыкта күргән өрәкләрне чынында Айсетдин: «Алла, каргышы, алтын-көмешне саклаучы җир асты каравылчылары!» дип кабул итте; «бандит» дигәннәре хәзер генә, Сания якасыннан алгач кына теленә һәм уена китерде... Дөресен әйтә язды бит, әй! Сания, авылдагы һәм сазлыктагы хәлләрне әле тулаем белмәсә дә, Уразаевка кыен хәл туура ук бу куркакның чыгып качуына ишарәләп, шулай ук туп-туры тидерде!

— Чынмы бу, чынмы бу! — дип кабатлады Сания күлмәк якасын ычкындырып.

— Ходай белән ант итәм! — дип ычкындырды кайнарланып Айсетдин һәм ходаен шушы ялганга тартуына күңеленнән генә тәүбә итә дә башлады. Бүтәнчә Санияне ышандырырлык дәлиле юк, ә аның ышануы бик кирәк иде...

Боерган булса, шушы татлы сулышлы хатын аныкы булачак!

Дөресен әйткәндә, төнге дүрттә уянып, иртән Айсетдин белән кыска гына очрашканда ук Сания Мөхәммәтенә нинди дер яман хәвеф килгәнен яки киләчәген уйлаган иде инде. Балаларга ул-бу булмас, алар әтиләре янында, әбиләре дә көн туса кыптырдап килеп җитеп, Фаягөлне яман күздән ана каз кебек саклап торадыр. Мөхәммәте генә караусыз, аның кинәтлеге дә, тәвәккәллеге дә бар, һәммә эшкә барып тыгыла, холкы шундый, туры һәм кискен, андый кешене хәзерге заманда буташтырып кую да бик җиңел...

Ырсытдиннәр гаиләсеннән башлап, аның төп-тамыры, Сәмукныкылар, һәммәсе ачулы ич аңа! Карун Рәхмәтулланың да нәсел-нәсәбе Яланда астан гына ут йөртә, боларын да ишетмәде түгел Сания, Шәукәтнең дә һаман оныткакы юк. Сания очраган саен: «Карт куеның да калач бар, калачыннан кан тамар!» — дип үртәп йөри... Мөхәммәтне борчымас өчен генә Саниянең бу хакта һич сүз чыгарганы юк, әмма

ишетә ул, рәхәтләнеп ишеттерәләр. Ялган белән яланың аягы җиңел шул! Аны абындыручы юк.

Чыннан да, Мөхәммәт, яшьләрне ияртеп хәзинә артыннан китте микәнни? Нигә ул хакта бер дә әйткәне булмады?..

Исенә кайтса, ул эскәмиядә утыра имеш, янында Айсетдин, ул бөтен кыяфәте, котсыз сүзләре белән аны ипкә китерергә маташа:

— Нигә ул кадәр янарга? Сез яшь, көчле. Алда гомерегез бар. Яшәргә дә яшәргә генә әле... Уразаев бүген булмаса иртәгә барып каба торган кеше иде. Аны утыртып куяр өчен бер сүз җитә. Дуамал яши...

— Җитте сезгә!

— Ни уйлаганымны гына әйттем, сезне кызганып, Сания ханым.

— Сәгать ничә?

— Тугызынчы ярты.

«Поезд төнге унберДә! Өлгерәм!» — дип Сания җилкенеп урыныннан купты.

— Кая барасыз?

— Кая барасын да белмәгән сарык дип белдеңме әллә мине? Аптырап, исәнгерәп калып, адаштырырмын дип көттеңме?

Һәм юаш Сания, сабыр Сания; чебенне дә рәнҗетмәгән Сания көлеп торган Айсетдинне ачу белән этеп җибәрде дә шундук юкка чыкты.

«Тагын хаталандым, тагын барып чыкмады!» — дип Айсетдин бакчада ыжгырып калды...

Сания атылып икенче катка менгәндә Галя чәйнек тотып кубовойдан чыгып килә иде, чак кына бәрелешмәделәр.

— Галя!

— Әбәү, котым калмады.

— Син декан Порфирьевның кайда торганын беләсеңме?

— Беләм. Профсоюз урамында.

— Киттек!

Сания әйберләрен аннан-моннан гына чемоданына тутырды да, Галя ясап өлгерткән чәйне дә эчмичә, чыгып чапты. Галя аңа иярде. Бәхетләренә күрә декан өйдә иде.

— Ирем бәхетсезлеккә очраган, миңа бер минут кичекмичә кайтып китәргә, кош булып очып кайтып җитәргә кирәк, — диде Сания. — Ике имтиханны кышкы сессиягә кичектерә аласызмы?

Порфирьев — ике иякле, шикәр чире белән интегә торган кеше — бераз уйланып торды.

— Кышын болай да биш имтихан, җиңә алырсызмы? — дип шик белдерде. Сания өчен Галя җавап бирде:

— Җиңәбез, Борис Ефимович, бергәләп җиңәбез!

Шунда ук гариза язылды, гаризага Порфирьев имза салып, аны иртән үк деканатка Галя кертеп бирергә килешенеп, тиз-тиз саубуллаштылар. Порфирьев Сания ишек катына житкәч, ул гына ишетерлек итеп:

— Кулга алганнармы? — дип сорады.

— Шулайрак...

Порфирьев гаризага шулай ашыгып кул куюына үкенеп куйды, аннары кул селтәде:

— Хәерле юл!

Күңелгә килгән — алга килә, билет та табылды, юлга ризык та сатып алып өлгерделәр. Омск вокзалында Санияне тугры дусты Галя озатып калды...

## 34

НКВД начальнигы Данилов бу юлы ягымлырак булып чыкты... Ул Уразаевны чиратсыз кабул итте, кергәч исәнләште, урындык тәкъ-

дим итте. Эче пошып килгән Уразаевның күңел ташы бераз гына эрегән сыман да булды.

— Качкын кешедән хәбәр-хәтер юкмы? — дип сорады ул тәмәке төтененә күмелә-күмелә.

— Бездә юк, сездә инде өмет, иптәш Данилов.

— Айсетдиннең югалу сәбәбе нидер дип уйлыйсыз?

— Бары тик куркаклыгы гынадыр дип беләм. Табигате белән куркак кеше иде бит.

— Алай! — Данилов тегесен сүндереп тә бетермичә, яңадан папирос кабызды һәм алдында яткан чуар-чабар кәгазьләрне актарды. — Үз белдегегез белән хәзинә эзләргә керешүегез өчен сезгә РОНОдан шелтә булачак, анысын көтеп торыгыз... Ә безнең тарафка килгәндә, сезгә шелтә дә бар, рәхмәт тә!

— Рәхмәте ни өчен, иптәш Данилов?

— Иске күн сумканы исән-аман кайтарып тапшыруыгыз өчен.

— Берәр файдалы нәрсә килеп чыктымы?..

— Без Ахманай авылы гражданины Закир Әхмәтов ярдәмендә сазга баткан кешенең мәетен юллап ала алдык. Кесәсендәге карындыкка төрелгән кәгазьләргә караганда, ул без бик күптән эзли торган Ялан авылы кешесе Рәхмәтулла булса кирәк.

— Рәхмәтулла!? Булуы бик ихтимал!

— Ни өчен алай ышанып әйтәсез?

— Урман өрәге: «Уразай килеп капты!» — дип кычкырмас бит инде.

— Дөрес сукалыйсыз, иптәш Уразаев... Тик безгә Рәхмәтулланың мәете түгел, үзе, сүзе кирәк иде. Аның кайдадыр сеңүе турында бездә кайбер фактлар бар иде. Алтын Мөгез атавы янында булган икән аның гомеренең соңы!

— Ә икенчесе кем, икенчесе!

— Иң кызыгы шунда ки, иптәш Уразаев... Икенчесе, качып киткән бандит белән дә сезнең юллар кисешкән булып чыкты... Теге чакта, партизаннарда йөргәндә, паромны аклардан тартып алырга җыенганда сез поручик Канталыев отряды белән очрашкан идегезме? Урамда очраткан икенче бандит шул отрядтан...

— Кем ул?

— Улмы? Бик билгеле кеше. Михаил Сорокин. Фотосы да бар. Менә карагыз.

Саргая төшкән фотодан алтын погоннарын ялтыратып, яп-яшь көяз генә офицер карап тора иде.

— Күргәнем юк сыман...

— Яхшылабрак карагыз! Хәзинә тирәсендә ул бер тапкыр элэгэ язган иде инде, шуннан безнең күздән югалды. Эзен чуалтты. Минемчә, алар Рәхмәтулла белән очрашып, шунда сүз берләшкәннәр дә, хәзинәне бергәләп яулап алырга ниятләнгәннәр.

— Сорокин тотылмадымы?

— Әлегә юк...

— Кызганыч...

— Хәзер бик кызыклы бер сорау туа бит әле! Сорокин да юк, Ялан авылы укытучысы Айсетдин Хәйретдинов та юк! Бергә качмадылар микән алар?

Данилов, тәмәке төтенен ачык тәрәзәгә өрә-өрә, өстәл артыннан калкынып Уразаевка таба иелә төште. — Я, ничек уйлыйсыз? — диде ул аның күзләренә керердәй булып карап.

— Юк, иптәш Данилов, андый эш аның кулыннан килмәс!

— Алтын дигәндә куркаклар да арысланга, юашлар да төлкегә әйләнә.

— Анысы шулай, тик Айсетдин Хәйретдинов андый үк этлеккә бармас. Кешегә кара ягасым килми, яшь кеше, хаталары да күптер, мәгәр ышанып әйтә алам: Сорокинга иптәш була торган кеше түгел.

Данилов көлемсерәде, бераз тик утырды, сул кулының бармакларын өстәлдә биетте.

— Шулай дисез инде, яклыйсыз?

— Яклыйм дип, дөреслекне әйтергә тырышам, чынлыкны.

— Сорокин әллә кая китә алмас! Барыбер килеп эләгер. Ә Хәйретдинов сезнең урында булса, алай яклап маташмас иде... Сезнең өстән язган кәгазьләре бар...

Боларын ни өчен әйткәндер Данилов, Уразаев аңлап бетермәде, барыбер, Айсетдин аңа нинди этлекләр эшләсә дә, ул үз сүзен кабатлады.

— Юк, иптәш Данилов, аңа юк гаепне тагарга кирәкми. Минемчә, булып үткәннәр өчен җавап бирүдән куркып кына чыгып ычкынгандыр ул. Кайтып та килер әле!

— Как знать, как знать!— дип кабатлады Данилов.— Кешене белү җиңел түгел. Сорокин бандит, тотарбыз без аны. Әгәр дә мәгәр алар Хәйретдинов белән бергә эш йөртсәләр, Уразаев, миннән пощада көтмәгез!

— Риза,— дип көлемсерәде Уразаев.— Сез, иптәш Данилов, җүләрлегем өчен мине гафу итегез инде.

— Нинди җүләрлек?.. Ә-ә, яшьләрне авантюрага тартып, хәзинә эзләүне әйтәсезме? Тапкансыз Клондайк! Алтын чыганагы! Юк анда хәзинә, юк, әгәр нәни генә ышаныч булса да, без әллә кайчан эзләп табар идек. Совет хөкүмәтенә алтын бик кирәк!

— Без дә хөкүмәткә тапшырыр өчен эзләдек лә аны!

— Әгәр шулай икәнлегенә ышанмасак, сезнең белән мин бөтенләй башка урында, бүтәнчәрәк сөйләшкән булыр идем!

Уразаев тирләп-пешеп утырса да, чыкканда шактый тынычланган, җиңеләеп калган иде. Сөенеченнән почтага кереп Саниясенә телеграмма да сугып чыкты.

«Һәммәбез исән-сау! Сагынып сине көтәбез!»— диелгән ул телеграммада, ике кат рәттән өндәү билгесе куелган иде.

Тик телеграмма хуҗасына барып җитә алмады. РОНОга кереп шелтәсен язма рәвештә алып, телдән дә байтак ачы-ачы сүзләр ишетеп, кара тиргә батып РОНО капкасыннан чыкса... каршысына чемоданын тотып Саниясе килеп басты.

Сания бер аңа карый, бер әллә кая уңга күз төшерә. Уңга борыла да тагын аңа карый. Уразаев бик аптырап ул караган якка борылды һәм чак кына егылып китмәде, анда, почмакта, очып китәргә җыенган кош кебек талпынып Йомабикә басып тора иде. Бер яктан Сания, икенче яктан Йомабикә Мөхәммәткә таба якынайдылар, ул Саниясен кочаклап алырга да кыймыйча, кызарынып-бүртенеп уртада калды.

Якынайдылар, дәшмиләр, икесе ике якка килеп бастылар. Икесенең авызыннан бер үк сорау яңгырады:

— Япмадылармы? Чыгардылармы?

— Туктагыз әле, ни сөйлисез сез? Нигә мине ябарга тиешләр? Ул хәбәр Омскига ничек барып ирешкән? Йомабикә апа монда ни кыдырып йөри?


— Сания, балам, рәнҗемә миңа... Мөхәммәтне камадылар дигәч, түзмәдем, барын ташлап чыгып киттем. Ырсытдин əкәң үкереп калды бичара. Нишлим, безнең кызыбыз бар ич, Мәүлиябез...

Менә син ә, ир белән очрашып сөйләшәсе урында, арага килеп кергән чит хатынны тынычландырырга калды... Чит дип, әнә ич, үзе дә әйтеп тора, «кызыбыз бар» ди. Бу хакта Саниянең хәбәрдар икәнен белә ич... Күңеле ташыган мизгелләрнең берсендә Йомабикә аңа бу хәбәрне үзе дә җиткергән иде, күңелен каралтып торган серне ачып салган иде.

— Мине ничек коткарырга иде инде исәбең, Йомабикә апа?

— Төрмә стенасын җимереп булса да алып чыга идем мин сине!

Ялан авылы хатыны бу сүзләрне шундый ышаныч белән әйтте ки, Мөхәммәт тә, Сания дә аңа хөрмәт белән, якын итеп карадылар.



А. Тимергалина рәсеме

— Тукта әле, хәбәр сиңа ничек килеп иреште?
— Айсетдин китереп житкерде.
— Ничек?
— Айсетдин югалды ләбаса!— дип сүзгә катышты Йомабикә.
— Ничек югалсын! Омскида апаларында кунакта ята. Мине эзләп тапты.

Мөхәммәт Уразаев эшне аңлый башлады, «Санияне эзләп киткән икән, явыз!»

— Апаларында дисеңме?
— Шунда. Адресын да беләм.

Уразаев Саниянең чемоданын күтәреп алды да, буш кулы белән аны житәкләп:

— Чаптык!— дип кычкырды.
— Кая?
— Баргач күрерсең!

Китә башлагач кына ул борылып карады һәм моңлы күзләрен мөлдерәтеп басып торган игелексез Ырсытдиннең бәхетсез хатыны Йомабикәне күреп, туктап калды.

— Йомабикә апа,— диде ул ягымлы, йомшак тавыш белән.— Кайгыртуың өчен рәхмәт. Тынычлан, миңа бер гаеп тә әйтмиләр. Әнә шул каһәр суккан жилкуарның югалуы гына жанны кыйный иде... Хәзер һәммәсе дә ап-ачык. Тагын бер тапкыр рәхмәт сиңа.

— Сания,— дип туктатты Йомабикә аларны тагын.— Мин... өтермәнгә тапшырырга дип ризык алып килгән идем. Акбалык, тогы, кәреш... Бер тавык суйдым...

Сания икеләнеп тукталып калды.

— Ризыгыңны алабыз. Йомабикә апа. Рәхмәт. Карын бик ачкан иде!

Мөхәммәт бер кулына чемодан, икенчесенә ак яулыкка төргән төенчекне тотып, Саниясен култыклап НКВДга чапты. Йомабикә еламсырап аларны озата калды...

## 35

Гади авыл кызының тормышы ничек үтә?

Авыл кызы бик яшьли олыларның кул арасына керә, кош-кортны карый, каз бәпкәләре, тавык чебиләре дә тулаем аның карамагында була; бәрәңге утыртканда ул иң зур булышчы, бәрәңге алганда ул төп жыючы, печән өстендә аның кулыннан тырма төшми, әйләндерә, жыя, чүмәләгә куя. Торнакүз жыярга да ул чаба, жылывытны да ул йолкып киптерә, карлыган кагын да ул коя. Ә карлыган Иртеш буе әрәмәләрендә бихисап, күз-ачып йомганчы бер түгел, ике чиләк жыярсың!

Мәүлиянең тормышы тыныч үтте дип әйтеп булмый. Иргә карышусыз буйсынган ана, гаиләдә бары тик үз сүзен генә сүз итәргә гадәтләнгән ата, яшьтән үк сугыш чукмары булган абый... Менә шушы өч ут тирәсендә, янмыйча да көймичә яшәп килде Мәүлия. Укырга тырыш иде, сәләте дә бар, шигырь ятларга дигәндә аннан да житез кеше юк, сәхнәдән торып Тукайның «Шүрәлесен» сөйләгәне бар, икенче көнне дә кое янында карчыклар аның аркасыннан кактылар: «Булса да булыр икән хәтер, гомереӊ озын булсын!»— дип теләделәр.

Шамил белән дуслыгы аның гомерен, балачагын бизәде.

Эш шуннан арыга узмады, Шамил аның бертуган энесе булып чыкты...

Алай да, «нишләрмен!» дип чәбәләнмәде кыз. Шамилдән кала тагын бер пар күзнең үзен бик нык яратканын ул әллә кайчан белә иде һәм үксез калган күңел дуамалланып шуңа тартылды. Кыюсыз Йосыф кыз күңеленә жил-давыл булып килеп керде. Шул кечтән чәче маңгаен каплап торган житди егет күз алдыннан бер дә китмичә берөзлексез тыйнак кына елмаеп каршысында тора башлады.

Авыр келәләре төшерелгән урыс капкасын көне-төне бикләп саклаcard салар да, Мәүлиянең хыялында — ул! Кая караса да, анда ул көлемсерәп тора, кул болгап чакыра, дәшә, сары толымнарын сыйпый, иркәли... Бу бәйләнчек татлы уйлардан арынырга, котылып торырга теләп, бәйли башлаган оекбашын кулына алып карады, бүлмәләрне, өйалды почмакларын — һәммәсен кырып диярлек юып чыгарды, гөлләргә су сипте — ләкин аны йөдәтеп йөрәген имгән нәрсәдән котыла алмады. «Чыгасы иде! Тизрәк, тизрәк тагын бер мәртәбә генә күрәсе иде!» — дип сулкылдады аның йөрәге.

Кинәт аның колагына ерактан чайкала-чайкала килгән гармун тавышы кагылып китте. Кеше йөрәген тәмам бозып кем уйната икән шул көмеш телле сыбызгыны! Шул хәерсез кызлар йөрәгендә посып яткан моңны тышка чыгара, халыкка фаш итә дә инде!

Ул, почмакка баскан килеш, күзләрен йомып Кызлар Убасын күз алдына китерергә тырышып карады. Алар анда кешкертмәвеч уйныйлардыр. Йосыф уенга катышмагандыр... Ул кедр төбендәге ышыкка баскандыр да аны, Мәүлияне юксынадыр...

Гармун тавышы Иртеш буеннан агыла.

Барасы иде шунда, йөрисе иде иркенләп бер!

Ә капка бикле. Әнкәсе өйдә булса, ул Мәүлиягә ярдәм итми калмас иде. Өйдә алар әтисе белән икесе. Ырсытдин теге якта әле ыңгырашып, әле мыгырданып ята. Хатынының җил-җил җиенеп каядыр барырга йөргәнен күзәтеп яткач, саңгырау гына:

— Кая җыенасың болай? — дип сорап куйды.

— Хөбәйбә түти сырхап тора икән, шуларга кагылыймчы дим. Хатынының чыраена карап, аның ялганлаганын тоя Ырсытдин, ләкин элеккечә сикереп торып кече якка өреп кертә алмый, хәле юк... Бер ягыннан икенче ягына авырлык белән генә әйләнеп ята, кәнтәй хатынының мимылдап торган тәнен күрмәсен күзләре...

— Әй, хатын, ачы бал коеп бирче!

Йомабикә дәү тустаганга бал коеп сүзсез генә китереп бирде, аның күз төпләре каралҗым алка белән уралган, гадәттән тыш борчылуы чыраена чыккан. Сизенә Ырсытдин, чамалый, ләкин сүз ката алмый, хәле юк... Ачы бал тамак төбен ачыттырып төшеп китте, җиңеллек китермәде, дәрт уянмады...

Хатыны чыгып киткәч, ул авырлык белән калкынып ишегалдына чыкты, шунда күз алдында гына йомышын үтәде. Хәле булмаса да капканың ике келәсен дә элде...

Кереп ятты. Икенче бүлмәдә Мәүлия мыштыр-мыштыр йөри.

Ул, тавышын тагын да зәгыйфьләндереп, аны дәшеп алды.

— Кызым, янкәм, керче монда.— Мәүлия керде, сүз катмыйча гына караватбашына килеп таянды.— Кызым, яман атың чыкканчы кияүгә бар. Үлмәс начар егет түгел, беләсең. Бүтән берәүдә күңелең булса да шуңа чык. Алар белән куешкан вәгъдәбез бар. Ияләнерсең, тора-бара яратып та китәрсең. Без әнисең белән яратышып өйләнешмәдек, барыбер торабыз бит. Һади зимагурның онытын башыңнан бөтенләй чыгарып ташла. Сәвсим аның атын ишетәсем килми... Кузайтын ашына әллә тамак хакына барды дип беләсеңме? Юк, каралты-кураларын, йорт-җирләрен күзәтим дип бардым. Адәм хурлыгы инде, валлаһи, шундый йортта ничек яшәп яталардыр! Шул йортка килен төшерергә уйлыйлардыр әле, җирбитләр. Оныт Һади онытын. Юкса, асла ризалыгым юк!

Соңгы җөмләсен әйтте дә Ырсытдин каты йөткереп китте. Сулышы көйләнгәч, зәгъфрандай сары йөзен яшерергә теләгәндәй, тагын стенага борылып ятты.

Кайчандыр үгезнекедәй таза муены нечкәреп, кабыгы сыдырылган нарат киртәсенә охшап калган. Иңбаш сөяге тырпаеп яткан бу өлкән кеше Мәүлиягә бик кызганыч булып күренде. «Юк, миңа сезнең Үлмәсегез кирәкми!» — дип җан авазы белән бер кычкырыр иде, кычкырмый,

түзә, бик күп кешеләрне кан елаткан шушы усал кешенс рәнҗетәсе килми...

Ул этисенең өстен рәтләп япты, дәшмәсме, дип бераз тыңланып торгач, шыпырт кына чыгып китте. Үз почмагына кереп утыруга, бая күңелне иңләгән татлы уйлар тагын әйләнеп кайттылар. Уйда — Йосыф! Менә Йосыфка бирәм дисә икән этисе! Аннан кызның уйлары капка төбендә саубуллашуга барып ялганды. Ул кичтә аны беренче тапкыр авылның сылу егете озата килде. Озатты гынамы әле? Кул биреп, саубуллашып кереп китәм дигәндә, капыл гына Мәүлияне кысып кочты да суырып үпте. (Ташкәй явыз нәкъ шул минутта кайтып җиткән иде!)

Мәүлиянең беренче тапкыр үбешүе иде бу...

Тукта, рөхсәтсез-нисез ничек үпте соң ул аны?

Шашып үбешү — ярату галәмәте, дип сөйләгән иде аңа берзаман җиңгәсе. Җиңги күпне күргән кеше, ул белми сөйләмәгәндер. Димәк, Йосыф аны ярата, бик нык ярата!

Мәүлия, янында сыенып утырган песи баласын күкрәгенә кысып, бер тәрәзәдән икенчесенә йөренә башлады. Әнисе һаман юк... Кайда йөрер икән ул?

Йосыф аны ярата! Билгеле, ярата! Яратмагач менә бер дә аның Үлмәс белән үбешәсе, күрешәсе килеп тормый! Бераздан кызның башында каршылыклы бер уй туып өлгерде, ул йөргән җиреннән туктап калды, тәне чымырдап китте. Күптән түгел генә аңа Сәлимә исе китеп сөйләде, Шәүкәтнең бер кичтә Шәгъбикә белән үбешеп торганын күргән, икенче кичтә үк Шәүкәт Гобәйдә буйдакны ялап маташа икән. Әгәр Йосыф та шундый җиңел холыклы булып чыкса?

Ничә төннәр юньле йокы күрмәгән башы әйләнеп китеп, ул чак кына егылмады. «Буш булма, кызым, башыңны сакла, авызы ачык кызлардан егетләр көлергә яраталар!»— дип әнисе аңа йөз тапкыр тукыган иде. Мөхәммәт абый да: «Кызлар тыйнак булырга тиеш, тыйнаклыкта матурлык!»— дип азмы ныгытты. Ә Мәүлия беренче озата кайткан кичтә үк үбешеп басып торды. Юк, юк, моннан болай ул бик сак булачак. Йосыф килеп карасын әле менә... Үптерсә дә чак кына, сак кына, нәни генә үптерәчәк.

Аңа хәзер кем беләндер сөйләшергә, күңелен бушатырга кирәк иде... Кызык бу дөнья! Мөхәммәт абыйга эти дип эндәшә алма... Әнкәсе дә һаман өйдә юк...

Төн урталары булгандыр, Мәүлиянең күзенә һаман йокы кермәде, мендәрен чылатып ята бирде. Песи баласын идәнгә бер төшерде, бер янына алды. Әллә этисе белән сөйләшсенме? Ырсытдин да йокламыйча бусарып ята бит теге якта! Кыз, күңеленнән, этисе белән әрепләшә башлады.

«Эти, нигә син мине бер чакта да яратмадың? Бер тапкыр да башымнан сыйпамадың? Сүзең гел бер булды: «Баланы аркага атландырмыйлар, бер атландырсаң төшми алар, җанны корыта. Кысып тоткан мал кулдан ычкынмаган кебек, кыз балага да катылык кирәк, азгын булмый!» Бүтән сүзең юк идемени синең?.. «Сәрвәргә иярмә, азгын ул», дидең. Азгын икән, ник Ташкәйгә аңа сыланырга кушасың?»

Шул чагында кемнеңдер тәрәзә төбендә кыштырдавы аны айнытып җибәрде. Ул, мендәрдән башын күтәреп, тыңлана башлады. Колагына тыштан: «Мәүлия!»— дип дәшкән тавыш чалынгандай булды. Ул эчке киемнән әкрен генә торып басты. Күрше бүлмәдә сырхау атасының гырылдаганы ишетелә. Ташкәй әле кичке уеннан кайтмаган. Шул йөриме әллә? Мәүлия бер-ике адым гына ясаган иде, «даң-даң» килеп стена сәгате ике тапкыр сукты да, өй эче тагын тынып калды. Бераздан баягы пышылдаган тавыш кабатланды: «Мәүлия!»

Аның тавышы! Ул килгән! Йосыф! Баягы икеләнүләр, шик-шөбһәләр берьюлы онытылды, «үптермәскә» дигән ант көл булып күккә очты, ул иңсәсенә шәлен каплады да тәрәзәгә ябырылды. «Ә» дигәнче миләш

куагы төбенә килеп баскан Йосыф ачык тәрәзәдән аны куенына төшереп тә алды. Алар авыз ачып сөйләшергә дә өлгермәделәр, ямьсез аяк тавышлары ишетелде. Йосыф бер суырып үпте дә Мәүлияне тәрәзә аша кертеп тә җибәрде. Кыз кереп китүгә үк урам якта тавыш купты:

— Тотыгыз, тот! Өй басалар! Карак килгән!

Бусы Ташкәй тавышы иде.

Ул арада Ырсытдин килеп җитеп хәлсез куллары белән кызны уңлы-суллы яңакларга тотынды.

— Кайда карак? Кем әле йорт баса?— дип Йосыф, җыелган кешеләр арасына чыкты.

— Йорт басмасаң, нишләп кешенең тәрәзәсен каерып йөрисең?

Гаугага халык уянды, анда да, монда да тәрәзә капкачлары ачылды, мыдырдап сөйләшкән тавышлар ишетелде.

— Нинди йөзе кара төн уртасында адәмнәрнең йокысын бүлеп йөри?

Бусы ялангач тәненә кыштыр туның каплап, ялан аягына кәвеш элдереп чыккан Чырык Абдрахманның нәзек тавышы иде. Ул тавышны ишеткәч, Йосыфның йөрәге өшеп китте.

* * *

Без капчыкта ятмый, биек коймалар, авыр капкалар артында булып яткан кыргый вакыйгалар турындагы хәбәр Уразаев белән Хәфиз әкәгә дә килеп иреште. «Мәүлияне җәберлиләр, көчләп кияүгә бирмәкчеләр», имеш...

Мәүлия үзе дә бу турыда Мөхәммәт абыйсына яшерен хат язып чыгарды: «Минем укуымны дәвам итәсем килә, ә эти көчләп кияүгә бирергә тели. Мине өйдә бикләп саклыйлар. Зинһар, ярдәм итегез!»

Төшке аштан соң савыт-сабаны юып бетереп, Йомабикә түти бозавын ашатырга дип агач лаканын күтәреп чыга башлаганда капка шакыдылар. Сул култыгына лаканын күтәргән көйгә барып, ул капка келәсен күтәрде һәм көтелмәгән кунакларны күреп телсез калды. Куркынган карашын Мөхәммәткә терәгән килеш аны очкылык тота башлады. Ул арада, кигәвеннән качып лапас астына кереп яткан чуар бозау, мөгерәп килеп җитеп, аның кулындагы савытка үрелде. Савыт Йомабикәнең кулыннан ычкынып китеп, кәвеш эченә боламык түлды. Бозавы аягына баскач кына ул телгә килде:

— Бу кадәр ачкак булырсың икән, хәерсез!

Бозау аның бармагын эләктереп алып имә дә башлады.

Йомабикәнең капка ачканда гына кан качкан чыраена кызыллык иңде, ул бөрмәгә кыстырган күлмәк итәген төшерә-төшерә, лаканны җиргә куеп бозауны куа башлады. Дәүләтша әкә белән Уразаев аңа бозауны ябарга булыштылар.

— Әйдәгез, хуш килдегез!— диде Йомабикә боламык сыланган кулларын алъяпкычына сөртеп.

Салкынча йортта шылт иткән тавыш та юк. Йорт башлыгына хөрмәт йөзеннән алар хаста янына үттеләр. Ырсытдин карт юрган астыннан ялтыравык башын күтәрде. Бу бәндәнең үзенә карата дошманлык тойгыларын сизеп йөрсә дә, Уразаев аның алдында үзен гаепле дә саный иде. Шуның өчен йортка ялгызы гына килмәде, эше-мәшәкате күп булса да, Дәүләтша әкәне ияртте. Заманасында дәһшәтле тоелган бу кеше хәзерендә аңа бик кызганыч булып күренде. Ул сүзне хәл-әхвәл сорашудан башлады.

— Терелеп китеп булмыймы, Ырсытдин әкә? Заңгеләдән суган бик дару диләр.— Аның чын күңелдән бу кешегә ярдәм итәсе килде. Ул арада өстен-башын алыштырган Йомабикә дә болар янына килеп кергән иде. Ырсытдиннең күз карашын очраткач, ул тиз генә чыгып та югалды. Хатыны чыгып киткәч Ырсытдин чыраен сытып, тимер кебек каралган нәзек сыйракларын караваттан салындырып торып утырды. Тирәнгә

баткан күзләрен төксе озын кашлары астыннан елтыратып, килүчеләргә карап алды.

— Әле үләргә җыенган юк. Авырулы үлми, әҗәлле үлә. Терелеп тә китәрбез, ходай насыйп итсә.

Картның бу сүзләрне сер бирмәс өчен генә әйтүе күренеп тора. Юкса электәге әзмәвер гәүдәсе бөрешеп калган, аркасы тактага әверелгән, беләкләрендә бер чеметем ит калмаган, калкан сөякләре тырпаеп чыгып, яшь чагында мөлаем генә булган йөзе бөтенләй гарипләнгән.

— Ырсытдин ага, сырхаусыз, күрәбез. Мәгәр, сүзебез житди булганга, аны-моны сөйләшмичә дә ярамас инде,— диде Мөхәммәт гаепле төс белән.

— Сөйләшеп алыйк дибез!— Дәүләтша әкә дә аны хуплап ияк какты.

Ырсытдин эндәшмәде. Ул арада бүлмәгә җинел адымнар белән Ташкәй кайтып керде, кунаклар барын абайлап ишек катында туктап тынлана башлады.

— Сез авыру булгач, балаларыгызга ярдәм күрсәтергә кирәктер дип керүебез иде,— дип дәвам итте Уразаев.— Рөхсәтегез булса, Мәүлия укуын дәвам итсен дигән идек.

Бу хакта ишеткәч, картның саргылт балавыз йөзе кара янып чыкты.

— Карале, Мөхәммәт! Минем балаларны котыртып йөрү житте сиңа! Керешмә син! Беләмсең, син минем кай җиремдә утырасың?— Ул бавырын тотып күрсәтте.— Тыгылма син минем тормышка, чурту!

Аның сулышы капты.

— Без алайса закон кушканча эшләрбез!— диде Дәүләтша әкә ашыгып.

— Төкерәм мин сезнең законыгызга! Барыбер теге дөньядан ары җибәрә алмассыз. Минем болай да бер аягым җирдә, икенчесе гүрдә. Тамчы да курыкмыйм мин сездән. Бозмагыз йөрәгемне!

— Без бары тик яхшылык теләп кенә кердек,— диде Мөхәммәт, акланган сыман. Аннан Ташкәйгә карады.— Ташкәй, эткәң авыру, аның белән сөйләшү безгә бик читен. Нигә син көчсез сеңлеңне җәберлисең? Кыз җәберләү егетлек түгел.

— Егетлекнең ни икәнен мин бик яхшы беләм,— дип мыгырдады Ташкәй.

Ырсытдиннең «законыгызга төкерәм!» дип кычкыруыннан соң, яман ачуы кабарган Дәүләтша әкә, Ташкәйгә җикеренә башлады.

— Син, малакасус, укытучыңа карышып маташасыңмы? Кем булдың ул кадәр? Олыларны олылый белергә вакыт.

— Мәктәптә чакта укытучы иде, хәзер ул миңа беркем дә түгел!— диде һаман киреләнеп Ташкәй.

Мондый чакта сүзне артык сузуның мәгънәсе юк иде, Дәүләтша әкә белән Уразаев бер-берсенә ым кагышып, чыгып китәргә булдылар, Ырсытдингә саулык-сәламәтлек теләделәр. Иреннәре калтыранган Ташкәй тайчынып аларга юл бирде.

Сөйләшүләрне ишетеп торган Мәүлия яулык читен тешләп чоланда җылап калды. Йомабикә түти аны кочып, колагына гына пышылдап торды:

«Курыкма, бар да син дигәнчә булыр! Укытам мин сине, Ташкәй сыман төн күчән итеп калдырмыйм...»

— Син үзең дә гомерең буе кол булгансың шул, әни!— диде аның кочагына капланып Мәүлия.

— Кол гына булмадым! Үз дигәнемне дә эшләдем мин. Хәзер дә үз дигәнемне итәрмен!— диде Йомабикә ышаныч белән. Мәүлия гаҗәпсенеп аңа күтәрелеп карады. Теге яктан Ташкәйнең куркынган тавышы яңгырады:

— Әни, әни! Керегез! Әти үлә!..

Керсәләр, Ырсытдиннең башы бер якка кыегаеп төшкән, күкрәге тимерче күреге сыман гыжылдап тора, күзләре калайлана башлаган.

— Ташкәй, йөгер Абдрахман абзаң артыннан. Тиз йөре!..

Ташкәй ачык калдырган капкадан чуар бозау иркенләп урамга ук чыгып китте һәм тыкрык башында качып торган Йосыфның тезенә камырлы борыны белән китереп төртте. Йорттан Йомабикәнең улауга охшаган җылау тавышы ишетелде...

**36**

Кеше исән чакта аңа бер төрле карасалар, вафатыннан соң аңа мөнәсәбәт кискен үзгәрә, яхшыра, кайчандыр кылган явызлыклары онытыла, татарлар кече күңелле халык, мәрхүмнәрне кичерә, кылган яхшы гамәлләре аз санлы булса да, ниһаять, шулары алга чыгып өстенлек ала.

Ырсытдинне бөтен авыл белән җирләделәр, хәтта мәрхүмне озатырга Йосыф та барды. Җеназа укылып, Ырсытдин җир белән кавышкач, егет беркемгә дә дәшмичә генә үз әнкәсенең кабере янына да барып килде. Бу аның туган Яланы, зираттагы әнкәсе, Һади бабасы белән быелга саубуллашуы иде...

Озакламый алар Мәүлия белән Төмәнгә укырга киттеләр. Якындарак, Тоболда да укырга була иде, Йомабикә абыстай: «Кеше күзеннән еракка китегез ичмасам, күрмәсәләр авызлары тигрәк торыр»,— дип иңәлде.

Шамил: «Әтиләргә якынрак булам, теләгән саен кайтып йөрермен ичмасам!»— дип Тоболда гына калмакчы иде, укыган институтлары Төмәндә генә шул аның. Шулай бит, кемгә еракка китеп тору яхшы, кемгәдер якында калу улай. «Әтиләргә якынрак булсам иде!»— диде Шамил, күңеленнән бәлки: «Сәрвәр сылудан читкә китәсем килми!»— дип тә уйлагандыр.

Сәрвәр исә Шамил янында өч айлык педагогик курсларда укыды да Ялан мәктәбенә башлангыч классларны укытырга кайтты. Бу — авыл өчен зур куаныч иде. Укытучы булу өстенә, Сәрвәр менә дигән оештыручы да, концертларда башлап йөри, спектакльләргә катнаша, Галиябану булып сәхнәгә чыкса, хатын-кызлар шундук борын яулыкларына тотына иде... Матур шул Сәрвәрнең тавышы!

Айсетдинне этап белән кайтарсалар да кулга алмадылар. Ике көн ябып тоттылар да, ул, Ялангa кайтып, ашык-пошык кына әйбер-караларын — яртысын Чырыктан, яртысын үз фатирыннан төяп алып китте. «Саубуллашырга кирәкме?»— дип көткән иде Уразаев, Айсетдин кермәде, карак сыман шыпырт кына авылдан чыгып тайды.

Ул китте, мәктәп киңәйде, хәзер сигезе тулганы бере укырга йөри башлый, Яланга өстәмә өч укытучы килде, өчесе дә комсомоллар, яшьләр, ут уйнатып торалар. Уразаевка эш җиңеләйде, ул күбрәк вакытын өй арасында үткәрә башлады.

Йөгереп бара Сания медпунктка, чабып кайта. Кайта да дәфтәрләренә кадала... Фаягөл йә әтисе белән, йә әбиләренә утырмага китә. Шамил каникул саен диярлек кайтып йөри. Аның кайтуы өй эчендә олы бер бәйрәм була...

Ялан авылы татарлары төрле яклардан җыелган халык булганга, аларның гореф-гадәтләре дә, бит-чырайлары да төрле-төрле. Ак маңгайлы, озынча битле, туры килешле борынны Сәлимә бәлки Казан якларында яшәгән болгар бабаларыннан алгандыр? Аларның нәселе мәгълүм — «казанлылар». Төп халык — йомышлы татарлар, ясаклылар. Алар исә чәчрәп торган чыгынкы яңаклы, кысык күзле, почык борынлылар. Ирләренең чәчләре каты кыл кебек, тарасаң-тарамасаң төрле якка сибелеп китә! Арада сартлар — Бохара ягыннан килгән үзбәкләр дә житәрлек. Алары да яши-яши татарга әйләнгән. Җирле гореф-гадәтләр авылда өстенлек алса да, Казан-Уфа ягыннан килгән татарлар ул гадәтләрне үз итеп үзләштерсәләр дә, телдә алар өстенлеге калган. Ясаклы татарлар да, сартлар да әле себерчә, әле китап теле белән казанча сөйләшәләр.

Сәлимә, гүзәллекләре телдән-телләргә күчеп макталган атаклы болгар чибәре кебек булмаса да, матур кыз! Гаиләдә бердәнбер кыз булганга, һичбер кимсетелү, кысанлык күреп үсмәде. Шуңа күрә күңеле дә күр иде. Урамга чыгып берәрсе аңа кагылсын гына, биш абыйсы шунда ук сызгырышып килеп җитәләр һәм бердәнбер кадерле сеңелләрен яклар-га басалар.

Үзенә кияүне дә тиз тапты.

«Яңа елда Маннур белән Сәлимәнең туе булачак!»— дигән хәбәр Яланнан Тоболга, Тоболдан Төмәнгә барып иреште.

Туй, туй! Ялан авылында туй!

Мөхәммәт Уразаев укучыларыннан беренче булып Сәлимә белән Маннур өйләнешәләр!

Сыкылы, салкын, чалт аяз иртә...

Кияү белән кәләш чыбылдык эчендә беренче тапкыр очрашканга хәтле, андагы мендәр һәм түшәк җәелгән чиста урында авылның иң тату, иң бәхетле гомер сөрүче, иң абруйлы ир белән хатын түшәк-мендәрне таптап чыгарга тиешләр. Мөхәммәт белән Сания түшәк өстенә тәгәрәп киткәч, Шәмсеруй җиңги әле көлеп, әле күз яшьләрен түгеп: «Шушы адәмнәр үрнәгендә яшьләр дә бәхетле яшәсеннәр!»— дип кабатлап торды.

Йортка яшь килен төшүен белдереп, куп көпшәле мылтыклар берьюлы шартлап хәбәр тараттылар. Болдырга чыгып баскан Рәукыя апа яшь киленне арбап каршылады.

Котлы аягың белән,
Таймас табаның белән
Келәмгә бас, киленчәк!
Чөмергәнең май булсын,
Балаларың бай булсын!
Мал-туарың уң булсын!
Кош-кортларың мул булсын!
Бала-чагаң ун булсын!
Кигән киемең тун булсын!
Өлгер дә бул, киленчәк!
Елгыр да бул, киленчәк,
Түремнән уз, киленчәк,
Бәхетле бул, киленчәк!

...Рәукыя апа Маннурының башлы-күзле булуына чиксез шат иде, аның күңеле почмакланды, улы авылның менә дигән кызын алды, һәм ул, туйлар үтеп, яшьләр җайлы гына көн күрә башлагач, тыныч күңел белән көнбатыш чигендә хезмәт иткән офицер улы янына кунакка китте...

Сәлимә белән Маннур, чордашлары Сәрвәр, Мәүлия, Йосыф, Шамилләрне кызыктырып, матур гына яши башладылар.

## 37

Шамил җәй көне Иртеш буенда Сәрвәр белән һич көтмәгәндә һәм бик сәер, дөресрәге җүләрләрчә аерылышуны гадәттән тыш авыр кичерде. Ызгыш гел юктан башланды...

Вәгъдәләшкән сәгатьтә Шамил Иртеш буена төште, ә Сәрвәр сүз куешкан урында юк иде. Шактый көтте Шамил, эч пошырып моннан ерак та түгел урында сыздырып гармун уйнады. «Әллә андамы?» дип шикләнеп уйлады ул. «Булмас! Шушы урында очрашабыз, дип сүз беркеттек ләбаса!»

Уен яңгыраган якка китәм дигәндә, ялт итеп Сәрвәр килеп чыкты, Шамилнең маңгаена җыерчыклар кунды.

— Кайда идең син?

— Уенда идем,— диде Сәрвәр ваемсыз гына.— Әллә кайчан килә идем, шул Ташкәй теңкәгә тиде, имгәк. Кырмавыктай ябыша, сагыз кебек сылана.

Озак көттергәне өчен Шамилнең ачуы сүрелмәгән иде әле, егетнең күңеленә әче телләр салган шөбһә куәтләнеп китте. «Ташкәй Сәрвәргә өметләнә икән!»— дип ишеттергәлиләр иде, ул ярым-үпкә аралаш әйтеп салды:

— Бәлки сыланырга үзең юл куясыңдыр?!

Сәрвәрне корт чактымыни, үз колакларына үзе ышанмыйча талпынып алды да егеткә төбәлде.

— Каян телеңә килде ул сүз?

— Кичер, кеше сөйләгәнне генә әйтәм.

Сәрвәр отыры нык үпкәләде:

— Синең үз башың кайда? Әгәр кеше сүзенә ышанып мине җилбәзәк бер кызга санысаң икән, хуш!

Һәм китте дә барды...

Шуннан ары алар байтак вакыт беркайда да очрашмадылар. Шамил курка-курка гына бер-ике хат язып карады, Сәрвәр ник берсенә җавап бирсен ләм-мим, кисте дә куйды...

Авылда чакта ул Сәрвәр белән яңадан очрашып аңлашу юлларын эзләде, күп тапкырлар Сәлимә аша да сүз салып карады. Сәрвәр исә тоташтан ут йотып йөрсә дә, төннәрен йокысыз үткәрсә дә дәшмәде. Урамда каршысына Шамил килеп чыкты исә юк йомышны бар итеп теләсә кемгә кереп китте, чыкмады, инде күзгә-күз килгәндә: «Безнең уртак сүзләр беткән!»— дигән сыман, егетнең бәгырен өзеп, күрмәмешкә-белмәмешкә салышып читкә карап үтте дә китте...

Курсларны бетереп, укытырга кайткач, ул көнозын мәктәптә булырга тырышты. Мөхәммәт абый аларның Шамил белән арасы бозылуын белмәмешкә салышты, ул элеккечә Сәрвәргә үтә мөлаем һәм игътибарлы иде. Сания гына кайвакытта аны йолыккалап куя:

— Яшьләрнең арасын нигытырга кирәк.

— Үзләре, Сания, үзләре бозганнар, ачысын үзләре татысын, татулашу юлын да үзләре эзләп тапсын. Шулай яхшырак булыр.

— Әгәр озакка китеп аралары тәмам бозылса?

— Ходайдан шундый әмер булгандыр! — дип көлде Уразаев. Эчендә ут уйнаса да тышка чыгармады.

Сәрвәр Шамилдән ким борчылмады. Кичләрендә шомлы җил сызгырып ялгызлыкны тагын да көчәйтеп җибәргәндә: «Әллә Шамилгә хат язып, барын да яңадан эзгә кертергәме?»— дигән уй кузгалып, каләмгә тотынган чаклары да булды. Йөрәк каны белән сугарылып язылган хатлар мичтән ары китмәделәр. Кышкы ачы җилләр искәндә, тыелгысыз бураннар дулаганда, нинди генә хәбәрләр ирештермәде озын телләр Сәрвәргә!

«Юкка көясең, Шамилең Төмәндә кичләрен шәһәр кызлары белән танцаларда сиптерә!» «Әллә кайчан онытты инде ул сине!»

Сәрвәр итәк астыннан кемнең ут йөрткәнен шәйләсә дә, кеше сүзе кеше үтертер, диләр, кайчагында, ялгыз калган чакларында ышана язып та куя. Аннан, акылына килеп: «Юк, Шамил андый түгел, түгел!»— дип күзгә күренмәгән дошманнары белән чәкәләшә дә хат язарга утыра... Ә кыз хатларының юлы мәгълүм... Төрле гайбәтләргә кара елан булып күңелгә шуышып керергә бер юл куйгач, акыл өстенлек ала алмый икән, йөрәк сызлавы басылмый икән!

Авыр, бик авыр үтте бу кыш...

Үзенең дә канатлары сынык бер мизгелендә Шамил утырып Сәрвәренә хат язды... Кичен дә сүрелмәс эссе июнь коешы үз бишегенә тәгәри башлаганда тыштан хат ташучы апаның тавышы килде:

— Сәрвәр, сиңа хат бар! Тыпырдатып бер биемәсәң, бирмим.

Хат ташучы Сәрвәрнең хат көтүен бик яхшы белә, шуңа күрә тавышы очып, уйнаклап чыкты. Кая ул, биеп торырга вакыт бармы соң, болдыр баскычыннан очып төшүе булды, хатны ике куллап

тартып алды, ихтыярсыздан күкрәгенә кысты, бер җылый, бер көлә башлады. Хат Шамилдән иде!

Ике атлыйсын бер атлап, сикерә-сикерә өйгә керде дә хат адресындагы чәчрәп торган тере хәрефләргә карап курка калды: ачаргамы, юкмы?!

Хат — табышмак. Йозакка бикләнгән хәзинә келәте ул, ачып кергәнче аңа нинди җан азыгы тутырылганны белмисең. Ачарсың, анда җан әрнеткеч бер-ике генә сүз булыр: «Минем хакта йөргән хәбәрләр хак, мин монда үз ярымны таптым. Көтмә мине!»

Әгәр шулай булса, соңгы өмет тә киселә. Тормышның иң актыккы яме дә калмый, кояш сүнә, ай кителеп-кителеп Иртеш өстенә коела. Әле болай өмет җылыта иде аның җанын! Өмет!.. Инде син дә өзелсәң, Сәрвәрнең җаны тәненә ничек ябышып торыр? Очып китәр ул. Тукай «Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы!»— дип язган... Нәкъ әнә шулай, өметсезлеккә бирелгән җан очар да китәр.

Әллә ачмаскамы? Ачылмаган хатны әллә нинди сүзләр белән җылытып була. Бәлки ул:

«Җаным! Дөньяда минем өчен синнән дә кадерле зат юк! Мин бары синең өчен генә тудым, синең хакка гына яшим!»— дип язгандыр.

Ачылмаган хат — җылы хат әле ул... Ачсаң, диңгез төбендә яткан чүлмәктән чыккан явыз гыйфрит кебек, ямьсез, салкын сүзләр чыкса?

Йөрәге ни янса да Сәрвәр хатны ачмады, ярты төнне җиткерде, хат букчасын утка куеп карады, иснәде, эчендә ниләр бар икән дип бармак араларында кыштырдатты. Хат дәшмәде, хат әлегә сүзсез иде.

Ниһаять, конверт ертылды, күзләрнең нуры хат юлларына чайпалып түгелде, күзеннән сөенечле яшьләр атылып чыкты.

«Сөекле Сәрвәрем!»

Инде бүтәннәрен укымасаң да була! «Сәрвәрем!» дигән, «сөеклем» дигән. Үз исеменең шушы кадәр матур икәнен ул бүген беренче тапкыр белде. Нинди ягымлы, яңгыравыклы һәм мәхәббәтле икән лә аның исеме! Сәр-вәр... Бу исемне «сөеклем» сүзе белән янәшә куеп җырларда җырларга була...

Хатның икенче юлы тагын да тирәнрәк мәгънәле икән:

«Өзелеп сагындым үзеңне!»

Кызның буыннары йомшап китте, хатны йөрәгенә кыскан килеш сәкегә утырды һәм өйне яңгыратып озак кына елады. Ел дәвамында эченә тулган ут-ялкын тышка бөркелде. Күптәннән елыйсы килеп ярсыган йөрәген бераз баскач кына хатны тоташтан укый алды, укыган саен төсе яктыра барды.

Күрче таң аткан түгелме? Тәрәзәдән төшкән нурлар яктысында Сәрвәрнең керфекләренә кунган тамчылар энҗе булып ялтырыйлар. Ул күзен кул аркасы белән сөртә-сөртә хатны йөзенче, юк, меңенче кат укыды. Хат җыр булып яңгырады, сандугач сайравы кебек ишетелде, моң дәрьясы Иртеш булып килеп бәрелде...

«Көннәр, айлар ашкынып чаба! Имтиханнарны бирә башлыйбыз. Июнь ахырына диплом тотып яныңа кайтачакмын! Гомерлеккә! Ялан мәктәбенә рус теле укытырга җибәрәләр. Бүген ул хакта әтигә дә хат яздым. Сабырсыз күңел синең янга ашкына. Сәрвәрем, теге вакытта ямьсез аерылышканнан соң бик күп уйландым, үземнең дорфалыгым өчен чиксез җәфа чиктем һәм шунда бер хакыйкатьне аңладым: мин синсез яши алмыйм икән! Мине дә дөрес аңларсың һәм кичерерсең дип ышанам. Бу соңгы ел минем сиңа булган саф хисләремне барлау һәм сынау елы булды. Кызлар Убасы, ямьле Иртеш буйлары сагындыра. Синең үпкәләгән карашың гел күз алдымда. Син җырлый торган моңнар — күкрәгемдә, җанымда... Берсен куен дәфтәремә дә күчереп алганмын:

Сагынам, дуслар! Сагынам, дуслар,
Сагынам туган илкәйне.
Илкәй белән берга сагынам
Яшьтән сөйгән иркәмне!

Сәрвәрем, көт мине! Үбеп, Шамилең дип белерсең!»

Кыз очынып өйнең бар тәрәзәләрен ачып җибәрде. Янбакчада муел, балан агачлары арасында пар сандугач сайраша иде. Башта берсе, бакчаның бер почмагыннан авыз сала да, икенчесе аңа җаваплый, аннан бер-берсен табышканнан соң, бер-берсен тыңлый-тыңлый өздереп сайрашалар. И дөнья, бу гашыйклар кошына нигә шундый бөек моң тапшырдың син? Нигә кызлар йә бик бәхетле чакта, йә бик бәхетсез мизгелләрдә генә сандугач сайравын ишетә икән?..

* * *

Сәрвәрнең әнисе Шәмсеруй җиңги инде бер атна буе күрше авылга кунакка барам дип җыена. Якшәмбе үтеп, дүшәмбе җитте исә, «Олы апамнарга барып кайтырга бик вакыт, сәфәр ае, бу атнадан да калмам!»— дип әйтеп куя. Дүшәмбе үтә, сишәмбе уза, тагын атна үткәне сизелми дә кала. Әйтерсең лә Шәмсеруй апа үн чакрымдагы күрше авылга түгел, бик еракка, Казаннардан да арырак китәсе!

Олы апасы янына барасы да килә, тыела да... Китәр, кунак көне бер атна, шушы атна эчендә өйдә ни хәл булмас? Кош-корт, тавыгы, казы дигәндәй, ул Сәрвәрнең малда кайгысы бармы?.. Әле шушы арада гына төннең төн буе хат кочаклап әле җырлап, әле җылап йокысыз чыкты. Өйдә эссе дип Шәмсеруй апа чоланга яткан иде, һәммәсен ишетеп ятты, чыгарга базмады. Сәрвәре артыгын төпченгәнне бер дә яратмый, Шамил белән ике арага кара мәче кергәннән соң, ни сорасаң да күзен чылатырга гына тора. Инде төн уртасында торып: «Кызым, нинди хат алдың?»— дип сорасаң, өйдә җил-давыл кубасын көт тә тор...

Их, андый чакларда Шәмсеруй апа вакытсыз дөнья куйган ире Эссәтне өзелеп сагына. Тол хатын — ярык казан. Ямыйсың, ямыйсың, барыбер ага, бер тишеге табыла аның. Ирле хатын — оядагы кош, җил-давылы да куркыныч түгел. Мазаны белми ул, утын әзерлисе юк, печән чабасы юк, быкыр-быкыр кайнаган казан янында йөрү рәхәт кенә ич ул!

Сәрвәре әткәсенә охшаган шул, кызулыгы да бар. Булганлыгы да бар инде, уңган кеше сүрән була алмый шул, кыза, ташый, дөньясын җимереп ташлый... Әнә, кешеләр балаларын өйләндерә, кияүгә бирә дә, тыныч кына яшәп ята... Йортта бер дә ваемы юк шул кызның, бар белгәне китап та дәфтәр, мәктәп тә бала-чага. Үз балаларың булгач та изаланырга өлгерерсең әле, дисең, юк, көлә генә.

Малда да кайгысы юк... Чебешләрне тилгәнгә алдырыр, көт тә тор! Ә каз бәбкәләрен кызыл күз Әйтмүшнең ач көчеге берәм-берәм чүпләп бетерер... Быел бәбкәләр мул чыкты, исән-сау үссеннәр, кышка, боерган булса, туй ясап җибәрербез, ә туйның асыл ашы — симез каз!.. Аннары, теге, Чәләкәләрдән алган бүрекле ала каз, чишмә суына риза булып тора мыни? Иртешкә чыгарлар да агым уңаена йөзеп китәрләр. Тот аннары син аларның койрыгын! Күршеләрнеке шулай булды бит. Үнбиш каздан бер көндә колак кактылар. Аллам сакласын!

Шулай уйлап йөри Шәмсеруй җиңги, шулай уйлап ята, шундый уйлар белән уяна. Кышын Рәукыйның улы Маннурны башлы-күзле иткәч, үзе аш остасы, туй остасы буларак, башыннан ахырынача аралашып йөргәч, гел туй турында гына ният кыла, кибеттән бер метр ситса алса да, «Сәрвәргә ярап куяр... Бусы фәләнгә бүләк булыр, бусы төгәнгә ярап куяр»,— дип юрый. Баштарак Сәрвәрнең туй дигән

сүзне ишетәсе дә килми иде, хәзер көнекте, көнде, әнисе ни әйтсә дә алай күтәрелеп бәрелми.

Кич житеп, Шәмсеруй апа колхоз эшеннән, Сәрвәр мәктәп тирәсе бакчасыннан кайтып кара-каршы утырып тирли-тирли чәй эчкәндә дә Шәмсеруй жиңги һаман кунакка барырга әзерләнә.

— Сәрвәр, мин югында кичкырын чебешләрне барлап келәткә яп. Онытма. Келәткә әрләп ияләшкән, почмак якта тишеге бар, аны таш тутыра-тутыра бүген үк күм, ишетсен колагың. Юкса бөтенесен ашап бетерер. Бакчаның ишегең ныгытып бикләп йөр. Чырыкның сарыклары көтеп кенә торалар, кыяр-кәбестәләрне кырып кына чыгарлар. Бу кадәр иясенә охшаса да охшар икән мал, икмәктер. Казларны карап ашат. Ата каз карт ананы аралый, ач калдыруы бар, гел шуны чукый... И аллам, картларны бераү дә сөйми инде...

Чәен итәгенә түгә-түгә Сәрвәр пырх-пырх көлә, ә Шәмсеруй апаның сүз йомгагы һаман тәгәри дә тәгәри:

— Сәрвәр дим, аш-су әзерләгәндә казанлыктан идәнгә күмер чәчрәп ут-күз чыга күрмәсен. Лампаны да карап як! Ишек-тәрәзәләреңне бикләә, капкага аркылы тәртә сал...

Эссәт Фәтхуллинны үтергәннән бирле Шәмсеруй апа моржа юшкәсенә кадәр томалап бикли, капка-ишекләрне һәммәсен күздән үткәреп, үз кулы белән бикләп кенә йокларга ята.

— Әллә бармасам да ярар микән? Нигәдер аягым тартмый! — дип, Сәрвәрнең сүзен дә көтмичә ишегалдына чыгып китте. Урамда йөргән тавыкларын ишегалдына өерләп кертте, капканы жентекләп бикләде.

— Сәрвәр, самаварыңны иске чиләккә генә как, күмере идәнгә коелмасын! Чәй суыңны көн дә алыштырып тор, өстен ябып тот, әйберкара төшмәсен. Токмачлык он агач тәпәндә, ипиең житәрлек, бәрәңгенең кабыгын юка әрче...

Түзде Сәрвәр, ай буена диярлек әнисенең үгет-нәсихәтләрен тыңласа да түзде. Чөнки Шәмсеруй апа ничә жыенып, ничә мәртәбә ярты юлында туктады, кунакка йөргәне юк, печәнгә төшкәнче, иркен арада аз-маз ял итеп, ирек ачып кайтсын инде.

Ниһаять, барысы да әзер, күчтәнәчләр төенчектә, әйтәсе сүзләр күңелдә. Алар барысын да аллага тапшырып кинчәбикәсе [1] белән юл тоттылар. Авылны чыгып та житмәделәр, Шәмсеруй апа бот чабып зарлана башлады.

— Әй, хәтер дигәнең, тишек иләк белән бер шул!.. Казларга каян жим бирергә кирәген әйтмәгәнмен... Тавыкларның кайсы ояларга күкәй салуын да белми торгандыр!.. Кич утырырга берүк Сәрвәр янына кер дип Мөхлисә әбине дә чакырырмын дигән идем... Берәр явызы кереп кызны куркытып йөрмәсә ярар тагын...

Бер жыенып чыккач, юлдан кире борылып кайту яхшы фал саналмый, шуны уйлап Шәмсеруй жиңги, кире кайтып тормады, мәгәр әйтәсе булып та әйтелмичә калган сүзләр аны юл буе борчып бардылар, олы апасы яшәгән Түгәрәккүл авылына барып житеп, йортка килеп керүгә үк, беренче сүзе итеп:

— Теге балага әйтәсе сүзләрем шулай күп калган! — дип сукрана башлады Шәмсеруй апа...

Шамилнең хаты Сәрвәрнең күңелен әллә кайларга үстерде, аңа яңа канатлар куйды. Ул әнисе кушканнарны да, кушмаганнарын да тиз арада аударып атты, идән-сәкеләрне юып, бүлмәләрне ялт иттерде. Кая караса да Шамил хатындагы юллар күз алдында булды, бар эшен аның хакына, Шамиленә багышлап аерата яратып башкарды. Өй эшләрен алай үз итеп бетерми иде Сәрвәр, моңарчы әнкәсе дә аның

[1] Кинчәбикә — иренең кече апасы.

уралып йөргәнен бик яратмады. «Кияүгә чыккач та камыт кияргә өлгерерсең, бар, әнә, укуыңны бел!»— дип йорт эшләренең иң авырын үзе башкарды.

Беркатка өй эшләре бетеп калды. Сәрвәр чормага менеп, киндер капчыкта сакланган ногыт ташыдай коңгырт кедр чикләвеге белән ян кесәсен тутырып төште. Бизәкле көянтәсен иңенә салып, черт-черт чикләвек чиртеп, ашыкмыйча гына Иртешкә су алырга төшеп китте. Кай заманнардан бирле беренче тапкыр аның җаны тыныч, җаны ял итә. Шамилнең хаты килде, ул озакламыйча кайтып җитәчәк. Сәрвәрен сагынып кайтачак, авылын сагынып...

Кинәт кенә Сәрвәрнең Мөхәммәт абыйсын күрәсе килеп китте. И куаныр иде аларның хәлләрен белсә! Сания апа да шатланачак, ул элегрәк, очраган саен: «Шамилдән хат киләме, нилэр яза?»— дип сорашып үтә иде, хәзер күрә калса, моңая да туктап Сәрвәргә карап тора. Кызганамы?.. Хәзер күрсен иде ул! Димәк, Мөхәммәт абый, сабый чактан ук яратып йөргән укытучысы, абруйлы өлкән кеше аның да этисе була инде!

«Әти, әти!»

Сәрвәр бу сүзне кычкырып-кычкырып кабатлады, ярый әле су юлы буп-буш иде, кеше-мазар күренмәде, аның ярымсаташып, ярымсөенеп: «Әти, әти!»— дип кабатлаганын беркем дә ишетмәде бугай... Бик иртә ятим калып, әтисез үскән Сәрвәргә әтиле булу аерым бер бәхет, тормышның иң югары кабатланмас шатлыгы кебек тоелды...

«Ә Сания апа әни була!»

Сания — әни... Әллә Казан яклары кебек «әткәй-әнкәй» дип йөрергәме? Ие, Шамил рөхсәт итсә, Мөхәммәт абый белән Сания апа ризалашсалар, ул аларны «әткәй-әнкәй» дип йөртер, кадерләп кенә әйтер ул олы сүзләрне!

Чикләвекнең кабыгын өреп төшерә дә төшен озаклап чәйни Сәрвәр, кедр чикләвегенең төшен озаклап чәйнәсәң, әүвәл май тәме, аннан каймак тәме килә башлый. Шулай ләззәтләнеп барганда Сәрвәрнең чырае әрем капканга охшап китте. Аңламаганда аның теш арасына күгәргән чикләвек эләгеп, тамак төбен яман куырып алды. «Тьфу, авызның тәмен бозды!» Ул никадәр төкеренсә дә ачы тәм тамактан китмәде, бер бозык чикләвек бөтен кәефне кырды. Ул ачудан барлык кесәсен айкап ыргытты.

Текә ярдан аска төште, күлмәк итәген күтәрә төшеп, җыерчыкланып ярга тәгәрәгән вак дулкыннарны ерып Иртешнең уртасынарак үтте. Көмештәй саф, татлы суны ике учына җыеп авызын чайкады. Иртеш, вак дулкыннарын тәгәрәтә-тәгәрәтә, аның йомыры тез башларын иркәләде, өскәрәк тә үрли башлады. Ул «Ай!» дип көлеп кычкырып сайгарак чыкты, учы белән су чәчрәтеп җибәрде... Менә Шамиле генә кайтып җитсен, Шамиле генә. Су керергә төшәрләр, су чәчрәтеп, балалар кебек куана-куана шушы урыннарда йөрерләр.

Су буе тып-тыныч, яр астында ышык һәм җилсез иде. Ул ашыкмады, чиләкләрен ком белән ышкый-ышкый озаклап юды. Ком катнашып болганган суның тонганын күзәтеп торды. Лып тулы авыр чиләкләрен яр итәгенә куеп, кояшта пешкән беләкләрен, ыспай сыйракларын юды... Араларыннан беренче булып кияүгә чыккан Сәлимәнең бер очрашканда көлә-көлә сөйләгәннәре хәтеренә төште. «Без Маннур белән, Сәрвәркәем, хи-и...»

Ул оялып як-ягына каранды, башын калкытты һәм тагын балаларча су чәчрәтергә тотынды. Кинәт сискәндереп якында гына ат пошкырды. Ул ашыгып күлмәк итәген төшерде, күкрәгенә күз ташлап өлгерде. Изүенең өске сәдәбе ычкынган икән, аны каптырды.

Ямьле Иртеш буйлары ла,
Кемдә икән уйлары!

дип болай да ямьле үк булмаган тавышын, юри, тагын ямьсезләндереп җырлый-җырлый ат җитәкләп Ташкәй су буена төшеп килә иде.

— Сәлам кызларга, судагы кондызларга!

— Саумы, Таштимер. Карале, атың көянтәмне таптап сындыра ич.

— Әй, кайгырма әле юкка, кәкре таяк кисәге сынудан ни зарар? Мин сиңа яңасын, менә дигәнен алып бирермен!

— Көмеш ыргаклысынмы?

— Теләсәң, алтын ыргаклысын!

Шуклык сүзе Сәрвәр авызыннан юккарак ычкынды. Ташкәйнең авызы ерылды, кәефе килде:

— Алып бирмәс дип беләсеңме әллә? Ышанмыйсыңмы?

Сәрвәр сүз сөрешен кинәт үзгәртте:

— Атыңны читкәрәк әйдә. Ашыгам, көянтәмне алыйм әле.

— Сәрвәр, сиңа сүзем бар минем.

Ташкәйнең аты бик сусаган күрәсең, сафьян иреннәрен мимылдатып каранып торды да, кызның чиләгендәге суга сузылды һәм күз ачып-йомганчы танавы белән чиләккә чумды.

— Нишли, нишли! Чиста чиләгемне пычрата лабаса!

— Аттан да чиста хайван юк, шуны белмисеңме, мөгаллимә?

Ташкәйнең тавышында ачы мыскыллау аһәңе яңгырады.

Шул мизгелдә җирән аргамак, чиләктәге суның азлыгына ачулангандай, борыны белән буш савытны төртеп җибәрде, чиләк чуерташлага бәрелеп зыңгылдап, елаган тавыш чыгарып суга тәгәрәп төште, иләп кенә агым уңаена тәгәри, ага да башлады. Ачуы кабарган кыз:

— Мәхлук, шул кадәр хуҗасына охшар икән! — дип кычкырды.

Шәмсеруй апа сүзләре бу. Чырыкның сансыз сарыкларын ул шундый сүзләр белән өерләп куа торган иде...

Сәрвәр бер кулына сыңар чиләген, икенчесенә башы кителгән көянтәсен тотып кайту чарасына кереште. Ташкәй, сусынын басарга теләп Иртешкә омтылган аты белән тартыша-тартыша, аның юлын бүлде.

— Сәрвәр, дим, тыңла инде сүземне бер тапкыр булса да. Күреп торасың бит, ничәмә еллар артыңнан йөрим. Нәрсәгә сиңа шул маңка балалар белән мәктәптә тузан әчеп, нервыларыңны бозып йөрергә? Икенче елымны әртилдә эшлим, Иртеш юмарт ул, балык та төшемле, бернәрсә эшләтмәм, рәхәттә яшәрсең. Чык үземә кияүгә! Туйны да гөрләтеп уздырырбыз. Маннур-Сәлимәләр ише генә булмас, инәм туйга дип кызыл үгезебезне дә симертеп куйган...

Китте тезеп, китте тезеп, пулеметтан атамыни!

Үгез кебек егетнең мескен хәлдә калып, шулай ялынып торуы кызганыч та, кызык та иде.

— Урамнан үткән бер баланы тәгәрәтеп сөзә торган кучкарыгызны да туйга дип симерттегезме? — дип үртәде дә, Сәрвәр, агым белән шактый ерак киткән чиләген барып алды, юды, су сосып, көянтәсенә элде. Ул арада кемнеңдер чиләкләрен шалтыратып су буена төшеп килүе ишетелде. Сәрвәр кабалана башлады, «Яман күз күреп калмасын, Шамилгә ямьсез итеп сүз ишеттермәсен тагын!»

Ташкәй ялварып әйтеп калды:

— Сәрвәр, ут белән уйныйсың. Сак бул!

Акъяр авылы егетләре, Ташкәйнең дуслары, байтактан бирле Сәрвәрне алып качарга котыртып йөриләр иде инде. Ләкин ул ризалашмады: «Төяп алып китәргә хайванмы әллә ул? Яраткан кешеңне шулай мәсхәрә итәргә ярыймы?»— дип кырт кисте.

Ә күңеле нидер сизә, Сәрвәрдәге үзгәрешне ап-ачык күреп тора. Моңарчы иелеп, мескенләнеп йөргән Сәрвәр, бүген ике чиләк суны әһ тә итмичә күтәреп, Иртешнең текә ярыннан менде дә китте... Ни булган?.. Әткәсе исән чагында: «Күңелең керсә, Эссәт кызы дип торма... Әтисе әллә кем булмаса да, кызын үзеңчә өйрәтерсең, кулыңнан кил-

мәсә, башка кеше табылыр! Кызы болай ару гына күренә!» — дип кабатлый иде... Шамил белән аралары бозылу авылга фаш булгач, Ташкәйнең өмете бөтенләй ныгыган иде, ул Сәрвәрне үзенеке санап, сәгате-көне килеп җиткәнне генә көтә иде. «Эх, Сәрвәр, Сәрвәр! Мин сиңа бары яхшылык кына телим ич, шуны да аңламыйсыңмы әллә?» — дип әйтергә теләде Ташкәй.

Шамилнең көттереп килгән хаты уяткан шатлыклы хисләре эченә сыймаган Сәрвәр шактый үзсүзле һәм гарьчел Таштимерне ни дәрәҗәдә кимсетүен аңламады...

Берничә көннән соң Йосыфлар чатында аңа Сәлимә очрады. Сәлимә матур гына түгәрәкләнеп килә, калынайган, алъяпкычы бүлтәеп алга чыккан, битенә килешле генә булып тут йөгергән. Сәрвәр Шамилнең хатын үзе белән йөртә иде, хатны Сәлимәгә тоттырды.

— Укы! Шамил язган!

Сәлимә сөенә-сөенә укып чыкты да Сәрвәрне нык итеп кочаклады да сөенеп кычкырып җибәрде:

— Котлыйм, дустым, чын йөрәгемнән тәбрик итәм. Әйттем бит мин сиңа, язмый калмас, язар дидем. Уразаев бит аның фамилиясе... Ул нык токымнан яралган зат. Кадерен бел син аның...

— Син алай ук димә әле, Сәлимә...

Сәлимә төрле яктан китереп Шамилне мактарга тотынды:

— Әтисеннән бер дә калышмас... Нәкъ аның шикелле дөрес кеше булыр!

Сәрвәргә шундый рәхәт булып китте, ул шунда ук хыял дулкыннарында тирбәлеп әллә кая, еракларга агып та бара башлады. Менә тиздән аларның туе булып, күч күчерерләр, гармун уйнарлар, казан тутырып ит пешәр, гармун чыңы яңгырар...

— Әнине кунакка җибәрдем әле,— диде кинәт Сәрвәр.— Әгәр Шамил Тоболга кайтып төшсә, мин аны каршыларга барыр идем. Син безнең кош-кортларны карап торырсың бит, Сәлимә.

— Карармын, карармын! Маннур белән икәүләп килеп карарбыз.

Әнкәсенең киткәндә әйтеп калдырган «васыять»ләрен хәтергә төшереп көлеп тә куйды.

— Нигә шаркылдыйсың?

— Болай гына... Бер мәзәк искә төште!

— Син, кызый, сак бул. Ташкәй сиңа бик нык өметләнә икән, диләр. Бер-бер ирмәк кылып ташламасын.

— Кызу, тупас булса да, Таштимер андый юлга басмас. Шамилне дә белә ул, Мөхәммәт абыйда укыды.

— Обдорскида аларны алыштырып кайтарганнар, диләр.

— Юк сүздер лә!

— Алай да сагай. Кичкә безгә куна кил. Маннур үз бригадасы белән Кызылбай төптә кунып печән чабарга китә. Кичен килсәң, барысы турында да рәхәтләнеп сөйләшеп утырырбыз, яме! — Сәлимә кызарынып дус кызының колагына иелде.— Мин дә барам дигән идем, «Бәбигә болын салкыны тидерерсең, өйдә кал»,— диде.

Алар икәүләшеп рәхәтләнеп көлеп җибәрделәр.

Көнен Сәрвәр йорт мәшәкатьләре белән уздырды, колагында әнисенең «наказ» биргән тавышы яңгыраса, күз алдында гел Шамил булды. Ул озакламый кайтырга тиеш! Сөйләште дә сөйләште Сәрвәр, сөйләшкән саен әле җиңеләйде, әле авырлашты. «Көтергә кушкансың, җүләрем, көтмәгән кайда ул! Кирәк булса гомер буе көтәргә дә риза! Туйны Сәлимәләрнеке кебек уздырырбыз микән? Ташкәй «алардан да уздырам!» ди. Нигә кешедән уздырып җибәрергә, аларның да туе бик матур булды, неме? Минем ап-ак күлмәк киеп, түрдә синә сырылып утырасым килә... Синең кайнарлыгыңны, тән җылыңны тоеп. Сине башкаларга һичвакытта алыштырмам, күңелем белән дә хыянәт итмәм, үем белән дә!.. Үлгәндә дә хыянәт итмәм!»

Тавыкларга җим сибеп аларны чакыра да, күңелендәге уйларын кабатлый:

— Мин Шамилне генә яратам, шулай бит, тавыккайлар?

Келәт почмагындагы әрлән тишегеннән вак ташлар белән төя-төя әллә кайчан күмеп куйды, курыкмагыз хәзер, кө-өш! Керегез дә тып-тыныч кына йоклагыз... Чишмә буасыннан казлар да канат кага-кага кайтып житте, аларны да аранга куып кертте Сәрвәр, алларына су китерде, тавыклардан калган җимне сипте. Сарыклар да әлсерәп мәәлдәшеп көтүдән кайтып керделәр.

Көтү кайтып озак та тормады өй эче шомлы бер төскә керде, кинәт караңгыланып китте. Сәрвәр ишегенә ат башы кадәр дәү йозак асып, капканы да бикләп алгач, Сәлимәләргә кунарга барырга чыкты. Мондый төндә зуп-зур өйдә япа-ялгыз калу куркыныч, аннары Сәлимәләрдә аулак өй, рәхәтләнеп бер сөйләшерләр ичмасам! Кияүдәге хатын белән кияүгә чыгарга җыенган җиткән кызның уртак сүзләре тавык чүпләп бетерә алмаслык була ич ул! Туасы бәбәйләренәниләр әзерлиләр икән, бишекләре бармы, кул арбалары, бик күп әле Сәрвәрнең сораулары, бик күп...

Көнбатыштан ишелеп чыккан кара болыт, утлы кылычын айкап, авыл өстенә аударылып килә иде. Җил урам тузанын себертә, вак-төяк йомычкаларны куа. Өй ышыгында качып торган бер-ике сарыктан башка авыл урамында җан иясе дә калмаган. Мәчет янындагы ялгыз тирәк, ышыграк бүтән бер урынга күчергә теләгәндәй, шомлы тавыш чыгарып чайкала-чайкала шаулап Сәрвәрне озатып калды, аны йөгерергә үк мәҗбүр итте. Җир буе китә алдымы икән, болыт тишелеп китеп жиргә чиләкләп яңгыр ява башлады. Сәрвәр яшен яктысында тыкрыктан чыгып килгән ике шәүләне күреп калды. Ул күлмәк итәген тотып, бер кулы белән битен каплап, җилгә каршы йөгерә башлады. Карун Рәхмәтуллалар абзары артыннан бер кеше чыгып, аның юлына аркылы төште.

— Ай, кем бу?

— Кая ашыгасың алай, асылкош? Җир күрмәй кая чабасың? Ыспай күлмәгеңә пычрак сылагансың гуй.

— Үлмәс? Синме бу?

— Мин булмыйча! Исемем дә Үлмәс, үзем дә үлмәс!

Бая тыкрыкта күренеп калган ике шәүлә дә кызны ике яктан камап алдылар, ул чәрелдәп кычкырып җибәрде, әмма нәкъ шул чагында Иртеш өстендә яшен яктысы чәчелеп китте, авыл өстенә Кызлар Убасы ишелде, Сәрвәрнең әрнеп кычкырганын беркем дә ишетми калды...

## 38

Ташкәй белән Үлмәс икесе бергә балыкчылар әртилендә эшлиләр. Әртил — яңа эш, әле оешып кына килә, бригадирлары Кузьма Матвеевич дигән урыс, күрше авылдан, ике дистә таза-таза егетләрне җыеп, Иртештән дә, Иртеш төбәгендәге күлләрдән дә балык тота башлады. Әле әртилнең конторасы да юк диярлек, кораллары да теләсә каян һәм теләсә кемнән җыелган елымнар, берничә көймә генә диярлек, тотылган балыкны саклар урыннары да юк, районнан: «Печән өстендә колхозларны тәэмин итегез»,— дигән күрсәтмә килде.

Алар элек тә бер-берсенә тартылалар, уеннарда бер-берсен яклыйлар, яшьләр арасындагы тарткалашларда, сугышларда гел бер-берсенә таяналар иде. Ташкәй буйга калкурак, тазарак, төскә дә чибәррәк. Үлмәс кешедән бигрәк йөнтәс, кырыс аюны хәтерләтә, гомере буе аттан төшмәгән кеше кебек аяклары да камыт, йөргәндә дә алга сөрлегебрәк, аска карап йөри...

Акъяр авылы егетләре тирә-якта иң кыдрач егетләр булып дан

алганнар, бу гомер-гомергә шулай килә. Сабан туе җиттеме, ул авылның егетләре ду килеп бер сугышалар... Балыкчылар артилендә алар авылыннан өч егет бар иде, болай күрер күзгә иплe генә йөриләр, эшкә дә осталар, елымны да иң белеп алар сала, балыклы күлләрнең кайдалыгын беләләр, су салкын дип куркып тормыйлар, кереп китәләр, бригадир да аларны үрнәк итеп куя, ай азагында акча алганда да алар өлешенә күбрәк төшә. Иң кызыгы әнә шул акча кулга кергәч булды. Кулына корал кергән ир үзгәргән кебек, кулына акча төшкән ир дә күзгә күренеп үзгәрә. Акъяр егетләре уч тутырып акча алдылар, менә йөриләр берзаман кабарган күркәләр сыман, әллә кай арада ящигы белән аракы кайтарганнар, әллә ни арада уха пешереп өлгерткәннәр, бригадир Кузьма Матвеевичны ике яктан култыклап алганнар да аш янына ук менгереп утыртканнар. Аракы сүз чыгара, сүз талашка әйләнә, Ташкәй белән Үлмәс тә шунда...

Ташкәй гомер-гомергә Үлмәсне үзеннән түбән санап йөрде, йомышюлга аны йөгертте, кирәктә-кирәкмәстә дә җикеренеп аны буйсынып яшәргә күнектерде. Ырсытдин гаиләсе читтә чакта Үлмәс кабарынып авыл егетләрен үз кулына алып өлгергән иде, Ташкәй кайтып төшкәч, сүзсез-нисез элекке хәл кабатланды, Ташкәй баш булды, Үлмәс аның койрыгы.

Шулай булды, шулай булып килде, шулай булып калыр да! дип уйлый иде Ташкәй. Гомумән, Ялан авылында үзеннән дә зиһенле, үзеннән дә көчле егет бардыр дип Ташкәй уйлап та карамый иде. Әнкәсе Йомабикә абыстай көн туды исә аның колагына тукый:

— Улым, төсең-башың килгән, көчкә дисәң Гали батыр белән берсең. Үзеңә тиңне генә кара, эшен дә, ярын да, һәммәсен дә...

Әнкәсе Ташкәйнең балык эшенә керүенә сөенде.

— Хәйләкәр балык бул үзең дә!— дип теләк теләде.

Ташкәйне Акъяр егетләре дә үз иттеләр, бүтәннәр белән якалашырга гына торганда да Ташкәй янында холыкларын тыйдылар, әтәчләнмәделәр, кирәк чакта киңәшкә килделәр.

Бу хәл белән Үлмәс кенә бер дә килешергә теләмәде. Һич югында авыл яшьләре арасында аның Ташкәйне үтеп китәсе, аста калдырасы килде. Кай көннәрне алар бер-берсенә сөзгәк үгезләр кебек кырын карап йөриләр-йөриләр дә, йә бер сәбәп табылып, йә бер сүз килеп чыгып Ташкәй гел өстә кала.

Ничек егарга аны? Ничек арт сабагын укытырга?

Теләсә нинди этлеккә әзер торган, теләсә нинди явызлыкка әзер Акъяр егетләре ярдәмгә килделәр...

«Ташкәй назлана, Ташкәй әйбәт булып күренергә тели, Ташкәй авылның сылуы Сәрвәрне яхшылык белән алдырмакчы, ә Сәрвәр яхшылык белән ипкә килми, сынмый, буйсынмый, кыз башы белән егеттән көлә...» Күпме түзәргә мөмкин?

Һәм Шәмсеруй апаның кунакка китүеннән, кызның ялгыз калуыннан файдаланырга уйлады Үлмәс. Кызны да сугып ала, Ташкәйнең дә борынына чиртә! Эш узгач, әйдә, сикереп карасын! Бер тәпәләп алса да Сәрвәр хакына риза, авылда: «Сәрвәр Үлмәснеке!»— дигән сүз генә таралсын. Әле Акъяр егетләре Ташкәйгә канат җәярга бик ирек тә бирмәсләр: «Әгәр шул кызны сугып аласың икән, без синең яклы, беркемгә сүз әйтергә ирек бирмәбез!»— дип әйтә-әйтә бер чирек ачы бал эчтеләр.

Төне гаҗәп уңай килде, өйгә кереп, ишек ватып торасы булмады, алар Сәрвәрне урамда ук очраттылар. Җитмәсә яшен яшьни, коеп яңгыр ява, урамда этле зат юк, чит күзләр-шаһитлар карап тормый. «Кыз урлау борынгыдан килгән йола... Ат урлау һәм кыз урлау татарларның мәңгелек гадәте!»— дип дәртләндерде Үлмәсне этказе...

— Юкны сөйләмәче, Үлмәс!

— Барны сөйлим лә, Сәрвәр.

— Шаярып чак тапкансың, әй, Үлмәс!— дип Сәрвәр анның янын-нан үтеп китәргә теләгәндә, Үлмәс селәүсен елгырлыгы белән кызга ташланды, ике беләгеннән дә эләктереп алды. Сәрвәр кычкырып та өлгермәде, уңнан чыккан кеше учы белән аның авызын томалады, икенчесе авыр, юеш толып ташлады. Кыз, бөтен көченә тыпырчынса да, берни кыла алмады, ике пар куәтле куллар аны ике яктан чытырдатып кысып алдылар, сасы толып эчендә аның тыны кысылды, йөрәге атылып чыгардай тибә башлады. Шул ук ыргаклар каптырып җирдән күтәреп тә алдылар, бераздан ул үзен арбага салуларын тойды. Берәү өстенә атланып утырды, икенчесе тарттырып аякларын кушып бәйләде. Атны куа башладылар. Бертуктаусыз күк күкрәде, яңгыр шыбырдап койды, юл сикәлтәләрендә, кызның ачылып киткән тез башы бәрелеп сызлады, сулышы кысылды. Инде үләм, беттем дигәндә тимер ыргак кебек куллар каптырып алдылар да очыртып алып киттеләр. Сәрвәр бу мәхшәрнең асылын аңлый алмыйча исәнгерәп чак-чак кына күзен ачса... «Әйдә, килен, түкле аягың белән!»— дип, күгәргән тавыш белән шыгырдап, аның каршысына язмышының өрәге булып Үлмәснең атасы килеп басты...

«Килен? Димәк, бу уен гына түгел!»

Хәлсезләнгән Сәрвәрне бер ягыннан таныш булмаган егет, икенче ягыннан мышнап калган Үлмәс култыклап алганнар. Түрдә, табын артында, яшертен муллалык итүче Чырык Абдрахман җәелеп утырган... Кызның өс-башын алыштырып та тормадылар, юеш күлмәге өстенә коры шәл ташладылар да, аңына килмәс борын Үлмәс белән янәшә утырттылар. Агач мулла никах укый башлады. Эшнең мөшкел, үтә хәтәр икәнен бөтен ачылыгы белән аңлап бетергән кыз җан авазы белән кычкырып җибәрде:

— Юк, юк! Кирәкми! Нишлисез? Тимәгез миңа!— дип, алга ыргылды. Үлмәс култыгыннан ычкынды, өстәлдә яткан пычакны эләктереп алып Үлмәскә кизәнде. Менә кадыйм дигәндә, баягы таныш булмаган егет кызның кулын боргычлап пычагын идәнгә төшерде, кыз «кияү егете»нең түбә чәчен йолкып чыгарды. Ачудан үкереп Үлмәс Сәрвәрне сугып екты. Ул яткан көйгә мәчедәй тырнашты һәм мүкәләп ишеккә үтәргә тырышты, аягына шәле уралды, юеш күлмәге тәненә ябышып хәрәкәтне кыенлаштырды. Аны аягыннан тотып алдылар, әлеге каты куллар тагын Үлмәс янына китереп яньчеделәр. Чырык «Әллә никахны калдырып торабызмы?» — дигән сораулы карашын Үлмәскә ташлап алды. Сәрвәрнең кем кызы булуы исенә төште, аның Мөхәммәт Уразаев улы белән ярәшелгән диярлек булуын хәтерләде, әгәр хәзер никахсыз-нисез генә чыгып котыла алса, мөгаен, ул бу «тантанага» яңадан эләкмәскә тырышыр иде. «Мөхәммәт Уразаев белән эшең төшмәсен, аллам сакласын!»— дип борчылып уйлады ул кызның юеш күлмәге ачылгач ятырып калган түгәрәк ботларына карап...

«Ник ичмасам арада бер хатын-кыз юк! — дип инәлде Сәрвәрнең күңеле,— ул минем хәлемне аңлар иде бит!»

Үлмәс Чырыкка усал карап алды да, Сәрвәрнең билен тагын да ныграк кысып, үзенә таба тартты.

— Нәрсә, коммунис килене буласың киләме? Булмый торсын, шәт, бик кирәксә, аңа бездән калганы да бик таманга килер. Монда бүтәннәр барын да белеп торсыннар! Укы никахыңны, нәрсә авызыңны ачып торасың? Утыз тәңкә бирелгәнме сиңа!? Бирелгән! Укы, канца канцов!

Чырыкның сирәк сакалы дерелдәп китте. Шул арада Сәрвәр бармагы белән Үлмәснең ирен читен ертып алды, кан күренде, егетнең әткәсе авызны сөртергә чиста тастымал китереп бирде.

Сәрвәр Чырыкка ялынды:

— Абдрахман әкә, алма җаныңа гөнаһ! Кирәкми, мин риза түгел, булмый, Коръән алай кушмый, ярамый!— дип үрсәләнде.

Чырык икеләнә башлады, эш болай зурга китәр, дип уйламаган

иде ул... Җәнҗәл кубачак, тавыш чыгачак! Кызны алырга нияте нык икән, ни пычагыма аңа никах! Тот та кочагыңа ал инде, имгәк! Бер яктан шулай, икенче яктан кулга килеп кергән утызлык та кесәне яндыра. Яндыра!..

Ниһаять, Үлмәснең әтисе дә тавыш бирде:

— Никах кирәк, кызым. Без, аллага шөкер, мөэмин мөселманнар, безгә, безнең йортка никахсыз килен ярамый. Менә хәзер никах укытабыз да ир белән хатын булып гөрләшеп яши башларсыз. Тормышыбыз житеш, беләсең ич!

— Үлмәс, оятсыз! Җирбит! Әтине җәлләгән булып йөрдең бит, явыз! Коткарыгыз мине, кыргыйлар, җибәрегез!

Сәрвәр калган көчен туплап тагын бер талпынды, чәйнәште, тырнашты. Ләкин көчләр тигез түгел иде. Аны күтәреп эчке бүлмәгә алып кереп киттеләр. Чырык Абдрахман никах сүзләрен мыдырдап калды... Үлмәсне дә шунда кертеп ябып, ишеккә йозак элделәр. Алгы бүлмәдә, очкылыгы тота-тота, Абдрахман Чырык бая башлаган никах догасын укып бетерде, дерелдәгән куллары белән битен сыйпады да чыгып сызды, никах чәен эчеп тә тормады...

Мыштым Үлмәс... Менә сиңа мыштыбый. Ул кеше күзенә ташланмыйча гына үсте, укытучы күзенә төртелерлек шуклык, явызлык кылмады, кылса да шома гына таеп китәргә күнекте, уртача укыды. Халык игътибарын җәлеп итәрлек берни дә эшләмәде.

Кыз урлау бер аннан калган гына гадәт түгел, ләкин күп вакытта бу эш ике якның ризалыгы белән кылына. Әгәр ата-аналары риза булмыйча ыкы-мыкы торалар икән, кыз «үзен урларга» егетне котырта ук башлый... Әгәр йортка сеңеп калса, мал табар Үлмәс Сәрвәрдәй чибәр һәм шактый акча төшерүче мөгаллим хатын белән чибәр генә гомер итәчәк, инде аерылып китсә, тормыйм дисә, дүрт ягы кыйбла, никах укылган, Үлмәснең өйләнүе белән беркетелгән, беркем бер сүз әйтә алачак түгел... Ир хатыннары аерылып китә, ирләрен ташлап чыгучы бичәләр бар, әгәр инде китәм дип чирәшеп катса, дүрт ягы кыйбла! Помабикә абыстай аңа Мәүлияне димләп тора:

— Ырсытдин әкаңнең сиңа әйткән сүзе минем өчен васыять, менә укып бетереп кенә кайтсын, тотабыз да туй итәбез!— ди.

Сәрвәрне татып караганнан соң Мәүлияне тотып ашарга да каршы түгел Үлмәс! Ташкайгә ике яктан тибү булыр иде бу! Кәләшеннән дә колак кага, сеңлесеннән дә...

Бу план җәй башында ук корылган, Акъяр егетләре белән мәслихәтләштерелгән иде. Ташкайнең гел Сәрвәр тирәсендә чуалуы гына Үлмәскә комачаулап килде.

Урамда җир тетрәтеп күк күкрәде. Күк гөрелтесе тынып торган арада эчке бүлмәдән җан әрнеткеч үксегән, дөбер-шатыр килгән тавышлар, ара-тирә: «Ах, ләгънәт!»— дип усал янаулар, кайчакта өзек-өзек сүгенгән авазлар, ярым-йорты җөмләләр ишетелеп калды, яңгыр тагын да шәбәйде, дөнья дөм-караңгы булып китте.

Үлмәс йортының тәрәзә капкачлары өченче көнне генә ачылды...

Дус кызын көтеп-көтеп тә көтеп ала алмаган Сәлимә, иртән нидер сизенеп, пошынып Шәмсеруй җиңгиләр йортына китте. Барса, капка бикле, колхоз рәисе Дәүләтша әкә атлы тарантас белән килеп туктаган һәм капкага шакып тора.

— Өйдә юклармы әллә, Дәүләтша әкә?— дип сорады Сәлимә.

Ишегалды ягыннан ач сарыклар мәэлдәгәне ишетелде.

— Юклар шикелле, шакыйм, шакыйм, ачмыйлар.

— Кирәк идеме, Дәүләтша әкә.

— Торадан шалтыраттылар. Анда Шамил кайтып житкән. Сәрвәрнең: «Шамилне үзем барып алам!»— дигән сүзе бар иде.

Сәлимә нидер сизенеп өенә таба йөгерде, байтак баргач кына Мансурның болында икәнлеге исенә төште. Аптырап борылып карады.

Дәүләтша әкә атның йөгәненнән тоткан да ашыкмыйча гына бара, балчык сарган тарантас тәгәрмәчләре авыр гына әйләнәләр, ат артыннан урам тутырып эре-эре балчык кантарлар каерылып кала...

## 39

Шәмсеруй апа атна торып, бик канәгать калып, күтәренке рух белән гомер кичергән йортның капкасын атлап керде. Өйгә кергәнче келәтне ачып карады, мур кыргыры әрлән, келәтнең икенче почмак астын тишеп, йодрык сыярлык тишекне шомартып бетергән, келәт идәнендә тавык башы аунап ята. «Аh, явыз, иң игелекле, иң эре күкәй сала торган бүрекле сары тавыгым!»— дип иңәлде хуҗа. Эшнең моның белән генә бетмәслеген сизенеп, абзар-кура капкаларын, лапас түбәләрен ачып-ачып карады, җим күрмәгән ач тавыклар аның аяк астына кайсыкаян йөгерешеп килеп җиттеләр, чишмә буасына чыкмаган казлар әлсерәшеп, моңаеп утыралар, тавык оялары шыплап күкәй белән тулы иде, беркем дә аларны җыймаган, беркем аларны карамаган. Тавыклар су эчә торган таба яңгырсыз елны Кызлар Убасы кебек коп-коры иде. Аптыраудан телсез калып, хәле китеп Шәмсеруй җиңги өйгә керде, тозлы каз боты кимереп яткан карак песи аны күргә йомылып кына чыгып сызды.

— Ах, оятсыз!— дип кычкырып калды Шәмсеруй апа.

Ул кесәләреннән, төенчегеннән күчтәнәчләр, эсседә изелә башлаган кәгазьле кәнфит, ватылган бавырсак кисәкләрен бушатырга, аларның кайсын-кая урнаштырырга кереште.

— Сәрвәр дим, Сәрвәр, күчтәнәчләрдән авыз ит. Кайда йөрисең?

Шул чагында эчке бүлмәдән сулкылдаган шикле тавыш ишетелгәндәй булды. Шәмсеруй апа сискәнеп, кулындагы кәнфитләрен чәчеп шунда узды һәм катып калды. Бер мәлгә: «Әллә күземә күренә инде?»— дип уйлады... Юк, күренми икән, бу хәл чын икән, кызының сулкылдаудан калтырап торган ябык аркасын барып кочкач ана барын да аңлады...

Сәрвәрнең чәче тузган, күз тирәләре күгәреп шешкән, күлмәге өзгәләнеп ертылган...

— Ниләр булды, күз нурым?

Ана йөрәк җимешен күкрәгенә кысып ачыргаланып, өзгәләнеп, җан авазы белән бүлмәне тутырып кычкырып җибәрде. Аннан тиз-тиз кызның кул, аякларын тотып карады, куллар яна, аяклары боз кебек салкын иде кызның. Әле аның Үлмәсләр йортыннан котылып кайтып кергән көне генә иде...

Нинди ягымлы сүзләр белән генә иркәләмәдә кызын ана, нинди татлы кушаматлар тагып кына бизәмәде, Сәрвәр дәшмәде дә, җавап та кайтармады, акылын җуйган кеше сыман тик бер ноктага карап утыра бирде. Ана самавырда су җылытып тиз-тиз генә аның аяк-кулларын юды, өс-башын алыштырды, эчке күлмәкләрен салдырганда, куркып шигәйде, көчләп диярлек Сәрвәргә бер чынаяк чәй эчертте һәм чипчиста урын җәеп йокларга яткырды. Үзе күршеләргә чапты...

Юк, күрмәгәннәр, өченче көн инде Сәрвәрнең өйгә кайтканы юк, ә мал-туарны Сәлимә килеп карап йөргән...

Шәмсеруй апа абына-егыла ашыгыч рәвештә чабып барып Өннә апаны алып килде, икәүләп бик озаклап кызны сөйләштереп карадылар, анда да җавап ала алмагач, кызны буш өйдә җен суккандыр, саташып чыгып киткәндер дә, ике төн буена кайдадыр бәрелеп-сугылып йөргәндер, шунда өс-башы таланып, ертылып беткәндер, дигән нәтиҗә ясадылар.

Шәмсеруй:

— Уразай Саниясен чакырып карыйк, дуктырлыкка укый, бер-бер әмәлен беләдер, табар!— диде.

Өннә апа:

— Әгәр Сәрвәрне җен алыштырган икән, брачлар ни әйтә алсын? Иң яхшысы, шыпырт кына Чырык Абдрахманны дәшеп карыйк!— дип карышты. Озак уйлашканнан соң, «Чырык Абдрахманның тавышы өне дә булмас, кешегә чыгармас, иншалла, әйдә килсен-килсен»,— дигән фикер яраклаштырдылар. Аларның әле кызып, әле борчылып, әле җылап табыш-киңәш итеп утыруларын Сәрвәр тавышсыз-тынсыз гына тыңлап ятты, Шәмсеруй минут саен диярлек барып карады — кызның түшәмгә төбәлгән күзләре ап-ачык, ап-ачык күзләрендә уй, моң юк иде...

«Сәрвәр җайсызланыбрак китте бит әле!»— дигәнне ишеткәч, Чырык ком җибәрде, «Алай икән, алаймыни? Ни булды икән тагын, гөнаһ шомлыгы!»— дип юк-бар сүз сөйләп утырды да, барудан баш тартты:

— Үземнең дә кәеф кыйгаеп тора бит әле, кем, Шәмсеруй, бил сызлый, баш чатный, күз төпләренә тиклем авырта!— дип зарланды...

Үлмәстән эләккән утыз тәңкәне эчеп бетергәнгә, махмырдан башы авыртуын, әлбәттә, әйтеп-ачыклап тормады. Шәмсеруй бик нык инәлде, ялварып сорады.

— Кадерле баламны аякка бастырсаң, көзен буш итмәм, Абдрахман әкә,— дип тезләнеп ялварды Шәмсеруй. Шуннан соң гына, анда да бик зур авырлык белән генә Чырык ризалашты.

— Ил теленә керерлек булмасын, Уразай яки Дәүләтша ишетеп калсалар, көн күрсәтмәсләр...

Абдрахман кичкырын гына килде, һаман урын өстендә хәрәкәтсез яткан Сәрвәрне аннан-моннан караштырды, күңеленнән: «Җаны туптуры җәһәннәмгә олакса гына ярар иде, тагын да зуррак гаугаларга дучар итмәсен тагын бу тиле җан!»— дип теләк теләде, авызын ачып:

— Әйе, Шәмсеруй килен, кызың йорт пәриенә сугылган, аны уйнату кирәк,— диде.

Сәрвәр терелеп, булган хәлләрне сөйләп бирсә, шаманлык хезмәтләре дә күрсәтә торган Чырыкның үзен биетүләре бик ихтимал!

Сәрвәр аз гына хәрәкәтләнә башласа да Чырыкның без кебек очлы сирәк сакалы дерелдәргә керешә иде. Ул кызның күзенә туры карарга курка, сүзе бутала, аптыраганнан «Сөбханалла!»— дип кат-кат әйтә башлый.

Иртеш буе татарларында акылдан шашкан кешеләрне биетеп, кагып-сугып имләү йоласы бар. Мөгаен, бу йола аларга күршеләрдән, төньяк халыклары ханты-мансилардан күчкән булырга кирәк.

Шәмсеруй туйга дип җыеп килгән бар акчасын тотарга риза, Сәрвәрнең җенен кусыннар да, терелеп аякка бассын. Чырык тәкъдиме белән ул буйдак Гобәйбәдән бер чиләк көмешкә сатып алды, гармунчыны, баш биючене Чырык күрше авылдан үзе алып килде. Ишек-тәрәзәләрне ныгытып бикләделәр. Пәрдәләрне төшерделәр. Мич капкачларын, юшкәләрне ачтылар. Пәри, Сәрвәрдән күчеп, мичкә сикерергә, аннан төтен юлы буйлап күккә чыгып югалырга тиеш икән...

Чырык, дога укып, башта Сәрвәрне өшкерде. Аннан ярдәмчеләре кызны сәке читенә күтәреп утырттылар да артыш төтәтеп шуның белән ысладылар. Икенче яктан Чырык мунча себеркесенә ут кабызып җибәрде. Өйгә ачы сөрем, зәһәр төтен исе таралды. «Пәри шушы исне сөйми!»— дип аңлатты Чырык һәм очкыннары сибелеп торган себеркене кыз тирәсендә чайкарга тотынды. «Кайдан килсәң, шайтан, шунда кач!»— дип яман үкереп, кызның эченә кереп урнашкан җенне куаларга, йорт буйлап чабарга кереште. Булышчыларыннан берсе, Чырык бегә, йорт буйлап чабарга кереште. Булышчыларыннан берсе, Чырык белән берничә тапкыр имләгәне бар икән анысының, йөгән тезгенен чайкап, авызлыгын шылтыратып Сәрвәр янындагы «кемнедер» куйнарга маташкандай кыланды. Артыш төтене өйне тутырды, кешеләр карлыга, йөткерә башладылар, күзләреннән сөремле яшь акты. Агай-эне берәр стаканны чөмергәч, гармунчы бию көен уйнап җибәрде.

— Әйдәң, уйнату кирәк, кызны торгызың!— дип кычкырдылар шактый кызып алган булышчылар. Сәрвәрне аягүрә бастырдылар, як-ягыннан тотып торып, биергә димли башладылар. Ул түшәмгә, почмакларга мәгънәсез караш ташлады да, анда гадәттән тыш кызык нәрсә күргән кебек шаркылдап көләргә тотынды. Соңыннан төсе кинәт үзгәрде, иреннәре еламсырагандай кыегая башлады, ул куркынып почмакка чигенде. «Тимәгез, кагылмагыз миңа!»— дип кычкырды. Үзе бупбуш урынга төбәлеп бармак янады, сул кулы белән күлмәк итәген бөреп тез астына өерләде. Булышчыларның буйга калкуы, тәҗрибәлесе:

— Ни карап торасыз? Уйнатырга кирәк! Кеше күргәнегез юкмы әллә?— дип бер җикеренгәч, тагын берәр тустаганны каплап килгән кешеләр кыюланып киттеләр, кызны әле нечкә биленнән кысып, әле йомшак кулларыннан тотып як-якка өстерәргә, биегәндәй итәргә керештеләр. Тустаган бертуктаусыз хәрәкәттә булды, шау-шу көчәйде, артыш төтене идәнгә кадәр төшеп җитте, аракы пары белән томаланган миләрне тәмам тилертте, Сәрвәрне биленнән алып чүктергәндәй иттеләр, икешәрләп тотып өскә чөйделәр, шәрә ботларына уч белән шапылдаттылар. Тоткан булып йомыры күкрәкләрен умырып-умырып алучылар да булды. «Эх, миңа булса, бер атнада акылга китерер идем мин бу сылуны!»— диде исерек булышчыларның берсе.

Кыз кинәт йокыдан уянгандай булды, авызын учы белән каплап йөткерде һәм гармун кеткелдәве колагына керде булса кирәк, иңбашларын сикертеп торды да биеп китте. Тальян гармун исерек кулында җәберсенгәндәй гыжылдап ала; ике-өч кеше берьюлы иске идәнне җимерер дәрәҗәдә сикереп биилләр иде.

Ай-һай, янем, ау!
Ай-ай, яннәрем, ау!
Җирдә уйнаган көннәрем, ау!
Озын-озын елгаларның
Очларына кем чыгар?
Чуар ала кубәләкнең
Йомыркасын кем табар?
Ай-һай, яннәрем, ау!

Сарнаучылар[1] җыен тузга язмаган сүзләр такылдыйлар, идән шыгырдатып сикерәләр, акыралар иде.

Өйалдына чыгып торырга кушылган Шәмсеруй белән Өннә, үзләренең хата ясауларын да аңлыйлар, үкенеп бетә алмыйлар, кочаклашып караңгыда икәүләшеп үксиләр иде.

Озак газапланганнан соң кыз, хәле китеп, идәнгә егылды һәм: «Су, су!»— дип ыңгырашты.

Чырык нәзек тавыш белән кулларын бутап:

— Торгызың, әмма ләкин су бирмәң! Юкса, шайтаны эченнән чыкмый аның, имеп ята!— дип акырды.— Әйтсен, кеме бар! Сөякне кайда күмгәнен тапсын?!

Пәри, имеш, кеше кыяфәтенә кереп йөри, аның җаны яшерелгән сөяктә, имеш...

Су сорап өзгәләнгән кызны тагын биергә дип өстерәп алып киттеләр, ул, мескен, аяклары тотмыйча егыла, аны сөйрәп торгызалар да тагын биергә боералар.

Шәмсеруй ишекне тартып карый, бикле ишек, биге нык, Эссәтне үтереп ташлаганнан соң Шәмсеруй үзе тимерчедән эшләтеп алган нык, авыр бикләр...

Таң атты... Көмешкә эчелеп бетте, бию, сарнау тукталмады.

— Кызың терелсен дисәң, тавык-кошыңны җәлләмә, пешер. Эчмәгәч кешеләр хәлсезләнде, пәри белән сугышыр чамалары юк, алып кил аракыңны! — дип шаулады булышчылар.

Шәмсеруй апага бер нәрсә җәл түгел, бер нәрсә, кызы гына терелә күрсен. Ул яшьле күзләрен тутырып Чырыкка карый:

— Абдрахман әкә, атам бул, хак-дөресне әйт, өмет бармы?— дип инәлә.

[1] Сарнаучылар — биегәндә җырлап, такмак әйтеп торучылар.

Чырыкның күзе тонган, күз кабаклары шешенеп беткән, ул кулын гына селкеде.

— Тырышып карыйк!

Бу куркыныч күпме дәвам итәр иде, ул арада бик нык итеп капка кактылар. Тагын, тагын...

Урам яктан:

— Ачыгыз, явызлар! Ачыгыз!— дигән тавыш яңгырады.

Бу Шамил Уразаев тавышы иде.

Чырыкның сакалы дер-дер килә башлады, ул шыпырт кына:

— Ындыр капкасы ачык, берәм-берәм шуннан таегыз!— дип боерды. Булышчылар кечерәеп, юкарып калган ике ананы — Шәмсеруй белән Өннәне баса-таптый лыпыр-лыпыр бакча ягына карап чаптылар, ачык ишектән сасы ис бөркелде һәм Сәрвәрнең:

— Әни, су!— дип инәлгәне ишетелде.

Өннә апа капка ачарга йөгерде, Шәмсеруй бар житезлегенә эчке бүлмәгә ташланды...

## 40

Түбәннән Тоболга килүче «Шлеев» пароходы шәһәргә якынлашканда пассажирлар барысы да палубага чыгып бөялделәр. Шамил палубага әллә кайчан чыгып баскан иде, хәзер аны төрле яктан китереп кыстылар. Пароход, тәгәрмәч калакларын тигез шапылдата-шапылдата, башта Тобол елгасының саргылт кара төсле суын бутады, аннары көмештәй ялтырап яткан Иртеш өстенә килеп чыкты.

— Карале, ходайның кодрәте, бу ике елганың суы бергә килеп кушылгач та җөй булып аерылып яталар икән бит!— Казанлыларча өстенә камзул, башына каләпүш кигән жыйнак гәүдәле бер бабай, янәшә китереп салган ак һәм кара җәймәгә охшап икегә ярылып яткан су өстенә исе китеп карап тора иде. Әнә шул атаклы Иртеш һәм Тобол елгалары кушылган урыннан ерак та түгел Тобол шәһәре урнашкан. Шәһәр-авыллар хакында, гадәттә: «Шунда-шунда, шул географик киңлектә җәелеп ята»,— дип сөйлиләр, әмма Тобол шәһәренә бу сүз килешеп бетми, аның хакында: «Ике елга кушылган урында Тобол шәһәре күккә ашкан!»— дип әйтәсе килә.

Моны палубага чыгып бөялгән олылар гына түгел, бала-чага да сизә икән, казанлы бабайның камзул итәге астыннан берсе кай арада алга чыккан да, кай арада бәялэп тә өлгергән, чәрелдек тавышы һаваны ярды:

— Йә, торага җитеп тә куйганбыз бит, караңчы шуның ыспайлыгын!

Аның күзе тау башына урнашкан кремльнең матурлыгына төшкән иде. Икенче бер тиктормас малай Шамилнең аркасын төя башлады, аның да «ыспай тора»ны күрәсе килә иде, ахрысы. Шамил янтая төшеп малайны алга уздырды, малай без кебек үткен чем-кара күзләрен кыса-кыса кычкырып та җибәрде:

— Чын, әй, манасырларын[1] карап бак, вәт биек икән!

Үзенең биек һәм очлы чиркәве белән кремль һәркемнең күзенә беренче булып ташлана. Каланың иң матур һәм хатирәле урыны булып Шамил күңеленә сеңгән шушы текә тауга беркеп калкынган өч катлы педтехникум бинасы, тауга менә торган йөз туксан дүрт араталы биек баскыч моннан ап-ачык күренеп тора икән.

Пароход пристаньга борынын төртүгә, ыгы-зыгы тагын да көчәя төште, алай да Шамил халык арасына кереп кысылган этисен күреп калды. Күзе белән уннан сулга сөзеп, ул тагын бер кешене эзләде, ләкин ул күренмәде, юк иде, ахрысы...

[1] Манасыр — чиркәү.

Житез матрослар, бераз кыланып, артистланып чаба-йөгерә пароходны юан арканнар белән дебаркадерга китереп бәйләделәр. Һәм кила-килә зарыккан халык, бөрелгән капчык авызыннан агып чыккан борчактай, трап аша сибелә башлады. Этелә-төртелә торгач, Шамил да сагынып кайткан туган туфрагына аяк басты. Ялан авылына әле шактый барасы булса да, Тобол пристане — авылның капкасы. Капканы чыгасың да туган якның һавасын киерелеп сулыйсың. Монда инде син ятим түгел, монда син үз өеңдә, монда синең газиз җан — атаң көтеп тора... Ул тагын сулдан уңга күз йөртеп чәчәкле яулыкны эзләде, яулыклар күп иде, яулык ияләре дә Шамилнең буй-сынына күз төшереп, бер-берсенә төрткәләшеп алдылар, тик ул көткән күзләр, ул эзләгән яулык кына юк иде.

Шатлыктан егетнең күңеле тулып китте. Аяклары аны тыгыз агым уңаена алып бардылар. Халык төркеме чүт кенә сирәгәйгәч, ул үзенә таба тартылып килүче этисен күрде, ул да аңа таба омтылды. Сагынылган икән, кочаклашып күрештеләр. Икесенең дә күзләре дымланып калды, атага сөенеч: мең газаплар күреп үстергән улы кеше булды, югары белем алып кайтты; Шамилгә куаныч — чәчләренә куе чал йөгерсә дә, этисе әле исән-сау, егәрле, иңбашлары егетләрчә биек тора. Алар бер мизгел ирләрчә тын калдылар. Шамилнең күзе кемнедер эзләвен сизенеп ата:

— Сине авылда көтәләр, бик көтәләр,— дип, тынычландырды.— Мәүлия ничек анда?

— Укыйлар! Йосыф белән икесе бер мәктәптә практикада. Бик күп итеп сәлам әйттеләр, икесе дә озата төштеләр.

Мөхәммәт Уразаев сизелер-сизелмәс кенә елмайды һәм үрелеп Шамилнең чемоданын алды.

— Үзем, эти, үзем... Авыр ул, анда китаплар,— диде Шамил, чемоданны бирмичә.

— Син кунак, улым, сәфәрдән кайтучы. Йола буенча, аз булса да йөгеңне мин күтәрергә тиеш.

— Эти, өйдәгеләр ничек яши? Сания әни? Фаягөл, әби?

— Рәхмәт, улым. Һәммәсе дә исән-саулар. Хәзер шулай итик, син Хафиз әкәң белән кайта тор. Минем эшләрем бетмәде. Керәсе жирләр байтак. Килгән-килгән, барын карап чыгыйм инде. Аннан бик еш килеп булмас, печән өсте. Мәктәпнең хәзер ике аты бар, аларга да кышлык әзерләргә кирәк. Әбиең һаман сыер асрый, аны да печәнле итү безнең өстә.

— Мин кайттым ич, эти!— диде Шамил күтәренке күңел белән.

— Синең көчкә ышанам да мин!— дип Мөхәммәт көлемсерәде.— Чират сездә. Дөньяның дүрт ягының тоткасы да сезнең кулда, яшьләрдә булырга тиеш. Мин монда калганга рәнжемисеңдер лә?

— Юк, юк, эти,— дип тынычландырды аны улы.— Синең һәр эшеңне жиренә җиткереп башкарырга яратканыңны беләм. Тыныч бул.

Мөхәммәт Уразаев, Хафиз әкәне эзләп табып, улын аның атына утыртып кайтарып җибәрде. Кайтсын тизрәк, Сәрвәрен күрсен... Өйдә дә көтәләр, әбисе дә килгәндер, Фаягөл инде ничә көн рәттән: «Шамил абыем кайта, мине карагат җыярга алып бара!»— дип такылдаган йөри... Үзенең Данилов янына да кагыласы бар, нигәдер «кереп чык!» дип хәбәр иткән. РОНОда да йомышлары байтак...

Авыл күренгәч, Шамилнең йөрәге гадәттәге тибешен тизләтте. Бүген үк Сәрвәр белән очрашасы иде. Хаты кыска һәм үтә мәгънәле иде бит аның! Шамил хатны яттан белә:

«Шамилем! Сине ил көтә, авыл көтә, Иртеш көтә! Барысыннан да узып сине мин көтәм, бердәнберем! Мин көтәм!»

Бүген үк аның белән аулакта очрашасы иде...

Менә ул сагындырган Иртеш буйлары... Горур Кызлар Убасы... Ничә тапкыр бергә атлап үткән таныш сукмаклар. Ялан авылы кырла-

рында алар аяк басмаган берәр почмак бармы икән? Сәрвәр кайда китә икән аны? Нигә торага килмәгән ул? Татлы уйларга чумган Шамил, юлның тау итәгенә килеп терәлгән җирендә, бик билгеле урында (алар Сәрвәр белән гел шушы каен тирәсендә очрашалар иде!) кушкаенның юкка чыгуын күреп аптырап китте. Каен төбе янындагы шомырт агачы да кәкрәеп җиргә бөгелгән. Анысы кем эше?

Кушкаен өчен кайгырып кайтып, авылга килеп керү сөенече ул көткәнгә караганда кимрәк булды. Менә таныш өйләр, таныш тыкрыклар, ындыр-бакчалар. Тиздән аларның өйләре... Мөгаен, капка төбенә чыгып ук көтәдер. Шамил сикереп төште дә арба үрәчәсенә ябышып акрын гына бара башлады, аның теләген сизгән кебек, ат та адымнарын акрынайтты.

Сәрвәрләр өе тирәсендә шомлы гармун тавышы һәм ниндидер гаугалы авазлар ишетелеп-ишетелеп китте. Бу ни бу?

Юлчыларга каршы томшыкларын киңәйтеп чабып килгән бала-чагa сүзеннән юньле бер нәрсә дә аңлашылмады.

— Әй, ирмәк!

— Сәрвәр апа шимшеп[1] киткән, аны уйнаталар!

— Рәтләп кенә, берәм-берәм сөйләгез.— Шамилнең тавышы калтыранды.— Кемгә, нәрсә булган? Ул нинди яман тавышлар?

— Әйтеп торабыз гуй, Сәрвәр апа шайтанга сугылып шимшеп киткән, аны уйнаталар!— дип такылдашты керле борынлы малайлар.

Алай да берни аңламады Шамил. «Ничек? Сәрвәр? Ничек уйнаталар?», ул йокысыннан айнып килгән Хафиз әкәгә аптырап карады. Бер дә андый хәлне ишеткәне юк иде ич Шамилнең.

— Нинди уйнату ул, Хафиз әкә? Бу нинди гөнаһ шомлыгы?

Әллә һаман зиһене ачылмаган, Хафиз әкәнең бер дә исе китмәде, ул сүс чыбыркысын йорт ягына селкеп:

— Ишетмисеңме әллә, әйтеп торалар бит, уйнаталар икән, җене чыксын өчен биетәләр, дигән сүз буладыр.

— Миңа нишләргә соң? Миңа?— Шамилнең аскы ирене калтырады, сүзе бугазына килеп утырды.

— Син нәрсә балавыздай эреп төштең?— диде тәмам айнып житкән Хафиз әкә.— Егетме син, әллә мәми авызмы? Әйдә, йөгер шул җиргә! Анда җиткәч тикшерерсең ни булганын. Йөгер диләр сиңа, марш моннан! Чап!

Шамил барып җитеп бикле капканы ике куллап төя башлады.

— Ачыгыз!

Эчтә тавышлар кинәт тынды, беравыкка бөтен дөнья тып-тын калып торды, аннан йогышсыз ыгы-зыгы, чыш-пышлар башланды, кемнәрнеңдер абына-сөртенә чапканы, сикергәне ишетелә иде... Менә ул авазлар да сеңде, югалды, ул капкага аяк үкчәсе белән тибә башлады.

— Ачыгыз! Ач!

Менә ишегалдында җиңел аяк тавышлары яңгырады, кела күтәрелде һәм Шамил атылып ишегалдына барып керде, кырлап йөргән ваемсыз тавыклар терекөмеш тамчылары сыман төрле якка сибелделәр. Болдырдан менгәндә аның борынына тәмсез, әшәке ис килеп бәрелде, шунда ук укшыта башлады, ап-ак агарынган Шәмсеруй апа күзгә чалынып калды, Шамил эчке бүлмәгә керде һәм сәкедә яткан Сәрвәрне күреп шып туктады: үлеме, тереме? Дөнья караңгы, дөнья шакшы, дөнья сасы иде, ул кулга беренче эләккән урындык белән тәрәзәгә тондырды, тәрәзә пыяласы зыңгылдады һәм тәрәзә капкачы шакылдап ачылып китте.

*Ахыры киләсе санда.*

---

[1] Шим — җүләр.

# ПОЭЗИЯ

## Эдуард Мостафин

# ЧУЛМАН ТӨБӘГЕ

ЭТЮДЛАР

1

Туган якка кайтам «Метеор»да,
Бик ачулы чагы Чулманның.
Ач акула булып өскә ыргый,—
Көтә генә суга чумганың.
Дулкыннары сөзгәк үгезләрдәй,
Нинди көч бар, нинди ихтыяр!
Давыл мәйданында матадордай
Тота белә үзен «Метеор».
Ә ярларның күренгәне дә юк,
Диңгезләрдә йөзәм диярсең.
Елга куба, төптән актарыла,
Куәтенә башың иярсең.
Күпме дулагандыр, улагандыр,—
Тынып калгач, елга өстенә
Кояш чыкты, үзе белән бергә
Ике яктан ярлар өстерәп.
Мираж сыман калкып чыкты ярлар,
Ай-һай, җәелгәнсең, Чулманым!
Элеккечә нигә күренми соң
Балыкларның уйнап чумганы?
Кая сазан, чөгә, чуртаннарың,
Алабугаларың, җәенең?
Шуларны да безгә күрсәтмәгәч,
Ник бу кадәр чиксез җәелдең?
Ярдан хәзер, безнең чама белән,
Төлке алып була төз атып...
Җырлардагы чулпылы кызмыни,
Ак каеннар кала озатып.
Матурлыгын җуеп бетермәгән
Табигатьнең исән почмагы,
Синең алда ачылырга әзер
Серләр тулы юмарт кочагы.
Телгә килер кебек өнсез ярлар —
Су юмаган эзләр калган бит.
«Яшәргәме, үләргәме» диеп,
Шобагасын ирләр салган бит.
Ничә еллар изге учак янган
Туң төшмәсен өчен тамырга.
Шул учакны саклап яшәгәндә,
Башлар очкан, сынган кабырга...
Утта янып, суда батып та, без
Исән калдык бергә ил белән.
Инде, заман, җирдә урынны да
Буебызга карап билгелә.
...Су өстеннән агач йөзеп килә,
Тамырлары белән йолыккан!
Күкрәп үскән чакта, нинди давыл,
Нинди бәлаләргә юлыккан?
Диңгезләргә кадәр агып чыкса,
Нишләр икән ерак суларда?
Әйе,
Тамырларың белән аерылгач,
Кайда да чит һава — суларга.

2

Бүгеннән үк, Чулман, икеләнми
Зур бәйгегә чыга аласың.
Минем өчен, ләкин, халкымның син
Бер бишеге булып каласың.
Суга якын җирне сайлаганнар
Борынгыдан — ерак бабайлар.
Тирә-якта гөрләп утырганнар
Бай базарлы авыл, калалар.
Халык иген иккән, балык тоткан,
Мал караган, тире иләгән,
Яуга чыккан илен-җирен саклап,
Үлсә үлгән, башын имәгән.
Кунак булса, кунак итә белгән,
Дошман килсә, каршы алалган.
Кунагыннан дошман күбрәк булгач,
Ничә тапкыр нигез таланган...
Дулкыннарның ялы агарган.
Шул чаклардан бирле ак дулкыннар
Нидер әйтеп, бәрә ярларга.
Тарихыңның өзелгән бер кылын

Дулкын белән булса ялгарга...
Ялгарга!
Бу төбәкләр төптән хәтерлиләр,
Күпне сөйләр иде ярлары.
Елга өстен күп кат боз каплаган,
Азмы кышның яуган карлары...
«Усал кышлар безне ирексезләп,
Бикләп тотты үз төрмәсендә.
Куәт җыеп яттык боз астында,
Аккан сулар өермәсендә.
Язгы дулкын булып бәреп чыктык

Еллар япкан бозны эретеп.
Нева дулкыннары дәште безне
Давылдашы күреп, иш итеп...»

Укый алсаң, һәр дулкыны — нота,
Бөек көйләр монда тугандыр.
Давыл кочагында туган җәүһәр,
Кешелекне җырга куандыр.
Дулкын тавышында дастаннарны,
«Туган тел»ләр моңын ишетәм.
«Метеор»да бүген мин үземне
Бишектәге кебек хис итәм.

3

Булган заман: көчләп күчергәннәр
Сулы ярдан безне бик эчкә.
Яр буйларын хәзер шәһәр даулый,
Иске чиркәү тора чак, көчкә:
Кысып килә шәһәр элеккеге
Бер терәген империянең.
Краннары белән яңы кала,
Кисәткәндәй: монда ия мин...
Әллә кемнәр, әллә ниләр өчен
Әрнеп куйды йөрәк ачынып.
Сөйләшәсе килә, Чулман-төбәк,
Бар күңелем белән ачылып.
Ракеталар очкан бер вакытны,
«Метеор»да йөзгән бу чорда.
Без тиешбез елга йотып яткан
Атлантидаларны ачарга.

Бер ярыңда, Чулман, йортлар үсә,

Каршы якта печән чабалар —
Әти-әни... Уллар-кызлар төзи,
Ясле тулы бала-чагалар.
Шундый-шундый хәлләр бу заманда,
Яшьрәкләр каера калага.
Су буенда икән — су буена,
Чүл-далада булса — далага.
Ата-бабаларның йортын ташлап,
Тугыз катлысына күчәбез.
«Кара урман»нардан ГЭСларгача
Краннарга ябышып үсәбез.

Безнең көчне күреп елга тына...
«Кара урман» көе колакта:
«Кара ла гына урман, караңгы төн...»
Шәһәрләргә китеп олакма,
Авылларга юлың югалтма,
Югалтма!

4

Кайчандыр бит монда бурлак халкы
Аркан белән тарткан баржалар.
Бүген әнә, «Метеор»да йөзә
Татар агай һәм рус апалар.
Шәһәр күреп авылына кайта,
Я каладан бара калага.
Кардәш-ыру илдә киң таралган,
Бер милләттә төрле кан ага.
Чулманга да төрле елга суы,
Күлләр суы кушылган хәзер.
Ә исемен үзгәртмичә инде
Кама булып калырга әзер.
Өреләнеп кара суы ага,
Чумып чыксаң, кара киярсең.
Төпкә учак ягып мазут-майдан,
Шулпа пешергәннәр диярсең.
Таныш кебек иде һәр дулкыны,
Яр буенда үскән һәр камыш.
Бүген менә сәер каршы алды

Элек гөрләп торган тукталыш.
Холкың белән үзгәргәнсең, елга,
Үзгәрткәнсең бөтен тарафны.
Су кызы инде өмет итмидер
Табылыр дип алтын тарагы.
Билдән суга батып, таулары да
Кечерәеп калган түгелме?
Күпне табып, күпне югалткансың,
Чулман,
Җуя күрмә, берүк, күгеңне!

Таудан биек плотинасы белән
ГЭСлар тарый чәчен Чулманның.
Күрәсеңме, әнә, тарады да
Ничә толым итеп чолгады.
Әкияттәге алтын тарактан бит
ГЭС-таракка кадәр ни ара!
Чулман биргән утлар яктысында
Ил буенча күпме туй бара.

## 5

Ә «Метеор» ыргый — күптәнме соң
Шаулап торган урман өстенә.
Анда хәзер давыл, өермәләп,
Кочагында дулкын үстерә.
Әнә, унда басу булган кебек,
Таудай калкып торган урында,
Бер комбайн калган су эчендә,
Чыккандыр да иген урырга...
Ул комбайн ялгыз Робинзондай
Посып ята су уртасында,—
Бу утрау... юк, күрсәтелмәгән ул
Кайсы якның картасында да...

Көтмәгәндә килде микән бәла
Ашлык җыеп яткан көннәрдә?
Нишләр идең өскә су ыргылса,
Баш терәгән чакта мендәргә.
Нишләр идең?..

Минем белән агай кайта иде,
Күреп торам, авыл ягыннан.
Сөйләп китте:
— Су китергән бәла
Артып ашты янгыннныкыннан.
— Янгын чыгып янса, бер йорт яна,
Ну, ике-өч, күп дигәндә авыл...
Судан, туган, судан берни калмый
Хет ела син, кычкыр каравыл!
Ни әйтсәң дә аяныч хәл, апай,
Гомер узды шушы якларда.
Шушы төбәктән мин. Монда үстем,
Моннан киттем илне сакларга.
Кирза итек... Европаны үттек.
Торгызыштым хәтта йортларын,
Плащ-палаткамны ташка җәеп,
Берлин урамында йокладым.
Монда кайтып, сыңар кулым белән
Йорт торгыздым гомерлеккә дип.
Нәсел-ыру яткан зираты да
Су астында калды. Әрним бик.
ГЭСлар кирәк, сүз дә әйтәсе юк,
Бу заманда ансыз буламы?—
Әнә нинди хикмәт төзеделәр,
Хөкүмәтнең дөрес планы.
Тик кайчакта, үзебез бит, якташ,
Күреп бетермибез барын да.
Уйлап эшләгәндә, элеккечә
Атлар йөрер иде болында...
Атлар әле дә минем күңелемдә,
Каннарымда кайный, ыргыла.
Ат өстеннән очып төшмәгәч бер,
Нәрсә күреп үсә ир бала?
Су басканчы монда болын иде,
Сабантуйлар шунда гөрләде.
Атта чабып сөлге алдым мин дә,
Ул сөлгедә чиккән гөлләре...

Тегермәне озак тартты моның,
Чынлап яратадыр атларны.
Ә бер сүзе белән көтмәгәндә
Башка сукты, җанны актарды.
— Да,
Заманында бер күл ята иде,
Йөзек кашы булып бу якта.
Чулман йотты аны, изге Чулман!
Көн-төн сызлыйм, туган, шул хакта.
Ул күл белән балачагым үлде,
Яшьлек китте, үткән инде ул.
Ә бу килеш эзләре дә бетте.
Их!
Беренче кат үпкән иде ул!
Күл буенда үзе үпте бит, әй,
Кыю нәмә диеп уйларсың.
Күзгә карарга да базмый иде,
Кәнишне, үзгәрде туйдан соң.
Җәл, оныклар күрәлмичә калды
Безнең күлне, иске нигезне.
Әйдә инде, күреп кинәнсеннәр
Кама дигән яңа диңгезне.

Канатларын сынап ага елга,
Каурыйларга ком-таш өелә.
Канат белән дулкын алышканда,
Урталыкта була өермә...
Гомер буе кешеләргә биреп
Бар байлыгын, куәтен, көчен,
Ага елга күп суларны кушып,
Илдә утлар янсыннар өчен.

## 6

...Ат тартканны гына тартамы ул?
Меңләп атың торсын бер читтә.
Күпме танкер, теплоходлар йөзә
Чулман дигән җанлы читлектә.
Буксир тарткан салы бер авыллык,
Йөзләп йортлык агач кимендә.
Кеше, егып, саллап җибәргән ич,
Ак син, Елга, ак син, кимемә.
Кемдер Кама, кемдер Чулман дия.
Минем өчен Чулман инде син.
Чорлар кичеп, ата-бабаларның
Җырларында яши шул исем.

Син бик якын, бик кадерле миңа,
Сиңа гына түгел бу үпкәм.
Мин югалттым авылымны, күлне.
Мин югалттым бүген бик күпне.
Беләсеңме, аңлыйсыңмы шуны.
Мин югалттым бар булганымны.
Мин югалттым ыру-нәселемне,
Мин югалттым җәй-йорганымны.
Мин югалттым очын йомгагымның,
Югалттым үз Атлантидамны.
Алар бар чагында җаным белән,
Рухым белән атлант идем мин.

...Чулман шавы аша әллә кайдан
Таныш тавыш килде колакка.—
Әйтерсең лә күлем пышылдый күк:
«Мин коллыкта, мәңге коллыкта.
Чулман белән без чордашлар идек,
Мин гади күл, ә ул зур елга.
Язлар килгәч, кушылып без бергә
Яшәп ала идек һәр елда.
Аны дөнья белә, мине — авыл.
Карталарда аның исеме.
Ял итәргә күбрәк миңа килде
Бар да — яше, карты дисеңме.
Моң, тынлыгым җәлеп итте микән,
Тартты микән гүзәл урманым.
Мин үзем дә бик ярата идем
Кешеләрнең килеп торганын.
Комсызга да җитә иде булган
Ул балыгым, җәнлек, кошларым.
Күпме кешеләрне күн бүрекле,
Тунлы итә идем кышларын.
Мин саклаган күпме җан иясе
«Кызыл китап»ларга кертелде.
Минем исем хәтта анда да юк.
Нинди ләгънәт өскә бөркелде?!
Минем суда йөк-йөк кер чайкалды,
Ничә буын миндә коенды.
Суларыма сансыз гасыр көзге
Сары яфрак булып коелды.
Сабантуйлар минем янда узды.
Каз өмәсе миннән башланды.
Вакыт, килеп, мине мәңгелеккә
Күршем кочагына ташлады.
Кешеләргә файда китерерлек
Кирәк икән корбан булуым.
Кама булып, әйдә, агыйк инде,
Дөрес якка барсын бу юлым».

...Елга өстен үле тынлык басты,
Туктап калды кебек «Метеор».
Кайсы дулкын сөйләп китте миңа?
Нәрсә әйтә алсын ерак яр...
Чулман-Кама, синең зурлыгыңны
Күз күләме житми карарга.
Берсен-берсе күрми үз ярларың,
Зур бер дәүләт сыяр арага.
Ярларыңда яткан болыннарда
Чәчәк исе, җиләк иседер.
Шул яклардан безнең палубага
Ник хуш исле җилең иссен бер.
Канат булып җилләр бәрә йөзгә,
Су чәчри, синең суыңмы?
Әллә әлеге күл мыштым гына
Үзе булып синдә сулыйммы?
Юк, түгелдер,— иреннәрдә калган
Тамчылардан башка тәм килә...
Тик бер мәлгә Чулман тәпләреннән
Ишетелгәндәй булды «Тәфтиләү».





*Совет Армиясенең*
*70 еллыгына*

**Якуб Чанышев**

# БЕЗНЕ ЯШЬЛЕК ҮЗЕ ЧАКЫРДЫ

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ*

Казан укытучылар мәктәбен тәмамлап, туган якларымда бер ел да эшләргә өлгермәдем, армиягә алдылар. Тагын бер елдан беренче Бөтендөнья сугышы башланды. Шушы афәт кеше язмышларын ике тегермән ташы арасында калган бөртекләр шикелле изәргә, имгәтергә кереште. Сугыш машинасыннан вак тәгәрмәчләр, үз эшен үтәгән һәм ватылган шөрепләр чәчрәп чыга, бөтен дөнья хәрби балаганы хуҗалары алар урынына ашыгыч рәвештә яңаларын куялар. Патша армиясе рядовое сыйфатында мин дә әнә шундый бер «шөрепкә» әйләнгән идем.

1916 ел ахырында, барлык фронтларда канкойгыч каты сугышлар барган чорда, Россиядә революция турында хәбәр итүче большевистик очкыннар кабынган көннәрдә, мин Өченче Варшава дивизиясенең лейб-гвардия артиллерия бригадасына буйсынган алтынчы батареяда кече фейерверкер, хәзерге төшенчәләр белән әйткәндә, сержант дәрәҗәсендә идем. Туп залплары — түземлеккә, окоп тормышы чыдамлыкка, ныклыкка өйрәтә, ә листовкалар исә революцион рухыбызны үстерә.

Беренче листовканы ятагымнан табып алдым. Артык гаҗәпләнмәдем. Яңа килгән солдатлар арасында Путилов заводы эшчеләре бар икәнен ишетеп өлгергән идем инде. Ә алар, солдатлар сөйләвенә караганда, барысы да «патшага каршы» имеш. Дөрес, пролетариатның көрәш мәктәбен үткән бу кешеләр, ачыктан-ачык сөйләнеп, теләсә кемнең йөрәгенә үтеп керергә ашыкмыйлар, карыйлар, кемнең кем икәнен өйрәнәләр.

Барысы да яшерен агитациядән башланды.

«Солдатлар, сез кем өчен, кем җире өчен сугышасыз?» Листовкадагы шушы сүзләр йөрәгемне яндырып үтте. Алар турыдан-туры миңа, Якуб Чанышевка да кагыла түгелме соң?! Чыннан да, үлемне санга сукмыйча, көчемне, батырлыгымны җигеп, кем өчен сугышам соң мин? Куркусызлыгым, кыюлыгым кемгә кирәк? Атакада күрсәткән гайрәтем өчен, әнә, саф алдына чыгарып, күкрәгемә Георгий тәресе тактылар. Анысы миңа ни бирә?

Листовка бик күп сораулар уятты. «Солдатлар, сез кем өчен сугышасыз?» Шушы гади генә сүзләр җанымның астын өскә китерде, кылган эшләремә генә түгел, бөтен сугышка икенче күзлектән карарга этәргеч булдылар. Алай карасаң да, болай карасаң да, бер нәрсә килеп чыга: үзем өчен, эшчеләр һәм крестьяннар өчен түгел, ә патша һәм аның иярченнәре — фабрикантлар, алпавытлар өчен сугышам икән ләбаса. Менә шул чакларда путиловчылардан берсе — гади эшче, әмма тәҗрибәле һәм ышанган большевик белән таныштым.

Бик тиз генә танышып, ачылып, иптәшләргә әверелмәдек. Ләкин бер-беребезне якыннанрак белгән саен, дуслыгыбыз арта, әңгәмәләребез эчкерсезрәк була барды. Сугышлар тынып торган арада ул большевиклар партиясе — патшаны бәреп төшереп, җирне крестьяннарга, завод-фабрикаларны эшчеләргә бирергә, бу каһәрле кан коешны туктатырга һәм җирдә гомумән сугышларны булдырмаска теләүче кешеләр барлыгы турында сөйли. Ә большевиклар партиясен — эшче-

*Журнал варианты. Әдәби эшкәртүче Валерий Анисимов.

лэр, солдатлар һәм интеллигенциянең иң алдынгы вәкилләрен Владимир Ильич Ленин җитәкли.

Әнә шулай мин беренче тапкыр бөек юлбашчы исемен ишеттем, дөньяны күзаллавымны тамырыннан үзгәрткән идеяләр белән таныштым. Алдагы вакыйгалар язмышымны өермәдәй бөтерепүз эчләренә алып кереп киттеләр. Путиловчының әңгәмәләре шулкадәр гади һәм аңлаешлы, большевиклар куйган максат һәм бурычлар шулкадәр ачык һәм төгәл, бер дә икеләнми «урыным алар арасында» дигән фикергә килдем. Бу партия сафына басу өчен бөтенесен дә эшләячәкмен! Теләгем шулкадәр көчле булган, күрәсең, берничә айдан мин большевик идем инде. Ләкин моңа кадәр әле фейерверкер сыйфатында бәрелешләрдә катнашырга, разведчиклар подразделениесенә күчәргә, дошман территориясенә үтеп, «тел» алып кайтырга да туры килде. Сугыш дәвам итә. Мин — ут сызыгындагы солдат.

Фронт аша үтеп, «тел» алып кайтырга чыгып киттек. Яңгыр ява, дымлы салкын сөякләргә кадәр үтә, көчле җил күз ачарга да ирек бирми. Ә без шуышабыз... Әкрен генә дошман ягына үрмәлибез.

Түмгәкләрне, чокыр-чакырларны әйләнеп уза-уза, дошман күзеннән яшеренеп, үзеңнең күләгәңә сыенып, ермачланган җир өстеннән шуышканда, күп нәрсә турында уйларга, бөтен тормышыңны искә төшерергә өлгерәсең.

Һәм мин дә искә төшердем. Ничек батрак булып йөргәнемне дә, энеләрем һәм сеңлем белән соңгы кисәк икмәкне бүлеп капканымны да, җан-фәрман тырышып, әниемә ярдәм итәргә теләгәнемне дә... Капкорсак алпавытларның тук, бәхетле тормышы, безнең хезмәт белән, безне сыгып, байлык туплаулары да күз алдыма килде. Әтием-әнием дә, мин дә аларга бил бөктек, тәүлегенә унике-шәр-уналтышар сәгать эшләсәк тә, туйганчы ашый алмадык. Ә алар безне ничек теләсәләр шулай мәсхәрәләделәр, җәберләделәр. Күптәннән, бик күптәннән шулай килгән...

Ләкин алай булырга тиеш түгел! Төн пәрдәсенә капланып, коеп яуган яңгыр астында пычрак җир өстеннән үрмәләгәндә, шуларны да уйладым. Путиловчы хаклы — патшага, алпавытларга каршы көрәшкә күтәрелергә, большевиклар белән бер сафка басарга кирәк!

...Ул чакта «тел»не алып кайттык без. Яхшы «тел» — штаб писаре. Яшерен-батырын түгел, бу юлы да батырлык күрсәттем. Табигать миңа көчле, таза гәүдә биргән, сугыш кыюлыкка, җитезлеккә, елгырлыкка өйрәтте; немецны бөтереп сыртыма салдым да дошман окопларыннан читкә ыргылдым. Ә аннан соң аны үзебезнең якка алып кайттык.

Бер көннән безне начальство чакырып алды. Рәхмәт белдерделәр. «Тел» кирәкле мөһим мәгълүматлар биргән булып чыкты. Башлыклар бик канәгать калган. Дошман тылына үтеп кергән һәр кешенең батырлыгын билгеләп үттеләр. Мине дә аерып күрсәттеләр. Түбән чиннар белән сөйләшкәннән соң штаб начальнигы миңа калып торырга боерды.

Боерыкны үтәү мәҗбүри. Торам, көтәм. Нинди сүз булу турында башыма да китерә алмыйм. Ә начальник бернинди кереш сүз-фәлән ясап тормастан, көтмәгәндә сүз кушты:

— Сине укырга җибәрергә булдык, фейерверкер. Канәгатьме?

Дөресен әйтим, югалып калдым.

— Нинди укуга? — дип сорадым.

— Кара син аны, — дип гаҗәпләнде начальник. — Офицерлыкка укырга. Синнән офицер әзерләячәкбез, Чанышев. Патша армиясе офицеры.

— Мин бит, — дип әйтә башлаган идем, начальник сүземне дәвам итәргә ирек бирмәде. Олы җанлы булырга тырышып, мәрхәмәт күрсәткәндәй, аңлатырга кереште:

— Син кыю, батыр кеше. Георгий тәресенә дә лаек булдың. Атабыз патшага шундый офицерлар кирәк. Бар, юлга әзерлән. Иртәгә Казанга, офицерлар курсына китәчәксең.

— Буйсынам, — дип кенә әйтә алдым.

Блиндажга кайтышлый әле генә булган сөйләшү турында җентекләп уйланырга керештем. Димәк, мин, укытучылыкка ирешкән элеккеге батрак, профессиональ хәрби белгеч булачакмын. Мин — патша армиясе офицеры! Моннан бер тәүлек элек кенә төн караңгылыгына посып «тел» алырга шуышканда, бөтенләй башка нәрсә — царизм белән көрәш турында хыялланган кеше — патша офицеры. Шушы хәлдә хыялларымны ничек тормышка ашыра алачагымны аңламыйча, тирә-яктагы бернәрсәне дә күрмичә кайтып килә идем.

— Якуб, нәрсә булды? Нишләп балтаң суга төшкән кеше кебек киләсең? — дип кычкырган тавышны ишеткәч кенә аңга килгәндәй булдым.

Алдымда басып торган яңа дустымны — путиловчыны күргәч, әчемә җылы йөгерде. Минә кем белән киңәшергә, тынгы бирмәгән уй-борчуларны уртаклашырга була. Ул гына мине дөрес аңлар һәм нәрсә эшләргә кирәклеген киңәш итә алыр.

Дулкынланып, штаб начальнигы янында булган әңгәмәнең эчтәлеген буталчык сүзләр белә сөйләп бирдем. Сөйләп чыктым һәм күзләренә текәлдем. Минә хәзер мөнәсәбәтләребез шартлап өзелер кебек тоела башлады. Шулай булмый, мин бит офицерлык курсларына китәргә ризалык биреп чыккан кеше.

— Яхшы бу,— диде ул берни дә булмагандай.— Киләчәктә безгә тәҗрибәле кадровый офицерлар кирәк булачак.

— Ничек,— дип гасабиланып сорадым мин,— начальствоның миннән офицер ясарга теләве сине бер дә борчымыймыни? Риза булуым да уйга салмыймы? Дөресен әйтим, мин бит каршы килмәдем. Китәргә җыенам.

— Нишләп әле бу мине борчырга янсә уйга салырга тиеш,— дип каршы төште путиловчы.— Минем фикерем ачык: син офицерлыкка укырга тиеш.

— Большевиклар сафында булырга теләвемне кая куясың?

— Берсе икенчесенә комачауламый. Укы!

Бераз тын торгач, ул миңа сынап карап алды, шинель кесәсеннән тәмәке янчыгы һәм кәгазь кисәге чыгарып, ашыкмый гына, үзенә хас осталык белән «кәҗә тоягы» төрде һәм каты итеп суырып, төтен боҗралары чыгаргач, яңадан сүз кушты:

— Мин сиңа ышанам. Сүзләреңә дә, хыялларыңа да. Алардан тайчанмаячагыңны да беләм. Холкың шундый. Үзсүзле кеше син. Шулай икән, хәрби эшкә өйрән, патша армиясендә офицер бул. Вакыты җиткәч, тәҗрибәңне, осталыгыңны уртак эшебез файдасына җигәрсең.

Тагын берничә боҗра чыгарганнан соң, путиловчы сорауга караганда күбрәк раслауга охшаш тон белән, ачык елмаеп сорады:

— Шулай бит, Якуб дустым! Ялгышмыймдыр ич?

Февраль революциясе турында хәбәр килеп ирешкәндә, мин Казан хәрби училищесында нигездә университет студентларыннан тупланган беренче ротада хезмәт итә идем. Арада шәһәр подпольесы белән тыгыз бәйләнгән большевиклар да шактый булып чыкты. Нәкъ менә алар — революцион рухлы студент-юнкерлар безгә Петроградта революция булганлыгын, патшаның тәхеттән ваз кичкәнлеген хәбәр иттеләр.

Бу хәбәрнең нинди тәэсир ясаганын сөйләп тору кирәк микән. Казармада иң куәтле бомба шартласа да, безне ул кадәр үк хәйран калдыра алмас иде!..

Хәйран калу тиз үтте. Казанда күтәрелеп килүче революцион хәрәкәтләргә катнашу теләге туды. Бик күпләр шул теләк белән яна. Командирларыбыз да хәрәкәт итәргә, нәрсәдер эшләргә кирәклеген аңлый. Революция! Бу сүз приказ кебек. Кемгә һәм нәрсә эшләргә — анысын әле вакыт күрсәтми. Әмма шул ук вакытта революцион рухлы кешеләр белән монархия яклылар арасында чик хасил булып, «безнеке»ләргә һәм «безнеке түгел»ләргә бүленү башланды.

«Җыелу» сигналы яңгырады. Күп еллык гадәтләр буенча командирларыбыз эшләп өлгергән беренче һәм бердәнбер эш шул булды. Актлар залына курсантлар һәм укытучылар җыелды. Барысы да училище начальнигы генерал Кедровны көтәләр. Генералның гына түгел, училище һәм курсантларның язмышы да аның нинди карарлар кабул итүенә бәйләнгән.

Менә генерал Кедров килеп керде. Төз гәүдәсе, хәрби ыспайлыгы белән дан тоткан генералны алыштырып куйганнар диярсең: йөзе ак, үзе бөкрәя төшкән. Калтыраган кулларында — депеша. Саф алдына басып ул текстны укырга тырышып карады, әмма булдыра алмады, иреннәре калтырый иде. Шул чакта юнкерлардан берәү, бөтен устав таләпләрен бозып, сафтан йөгереп чыкты һәм генералның кулыннан кәгазьне тартып алды, Россия императоры Николай II нең тәхеттән ваз кичүе турындагы хәбәрне кычкырып укыды. Ура-а! авазлары актлар залын күмеп китте. Кече офицерлар кул чаба башлады, өлкәннәр агарынып катты, һәм шушы мизгелдә үзләренә янаган куркынычны хис иткән кебек алар, тирәякларына карана-карана, бер төркемгә җыелдылар.

Әмма ул чакта Казан хәрби училищесында ачыктан-ачык кораллы бәрелеш булмый калды. Вакыты җитмәгән иде әле. Иң элек кемнең нинди позициядә торганлыгын ачыкларга кирәк иде. Җыелучылар бертавыштан училище начальнигын посттан төшерергә, аның урынына тәҗрибәле фронтовикны сайларга карар бирделәр. Хәл иткән бердәнбер нәрсә шул булды.

Моның өчен үзенә күрә «нигез» ясадылар. Елгыр юнкерлардан берәү сәхнәгә йөгереп менеп, кычкырып сөйли башлады:

— Сугышта җиңү өчен училище офицерлар хәзерләүне дәвам иттерергә тиеш!..

Окоп һәм блиндажларда өч ел аунаган, солдат язмышын үз җилкәсендә татыган кеше буларак, сугышны дәвам иттерү турындагы сүзләр ачуымны шул кадәр кабартты, түзә алмадым, кычкырып җибәрдем:

— Беркем дә сугышырга теләми! Сугыш турында нинди сүз булырга мөмкин? Россиядә — революция! Һәм хәзер хәрби кадрлар хәзерләү түгел, ә тынычлык хакындагы мәсьәләне куярга кирәк!

Минем янда торган курсантлар кычкыра башлады:

— Яшәсен тынычлык!

— Бетсен сугыш!

Шул вакыт сәхнәдә тагын бер оратор күренде. Ул шундый таныш иде, хәтта күзләремә ышанмый тордым. Тыныч, ышандыручан тавыш белән беренче сүзләрен әйтүгә үк аңлап алдым: алдымда окоп тормышы буенча күптәнге иптәшем, путиловчы, ленинчы-большевик тора иде.

— Иптәшләр!

Аның сүзләрен шау-шу күмеп китте. Ул көтелмәгән «атака»ны тыныч кына уткәреп җибәрде һәм дәвам итте:

— Әйе. Иптәшләр! Мин яңа гына фронттан кайтып төштем. Солдатлар һәм кече офицерларның күбесе патшаның тәхеттән ваз кичүен шатланып каршы алды. Аларны аңлау җиңел. Өч йөз ел дәвамында Россияне, халыкны эчке фронтларда да, тышкы фронтларда да канга батырган самодержавие, Романовлар йорты җимерелде. Халык күтәрелде! Әйе, халык... Февраль революциясен дә ул ясады. Бөтен илдә, аерым алганда, безнең училищеда да нәкъ менә халык таләпләре, аның теләкләре һәм өметләре тормышка ашырылырга тиеш. Ә халык үзенең ни теләгәнен күптән әйткән иде инде: тынычлык, җир, икмәк... Җыелышны чын-чыннан революцион итү, сүзне эштән аермау өчен мондый тәкъдим кертәм: шушы позиция белән риза кешеләр казармаларга таралып, солдатлар белән очрашсын, аларга илдәге хәлне аңлатсын. Аннан соң рота һәм полк комитетлары сайлауны оештырырга! Армиядә нәкъ менә алар революцион власть органнары булачак.

Дустымның чыгышы шулкадәр аңлаешлы иде, түзә алмыйча тагын кычкырып җибәрдем:

— Дөрес! Полк комитетлары сайларга!..

Сүзләремне залда бик күпләр яклады. Путиловчы да хуплады аны. Ул мине сәхнәдән үк күреп торган икән, төшү белән яныма килде. Шатланып кул кысыштык.

— Ничек, революциягә белемнәрең кирәк булачакны аңладыңмы инде?— диде ул.

— Әлбәттә аңладым,— дип ризалаштым.— Тик, әйт әле, үзең безнең училищега ничек килеп чыктың?

— Язмыш, ә дөресрәге — сугыш мәҗбүр итте. Хәрәкәттәге частьларда, солдатлар арасында ризасызлык, чуалышлар үсә. Офицерлар җитми. Начальство мине монда озатып, берьюлы ике көймәнең койрыгын тотмакчы булган, күрәсең. Солдатлар арасында агитация дә сүрелер, патша армиясе исә тагын бер яңа «офицер» алыр дип өметләнгәннәр. Тегеләй дә, болай да булмас. Миңа исә шул гына кирәк тә. Хәзер мин ирекләрәк, димәк, партиягә дә күбрәк файда китерә алачакмын.

— Нәрсә эшләргә җыенасың соң?— дип сорадым путиловчыдан.

— Халык арасында, солдатлар арасында булырга кирәк, дустым,— диде ул.— Революцион масса белән эшләргә. Кешеләрне яңа, тагын да зуррак эшләргә әзерләргә. Февраль революциясе әле аның башы гына. Бу турыдан-туры синң да кагыла.

— Ләкин мин партия члены түгел бит.

— Озакламый булырсың,— дип җавап бирде ул.

Тәҗрибале революционерларның сүзләре дөрес булып чыкты. Озакламый мин чыннан да большевиклар партиясе члены булдым.

1917 елның 15 марты иде. Кышкы йокыдан уянып кына килүче табигать бар нәрсәгә җан өргән. Агач бөреләре бүртә башлады. Яз кояшының көннән-көн көләчрәк, яктырак, елмаюыннан карлар эри, өй кыекларыннан тамган тамчылар боз сөңгеләр хасил итеп, дөньяга үзенчәлекле ямь, үзгәреш өстиләр. Мена-менә кырлар кардан арчылыр, бар табигать язгы тантанага чумар. Большевик-лар партиясенә, революцион эшчәнлек юлына мин язын, әнә шундый көннәрдә аяк бастым.

Тыныч күк астында яшәргә, балалар тавышына, өлгергән ашлык исенә, күктән очып үтүче торналар кычкыруына сөенергә мөмкинлек биргән газиз туган җирем һәр елны яңарыш, тормыш язын күрә алсын өчен көчемне дә, канымны да, гомеремне дә кызганмадым.

Март башларында прапорщик чины алдым. Ул чактагы барлык законнар буенча, фронтка, офицерлар сафын тулыландырырга озатылачагымны чамалый идем. Ләкин алай чыкмады. Моңа, беренче чиратта, Казан хәрби округының мөселман комитеты председателе урынбасары итеп сайлануым сәбәп булды.

1917 елның февралендә Казан Россия үзәгендә гаскәр иң күп тупланган урыннарның берсе иде. Округта 98 гарнизон булып, Казанның үзендә генә дә 50 меңгә якын солдат, офицер һәм төрле чиновник исәпләнә.

Округ башында — 1905 елгы революциянең кансыз палачы, рус булмаган миллэт кешеләренең, ул вакытта әйтелгәнчә, «инородецлар»ның явыз дошманы, инфантерия генералы Сандецкий. Ул һәм тирән тылда оя корган, аңа буйсынган башка генераллар миллионнарча солдатларны кан калтыратып торалар, дөнья сугышының барлык фронтларын «пушка ите» белән тәэмин итәләр. Ай саен фронтка 100—200 мең солдат озатыла. Хәрби промышленность комитетына оялаган кадетлар, меньшевиклар, эсерлар белән бергә алар фронтның азык-төлеккә, сугыш припаслары һәм медикаментларга булган ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерәбез дип шапырыналар. Чынлыкта исә моның өчен берниндн чара күрелми. Солдатларның чабата киеп йөрүе дә сирәк күренеш түгел.

Мондый мөнәсәбәткә җавап йөзеннән солдатлар яшерен рәвештә дә, ачыктан-ачык та баш күтәрәләр, саботаж оештыралар. Сугыштан кайткан яралылар, запас полкларга китерелгән революцион рухтагы солдатлар патша һәм сарай даирәсенең хыянәте, фронтлардагы чын хәл турында сөйлиләр, моннан котылу өчен большевиклар күрсәткән юлны пропагандалыйлар.

Эш шуңа барып җитте ки, Петроградтагы гвардия полклары, ә Казанда шәхсән Сандецкий үзе өйрәткән полклар Февраль революциясе көннәрендә эшчеләр сыйныфы ягына чыктылар. 1917 елның 4 мартында Казанның бөтен гарнизоны баш күтәрде. Солдатлар үзләрендә нәфрәт тудырган күпчелек офицерларны кулга алдылар, хәтта Сандецкий да чак кына эләкми калды. Мәкерле һәм хәйләкәр генерал иң соңгы моментта, округны ашыгыч рәвештә штаб начальнигына тапшырып, Петроградка сызды!.. Әмма ерак китә алмады. Солдатлар аны юлда эләктереп алдылар һәм гауптвахтага утырттылар. Табигый ки, мондый хәлдә большевикларга һәм аларга теләктәшлек күрсәтүче офицерларга акыл белән барысын да үлчәп, сак эш итәргә кирәк иде. Шәһәр большевиклары җитәкчеләре шулай эшләде дә, барысы да оешкан төстә барды.

...17 июльдә Бөтенроссия мөселманнарының хәрби съезды чакырылды. Анда катнашу өчен Казанга дәрәҗәле бик күп кунаклар — татар халкы белән бәйләнешен бик күптән югалткан, туган телен онытхан, әмма... милли мәсьәләләрне хәл итәргә, татар халкының язмышын үз кулына алырга дәгъва кылучы генераллар, офицерлар, князьләр җыелды.

Бу съезд һәм шул көннәрдә булган тагын ике съезд иң четерекле мәсьәләләрне: Учредительное собраниегә сайлаулар, культура милли автономиясе һәм мөселманнар берлеге мәсьәләләрен тикшерделәр. Нәтиҗәдә, эчке Россия мөселманнары эшләре буенча өч зур Бөтенроссия оешмасы: Милли шура, Хәрби шура һәм Мөселманнарның дини идарәсе төзелде.

Хәрби шураның беренче адымнары аның, чын мәгънәсендә революцион позициягә басмаса да, һич югында солдатлар мәнфәгатен яклау буенча эшләвенә өмет уяткан иде. Баштарак шундый адымнар ясалды да. Хәрби шура җитәкчеләре Казан гарнизоны солдатлары һәм офицерлары киңәшмәсендә Мөселман хәрби комитеты төзеделәр, аның председателе итеп Ильяс Алкин, ә округ комитеты җитәкчесе итеп поручик Әбелханов сайланды. Комитет председателе урынбасарлыгына мине күрсәттеләр.

Шурачыларның агитаторлары һәм пропагандистлары солдатлар арасында киң политик-агарту эшләре башлап җибәрде: китапханәләр, уку заллары ачылды, алар газета-журналлар белән тәэмин ителде. Роталар театрга, киногя йөри. Ял һәм көнкүреш шартлары, милли колорит турында кайгырттылар. Роталар яхшы тәэмин ителгән, киендерелгән, өр-яңа винтовкалар һәм пулеметлар белән коралланган. Солдатларга милли ашлар бирелә. Оештыру ягыннан да бу хәрби подразделениеләр башкаларыннан нык аерыла. Алар маршевый рота түгел. Шулай булгач, фронтка җибәрелергә әзерләнми. Бу исә үз чиратында гади солдатларның күңеленә хуш килә.

Ниһаять, шурачылар башка округлардан мәҗбүри рәвештә диярлек Казанга

шактый санда офицерлар һәм солдатлар чакырткач, 94 нче, 95 нче, 164 нче һәм 240 нчы полкларда татар роталары төзелде. Моны, әлбәттә, большевиклар да, округ командованиесе дә күрми кала алмады. Хәрби округ командующие полковник Коровиченко, офицерлар җитәрлек булмауны сылтау итеп, татар частьлары оештыруга каршы төшеп тә маташты. Ләкин шурачылар басымы астында барысына да кул селтәде. Шуның өстенә татар гаскәри оешмалары лояльлек күрсәттеләр, дисциплинаны нык сакладылар, бернинди башбаштаклыкта катнашмадылар. Шурачылар хәрби властьларның шулай бармак аша каравына исәп тотканнар да иде. Гаскәри формированиеләрдән үзләренә ышанычлы «тыл» булдыргач, алар тыныч халык арасында эшчәнлекләрен җәелдереп җибәрделәр, политик аренада исә астыртын уен башланды.

Власть өчен көрәштә дини бәйрәмнәр төп таяну ноктасына әйләндерелде. Мондый көннәрдә гади солдатларны, шәһәр ярлыларын, Казанга еракта килгән эшче һәм крестьяннарны үз якларына аудару өчен алар ни генә кыланмый: кунакка чакыру, тәмле ашлар белән сыйлау, бергаләп күңел ачу дисеңме — берсе дә калмый. Ә мәҗлес вакытында большевикларга, Ленин партиясенә, пролетариат юлбашчысына каршы ярсу агитация башлана.

Контрреволюционер шурачылар тагын да ераккарак сузыла башлагач, большевиклар битараф калмады. Партиянең Казан оешмасы җитәкчелеге, Мөселман социалистлар комитеты белән берлектә, шурачы агитаторларга аяусыз көрәш игълан итте, татар роталарында солдатларны өйрәтү эшен һәм тәрбияләүне тулысынча үз кулына алды.

Тиздән бу эш уңай нәтиҗәләрен бирде. Татар подразделениеләре солдатлары эшче-крестьян митингларында активрак катнаша башладылар, ялкынлы трибун Вахитов һәм аның шәкертләренең чыгышларын тыңладылар. Большевик һәм социалистлар белән күзгә-күз очрашулар эзсез калмады, гади кешеләрнең үзаңын үстерде, 1917 елгы катлаулы революцион вакыйгаларның асылын төшенергә, кемнең дус, кемнең ачык яки яшерен дошман икәнен аңларга ярдәм итте. Күпчелек рядовойлар, кече офицерлар милли комитетның нинди юлдан баруын аңладылар.

Шунысын да әйтергә кирәк, соңрак, татар роталары Совет власте өчен көрәшнең алгы сафында булды. Казан кремлен штурмлаганда да алар батырлык күрсәтте.

...Көнчыгыш фронт барлыкка килү, чехословак корпусының фетнәсе, кулакларның баш күтәрүе илдә хәлне кискен катлауландырды. Кызыл Армияне һәм шул җөмләдән Казан хәрби округын шактый ныгытуны таләп итте. Яңа көчләр, яңа сугышчылар кирәк. Бу вакытларда мин хәрби округның комиссары итеп сайланган идем. Ярдәмчемне ияртеп, туган якларыма, балачактан таныш авылларга чыгып киттем. Халыкка партия политикасын, большевиклар куйган бурычларны аңлатырга, Кызыл Армия сафларына яңа революцион солдатлар тупларга кирәк иде... Авылдан-авылга йөрибез, һәм үзебез дә сизмәстән, акгвардиячеләрнең тылына килеп чыкканбыз. Без Шафраново станциясендә идек, ә аны һөҗүм ясап, аклар кулга төшергән булып чыкты.

Хәер, кулга төшергән дип әйтүе дә кыен. Чөнки станциядә кызылларның көчләре бөтенләй диярлек юк, сугыш булмады дип тә әйтергә ярыйдыр. Атака вакытында станциядән ерак түгел урнашкан бер күл янындагы камышлыкка качып өлгердем. Караңгы төшкәнче шунда утырып, кичен көнбатышка үтүче поездларның берәрсенә эләгермен дип исәпләгән идем.

Станциягә килгәч, андагы постларның тимер юлга беркемне дә якын җибәрмәүләре ачыкланды. Әле анда, әле монда чехлар яки акгвардияче офицерларның нарядлары күренә. Инде нишләргә! Фикеремне туплап та өлгермәдем, ике солдатның миңа таба килгәнен күреп алдым. Артка да, алга да китәр җай юк. Барысы да уч төбендәге кебек күренеп тора.

Таш стена чыгынтысына ышыкланып көтәм, үтеп китәрләрме-юкмы... Шул чакта бөтенләй көтмәгән яктан, арттан тавыш ишетелде:

— Тукта! Кымшанма!

Ирексездән тавыш килгән якка борылдым. Берничә адымда гына винтовкаларын төзәп ике солдат басып тора иде.

— Мине кем беләндер бутагансыз ахры,— дип эндәшүдән башка чара калмады.

Солдатлар янына килеп җиткән офицерның командасы яңгырады:

— Кулларыңны! Кулларыңны күтәр!

Алар артыннан килгән гражданский киемдәге берәү солдатларга борылып:

— Тотыгыз! Бу — шул!— дип ысылдады.

Хыянәт корбаны икәнемне шунда гына аңлап алдым. Җирле халыктан кем дә булса бераү Шафраново станциясендә кызыл офицер йөрүен, аны революцияне яклап агитацияләвен әйтеп өлгергән булса кирәк.

Ялт кына наганымны тартып чыгардым һәм атып җибәрдем. Алдымдагы солдатларның берсе бөгелеп төште. Тагын чакмага бастым. Шул мизгелдә арттан кемдер мылтык түтәсе белән башыма китереп тондырды.

...Аңыма килгәндә, өч ат җигелгән арбада ята идем. Атлар томырылып чаба. Янымда кулларына винтовка тоткан ике солдат утыра. Алда — кулга алуда катнашкан офицер. Күтәрелергә тырышып карасам да, тора алмадым. Кулларым каерып артка бәйләнгән.

— Хәзер дә безнең контрразведчикларны әгитләргә җыенасыңмы, комиссар иптәш-әфәнде,— диде офицер миңа борылып. Борыныма сасы махмыр исе килеп бәрелде.

— Контрразведчикларны?— дип кайтарып сорадым мин, аның шулай ачыктан-ачык сөйләвенә гаҗәпләнеп.

— Кем сиңа алай дип әйтте, болван?— дип кычкырып җибәрде ул, үзенең артыгын сөйләп ташлавын аңлап.

Ләкин миңа башка сүз кирәк түгел иде инде. Тагын да авыррак, катырак газаплар һәм сынаулар көткәнен аңлау кыен булмады. Штатский киемдәге кешенең «Бу шул!» дип кычкырганы тынгы бирми. Аның белән кайдадыр очрашканыбыз бар, аның кыяфәте таныштыр кебек тоела...

Һәм кинәт исемә төште! Бер күзле!.. Аның турында миңа Курманайда, Уфадагы приютта бергә тәрбияләнгән иптәшем сөйләгән иде. Совет властен яклап, Кызыл Армия сафларына керергә чакырып чыгыш ясаганнан соң бик озак сөйләшеп утырган идек. Уртак танышлардан кемнең кайда булуы,ниләр эшләве турында бәйнә-бәйнә сораштык, сөйләштек. Шул чакта ул: «Атаман»ны, приютта син килгәнче баш булып йөргән Насыйрны хәтерлисеңме?— дип сораган иде,— Хәзер Уфадагы Милли шурада зур начальник, тулы вәкаләтле вәкил. Бик бай яши. Соңгы вакытта аны безнең якларда күргәләдем, офицерлар белән килеп, «тәртип» урнаштырып йөргән иде. Элеккечә усал, кәперәючән икән! Үзгәрмәгән. Хәер, кемдер бер күзен бәреп чыгарган аның. Бәйләп йөри».

Димәк, шул Насыйр саткан. Моны аңлап алгач, арбада яткан көйгә көлеп җибәрүемне сизми дә калдым: «Язмыш гаҗәп нәрсә. Приюттагы «дошман»ым тәки эзләп тапты бит. Эзләп тапты, таныды... һәм сатып та җибәрде». Хәзер миңа станциядәге вакыйгалар ачык аңлашылды. Балачактагы рәнҗүләре өчен үч алырга шуннан да яхшырак юл тапмаган, күрәсең.

Стәрлетамак төрмәсендә бик озак һушыма килә алмый ятканмын. Килешли Раевкада тукталып алган идек. Инде айнып өлгергән офицер мине бик озак һәм үчләнеп кыйнады. Исерек теленең тик тормаганы өчен үч ала иде ул. Аңымны югалткан саен, өстемә салкын сулар сибә-сибә типкәләде.

Аңыма килгәч, беренче эш итеп, аякка басарга тырыштым һәм стенага сөялеп, тирә-якка күз салдым. Карашым беренче кешедә тукталып калды. Насыйрны таныгандагыдан ким гаҗәпләнмәгәнмендер. Салкын таш идәндә Сәхип, Тукай авылыннан Озын Сәхип утыра иде.

— Монда ничек эләктең? Нәрсә өчен?— дип сорадым мин газаплы авыртуларымны да онытып.

Сәхип күзләремә тыныч карап, исәнләшергә кулларын сузды һәм ашыкмый гына җавап бирде:

— Нәрсә өчен дип сорыйсың. Совет власте өчен. Аның яклы булган өчен.

— Сине ничек аңларга?— дип кайтарып сораган идем.

— Авыл советы рәисе мин. Беләсеңме кем... энең Хәсән тәкъдим итте. Халык сайлап куйды. Ә аклар килүгә иң беренче итеп мине кулга алдылар да төрмәгә ташладылар. Хәер, мин өйрәнеп беткән инде. Үзен беләсең, патша вакытында да утырдым. Ә хәзер аның элеккеге ялчылары утыртты. Ярый. Моннан да чыгарбыз. Иң мөһиме — борынынны салындырмаска...

Сәхип сүзләрен әйтеп тә бетермәде, камера ишеге ачылды, надзирательнең тавышы яңгырады:

— Чанышев! Ишеккә!

Бик авырлык белән аягыма басып, төрмәче артыннан кузгалдым.

Кояш нуры балкыган бүлмәгә килеп кергәч, башта бернәрсә дә күрә алмый интектем. Караңгы камерадан соң күзләрем яктылыкка ияләшеп өлгермәгән иде әле. Нindидер таныш сыман тавыш ишетелде:

— Әйдә, уз, Чанышев. Ишек төбендә торма, кыюрак бул.

Тавышка борылып карадым һәм соңгы көннәрдә инде ничәнче тапкыр гаҗәпләнергә мәҗбүр булдым: алдымда прапорщиклар мәктәбендә бергә укыган Ишмурзин басып тора.

Бүлмә почмагыннан тагын берәү тавыш бирде:

— Иске дус! Менә нинди очрашу!

Монысы — Мамлеев тавышы.

— Ну, комиссар, иң элек синең приказ буенча Казанда безнең хатыннарны ничек ачка интектерүләре турында сөйләшикме?— дип башлады ул сүзен.— Бәлки авылларда кызыл коткы таратып йөрүең турында сөйләрсең? Үзеңә кайсысы күбрәк ошый, ибдәш?

«Иптәш» сүзен әнә шулай бозып, мыскыллап әйтте ул. Сүз арасында тыелгысыз нәфрәтен дә аңлау кыен түгел. Шунысын ачык төшендем: монда, Стәрлетамакта, Мамлеев та, Ишмурзин да миннән барысы өчен дә үч алачаклар. Казаннан хурлыклы качып китүләре өчен дә, Казанда калган хатыннары өчен дә. Ак офицер хатыннары буларак, мин аларга паек бирүдән баш тарткан идем. Әйе, теләсә нинди юл белән үч алачаклар, бер нәрсә адымда да тайчанып калмаячаклар. Сүз башында исә үзләрен кулда тотарга тырыштылар.

— Качышлы уйнап тормыйк,— дидем мин.— Без — дошманнар. Сүзебез дә кыска. Исән калдырыгыз дип ялынырга җыенмыйм. Мин революциянне сатмаячакмын! Мин — аның солдаты, һәм соңгы сулышыма чаклы аның өчен көрәшәчәкмен.

— Борчылма, борчылма,— дип башта алган тонда дәвам итте Мамлеев.— Соңгы сулышыңа ерак калмаган инде.— Өсталдән ниндидер фоторәсем алып миңа сузды.— Таныйсыңмы?

Рәсемдә энем Хәсән иде. Моның нәрсә аңлатканын белергә теләп, Мамлеевка карадым. Ул кайгы уртаклашкан кыяфәт белән, авыр сулап, кыланып сөйли башлады:

— Качарга маташканда... Аны туктату... мәңгегә туктату өчен бер пуля җиткән...

Төлке бүрегә әйләнде. Усал карап кычкырып җибәрде:

— Минем нәрсә әйткәнем аңлашыламы? Бу бит синең энең, шулаймы? Өяз милициясе начальнигы. Дөресме? Хәзер инде элеккеге начальник.

Барысы да аңлашылды. Хәсәнне үтергәннәр! Хәсәнне... Әле яз көне генә ул минем янга, Казанга килгән иде. Ике көн бергә булдык. Нәрсәләр турында гына сөйләшмәдек тә кемнәрне генә искә алмаган идек. Икебез өчен дә бәхетле көннәр иде ул. Хәсән аеруча шат. Стәрлетамак милициясендә эшли башлавына шатлана, большевиклар партиясенә керүе белән горурлана иде ул. Сүзләре әле дә исемдә: «Якуб, хәзер мин дә большевик! Синең кебек үк. Икебез бергә, халык белән бер юлдан барачакбыз. Нинди бәхет бу!»

Һәм менә хәзер Мамлеев белән Ишмурзин энемнең һәлакәте турында хәбәр белән рухымны сындырмакчылар. Юк! Сындыра алмассыз. Барып чыкмас!

Үземә шундый карар бирдем һәм йөзләренә карап:

— Тезләндермәкче буласызмы?.. Тырышмагыз, булмас. Кайгылы хәбәр белән дә, мәсхәрәләп тә теләгегезгә ирешә алмассыз,— дидем.

Мамлеев ачуына буылып, турыдан-туры яра башлады:

— Ә качып китәргә маташудан курыкмыйсыңмы, комиссар? Аның ничек беткәнен белмисеңме?

— Үтермәкче буласызмы? Тинтәкләр! Ә минем өчен җавап бирергә туры киләчәген оныттыгызмы?

— Кем алдында?— дип ачу катыш гаҗәпләнеп сорады Ишмурзин.

Һәм шунда мин Стәрлетамакка килешли юлда исерек офицердан ишеткән соңгы козыремны чыгарып салдым:

— Контрразведка алдында!

Исәбем дөрес булып чыкты. Ниндидер максатларда аклар контрразведкасына мин тере килеш(!) кирәк идем. Бу турыда Мамлеев белән Ишмурзин да белә.

Берничә көннән соң Уфага алып киттеләр. Элекке губернатор йортының подвалында урнашкан аклар контрразведкасына китереп яптылар. Ә анда, кулга алынган кешенең Казан хәрби округы комиссары Якуб Чанышев икәнен ачыклагач, шунда ук приказ бирделәр: «Төрмәгә!» Уфа төрмәсенә шулай килеп эләктем.

Хикәямне дәвам итү өчен, тагын Казан хәрби округы комиссары булып эшләгән чорга кире кайтыйк. Юкса, язмыш әзерләгән «бүләкләр» һәм «очрашулар» турында искә төшереп, сөйләү җебең читкәрәк алып киткәнбез икән.

Тормышымның Казан чоры...

Хәрби округ комиссары буларак нинди генә мәсьәләләр белән шөгыльләнергә туры килмәде. Митинглар оештыру һәм чыгыш ясау дисеңме, гарнизонда хәрби әзерлекнең торышын тикшерү дисеңме, хәрбиләр белән шәһәр халкы арасындагы бәхәсләрне хәл итү дисеңме — берсе дә калмады. Ә берчакны хәтта дин мәсьәләләре белән дә шөгыльләнергә туры килде.

Комиссариатка Уфадан, Мөселманнарның диния назариятеннән хат килеп төште. Совет власте исеменнән эш йөртүче кызыл офицер боерыгы белән Уфада диния назариятенең мәчетен тартып алганнар, имеш.

Моңа никадәр ачуым килү әле дә хәтеремдә. Мондый башбаштаклык нигә, ни өчен һәм нинди нигездә эшләнгән? Һәм, ниһаять, кемнең ахмаклыгы бу? Шуның өстенә руханилар белән араның шундый катлаулы чорында. Совет власте исеменнән эшләнгән бу акция кичекмәстән төзәтүне, принципиаль хәл итүне сорый иде. Әгәр шулай булмаса... Нәтиҗәләре белән бик еракка китүче күңелсез хәл туу ихтимал.

Әле бу хатны алганчы ук Казан большевиклар комитеты Сөембикә манарасын халыкка тапшыру тантанасы оештырган иде. Ул ситуацияне төгәл һәм нечкә аңлый белүче, милли мәсьәләне бердәнбер дөрес юл белән хәл итү өчен барысын да эшләүче Ленинның турыдан-туры күрсәтмәсе нигезендә эшләнде... Казан кремлендә урнашкан мәшһүр тарихи истәлеккә керү өчен гади халыкка киң юл ачылды. Тантанада катнашучы буларак әйтә алам, Совет властеның бу бүләге татар хезмәт ияләрендә большевикларга тирән рәхмәт хисләре уятты.

Ләкин... «хан мәчете»н халыкка тапшырасы көн алдыннан гына кемнәрдер мәгълүм дин эшлеклесе, мөселман мәзһәбе башлыгы Вәисовны астыртын рәвештә үтереп киттеләр. Моны, әлбәттә, совет власте вәкилләренең абруен төшерү максатында контрреволюционерлар эшләде. Һәм, әйтергә кирәк, пычрак үтерү үз ролен уйнады: большевикларның кансызлыгы һәм мәкере турында шәһәрдә имеш-мимешләр, дингә ышанучылар арасында уйдырмалар таралды. Казан партия комитеты кичекмәстән белдерү белән чыкты һәм контрреволюционерларның «Вәисовны үтерү большевиклар намусында» дигән уйдырмасын кискен төстә кире какты.

Шуңа күрә Уфадан килгән хат буенча ашыгыч чаралар күрергә кирәк. Дежурныйга боерык бирдем:

— Ашыгыч телеграмма тапшырыгыз: «Уфа. Хәрби комиссариатка. Һич кичекмәстән мәчетне бушатырга, назариятка кире кайтарырга боерам. Приказ үтәлмәсә, Уфага килеп, гаепләнене үз кулым белән атачакмын».

— Иптәш комиссар...— дип гаҗәпләнеп миңа текәлде дежурный.

Аны бүлдереп дәвам иттем:

— Әйе, нәкъ шулай. Уфага нәкъ шундый текст җибәрегез. Башкача ярамый! Без киләчәк турында уйларга тиеш. Киләчәк хакына бүген сизгер һәм зирәк политика үткәрергә тиешбез. Безне Ленин шуңа өйрәтә.

— Ләкин без бит дингә каршы,— диде дежурный.

— Әйе, каршы,— дип җавап бирдем.— Әмма үз халкыбызга каршы түгел. Ә халык арасында әлегә дин сөреме белән агуланган кешеләр бар. Аларны терелтергә, айнытырга, дәваларга кирәк. Үзебезгә каршы котыртмаска, ә дәваларга!

Тагын берничә секундтан икенче телеграмманы җибәрергә куштым:

— «Уфа. Мөселманнарның диния назариятенә, мөфти хәзрәтләренә. Уфаның хәрби комиссариатына кичекмәстән мәчетне бушатырга боерык бирелде. Аның үтәлүе турында миңа хәбәр итүегезне сорыйм». Имзаны куй: «Казан хәрби округы комиссары Чанышев». Менә шул. Икесен дә хәзер үк җибәрегез. Һәр секундның алтын бәһасенә торган чагы.

...Әйе, мизгелләрнең, секундларның иң кадерле, кыйммәт бәяле чаклары иде ул. Мизгелләр — кеше, сәгатьләр — шәһәр, ә көннәр кешелек язмышын хәл итә.

Мин Уфа төрмәсендә яткан көннәрдә Кызыл Армия частьлары бер яктан Бәләбәйне, аннан соң Чишмә станциясен азат иттеләр, икенче яктан Стәрлетамак — Бозаяз линиясенә чыктылар. Уфага якынлаштылар. Кызыл частьларның мондый омтылышлы хәрәкәте акгвардиячеләр арасында чын-чынлап ыгы-зыгы тудырды. Хәтта калын төрмә стеналары аша да фабрикант һәм заводчикларны «азат итүче»ләрнең, халыкны талап җыйган байлыкларын чемоданнарга тутыручы промышленникларның шау-шуы, тавыш-гаугасы сизелеп тора иде.

Чын азат итүчеләрнең якынлашуын без аеруча бер кискенлек белән тоеп тордык. Алдынгы частьларның, дөресрәге — разведчикларның һөҗүме хәтта безнең өчен, Уфа төрмәсе тоткыннары өчен дә көтелмәгәнчә булды. Подполь-

щик-большевиклар ярдәмендә разведчиклар шәһәргә үтеп керәләр, караңгы кичләрнең берсендә тупланып, яшен тизлеге белән төрмәне атакалыйлар. Бу гаҗәеп дөрес сайланган «адрес» һәм уңышлы атака иде. Төрмә, азат итүчеләребез өчен дә, тоткыннар өчен дә, кызыл гаскәрләрнең төп көчләре килеп җиткәнче, чын крепостька әйләнде. Разведчиклар, подпольщиклар һәм, соңыннан билгеле булганча, үлем җәзасына хөкем ителгән тоткыннар, барысы меңләп кеше, төрмәдә бөҗрасыман оборонага урнаштык, төрмәчеләр һәм дошманнарның һөҗүмнәрен кире кайтардык.

Бишенче армиянең 26 нчы һәм 27 нче дивизия полклары Уфага кергәч, мин төрмәдән чыктым. Урамнар бәйрәм итүче халык белән тулы. Өстемдә ертылып беткән куртка, аякларымда агач башмаклар булса да күңелем шат, үземне чиксез бәхетле хис итәм. Азат һәм исән булудан да олырак бәхет бар микән!

1918 елның 31 декабрь көне иде бу. Яңа елның беренче көннәреннән исә өстемә яңа вазифа йөкләнде — Уфа большевиклары, армия штабы белән киләшенеп, миңа шәһәр коменданты постын тәкъдим иттеләр. Тагын шау-шулы көннәр, мәшәкатьләр башланды. Озак та үтми, Кызыл Армиянең яңа гаскәри формированиеләренә корал алу өчен Уфа ревкомы мине Мәскәүгә җибәрде. Анда мин Германия һәм халыкара эшчеләр хәрәкәтенең күренекле эшлеклеләре Карл Либкнехт һәм Роза Люксембург истәлегенә багышланган митингта Владимир Ильич Ленин чыгышын тыңлау бәхетенә ирештем. Юлбашчыбыз сүзләре күңел түремдә мәңгегә уелып калды. Аның якты образы, акыллы, кыю, энергияле, социалистик җәмгыятебезнең үсешен күп дистә елларга алдан күрә белүче, үзенең кыска, әмма бай гомерен халыкка хезмәт итүгә, халык бәхете һәм киләчәге хакына багышлаган юлбашчы образы бүген дә исемдә.

Мәскәүдә озак тормадым, яңа җиргә билгеләнүем турында белдем. Үзем өчен аеруча якын, кадерле, беренче революцион бәрелешләр истәлеге белән дә бәйле булган нурлы Казан иде ул. Миңа Үзәк Мөселман хәрби коллегиясе карамагына китәргә тәкъдим ителгән иде.

Давыллы тормышымда яңа чор башланды.

* * *

Октябрь социалистик революциясеннән соң ярты ел да узмаган иде әле, инде 1918 елның февралендә Милләтләр эше Комиссариаты коллегиясе Кызыл Армия сафларында мөселман частьлары булдыру мәсьәләсен күтәреп чыкты. Шуннан соң күп тә үтмәде, Үзәк Мөселман комиссариатының «Революцион мөселман халкына» чакыруы игълан ителде:

«Иптәшләр, мөселман туганнарыбыз! Хөрриятебез хакына, милли үсешебез һәм чәчәк атуыбыз хакына, киләчәк буыннар бәхете һәм шатлыгы өчен башларын салган эшчеләр һәм солдатлар каны әле диварларында кибеп тә җитмәгән революция крепостен саклаучылар сафына басыгыз!..»

Бу чакыру меңнәрнең күңеленә юл тапты һәм, шул ук елның маенда Үзәк Мөселман комиссариаты турыдан-туры Халык Комиссарлары Советына буйсындырылып, Үзәк Мөселман хәрби коллегиясе итеп үзгәртеп корылгач, беренче татар-башкорт батальоны оеша башлады. Июнь аенда инде ул Самарага озатылды, бишенче армия составына кертелде һәм фетнә күтәргән чехословак корпусы белән сугышларда батырлык һәм кыюлык күрсәтеп, «Тимер батальон» дигән мактаулы исем яулап алды.

Бу берләшмәдән соң Мәскәүдә тагын бер милли часть — Икенче җыелма татар-башкорт батальоны оешты. Мөселман хәрби коллегиясе фәрманы белән Казан, Уфа, Пермь, Оренбург, Әстерхан шәһәрләрендә дә берләшмәләр һәм гаскәри формированиеләр туды.

Шулай итеп, революцион рухтагы татар һәм башкортлар Кызыл Армиягә күпләп килә башлады. Әмма илдәге хәл шулкадәр катлаулы һәм авыр иде, революция казанышларын сакларга армиягә торган саен күбрәк солдатлар кирәк була барды. Халык Комиссарлары Советы һәм Үзәк Мөселман комиссариаты нәкъ менә шул көннәрдә «Барлык мөселман хезмәт ияләренә» мөрәҗәгать белән чыктылар. В. И. Ленин һәм М. Вахитов кул куйган бу өндәмәдә, аерым алганда, мондый юллар бар иде:

«Иптәшләр, туганнар, мөселман хезмәт ияләре!

Милләтләрнең Россия социалистик федерациясе дәһшәтле көннәр кичерә...

Әгәр йөрәкләрегездәге өмет изелгән һәм кыерсытылган миллионнарча кешеләрнең иң изге өмет-ышанычлары белән тәңгәл килә икән, мөселман социалистик

армиясенең кызыл байраклары астына басыгыз. Җиңүчән революцион мөселман сугышчылары Россиянең барлык якларыннан утлы ташкын булып эшчеләр һәм ярлы крестьяннар властен саклауга агылсын...»

Һәм яңадан Кызыл Армия сафларына күп санлы эшче һәм крестьяннар, студентлар һәм интеллигенция кушылды. Аерым батальоннар гына түгел, зур гаскәри берләшмәләр оеша башлады.

Беренче Идел буе бригадасы тәүге карлыгач булды һәм ул шәрык халыкларын изелүдән азат итүдә, революция казанышларын саклауда мөһим роль уйнады. Аны оештыру, бердәм, куәтле сугышчан берләшмәгә туплау, һәр яктан тәэмин итү белән Мәүлетов, Усманов, Хәкимов, Касыймов, Ибраһимов, Белоусов, Еникеев кебек зур сынаулар узган большевиклар җитәкчелек итте. Беренче көннәреннән үк бу катлаулы процесста миңа да катнашырга туры килде.

Беренче Идел буе татар бригадасы составында фронтлар, Гражданнар сугышының утлы бәрелешләре аша үттем. Баштарак артиллерия начальнигы идем, соңыннан бригаданың комиссары итеп билгеләндем.

Язмыш миңа мәрхәмәтле булды. Бригадада үземнең иске дусларым, башта Мәүлетовны, аннан соң тормышта дөрес юл сайлауда булышкан Питер эшчесе Семен Минаевны очраттым. Әле дә хәтерлим: 1917 елның унбишенче мартында, Казанда ул мине Ольксницкий янына алып килгән иде. «Чанышев намуслы кеше, крестьян, солдат. Большевик булырга, партия эше өчен, гади халыкның якты киләчәге өчен көрәшергә хыяллана. Тәкъдим итәм!..»— дигән иде. Һәм менә язмыш тагын аның белән очраштыра.

Башта Хөсәенне күрдем. Кочаклашып, бер-беребезне аркаларыбыздан кага-кага сөенешеп күрештек. «Син кайдан?» «Пермьнән. Ә син?» «Туп-туры Мәскәүдән...» Бер-бер артлы сораулар ява. Без Мөселман хәрби коллегиясе бинасында идек. Коридорның икенче башында коралланган ике кеше күренде.

— Менә безнең комиссарыбыз,— дип куйды Мәүлетов һәм,— Касыймов,— дип өстәде.

Ләкин игътибарны аларның икенчесе җәлеп итте. Аны кайдадыр күргәнем бар кебек. Ләкин кайда... Бераз якынлаша төшкәч, Минаев икәнен танып алдым.

Гадәттәгечә, ул аңгәмәнең җебен бик тиз үз кулына алды.

— Бригадага әйбәт кешеләр җыела. Мондый егетләр булганда Антанта да, акгвардиячеләр дә, хәтта шайтан үзе дә куркыныч түгел.

— Дошман да көчле,— дип куйды Касыймов.— Ләкин бездә дә җитәрлек. Бөтен халык, бөтен ярлы халык безнең яктан көрәшкә күтәрелә. Шулай булгач, җиңүнең кем ягында булачагына шикләнмәскә мөмкин.

Әнә шулай, Беренче Идел буе татар бригадасын оештыра башлаганда ук, үз көчебезгә тирән ышаныч бар иде. Шунысын да искә алырга кирәк, яхшылап өйрәтелгән көчле дошман белән сугышырга әзерләнү өчен бездә иң кирәклесе — вакыт дигән нәрсә бик аз иде. Әле тулысынча оешып та җитмәгән килеш, бригада Җаек елгасы буйларына озатылды; кешеләр туплау, полклар төзү анда да дәвам итте.

Легендар полководец, фронт командующие Фрунзеның аталарча кайгыртуы һәм гаять зур ярдәме турында аерып әйтәсем килә. Миңа аның белән күп тапкырлар очрашырга туры килде һәм без озак вакытлар аның белән ныклы дуслык мөнәсәбәтләрен саклап яшәдек. Теләсә нинди хәлдә дә салкын канлылыгын саклый алуы, үз-үзенә, гомуми эшебезнең хаклыгына инануы, партиягә, халыкка бирелгәнлеге, гаҗәеп кыюлыгы һәм куркусызлыгы белән ул мине һәрвакыт сокландыра иде.

Беренче килүендә Михаил Васильевич бригада командирларын җыеп алды һәм үз җитәкчелегендәге фронт алдында торган гомуми бурычны аңлатты. Аерым алганда, акгвардиячеләрнең «Оренбург бөкесе»н сугып чыгарырга, Төркестаннан килүче кызыл отрядларга кушылу өчен Арал диңгезенә таба һөҗүм җәелдерергә, алар белән берләшеп куәтле сугышчан «йодрык» хасил иткәч, ашкынулы, кыю һәм җиңүле маршта Урта Азиягә хәрәкәт итәргә, андагы халыкка азатлык юлында булышырга кирәк иде.

Күп тә үтмәде, бригаданы гаскәри эшелоннарга төяделәр һәм фронтка озаттылар. Берничә көннән без Беренче Кызыл Армия тупланган районга килеп җиттек, Сырт һәм Переволоцкая станцияләрендә бушатылдык һәм 49 нчы укчы дивизия частьларын алыштырып, Татищевская-Рычковская-Якунино участогында Сакмар суының тамагына кадәр позицияләрне биләдек.

Җаек суының уң як ярын дошманның вак частьларыннан чистартырга һәм яңа сугышчан бурыч алганчыга кадәр елга ярында ныгып урнашырга приказ алдык. Бу сират күперен кичү белән бер булды.

Ут сызыгына ятуыбызның икенче көнендә үк кайбер подразделениеләр дошман белән канлы бәрелешләргә керде, тәүге сугышчан чыныгу алды. Бу хәл дошман күзәтүчеләренең безнең хәлләрне ачыклау нияте белән елганы кичәргә маташкан чагында булды, бу маташу аларга зыян гына китерде. Берни дә ачыклап өлгерә алмаган дошман группасы артка алып ташланды. Шул шаушудан файдаланып, безнең разведчиклар эшкә керește. Өченче полк кызылармеецлары тавыш-тынсыз гына елганы үтеп, өч казакны кулга төшерәләр һәм частька алып кайталар. Куркудан телләрен тешләгән ак казаклар, бераз аңга килгәннән соң, үз тормышларын саклап калу өчен, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә күп нәрсәне сөйләп бирделәр. Әсирләрдән алынган мәгълүмат бик кирәкле һәм, чын мәгънәсендә, кыйммәтле булып чыкты. Алар бригада сугышчыларына байтак операцияләрне уңышлы үткәрергә, шул исәптән, Җаек елгасын кичкәндә нык ярдәм иттеләр.

Елганы кичү унберенче августта башланып китте.

Бригаданың сугышчан юлында иң мөһим операцияләрнең берсе саналучы бу вакыйга әле бүген генә булгандай, хәтеремдә.

Иртәнге сәгать өч. Барлык частьлар ут сызыгында. Туплар һәм пулеметлар яр буена ук тарттырылган, яхшылап яшерелгән һәм турыдан төбәп ату өчен көйләп куелган. Командирлар, комиссарлар — барысы да сугышчылар арасында. Алар әңгәмә үткәрәләр, егетләрне хәлиткеч бәрелешкә әзерлиләр, күңелләрен күтәрәләр.

Елга буенда салкынча. Талгын җил исеп куя. Бар нәрсәне куе томан каплаган. Аның аша аргы як ярны гына түгел, янәшәңдә кемнәр торуын да абайлый алмыйсың. Кичүнең ничек үтәчәген әйтү кыен. Бу урында су котырынып, ургылып ага. Һәркем түземсезлек белән һөҗүм башлау өчен сигнал көтә.

Һәм, ниһаять— сигнал.

Ярдан, мөмкин кадәр тавыш чыгармаска тырышып, бер-бер артлы сугышчылар төялгән көймәләр, саллар аерыла. Барыбызны да бер нәрсә борчый: дошман алдынгы частьларыбызны кайда күреп алыр — ярдан аерылгач укмы, елга уртасындамы, әллә килеп җиткәч кенәме? Операциянең уңышы күп яктан шуңа бәйле.

Кызыл сугышчыларны елга уртасында күреп алдылар. Шул мизгелдә елга өстендә утлы өермә уйный башлады. Ак казакларның пулеметлары, күп санлы мылтыклары телгә килде. Пулялардан су өсте кайнап торгандай күбекләнә башлады. Яраланган сугышчыларның кычкырып куюы, һәлак булучыларның иңрәп ыңгырашуы ишетелде. Уралның салкын дулкыннары бик күп сугышчыларны үз кочагына алды.

Ләкин кызылармеецларның күбесе дошманның алгы сызыгына килеп җиткән иде инде. Котырынкы каршылыкны бастырып, һәр өч полкның алдагы подразделениеләре яр буенда ныгып алдылар һәм төп көчләрнең һөҗүме өчен плацдарм булдырдылар.

Атлы гаскәр дә, икенче полкның төп көчләре дә форсаттан оста файдаланды, тиз арада елганы кичеп, куәтле дулкындай дошман өстенә ташланды. Ак казаклар бирешергә теләми, ничек тә сугышчан тәртибен сакларга тырышып, тулы полклар белән контрһөҗүмгә күтәрелә, кыргый тавышлар чыгарып, чиный-чиный кызыл гаскәргә ябырыла. Ләкин инде безнең сафларны какшатырга мөмкин түгел.

Өченче полкка аеруча кыенга туры килде. Дошманның атлы гаскәре белән бәрелешләрдә Краснохолмск станицасы өч мәртәбә кулдан-кулга күчте. Бары тик икенче көнне генә без аны тулысынча кулга төшерә алдык.

Бу бәрелешләрдә мин батареяга командалык итә идем һәм операциянең күп нечкәлекләрен яхшы хәтерлим. Сугышчыларыбыз гайрәт белән, чын-чыннан кыюлык һәм батырлык үрнәкләре күрсәтеп сугышты. Дошманның әллә ничә атакасы кире кайтарылды. Безнең тупларның тоташ уты, пулеметларның өзлексез кургашын сибүе атлы гаскәрне чалгы белән чапкандай кыра, аның бердәмлеген юкка чыгара, ваклый, тарката. Бердәм җитәкчелектән мәхрүм калган бу төркемнәр, ахыр чиктә бер-берсен изеп-сытып, артка тагәри. Пулеметчы Сабитов батырлыгы аеруча сокландыргыч хатирә булып истә калган. Аның иң җаваплы урынга куелган ут ноктасын акгвардиячеләр берничә тапкыр бастырырга тырышып карадылар. Әмма Сабитов җан өшеткеч атакалардан да, кылычлар ялтыравыннан да, дошманның дәһшәтле кычкыруыннан да курыкмады, алар өстенә үлем яудыруын белде. Батыр егет шушы сугышта революция эше өчен башын салды.

Уңышлы операцияләр нәтиҗәсендә безнең полклар 13 августта Соленый,

Колесников, Ирица, Никитовка, Никольский хуторларын алдылар һәм дошманны эзәрлекләүне дәвам иттерделәр. Батальоннарның берсе, хәзергечә әйтсәк, «механикалаштырылды». Сугышчыларны пар ат җигелгән тимер күчәрле арбаларга күчереп утырттык. Дошманга тын алырга да ирек бирмичә куып баруда бу зур бер өстенлек бирде. Каты бәрелешләрдән соң, 17 августта без Соль-Илецк, Линевка, Озерки поселокларын алдык. Шулай итеп, шактый зур территориядә үз контролебезне урнаштырдык. Беренче Идел буе татар бригадасы йөзендә Кызыл Армиянең көчле сугышчан берләшмәгә ия булуын җиңүләребез белән раслыдык.

Бернечә көннән бригадага Фрунзе һәм армия командующие Зиновьев килде. Шул уңай белән үткәрелгән митингта Михаил Васильевич, кызылармеецларга мөрәҗәгать итеп, болай диде:

— Сугышчы иптәшләр! Сезне Кызыл Армия частьларының һөҗүменә юл ачкан зур һәм мөһим операциядә җиңеп чыгуыгыз белән котлыйм! Уральны кичү, станицаларны алу, атаман Дутов частьларын тар-мар итү — теләсә кайсы гаскәри формирование өчен дан. Ә сезнең өчен ул икеләтә данлыклы, чөнки бу — Идел буе укчы татар бригадасы катнашкан беренче зур бәрелеш. Һәм сез аны бик яхшы башкарып чыктыгыз. Сез мактау сүзләренә генә түгел, бүләкләргә дә лаек!

Фрунзе бригаданың бик күп сугышчыларына һәм командирларына исемнәре язылган сәгать һәм күн обмундирование тапшырды.

— Барыннан да элек Темир шәһәре һәм Джурун станциясе юнәлешендә тизләтелгән, ашкынулы һөҗүм алып барырга кирәк,— диде Фрунзе.— Аларны 10—15 сентябрьдән дә соңга калмыйча алырга тиешбез. Командование бу эштә сезгә зур өмет баглый.

Михаил Васильевич сабыр һәм тыныч, үз-үзенә нык инанганлык белән сөйләде. Гәрчә бөтен кешегә берьюлы мөрәҗәгать итсә дә, безнең һәрберебез, шул исәптән мин дә, ул сүзләрне нәкъ миңа үзенә төбәп әйтелгәндәй кабул итте. Фрунзе үтә мөһим проблемалар турында да, өлкән кеше үзеннән яшьрәкләр белән аралашкандагыча, ышанып һәм ышандырып сөйли белә. Аның приказы да боерык кебек түгел, ә теләк сыман яңгырый. Ләкин ул өлкән кеше теләге! Аны үтәми калу мөмкин түгел.

Фрунзе, гаскәри формированиегә хәрби бурыч куйганда, шулкадәр анык һәм аңлаешлы итеп сөйли, аның тормышка ашырылачагына бернинди шик калмый торган иде. Бу юлы да шулай аңлатты:

— Һәр полкта махсус удар группалар оештырыгыз. Алар бәрелешләрдә әйдәүче, юл салучы булыр. Һөҗүм башлар алдыннан дошман урнашкан җирне, аның частьларының оешу тәртибен, ут нокталарын җентекләп өйрәнегез. Иң мөһиме, флангларыгызның куркынычсызлыгын тәэмин итегез. Ялан кыр шартларында бу аеруча нык таләп итела. Штабларны саклауны көчәйтегез.

Әнә шундый теләкләр белән китте берләшмәдән Фрунзе. Ә без ул теләкләрне һәм приказны тормышка ашырырга керештек.

Бригада Казаннан килгән, өйрәтелгән яңа солдатлар белән тулыланды, фронт йөздән алтмыш чакрымга кадәр тарайтылды, тыллар алгарак тарттырылды. Болар гаскәрнең рухын тагын да күтәреп җибәрде, алдагы операцияләрдә дә уңышка ирешәчәгебезгә ышаныч уятты. Шуның өстенә, партия оешмалары, бригада политбүлеге (аңа 1919 елның августыннан Еникеев җитәкчелек итә башлады) һәм хәрби комиссарлар җирле халык арасында киң аңлату эшләре җәелдереп җибәрделәр.

Шушы эш Кызыл Армия частьлары белән халык арасында дуслыкны һәм үзара ярдәмләшүне ныгытырга булышлык итте. Бу тирәләрдә яшәүче татарлар, һәм казахлар безгә ит, сөт, башка төр азык-төлек алып киләләр, кавалерия өчен яхшы ат бирәләр. Еш кына аерым подразделениеләрне акларның һөҗүмгә әзерләнүе турында кисәтеп куялар. Болар барысы да алда торган операцияне җентекләп, уйлап эшләргә мөмкинлек тудыра, сугышчыларның мораль хәленә уңай йогынты ясый.

Бригада 30 августта фронт командующие Фрунзе һәм Беренче армия командующие Зиновьев фәрманы нигезендә, яңадан һөҗүмгә күчте. Безнең частьлар дошманнан алдарак өлгерергә, Актүбәне көнбатыштан урап узып, аклар килеп җиткәнче Темир шәһәрен һәм Джурун станциясен кулга төшерергә омтылалар иде. Бу планнар да уңышлы үтәлде. 13 сентябрьдә бригада частьлары, Турчаниновның беренче кавалерия бригадасы белән берлектә, Петровск, Сергиевский поселокларын, Ново-Украинский хуторын алдылар. Ә икенче көнне иртән кавалерия бригадасы һәм өченче укчы полк кетмәгәндә Темир шәһәренә бәреп керде, ак казакларның ике полкын кысрыклап чыгарды.

Шәһәрдә бик күп корал, азык-төлек, медикаментлар кулга төшерелде. Ярап куйды алар безгә, чөнки соңгы вакытта бригадада житмәүчелек үзен нык сиздерә башлады, чөнки без шулхәтле тиз алга киттек, йөкләр гаскәр артыннан иярергә өлгерми иде.

Акларның эш хөртиләшә, сафлары сирәгәйгәннән-сирәгәя бара. Берләшмәләре тар-мар ителү, Темир һәм шулай ук Актүбә,Тургай, Иргиз шәһәрләрен алу аклар арасында паника уятты. Акгвардиячеләр, кем әйтмешли, артларына да борылып карамыйча табан ялтырата башлады. Совет властен жаны-тәне белән күралмаганнары гына тартышып маташа, яки зур югалтулар белән сугыша-сугыша көньякка, я булмаса көньяк-көнбатышка бәреп чыгарга омтыла.

Шулай итеп, 13 сентябрьдә беренче армия гаскәрләре Джурун һәм Челкар станцияләре тирәсендә, Арал диңгезе ягыннан һөжүм итеп килүче Төркестан частьлары белән кушылды. Кызыл Төркестанга юл ачылды. «Оренбург бөкесе» дип аталган нәрсә бетерелде. Яшь Советлар республикасына Эмба нефтенә һәм Урта Азия мамыгына чыгу мөмкинлеге туды, байтак кына башка экономик мәсьәләләрне хәл итү өчен уңай шартлар барлыкка килде.

Сугышчыларның батырлыгы, кыюлыгы, куркусызлыгы югары житәкчеләр тарафыннан тиешле бәя алды. Эшче-крестьяннар Оборона Советы 1919 елның 1 октябрендә бригаданың барлык сугышчыларына һәм командирларына рәхмәт белдерү турында карар кабул итте.

Ә тагын бер атнадан, Төркестан фронты гаскәрләренә приказ биргәндә, Фрунзе болай дип язды:

«Тормышка ашты! Төркестанга юл ачык!.. Тагын бер тапкыр сезне менә дигән уңыш белән тәбриклим; жиңүләрегезне Кызыл Төркестанда, туганнарыбызга ярдәм иткәндә тагын да ныгытырсыз дип нык ышанам».

Һәм без ярлы халыкны изелүдән һәм кыерсытылудан азат итә-итә, жиңүле адымнар белән алга ыргылдык.

Төркестанлыларга һәм Татар бригадасына, Турчанинов кавалеристлары белән берлектә, әле һаман аклар кулында булган Уильск ныгытмаларын һәм Кызыл Күгәне алу, «Алаш-Орда хөкүмәте»н нейтральләштерү бурычы куелды.

Шул максат белән бригаданың төп көчләре Темир-Джурун-Зайсан-Мартук районында, ә штаб һәм махсус частьлар Актүбәдә урнаштырылды.

Барлык полклар, кырык-илле жайдаклы взводларны йөз-йөз илле чакрымга дошман тылына үткәреп, тирән разведка ясарга приказ алды. Бу чара исә ак казаклар турында кирәкле мәгълүмат тупларга һәм хәлиткеч һөжүмгә житди әзерләнергә мөмкинлек бирде.

Уильскиның үзендә укчы, атлы һәм тупчы частьларның барлыгы ачыкланды. Сан ягыннан шактый булсалар да, дисциплина житмәү дошманның хәрби потенциалын нык киметә: көчләп мобилизацияләнгән казаклар һәм казахлар безнең соңгы жиңүләр турында яхшы беләләр, дистәләп-дистәләп качып киталәр, ак берләшмәләрнең сугышчан сәләте айлап түгел, көнләп кими бара. Моннан тыш ак казаклар арасында тиф белән авыручылар, ачлыктан хәлсезләнгән кешеләр байтак. Хәер, бу проблеманың соңгысын алар үзләре үк тудырды: әле хәлләре чагыштырмача әйбәт вакытта жирле халыкка карата шундый террор оештырдылар ки, халык ачыктан-ачык булмаса да, аларга каршы баш күтәрә башлаган иде инде. Крестьяннар дошман гаскәреннән мал-туар, ашлык һәм башка азык-
төлекне яшерә, аларның таләбен үтәүдән качалар.

Унсигезенче ноябрьдән дә калмый Уильскины алу турында приказ килгәч, бригада сазлыкларны, инде ката башлаган салкын елганы кичеп, бер талпынуда шәһәргә бәреп керде. Аптырашта калган дошман һушына да килеп өлгермәгән
көйгә тар-мар ителде; шәһәрдән чыгып качты.

Безнең полк, бригада үз тарихына тагын бер жиңүле сәхифә язды. Хәлдән тайдыргыч авыр бәрелешләрдән соң ял итү никадәр ымсындырмасын, аның турында уйларга вакыт юк. Кул кушырып утырыр чак түгел. Хәер, ул чакларда бу
нәрсә кызылармеецлар һәм большевиклар өчен бөтенләй ят нәрсә иде.

Декабрь башында кавалерия бригадасы тактик максатларда кире Темир шәһәренә кайтты, ә Татар кавалерия дивизионы, өченче Татар полкы һәм тупчылар батареясы алга кузгалды. Безгә ничек кенә булса да Кызыл Күгәне
алырга кирәк иде.

Шунысын да әйтергә кирәк, бу поход отряд өчен шактый хәвефле иде. Без инде бригаданың төп көчләреннән ике йөз километрга диярлек аерылдык. Көтмәгәндә көчле дошман белән күзгә-күз килү ихтималы да, бөтенләй ярдәмсез калуыбыз да бар. Ләкин жирле халыкның дустанә мөнәсәбәтен, акрынлап Совет власте ягына күчә баруын барыбыз да яхшы аңлый идек инде. Шуны аңлау

безгә көч өсти, рухыбызны күтәрә. Шуның өстенә, «Алаш-Орда хөкүмәте»нең большевиклар ягына күчүе турында инде декабрь урталарыннан ук ике арада сөйләшүләр башлануы да мәгълүм. Сүз уңаеннан әйтеп үтим, аларга башка юл юк иде инде.

Сөйләшүләр барган арада отряд тизләтелгән марш белән Кызыл Күгәгә таба хәрәкәт итте. Уильскидан 120 чакрымдагы Илецк һәм Иртецк шәһәрләрендә ак казакларның өйрәнү полкларын тар-мар иттек, олауларын, шактый күләмдә корал кулга төшердек. Бу операция алаш-ордалыларга үзенчәлекле сигнал кебек булды; алар, ниһаять, бердәнбер һәм иң дөрес юлны сайладылар. Без шәһәргә якынлашып килгәндә «Алаш-Орда хөкүмәте»нең казах частьлары баш күтәрде, алар көтелмәгән удар белән Кызыл Күгәдә Илецк корпусы командиры Акутинны һәм аның штабын кулга алдылар.

Шулай итеп, катлаулы операция башланды. Аның төп авырлыгы, аңлашыла ки, безнең отряд җилкәсенә төште. Дошман өстенә гайрәт белән ташлана торган куркусыз командир Шәйхетдинов, аерым Татар кавалерия дивизионы командиры Мельниковлар батырлыгын искә алмый мөмкин түгел. Операциянең уңышында, сугышчан һәм сәяси бурычның намус белән үталүендә, тугрылыклы иске дусларым Мәүлетов һәм Касыймовның роле гаять зур булды.

Кызыл Күгәдә безнең частьлар әле яңа гына Энәдән төшкәндәй өр-яңа инглиз обмундированиесе саклана торган интендантлык складларын кулга төшерде. Бу байлык, әлбәттә, шунда ук кызылармеецларга таратылды. Шул уңайдан сугышчыларның шаяртып сөйләшүләре әле дә хәтеремдә. «Англиянең капиталист әфәнделәренә рәхмәт: киендерделәр дә, туендырдылар да. Хәзер инде шундый кече күңелле игелек ияләрен тагын да ныграк тукмый алачакбыз»,— диләр иде алар.

Әйе, Антантаның башка вәкилләре шикелле үк, инглизләрнең яшь Совет республикасына карата игелек күрсәтүе турында ул вакытларда бары тик шаяртып кына сөйләргә була иде. Безне ачлык һәм чир белән, алар акчасына симертелгән акгвардиячеләрнең ярсулы атакалары белән буу өчен, кулларыннан килгәннең барысын да эшләделәр алар. Теләсә нинди мәкер, алдау, кабәхәтлек аларның коралы булды.

Әнә шундый көннәрдә, авыр һәм җаваплы көннәрдә без Төркестан халкына ярдәмгә ашыктык. Биредә сугыш дүрт фронтта: Каспий аръягы, Җидесу, Фирганә һәм Актүбә фронтларында бара. Каспий аръягында акгвардиячеләр баш-кисәрлек итә, Җидесуда кулаклар баш күтәрде, Фирганәдә басмачылар котырына. Буржуаз милләтчеләр, диндар руханилар, акгвардияче офицерлар һәм Англия разведкасы милләтчеләр, акгвардиячеләр һәм басмачылар оешмаларының эшенә житәкчелек итә, юнәлеш бирә. Аларның максаты бер — Төркестанны Совет республикасыннан аерып алу һәм биредә Англиянең яңа колониясен булдыру. Инглизләрнең шулкадәр обмундирование, корал һәм азык-төлекне нинди исәп белән җибәрүен аңлау кыен түгел.

Колчакчыларның көньяк группасын һәм Урал ак казакларын тар-мар иткәннән соң, Җидесу, Каспий аръягы һәм Фирганә өлкәләрендә сугышучы кызылармеецларга ярдәм күрсәтү Төркестан фронтының төп бурычына әйләнде. Нәкъ менә шуңа күрә фронт командующие урынбасары Новицкий ул вакытта Мәскәүдә булган Фрунзе белән туры чыбык аша сөйләшкәндә, бу мәсьәләне кабыргасы белән куйды.

— Фирганәгә килгәндә, мәсьәлә ачык,— диде Новицкий.— Җирле гаскәрләрнең тотрыксызлыгы һәм андагы соңгы уңышсызлыклар Беренче татар бригадасын тулысы белән шунда җибәрүне таләп итә.

Шушы сөйләшүдән соң күп тә үтмәде, бригада — штаб, политбүлек, икенче укчы полк һәм башка подразделениеләр составында — эшелоннарга төялде һәм Әндиҗанга озатылды. Анда без 1919 ел азагында, яңа елны каршыларга әзерләнеп барган көннәрдә килеп җиттек.

Сугышчан хәрәкәтләр бөтенләй башка төсмер алды. Тоташ, бердәм фронт сызыгы юк. Ул һәркайда — һәр өйдә, һәр чатта, һәр тыкрыкта диярлек. Басмачы — хәтәр дошман: ул хәйләкәр, мәкерле. Көндез ул тыныч, ягымлы, хәтта дус булып күренергә мөмкин. Ә төннәрен өненнән чыга да кешеләрне суя башлый, суя, суя, суя! Әндиҗанда да, Маргеланда да, Ошта да, Нәманганда да, башка шәһәрләрдә дә шулай. Басмачылар ревкомнарда, милициядә һәм ЧКда эшләүче дистәләрчә җаваплы совет работникларын һәм активистларны үтерделәр, пәрәнҗәләрен салган, өяз яки волость комитетларының хатын-кыз бүлекләренә килеп йөргән хатын-кызларны да кызганмадылар. Көн саен диярлек Ташкент белән Әндиҗан, Әндиҗан белән Җәләлабад арасындагы элемтәне бозып, әле анда, әле

монда тимер юлларны җимереп тордылар. Хәл-Хуҗа, Мөәтдин бәк һәм Мәдәмин бәк отрядлары аеруча котырынды.

Әлеге хәлне Әндиҗан коммунистлары белән тикшергәннән, уйлашканнан соң бригада политбүлеге һәм командование халыкны башкисәрләрдән саклау чараларын эшләде. Иң элек, «психологик атака» ясалды — шәһәр һәм өяз ревкомнары «иске шәһәр»гә, халык арасына күчерелде. Бу — большевикларның халык турында кайгыртуын раслаучы мисал иде. Басмачылар артык узынырга базмый башлады. Ни дисәң дә, коралы большевикка һөҗүм итү ул бернинди чарасы булмаган кешене суеп чыгу түгел.

Яуланган беренче уңышны ныгытырга кирәк иде. Җирле власть органнары шул максаттан активистларны арттырырга керештеләр. Урамнарда, мәйданнарда, коммунистлар оештырган митингларда Совет власте үткәрә торган политика сабыр һәм үтемле итеп аңлатыла, безнең якка күчүнең өстенлекләре ачыла, Кызыл Армия сафларына язылырга чакыру яңгырый. Совет власте вәкилләре «иске» шәһәргә күчеп берничә көн үтүгә күп кенә әндиҗанлылар дошман белән көрәштә ярдәмнәрен тәкъдим иттеләр. Дошман бик хәйләкәр иде, шунлыктан көрәш ысулларын гел үзгәртеп, яңартып торырга кирәк булды.

Басмачылар белән көрәш гадәттә ничек бара иде? Теге яки бу кышлактагы суештан соң анда шау-шу белән кызылармеецлар яисә милиция отрядлары килеп керә. Кергән уңайга халыктан сорый башлыйлар: кемнәр килде? Кем үтерде? Кем талады? Аларны таныйсызмы? Кайда яшиләр? Ничек табарга?.. Кем дә булса берәү юлбасарларның кайда яшеренеп ятуын әйткән очраклар да булгалады. Ләкин икенче көнне иртән ул кешене үз йортында үтерелгән хәлдә табып алалар иде. Кызылармеецларга ярдәм күрсәтергә тырышкан һәркемнән дошман канлы үч алды. Басмачылар башбаштаклыгы дәвам итте.

Төбәккә Беренче аерым укчы Татар бригадасы килгәч, без һәр кышлакны, һәр мамык эшкәртү заводын, һәр нефть промыселын басмачылар белән көрәш пунктына әйләндердек. Үзебез үткән һәр җирдә берәр рота солдат яки атлы эскадрон калдырабыз, алар халыкны башкисәрләр ябырылуыннан саклый.

Дөрес, эре берләшмәләргә каршы сугышканда бу чаралар гына җитми. Ләкин монда да әмәле табылды. Фрунзе, хәрби стратегия һәм тактиканы искиткеч шәп белүен тагын бер кат раслап, яңа ысул тәкъдим итте. Волость үзәкләрендә, тимер юл станцияләрендә гарнизоннар сизелерлек ныгытылды. Таулы районнарны айкап, басмачыларны кырып йөрүче хәрәкатчән кавалерия отрядлары белән алар арасында даими элемтә оештырылды. Әле һаман үзенең элеккеге тактикасын куллланучы банда көтмәгәндә һөҗүм итүгә, гарнизон оборонага күчә һәм юлбасарларны сугыш белән бәйли, ә шушы төбәктә хәрәкәт итүче кавалерия группасы аларны тылдан чолгап ала һәм юк итә. Дошман бандасы инде беркая да ычкына алмый. Кызылармеецлар тиз арада югары камиллеккә җиткергән шушы тактик яңалык соңра басмачыларны тулысынча бетерергә ярдәм итте дә инде.

Гадәти паровоздан, берничә вагоннан торган, пушка һәм пулеметлар куйган ике ачык платформа тагылган җиңел «бронепоезд»лар да шул максатка хезмәт итте. Платформаларга броня урынына прессланган мамык тюклары куя идек. Алар пуляны гына түгел, хәтта өч дюймлы снарядларны да тотып кала, сугышчыларга үзенчәлекле калкан була иде. Әндиҗан-Коканд, Әндиҗан-Җәләлабад участокларында тимер юл линияләрен шундый «бронепоезд»лар саклады, алар шулай ук гарнизоннарга басмачыларның зур отрядлары белән көрәшергә дә ярдәм итте. Мондый бронеотрядлар безнең карамакка Фрунзе күрсәтмәсе нигезендә бирелгән иде.

Әндиҗанга килүгә үк бригада дошманның бертуган Әкбәр-Али һәм Мәхкам-Хуҗа җитәкчелегендәге отрядларына көчле удар ясады. Ул шулкадәр көчле һәм сизелерлек булды, башкисәрләр сугышчан хәрәкәтләрне туктатуны һәм... Совет власте ягына күчәргә мөмкинлек бирүне сорап парламентарий җибәрделәр. Әкбәр-Али һәм Мәхкам-Хуҗа белән безнең якка алты йөзләп кеше күчте. Шактый көч иде бу! Ләкин аны, математика кануннарын бозып булса да, икеләтә арттырып санарга кирәк. Моны аңлату кыен түгел. Бердән, алты йөз дошман «юкка чыкты», икенчедән, Кызыл Армиягә шуның кадәр үк дус, яки, һич югында, аңа теләктәшлек күрсәтүче өстәлде. Сугыш дәвам итсә, сафларыбыздан күпме кеше югалыр иде.

Урта Азиядә бандитизм юлбашчыларыннан берсе Мәдәмин бәк Әкбәр-Али белән Мәхкам-Хуҗаны үзенең кан дошманы дип белдерде, баддога укып, алардан каты үч алырга ант итте. Бу антның ни дәрәҗәдә ачулы булуын үз җилкәбездә татырга туры килде.

Ике айлап өйрәтелгәч һәм Октябрь идеяләренә тугрылыгы тикшерелгәч, Әкбар-Али һәм Мәхкам-Хужа группалары Төрки кавалерия бригадасының дүртенче полкы составына кертелде һәм Пайток авылы тирәсенә җибәрелде. Ул вакытта анда бригаданың комендант ротасы урнашкан иде. 1920 елның өченче февралендә шул рота командирыннан чапкын килде.

«Пайток кышлагыннан сигез чакрымдагы Око-Обори дигән җирдә Мәдәмин бәк белән Иргәш зур көч туплады. Дошманның 3000 гә якын җайдагы бар. Командирлары арасында рус офицерлары да күренә. Иртәнге сәгать алтыда Пайтокка ут ачтылар. Кышлак чолганышта. Гарнизон ашыгыч ярдәм сорый. Гафуров.»

Кыю һәм тәҗрибәле командир Гафуровтан әлеге хәбәр алынуга бригада командиры Ибраһимов җитәкчелегендәге атлы отряд Әндиҗаннан чыгып китте. Аның Пайток янында күренүе басмачылар өчен шул кадәр көтелмәгәндә була, ашкынулы һөҗүмгә ташланган кызыл гаскәрнең кысрыклавына чыдый алмыйча алар ашыгычлык белән төньяк-көнбатышка, Каракүл кышлагына таба чигенә.

Пайток кышлагы янында операция төгәлләнүгә, Ибраһимов, вакытны бушка уздырып тормастан, Берләшмәне чигенүче башкисәрләр артыннан алып китә. Мәдәмин бәкне тулысынча тар-мар итү өчен тагын да куәтлерәк отряд төзергә боерык бирә. Аның кул астындагы атлы гаскәргә озакламый икенче полкның укчы батальоны, җәяүле разведчиклар һәм бригада штабының комендант командалары, хәрәкәтчән отряд сотнясы, уналтынчы атлы полк эскадроны, Әкбар-Али белән Мәхкам-Хуҗа егетләре* кушылды. Бу инде куәтле көч иде. Һәм ул кыю, ашкынулы һөҗүмгә күчте. Мәдәмин бәк гаять авыр хәлдә калды: сугышны дәвам иттерсә, тулысынча кырылып бетү куркынычы бар, ә берләшмәне бөтен көе саклау мобильлекне югалту дигән сүз. Шундый шартларда ул үзе өчен бердәнбер дөрес юлны сайлады, утыз-кырык кешелек вак төркемнәр белән ерактагы кышлакларда «эреп югалырга» карар бирде. Дүртенче февраль кичендә Мәдәмин бәк отрядлары безнең күз алдында кими башлады.

Бу да ахырынача җиңү дигән сүз түгел иде әле. Дошман качса да, тар-мар ителмәгән. Димәк, бераз көч җыйгач, ял иткәч, тагын безнең өскә ташланачак. Ибраһимов моны яхшы аңлый. Шуңа күрә дә теләсә кайсы минутта сугышка әзер булырга приказ бирде.

Командир ялгышмаган булып чыкты. Бишенче февраль көнне иртән разведчиклар Мәдәмин бәк берләшмәләрен Горбуа һәм Тода кышлаклары тирәсендә күрүләрен хәбәр иттеләр. Бирегә аңа инде шактый талкынган Хәл-Хуҗа һәм Иргәш отрядлары кушылган. Бер урында — җәмгысы дүрт меңнән артык басмачы... Бу совет властен бөтен зәһәрлеге белән куралмаучы, нәфрәтенә буылган зур һәм куркыныч отряд дигән сүз. Бүтән барыр юллары булмау аларның зәһәрлеген тагын да арттыра төшә.

Составына безнең бригада да кертелгән Икенче Төркестан дивизиясе командованиесе хәлне дөрес бәяләп, Мәдәмин бәк һәм Хәл-Хуҗага каршы көрәшне тагын да нәтиҗәлерәк иттерү өчен ике сугышчан группа оештырды. Аларның һәркайсы анык һәм шул ук вакытта катлаулы задание алды.

Комбриг Ибраһимов җитәкчелегендә уң группага, Кужело кавбригадасы белән берлектә, тизләтелгән маршта Горбуага таба хәрәкәт итәргә, анда сул группага кушылып, ачык сугышта дошманны тар-мар итәргә кушылды. Хәрәкәт барышында Шарихаг һәм Азиван кышлакларын алырга, Аим кышлагындагы гарнизонны үзебезгә ияртергә кирәк иде. Сул группа да юлында очраган кышлакларны басмачылардан чистартып барырга тиеш.

Сул группа безнең белән кушыла алмады. Ул Горбуа янында басмачыларның каршылыгына очрый һәм алга бару гына түгел, хәтта Владыкино станциясенә чигенергә мәҗбүр була. Котылгысыз хәлдә калган башкисәрләрнең ярсып, үчләнеп сугышуы да, вакытлы чигенү дә кызылармеецларның рухын сындыра алмый. Группа, көчен җыеп, контрһөҗүмгә күтәрелә һәм дошманны, сизелерлек югалтуларга дучар итеп, кысрыклый башлый. Бу операция алдагы сугышлар өчен шактый әһәмиятле булды. Ул еллардагы сугышчан хәрәкәтләр тасвирланган язмаларны бүгенгә кадәр архивымдагы иң истәлекле хатирәләрдән саныйм. Арада шулай ук Татбригада командованиесе приказлары да бар.

...Кызыл Армия частьларының тәвәккәл һәм кыю һөҗүме, канкойгыч бәрелешләр басмачы бандаларының һәлакәтен якынайтты, ә Мәдәмин бәк коралын ташлап, бирелергә мәҗбүр булды.

1920 елның беренче апрелендә бригадабыз оештырылуга бер ел тулды. Бу вакыйга уңаеннан Әндиҗанның үзәк мәйданында бригаданың шәһәрдәге барлык частьлары, шулай ук кавалерия бригадасы һәм башка подразделениеләр

сафка тезелде. Җыйнак, пөхтә киенгән, ялтыраганчы чистартылган кораллы җайдаклар ат өстендә уйный, куәтле орудиеләр янында яшь солдатлар елмая. Сафларда — бәйрәм рухы.

Бу тантана шәһәр халкы өчен дә чын бәйрәмгә әверелде. Урамнарда гына урын житмәгән кешеләр өйләрнең яссы түбәләренә менеп тулды. Һәркайда оркестр уйный, милли уен кораллары тавышы ишетелә. Хәрби парадка Ташкенттан, Фирганәдән, Кокандтан һәм шулай ук Төркестан фронты частьларыннан һәм берләшмәләреннән кунаклар килде. Митингта бригада сугышчыларына бик күп мактау һәм тәбрик сүзләре әйтелде.

Командование һәм политбүлек вәкилләре, Төркестан Үзәк башкарма комитеты, Коканд, Фирганә, Әндиҗан ревкомнары хезмәткәрләре, үзбәк яшьләре һәм гаскәри частьлар вәкилләре чыгыш ясады.

Бригада сугышчылары төгәл, нык адымнар белән шәһәр урамнары буйлап тантаналы маршта үттеләр. Парадтан соң командование бригаданың барлык подразделениеләрендә бәйрәм ашы уздырды. Пылауга җирле яшьләрне дә чакырдык. Командирлар, политработниклар белән алар арасында дусларча җанлы әңгәмә башланып китте.

Ә кичен зур бәйрәм концерты. Анда бригада һәвәскәрләреннән тыш, Ташкенттан һәм Казаннан килгән үзбәк һәм татар артистлары катнашты, сугышчылар аларны алкышларга күмделәр. Бәйрәм артиллерия салюты һәм фейерверк белән тәмамланды, яшеллеккә төренгән шәһәр урамнары аллы-гөлле утлар балкышына чумды.

Без, Төркестан фронты реввоенсоветы членнары, Куйбышевтан, Ибраһимовтан, Төркестан Үзәк башкарма комитетыннан, Коканд большевикларыннан, Сәмәркәнд өлкәсе ревкомыннан, Беренче төрки бригадасы политбүлегеннән котлаулар алдык.

Без, сугышчылар һәм командирлар, Фрунзе һәм Куйбышевның даими кайгыртуын тоеп яшәдек. Баштарак таркау булган, үзара бәйләнеш житмәгән Төркестан фронты отрядларын Кызыл Армиянең регуляр частьларына әйләндерү өчен алар күпме көч һәм энергия түктеләр! Һәр сугышчы моны үз тәҗрибәсендә татыды.

Әйе, һәр сугышчы, һәм, шул исәптән мин дә... Гомумән алганда, Михаил Васильевич белән һәр очрашу минем хәрби язмышыма нинди дә булса үзгәреш кертә иде. Шундый очрашуларның берсе турында бирегә киңрәк тукталып үтәсем килә.

...Зур авырлыклар белән Бохарага таба күченеп барганда, дустым Мәүлетовны күреп сөйләшәсем килеп китте. Аның полкы колоннаның башында, ә ул үзе комиссар белән бергә полк алдыннан бара иде. Мин нәрсәдер эшләргә җыенсам, шуны башкармыйча туктамыйм. Атымны кызурак атлата башладым. Күпмедер вакыт үтүгә Хөсәенне куып житкән идем инде.

Исәнләштек, күрештек, әңгәмә ялганып китте. Бригада комиссары Белоусовның һәлак булуын барыбыз да бик авыр кичергән идек, табигый ки, сүз җебе дә шул тирәдә чуалды. Эш шунда, реввоенсоветның азрак кан түгү, басмачыларны ирекле рәвештә сугышны туктатырга авыштыру турындагы күрсәтмәсен тизрәк үтәргә омтылып, ул төрекмән басмачыларының башлыгы, ерткычлыгы белән дан тоткан Җүнәедхан янына үзе барырга карар бирә.

Иптәшләре никадәр генә үгетләмәсен, ни җирле гадәтләрне, ни телне, ни юлбасар торган кышлактагы хәлне юньләп белмәгән көйгә комиссар Белоусов сөйләшүләргә чыгып китә. Чыгып китә... Ә бандитлар безгә аның чабып өзелгән башын җибәрделәр.

Мәүлетов та, мин дә сугышчан иптәшебезне сагынып, юксынып искә алдык. Үзенең батырлыгы, куркусызлыгы, атакаларда һәрвакыт иң алда булырга тырышуы белән ул сугышчыларның тирән хөрмәтен һәм мәхәббәтен казанган иде. Безгә — командирларга да, гади солдатларга да тугрылыклы дус иде ул.

Шул чакта арттан килүче солдатларның берсе үз-үзеннән сорагандый әйтеп куйды:

— Белоусовны кем алыштырыр, кем хәзер комиссар булыр икән?

Чыннан да, бу сорау күпләрне борчый. Теләсә нинди берләшмәдә комиссар эше гаять җаваплы һәм четерекле эшләрдән санала. Ә безнең өчен, басмачылар белән рәхимсез көрәш шартларында берләшмә өчен бигрәк тә. Әйе, бу югары постка шул җаваплылыкны җаны-тәне белән аңлый торган киң карашлы кеше куелырга тиеш.

Уйга чумып тын гына бара идек, арттан чаптырып килгән ат тояклары тавышлары уйларыбызны бүлде. Җайдак, килеп житүгә, бер сулыштан сүзен әйтте:

— Чанышевны командующий чакыра!

Бу минем өчен көтелмәгәнчә яңгырады. Командующийга ник кирәк булдым икән? Хәер, армиядә андый сорау бирмиләр. Берничә минуттан Фрунзе каршында басып тора идем инде. Ул мине дусларча, ачык йөз белән каршы алды һәм якынлашып килүче Куйбышевны күреп, берниндиң кереш сүз ясап тормастан болай диде:

— Валериан Владимирович сезне бригада комиссары итеп билгеләргә тәкъдим кертте. Мин дә, штаб начальнигы да сезнең кандидатураны хуплыйбыз. Бу тәкъдимгә ничек карыйсыз?

Фрунзеның сүзләре минем өчен гадәттән тыш яңгырады дип әйтә алмыйм. Фронтта көтмәгәндә, искәрмәстән була торган хәлләргә күнегеп беткән идек инде. Ә бусы бит, көтелмәгән булса да, күңелле яңалык! Шулай да, бераз югалып калдым, мондый сөйләшүгә әзер түгел идем. Тынлык озакка бармады, сүзгә Куйбышев кушылды.

— Реввоенсовет сезгә ышана, иптәш Чанышев,— диде ул.— Сезнең революция эшенә бирелгәнлегегезгә ышана.

— Ышанычыгыз өчен зур рәхмәт. Аны акларга тырышырмын.

— Яхшы. Барысы да әйбәт булыр,— дип елмайды Фрунзе һәм янында басып торган бригада командиры Ибраһимов белән штаб начальнигы Тальковскийга борылып дәвам итте:

— Иптәш Чанышевны яңа вазифасы белән котлый аласыз.

Аннан соңгы сүзләре тагын миңа юнәлгән иде.

— Исеңдә тот, безне алда яңа, җитди сынаулар көтә. Алим-ханга ярдәмгә инглизләр ашыга. Контрреволюция баш калкытырдай ситуацияләргә юл куя алмыйбыз. Безнең бурыч — Бохара төенен чабып өзү! Сезнең бригадага, комиссар, фронт реввоенсоветы аерым өмет баглый. Сынатмагыз!..

* * *

Басмачылар белән көрәшнең иң авыр көннәрендә без шактый зур берләшмәнең башында торган курбашы Хәл-Хуҗаны үз ягыбызга аударырга булдык. Әлбәттә, моның ни дәрәҗәдә куркыныч икәнен дә, Хәл-Хуҗа белән очрашуга барачак кешенең гомерен кыл өстенә куюын да яхшы аңлыйбыз. Моны мин дә беләм, ләкин шулай да үз кандидатурамны тәкъдим иттем. Шул турыда сүз чыккач, Ибраһимов байтак уйланып торды.

— Нәрсәгә барганыңны яхшылап уйла, Якуб,— диде ул, ниһаять.— Курбашы мәкерле, хәйләкәр. Явыз дошманыбыз Мәдәмин бәк кебек үк эче-тышы пычрак агу белән тулган кеше. Онытканчы әйтим, әгәр бандитлар турында шулай дияргә яраса, ул аның белән бик дус, җитмәсә Мөәтдин бәк белән дә әшнәләр, ди. Анда бару, бу инде үлем белән уйнау дигән сүз. Һәм бар дип синә беркем дә приказ бирә алмый...

— Барысын да яхшы аңлыйм,— дип җавап бирдем мин комбригка.— Ләкин йөзләрчә гомерне саклап калу хакына тәвәккәлләргә, дошман өненә дә керергә ярый торгандыр.

— Яхшы,— диде Ибраһимов.— Бар,— һәм бераздан дулкынланган тавыш белән өстәде,— Рәхмәт сиңа, Якуб...

Шулай итеп, батыр йөрәкле ике кызылармеец: Рәхимбаев һәм Халиков белән мин Хәл-Хуҗа янына чыгып киттем. Безне озата килгән Бажанов һәм Хусанбабаев җитәкчелегендәге атлылар отряды дошман урнашкан җиргә ун чакрым кала бездән аерылды. Басмачыларның разъездларын һәм заставаларын исән-имин генә үтеп, Хәл-Хуҗа оя корган Араван кышлагына килеп җиттек. Курбашы монда мамык эшкәртү белән шөгыльләнүче элекке промышленник йортына урнашкан, аны, зурлап, «сарай» дип йөртәләр.

«Сарай»ның зур ишегалдында басмачылар мыж килә. Керүебезгә атлардан төшерделәр, кулларыбыздан тотып, Хәл-Хуҗа утырган бүлмәгә алып керделәр. Бүлмә идәненә төрле төстәге затлы келәмнәр җәелгән, алар өстендә ярым түгәрәк ясап баштанаяк коралланган киңәшчеләр утыра. Хәл-Хуҗа чиккән тышлы зур мендәргә кунаклаган. Өстендә зиннәтле ефәк чапан, билендә алтын һәм бриллиантлар белән бизәлгән пута. Аңа берничә хәнҗәр һәм түтәсе бизәпсырлап эшләнгән алтатар кыстырылган. Курбашының артындагы диварда инглиз карабины асылынып тора. Бер сүз белән әйткәндә, алдыбызда үзенең бөтен «матурлыгы» белән «шәрык хөкемдары» утыра иде.

Шул мизгелдә мин үзебезнең дә алай начар коралланмавыбыз турында уйлап алдым: һәркайсыбызда револьвер, кылыч, ә минем кыр сумкасында, ан-

дый-мондый очракка дип ике гранатага хәтле бар. Ләкин шунда ук башыма икенче уй килде: нинди «очрак» булырга мөмкин, Хәл-Хуҗа янындагы җиңел пәрдәләр артында баштанаяк коралланган ничә тән сакчысы!.. Мондый ситуациядә саксызрак бер хәрәкәт ясавың белән үк маңгаеңа пуля алырга мөмкин. Юк! Мәкерле дошман белән сөйләшкәндә хәзергә безнең бер генә коралыбыз бар. Ул да булса түземлек, сабырлык һәм хәйлә. Без аның янына үлем эзләп түгел, сөйләшергә дип килдек.

Мул табын әзерләнгән. Аңа күз төшерүгә үк, басмачыларның инде күптәннән кәеф-сафа корып утыруларын аңлап алдым. Димәк, алар тук, кәефле, беренче минуттан ук бәхәскә һәм бәрелешкә бармаячаклар. Тычкан белән уйнаган мәче шикелле, кызыл комиссарларны ирештерергә тырышачаклар. Монысы да безнең файдага, шартларыбызны тәкъдим итәргә, аңлатырга ара булачак дигән сүз.

Фикеремне раслагандай, Хәл-Хуҗа мендәрләре өстендә киерелеп алды һәм иренеп кенә сүз кушты:

— Я, комиссар... Минем янга ник килдең, сөйлә...

«Башлана... Уйнарга кереште... Юансын әйдә... Ничек башлау түгел, ничек төгәлләү мөһим», дип уйладым һәм «уенга» кушылырга булдым:

Үземнең дулкынлануымны берни белән дә сиздермәскә тырышып, хәер, аны сиздерү оттыру булыр иде, сүз башладым:

— Әле Үзбәкстанга килгәндә үк, Хәл-Хуҗа изге кеше, мәрхәмәтле, итагатьле мөселман, дип ишеткән идек. Мөселманнарда кунакчыллыктан да изге нәрсә юк. Яшермим, безне шул гадәт буенча каршы алырлар, дип ышанган идек. Ләкин без килгәнгә артык шат күренмисез... Әгәр шулай булса, без отрядка кире кайтып китәбез.

«Кунакчыллык», «гадәт» дигән сүз үзенекен итте. Хәл-Хуҗаның яраннары пыш-пыш сөйләшә башладылар, башлыкларын мөселман кануннары, шәригать кушканны үтәргә өндиләр иде булса кирәк. Аларның киңәше курбашының тәкәбберлеген киметә төште һәм ул ясалма елмаеп, үзенең киң күңелле хөкемдар икәнлеген күрсәтергә теләгәндәй, сөйләнә башлады:

— Ашыкма, комиссар. Табын янына, минем уң ягыма утыр. Кунак бул, безнең сыйдан авыз ит.

Мондый да «чын күңелдән» чакыруны кире кагып булмый. Без аякларыбызны бөкләп, табын янына килеп утырдык.

Хәл-Хуҗа берәр касә эчемлек күтәрергә тәкъдим итте. Без риза булдык. Мәҗлес икән, мәҗлесчә булсын. Алар белән бер табында утырырга да, әңәргә дә курыкмавыбызны күрсеннәр әйдә. Үз-үзебезне тотышыбыз ук җиңүче мәрхәмәтенә бирелүне таләп итеп түгел, ә тыныч тәкъдим белән килүебезне, һәр сүзебезгә, биргән вәгъдәбезгә ышанырга мөмкин икәнлеген күрсәтеп торсын. Без — Совет власте вәкилләре.

Хәл-Хуҗа акрынлап барыбызны да кызыксындыра торган темага якынлаша башлады. Хәер, аны аңлавы кыен түгел. Мондый кунаклар көн саен килеп тормый... Ул бригаданың хәле, Совет власте үткәрә торган милли политика, большевиклар программасы турында сораулар бирә. Кызыксынуын яшерә алмыйча, Ленин һәм Фрунзе турында сөйләвебезне сорый. Ә инде минем юлбашчыны күрүем, комбриг белән сөйләшкән булуымны ишеткәч, чын-чыннан гаҗәпкә калды. Кайбер сүзләреннән аның миңа да ихтирам белән карый башлавын аңлау кыен түгел иде.

Әңгәмәбез дүрт сәгатькә якын барды. Ахыр чиктә бер-беребезне аңлый башладык кебек. Хәл-Хуҗа, Кызыл Армиягә каршы сугыш хәрәкәтләрен туктату һәм отряды белән Совет власте ягына чыгу турындагы тәкъдимебезне яраннары белән тар даирәдә тикшерергә риза булды.

Яшермим, тыштан үтә тыныч күренсәк тә, Хәл-Хуҗа белән хушлашканда кыл өстендә йөргәндәй куркыныч астында булуыбыз турындагы фикер тынгы бирмәде. Ягымлы караш та, елмаеп сөйләшү дә, теге яки бу тәкъдимгә ризалашкан кебек баш селкү дә бер мизгелдә кансыз боерык белән алмашына ала. Басмачылар өеннән чыкканда әнә шуларны уйлап аркам чымырдап китте. Ләкин соңгы вакытта басмачыларның хәле шактый мөшкел иде инде, шуңлыктан тәкъдимнәребезнең аны нык уйландыруын да аңлыйм.

Мәсьәләне хәл итү, уйлану өчен бирелгән бер тәүлектән соң, Хәл-Хуҗа үзе өчен авыр булса да, дөрес карарга килә алды.

Көн кичкә авышып барганда часовойлар чалма-чапан кигән җайдакларның лагерьга якынлашып килүен күреп алалар. Тиз генә коралга ябышып, сугышка әзерләнәләр. Кызылармеецлар белән тигезләшкәч, алдан килүче җайдакларның берсе тавыш бирә:

— Миңа сезнең командующий кирәк!
— Ул юк,— дип җавап бирә кызылармеецлардан берәү.— Ташкентта ул.
— Алай булса, Чанышевны чакыр!
Бу фамилияне ишетүгә кызылармеец тиз генә мине эзләргә ташлана. Берничә минуттан мин Хәл-Хуҗа каршында басып тора идем инде. Килгән кеше нәкъ ул үзе булып чыкты.
— Совет власте ягына күчкән очракта безнең барыбызның да тормышы сакланачагын, кичә әйткән сүзләреңне раслыйсыңмы? — дип сорады курбаши.
— Раслыйм.
— Яхшы,— диде Хәл-Хуҗа.— Шартларыгызны кабул итәбез.
Үзенең юлдашларына күз йөртеп чыкканнан соң миңа борылды:
— Без килдек,— дип сүзен бетерде.
«Хәл-Хуҗа» дип шартлы исем биргән операция әнә шулай тәгамәлләнде. Бу операция, һичшиксез, йөзләрчә кешенең тормышын саклап калган һәм Урта Азиядә басмачыларны тәмам бетерүнең хәлиткеч этапларыннан берсе булды.
...Ләкин мондый сөйләшүләр һәрвакытта шулай уңышлы тәмамлана иде дип әйтеп булмый. Хәтта шулай тәмамланган очракта да еш кына басмачылар отрядта «утырып» калмый иде. Хәйләкәр һәм мәкерле дошман яратып куллана торган тактик алымын — көтеп тору тактикасын куллана. Үзләре өчен уңай вакыт җитүгә, берләшмәләрдән аерылып китәләр дә тагын Кызыл Армия частьларына каршы сугыш хәрәкәтләре башлыйлар. Аларның мондый кабәхәт политикасы ахыр чиктә командованиене яңа тактика кулланырга мәҗбүр итте. Без «качышлы» уйнаудан туктадык һәм башкисәрләрнең бастионнарына кискен һөҗүмгә күчтек. 1920 елның маеннан алар белән көрәштә яңа этап башланды һәм егерменче елның урталарына төбәктәге бик күп шәһәрләр һәм кышлаклар Кызыл Армия берләшмәләре контролендә иде инде. Аерым алганда, Курган-Түбә, Карасу, Базар-Курган, Лянгар, Избаскент, Аман-Чура, Ош, Әндиҗан һәм башка торак пунктлар азат ителде. Аларның һәркайсында хәрби гарнизоннар булдырылды. Икенче төрле итеп әйткәндә, без төбәк картасындагы «ак таплар»ны бетереп барабыз.
Озак дәвам иткән бу операциянең шактый мөһим тагын бер детален билгеләп үтми мөмкин түгел: гаскәри частьларның актив һәм уңышлы эшчәнлеге нәтиҗәсендә җирле халык Совет властеның, Кызыл Армиянең көченә торган саен ныграк ышана барды, басмачыларның үченнән курыкмыйча, кыю рәвештә безнең якка күчте һәм явыз дошманга каршы көрәшкә кушылды. Тимер юлчылардан һәм «Биш-Бош» заводы эшчеләреннән берничә рота нәкъ әнә шул юл белән оештырылды. Аларга карт эшчеләр җитәкчелек итте. Бу роталар безнең солдатлар белән иңгә-иң торып уңышлы гына сугышып килделәр һәм бәрелешләрдә шактый җиңү яуладылар. Урта Азиянең бу катлаулы регионында да Кызыл Армия чын-чыннан эшче-крестьяннар армиясенә, хезмәтчел халык армиясенә әйләнә барды.
Бригада структурасына да кайбер үзгәрешләр кертелде. Төркестан фронты реввоенсоветы приказы нигезендә 1920 елның июнендә Хәрби Совет төзелде, аның составына бригада командиры һәм комиссары, өяз хәрби комиссары һәм ревком председателе керде. Оператив һәм хәрби мәсьәләләрне хәл итү элеккечә комбриг һәм комиссар карамагында калдырылды, ә сәяси, административ, хуҗалык һәм оештыру мәсьәләләре хәрби советта каралачак иде.
Шул ук вакытта Татар бригадасы хәрәкәт иткән Әндиҗан-Ош районы участокларга бүленде, аларның начальникларына кышлаклардагы барлык вак гарнизоннар эшчәнлеген берләштерү мөмкинлеге бирелде. Тимер юлны саклау да көчәйтелде.
Безнең мондый оештыру чараларына җавап итеп дошман да берләшмәләрен үзгәртеп корды, ныгытты. Күп санлы вак төркемнәр һәрберсендә ике-өч мең штык туплаган зур отрядларга берләштерелде. Нәтиҗәдә курбашылар кыюланды, кискенрәк чыгыш ясый башлады. Алар безнең ваграк гарнизоннарны камыйлар, арыкларны ябып, кырык градуслы эсседә кызылармеецларны сусыз тилмерергә мәҗбүр итәләр, я булмаса барлык арыкларны берьюлы ачып, кышлакларны ташкын астында калдыралар.
Басмачылар мәкеренең чиге юк иде. Әмма гарнизоннар да искитәрлек түземлек һәм батырлык күрсәттеләр. Сугышчыларның байтагы бизгәктән җәфа чигә, еш кына каты авыру хәлендә сугышырга мәҗбүр була.
Кышлакларны батырларча саклауның дистәләрчә үрнәген күрсәтеп булыр иде. Ләкин мин ул ерак еллар хатирәсеннән аеруча истә калган ике эпизодны гына сөйләмәкче булам.

...Әле Горбуа янында ук кыйналган зур банда житәкчесе Курширмәт, кем әйтмешли, реванш алырга, ягъни үч кайтарырга уйлаган булса кирәк. 1920 елның июлендә ул Әндижаннан 48 чакрымдагы Яңа-Чик һәм Болак-Башы кышлаклары тирәсендә мең ярымлап жайдак туплады.

Безнең бригадага Нияз Батыр ягыннан килүче Кужело кавалеристлары һәм уенбишенче кавполк белән берлектә Курширмәтне тар-мар итү, аның тауларга качу юлын бикләү бурычы йөкләнде.

Берничә бәрелештән соң без Яңа-Чик кышлагын алдык, ләкин шунда гына дошманның төп көчләренең Болак-Башы гарнизонын камавы һәм Татар бригадасының Коновалов житәкчелегендәге дүртенче ротасын юк итәргә маташуы билгеле булды.

Гарнизон өчен сугыш уңайсыз шартларда башлана. Патроннар бетә. Үтерелгән пулеметчыны алыштыручы Коновалов тасмада нибары ун-унбиш патрон калганын абайлап ала. Сугышчыларда да патроннар дүртәр-бишәр генә. Сугыш кирәк-яраклары алырга жибәрелгән элемтәчеләр һалак була.

Кызылармеецларның утны киметкәнен сизеп басмачылар һаман әрсезләнә бара. Шул чакта безнең солдатлар йодрык сугышына ташлана. Каты яраланган Коноваловны взвод командиры Бочаров алыштыра. Һәм исән калган бер төркем сугышчылар белән бригададан ярдәм килгәнчегә кадәр басмачылар кысрыклавын кире кайтара.

Болак-Башы янында Курширмәтнең төп көчләренә каршы халиткеч сугыш башланды. Безнең пехотачылар кышлактан чыгу юлларын, арыклардагы күперләрне алдылар; атлы эскадроннар басмачыларны урамнарда турый башлады. Берничә сәгатьтән башкисәрләр юк ителде. Кызганычка каршы, курбашины гына тота алмадык. Ул милиционер формасы киеп качкан булып чыкты.

Әнә шулай, карыш арты карыш безнең гаскәрләр бу якларны да азат итә барды.

...Тагын бер вакыйганы яхшы хәтерлим. Ун сугышчыдан һәм өч телефонистка хатыннан торган Ак-Бусага станциясе гарнизоны чолганышта кала һәм егерме сәгать буе башкисәрләр һөжүмен кире кайтара.

Кызылармеецлар кереп яшеренгән станция бинасына басмачылар ут төртә. Ләкин кызыл сугышчылар монда да югалып калмый, ярсулы ут астында янгынны сүндерәләр һәм кавалеристлар килеп житкәнче дошманның дисталәгән атакасына каршы торалар.

Кайчакта фронт командованиесе элегрәк Урал, Оренбург һәм башка фронтларда сугышкан частьларны безгә ярдәмгә жибәрә иде. Кагыйдә буларак, ул частьларның сугышчылары һәм командирлары жирле гадәтләрне һәм шартларны белми. Кайберләре басмачыларны житди көч дип санамый. Ләкин хәйләкәр дошман белән беренче очрашу ук аларның мондый фикерен үзгәртә. Мондый жилбәзәклек кайчагында бик кыйммәткә дә төшә торган иде. Яңа килгән командирлардан берәүнең үз-үзенә артык ышануы аркасында килеп чыккан фажигале бер вакыйга хәтердә яңара:

Июнь уртасында без Курган-Түбә гарнизоны начальнигы Лавровтан Куршермәтнең туганы Парпи һәм Юлчи исемле курбашыларның ике мең жайдактан торган отряд белән Курган-Түбә, Грунч-Мазар, Карасуга өзлексез һөжүм ясап торуы, Ханабадны камаулары турында хәбәр алдык. Бандаларның берсе Курган-Түбәдә берничә кешене суйган, Совет властена теләктәшлек күрсәтүче егермеләп кешене әсир итеп, Аим кышлагына алып киткән.

Бу хәбәрне тикшергәч бригада командиры Ибраһимов берничә гаскәри берләшмәгә мондый боерык язды:

«Зур көчләр туплап, дошман Курган-Түбә, Грунч-Мазар һәм Карасу гарнизоннарына һөжүм итә, аларны камап алырга һәм юк итәргә омтыла. Курган-Түбә гарнизонына ярдәм күрсәтү һәм юлбасар шайкаларны тар-мар итү өчен приказ бирәм:

Икенче полк командиры Романовка 17 нче автоброненоезд карамагына егерме штык һәм бер пулемет белән комендант командасын һәм атлы разведчиклар командасын бирергә.

Автоброненотряд командирына жыелма отряд тупларга (бронемашина, йөк машинасына утыртылган пехота, мотоциклчылар һәм атлы разведчиклар командасы) һәм поход тәртибе белән, Курган-Түбә станциясенә китәргә.

Жирлекне һәм дошманны өйрәнү өчен атлы разведчиклар командасыннан файдаланырга».

Жыелма отрядны Әндижаннан озатыр алдыннан мин командирны катгый кисәттем:

— Аеруча сак булырга һәм Курган-Түбә гарнизоны белән тыгыз элемтәдә торып эш итәргә! Дошман бик хәйләкәр, мәкерле...

Командир егетләрчә елмаеп җавап кайтарды:

— Дошманмыни бу? Бигрәк тә безнең өчен. Бәлки белмисездер, без — Фортунатов белән Беловны кыйнаган кеше! Ә болар...

Инде ничә еллар үтте, ә мин бу аяныч вакыйганы һаман да тетрәнеп искә төшерәм. Унтугызынчы июньдә үк Лавровтан донесение килде: автобронеотряд «Изелгәннәрне азат итүче» броневигы белән бергә Курган-Түбәгә килеп җитте һәм шунда ук дошманны эзәрлекләп Аим кышлагына чыгып китте.

Бу хәбәрдән нинди дер күңелсезлек булачагын тоемлап, ә иң мөһиме — приказның бозылуын күреп, Лавровка үзебезнең таләпне җиткердек: һич кичекмәстән бронеотряд белән кушылырга һәм бергәләп хәрәкәт итәргә! Ләкин икенче көнне үк аннан тагын да шөбһәлерәк хәбәр алдык:

«Курган-Түбәдә сугыш алып барам. Дошман зур көч белән гарнизонны камый. «Изелгәннәрне азат итүче» броневигы һәм отряд белән элемтә урнаштыру мөмкин түгел. Разведчиклар Аим кышлагына барып җитә алмады. Агентура мәгълүматларына караганда, броневик басмачылар белән уратып алынган. Пехота отрядын суеп чыкканнар, бригаданың оператив отряды начальнигы Ласовский үтерелде».

Камалышта калучыларга ярдәмгә чыгу турында карар кабул иттек. «Аяусыз» броневигы, мотоциклчылар звеносы, сиксән штыктан торган саперлар командасы, бригада политбүлегенең махсус ротасы, Әндиҗанның партия дружинасы һәм унынчы бронепоезд составында отряд оештырылды. Отрядка ике пулемет һәм ике пушка бирелде. Сугыш хәрәкәтләре барган районга унөченче кавполк эскадроны чыгып китте.

Икенче полк командиры Романов җитәкчелегендәге поезд белән Курган-Түбә станциясенә килеп җиттек. Басмачылар артка алып ташланды, ләкин шул ук вакытта Аим кышлагындагы беренче отрядның һәлак булуы турындагы хәбәр дә килеп җитте. Карасу станциясендә, Хакулабадта, Грунч-Мазарда һәм башка җирләрдә каты сугышлар башланды. Басмачыларның төп көчләре исә Аим кышлагына тупланды. Разведка мәгълүматларына караганда, анда ким дигәндә дә ике меңләп басмачы һәм бик яхшы коралланган берничә йөз акгвардияче булырга тиеш.

Без унөченче кавполк эскадроны килеп җиткәнне көтеп тормастан, Аим кышлагына һөҗүм итәргә, аны чолгап алырга һәм дошманны юк итәргә карар бирдек.

Егерменче июньдә 16 сәгатьтә отряд Аимгә таба юлга чыкты. Артык кыенлыкларсыз гына Шәрихан-Сай дигән елганы кичтек һәм озакламый сугышта һәлак булган кызыл сугышчыларның үле гәүдәләренә тап булдык. Алар янында басмачылар мәетләре дә аунап ята.

Безнең сугышчылар һәм командирлар коточкыч мәсхәрәләнгән, аларны танырлык түгел. Бандитлар ярсуларына чыдый алмый аларның күзләрен чокыганнар, колакларын, борыннарын һәм бармакларын кисеп алганнар. Оперотряд начальнигы Ласовскийны бөтенләй тураклап ташлаганнар... Басмачылар белән күрәшнең бөтен нечкәлекләрен белгән кешеләрнең киңәшенә колак салмау менә шундый аяныч хәлгә китергән.

...Һәлак булганнарның гәүдәләрен Әндиҗанга җибәрүне оештыргач, тагын алга киттек. Исән калганнар өчен куркыныч сугыш дәвам итә иде әле.

Озакламый Аим кышлагы күренде. Бирелдәге бәрелешләр өч көн дәвам итте. Баштагы ике көндә әллә ни уңышка ирешә алмадык. Басмачылар үз кавалериясенең өстенлегеннән оста файдаланды. Безнең исә атлы взвод нибары берәү. Ләкин кызылармеецлар ук булып атылган җайдаклар ташкыны алдында да калтырап төшмәделәр, зур кыюлык һәм гайрәт күрсәтеп, бер карыш та артка чигенмәделәр.

Икенче көнне разведка «Изелгәннәрне азат итүче» броневигы язмышы турында күңелсез хәбәрләр алып кайтты. Машина бандитлар кулына эләккән. Сугышчыларның аяусыз каршы торуына карамастан, аларны әсир алганнар һәм ерткычларча суеп ташлаганнар. Броневикның кайда икәнлеген әлегә ачыклау мөмкин булмады.

Озакламый Татар кавалерия дивизионы һәм унөченче полк эскадроны да безгә кушылды. Сугышчыларның рухы күтәрелде. Кышлакны туплардан утка тотканнан соң бөтен роталар һөҗүмгә ташланды; басмачыларның көньякка качу юлын кисәр өчен кавалерия дивизионы һәм бронемашинаны кышлак артыннан уратып җибәргән идек.

Өметебез акланды. Башкисәрләрнең артына төшкән кавалерия кышлакның кырый урамнарына бәреп керде, пехота басымын арттырды. Егерме өченче июнь таңында, дошман уты астында елга аша күпер салып, кышлакның үзәк урамнарына килеп кердек. Басмачыларның төп көчләре тар-мар ителде.

Аим кышлагын алганнан соң без «Изелгәннәрне азат итүче» броневигын эзләргә керештек. Озак вакытлар берни дә ачыклый алмадык: кышлак халкы урам сугышларыннан куркып тауларга качып беткәнлектән, сорар-белешер кеше дә юк иде. Ниһаять, безнең сугышчылар минем янга ике картны алып килделәр. Алар броневикның ватылып Кара-Дәрья суына ташланган булуын әйттеләр. Без аны шуннан табып алдык та. Романов фамилияле бик оста мастерыбыз бар иде. Ул броневикны шактый тиз арада төзәтте һәм «Изелгәннәрне азат итүче» революция дошманнарын себереп түгүдә тагын бик озак вакытлар безгә ярдәм итте.

Басмачылар белән көрәш дәвам итте. Кайчагында ул бөтенләй көтелмәгән форма ала, күз алдына да китерергә мөмкин булмаган урыннарда башланып китә. Әндиҗанга Фрунзе килгән көнне бик кыска, әмма аеруча куркыныч бәрелешләрнең берсенә шаһит булырга туры килде.

Әндиҗан басмачыларының элекке җитәкчесе Ахунҗан беренче Төрки полкы командиры итеп билгеләнгән иде. Менә шуның Совет властена хыянәт итеп, үз полкын шәһәрдән алып китәргә җыенуы турындагы сүзләр ишетелде. Фрунзе Әндиҗанга шул уңай белән килде дә. Килеп җитүгә үк, бер генә минут вакытны да әрәм итмичә, ревком, партиянең өяз комитеты, Татбригада командованиесе һәм политбүлек вәкилләрен җыеп алды, четерекле хәлдән чыгу юлын, Ахунҗанның хыянәтчел планын гамәлгә ашыртмый калу чараларын эшләргә тәкъдим итте. Аерым алганда, Михаил Васильевич полкны коралсызландырырга һәм таркатырга кирәклеген әйтте. Бу, әлбәттә, иң кулай тәкъдим иде һәм барысы да аның белән килеште.

Операция планын билгеләү бер нәрсә. Ләкин аны ничек тормышка ашырырга? Полкның яхшы кораллануын, Ахунҗанга буйсынуын, ә аның, бездәге мәгълүматларга караганда, нык һәм кискен карарга килгәнлеген дә истән чыгарырга ярамый.

Шулай да юлын таптык... Ахунҗанга, фронт командующие килү уңаеннан, полкны гарнизон парадына алып чыгу хакында приказ җибәрелде. Шик тудырмас өчен, полкны яңадан киендерергә, байракларны алып чыгарга һәм патронсыз кораллар белән чыгарга тәкъдим ителде. Ул үзе исә полкның башка командирлары белән берлектә, парад алдыннан клубка, командующий янына кыскача киңәшмәгә чакырылды.

План начар уйланмаган иде. Парадта без гаскәрләрне һәр басмачы каршына ике кызылармеец туры килерлек итеп урнаштырдык. Шуның өстенә басмачылар атларын тезгеннән тотып тора. Бусы да бер өстенлек бирә — куллары буш буласы түгел. Минем сигнал буенча кызылармеецлар аларның мылтыкларын тартып алырга тиеш... Ә ул арада, үзенең сакчылары белән берга, Фрунзе Ахунҗанны һәм аның курбашыларын коралсызландыра.

Андый-мондый очракка дип, якын-тирә тыкрыкларга һәм урам чатларына пулеметлы повозкалар урнаштырдык, вокзал янында һәм ишегалларында хәрби төркемнәр тупланды. Әндиҗан тирәсенә атлы частьлар җибәрдек. Шәһәрдән чыгарга маташкан теләсә нинди басмачылар отряды алар уты астына килеп керәчәк иде.

Ләкин операцияне никадәр генә уйлап эшләсәк тә, кайбер моментларны исәпкә алып җиткермәгән булып чыктык. Аларның беренчесе, басмачыларның парадка корылган мылтык белән килү мөмкинлеге. Икенчесе, парад карарга дип тыныч халыкның да җыелуы. Болар, атыма атланып, мәйданга якынлашкач, аның халык белән тулы икәнен күргәч кенә башыма килде. Парадның «өйрәнү өчен» генә үткәрелүен аңлату да, читкәрәк, өйләр янына китеп торырга үгетләү дә ярдәм итмәде, бөтен кеше диярлек сугышчылар янында айкала иде.

Трибунага күтәрелеп мин гаскәрне сугышчан операцияләрдәге уңышлары белән тәбрик иттем һәм Ахунҗанның буйсынудан чыгуы, аның полкына коралын ташлатырга тәкъдим ителү турында фронт командующие приказын укый башладым... һәм сигнал бирдем. Ләкин кызылармеецлар винтовкаларны ала башлауга кемдер атып җибәрде. Тәртипсез ату тавышлары яңгырады, паника күтәрелде, чатлардагы пулеметлар телгә килде. Үзебезнекеләргә: «Атышны туктатыгыз!» — дип күпме кычкырсам да, мине басмачыларның берсе дә ычкына алмас».— дип күпме кычкырсам да, мине ишетүче юк иде инде. Трибунадан атылып төштем дә, кул астына эләккән беренче атка атланып, клубка чаптым. Ахунҗанны һәм аның курбашыларын коралсыз-

ландыру ничек үткән дигән сорау тынгылык бирми. Аларның да коралларында сугышчан патроннар булырга мөмкин.

Бераз дулкынланганы сизелгән Фрунзе болдырда басып тора иде. Ул операциянең үзенә тигән өлешен инде тәмамлаган булып чыкты. Дөрес, монда да бәрелешсез генә булмаган.

Үзенең үндүрт курбашы белән Ахунҗан килеп кергә Михаил Васильевич аларның барысын да өстәл янына чакыра. Бер якка штаб работниклары белән үзе утыра, икенче якка Ахунҗан кешеләренә урнашырга тәкъдим итә.

Шунда ук турыдан-туры җитди сүзгә дә керешә.

— Реввоенсовет сезнең буйсынудагы полкны Ташкентка җибәрергә карар бирде,— ди Фрунзе.

Ахунҗан каршы төшә:

— Мин полкны моннан алып китмим. Әгәр без китсәк, балаларыбыз, гаиләләребез яклаучысыз, мөлкәтебез саклаучысыз калачак.

— Әндиҗанда Татар бригадасы частьлары бар,— дип тыныч кына каршы төшә Михаил Васильевич.— Шәһәр халкының иминлеген алар тәэмин итәчәк.

— Ләкин без Әндиҗаннан китәргә теләмибез,— Ахунҗанның тавышы кискенләшә.— Бу — безнең шәһәр, без монда яшибез. Саклавын да үзебез саклар-быз.

— Кызыл Армия Әндиҗанны гына түгел, Төркестанның бөтен хезмәт ияләрен Совет власте дошманнарыннан саклый,— дип элеккеге тынычлык белән дәвам итә Фрунзе.— Һәм сез, Кызыл Армиядә хезмәт итәсез икән, аның тәртипләренә буйсынырга, командующий боерыгын үтәргә тиешсез.

Ахунҗан Фрунзеның әнә шул үз-үзенә нык ышанган тынычлыгын күтәрә алмый, урыныннан сикереп торып, кычкырып җибәрә:

— Әйттем бит инде, без моннан беркая да китмибез!

Шул чакта Михаил Васильевич тора да кулын басмачыга сузып, кырыс һәм катгый тавыш белән:

— Коралыңны тапшыр! — ди.

Ахунҗан ачу белән кобурасыннан маузер тартып чыгара һәм командующийның күкрәгенә төби. Курбашылар урыннарыннан сикерешеп тора. Фрунзе, дулкынлануын сиздермичә, берни әйтмәстән туп-туры Ахунҗанның күзләренә карый. Аның карашы тыныч, һәм шул ук вакытта таләпчән, кырыс та була.

— Мә, ал! — дип кычкырып җибәрә Ахунҗан һәм маузерын өстәлгә ташлый. Башка курбашылар да аның үрнәгенә иярә.

...Данлы полководец тормышындагы бу эпизодны мин соңрак белдем. Ә килеп җитүгә Фрунзега мәйдандагы хәл турында сөйли башладым. Сөйләп тә бетермәдем, клуб янына сугышчылардан берәү килеп житте һәм басмачыларның каршылыгы бастырылу, аларның корал ташлаулары турында хәбәр итте.

Фрунзе боларны сабыр гына тыңлап торды һәм корал тапшырган барлык сугышчыларга аларның Совет законнары яклавында булуларын, аларга карата бернинди эзәрлекләү үткәрелмәячәген белдерергә кушты.

...Ә алда — Бохара юлы. Безне Бохар әмире кулы астында изелүчеләр көтә.

Бохара ханлыгына сәфәребез шактый авыр булып чыкты. Бәрелешләр аяусыз, дошман тәҗрибәле. Шуның өстенә ул җирле шартларны һәм гадәтләрне биш бармагы кебек белә, шушы «корал»ны безгә каршы даими файдалана.

1917 елгы революциягә кадәр гаять зур бу төбәкнең аерым хәлдә булуын да искәртеп үтәргә кирәк. Патша хөкүмәте бик хәйләкәр политика үткәреп килде. Инглиз колонизаторларыннан аермалы буларак, ул халыкның эчке эшләренә тыкшынмаган булып кылана, чынлыкта исә һәр вакыйганы җентекләп күзәтеп бара һәм хөкемдарларның халык өстеннән кыргыйларча башбаштаклык итүенә юл куя гына түгел, аны хуплап тора.

Бөек Октябрь революциясеннән соң, Бохара әмире, Англия империализмы яклавына таянып, хезмәтчел халыкка карата канлы террор политикасын дәвам иттерде — асты, үтерде, теләсә нинди революцион чыгышны аяусыз бастырып килде. Шундый авыр шартларда яшәүгә дә карамастан, ханлыктагы гади халык үз тавышын ишеттереп кенә калмады, кансыз хөкемдарга каршы кулына корал тотып көрәшкә күтәрелде. Халык Бөек Октябрь социалистик революциясе, Совет хөкүмәте декретлары, аерым алганда, Җир турында, «Россия халыкларының хокуклары Декларациясе» турында ишетеп белде. Бөек Ленин исеме телдән-телгә күчеп йөри башлады.

1920 елның августында коммунистлар партиясе һәм яшь бохаралылар партиясе әмир залимлыгына каршы коралды баш күтәрү турында чакыру таш-

лады. Ул хезмәтчел дехканнар, шәһәрләрдәге күпсанлы һөнәрчеләр, мамык чистарту заводлары эшчеләре, тимерьюлчылар һәм зыялылар йөрәгенә юл тапты.

Әмма Иске Бохара крепостена кереп оялаган әмирне бәреп төшерү җиңел эш түгел иде. Крепость ныгытылган, стеналары нык һәм биек, сакта торучы отрядлар хәрби бәрелешләргә өйрәтелмәгән тыныч халыкны бик җиңел кырып ташлый алачак. Менә шуңа күрә дә Бохара әмирлегенең революция яклы кешеләре ярдәм сорап Совет хөкүмәтенә мөрәҗәгать итте. Ярдәм озак көттермәде.

Һәм Кызыл Армия гаскәрләре туганнарыбызга ярдәмгә килде. Бохара гаскәрләре регуляр частьлардан һәм үз коралы белән коралланган ополченецлардан, ягъни наукерлардан тора. Пехотада да, кавалериядә дә төп тактик берәмлек «байрак» дип атала. Аларның һәрберсендә ике йөзәр сугышчы. Коралланууга килсәк, әмир гаскәрләрендә рус һәм инглиз винтовкалары, иллегә якын пулемет, ике йөзләп туп бар. Һәр сугышчыда кылыч, гранаталар җитәрлек. Ханлыкның үзендә дары заводы эшләп тора.

Фрунзе боерыгы белән Татар бригадасының 10 нчы һәм 12 нче полклары Бохара янына җибәрелде. Алар исә гаскәрнең уң канатына кушылдылар, аларга шулай ук 1 нче һәм 4 нче кавалерия полклары, бронепоезд, бронеотряд, авыр артиллерия һәм бохаралыларның коммунистик отряды кертелде. Бохара янына тупланган безнең гаскәрләр составында җиде меңгә якын штык, ике мең биш йөз кылыч, утыз биш җиңел һәм биш авыр туп, биш бронепоезд һәм унбер самолет бар иде. Әйе, ул вакытта ук инде коралланууда самолетлар бар иде. Мондый көч белән Бохара әмиренә барып була иде.

Коммунистлар һәм яшь бохаралыларның баш күтәрүе безнең һөҗүмгә сигнал булып хезмәт итте. Алар 28 августта Чарджоу шәһәрендә ревком оештырып, шуннан Иске Бохарага һөҗүм башлап җибәрделәр.

29 август таңында Кызыл Армия полклары һәм Бохараның үз отрядлары артиллерия хәзерлегеннән соң, дүрт яктан крепостька һөҗүм иттеләр һәм икенче көн ахырында аның калын стеналарына якынлаштылар. Бик күп сынаулар үткән, эсселек һәм сусызлыктан җәфа чиккән безнең гаскәрләргә киң колачлы операциянең чираттагы өлешен тормышка ашырырга: калын стеналарны җимереп, крепостька үтеп керергә һәм әмир сараен кулга төшерергә кирәк иде.

Беренче сентябрь иртәсендә Бохараның соңгы әмире крепостен штурмлау башланды. Калын диварлар артына яшеренеп еллар буе үз илен, гади кешеләрне, гөлбакчага тиң якның хезмәт ияләрен талап килгән әмирнең крепосте иде ул... Бохараның революцион гаскәрләре һәм Кызыл Армия частьлары крепостька бәреп керделәр һәм дошманның аяусыз каршы торуына, һәр биек җирдән, түбәләрдән ут яудыруына карамастан, әмир сараена килеп җиттеләр.

Ниһаять, сарай кулга төште. Качып котылган бердәнбер кеше Бохара әмире үзе иде. Ул әле 31 августка каршы төндә үк крепостьтан чыгып качкан. Әлбәттә, явыз, канечкеч ерткычны кулдан ычкындыру аяныч. Ләкин әһәмиятле җиңү бу «югалту»ны тулысынча каплый иде.

Иң мөһиме — Кызыл Армия үзенең көч-куәтен, какшамас ныклыгын тагын бер кат күрсәтте, Төркестан һәм Бохара шартларында ленинчыл милли политиканы хәрби стратегия белән уңышлы үреп алып бара белгән полководец Фрунзеның бөек таланты тагын бер җиңү белән расланды. 1920 елның 1 сентябрендә Ленинга җибәргән телеграммасының беренче юлларында ук шушы берлек бик ачык итеп әйтелә:

«Бүген Бохараның Кызыл частьлары һәм безнең көчләрнең уртак тырышлыгы белән Иске Бохара крепосте алынды. Регистан өстендә Бөтендөнья революциясенең Кызыл Байрагы җилферди. Әмир һәм ияренчеләренең калдыгы качып китте, аларны тоту чаралары күрелә. Үзәк һәм Төньяк Бохарада инде революцион режим урнашты. Россия һәм Бохара Кызыл Армиясе гаскәрләре Төркестан һәм бөтен Россия эшче-крестьяннарын шатлыклы хәбәр белән котлыйлар».

Фронт командованиесе безнең берләшмәләр хәрәкәтен югары бәяләде. Катлаулы һәм канкойгыч операциядә катнашкан барлык сугышчыларга, командирларга һәм политработникларга Фрунзе рәхмәт белдерде.

Җиңүчеләр һәм азат ителгәннәрнең уртак шатлыгында аерым мәгънә бар иде: әмирлекнең тар-мар ителүе, әмирнең качып китүе Бохараның гади халкына гүзәл һәм якты киләчәккә юл ачты.

Ә безнең юл — Татар бригадасы полкларының юлы — яңадан Фирганәгә барып тоташты. Шәһәргә кайтып җитүгә ук сугышчылар «гадәти» задание — басмачыларны тар-мар итү заданиесе алдылар. Мондый сугыш әле һаман дәвам итә иде. Әмма Кызыл Армия частьларының уңышлы операцияләре

нәтиҗәсендә инде ул акрынлап сүнеп килә. Ә Курширмәт, Парпи, Казак-би, Аман-Палван, Исламкул һәм Рахманкул бандалары юк ителгәннән соң гомумән тынлык урнашып калды. Дөрес, ул күк күкрәү алдыннан була торган сәер тынлык иде. Исән калган басмачылар төньякка, таулы районнарга үтеп Мөәтдин бәк кул астына туплана башлады, ә анысы үзен «ислам гаскәрләре»нең башкомандующие дип игълан итте.

Бу игътибарсыз кала алмый иде, әлбәттә. Фронт командующие һәм дивизия командиры приказы белән безнең бригада 1920 елның октябрендә Ош-Җәләлабад хәрби районына озатылды һәм нигездә Иске Нәүкәт, Яңа Нәүкәт, Базар-Курган, Узген, Гөлчә, Лянгар пунктларында — Кытай (Иркештам) һәм Әфганстан (Хорог) чикләрендә урнаштырылды. Штаб һәм идарә Ош шәһәрендә урнашты.

Ул чорда Мөәтдин белән бары тик сугыш телендә генә сөйләшергә мөмкин иде. Хәер, катлаулы, капма-каршы мәсьәләләрне тыныч юл — сөйләшүләр нигезендә хәл итү ихтималын да күздән ычкындырмыйбыз. Халыкка пролетариат революциясенең асылын һәм сәбәпләрен аңлатуда, басмачылык һәм буржуаз милләтчелекнең чын йөзен фаш итүдә армый-талмый эшләүне бурычыбыз дип саный идек. Бу катлаулы һәм куркыныч эштә кыю, батыр политработниклар — Татар бригадасы хәрби комиссарлары Садыйков, Солтанов, Бурнашев, Шакиров аеруча яхшы эшләделәр. Фирганәдә тупланган пропаганда эшенең бай тәҗрибәсен оста кулландылар.

Чик сакчылары, политруклар һәм командирларыбыз аркылы ерактагы чик буе пунктларына листовкалар һәм политик әдәбият җибәрәбез. Көч туплап килүче пролетариат дәүләтенең барлыкка килүе һәм аның беренче еллары турындагы хәбәрләр ерактагы кышлакларга барып ирешә, кешеләр күңелендә өмет чаткысы уята.

Халык арасында политик эш алып бару белән бергә безнең частьлар Мөәтдин бәк бандаларына каршы кискен сугыш хәрәкәтләрен дәвам иттерәләр. Халыкта таянычын югалткан бандитлар ризасызлык күрсәткән һәркемгә шунда ук җәза бирә, ә инде кемнең дә булса Совет власте ягына күчәргә җыенуы сизелсә, аны үлем көтә.

Мөәтдин безнең частьларга чын-чыннан каршы тора алырлык «мөселман армиясе» булдырырга көчәнә. Ул үзен хәтта кяферләргә каршы изге сугыш — газават башларга алла тарафыннан җибәрелгән пәйгамбәр дип игълан итәргә үк җыена иде.

Безгә калса, аның нинди пәйгамбәр икәне күптән билгеле. Чыгышы белән ул Маргелан өязендәге Иске Нәүкәт волостеның Күк-Җар дигән кыргыз кышлагыннан. Ыруы үз вакытында гаять бай булган. Ләкин моның белән генә канәгатьләнмичә, Мөәтдин балачагыннан ук урлаша башлый һәм инде унсигез яшенә җиткәндә караклык өчен берничә тапкыр хөкем ителгән була. Февраль революциясеннән соң ирекккә чыга һәм башкисәрләр өерен җитәкли, кыңгыр эш өчен кем күбрәк түли, шуларга хезмәт күрсәтә башлый. Өч йөз кешедән торган шушы өер соңрак Мәдәмин бәк отрядларына кушыла, ә аннан соң Мөәтдин үзе дә күп санлы басмачыларның җитәкчесенә әйләнә.

Болар шактый актив группалар иде. Алар Җидесу өлкәсенә үтеп керәләр, контрреволюцион кулаклар, Анненков һәм Семенов бандалары калдыклары белән кушылалар. Әгәр революциягә, Совет властена каршы көчләрнең бу куркыныч берләшүен туктатмасак, Урта Азиядәге казанышларыбызны саклап калу авыр булачагы аңлашыла. Контрреволюцион көчләрнең үсүенә юл куймаска, аларны бер-берсеннән аерырга һәм Верный (хәзер Алма-Ата), Әулия-Ата (Джамбул), Пишпек (Фрунзе), Копал һәм башка төбәкләрдәге акгвардияче отрядларны юк итәргә кирәк иде. 1920 елның азагында Төркестан фронты командующие Татбригаданы Җидесуга күчерү турында боерык бирде.

Яңа, 1921 елны без юлда каршы алдык. Ә беренче январьда Ташкентка килеп җиттек. Эшчеләр, интеллигенция, яшьләр, Үзәк башкарма комитет членнары бригада сугышчыларын һәм командирларын туганнарча җылы каршыладылар. Безне кунакка чакыралар, пылау, җиләк-җимеш тәкъдим итәләр.

Иске Ташкенттагы Яңа ел кичәсе аеруча истә калган. Анда партия һәм совет активы, артистлар, язучылар һәм шагыйрьләр җыелган иде. Яңа елны билгеләп үтү белән бергә Татар бригадасы килеп җитү дә бәйрәм ителде. Безгә дусларча бик күп котлаулар, җылы сүзләр, теләкләр әйттеләр, рус, татар, үзбәк һәм күпмилләтле Ватаныбыздагы башка халыклар дуслыгы хөрмәтенә тостлар яңгырады. Болар бик тәэсирләндерде һәм күп елларга хәтергә сеңеп калды.

Ләкин... Ташкентта озак торып булмый иде. Безне сугышчан эшләр көтә.

Январь һәм февраль айларында эшелоннар кар көртләре һәм бураннар аша алга үтәргә тырыштылар. Бригада Әүлия-Ата һәм Бурное станциясеннән алып Карасуга кадәр гаять зур арада таралып калды. Штаб исә үзенә беркетелгән частьлар белән, Әүлия-Атада бушатылды, коточкыч пычрак, бернигә ярамый торган юл буйлап Пишпеккә чыгып китте.

Минем үземә вакытлыча бригаданы калдырып торырга туры килде. Моның бик мөһим сәбәбе бар: партиябезнең X съездына Төркестан коммунистлары мине дә делегат итеп сайлаганнар иде.

Мин Ленинны тагын күрдем. Аның сөйләгәнен ишеттем, ничек эшләгенен белдем. Һәм иң мөһиме — партия форумы ачылыр алдыннан делегациябез составында дөнья пролетариаты юлбашчысы белән әңгәмәдә катнаштым.

Съездан мин туры Әүлия-Ата станциясенә килеп төштем һәм, бригаданы тизрәк куып житү өчен, елгыр һәм күндәм өч ат жиктердем. Жилдереп кенә үтәрмен дә озакламый дусларымны күрермен, аларга юлбашчы белән очрашуым турында сөйләрмен дип уйлаган идем. Юл газабы — гүр газабы дип белми әйтмәгәннәрдер... Безнең частьлар бер ай диярлек атлаган юл бу. Арба тәгәрмәчләре сазга бата, ватыла, хәлдән тайган кешеләр соңгы көчләрен жыеп, аларны ябышкак ләмнән сөйрәп чыгара. Шулай итеп, сугышчылар Пишпеккә 1921 елның февраль азагында — март башларында гына барып житә.

Озын сүзнең кыскасы — Жәләлабадтан Пишпеккә кадәр юлны үтү безнең өч ай вакытыбызны алды. Юл буена сибелгән рус поселокларында азык-төлек мулдан. Бердәнбер юанычыбыз шул. Бөтен ил ачлыктан интеккән вакытта Черняево, Беловодское, Троицкое кебек еракта урнашкан жирләрдә кулаклар он һәм итне яшереп саклыйлар. Һәркайда суктырылмаган ашлык эскертләре. Һәр кулакта жигеп йөрү өчен генә дә ким дигәндә өчәр ат, бернечә бүлмәле өй, абзар тулы сарык, сыер, башка мал-туар.

Жирле кулакларның болай иркен яшәве байгураларга «ләббәйкә» дип торган Вакытлы хөкүмәт эмиссарлары политикасының нәтижәсе иде. Бу эмиссарлар 1916 елдагы вакыйгаларда зыян күргән Жидесу өлкәсенә ярдәм күрсәтү сылтавы белән ярдәмгә мохтаж ярлыларга түгел, ә кулакларга, Шуран Исламия белән Алаш-Орда байларына һәм милләтчеләренә булышалар иде.

Совет власте исә бөтенләй башка политика үткәрә. Кызыл Армия отрядлары жирле большевикларны кулак фетнәсен бастырырга, халыкка тыныч тормыш корып жибәрергә ярдәм итәләр. Ләкин... моның бөтен кешегә дә ошап житмәгәнен искәртергә тиешбез. Контрреволюция һаман шашына. Без Жидесу өлкәсенә килеп житкәндә, Анненков, Семенов, Щербаков өерләре тар-мар ителгән, атаманнары чит илләргә качып өлгергән иде инде. Шуннан торып алар кулаклар һәм басмачыларга житәкчелек итәләр, Кыргызстан, Казахстан шәһәрләренә, авылларына басып керәләр.

Менә шуңа күрә командование Татар бригадасының Жидесуга килүенә зур өмет баглады да.

Яңа сугышчылар белән тулыландырылган һәм ныгытылган Татар бригадасы куәтле хәрби берләшмә тәшкил итә. Уңышлы сугышчан операцияләр нәтижәсендә 1921 елның маена короллы бәрелешләр бетте диярлек, без, асылда, тыныч политик бурычлар һәм хужалык мәсьәләләрен хәл итәргә керештек. Аерым алганда, сугышчыларны өйрәтүне, бигрәк тә, тез атарга өйрәтүне көчәйттек, кызылармеецлар арасында наданлыкны бетерү дәресләре һәм политик әңгәмәләр үткәрә башладык.

Беренче Майны тыныч шартларда билгеләп үттек...

Бу көнне политбүлек хезмәткәрләре һәм часть командирлары сугышчылар белән әңгәмәләр үткәрделәр, партиянең X съезды һәм юлбашчыбыз Ленин турында сөйләделәр. Бәйрәм хәрби частьлар парады белән тәгәлләнде. Аннан соң халыкны бригада торган урынга чакырдык.

Безнең кунакчыллыкка ярлы халык та шундый ук киң күңеллелек белән жавап бирде. Бер айлап та вакыт узмагандыр, алар безнең өчен дә бәйрәм ясадылар. Милли бәйрәм.

Еракта калган ул көннәргә бәя биргәндә, Жидесуда Татар бригадасы эшчәнлегенең политик әһәмияте хәрби әһәмияткә караганда зуррак булды дисәм, ялгышмамдыр. Халык арасында киң рәвештә алып барылган аңлату һәм сәяси эшчәнлек нәтижәсендә жирле совет һәм партия органнарының абруе ныгыды, ленинчыл милли политиканы тормышка ашыруга юл ачылды. Хәрби эшчәнлегем тарихында беренче тапкыр буларак, зур берләшмә бер генә тапкыр да атмыйча гаять зур һәм мөһим жиңү яулады дип әйтсәм килә. Аерым

шәһәрләр һәм крепостьлар яулап алу гына түгел ул. Без тагын да зуррак һәм мөһимрәк нәрсә — кешеләр йөрәген, аларның безнең идеалларга инануын яулап алдык.

...Ләкин кирәк чагында... безнең пулемет һәм винтовкалар да телгә килде. 1922 елда Татар бригадасы Төркестан фронтының башка частьлары белән кушылды. Мәүлетов җитәкчелегендәге Уникенче Төркестан укчы полкы фронт штабы карары белән Көнчыгыш Бохарага җибәрелде һәм анда, башка берләшмәләр составында Әнвәр паша бандаларын тар-мар итүдә катнашты. 1922 елның 4 августында Оби-Дәрья кышлагы янында (Көнчыгыш Бохара) җан сакчылары белән атакага ташланган Әнвәр паша үтерелде.

Мөәтдин бәк язмышы да үзенең логик йомгагына килеп җиткән иде. Отрядларын тәэмин итү мөмкинлегеннән мәхрүм калгач, ул юха елан шикелле боргаланырга керешә һәм тагын сөйләшүләр башлап җибәрде. Әмма мондый тактика Мөәтдингә бераз тын алу, азык-төлек һәм корал туплау өчен генә кирәк икән. Июнь аенда ул тауларга китте һәм яңадан безнең гарнизоннарга һөҗүм башлады. Табигый ки, моны җәзасыз калдырып булмый иде. Без Мөәтдин артыннан куа киттек, һәм тауларда киеренке сугыш хәрәкәтләре башланды. Аларның берсе юлбасарлар башлыгы өчен фаҗигале тәмамланды: отрядлары тар-мар ителде, ә ул үзе кызылармеецлар кулына төште. 1922 елның 26 сентябрендә Ош шәһәрендә Мөәтдин һәм аның яраннары өстеннән күргәзмә суд уздырылды. Анда меңнәрчә кеше катнашты. Җәмәгать гаепләүчесе Түрәкуловның рече хезмәт халкы дошманнарын юк итәргә какшамас омтылыш белән сугарылган иде. Дөрес һәм ачыктан-ачык сөйләнгән бу сүзләр барысын да тирән дулкынландырыды.

Басмачыларга мөрәҗәгать итеп ул болай диде:

— Сез, үзегез әйткәнчә, мөселман халыклары вәкилләре һәм юлбашчылары түгел. Сез дус та түгел. Сез — карчыгалар, үләксә козгыннары. Гадирәк итеп әйткәндә — юлбасарлар һәм үтерүчеләр. Чын йөзегез шундый!

Гаепләнүчеләрдән сорау алып, йөздән артык шаһитны тыңлаганнан соң суд каты, әмма гадел хөкем карары чыгарды.

Мөәтдин бәкнең хәрби карьерасы, ә төгәлрәк әйтсәк, юлбасарлык язмышы шулай төгәлләнде. 1923 ел ахырына басмачыларның башка зур төркемнәре дә юк ителде.

Бу яклардагы халыклар, ниһаять, җиң сызганып, тыныч иҗади хезмәткә керешә. Совет һәм партия органнарының эше бер эзгә төшә башлады. Урта Азия республикалары интенсив социалистик үсеш юлына басты. Башка бик күп республикалардагы шикелле үк, коммунистлар партиясе җитәкчелегендә меңнәрчә кешеләр кыска гына вакыт эчендә гасырлардан килгән экономик һәм культура артталыгын җиңеп, экономика, промышленность һәм авыл хуҗалыгын яңа биеклекләргә күтәрделәр.

Татар бригадасының Урта Азиягә походы ветераны буларак, оҗмахка тиң бу гүзәл якларның чәчәк атуында сугышчан дусларымның һәм үземнең дә өлешне тою мина бик күңелле, әлбәттә. Азатлык хакына китергән корбаннарыбыз искә төшсә, күңелне моң, сагыш баса, ләкин алар берсе дә бушка китмәде. Татар, үзбәк, казах, кыргыз, таҗик, рус халыкларының туганнарча дуслыгы иң яхшы уллары һәм кызларының каны белән дә мәңгелеккә ныгытылган. Бу дуслыкны, бөек пролетар туганлыкны, күпмилләтле гаиләбезнең бердәмлеген, бөек Ленин идеяләренә тугрылыкны какшатырлык көч юк.

Без бердәмлек белән көчле. Яшь республиканың беренче җиңүләре чорында да, эчке һәм тышкы дошманнарга каршы көрәш елларында да шулай иде. Бөек Ватан сугышының гаҗәеп хәсрәтле, авыр елларында да без бердәмлек, батырлык, рухи инанганлыгыбыз һәм ныклыгыбыз белән көчле булдык. Һәм хәзер дә, илебез экономиканы, промышленностьны, культураны үстерүдә моңарчы күрелмәгән үрләргә ирешкәндә дә шулай.

Флүс **ЛАТЫЙПОВ** тәрҗемәсе.

## Хәниф Хөснуллин

# ДУСАЙ-КИЧҮ

1

Җиңел түгел ул еллардан
Бүгенге көнгә күчү...
Ык буендагы авылның
Исеме — Дусай-Кичү.
Җәяүле булса да буран
Кар чөеп күккә, уйный...
Үз көне һәм ил язмышы
Турында авыл уйлый.
Ә ул язмыш гади түгел,—
Өермәле, катлаулы.

Һәлакәтле сугыш бара,
Шуның аша атлавы...
Төннәр озын, көннәр кыска,
Төннәр белән көн катыш.
Көнбатышта сугыш бара.—
Өмет белән моң катыш,
Әнә шундый уйлар белән
Борчулы Дусай-Кичү...
Җиңел түгел ул еллардан
Бүгенге көнгә күчү.

2

Карлы юлдан атлы бара,
Салкыннан йөзе яна.
Салулап та ала кайчак —
Уйнаклый җиңел чана.
Дилбегәсен кага атлы,
Юлчыга карый тыйнак.
Ә ул — бу юлда беренче
Хәрби киемле кунак...
Билгеле инде татарның
Чәй һәм коймакчыллыгы.
Язмышыннан ашып тора
Шәфкать-кунакчыллыгы.
Капкасын ачар каерып,
Ишеген ачар һәр өй.
Тик бүген бөтен авыллар,
Барча шәһәрләр хәрби.
Күптән шулай, ирегенә
Дошман янаган мәлдә,
Басулар да солдат була,
Бөтен ил хәрби хәлдә.
Әнә бит юлда атлы да,
Сөртә дә керфек карын,
Юлчысына әйтеп куя
Күңелендә нәрсә барын:

— Менә сез,— ди,— шагыйрь иптәш,
Үзегез хәрби кеше.
Ничегрәк тора икән
Тегендә фронт эше...
Ачыклык теләп кертергә
Газеталар сүзенә
Муса да бит ул сорауны
Кат-кат бирә үзенә.
Җиңел чана бара юлда
Сай эзләр сызып кына.
— Фронт — фронт инде, абзый,—
Ди Муса сузып кына.
Күңеле тарта Көнбатышка,
Тарта ут арасына.
Үзе дә ышанып йөри
Тиз көндә барасына.
Ә хәзергә Минзәләдә
Хәрбигә укый әле,
Фашистларны кыйнар өчен
Көч-белем туплый әле.
Табигатең җор булса да,
Кирәктә тыя өйрән:
Юлда чана эзләре сай,
Сугыш ярасы тирән.

3

Ярсый йөрәк, ярсый йөрәк,
Бу бит иң изге ярсу.
Җилдә җилфердәгән саен
Байраклар нинди алсу!
Ат чабып керә авылга,

Бәйгедә килгән сыман.
Һәм өйләр үз шагыйренә
Сәламен биргән сыман.
Шуларгамы әллә сөйләп
Эч серен бушатасы...

Аны да кетә Уралда
Авылы — Мостафасы...
Каратып Мусаның уен
Үткән елларга таба,
Җиңел чана тирәсенә
Җыела бала-чага.
— Шагыйрь килгән...
— Муса абый...
Сөйлиләр кызып-кызып.
Кызык эзләгән балага
Авылда олы кызык.

Йөзе буйлап кан йөгерә,
Яңагы уттай яна.
Күрә Муса: вакыйгалар,
«Кызыклар» кабатлана;
Кайчан гына ул үзе дә
Нәкъ алар чаклы иде,
Кызыллы-аклы афәттә
Кызыллар яклы иде.
Ярсый йөрәк... ярсы, йөрәк,
Бу бит — иң изге ярсу.
Җилдә җилфердәгән саен
Байраклар нинди алсу!

4

Хуҗаларны киң күңелле
Кешеләр итеп юра:
Әхмәдиевләр өендә
Агач караваt тора.
Башка төрле инде тормыш,
Үзгәрде хәзер заман,
Алар агач караватны
Нигә саклыйлар һаман?—
Мендәр, җәймәләре ап-ак,
Пөхтә итеп җыелган.
Шушы агач караватка
Олы хәтер сыенган...

Ул чакта Дусай-Кичүдә
Төн дәвамы — көн туса,
Идарәгә, я фермага
Юл алган хәрби Муса.
Фермаларда хатын-кызлар,
Төзәтә төшеп шәлен,
Бер-бер артлы сөйләткәннәр
Мусадан фронт хәлен.
Кич клубка кеше тулган,
Һәм көткән китапханә.
Ярсу шигърият һәм нәфрәт
Илчесе сөйли янә...

5

Кышкы иртә. Ат җигелгән.
Нәкъ юлга чыгар сәгать.
Озатканда, саубуллашу
Электән килгән гадәт.
Нәрсәдер онытkan сыман
Борчылып ала хуҗа.
Һәм аңа яңа бәйләнгән
Оек, бияләй суза.
Бияләе өч бармаклы.
Җорланып шагыйрь дәшә:
«Болай булгач фашистларны
Кыйнавы җиңелләшә».
«Еллар тынып, вактың булгач,
Тагын, диеп, кил безгә»,—
Дусай-Кичү — кунагына
Киез итек кигезә...

И авыл, зур булмасаң да,
Рухың белән олы син.
Илең яуласы җиңүнең
Ышанычлы тылы син.
Атлы абзый юлга чыга,
Шәһәргә кунак илтә.
Ә алда аның кунагын
Дәһшәтле фронт көтә...
Хуҗаларны киң күңелле
Кешеләр итеп юра:
Әхмәдиевләр өендә
Агач караваt тора...
Ярсый йөрәк, ярсы, йөрәк,
Бу бит иң изге ярсу...
Җилдә җилфердәгән саен
Байраклар нинди алсу!

**Рәис Сафаров,**
Бөек Ватан сугышы ветераны,
отставкадагы капитан.

# ҺӘЛАК БУЛГАН СОЛДАТ ЯЗМАЛАРЫ

Телевизор каршында утырам. Беренче программа буенча Мәскәүдән «Миллионнарның Ленин университеты» дигән тапшыру күрсәтәләр. Алып баручы озынчарак битле, күзлекле, минем яшьләрдәге ир кеше. Озакламый аста язу да күренде: «Мәскәү дәүләт университеты профессоры, юридик фәннәр докторы Николай Андреевич Сидоров».

Бу фамилия русларда шактый күп таралган. Шуңадырмы, башта әллә ни игътибар бирмәгән идем. Тик шулай да бу кеше миңа ничектер таныш күренә. Йөз чалымнары да, сөйләү рәвеше дә бик якын кешемне хәтерләткән кебек. Туктале, тукта! Минем батальондагы рота командиры кече лейтенант Коля Сидоровка бераз охшый түгелме соң?

Тапшыру тәмамлануга, Үзәк телевидениегә сорауларымны язып җибәрдем: профессор Н. А. Сидоров 1942 елда Сталинград сугышларында катнашмаганмы? Катнашса, 37 нче дивизия составындагы 109 нчы полкның икенче батальонында рота командиры булмаганмы?» Үземнең кемлегемне, адресымны яздым.

Җавап озак көттермәде: «Хөрмәтле Рәис Галиевич! Котлыйбыз. Николай Андреевич сез эзләгән кеше булып чыкты. Аңа адресыгызны бирдек».

Берничә көннән телефоным шылтырады:

— Рәис, синме?

— Әйе, мин. Кем соң әле бу?

— Мәскәүдән, Коля Сидоров! — Йөзләрчә чакрым араларны үтеп, колагымда яшьлек дустымның сөенү катыш гаҗәпләнүле тавышы яңгырады:

— Рәис, син исәнмени?

— Ишетәсең ич: исән, Коля!

— Син бит үлгән идең... Үлгәнеңне үзем күрдем, минем кулда үлдең бит!..

— Үлгәнемне хәтерләмим. Ә менә терелгәнем әле дә истә.

— Болай телефоннан гына барысын да сөйләшеп булмас. Тот та хәзер үк юлга чык! Сабырсызлык белән көтәм!

7 май кичендә «Татарстан» поезды мине Мәскәүгә алып китте.

Төн. Пассажирлар йокыга талган. Вагонда тынлык. Ә миңа йокы килми. Күз алдымнан Коля Сидоров, Петр Колотильщиков, Ваня Гречко, Мансур Вафин, Гриша Харахашьян һәм башка яшьтәшләр белән бергә үткән авыр сугыш көннәре уза.

Революция елларында «Кремль курсантлары мәктәбе», ә соңыннан «РСФСР Верховный Советы исемендәге пехота училищесы» дип аталган уку йортын сугыш башланган көннәрдә тәмамлаган идем. Гимнастерка якаларымда икешәр кубик. Немец телен дә ярыйсы гына сукалаганымны белеп, мине РККА (Эшче-крестьян Кызыл Армиясе) генераль штабы каршындагы хәрби разведка идарәсенә билгеләделәр.

Һәм менә безне, ягъни һава десантчыларының 1 нче корпусын, 37 нче укчы гвардия дивизиясе итеп үзгәртеп, Сталинградны сакларга, Дон ярларына җибәрделәр. Ә мин батальон штабы начальнигы итеп билгеләндем.

...Идел белән Дон, кавышырга теләгәндәй, Сталинград турысында дуга сыман бөгелеп бер-берсенә якынаялар.

Уйсулык, әрәмәлекләрне ярып Донның берничә тармагы сузылган. Мондагы кичүләр өчен 1942 елның июль-август айларында безнең гаскәрләр каты сугышлар алып барды. Әгәр шул көннәрдәге Совинформбюро хәбәрләренә күз салсагыз, күрерсез, ай буе бер үк төрле сводка бирелгән: «Дон буенда Вертячий, Хлебный хуторлары янында аяусыз сугышлар дәвам итә».

Полк иң хәтәр участокта, Хлебный хуторы янындагы басуда позицияләр алды. Бераз югарырак сирәк урман, ә артында дошман. Ә безнең хутор яр буенда ук. Тимерче алачыгы янында «Коммунар» комбайны тора. Бер ышык урын табып, хәрби картаны күздән кичермәкче идем. Шул ният белән комбайнның штурвал күперчегенә мендем, Сталинград өлкәсенең хәрби картасын җәеп салдым. Тирә-якта шактый күп авыл, елга-күл исемнәре безнеңчә икән ләбаса: Аксай, Сары сай (бу Царицын икән),

Актүбә, Калач, Камышлы, Балыклы, Нариман, Котлыбан, Бозаулык, Кортлык, Кара Ил, Елан, Кадреево, Яр-Ослан, Кече Үзән, Олы Үзән, Кайсак, Булак, Чир, Чиләк, Басарга... Соңыннан белдем: Дон елгасы да төркичә Тын сүзеннән һәм Нижний Новгородтан тыш (Горький шәһәре) Идел, Кама буйларындагы топонимик, гидронимик атамалар бөтенесе диярлек төрки сүзләрдән алынган икән.

Шулай уйланып торганда, немец самолетларының һөҗүме башланды. Якында гына бомба шартлады. «Минем» комбайн бераз селкенеп алды да урыныннан кузгалып, сикергәли-сикергәли, Донның текә ярына табан юл тотты. Картамны җыештырып, планшеткага салганчы, ул яр буена килеп җиткән иде инде. Бер мәлдән ул, ярдан Донга очачак. Әле каян, ничек төшәргә, сикерергә белми аптыраган шул мизгелдә, алда атлап барган бер егет комбайн тәгәрмәче астына алачык янында яткан бер түмәрне ташлады. Комбайн кинәт бер якка борылды һәм, авам дигәндә генә, туктап калды. Менә шулай очраштык без Коля Сидоров белән.

Иделнең уң ярында — Сталинград. Су буйлап илле километрга сузылган шәһәр тоташ ут эчендә. Хәтта Идел үзе дә... Ул да яна — дистәләрчә нефть, бензин резервуарлары шартлап, алардагы ягулык елгага утлы чишмә булып төшә дә Каспийга таба дөрли-дөрли ага. Йортларның гөрселдәп җимерелүе күренеп тора. Туплар шартлавы, автомашиналардан ату тавышлары ишетелә.

Болар барысы да күңелдә шомлы, шөбһәле тойгылар кузгата, бу ут, җәһәннәм эченнән чыгып, исән калып булмастыр ахрысы, дигән уйлар килә башлый. Дошманның бомбалары, миналары шартлавы астында безнекеләр Идел кичә. Елга өстендә пароходлар, катерлар, баржалар бик ашыгып йөзәләр. Әнә яр кырыена бер-бер артлы кечкенә пароходлар борыла: «Гаситель», «Надежный», «Пожарский», «Алтай», «Ласточка», «Абхазец», «Лена» баркаслары, «Лейтенант Здоровин» катеры.

Төн уртасында кичеп өлгерә алмаган безнең полк таң атканда гына баржаларга төялде. Шуны гына көтеп торгандай, фашистларның берничә дистә самолеты ач козгыннардай Идел кичүенә ябырылды. Хисапсыз күп минометлар ут ачты. Ярдан кузгалып киткән баржа, катерлар ут эчендә калды. Менә бер батальон төягән баржа өстенә авыр бомба төшеп шартлады, аны сөйрәп барган кәкре морҗалы иске буксир да яна башлады. Икенче бер бомба алдарак барган бер катерның уртасына ук туры килде. Исән калганнар су өстендә чапалана, кайсы ярга карап йөзәргә белмичә бөтерелә. Өстән дошман самолетлары пулеметлардан ут яңгыры яудыра. Күпләр йөзә дә белми, ахрысы, белгәннәре дә шинель белән, авыр йөкләр белән су өстендә озак тора алмадылар. Аларның кычкырып ярдәмгә чакыруы, үзәк өзгеч тавышлары әле дә колак төбендә яңгырый...

Сталинград урамнарында, йортларында, подвал, коридорларында моңарчы тарихта күрелмәгән, үрнәге белән дә, үзенчәлекле, каһарманлыгы белән дә тиңе булмаган искиткеч авыр бәрелешләр башланып китте.

Яр буенда безгә танкларга каршы һөҗүмгә ташлану өчен яндыргыч сыекча тутырылган шешәләр бирелгән иде. Таң атар-атмас, ярдан үрмәләп, югарыга күтәрелдек. Алма бакчасы янында немецларның берничә танкы тора иде.

Батальон командиры Бондаренконың да, минем дә, башкаларның да кулында әлеге шешәләр. Иелеп, танкларга каршы йөгерәбез. Бөтен тирә-як җимерелгән, аяк астында — таш, ватык кирпечләр.

Комбат шуларга абынып егылды, кулындагы шешәсе шартлады, һәм ул ут эчендә калды. Бу тере факелны күреп, фашист танклары пулеметлардан ут ачтылар. Ләкин без аларга якын ук килеп җиткән идек инде. Берәрттән дүрт танкларын яндырдык. Сталинград туфрагындагы бу беренче бәрелештә үк без дә берничә кешебезне югалттык.

Бондаренко үлеменнән соң, миңа, егерме бер яшьлек егеткә, батальон белән командалык итү йөкләнде. Җитмәсә, миңа терәк була алырдай комиссар да юк иде.

Инде десантта чакта — Дон буендагы каты бәрелешләрдә утлар-сулар кичкән, дары исен туйганчы иснәгән сугышчылар булсак та, шәһәр арасында, урамнарда, йортлар эчендә сугышу тәҗрибәсе юк иде. Разведка ясау аеруча читен булып чыкты: ят шәһәр, ят урамнар — бернәрсә таныш түгел. Йортларның күбесе җимерелгән, янган; кайсы урам, кайсы йорт кем кулында икәнен дә белеп булмый. Ату башлануын күргәч кенә, дошманның кайда икәнен белеп аласың. Шуның өстенә, без җиңелчә — десантчыларча гына коралланган: ППШ автоматы, граната, хәнҗәр... Рота һәм батальон минометлары, танклар, авыр артиллерия Иделнең теге ягында. Хәер, аларны кулланып та булмас иде, чөнки снарядларның кем өстенә төшәсе билгеле түгел. Ә дошман кулында барысы да бар — танклар, пушкалар, күп көпшәле минометлар... Сталинград күге дә — алар кулында. Мондый шартларда сугышу тактикасын без буйсындырылган 62 нче армия командующие генерал-лейтенант В. И. Чуйков уйлап тапты: дошман

самолетларының, авыр артиллериясенең туктаусыз бомбага тотуыннан, меңәрләп снаряд-мина яудыруыннан котылу өчен, сугышчан позицияләрне, штабларны һәм командалык пунктларын мөмкин кадәр алгы сызыкка якынлаштырырга; взвод, рота, батальоннар белән бердәм һөҗүм ясамаска, сугышны аерым йортларда, коридорларда, катларда алып барырга, моның өчен автомат, пистолет, граната, хәнҗәр белән коралланган кечкенә штурм группалары оештырырга. Бу группалар төн уртасында, таң атар алдыннан, яки кичке эңгер-меңгердә тизлек белән немецлар урнашкан йортларга ыргылып керергә, анда фашистларны кырып ташларга, йортта урнашып калырга тиешләр. Менә шушындый тактика нәтиҗәсендә алынган йортларның берсе — Сталинградның батырлык мирасы булып әверелгән Павлов йорты хәзер бөтен дөньяга билгеле.

...Шулай бервакыт, өске катлары җимерелгән элекке больница йортының аскы катыннан немецларны куып чыгардык.

Кайнар аш, чәй дигән нәрсәләрне күптән күргән юк. Концентрант ярмаларын кимереп утырабыз. Аларны чылатырга су да юк. Группабызда ун кеше. Һәркемнең үз холкы, үз гадәте, сөйләшүе.

Сержант Шапиро — сугышка физматтан киткән яшүсмер. Хисаплауны ярата, саннар телендә сөйләшә иде.

— Шәһәрдә зениткалар күбәйгән шикелле,— ди бер солдат.

— Күп — ул сан түгел. Конкрет санны китерергә кирәк! Ә болай юкка лыгырдау гына. Мәсәлән, ярның теге ягында һәм шәһәрдә 25 зенит батареясе бар дип хисапласак, шуны әйтә алабыз: әгәр дә алар бер минут эчендә 750 снаряд җибәрсәләр, ихтималлык теориясенә таянып әйтсәк...

— Ә хәзер безнең өстә немецларның ничә самолеты очып йөри? Гомумән, аларның самолеты күпме? — дип сорый берәү.

— Сугыш башланганда ун мең иде. Хәзер аларның кулындагы йөз дә уникe завод һәр көнне бер генә самолет эшләп чыгарса да...

— Бер йөз уникe! — ди Шалунов.

Тагын бер солдат, интеллигент гаиләсеннән булгандыр, хәрби терминологиягә, приказ тоннарына, сүгенүләргә, кычкыруларга, бакыруларга һич тә күнегә алмады. Фамилиясе Смоленцев иде шикелле. Ул иң авыр очракларда да бик «мәдәни» телдә сөйләшә. Менә хәзер дә ул сүзгә кысылды:

— Минем фикеремчә, гафу итегез, бәлки мин, бераз ялгышамдыр, кайбер философик концепцияләрдән чыгып уйлаганда...

— Ташласана шул нәзберек сөйләнүеңне! — ди берәү.— Менә син әйт, философ, кайчан без аена хет бер тапкыр кайнар аш яки чәйдән авыз итәрбез? Менә мәсьәлә нәрсәдә! Ә син — концепция...

Шул чак тәрәзә янында сакта торучы Вафин:

— Иптәш командир, ишегалдына фашист мотоциклисты килеп туктады.

Урынымнан торып, тәмәке төпчеген ташларга да өлгермәдем, бүлмәгә немец ефрейторы килеп керде. Безне күрүгә йөзе агарып чыкты. Егетләр аны уратып та алдылар. Мин немец телендә кыска гына сорау алдым:

— Ничек болай безгә кетмәгәндә кунакка килеп чыктыгыз?

Теге тотлыга-тотлыга әйтеп бирде:

— Мин — кухняда хезмәт итүче. Батальон офицерларына әзерләнгән ашларны таратып йөрим. Иртән килүемдә монда безнекеләр иде. Менә төшке аш китердем аларга.

Аның бишекле мотоциклындагы термосларның берсендә кайнар аш, котлет, кыздырылган кәбестә, икенче термоста кофе, тагын ике шешә ром, өч плитә шоколад безнең өчен көтелмәгән бәйрәм булды. Күптән, бик күптән күрмәгән-татымаган ризык иде болар. Егетләрнең күңеле күтәрелде, көлү-шаярулар башланып китте.

Кайсы йортның кем кулында икәнен анык кына белмәгәнлектән, мин үзем дә әлеге мотоциклчы хәлендә кала яздым.

Рация буенча 109 полк штабына (Дзержинский урамына) чакырганнар иде. Автоматымны предохранительгә куеп, күкрәккә астым да чыгып йөгердем. Квартал безнең кулда дип хисаплана һәм шуңа күрә аны-моны уйламыйча йөгерә бирәм. Менә урам чатында бөтенләй җимерелгән йорт. Аның почмактагы бер каты гына исән калган. Шуны борылганда, минем шикелле үк муенына автомат аскан берәү белән маңгайга-маңгай бәрелештек. Карасам — алдымда немец! Икебез дә бер-ике адым артка чигендек. Нишләргә? Күрәм, әлеге немецның йөзе акбур шикелле агарынган, хәер, минеке дә шулай булгандыр. Мин дә, ул да көтелмәгән очрашудан каушап калдык. Дошман белән моңарчы болай бик якын очрашкан юк иде әле. Дересен әйтим, башта немец һушына килде. Автоматына ябышты. Мин дә автоматыма тотындым, чакмасына бастым, шунда ук пуляләр ява башлады. Немец егылмаган иде әле. Мин алга йөгердем. Штабка җитәрәк, туктап тын алмакчы булдым. «Ничек болай котылдым

соң?» — дигән уй башны бораулый. Юлга чыкканда, автоматымны предохранительга куйган идем... Ничек ул бер басуда ата башлады икән?

Соңыннан белдем: йөгереп барганда, селкенүдән, автоматымның предохранителе урыныннан ычкынган икән!

Үлем белән тормыш арасын санаган мондый хәлиткеч секундлар сугыш ветераннарының күбесе башыннан кичкәндер.

Берсендә, радиодан алынган боерык буенча, җимерелгән йортның подвалында 109 нчы полкның батальон, рота командирлары, комиссарлары җыелырга, командованиенең күрсәтмәләрен алырга тиешләр иде. Мин дә килдем. Өлкән командирларны көтеп утырабыз. Кемдер анекдот сөйли, кызык эпизодларны искә алабыз. Тәмәке тартабыз. Бу подвалга килү дә ансат түгел. Күпләр шуыша-шуыша йөзәр метр үткәннәр, бомба астында калганнар. Әнә, 3 нче батальон комиссары Алексей Антонов көч-хәл белән баскычтан төшеп бер почмакка ауды. Юлда дошманның мина утына туры килеп, битенә, җилкәсенә ярчыклар кергән. Бите шешенгән, күгәренгән.

— Леша, әйдә тышта бераз ял ит, һава сула,— дип, аны култыклап алып чыгып киттем. Подвал ишеген ябып өлгерүем булды, аста каты гөрселдәү ишетелде. Тиз генә йөгереп аска төштем. Күрәм: андагы командирлардан сигезе үлгән, күпләре авыр яраланган. Мин дә, Антонов та исән калдык. Әмма Алеша бу вакыйгадан соң өч көн генә яшәде. Дошман минасы нәкъ алар окобы өстенә төшеп шартлаган икән. Сугышчылар аны бик яраталар иде. Икенче көн таңында «За нашего комиссара!» дип атакага ташландылар. һәм бер йортны фашистлардан азат иттеләр.

Фронтта, бер төшкән урынга икенче мәртәбә бомба да, снаряд та, мина да төшми имеш дип ышаналар. Моңа үзем дә нык ышана идем.

...Күктә йөзләрчә фашист козгыннары. Минә вокзал артыннан парадка чыккан шикелле аларның тагын бер төркеме күренде. Безгә карап, киек казлар очкандагы кебек почмак ясап киләләр. Канат очлары сары, уртасында кара тәре, корсак астындагы шассиләре тилгән тырнаклары шикелле тырпайган. Без аларны күптән таныйбыз. Котсыз тавышларыннан ук беләбез. Алар, безнең күзләрне чагылдыру өчен, кояш ягыннан килеп чыгалар да, сиреналарын акыртып, өстебезгә ташланалар. Корсакларыннан кара «ноктала» тама башлый. Бер, ике, өч, дүрт... Тиздән бомбалары, өстебезгә төшеп, шартлый. Кояш күренми. Тирә-якта тузан, төтен, караңгылык...

Без, элемтәче кырым егете Сәйдали Алиев белән, бомбежка тукталганын көтеп «воронка»да ятабыз.

Кинәт Сәйдали җиңне тарта:

— Командир, әйдә тизрәк, әнә теге «воронка»га күчәбез.

— Бередә дә «воронка» ич!

Ул тагын: «Тизрәк — теге «воронка»га!» — ди.

Үрмәләп чыгып, икенче чокырга сикерүебез булды, берничә секунд кына элек без яткан «воронка»га йөз килограммлы бомба сызгырып килеп тә төште.

Сталинград тимер юл вокзалыннан ерак түгел бер мәйдандагы кечкенә фонтан тирәсендә кулга-кул тотышып әйлән-бәйлән уйнаучы яшь балаларның гипстан ясалган скульптурасы бар иде. Ул без оборона тоткан йортның каршында гына. Фашист самолетларының туктаусыз бомбага тотуы нәтиҗәсендә йорт җимерелде, без подвалга күчтек. Бомбалар әлеге балалар янына төшеп шартлаудан туктамады. Ләкин шунысы гаҗәп, таш йортлар җимерелеп ауды, ә «балалар»га әллә ни зыян килмәде. Берсенең генә аяклары өзелеп, чәлпәрәмә килгән. Әмма нәни куллар бер-берсен нык тоткан хәлдә әйлән-бәйлән уйнауларын дәвам иттеләр. Бу скульптура Сталинград сугышлары турындагы документаль фильмнарда хәзер дә еш кына күренеп китә...

Октябрь башлары иде. Сталинградтагы сугышларның иң киеренке чагы. Авыр бәрелешләрдән соң бик сирәгәеп калган безнең батальон трактор заводы янында, хәрабәгә әйләнгән таш йортның исән калган беренче катында оборона тота. Фашист самолетлары өстебезгә туктаусыз «күчтәнәч» ташлый. Бомбадан тыш кайчакта алар төрле әйберләр — тимер яки агач тырма, сабан, буш тимер мичкә, арба тәгәрмәчләре дә ташлап китәләр. Яртылаш җиргә күмелгән тәрәзәләр янында бомбежка беткәнен түземсезлек белән көтеп торабыз. Янымда ике татар егете: сары чәчле, чандыр йөзле, табәнәк буйлы, утә дә җитез, тиктормас, җор телле Мансур Вафин һәм салмак хәрәкәтле, сабыр холыклы, һәрвакыт көләч йөзле кырым егете Сәйдали Алиев. Алар гел янымда булырга, һәрвакыт ярдәм күрсәтергә тырышалар иде. Минә вокзал ягыннан тагын дошман самолетлары килеп чыкты.

Тиздән тирә-якны тоташ гөрселдәү каплады; җир селкенә, туфрак өермәсе күккә күтәрелә. Бер генә исән йорт та юк. Сугыш хәзер подвалларда бара. Фашист самолетлары, ач тилгәннәр шикелле, бомбага тотарга объект эзләп, күктә әйләнәләр.

Бездән ерак түгел — «Кызыл Октябрь» заводы. Баштарак заводның 5-6 торбасы күренә иде, хәзер алардан берәү генә калды. Аның да очындагы бер чите кителеп

төшкән. Берничә дошман самолеты шушы торбага ташланды. Торба өстенә дистәләрчә бомбалар ташладылар. Әмма ул исән калды. Икенче көнне тагын бер өер кара тәреле карчыгалар килеп чыкты һәм берничәсе тагын торбага ябырылды. Без аның чайкалганын күрәбез. Тиздән һавага тузан-туфрак күтәрелә һәм торба күздән югала. Самолетлар китеп, тузан басылгач, торба тагын күренә.

Вафин, Алиевның җилкәсенә төртеп:

— Әйттемме? Иртәгә тагын киләчәкләр, ә барыбер аудара алмаячаклар! — ди.

Чыннан да, иртәгесен кичәге козгыннар тагын килеп торба өстенә бомба яудыра башлады. Гаҗәп, бомба төшеп шартлаган саен торба чайкала, әмма аумый. Сталинградның батырлыгы һәм җиңелмәслеге билгесе кебек үз урынында мәгърур басып тора иде ул.

Аннан соңгы көннәрнең берсендә Вафин да, Алиев та батырларча һәлак булдылар. Мин каты яраландым. Кыр госпиталендә берничә көн ятканнан соң, мең мәшәкатьләр белән, Энгельс шәһәрендәге эвакогоспитальгә элактем. Бервакыт янымда буш караватка бер яралыны китереп салдылар. Карасам, безнең батальоннан икән. Иптәшләр турында, кем үлгән, кем яраланган, соңыннан ни хәлләр булган, шулар турында сөйләштек. Аннары әлеге торба искә төште:

— Ә теге завод торбасын аудардылармы? — дип сорадым.

— Тора,— диде ул елмаеп.— Сталинградның үзе шикелле.

Билгеле булганча, Бөек Ватан сугышы 1418 көн дәвам итте. Бик авыр, фаҗигале көннәрне үткәрдек без.

Сугышның язмышын хәл иткән, аның барышында төп борылыш ясаган, әле тарихта күрелмәгән иң аяусыз бәрелеш Сталинградта, Идел ярларында барды. Ул бертуктаусыз 200 көн һәм 200 төн дәвам итте. Ә минем иң авыр, әйтеп бетерә алмаслык кичеренке, я үлем, я Җиңү мәсьәләсен хәл иткән кульминация ноктасы 14 октябрь көне һәм төне булды.

Мин әле ул чакта бу бәрелешнең тарихи икәнлеген, аның ил, сугыш язмышын хәл итәчәген аңламый идем, әлбәттә. Тулы манзарасын, күләмен, фаҗигасен дә күз алдыма китерә алмый идем.

Хәрби язмаларда бу көн турында мондый сүзләр бар:

«14 октябрь Сталинград оборонасында иң авыр һәм хәлиткеч, иң каты бәрелеш көне булды» («Бөек Ватан сугышы тарихы»).

...«37-гвардия дивизия дошманның иң көчле ударына дучар булды. Аның позицияләренә фашистларның йөздән артык самолеты бомба яудыра».

«Миңа дүрт ел буе туктаусыз сугышларда катнашырга, авыр көннәр кичерергә туры килде. Ләкин истән һичбервакыт чыкмый торган иң авыр, иң кыен, иң фаҗигале, иң куркынычлы, иң кискен момент 1942 елның 14 октябрь көне булды» (В. И. Чуйков).

Менә шушы дәһшәтле 14 октябрь көнне безнең дивизия трактор заводын саклый иде. Дошман төп ударын шушында ясады. Инде шактый сирәкләнгән дивизия өстенә фашистларның өч пехота һәм ике танк дивизиясе ташланды. Соңыннан мәгълүм булды: дошман көчләре, безнекенә караганда, унике мәртәбә өстен булган.

Автомат, граната, берничә ПТР белән коралланган безнең батальон ике катлы кызыл кирпечле өйгә урнашты. Ул завод янында гына һәм аны, ни өчендер, «профессорлар йорты» дип йөртәләр иде.

Кояш чыкты. Көн аяз, җылы. Ләкин бу безне бер дә куандырмый, чөнки мондый һава гитлерчы самолетлар өчен шәп. Димәк, алар көне буе китмәячәкләр.

Менә алар кара болыт булып өстебезгә киләләр. Күп тә үтмәде, бер километр чамасы киңлеккә таралып, дивизия өстенә йөзләрчә козгыннар бомба яудыра башладылар. Тирә-якны кара болыт басты, кояш күренмәс булды. Бомбаларның гөрселдәп шартлауларыннан җир чайкала башлады. Самолетлар сиреналарын бөтен көчкә улаталар, түбән төшеп, пулеметларыннан ут сиптерәләр. Артиллерия көчле ут ачты, ул тынып калуга, дивизия өстенә ике йөзгә якын танк ябырылды. Алар артыннан меңнәрчә автоматчылар килә...

Ничек каршы торырга бу дәһшәткә?! Иң мөһиме — каушап калмаска, паникага бирелмәскә! Менә шундый иң коточкыч кичеренке минутларда кемнең кем икәнлеге сынала да икән.

Телефон чыбыклары күптән теткәләнеп беткән. Һәркем үзе белгәнчә, үз батырлыгына ышанып сугыша. Шулай да кайчакта күчмә радио эшләп куя. Шундый хәбәрләр ишетелә:

...Берничә немец танкы 4 нче рота траншеяләрен таптап үтте. Рота һәлак булды...

...3 нче батальонда Иван Артамонов, Петр Терехов, Әнвәр Гарипов граната бәйләмнәре тотып танк астына ташландылар.

...2 нче батальон пресслау цехында якага-яка, хәнҗәр сугышы алып бара. Үлүчеләр күп. Ярдәм булмасмы?..

...Ананьев ротасында 6 кеше калды...

...Сәмигуллин взводы тулысынча һәлак булды...

...Стадион — дошман кулында. 117 нче полк командиры Андреевның башын снаряд өзеп китте... Безне чолгап алдылар... Үләбез, ләкин бирелмибез...

Безнең батальон да бик мөшкел хәлдә. «Профессорлар йорты» алдыннан уннан артык танк узып бара иде. Шуларның дүртесе өйне чолгап алдылар да, турыдан төбәп ата-ата, стеналарны җимерә башлады. Йорт селкенә, дерелди. Артта тагын бүлмәнең стенасы убылып төште. Шулай да иске йорт нык икән, тиз генә бирешергә теләми.

Караңгы төшәр алдыннан гына чолганыштан чыктык. Дүрт танкны яндырдык, бик күп фашистларны кырып ташладык. Югалтулар да аянычлы. Батальонда нибары алтмышлап кеше исән калган иде. Якташларым Вафин, Галләм Тимербаев, Нәсим Исмәгыйлов та шушы йортта ятып калдылар.

Чолганыштан чыккач, калган көчләрне туплап, СТЗның пресслау цехында чолганышта калган батальонга ярдәмгә ашыктык. Без барып кергәндә, анда язып-әйтеп аңлата алмаслык йөзгә-йөз, якага-яка алышу бара, табигый булмаган кычкырулар, әллә нинди йөрәк өзгеч тавышлар яңгырый иде. Караңгы төшеп килә, кемнең кем икәнен аеру мөмкин түгел, идәндә, тәрәзә төпләрендә, батарея, станоклар өстендә хисапсыз мәетләр ята, идәнгә аккан каннан аяклар тая. Бу цехтагы бәрелештә, безнең батальон бөтенләй диярлек һәлак булды (соңыннан белдем: дүрт кеше исән калган).

Хәтерлим: бер фашист арттан килеп, башыма автомат түтәсе белән сукты. Күз алларым караңгыланып идәнгә егылганда, миңа төбәп, автоматтан атканын да ишеттем шикелле...

Трактор заводы эченнән мине кем алып чыгып, Идел ярына китереп куйган икән! Белмим. Вакыт-вакыт хәтер кире кайта, һушыма киләм. Янымда пилотка кигән бер кыз утыра, елый. Кабарып торган куе чәчләрен, коңгырт күзләрен күреп алам. Таныш, шундый таныш күзләр. Кайда күрдем соң мин аларны? Озак карый алмыйм, күзләрем йомыла, үксеп-үксеп әйткән сүзләре генә колакка керә:

— Бөтен санбаттан берүзем калдым. Күз алдымда... бичаралар, кадерле дусларым. Ул-бу булса, өйләребезгә, туганнарыбызга хәбәр итәргә вәгъдә бирешкән идек... Ә ничек, ни дип хәбәр бирим? — Аннары кыз миңа әйтә: — Ичмасам, сез исән калырга, терелергә, үч алырга тиеш. Мин сезне мәетләр арасыннан узганда танып алдым. Без бит күршеләр идек... Мәскәүдә... хәтерегездәме?

Бик авырлык белән күзләремне ачам...

— Студентлар шәһәрчеге Алексеевскийда безнең тулай тораклар күрше иде. 4 нче проезд. Безгә каршы 21 нче йорт сезнең полиграфия техникумы торагы, безнеке — мединститут. Трамвайдан төшкәч, бергә кайта идек...

Тагын һушыма киләм, селкенерлек тә хәл юк. Вак салкын яңгыр сибәли. Мин уяулы-йокылы саташып ятам. Эч яна, су, су кирәк! Тирә-якта, яр буйлап йөзләрчә яралылар ята. Алар кичә, 14 октябрьдә яраланганнар.

Аз гына уйлый башласам да, караңгылыкка төшеп китәм. Күз алдыма әни килә. Җыерчыклы битендә балкыган нурлы күзләре белән миңа елмая, гомергә эштән бушамаган, карап торуга кытыршы, ләкин мамыктай йомшак куллары белән йөземне сыйпый:

— Тор, балам, тор, бәбкәчем! Ач күзләреңне!

Уйлыйм: димәк, кояш чыгып килә, малларны көтүгә чыгарырга кирәк. Бу — минем эшем.

Әни авызыма ширбәт тамыза. Ул аны җир җиләгеннән, каен җиләгеннән, карлыганнан ясый иде. Әнинең кашыклы кулын тотмакчы булам. Күзләр ачыла. Әни югала. Санитар кызларның берсе:

— Менә сиңа яхшы булыр хәзер,— ди.

— Түз, түз, кадерлем, сабыр ит, җан кисәгем,— ди икенчесе. Ярамны чистартып, беренче ярдәмне күрсәтәләр.

Үлеп барган яралы солдат авызына су тамызган кыздан да гүзәлрәк хатын-кыз юктыр бу дөньяда. Әкияттәге фәрештәләр бер якта торсын!

...Менә 43 елдан соң очрашу. Поезд Мәскәүгә килеп туктады. Николай каршы алырмын дигән иде. Аны телевизор экранында таныган идем инде, ә менә ул мине танырмы?

Поездден төшүчеләр, каршы алучылар төркемен ера-ера Николай йөгереп килә!

— Рәис, дустым! Фронтташ туганым! Мин сине вагон тәрәзәсеннән үк танып алдым!

Кочаклашып үбештек, елаштык. Ул мине үзенең өенә алып китте.

Өстәл янында ул миңа шуларны сөйләде:

— Мин сине әлеге фаҗигале бәрелештән соң, көн урталарында трактор заводының цехы янында күрдем. Биһуш ята идең. Әмма тәнеңдә җан бар иде әле.

Тирә-якта сугыш бераз вакытка тынып калган. Мин сине шинель якаһнан тотып, Идел ярына, кичүгә таба сөйрәп киттем. Бераз баргач күрәм: җирдә шулай ук биһуш хәлдә безнең полкның штаб начальнигы Иван Малков ята. Аны да ташлап китәргә ярамый. Санитарлар, медперсонал кырылып беткән. Тирә-якта хисапсыз күп яралылар. Ярдәм кулы сузучы кеше калмаган. Нишләргә? Ике кешене ике шинельдән сөйрәп бару бик авыр иде. Берничә минуттан соң, ял итеп алырга туктагач, башыма бер уй килде. Синең гәүдәң бик зур, буең озын, димәк, шинелең дә шуңа яраша. Ә Малков, үзең беләсең, бәләкәй буйлы, чандыр гына егет иде. Аны синең янга китереп салдым. Шинель җиңнәрен бәйләп, аяк очларыгызны якында яткан противогаз тасмалары кисеп алып, бергә биләүләп сөйрәп алып киттем.

Яр буенда меңнәрчә яралылар ыңгырашалар, кычкыралар, сүгенәләр, ярдәм сорыйлар. Идел суы бер-ике метрда гына, әмма аларның авызына су тамызырга кеше юк.

Бераздан Малков җан бирде. Сине саклап утырам: бәлкем катер килер? Карыйм, синең йөзең дә агарды. Сулышың туктады. Шинель җиңнәреңне йөзеңә каплап куйдым да, кире киттем. Бу чак полкта берничә генә кеше калган иде.

24 октябрьдә дивизиядә, барлык штаб офицерларын кушып, 165 кеше калды. Башта кичүне сакладык. Соңыннан безне сул якка чыгардылар. Краснослободск поселогында дивизия резервлар хисабына яңадан оештырыла башлады. Яңа состав белән бергә мин Берлингача барып җиттем. Сине үлгән хисаплап, соңыннан эзләп маташмадым. Ә Краснослободск поселогында миннән сорадылар: үзегезнең полктан батырларча сугышып һәлак булганнардан кемнәрне беләсез? Алар күп, бик күп иде. Барысының да исемнәрен белеп булмый. Батальон, полк, дивизия штаблары юкка чыккан, меңнәрчә каһарманнар шулай исемсез һәлак булдылар. Аларга соңыннан гомуми һәйкәл-ансамбль корылды. Мамай курганы, Ватан-ана монументы. Әлеге сорауга җавап итеп мин әле дә күз алдымнан китмәгән ике кешене әйттем:

— Капитан Иван Малков, өлкән лейтенант Раис Сафаров.

Безнең исемнәрне политбүлек кешеләре язып алган. Мамай һәйкәле ансамбленең Сугыш даны залында диварга Сталинград өчен батырларча сугышып һәлак булган дүрт меңләп сугышчының исеме теркәлгән. Алар арасында И. Малков һәм минем исем дә бар.

9 май. Җиңү бәйрәменең 40 еллыгы... Кызыл мәйдандагы парадтан соң без, сугыш ветераннары, Максим Горький исемендәге ял паркына җыелдык. Һәр армия, дивизия өчен махсус урыннар билгеләнгән. Менә безнең легендар 37 нче дивизия урыны. Йөздән артык кеше бар. Әмма Сталинградта сугышканнардан алтау гына исән икән. Мәскәүдә яшәүчеләрдән И. Глотов (полковник), Николай Сидоров (полковник, профессор), Г. Харахашьян (полковник, профессор), Могилев-Подольскидан Семен Фукс (капитан, агроном), Владимирдан Петр Колотильщиков (сержант-инструментальщик) һәм мин (капитан, экономист).

Николай Сидоров белән минем 43 елдан табышып очрашуны Мәскәү Үзәк телевидениесе төшереп алды һәм аны беренче программа буенча 10 майда («Вакыт» программасында) һәм 30 майда махсус тапшыруда күрсәттеләр.

Авыр яралангannan соң мин төрле госпитальләрдә елдан артык яттым. Берничә айлар өйгә, әнкәйгә хат яза алмадым. Үземнең хәлдән килми, ә әйтеп яздырырга арабызда татарлар юк иде.

Без ятим үскән бертуган биш бала бер йорттан сугышка чыгып киткән идек. 1942 елда ук инде әнкәй бичара дүрт улы — Мулланур, Шамил, Һабил, Наилнең хәбәрсез югалулары турында кәгазь алган. Тиздән аңа тагын коточкыч хәбәр килә: «Улыгыз Раис Сафаров Сталинградтагы сугышларда батырларча сугышып һәлак булды».

Бер ананың биш баласы, биш кайгысы! Күпме яшьләр түкте икән бичара әнкәем!?

Миннән хәбәр килгәч, ул куанычыннан елый-елый, бу сөенечле хатымны авылыбыздагы өйләрнең барысына да кереп күрсәтеп чыккан. Сидоров минем үлгәнемә ышангач, кесәмнән кара эбонит медальонны алган икән, анда туган җир адресы, үлә-нитә калса, кемгә хәбәр итәргә кирәклеге язылган була.

Тиздән госпитальдә әнидән, күрше кызы кулы белән язылган хат алдым. «Балакаем, терелеп чыкканнан соң инде тагын фронтка бара күрмә, тизрәк өйгә кайт, бик картайдым, елый-елый, күзләрем сукырая бара, зинһар, сүземне тыңла, аякка баскач та өйгә кайт!».

Ләкин сугыш вакытының үз законнары бар. Госпитальдән култык таякларына таянып чыксам да, мин өйгә кайткалаганчы, тагын шактый вакыт узды.



# ИҖАТ БИЕКЛЕГЕ

## ФАТИХ ХӨСНИГӘ 80 ЯШЬ

Фатих Хөснинең фатиры югары катларның берсендә. «Олы кешегә менеп-төшеп йөрүләре кыендыр бит, түбәнгерәк катта урнашмагансыз»,— дим. Фатих абый, гадәттәгечә уенын-чынын бергә кушып: «Дөньяга биектән карарга яратам, өстән дөнья күбрәк ачыла»,— ди.

Баксаң, Фатих Хөсни әдәбиятыбызда үзе бер биеклек бит. Сүз сәнгатендә мондый зур эшләр башкарырга өлгергән язучыларыбыз исәпле-санлы гына. Ул — гомере буе халык гаме белән яшәгән кеше. Менә шул аның иҗатын тормышчан рух белән даими азыкландырып тора.

Ф. Хөсни барыбыз да сөйләшә, аралаша, укый-яза торган туган телебездә иҗат итә. Барлык сүзләре дә халыкныкы. Ләкин «Фатих Хөсни теле» дигән төшенчә дә яши. Кайдан килгән ул тел? Болай дигәндә, без әдипнең билгеле сүзләрне үзенә генә хас бизәкле, хисле-уйлы итеп куллануын күздә тотабыз. Әсәреннән берәр өзекне укып караган һәркем аның авторын ялгышмыйча билгеләячәк. Андагы сүзләр — солдатлар безне Фатих Хөсни язды дип авыз ерып торалар. Мондый хәл язучының төп корал белән эш итүдә югары осталыкка ирешүен раслап тора. Ләкин сүзне оста куллану сәнгатьлелекнең бер генә ягы. Ф. Хөсни әйткәнчә, «кемгә, нигә кирәге бар аның — олы газаптан башка туган һәм кешеләргә булышмый торган матур сүзнең! Матур идеядән башка матур тел була алмый, дусларым».

Ф. Хөсни дә, күпчелек язучылар кебек, иҗатны шигырьдән башлый. Драма әсәрләре дә язып карый, хикәяләре дә каләменнән төшә тора. Алар басылалар, укылалар, шулай авторның үзен дә, әдәбият сөючеләрне дә канәгатьләндереп бетермиләр. Беренче романы да тәнкыйтькә очрый. Ләкин яшь кешенең иманы нык: бар аның күңелендә кеше җанын кузгатырлык уйлар, дәртләр. Тик әле никтер билгеле бер рәвеш, кыяфәткә кермәгәннәр генә. Менә шундый эчке ышаныч аңа каләмне кысыбрак тотарга көч бирә.

1942 ел. Ватан сугышы бара. Фронттан өметле хәбәрләр килә торса да, кемкемне мәсьәләсе әле ахырынача тәгаенләнеп җитмәгән. Әмма кеше күңеле нинди авыр шартларда да яктылыктан мәхрүм булмый. Тик ул чаткыларны вакытында үрләтеп җибәрергә генә кирәк иде. Шушындый ихтыяҗ зур булган көннәрдә дөньяга «Йөзек кашы» повесте килә һәм укучылар күңелен яулап ала. Ике дистәләп ел үткәч, автор бу әсәрнең уңышын болай аңлатты: «Бу кечкенә генә китап мисалында мин, язучы буларак, бер хакыйкатьне тагын һәм тагын бер кат төшендем: тик кешеләр язмышы турында язылган китаплар гына кешеләргә якын булып җитә ала икән».

Әйе, чын мәгънәсендә җанлы кеше образын сурәтләүнең матур үрнәге бу. Әдәбиятта бары тик уңайны гына сурәтләү гадәт булып бара торган бер вакытта кешене бөтен катлаулылыгында бирү укучыларның күңеленә хуш килде. Сүз уңаеннан әйтик, Ф. Хөсни — күренекле әдип Г. Ибраһимов белән очрашып, аңардан үз язганнарына карата фикер ишеткән, киңәшләр һәм фатиха алган бәхетле кеше. «Йөзек кашы»н иҗат иткәндә, ул киңәшләр бик тә ярап куйгандыр дип уйларга кирәк.

Котдүс Вафин, ике Айдар, Сәфәргали, Вәсилә, Зәйтүнә, Гыйльмениса һәм башка образлар һичшиксез аның үз йөрәгеннән өзелеп төшкән. Моңа әсәрләрне укыган кем генә шикләнер икән? Ике роман, ике дистәдән артык повесть, өч-дүрт пьеса, йөзләрчә хикәя — болар барысы да сүз сәнгатенә ул алып килгән байлык. Шулар

арасында «Җәяүле кеше сукмагы» романы — күтәргән идеясенең яңалыгы, образларының камиллеге, психологик тирәнлеге белән язучының иң югары казанышы.

Ф. Хөсни бездә хикәя остасы буларак та телгә кергән. Әйе, ул хикәянең бөтен хасиятен тирән белеп, исәпкә алып яза белүче. Рус әдәбиятында «Чехов хикәяләре» дигән критерий бар. Бездә исә хикәяне Ф. Хөсни дәрәҗәсендә иҗат итү дип әйтү гадәткә кереп бара.

Хикәя дигәч тә, бу жанр — үзе шактый катлаулы күренеш. Бар аның Ф. Әмирхан кебек осталар тарафыннан шактый катлаулы, тасвири язганнары, бар Г. Ибраһимовтай повесть сыйдырырдай хәл-әхвалләрне иңләгәне, бар Г. Бәширов, Ә. Еникиләрдәге салмак-сабыр агышлысы. Ниһаять, бар Ф. Хөсничәсе, ягъни җор телле, җырлап тора торган, уены-чыны белән теләсә нинди вакыйганы яки кеше холкын кечкенә генә мәйданда коеп куйганы. Кем ничектер, мин күңел төшкән чакларда Ф. Хөсни китапларын кулга алам. Ике-өч бит укуга, күзгә яңгырлы көннәрдә дә күңел күгенә кояш иңә, уйларны яктыртып ала. Кешегә күп кирәкми, шулай кабынып алу көч өстәп җибәрә, күңел эшкә көйләнә.

Ф. Хөснине без прозада мәхәббәт җырлары иҗат итүче дип тә атый алабыз. Ярату хисләрен кешелекле, психологик дөрес һәм шул ук вакытта җорлык белән сурәтләүнең остасы ул. Мәхәббәт — бик киң төшенчә. Ул — халкыңа, җиреңә-суыңа, кешеләргә булган мәхәббәт. Мәхәббәтне саклый белергә, аның өчен көрәшергә дә кирәк. Язучы безне шуңа өнди.

Ф. Хөсни «Утызынчы ел» романы ахырында болай дип язып куйган: «Озын бер роман дәвамында сөйләп бетереп булмаганны, кыска бер эпилогта гына сөйләп бетереп булмастыр. Һәм, гомумән, кешеләр турында барысын да сөйләп бетерергә мөмкинме икән? Бигрәк тә хәрәкәттәге, юлдагы, көрәштәге кешеләр турында?» Болар язучының үз иҗатына да карый торган сүзләр. Ф. Хөсни иҗаты турында да кечкенә генә бер мәйданда сөйләп бетереп булмас. Укучы аның китапларын кулына алыр, ошап китсә, барысын да укып чыгар. Шуннан соң үз хөкемен чыгарыр, кирәк тапса, безнең белән бәхәскә керер яки куәтләү сүзләре әйтер. Ник дигәндә, Ф. Хөсни әсәрләрен укыгач, уйның хәрәкәткә килмәве мөмкин түгел. Ул уйның әдипкә мәхәббәт, хөрмәт хисләре кабызачагы да шиксез!

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН.**

## Фатих Хөсни

# КУРКЫНЫЧ ЙОРТ

ХИКӘЯ



ормыш минем сакалымнан да озын түгел, җанкисәкләрем. Мин дөньяда озак яшәдем. Кайсы тауда нинди таш ятканына чаклы беләм. Әкият сөйләп утырырга — унбиш тешен ире бәреп төшергән, унбиш теше болай төшкән карчык түгел мин. Әгәр тыңларга телисез икән, минем яртычәчемне агарткан бер хәл турында сөйләрмен.

Ул, бераз кәкрерәк аякларын кочаклап, яна торган учакка таба карап утыра. Ялкын нурында без аның чал керә башлаган түгәрәк сакалын, җыерчыклы йөзен, әле нурын югалтып бетермәгән яшькелт күзләрен күрәбез. Без, сөйләнәчәк хикәяне кулларыбыз белән тартып алырга теләгәндәй, аның тирәсенә якынрак елышабыз. Безнең кызыксыну белән янган күзләребездән очкыннар чәчрәгәнгә шулай котырган кебек, учактагы ут һаман саен ныграк үрли

бара. Ялкыннар озын телләре белән элек агач ботакларына, аннан йолдызларга таба үрелəләр...

— Сез ул чагында аналарыгызның карынында йөргәнсездер әле,— дип, карт тыныч кына итеп янә башлый һәм, бик кирәкле нәрсәсен оныткандай, кинәт туктала. Яна торган утка төкерә. Аннан тагын башлый:

— Мин яшь чагымда тегүчелек кәсебе белән тамак туйдырып карадым. Үзегез беләсез, тегүче белән киез итек басучы күп йөрүчән, күп күрүчән була. Мин дә шул, елларның берсендә, күбрәк акча эшләү нияте белән, еракларга, Закама якларына киттем. Тик, җанкисәкләрем, дөньяның бер почмагында да акча агач башында үсми икән. Йөрдем, кеше сүзен тыңладым, үзем борчак сиптем, әмма бер җирдә дә акчаны санамыйча бирмиләр икән, әй. Озын сүзнең кыскасы шул: хатынга күлмәклек, бала чагага күчтәнәчлек, бер арык тана алырлык акча җыйдым да тәртәне кайту ягына бордым. Тукта, мин әйтәм, байлыкны кайда да өеп куймаганнар, ичмасам, җылы түшәгемдә хәләл хатынымның беләгенә башымны куеп ятармын дим. Шулай итеп шул, станциягә чаклы илтеп куяр өчен яшь бер мишәрне яллыдым да — әйдә үз авылыма.

Яшь мишәр дигәнем, әле яңарак кына атасыннан башка чыгып, үзенә аерым тормыш кора башлаган бер адәм булып чыкты. Тормыш кору дигән сүз ул, җанкисәкләрем, колга башына сыерчык оясы менгезеп кую гына түгел. Минем олаучым да шул, яшь кенә булуга карамастан, төн чаба, көн чаба икән. Элек ат булдырган. Аннары яңа өй җиткерергә дип тир түгәргә тотынган. Ат дигәннән, әй, аты да иде соң!.. Аннан соң да бик күп җир йөрдем мин, мәгәр андый атны күрә алганым юк, һич ялгансыз менә. Канатлы кош иде инде. Хуҗасы бер сызгырып җибәрсә, мин сиңа әйтим, күз алдында бураннар уйный. Юл буендагы маяклар егылып-егылып кына калалар. «Хакын да сорый белде, каһәр суккан мишәр, малы да мал икән шул. Мондый атка әрәм түгел»,— дим эчемнән генә. Ә мишәрем атына әллә нидә бер сызгырып җибәрә дә сөйләнепме-сөйләнә:

— Мин юк-барны яратмыйм. Миңа булса бер дигән булсын.

Чанадагы печәнгә күмелеп утырган килеш, тыңлар-тыңламас кына барам, ә теге сибә генә борчакны:

— Бөтен өяздә бер ат бу, кәбәм. Аның турында бөтен мир сөйли. Әле бер чәкне шулай Семеновкадан урыс килгән — теге Ивашка малае. Сат, князь, ди. Ни теләсәң, шуны бирәм, ди.

Үзе белмәгәч, кешенең авызына сугасыңмыни! Майлы коймак, җылы түр башыннан башканы уйламый торган җильяк тегүчегә аның аты турында лыгырдап баруы пычагыма кирәкмени. Мин үзем ат турында берәр җиргә барасым булса гына уйлыйм. Шулай итеп шул, ат турындагы сүзен җупләмәгәч, олаучым өй салдыру турында тотынды. Башта ук әйттем, лыгырдарга мин үзем дә бик мачтыр, мәгәр миннән дә мачтыррак кешеләр бар икән, җанкисәкләрем!

— Ашамасам ашамыйм, йокламасам йокламыйм, әмма ызбаны менә дигән итеп салдырам. Әле абзарлар кирәк, әле конюшнига тырышырга кирәк. Өяздә бер алашаң булсын да, конюшнисыз ярыймы соң, атакайгынам.

Йөри торгач, дуракның сиксән бишенче төрлесенә очрадым, ахрысы. Тизрәк кайтып җитеп, хатын белән мунча керүдән башка нәрсә турында уйламый торган тегүчегә аның конюшние нигә кирәк соң, авызларына пычрак сылап куясыңмыни шундый тел бистәләренең.

Шулай төчеләнеп сөйләнеп бара торгач, тегенең мактаулы аты ялгыш юлга кереп киткән, әй. Барабыз, барабыз, ник бер генә җан иясе күренсен. Барабыз, барабыз, бервакытны зур карурманга килеп кердек. Урман калын, кич булды, караңгы төшә башлады, күз ачкысыз буран купты. «Харап булдык»,— дим эчемнән генә. Урманны әйтәм, калынлыгы белән дә, караңгылыгы белән дә безнең өскә авып бара төсле. Күрәм, олаучымның тамагы карлыга башлады. Ул дәррәү телсез калды. Аның

тыгылып калуы куркытмый, мәгәр шартларлык дәрәҗәдә күнелсез иде.

Олаучым, үлем алдындагы кеше кебек, сулышын еш-еш ала һәм, бәлане миннән күрергә теләгәндәй, минуттан-минутка миңа сүзсез генә күперенә барган кебек иде.

Ахырында түзмәдем, сорадым:

— Син нигә телсез калдың? Инде хәзер нишлибез?— мин әйтәм.

Ул ни дип тә җавап бирмәде. Миңа таба ачуланып бер карап алды да, яңадан атына таба борылып, тынып калды. Без урман эче белән байтак җир киттек. Әле урманның очы-кырые күренми иде. Менә шул вакытта мин олаучы егетемнең елаган тавыш белән мыгырдануын ишеттем.

— Алашамның башына җитәргә дип кенә чыкканмын икән...

Без озак вакыт бернинди сүзсез бардык. Урманны чыктык. Ләкин бөтен дөньяны каплаган буранда бернәрсә дә күренми иде. Кар яумый, ә ничектер шунда ишелә. Күк бөтен салкынлыгы, бөтен авырлыгы белән безне сыта бара кебек иде.

Мин үзем ходай белән әллә ни күп эш иткән кеше түгел, кече яшемнән мәчет белән дуслыгым булмады. Шунда да ул чагында шүрли төштем, җанкисәкләрем.

Барабыз, барабыз, бара торгач, каршыбызда зур бер чокыр күрдек. Чокырда ниндидер карамчыклар күренәләр иде. Икебез дә җылынып киткән төсле булдык. Бу карамчык дигәнбез өч-дүрт кенә өйдән торган кечкенә бер авыл булып чыкты. Чокырда, буран эчендә, җиргә ябышып яткан бу өч-дүрт йорт, ташлап чыккан кебек, тын иде. Хатынын, балаларын сагына белүче яхшы күңелле тегүчене (мин үземне яхшы күңелле дип уйлыйм) каршы алып, ичмасам, сыңар аяклы бер эт өреп чыксын икән.

Шулай да читтәге бер йортта әлҗе-мәлҗе генә ут елтыраган була. Утын әйтим инде, ташка үлчим, тычкан утыннан бер дә аермасы юк. Башка вакыт булса, тегүчегез бераз кыстатыбрак торган булыр иде дә, нужа якаңнан эләктереп алса, иркәләнеп торып булмый икән шул, җанкисәкләрем. Мең мәртәбә куанып әлеге өйнең тәрәзәсен кактык.

Сәламәгә төренгән бер карчык безгә капка ачты. Кердек. Өй эче караңгы, түшәм корымга каткан, тараканнар төтеннән исерешкәннәр — әкрен генә шыбырдашып йөриләр. Ишектән атлауга, борынга әллә ниткән тәмсез ис бәрелде. Үзегез беләсез, җанкисәкләрем, тегүчегә үз гомерендә күпне күрергә туры килә, мәгәр минем мондый өй эче күргәнем юк иде.

— Туры килдек, малай,— дим олаучыма. Күз кысам, теге дәшми. Аның чырае сытылган, куркуыннан әле һаман айнымаган. Саташкан нәрсә. Өстенә бөтен авырлыгы белән озын, безнең авылның багана Хәйри чаклы озын, буранлы төн авып төшкәндә, уйлап торырга мөмкинме соң? Баш астыңа нужаңны бөкләп сал да ята бир. Мин үзем шундый фикердә.

Булмас, мин әйтәм, авызны бераз җылытып алырга кирәк, шуннан соң барысы да онытылыр, дим. Үзегез беләсез, акча эшләп кайтып килә торган чак, капчыкта кызылбаш бар. Түтәрәме белән ит чыгардым, әйдә, мин әйтәм мишәргә, барысына да төкер, дим. Теге һаман дәшми. Шулай да бик нык туңган булган, күрәсең, табынга якынрак елыша төште бу.

Соңга таба мишәрнең теле яңадан ходка китте. Ул тагын атын мактарга тотынды. Дуракның дураклыгы теленә чыга, күрәсең. Үзем утырам, үземнең ит белән тире арамда кырмыскалар чабыша. Тамак төбе кычыта, ничектер тегене күмеп ташлыйсы килә. Шуннан тотындым борчак сибәргә.

Сез белмисез генә, җанкисәкләрем, әгәр ачулансам, сез уйлаганча ук яхшы кеше түгел мин. Дөресен әйткәндә, бүтән кешеләр бик шәп булмаганда, ни өчен тегүче байгышка гына шәп булып маташырга! Шулай итеп шул, тотындым ялганларга, тотындым шартлатырга, чыдап кына тор:

— Миңа аршин белән бер селтәнү җитә, мин синең алашаңны да, ызбаңны да, барысын да олтан астында калдырам. Мин акчаны энә белән түгел, көрәк белән көрим. Мине Мәскәвеңә дисеңме, Мәкәрҗәсенә, Минзәләсенә, бөтен җиргә чакырып торалар.

Бер сүз белән әйткәндә, сабын куыгын очырам. Мишәрем буыла-буыла сөйли. Күрәм, ул ялганламый. Мәгәр аның чын дигән сүзе дә минем ялганга тормый. Читтән карап торучыга без шул адәмгә охшап күренгәнбездер. Теге карчык безнең тирәдә ешрак чуалгалый башлады. Сораша, кайдан килүебез, ниләр майтарып йөрүебез белән кызыксына. Мин үзем аңа җавап бирәм, үзем аның авызына карап торам. Карчыкның авыз эче никтер караңгы. Сез караңгы авызлы кешеләрдән сак булыгыз, җанкисәкләрем. Андый авызларга дүрт аяклы атлар сыя...

Шул карчык безнең тирәдә бөтерелеп йөри. Алай итә, болай итә, өстендәге сәләмәләрен селкетеп хихылдап көлгән була. Ә без мишәр белән сөйләнепме-сөйләнәбез.

Бервакытны карчык каядыр чыгып югалды. Карчык китеп, бераз узганнан соң, өйнең ишеге кинәт ачылып китте. Ә ишектән... Колакларыгызны миңа табарак борыгыз, җанкисәкләрем, мин хәзер аның турында әйтәм...

Шулай итеп шул, ишек кинәт ачылып китте дә, безнең янга тулган ай кебек нәкәс бер кыз атылып керде. Башта ук әйтеп куйдым, мин — аршын белән дөньяның аркылысын-буен үлчәгән кеше. Мин — озын чәчле су кызлары турында әкиятләр тыңлаган кеше. Юк, инде, җанкисәкләрем, әкиятләрдә сөйләнә торган су кызлары, озын чәчләрен тарыйтарый, яр буенда утыра торсыннар. Бу — ул түгел инде. Күзләр дисеңме, кашлар дисеңме, сыйраклар дисеңме, бил дисеңме — барысы да коеп куйгандай. Күл шикелле күзләрен тутырып бер карамасын инде, карасa — шундук эреп китәсең: бөтен ялганнарың, бөтен бозыклыкларың белән аның күзләрендә эрисең!

Шул, бу кыз керде дә безнең тирәдә әрле-бирле әйләнгәләп йөри башлады. Әле тоз савыты китереп куйган була, әле суган әрчеп китерә. Шул чаклысы да бар, җанкисәкләрем, килгән саен я күкрәге, я беләге белән икебезнең беребезгә ышкылып китә бу. Ул бит юри ышкыла. Безнең таш күңелләр дәррәү эреп китте, әллә утырабыз, әллә очабыз — белгән юк.

«Йа ходай!.. Өйдә калган яшь хатыным, балаларым хакына башка бәла җибәрә күрмә!»— дим эчтән генә.

Бераздан кыз чыгып китте. Ай урынына килгән болыт булып тагын теге ямьсез карчык килеп керде. Карчык, караңгы авыз эчен күрсәтеп, тагын сөйләнергә тотынды. Олаучымның дурак иканлегенә янә бер кат иман китердем, мин сүзен җупләмәгәч, карчыкка лыгырдый башлады. Аның алашасы фәлән, аның алашасы төгән... Аның алашасы өяздә бер, имеш.

Әле дә ярый, дөньяда дураклар күп, югыйсә, минем ише шырсыйрак тегүче ничек яши алыр иде.

Мин тегеңә ачу итеп бүтән сүз башлыйм:

— Бик шәп кызың бар икән ләбаса, әби,— дим.

— Әйе,— ди карчык.

Бераз сүзсезлектән соң өсти:

— Сез аның биеп күрсәтүен сорагыз. Бии башласа, табан астыннан очкын чыгара.

Ай белән болыт урыннарын алмашкан кук, алар тагын алмашындылар. Берсе чыкты, икенчесе әйләнеп керде.

Без тәмам исергән идек инде.

Ошыймы, ошап җитмиме — ул турыда сорау биреп тормадык. Керү белән теге кызга бәйләнә башладык. Бие булгач, бие, дибез.

Кыз, артык назландырып тормыйча, яланаяк көйгә шәп-шәрә идәндә бии башлады.

Туктагыз, җанкисәкләрем, алдан ук кисәтеп куям, бу төшкә җиткәч, сез мине бүлдерәсе булмагыз. Ул турыда сөйләгәндә, мин үземне дә, сезне дә яратмыйм. Минем күз алдымда бары тик яланаяклы ул чибәр кыз гына кала. Менә ул сикерә... Менә ул оча... Куллары канатларга әйләнәләр... Кап-кара чәче таралып җилкәсенә төшә. Нечкә кара кашлар уйныйлар. Ә күзләр... Күзләр зур булып ачылалар. Ул күзләрдән безгә — гөнаһлы кешеләргә — очкыннар чәчри. Беркатлы тегүчең хатынын да, баласын да, тана алырга дигән акчасын да оныта. Беркатлы тегүчең ул чибәр кызның чәчләренә асылынып күккә аша...

Сез мине ачуланмагыз, җанкисәкләрем, сезгә тегүченең күккә ашуы, бәлки, кирәк тә түгелдер. Мин әле болай гына. Артыграк кызып киткәнмен. Ә шулай да бик шәп иде ул кыз.

Кыз тәмам кызып житкән вакытта гына кинәт мишәрем аягына калыкты. Белмим, ни өчендер, бу минутта аның күзләре ямьсезләнгән иде. Тынычландырырга ничаклы маташсам да, булдыра алмадым. Ул, кызны да, мине дә тыңламыйча, ишеккә таба бара башлады. Үзе салган тавыш белән мыгырдана:

— Капка тавышы ишеттем. Алашама берәр хәл булмагае, кәбәм.

Аның күзләре яшьләнгән иделәр. Ул, бүреген киярга онытып, ялан-баш көйгә, ишегалдына чапты. Төн уртасы житеп килә иде инде. Буран котырганнан-котыра иде. Ләкин аны берсе дә туктата алмады. Ул ишег-алдыннан бөтенләй кара көеп керде. Керде дә, кемгә дә сүз кушмыйча, өстен киенә башлады. Мин аңа гаҗәпләнеп карап тордым. Ул үзе киенә, үзе бөтен саны белән калтырана. Аның күзләре кызарган. Әледән-әле тешләрен шыкырдата. Бу минутта ул миңа бөтен нәрсәдән, хәтта теге ка-раңгы авызлы карчыктан да ямьсезрәк булып күренде. Ул куркыныч иде. Кызарган күзләре дә, бүре шикелле тешләрен шыкырдатуы да, калтыранулы да — барысы да куркыныч иде.

— Синең нишләвең? — дип биргән соравыма каршы, ул ачулы гына җавап кайтарды:

— Монда кунып, алашамнан колак кагасым юк. Киттем. Катсам, юлда, буран астында, алашам белән бергә катармын.

Аның тешләре тагын да куркынычрак шыкырдарга тотындылар. Минем майлы тел белән юмалап маташуым аны тынычландыра алмады.

Шулай итеп, күз ачкысыз буранда, төн уртасында, ялгызы юлга чыгып китте ул. Төн караңгы иде. Без аны бик тиз күздән югалттык.

Мин, таң атканны көтеп, шушы шомлы өйдә кунып калдым. Нәрсә турында уйланылган, нинди сүз әйтелгән — берсен дә белмим.

Төннең бер вакытында баш авыртуга чыдый алмыйча уянып китсәм, колагыма елау тавышы килә. Кеше елый. Кеше шыңшып елый. Бу йөрәк өзгеч тавыш, өй түрендә улаган буран тавышы белән кушылып, тагын да куркынычрак булып ишетелә. Караңгы өйнең корымлы стеналары, теге йөрәк өзгеч елау тавышы, тараканнарның ярыкларда, түшәмдә, тагын әллә кай төшләрдә шыбырдашулары — барысы бергә мине сыта шикелле иде.

Ахырында түзмәдем, урынымнан тордым да елаган тавыш ягына киттем. Почмакка керсәм, ни күзем белән күрим, бөтенләй дип әйтерлек ялангач көйгә, тәрәзә турына килеп баскан да, тәрәзә аркылы буранлы төнгә карап, теге чибәр кыз елап тора...

Бу — барысыннан да куркынычрагы иде. Мин кинәт калтырап кит-тем. Ләкин шулай да, берни турында уйлап тормастан, кызга таба якынлаштым мин. Күз яше белән аның бөтен бите чыланган, чәчләре чуалып, ялангач күкрәгенә таралган, ә үзе кулны пешерерлек кызу иде.

Башта ул нәрсә дә әйтмәде. Бары тагы да көчлерәк, тагын да йөрәк өзгечрәк итеп елый гына бирде. Минем чын күңел белән сораганымны аңлаганнан соң гына, аның яшь аралаш әйткән өзек-өзек сүзләрен ишеттем:

— Бу куркыныч йорт, абзый! Монда караклар тора. Син теге ямьсез карчыкны күрдең ич. Мин — аның ятим калган туганы. Ул мине чүплек башында тота. Ул миңа келәсем килмәгән чагында көләргә куша. Ул миңа сезнең кебек юлчыларны кунарга кертә дә, мин аларны юатырга тиеш булам. Ә шул вакытта алар, кемнәр беләндер берләшеп, юлчыларның йөкләрен кисәләр, атларын урлыйлар. Үзең күрдең, мин бүген үземнең биюләрем белән теге кешене тота алмадым. Шуның өчен ул әшәке карчык мине тимер көрәк белән кыйнады. Ул мине яланаяк карга чыгарып бастырды. Миңа куркыныч монда, абзый. Миңа бик куркыныч монда. Син яхшы кеше бугай, зинһар өчен дип әйтәм, мине бу убырлы карчыктан коткара күр. Мин — матур кыз, син мине үзеңә хатын итеп ал. Мин таза кыз, рәхәтләнеп эшләп яшәрбез.

Ул үзе елый, үзе сөйли иде. Ул кайнар күкрәге белән минем алдыма ауды. Аның күз яше агып минем тәнемә сеңде. Күз яше белән бергә аның кайгысы да сеңде миңа. Мин, ничек кенә булмасын, аны бу йорттан коткарырга үземә-үзем сүз бирдем.

Без ул кыз белән сөйләшә-сөйләшә таң аттырдык. Иртәгәсен мин, кызны юатып, ул куркыныч йорттан исән-сау чыгып киттем. Ләкин бик озак барырга туры килмәде, миңа кешеләр очрадылар. Алар кыр ягыннан кеше гәүдәсе күтәреп киләләр иде. Якынрак килә төшкәч кенә таныдым: бу минем олаучым иде.

Үз башына чыгып киткән булган икән, мескенкәй!..

Аның башы ярылган, теле аркылы тешләнгән көйгә катып калган, бите бөтенләй кан таплары белән тулы иде. Аны арба кендеге белән кыйнаганнар. Кыйнаганнар да, үлеп җитмәгән көйгә буран астында калдырып, атын алып киткәннәр. Миңа сөйләделәр: ул үлмәскә тырышып, әллә ничаклы җәфаланган. Ләкин сез бернәрсәне онытмагыз, җанкисәкләрем, ул йортта үлмичә калу бик әзләргә генә мөмкин иде шул.

Сез, яшь кешеләр, теге матур кыз нишләде соң, дип кызыксына булырсыз. Юатуын бик шәп юаткан идем дә, мәгәр мин аны ул йорттан тиз генә коткара алмадым. Күршеләремә әйтеп караган идем дә: «Кеше өчен борчылып йөри тормыйбыз әле, усал белән тапма да, бүлешмә дә. Усалның зарар салуы бар»,— диделәр. Үзем генә барып коткарырга көчем җитмәс дип уйладым. Еллар узганнан соң, безнең авылга каладан таза гәүдәле бер егет килде. Заводта эшләүче егет иде. Мин әлеге хәтәр эшне аңа сөйләдем. Аңа нәрсә, карактан урлатыр әйбере юк. Тазалыгы бар... «Әйдә, алып бар мине»,— ди. Алып киттем шул. Кыз бик матур булып өлгергән иде инде. Егет белән шундук күз кысышып алырга да өлгерделәр болар. Ә егет батыр. Исе дә китми. Шулай итеп, теге куркыныч йорттан кызны алып китте шул.

Ул сөйләп бетерде дә яна торган учакка карап уйланып калды. Без аннан тагын нидер сөйләтмәкче идек тә, ул арада бригадир килеп, эшкә кузгалырга кушты. Без, яшьрәкләр, әнә шул караңгы йортта торырга туры килмәве өчен шатланган шикелле, шау-гөр килеп урыннарыбыздан күтәрелдек.

*1936*

*Күренекле башкорт шагыйре, драматург һәм публицист, җәмәгать эшлеклесе, РСФСРның М. Горький, Башкортстан АССРның Салават исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Нажар Нәҗми исеме журналыбыз укучыларына яхшы таныш: аның күп шигырьләре, шул исәптән, «Татар теле», «Шагыйрьләр» циклы (Г. Тукай, Х. Туфан, С. Хәким һ. б.га багышлаулар), «Иблис» поэмасы «Казан утлары» аша күп меңләгән укучыларын тапты. Татарстан китап нәшрияты аның «Ут күрше» һ. б. китапларын татар телендә дөньяга чыгарды. Шагыйрьнең каләмдәш дусларына — бүгенге шагыйрьләребез иҗатына багышланган «Дим буеннан хатлар»ы да, халыклар һәм әдәбиятлар дуслыгына багышланган башка мәкалә-истәлекләре дә әдәби җәмәгатьчелеккә яхшы мәгълүм. Ә инде аның сүзләренә язылган «Котелогым», «Син гомер агышларым», «Өфе юкәләре», «Юкка түгелдер» кебек популяр җырларны республикабызда да яратып җырлыйлар.*

*Февраль аенда татар әдәбиятының якын дусты Нажар Нәҗмигә 70 яшь тула. Шагыйрьне юбилее белән котлап, бу санда укучыларыбызга аның берничә шигырен тәкъдим итәбез.*

# Нажар Нәҗми

## Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям...

*Сибгат Хәкимгә*

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Якыная төсле миңа ул.
Төрле усал, яман карашларны
Өтеп, этеп, ерып килә ул.

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Узган язмышларга үч итеп,
Килә кебек, якыная кебек:
«Иң бәхетле итәм үзем»,— дип.

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Тоям аның авыр булырын.
Башкарылмаганнар башкарылыр —
Җан, ниһаять, табар урынын.

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Ләкин аңа калмам кол булып.
Тормышымның очсыз хыяллары
Очачаклар күккә көл булып.

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Чигенә кебек артка яшь саны.
Яшьлегемнән кабат килә-килә,
Яшәртермен кебек дөньяны.

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Үзе килә, килә тирәннән.
Башкодасыз, димләүләрсез килә,
Өстән түгел, килә түбәннән.

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Язмыш бүләк иткән уттыр ул...
О, җиреңнең җирле мәхәббәте!
Шуннан да зур бүләк юктыр ул!

Мәхәббәтнең килерен мин тоям...

## Казанның татар зиратында

*Шунда тамсын күз яшемнең*
*Иң ачы һәм татлысы.*

Г. Тукай

Шушы сүзләрне укыдым
Мин кабер ташларыннан.
Алар уелган шикелле
Әче күз яшьләреннән.
Шагыйрь һәм кеше күңеле
Эреп коелган бергә.
Шагыйрь сүзләрен ябынып
Яталар төсле гүрдә.
Әй язмыш, шагыйрь язмышы
Кешеләр бәгырендә!
Сүзләр көчсез — бер сүз дә юк
Шагыйрьнең каберендә.
Тик анда тере чәчәкләр,
Ташында көн яктысы...
«Шунда тамсын күз яшемнең
Иң ачы һәм татлысы».

## Шадра пәри

Бала чакта дуслашып та,
Үстек исем аташып та:
Кемдер «Тартай», кемдер «Борча»,
Кемдер «Күркә», ә мин исә —
«Шадра пәри»... «Шадра пәри»...

Балалыктан һәр сүз сеңеп
Кала икән күңеленә:
Кайда барма, булды юлдаш
Минем бөтен гомеремә
«Шадра пәри»... «Шадра пәри»...

Үсеп җиттем... Булдым гашыйк —
Ул фәрештә иде, шөйлә.
Карашлары әйтте кебек:
«Син тиң түгел, түгел миңа,
Шадра пәри... Шадра пәри...

Гомер үтте... Хыялымның
Очтым сыңар канатында.
Ничек булсам, калдым шулай
Мин матурлык арасында —
Шадра пәри... Шадра пәри...

Матурлыкның чиге юктыр,
Аның чиген тоймадым мин.
Кеше матур булсын өчен,
Матурлыкны җырладым мин —
Шадра пәри... Шадра пәри...

## Хыялларның юктыр ул чиге

*Онытым Ансафка*

Бу беренче синең Яңа елың,
Ә минеке ашкан алтмыштан.
Минем гомер тора кебек бары
Алтмышлардан артык сулыштан.
Бар белгәнең синең елау әле,
Мин дә шулай елак булганмын.
Мин бүген дә төрле кайгыдан һәм
Шатлыктан тиз елый торганмын.
Еламасаң, елатучылар бар —
Чиге юктыр кысыр көнләүнең,
Синең туудан да көнләшергә
Хакы бардыр кайсы берәүнең.
Олыгайгач хыял кими төсле,
Ә ул артты хәзер син тугач:
Күрсәм иде тәпи басканыңны...
Көннәр килеп телең ачылгач,
«Картәти!» дип эндәшүләреңне
Көтү миңа хыял түгелме?
Мин бүген үк синең белән уйнап
Йөрегәндәй тоям үземне.

Күрсәм иде син мәктәпкә төшеп,
Кайтканыңны тәүге дәрестән,
Күрсәм иде кеше җанлы итеп,
Баш тартмаучы итеп һәр эштән.
Хыялларның чиге юктыр кебек,
Шулай да бар кебек бер чиге.
Еллар үтеп, уналтыңа җиткәч,
Күрә алсам икән мин сине.
Нигә әле уналтыңа җиткәч?
Үсмерлекнеңме ул асылы?
Уналтыда каршы алачаксың:
Уналтыда — яңа гасырны.
Искитмәле булыр бөтенесе —
Ил кылганы, халык кылганы.
Ләкин бүген афәтләрдән саклап
Калырга без тиеш дөньяны.
Бу беренче Яңа елың гына...
Яңа гасыр белән син мине
Котлый алсаң иде... Һай, син хыял!
Хыялларның юктыр ул чиге...

## Плащ-палатка

Сугышларда кигән әйберләрне
Я ташладым, я мин югалттым.
Плащ-палаткам! Яудан син бердәнбер
Сакланып бит калган комарткым[1].

Окопларда яки походларда
Җил-яңгырда сине ябындым.
Тере шаһиты син ут эчендә
Тере калган солдат чагымның.

...Бүген менә көннәр салкынайды,
Иртән кырау төшәр, мөгаен.
Кичен сине чәчәкләргә яптым
(Бик холыксыз быел май ае).

Чәчәкләргә яптым... Моңсу уйлар
Урап алды мине:
Сине ябынганда, минем дә бит
Чәчәк чагым иде.

[1] Истәлекле әйбер (Ред.)



Каләмдәшебез, 1968 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы, танылган шагыйрь, прозаик һәм драматург Фәнис Яруллинга 50 яшь тулды.

Фәнис **Гатаулла улы Яруллин 1938 елның 9 феврале**ндә Татарстан АССРның Баулы районы Кызылъяр авылында туган. Җидееллык мәктәпне, аннан Баулы урта мәктәбендә сигезенче классны тәмамлагач, 1954 елда «Татнефть» берләшмәсенең Баулы элемтә конторасында монтер булып эшли башлый. 1957 елда Совет Армиясе сафларына чакырыла; һава укчы радистлар мәктәбендә укый, спорт белән мавыга. Әмма күнегүләр вакытында турниктан егылып имгәнә, йөри алмас хәлдә кала. Яшәү өчен, тормышта Н. Островский һәм аның герое — Павел Корчагин кебек үз урыныңны табу, чын кеше булу өчен көрәш башлана: ул 1963 елда экстерн тәртибендә урта мәктәпне, аннан 1970 елда читтән торып укып, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. Әмма чын батырлык, рухи көч иясе булып Ф. Яруллин иҗатында танылды — яшәү көче, оптимизм, тормышны ярату белән сугарылган, заманча, көчле рухлы әдип була алды ул.

Ф. Яруллинның шигырь һәм хикәяләре башта Баулы район газетасында, аннан республика көндәлек матбугатында басыла; 1964 елда исә аның беренче мөстәкыйль китабы — «Мин тормышны яратам» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Аннары — хикәя, балалар өчен шигырь җыентыклары. Хәзерге көндә ул — ике дистәгә якын шигырь һәм проза китаплары авторы. «Аерылмас дустым» һәм «Сулыш» исемле шигырь китаплары өчен ул 1978 елда Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясенә лаек булды.

Шулай ук аның җитмешенче, сиксәненче елларда дөнья күргән «Җилкәннәр җилдә сынала», «Кыйгак-кыйгак каз кычкыра» повестьлары да укучылар тарафыннан җылы каршыланды. Ф. Яруллин — хикәя жанрында да матур уңышларга ирешкән язучы.

Ул драматург буларак та танылды: «Әнә килә автомобиль» комедиясе, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия һәм республика драма һәм комедия театрлары сәхнәсендә уйналып, уңыш казанды.

Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен Ф. Яруллинга 1985 елда Татарстан АССРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем бирелде.

50 яшен әдип иҗат күтәренкелеге белән каршылый: 1988 елда «Шигырь китапханәсе» сериясендә аның зур сайланмасы дөнья күрәчәк.

Юбилее белән котлап, без бу санда укучыларыбызга Ф. Яруллинның яңа шигырьләрен тәкъдим итәбез.

# Фәнис Яруллин

## Бәхет турында уйлану

Әгәр бәхет шатлык кына булса,
Шатлыкларны булды кичергәнем:
Эшли алуыма сөенә-сөенә,
Иңнәремдә таулар күчергәнем.

Әгәр бәхет сөю-сөелү булса,
Йөзгәнем бар сөю диңгезендә:
Шул диңгезнең ачы тамчыларын
Саклап йөртәм әле мин күземдә.

Әгәр бәхет җиңүләрдән торса,
Күргән булды минем җиңүләрне:
Янартауда басып торганым бар
Давылларга ачып изүләрне.

Әгәр бәхет дус-ишләрдән торса,
Дусларымның булды алтыннары...
Җуйсам да мин хәзер бик күпләрен,
Йөрәгемдә калды ялкыннары.

Бәхетне соң сөю-сөелүләрдән,
Шатлыклардан аеру җиңелмени?!
Җиңеп-җиңелеп, янып-ялкынланып
Яшәү үзе бәхет түгелмени!

## Бер сукмак салыр идек

Йөзләреңдә яшьлек яме,
Күзкәйләрең сөрмәле.
Күзләреңә яшеренгән
Мәхәббәтнең серләре.

Күзләреңдәге серләрне
Гел укыр, армас идем.
Күңелеңдә ниләр барын
Аңламый калмас идем.

Синең күздән минем күзгә
Күпме нур күчәр иде.
Ике күңел арасында
Чәчәкләр үсәр иде.

Шул чәчәкләр арасыннан
Бер сукмак салыр идек.
Серле мәхәббәт илендә
Мәңгегә калыр идек.

*

Ятамын юрган астында
Салкыннан куырылып.
Чапмыйлар хәтта уйлар да
Ат кебек томырылып.

Кышларның салкын вакыты,
Язларга әле иртә.
Җилләр дә, өйгә керт диеп,
Черт-черт тәрәзә чиртә.

Китегез, кит, кертә алмыйм,
Үпкәләмәгез, җилләр.
Иркенлек сөйгән җилләргә
Бик кысан безнең өйләр.

Исегез дала-кырларда
Йөрүнең тәмен татып.
Кысанлыкта яшәгәнче
Иркендә үлү артык.

*

Ут әйләнеп очкан күбәләктәй,
Зур дөньяның нәни тирмәсендә —
Әйләнәбез гомер буена без
Үзебезнең язмыш тирәсендә.

Чыгалмыйбыз олы орбитага,—
Шул ут безне гүя бәйләп куйган.
Язмышларның нәни учагында
Күпме җаннар янып һәлак булган.

## Оныт

Оныт әйдә, үпкәләмим,
Алма мине телгә дә.
Онытып, син йөрәгемне
Парә-парә телгәлә.

Очрашканда, күрмичә кит,
Җаным үксеп еласын.
Күкрәгемдә көне-төне
Җил-давыллар уласын.

Оныт әйдә, гамьсезлегең
Шундый хәлгә җиткерсен —
Хисләремнең һәр тамчысын
Ярсу диңгез иттерсен.

Шул чагында, теләп синең
Игътибарың яуларга,
Үрелермен болытларга,
Үрмәләрмен тауларга.

Оныт мине, утларга сал,
Ташла әйдә суларга.
Өйрәт шулай уттан — янмый,
Судан батмый чыгарга.

*

Җир — зур йомгак,
Урый язмышларны,
Җеп очларын яшереп бик эчкә.
Тик бер җебен генә тартып кара,
Уннарча җеп чыгачак өскә.

Миллион язмышларны урый-урый,
Әйләнә Җир көн-төн, әйләнә.
Торган саен күбрәк җепнең очы
Бер-берсенә килеп бәйләнә.

Язмыш җебен сүтеп караганда
Сак эш ит, син берүк, Кешелек.
Урар җаен табып булмас аннан,
Йомгагыбыз куйса бүселеп...

*

Бер шатлыгымны аккош иттереп
Очырган идем ак юллар юрап,
Явыз браконьер атып төшерде,
Оча алмады аккошым ерак.

Шул көннән бирле аккошларымны
Зәңгәр күкләргә очырам сирәк:
Шатлыкларымны — аккошларымны
Браконьерлардан сакларга кирәк...

*

Язмыш, язмыш, күп сорамыйм
Синнән бер дә:
Яманлыкны онытмаслык
Хәтер бирмә;
Йөрәгемне май капларлык
Байлык бирмә;
Һичкем өчен сызланмаслык
Саулык бирмә;
Кешелегемне кимерлек
Шөһрәт бирмә;
Сөюне таптап изәрлек
Кодрәт бирмә;
Усаллыктан сукраерлык
Күңел бирмә...
Кешеләрне туйдырырлык
Гомер бирмә.

*

Чит җирләрдә озак еллар йөреп
Авылына кайткан бер картка
Сорау биргәннәр ди якташлары:
— Я, ниләр бар читтә, еракта?
Тәмәкесен алып кабызган карт,
Түбәтәен төзәтеп кигән,
Ә аннары, тирән көрсенгән дә:
— Чит җирләрдә сагыну бар,— дигән.

## Тукай Петербургта

Салкын җилләр белән каршылады
Петербург сине — пайтәхет.
«Тешен сындырып бирә, диләр, имеш,
Алла бүрегә бирсә дә бәхет»[1].

Язмыш синнән барсын күпсенде шул —
Үрелсәң дә бәхет кошына,
Синең өчен түгел бит ул, диеп,
Суга торды синең учыңа.

Башкалада инде бер опера
Карармындыр диеп килсәң дә,
Челпәрәмә килде хыялларың —
Алган билет калды кесәңдә.

Маринский театрда[2] әнә
Бара иде «Евгений Онегин».
Татар тормышыннан шундый әсәр
Язарга дип йөри идең син —
Өлгермәдең.
Һаман шул хәсталек
Киртә куя торды юлыңа...
Петербург ул чак зур хөрмәтен
Күрсәталмый калды
Россиянең бөек улына.
Әмма тарих бераз соң булса да
Үз хатасын барыбер төзәтте:
Үзең баралмаган театрга
«Шүрәле»ңне китереп күрсәтте.

---

[1] Тукайның «Мәкаләи махсуса» әсәреннән.
[2] Маринский театр — хәзерге Киров исемендәге опера һәм балет театры.

## Ике күз

Язны тамчы ашыктыра:
— Тиз-тиз-тиз!
Тәрәзәдә карап тора
Ике күз.

Бал кортлары оча башлый
Без-без-без!
Тәрәзәдән карап тора
Ике күз.

Уйный яфрак бураннары,
Тышта көз.
Тәрәзәдән карап тора
Ике күз.

Кышлар җитә, тел очында
Туңа сүз.
Тәрәзәдән карап тора
Ике күз.

Бик ваемсыз түгелме соң
Кайчак без?—
Тәрәзәдән карап тора
Ике күз.

## Алданып та куям кайчакларда

Инде бүтән гашыйк була алмыйм,
Очрамыймы әллә кешесе?
Чибәрләрне күрсәм, борылып карыйм,
Юкмы диеп синең төслесе.

Очрамый да түгел, очрап тора
Карашы — таң, йөзе — кояшлар.
Тик берсе дә аның син булмый шул,
Була бары сиңа охшашлар.

Алданып та куям кайчакларда
Охшаш йөзләр китсә чалынып.
Яшимен мин шулай әллә сиңа,
Әллә мәхәббәткә табынып.

## Очкын калсын

Яратып бер кара әле күзләремә,
Карашыңнан ут йөгерсен йөзләремә.
Шушы утның очкынын да сүндермичә
Алып кереп китим әле көзләремә.

Көзләремнең озын, салкын кичләрендә
Соңгы күмер сүнгән чакта мичләремдә,
Шушы уттан бәлки җылы алырмын да
Бер талпынып куярмын мин хисләремдә.

Кабына алмам, табына алмам, беләм ансын,
Йодрык кадәр йөрәк тагын күпме янсын?
Ә шулай да иң ахыргы җырым өчен
Күкрәгемдә бер булса да очкын калсын.

Заман гел-гел ашыктыра безне,
Алга текәлгәннәр барлык күзләр.
Тәгәрмәчкә каткан балчык кебек
Читкә сибелеп кала кирәксезләр.

Тизлек арткан саен, җаннар ярсый,
Җитдиләнә бара безнең йөзләр.
Куркакларга заман арбасында
Урын бетә — коела йөрәксезләр.

Без барабыз иңләп олы юлны,
Бер-беренә кушыла күпме эзләр.
Авып кала безнең җилебездән
Тамырлары черек — терәксезләр.

## Сезне яратканга, дусларым

Йөз төрле чир белән тапаләшеп
Үтсәләр дә көз һәм кышларым,
Зар сораган телне тешләп калдым,
Сезне яратканга, дусларым.


Күрсәтмәдем сары сагышымны,
Белгертмәдем эчем пошканын.
Шулай җиңел булган өчен түгел,
Сезне яратканга, дусларым.

Сезнекеннән зуррак уңышым булса,
Шатлыгымнан күккә очмадым.
Шашып сөенә белмәгәнгә түгел —
Сезне яратканга, дусларым.

Сезнең дошманнарга кул бирмәдем,
Бер кысуга
Тилмерсә дә кайчак учларым —
Сезне яратканга, сезне яратканга,
Сезне яратканга, дусларым.



Уфада культурабыз истәлекләре



**«Галия» мәдрәсәсе урнашкан бина**

Чернышевский урамы, 5 йорт.

*А. Тимергалина рәсеме*

# «ГАЛИЯ» МӘДРӘСӘСЕ

Культурабыз тарихында тирән эз калдырган күп кенә атаклы шәхесләрнең тормышы, иҗат эшчәнлеге Уфадагы татар мәдрәсәсе «Галия» белән тыгыз бәйләнгән.

Мәдрәсә Россиядә беренче буржуаз-демократик революция елларында, «бишенче елны таң белән» уянган чорда — 1906 елда ачыла. Бу эштә башлап йөрүчеләрдән икенче мәхәллә имамы Зариф Галикәев була. 1908 елны «Галия» өчен элекке Уфимская (хәзерге Чернышевский урамы, 5 йорт) һәм Вавилов (хәзерге Нагорная) урамнары почмагында кызыл кирпечтән өч катлы махсус бина салына. Өченче катында класслар, китапханә, икенчесендә торак бүлмәләре, аскы катта аш өе, келәт һәм... тәмәке тарту бүлмәсе.

«Галия» мәдрәсәсе ачылу хәбәре татарлар яшәгән Идел-Урал буйларында гына түгел, Кавказ, Кырым, Урта Азиягә, хәтта чит илләргә дә тарала. Илебезнең төрле төбәкләреннән аңа шәкертләр агыла. Башка мәдрәсәләрдән мөгаллим-укытучылар да күчеп киләләр. Мәгълүм ки: революциягә кадәр татар мәктәп-мәдрәсәләренә патша хөкүмәте бер тиен дә акча тотмаган. Алар халык һәм аерым меценатлар хисабына яшәгән. Садрый Назиров, Хәсән Акчурин, Әхмәтсолтан Терегулов — «Галия»гә иң күп матди ярдәм күрсәтүчеләрдән. Әмма тора-бара байгуралар һәм морзалар, мәдрәсәдә укыган шәкертләрнең динсез булып чыгуларын сәбәп итеп, матди ярдәм итүне туктаталар. Мәдрәсә җитәкчесе Зыя Камали ниләр генә эшләми бу уңайдан?! Әнә шуны истә тотып, Г. Ибраһимов: «Зыя әл-Камали әфәнде хәтергә килә: ходай түзем бирсен, ул җан ничек кенә сугышмый да, ничек кенә кырыкка ярылмый»,— дип язган.

Мәдрәсәдә нинди фәннәр укытылган, ягъни аның исеме (Галия — югары дигән сүз) җисеменә туры килгәнме? 1914 елгы мәгълүматларга караганда, «Галия»дә шәригать кануннары, ислам дине тарихыннан тыш, татар, рус һәм гомуми тарих, татар, рус һәм гарәп телләре, алгебра, геометрия, табигать белеме, химия, Россия законнары, психология, логика, арифметика, матур язу һәм рәсем укытылган. Соңрак Г. Ибраһимов инициативасы белән музыка дәресләре дә кертелә башлый. Беренче империалистик сугыш башлангач эвакуацияләнеп Уфага килгән профессор Вильгельм Клименц, бөек язучының тәкъдиме белән, музыка укытучысы итеп алына. Ул мәдрәсәдә хор һәм кыллы оркестр оештыра. Тора-бара бу оркестр шәһәр халкының тирән ихтирамын казана.

Мәдрәсәдә шәкертләрнең төрле ирекле түгәрәкләре эшләгән. Аларның иң зурысы һәм иң озын гомерлесе «Милли көй, сәхнә һәм әдәбият» түгәрәге була. Монда шәкертләр җыр-музыка белән шөгыльләнәләр, спектакльләр куялар, җәй айларында халык авыз иҗаты җәүһәрләрен җыюда да мәгълүм эш башкаралар.

Кадим мәдрәсәләр белән чагыштырганда «Галия» шәкерте үзен шактый иркен тота: ул театрга бара, чәч җиткерә, китапханәгә кереп татар, гарәп, фарсы, төрек телләрендә генә түгел, рус газета-журналларын да укый.

1908—1909 елларда Хөсәен Ямашевның көрәштәшләреннән берсе, большевик Галимҗан Сәйфетдинов һәм башкалар мәдрәсәнең алдынгы шәкертләре арасында революцион эш алып барганнар. Алар яшерен җыелышлар үткәреп, докладлар, лекцияләр сөйләгәннәр, революцион әдәбият таратканнар.

Мәдрәсәгә Г. Ибраһимов мөгаллим-укытучы булып килгәч, татар теле һәм әдәбиятын укыту яңа баскычка күтәрелә. Шәкертләр ирекле темаларга иншә яза, шигырь-хикәя иҗат итә. Татарча гына түгел, казах телендә дә кулъязма журналлар күренә башлый.

«Галия»дә белем эстәгән йөзләгән, меңләгән шәкерт арасыннан соңыннан татар мәдәниятының гына түгел, казах, үзбәк, төрекмән, башкорт, Кавказ халыклары культурасының гүзәл сәхифәләрен язган эшлеклеләр үсеп чыккан.

*Х. Гобәйдуллин һәм Җ. Миңнуллин тексты.*

Марсель Зарипов

# ТАГЫН КАРАБОДАЙ ТУРЫНДА

Карабодай белән мин беренче тапкыр 1980 ел башларында — Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты селекционер-агрономы Наталья Николаевна Петелина белән очрашканнан соң кызыксына башладым. Безнең бу очрашуыбыз кыш көненә, елның һәртөрле ыгы-зыгылары, борчулары азмы-күпме кимегән, җир һәм басулар белән бәйләнешле кешеләрнең эшләгән эшкә йомгак ясаган — уңышларга куанган, кимчелекләрнең сәбәпләрен ачыклаган бер вакытка туры килде. Хәер, селекционерның уй-борчулардан арынып торган сәгате буламыни?!

Әңгәмәбез, әлбәттә, башыннан ахырына кадәр илебезнең карабодай кырлары турында, чәчәк аткан вакытта акка төренеп утыручы ул кырларның, бик күп сәбәпләр аркасында, әле һаман да кысыр булып калулары турында барды.

Төшке аш сәгате сукты. Мин үземнең кайда булуым, карабодайның яңа сортларын иҗат итү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтында икәнлегемне, бу өлкәдә бодай, көнбагыш, кукуруз игү буенча эшләүче селекционерлар шикелле үк зур хезмәт куйган кеше белән сөйләшүемне истә тотып, сорый куйдым:

— Нинди ризык белән сыйларга җыеналар икән соң бүген сездә? Карабодай боткасы булырмы?

— Нәрсә сөйлисез сез?! — дип кычкырып көлеп җибәрде Наталья Николаевна, кулларын як-якка җәеп.— Каян килсен ди ул карабодай?

— Ничек инде каян? Басудан.

— Гомер-гомергә карабодай иккән Төньяк-Көнбатыш хәзер аны чәчми,— дип сүз башлады Наталья Николаевна.— Алтайда, Башкортстанда һәм Татарстанда, Ерак Көнчыгышта карабодайны әле санга сугалар. Башка җирләрдә исә аңа тиешле хөрмәт тә юк. Калуга өлкәсендә аның турында бөтенләй онытканнар, Чувашстан аны нибары ике мең гектарга чәчә. Ставрополь краенда аны игәләр, Кубаньда исә кара туфраклы җирләрдән кысрыклый баралар. Красноярский краенда да эшләр шәп тормый. Югыйсә карабодайга анда шундый рәхәт! Куйбышев өлкәсендә дә аның чәчүлек мәйданын тагын утыз мең гектарга арттырырга мөмкинлек бар. Волгоградлыларның да бу кыйммәтле культураны утыз мең гектарга җиткерергә көчләреннән килә...

Мин әңгәмәдәшемне бүлергә мәҗбүр булдым:

— Сез бигрәк инде, меңәрләгән гектар турында хыялланасыз!..

— Шулай шул! Иген басуларының сигез-ун процентын карабодай тәшкил иткәндә нинди яхшы булыр иде!

— Ә хәзер ничегрәк?

— Кайда ничек. Иң күп дигәндә, бер ярым-ике проценттан артмас. Арыш үскән җирдә карабодай да каерылып уңа. Өстәвенә, карабодай — менә дигән фитокультура, әче туфракны дәвалый. Чүп үләннәренә җирлекне бетерә.

Сүзгә-сүз, мисалга-мисал ялганып, без карабодайны кайда күпме арттырырга мөмкин икәнлеген исәпләргә керештек. Һәм шактый зур санга менеп җиттек — тагын миллион гектар өстәмә алырга мөмкин икән.

Селекционер булып өч дистә ел эшләү дәверендә Наталья Николаевна Петелина карабодайның дүрт яңа сортын ачты. Ул — фәннәр кандидаты, өлкән гыйльми хезмәткәр.

Наталья Николаевна Татарстанга 1967 елда инде оста, тәҗрибәле, ләкин, кызганычка каршы, эшенең нәтиҗәсен күрә алмый интегүче селекционер булып килә. Аңа кадәр ул Россиянең төрле җирләрендә эшли, конкурс сынауларының нечкә иләге аша үткән үз сортларын булдыра. Уйларының басу киңлекләрендә дә тантана итүен тели ул. Әмма чалгысы гел ташка тия — иҗат иткән сортлары кулланылышка бик акрын кер-

телә. Юлында һәрвакыт туып торучы киртәләрне атлап чыга алмыйча ул, бәхет кошы артыннан, бүтән җиргә күчеп китә.

Татарстанда Наталья Николаевна селекционер бәхетенең һәм уңышының нәрсә икәнен үз гомерендә, мөгаен, беренче тапкыр татыгандыр. Әмма институтта карабодай буенча штаттагы ике селекционер урынының берсен алганчыга кадәр әле ун ел вакыт уза. Наталья Николаевна ачкан «Майская» һәм «Краснострелецкая» сортлары инде шул чакта ук безнең республикабызда чәчелгән карабодай мәйданының туксан процентын били. Моны, әлбәттә, гадәттән тыш кыска срок дип әйтү дөрес булмас. Ләкин бер нәрсәне истән чыгарырга ярамый: биредә сүз игенчене бик нык сыный торган, таләпчән, четерекле карабодай турында бара. Аны игүгә көчле рухлы, үз-үзенә нык ышанган оста кешеләр генә алына. Ниһаять, Татарстанның ил күләмендә, карабодайдан иң зур уңыш алган Азнакай районыннан Наталья Николаевна исеменә рәхмәт хаты килеп төшә: «Кадерле Наталья Николаевна! — диелә анда,— «Краснострелецкий» сортлы карабодайны районның барлык колхозлары һәм совхозлары кимендә меңәр гектар мәйданда игәчәкләр. Бик зур рәхмәт сезгә шундый сортны иҗат итүегез өчен!

Ихтирам белән В. Левин».

Мондый мактау һәм хуплау сүзләре кеше күңеленә күпме рухи күтәренкелек, күпме көч өсти! Агрономнар «Майская», «Краснострелецкая» сортларын куллана башлаган көннәрдә үк Наталья Николаевна инде карабодайның яңа төрләрен булдыру турында баш вата. Аңа төрле яклардан фикердәшләр табыла. Әйе, агроном-практикларның ярдәмен тоймаган селекционер — җилгә каршы атлаучы ялгыз юлчы кебек ул.

Һич уйламаганда, Н. Н. Петелинага Белгород өлкәсенең «Новая жизнь» колхозыннан Россия Федерациясенең атказанган агрономы В. С. Швыркин үзенең ярдәмен тәкъдим итә: «Наталья Николаевна! Безгә карабодайның үзегез уйлап тапкан «Сокуровская» сортлы орлыгын җибәрүегезне үтенәбез,— дип яза аңа колхозның баш агрономы.— Безнең хуҗалыкта бөртекле культураларның күп төрләре сынау уза. Бездә үткәрелә торган семинарларда өлкәнең барлык агрономнары катнаша. Әгәр сез иҗат иткән сорт әйбәт бәяләнә икән, аны ишәйтү киң колач алачак».

1978 елның көзендә институтка шатлыклы хәбәр килә: «Хөрмәтле Наталья Николаевна! Сез җибәргән өч центнер орлыктан 65 центнер уңыш алдык. Җитмеш гектар мәйданлы төп басуга чәчелгән «Шатиловская-5» сорты гектарыннан уртача тугыз, ә «Сокуровская» сорты 16,2 центнер уңыш бирде!..»

Мактауга лаек мисаллар, энтузиаст-агрономнарның шәхси уңышлары, саный китсәң, шактый җыела. Әмма аерым участоклардагы уңышлар гына илнең аграр фронтындагы югалтуны каплый алмый. Карабодайның тулаем хәле әле дә шәптән түгел. Әйтерсең, социаль һәм техник революция алып килгән искиткеч зур үзгәрешләр аңа бөтенләй кагылмый. Карабодай игелә торган җирләрнең мәйданы кими бара, шунлыктан уңыш җыеп алу да һичничек арта алмый.

* * *

Турысын әйтергә кирәк, соңгы елларда хәлләр нәкъ менә шулай килеп чыкты: мөмкинлекләр арткannan-артты. Фәнни-техник революция, куәтле машиналар һәм химия яңалыклары алып килгән материаль байлыклар карабодай игү өчен моңарчы беркайчан булмаган шартлар тудырды. Ләкин бу уңайлы шартларның нәтиҗәсе генә күренми. Үзгәрешләр һаман кире якка.

Советлар Союзы, мәсәлән, иген чәчү җирләренең мәйданын ике йөз унбиш миллион гектарга җиткерде. Исең-акылың китәрлек сан бу! Нинди бөек эш эшләнгән! Моңа күпме көч, күпме чыгымнар түгелгән?! Шуның өчтән ике өлешен, чама белән әйткәндә, йөз илле миллион гектарын ике мең ел буена үзләштергәннәр. Ә калган өлеше бер кеше гомере эчендә булдырылды. Чирәм җирләр үзе генә дә кырык миллион гектардан артыграк яңа чәчүлек мәйданын бирде.

Безне туендыручы кишәрлекләр артты. Бу исә үз нәүбәтендә кешеләргә яңа борчулар, яңа мәшәкатьләр дә өстәде. Аларның беренчесе — сөрү җирләренең уңдырышлылыгын күтәрү. Җирнең көчен саклап калу һәм тагын да арттыру өчен ашламалар куллануның, аны эшкәрткәндә төрле ысуллардан файдалануның кирәклеге һәркемгә мәгълүм. Бу юнәлештә игенченең борын-борыннан тупланып килгән тәҗрибәсеннән файдалану отышлы. Һәр үсемлек җирдән бары тик үзенә кирәкле азыкны гына ала. Йөземгә, мәсәлән, якты кояш җылысы төшкән тау битләре, кыяташлы урыннар, карбыз һәм кавынга кайнар комлы бакчалар кирәк. Ә кыяр, кабак ише культуралар тиресле җылы, йомшак җирне ярата төшәләр. Бодай, арыш, арпа, солы, кукуруз туфрактан азот, фосфор ала. Аның караваы калий алар өчен әллә бар, әллә юк. Дефицитлы азотны җирдән түгел, һавадан җыючы борчак, вика, соя, фасоль кебек

үсемлекләр дә бар. Басуларның җегәрен саклау чаралары табигатьнең үзендә үк көйләнгән, кешегә бары тик һәр үсемлекнең мөмкинлекләрен, бер культураның җирдән нинди азык алуын, икенчеләренең нәрсә калдыруын белергә һәм чәчүлекләрне дөрес чиратлаштырырга гына кала.

Игенчелектә халык туплаган йөзьеллык, меңьеллык тәҗрибә агрономнар теленә «чәчү әйләнеше» дип кергән. Вакыт бу бөек ачышны камилләштерә бара.

Хәзерге көндә агрономнар чәчү әйләнешенең нинди генә системаларын кулланмыйлар! Бодай чәчәр алдыннан ул җирдә нәрсә үстерергә, сөрелгән клевер басуына нәрсә чәчсәң әйбәтрәк уңыш бирер, үзләреннән алда игелгән культураларга шикәр чөгендеренең, дөгенең, кукуруз яки җитеннең нинди дәгъвалары бар — боларны белү хәзер зарури.

Ә чынбарлыкта эш ничек тора соң?

Кагыйдәләр иҗат ителгән, һәм, әйтергә кирәк, алар җиңел генә, үзләреннән-үзләре генә тумаган. Алар өчен тир һәм газаплар белән бик кыйммәт түләнгән. Табигатьнең мәрхәмәтлелегенә ышанып, басуларын чиратлаштырмыйча, арыш артыннан арыш, бодай артыннан бодай чәчкәне, бәрәңге җиренә бәрәңге утыртканы өчен игенче күпме җәфа чиккән?!

Үсемлекләр, бер-берләрен чиратлашып алыштырып торганда, кыйммәтле ашламалар кулланмаган очракта да, җинең бөтен сүлен суырып алып бетермиләр, игә белеп иккәндә, хәтта аның көчен арттыралар икән.

Мин җирне дәвалау чараларының берсе булган карабодайны игү мәйданы күпмегә артырга тиешлеген якынча исәпләп карадым. Юк, чама чамага һич тә туры килми. Аны елдан-ел азрак чәчәләр. Дөрес, карабодай боткасының абруе элекке еллардагы кебек үк түгел. Табыннарыбызда ит, сөт, яшелчә, җиләк-җимеш кебек ризыкларның муллыгы да карабодай куллануны шактый киметте. Ләкин илдә бит җан саны да йөз сиксән миллионга артты. Шуңа күрә бу ризыкка ихтыяҗ кимемәде, киресенчә, арткаңнан-арта, тик шул ихтыяҗны канәгатьләндерү буенча эшләнгән эш көн таләпләренә җавап бирел бетерми.

Бу мәкаләне язарга утырыр алдыннан мин бик күп мәгълүмат тупладым.

Алга менә нинди күренеш килеп басты.

Революциягә кадәр Россиядә карабодайны бер миллион ике йөз илле бер мең гектар мәйданда чәчкәннәр. Күмәкләшү елларында бу сан ике йөз мең гектарга кимегән. Әмма сугыштан соңгы беренче бишьеллыкта ул ике миллион гектар мәйданны били. Бу — барлык чәчүлек җирләренең ике процентган артыграгы диген сүз.

Шуннан соң карабодай игүдә ниндидер бер аңлашылмаучылык хөкем сөрә. Чәчү мәйданы кимүдән күрелгән зарар югары уңыш алу хисабына капланса, бер хәл иде. Сигезенче бишьеллыкта Россия Федерациясе колхоз-совхозлары бер миллион ике йөз туксан сигез мең гектар карабодай чәчкәннәр. Һәр гектар уртача алты центнердан чак кына күбрәк уңыш биргән. Аннан соңгы бишьеллыкта бу басулар йөз илле мең гектарга кимегән. Мондый хәл карабодайны санга сукмаудан бигрәк, агротехника белән исәпләшмәүне, авыл хуҗалыгы белән идарә итүнең тиешле югарылыкта тормавын күрсәтә. 1979 елда карабодайдан биш центнердан да азрак уңыш алынган. Элеваторлар аны биш йөз утыз мең тонна кабул итәргә план коралар, әмма карабодай кеткәннән дүрт тапкырга кимрәк килә. Аны житештерү 1913 елгы дәрәҗәгә дә җитми.

Шулай булгач, карабодайның табыннарда әллә нигә бер очрый торган ризыкка әйләнүе гаҗәпмени?!

Карабодайның язмышы турында беренче тапкыр язганда мин, үземне борчыган сорауларга җавап эзләп, Мәскәүгә, бу тармакның штабы саналган В. И. Ленин исемендәге Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы академиясенә юл тоттым.

Мәскәүгә килгәч мин телефон аша ВАСХНИЛның үсемлекчелек бүлеге фәнни секретаре Григорий Трофимович Лавриенко белән элемтәгә кердем. Аңа үземне нәрсәләр борчуы турында сөйләп бирдем, хәзерге көндә карабодай белән эшнең ничек торуы, аның киләчәге турындагы уй-фикерләре белән уртаклашуын үтендем. Фактлар, саннар — болары бер нәрсә, иң мөһиме — нәрсәне аңлата алар? Әнә шуның серенә төшенергә иде!

Григорий Трофимович Лавриенко гомуми проблемалар белән шөгыльләнә икән. Минем бәхетемә, академиягә Орелдан бөртекле-кузаклы һәм ярма культуралары Бөтенсоюз институты директоры, биология фәннәре докторы Николай Михайлович Чекалин килеп төште.

— Дөрес, карабодай белән эшләр шәп түгел,— диде Николай Михайлович.— Аның караве, һәртөрле рекомендацияләр, уйланылган планнар, теләкләр һәм киңәшләр буа буарлык. Эшләргә, фән сүзенә колак салырга кирәк!

Ә менә бөртекле һәм майлы культуралар баш идарәсенең тармак бүлегендә миңа болай дип аңлаттылар:

— Селекционерлар яңа сортларны җитәрлек иҗат итми. Элита орлыклар турында әйткән дә юк...

Менә сиңа мә! Үзара әйбәтләп аңлашу, фикер бердәмлеге һәм иҗади дуслык урынына кара-каршы шелтәләшү, үпкәләшү... Мондый аңлашылмаучылык агроном-практикларның күз алдында карабодайның абруен төшерә, элек ул биләгән җирләрне башка культураларга биреп, аңардан котылу ягын чамалыйлар.

Яңа сорт тудыру өчен, осталыкны чын-чынлап эшкә җиккәндә, ун ел вакыт бик җиткән. Наталья Николаевна Петелина уңышын исә һичбер икеләнүсез сирәк очрый торган күренеш дип әйтергә мөмкин. Россия Федерациясе чиксез киң. Һава шартлары һәр җирдә төрлечә. Иксез-чиксез киңлекләрдә карабодайның өч дистә сорты игелә. Агрономия нечкәлекләрен белеп җиткермәгән кешегә бу санның зур күренүе дә ихтимал. Кул астында карабодайның шул кадәр сорты булганда, иң яхшысын сайлап ал да шунысын игә бир!

Ашлыклар каталогында карабодай төрләренең саны иң соңгы урыннарның берсен алып тора. Чәчүлек әйләнешендә бодайның — йөз кырык, арпаның — җитмеш җиде, кукурузның туксан алты сорты исәпләнә...

Карабодайның яңа сортларыннан алынган элита орлыгын тапшыру бурычы йөкләнгән тәҗрибә хуҗалыклары 1977 елда дәүләткә егерме сигез мең йөз алтмыш центнер иң яхшы сыйфатлы орлык сатарга тиеш булганнар. Бурыч кырык процентка гына үтәлгән. Уңышсызлыкның сәбәбен аңлату өчен сүзләр әзер — һава шартлары «утырттты». Икенче көздә эшләр тагын да түбәнгәрәк тәгәри. Агрономнар үзләренә кирәкле орлыкны нибары җиде мең җиде йөз утыз бер центнер гына алдылар.

Хәлләр елның-елында шулай кабатлана — яңгырлы яки коры елда да, җәйләр кызу яки салкын килсә дә... 'кими генә карабодай орлыгы! Ә яңа төр орлыксыз нишләргә? Тылсымчы-селекционерларны күпме көтәргә?

Сугыштан соңгы елларда иҗат ителгән «Майская», «Красностреленкая», «Шатиловская-5» сортлары илебез селекциясенең беренчеләреннән булган «Богатырь» сортына караганда уңышны бер ярым-өч центнерга артыграк бирәләр. Инде басуларга нәрсә чәчелгәнен карыйк! Бәхетле һәм шул ук вакытта эшендә һәртөрле каршылыкларга очраучы селекционер Наталья Николаевна Петелина ачкан «Красностреленкая» сорты 1978 елда җитмеш бер мең биш йөз кырык дүрт гектар мәйданда чәчелгән, «Богатырь» исә ярты миллион гектардан артык җирне биләгән. Югыйсә бит ул вакытка инде «Красностреленкая» конкурс сынауларын үткән һәм тугыз ел элек «Хәерле юл!» сүзен ишеткән була. Теләк, төгәллек һәм оешканлык булганда бу вакыт эчендә күпме файда китерергә мөмкин иде!

Карабодай игү өчен, бөтен ил күләмендә, Орел яклары уңайлырак санала. Эш монда һава шартларының искиткеч әйбәт булуында гына түгел. Бу як илебез һәм дөньякүләм селекция тарихында үзенең күп санлы зур казанышлары белән дан тота. Биредә урнашкан ярма һәм бөртекле-кузаклы культуралар фәнни-тикшеренү институты нәкъ менә шул җирлектәге Шатилов селекцион станциясеннән үсеп чыккан. Арышның, солының, клеверның, озын сүсле җитеннең, кышкы салкыннарга чыдам люцернаның төрле сортлары һәм «Богатырь» сортлы карабодай безнең басуларга шушыннан таралган.

Карабодайның отышлы «Урожайная» сортын Орел селекционерлары 1975 елда чыгарганнар. Ул әле дүрт елдан соң да өлкәдә нибары җиде йөз гектардан чак кына күбрәк мәйданны биләгән. «Шатиловская-5» сортын, районлаштырганнан соң да, әле ун ел буе нибары сигез мең йөз утыз гектарга, ә элекке «Богатырь»ны илле җиде мең йөз туксан (!) гектарга чәчкәннәр.

Бер нәрсә бәхәссез: басу культурасы, кешенең үз культурасы кебек ук. Монда игенченең эшенә һәм оешканлыгына тулы бәя бирелә. Сигезенче бишьеллыкта Орел җире карабодайның гектарыннан — 6,3 центнер, тугызынчы бишьеллыкта — 5,6 центнер, унынчы бишьеллыкта — 2,6 центнер, унберенче бишьеллыкта 3,6 центнер уңыш биргән. Күрсәткечләр кечерәя бара. Гаҗәп түгел, табигый нәтиҗә. Җирне эшкәртү, басу әйләнеше кагыйдәләре үтәлми, игенче белән җитәкчелек итүгә игътибар юк. Кулларына нинди орлык эләксә, агрономнар туфракка шуны сибә бирәләр. Күпчелек очракларда орлык инде яшәүгә, үрчүгә сәләтлелеген әллә кайчан югалткан була. Тагын шул ук 1977 елны алам. Артык начар да, авыз тутырып мактарлык яхшы да килмәгән гадәти ул елны специальләштерелгән орлыкчылык хуҗалыклары колхоз-совхозлар өчен дүрт мең алты йөз центнер элита сортлы орлык җитештерергә тиешләр иде. Ул җитмеш центнер гына җитештерелде. Икенче елны алар алдына куелган шул ук бурыч көчхәл белән нибары яртылашка үтәлде.

Башка культураларга карата гафу ителмәслек, гадәттән тыш хәл дип бәяләнә торган күренешләр карабодай өчен гадәти, күнегелгән, табигый исәплнә. Моны берkem дә күрми, моңа беркем дә гаҗәпләнми. Борчыласы да, җавап бирәсе дә юк.

Шул ук вакытта берәү дә үзен гаепле санамый: «Эшли белмибез», «Барып чыкмый», «Ялкаулык зур, ихтыяр көче бәләкәй»,— дип әйтергә батырчылык итми. Аның карашы алар карабодайның үзе турында нинди генә яман сүзләр яудырмады, аңа нинди генә гаеп такмады?! Аларның фикеренчә, карабодай ул киргәгеннән артык иркә, назлы, нәзберек, үзсүзле культура икән. Үзенә һәрвакыт зур игътибар сорый, уңышы бинн-һая күп чараларга бәйле. Ул, имеш, салкыннан да курка, кызу һаваны да яратмый. Бал кортлары очмаса, чәчәге дә кысыр кала. Кыскасы, үги кыз хәленә төшүенә, имеш, ул бары тик үзе гаепле.

Мине иң гаҗәпләндергәне — кешенең табигатькә дәгъва белдерүе, урынсыз таләпләр куюы һәм, шуның артына посып, үзен акларга тырышуы. Газетада басылган беренче мәкаләдә мин нәкъ менә шул хакта язган идем дә. Нигә читәнгә бәйләнергә? Үсемлекләр турында гайбәт таратуның кемгә нинди файдасы бар? Ул мәкаләдә менә мондый ачулы юллар язылган иде: «Агротехника культурасының түбән булуы, идарә итүдәге ялгышлар, орлыкчылыктагы башбаштаклык карабодайга, иң рәхимсез корылыклар яки иң каты кыраулар алып килгән бәлагә караганда да, күбрәк зыян китерде!»

Икенче мәкаләмне ашыгыч рәвештә язарга мине илебезнең иң карабодайлы төбәге саналган Азнакай районындагы «Коммунизмга» колхозының тырыш, үз сүзендә торучан, талантлы механизаторы Фәхразый Кәримов белән әңгәмә этәрде.

Карабодай — күкрәгендә Алтын Йолдыз балкыган Фәхразый Кәримовның щатлыгы да, кайгысы да. Уңыш бирү ягыннан карабодайның алтын башаклы, гәрәбәдәй сапсары бөртекле бодайдан һич тә калышмавын исбатлаганы өчен ул Социалистик Хезмәт Герое дигән мактаулы исемне алды. Кайгысы шул — Фәхразый карабодай басуларының елдан-ел тарая баруына пошына. Кырлар күркенә кирәгенчә хөрмәт күрсәтелмәү аның йөрәген әрнетә.

Тышта яз иде. Чәчүгә төшәр көннәр. Игенченең баш өстендә бүз тургайларның күңелләрне җилкендергеч дәртле моңы тирбәлә. Карабодай игү осталарының югары сәнгать дәрәҗәсенә җиткерелгән нечкә, төгәл эшләренә имтихан тотар сәгатьләре. Ишетергә туры килгән төрле имеш-мимешләрне, әләк-ялаларны күз алдымда тотып, мин турыдан-туры әйтә куйдым:

— Эшегез бик үк татлыдан түгел сезнең.

— Нишләп? — Фәхразыйның сер бирәсе килми. Тыныч. Бернәрсәгә дә исе китмәгәндәй утыра. Күзләрендә генә кырыс очкыннар чагылып китте.— Ник алай булсын?

— Күпме генә тырышсаң да, җыеп алган уңышың белән беркемне дә таң калдыра алмаячаксың. Бодай түгел, арыш түгел, арпа түгел...

— Карабодайга кирәгенчә тәрбия бирсәңме?! Берсеннән дә калышмаячак.

— Ничек инде калышмасын? — Мин моннан бер сәгать элек кенә колхоз экономистыннан алынган саннарга күрсәтәм.— Менә: сиксән өченче елны колхоз һәр гектардан уртача егерме дүрт центнер алган, карабодай гектардан егерме центнер ярым гына чыккан.

— Шуның белән нәрсә әйтергә телисез? — Механизатор нindидер серне белә шикелле. Ләкин минем дә бирешергә исәп юк, бәхәсләшергә икән, бәхәсләшергә:

— Нәрсә генә әйтмә, өч центнер ярым — шактый аерма...— дим.

— Шулай да булсын! Ашлама бир, киң рәт белән чәчәр өчен техника бир! Җәй көне ике-өч мәртәбә культивация ясa! Гектарына өч оя исәбеннән бал кортлары китер! Шунда берни дә аерма булмаячак. Карабодай буенча Татарстан игенчеләрен зур осталардан саныйлар. Безнең тәҗрибәне күрергә илнең төрле якларыннан киләләр. Ә без орлыкның яртысын кадимдәге чәчкечләр белән чәчәбез. Ярты мең гектар мәйданда карабодай игәбез, умарталарыбызның саны дүрт йөз баштан да артмый.

— Карабодайга җил дә, эссе дә ярамый. Һавалар бозылып китсә, бал кортлары да оча алмый. Чәчәкләр кысыр калды дигән сүз.

— Сез нәрсә, табигатьне кешедән акылсызрак дип уйлыйсызмы әллә? — Фәхразыйның ачуы йөзенә бәреп чыкты. Мин нәүбәттәге соравымны читләтебрәк бирдем:

— Башакта ничә бөртек орлык була?

— Белмим. Агрономнардан сорарга кирәк.

— Юк, кирәкми. Мин болай да әйтә алам: утыз-кырык бөртек... Ә карабодай сабагында?

— Карабодай сыңар сабак булып үсми, күп ботаклы ул. Һәр ботагында өчәр мең чәчәк.

— Чәчәк бит әле ул бөртек дигән сүз түгел.

— Һәрбер чәчәкнең бөртеккә әверелүеннән алла сакласын! Ул чагында уңыш гектарыннан йөз-ике йөз центнерга җитәчәк. Ничек җыеп бетермәк кирәк шул кадәр байлыкны?!

Фәхразый әйткән сүзләренең бәясен белә. Аның һәр сүзе зур тәҗрибәгә нигезләнгән, фикерләре ышандырырлык, җитди һәм төпле.

* * *

Башта бер нәрсәне ачыклап үтәргә кирәк. «Советская Россия» газетасында 1980 елгы 6 апрель санында карабодай турында мәкаләм басылып чыкканнан соң нәрсә дә булса үзгәргәнме? Ул мәкаләдә мин игътибарны конкрет күренешләргә — күбрәк кайгырту таләп итүенә карамастан карабодайның башка культуралардан азрак уңыш бирүенә, моның сәбәпләренә, оешмаганлык, йомшак дисциплина, идарә итү алымнарының камил булмавы кебек субъектив факторларга юнәлткән идем.

Аннан бирле инде берничә ел вакыт узып китте. Шул арада нәрсә үзгәрде соң? Беренчедән, карабодайның бәясе күтәрелде, хәзер дәүләт аның тоннасын дүрт йөз сумга сатып ала. Табыш бирү ягыннан аннан да отышлырак культура юк. Бодайның бер тоннасы өчен, мәсәлән, элеватор йөз илле сум акча түли. Фәхразый Кәримов туып-үскән «Коммунизмга» колхозында бодайның гектары йөз унбиш, ә карабодайныкы ике йөз алтмыш сум табыш бирә. Рентабельлелек, тотылган чыгым һәм сатудан кергән акчаның нисбәте — биш йөз проценттан артыграк!

Менә сиңа карабодай!

Икенчедән, дәүләт карабодай тапшыручыга бер тоннага бер тонна исәбеннән комбиазык сатуны оештырды. Акчага тагын бер зур өстәмә. Бу колхоз председательләрен һәм совхоз директорларын иң кызыксындырган нәрсә. Монда инде икеләнеп торасы юк — тот та карабодай игәргә алын.

Болардан тыш тагын менә мондый өченче гаять мөһим шартны да истән чыгарырга ярамый. Карабодай сатуда бурычлы булып калмаган очракта гына хуҗалыкның дәүләткә ашлык сату планы үтәлгән дип исәпләнергә тиеш. һәм бу аңлашыла да. Промышленность предприятиеләре үзләре эшләп чыгарган товарның барлык төрләре һәм сортлары өчен җавап бирәләр. Игенче дә продукциянең тулы җыелмасы өчен җавап бирергә тиеш түгелмени?

Карабодай басуларында бераз алга китеш бармы соң? Мин матбугаттагы чыгышымның вакыйгалар агышына йогынты ясау-ясамавын үз күзләрем белән күрергә теләп, күзәтүләремне дәвам итәм. Чак кына булса да мактанырлык кайбер күңелле нәтиҗәләр бар кебек. Дөрес, чәчүлек мәйданы артмады. Кая ди ул, булган кадәресен дә тиешенчә тәрбияли алмыйбыз. Әмма уңыш азмы-күпме күтәрелде. 1983 елда карабодай биш йөз унбиш мең тонна, ягъни уңынчы бишьеллыктагыга караганда йөз дә өч мең тоннага артыграк, җитештерелде. Дәүләткә ул алтмыш мең тонна күбрәк сатылды. Ә шулай да планда каралган саннар дәрәҗәсенә күтәрелә алмадык. Илдә карабодай игелә торган край һәм өлкәләр күп, ләкин, Алтай краен исәпләмәгәндә, мактап телгә алырдайлары бөтенләй юк диярлек. Кара туфраклы Курск өлкәсе өч еллык планны нибары — егерме биш, Тула, Липецк өлкәләре унҗиде, Тамбов һәм Рязань өлкәләре үндүрт-унсигез процентка гына үтәде...

Һаман бер үк балык башын чәйнибез икән шул. Йөк урыныннан кузгалмаган. Безнең илдәй зур илгә алтмыш мең тонна — артыммыни ул?

Нишләргә, яклаучысыз калган карабодай башына төшкән бәла-казаларның сәбәбен каян эзләргә? Агротехника чытырманлыкларына кереп чумаргамы? Язганнарымның берәр кешегә кирәге булырмы? Кәгазь битенә күчкән уй-теләкләрем кемдә дә булса яклау табармы?

Карабодай турында язып оттырдым димәс идем. Менә: «Ник кирәкмәгән нәрсәгә тыгыласың, ник укучылар күңелен алгысытасың,— дип битәрләүчеләр дә, язганнарымны ике куллап хуплаучылар да булды. «Инде бу эшкә алынгансың икән, әйдә, тирәнрәк сөр, каләмеңнең үтмәсләнүеннән курыкма»,— диделәр. Алар, матур-матур теләкләр белдерделәр. Элекке заманнарда базарында карабодай сатыла торган махсус урыны булган борынгы Новгород шәһәреннән Александра Филипповна Зачиналова, мәсәлән, менә мондый хат язды: «...Урып-җыю өчен кирәкле машиналарның җитәрлек булмавы хакында бик күп аһ-зарлар ишетелә. Сатуда карабодай ярмасының күренмәве дә шуның белән аңлатыламыни? Төп сәбәп нәрсәдә соң? Промышленность предприятиеләрендә планны үтәмәсәләр, директорны елдан артык тотмыйлар. Теге яки бу күрсәткечнең ни өчен үтәлмәве турында аңлатмалар кабул итәлми. Ә монда дистәләгән еллар уза һәм барысы да элеккечә кала...»

Мин, һәртөрле объектив һәм субъектив шартлар тудырган хәлләргә буйсынып, язу-сызулардан ваз кичәргәме, әллә алган темамны алга таба дәвам итәргә, тагын да көчлерәк, саллырак дәлилләр табарга тырышыргамы, дип уйланып йөргән көннәрдә Чувашстаннан икенче бер хат килеп төште. «Язучы да, аның фикеренә үз битләрендә урын биргән газета да, ди ул, болытлар арасында очып йөриләр. Куктә очып йөрмәскә, җиргә төшәргә, эшне тәртиптән, катгый җаваплылыктан башларга кирәк!» Дөрес сүзләр! Һәркем үз бурычын намус белән үтәсә, башка берни дә кирәк түгел — карабодай, басуларыбызның үги кызы булуыннан туктап, кырлар патшасына әверелачак.

Беркем дә бәхәсләшми, тәртип, җаваплылык, намуслы эш кирәклеге үзеннән-үзе аңлашыла. Ләкин һәр фикернең нигезендә фактлар ятарга тиеш. Чувашстаннан килгән бәхәсле хатта исә фактлар урынына «Советская Чувашия» газетасының карабодай мәсьәләсенә багышланган мәкаләсе тәкъдим ителә. Мәкалә 1984 елның 23 мартында басылган.

Мәкаләне тулысынча шәрехләп тормастан, төгәл һәм ачык мисалларга, фактларга тукталып үтәм. Менә аларның кайберләре:

«...Соңгы биш ел эчендә карабодайның һәр гектарыннан уртача нибары 2,75 центнер уңыш җыеп алынды»...

«...Күпчелек хуҗалыкларда карабодайны уңыш алу өчен түгел, бирелгән чәчү планын үтәү өчен генә чәчәләр»...

«...1983 елда тикшерелгән участокларның җитмеш өч процентына — гадәти репродукциядәге, унбиш проценттан артыграгына кондициясез орлык чәчелде»...

«...Узган өч елда Чуваш дәүләт авыл хуҗалыгы тәҗрибә станциясе йөз илле өч центнер «Сокуровская» һәм «Шатиловская-4» элита сортлы карабодай орлыгы җитештерергә һәм сатарга тиеш иде, әмма ул аны бер центнер да сатмады»...

«...Үткән биш елда республика хуҗалыкларыннан дәүләт ресурсларына планда билгеләнгән биш мең тонна урынына өч йөз илле тонна гына карабодай керде. Узган ел дәүләткә аны сатуда йөз алтмыш хуҗалыкның унтугызы гына катнашты...»

«...1982 елда карабодайның тулаем күләме алты мең бер йөз җитмеш ике центнер тәшкил итте, дәүләткә шуның бер мең бер йөз алтмыш центнеры сатылды»...

«...Күп кенә хуҗалыкларда, мәсәлән, Батыр районында, карабодайны терлекләргә ашаталар.»

Мондый мисалларны мин тагын да китерә алган булыр идем, әмма нәтиҗә ясарга болары да җитә. Саналып узылган хәлләр турында уйлануны укучының үзенә калдырыйк.

Дөрестән дә, мин сүзне зурдан кубарам — агротехника, чәчү әйләнеше, орлык сортлары турында алып барам, күкләрдә йөзәм кебек, ә тормыш җирдә дәвам итә.

Аннан соң мине икенче бер нәрсә — терлекләрне карабодай боткасы белән туйдыручы сәер кешеләр кызыксындырды. Кемнәр алар, кайда туып үскәннәр?

Александра Филипповна Зачиналова сүзләре бөтен җитдилеге белән яңгырарга тиеш. Завод конвейерында эшләүчеләр алдына куелган таләп ни өчен әле авыл хуҗалыгы тармагындагы җитәкчеләрне читләтеп үтә?

План ул — агротехника гына түгел, ә кешеләр. Аны үтәү кешеләрнең ничек эшләүләренә, үз бурычларын ни дәрәҗәдә җаваплылык тоеп башкаруларына бәйләнгән. Кыскасы, мин куен дәфтәремне, каләмемне һәм әлеге газетаны алып, ачулы, принципиаль мәкалә эзеннән Чувашстанга юл тоттым.

Батыр районы — Чувашстанның икмәккә бай төбәкләреннән берсе. Партия райкомының беренче секретаре Василий Антонович Никитин гектарыннан утыз гына центнер уңыш алу канәгатьләндермәвен, андый күрсәткеч белән терлек азыгы запасы туплауга ирешеп булмаячагын, ит һәм сөт җитештерү буенча торгынлык килеп чыгачагын, кешеләрнең хуҗалык итүдәге материаль һәм мораль кызыксынулары кимиячәген бер-бер артлы тезеп китте.

Әмма мине карабодай кызыксындыра, күкрәгемне кесәмдәге аны терлекләргә ашату турындагы мәкалә яндыра. Дөресен генә әйткәндә, мин андагы фактларның расланмавын телим.

Кызганычка каршы, язылганнар расланды. Соңгы сигез ел эчендә Батыр районы хуҗалыклары дәүләткә карабодай сату буенча һәр ел саен бурычлы булып калганнар. Түлисе әҗәт биш йөз тонна чамасы. Карабодайны биредә бик аз, барлыгы ике йөз гектар мәйданда чәчәләр. Райондагы уналты хуҗалыкның һәрберсенә уртача 13 әр гектар чамасы туры килә дигән сүз. Эш түгел, күңелле бер мавыгу! Уңыш бирсә — хуп, бирмәсә — хуп!

— Карабодай белән мәшәкатьләнүдән файда юк,— диде Василий Антонович Никитин, хәл бераз ачыклана төшкәч.— Бодайдан без — егерме бишәр-утызар, хәтта аннан да артыграк, ә карабодайдан, иң күп дигәндә, сигез-ун центнер уңыш алабыз...

Бурычны үтәмәгән өчен җавап бирү мәсьәләсе искә төште дә мин аңа ачыктан-ачык сорау бирергә җөрьәт иттем:

— Әйтегезче, Василий Антонович! — дидем.— Карабодай аркасында сезнең җаваплылыкка тартылганыгыз булдымы?

— Юк.

— Ә сезнең, партиянең район комитеты беренче секретаре буларак, әлеге тармакны үстерүгә аяк чалучыларга җәза биргәнегез бармы?

— Мине карабодай белән борчымадылар, үзем дә ул хакта сүз кузгатуны кирәк тапмадым.

Мәсьәләгә әнә шулай җавапсыз карау — илдәге бөтен регионнарга хас күренеш.

Шул ук көнне мин Чувашстанның экономик яктан нык, көчле һәм илнең иң югары бүләге — Ленин орденына лаек булган «Гвардеец» колхозына киттем. Дөресен әйтергә кирәк, бу колхоз игенчеләре әле хуҗалык итүнең «югары математикасын» ахырынача үзләштереп җиткермәгәннәр. Иген кырларында яуланган уңыш — терлекчелектәге казанышлар белән беркетелмәгән. Шулай да алар югары уңыш үстерү серләрен яхшы беләләр. Олы бүләккә дә игенчелектәге уңышлары өчен лаек булганнар. Барлык чәчү мәйданының туксан биш процентына элита сортлы орлык чәчелә. Утыз центнерны бирердә түбән уңышка саныйлар. Чәчү әйләнешендә карабодай да бар. Аңа бүлеп бирелгән җирнең мәйданы егерме гектар чамасы. Ләкин ташландык хәлгә килгән ул басуга орлыкның һәртөрле очраклы сортларын чәчәләр, якын тирәдә бер генә умарта да күрмәссең. «Гвардеец» ел саен йөз ун центнер карабодайны дәүләткә сатарга тиеш. Соңгы тапкыр элеваторга аны 1979 елда илткәннәр: суктырып алынган йөз дә сигез центнер бөртекнең дәүләткә җитмеш центнеры сатылган. Башка елларда күбрәк, ике йөз иллешәр центнер уңыш алган чаклары да булгалаган, әмма дәүләткә аның бер килограммын да сатмаганнар.

Мин әле «Гвардеец» колхозының тырыш механизаторларын туклыклы карабодай боткасы белән сыйлый торганнардыр, бу тансык ризыктан колхозчыларга да өлеш чыгаралардыр, дип уйлаган идем.

Каршымда колхоз председателе Мөлеков, авыл советы рәисе Немцев, партком секретаре Торговцев утыра. Барысы да — җитди, укымышлы кешеләр.

— Карабодай боткасын без төшебездә генә күрәбез,— дип кире какты минем фикеремне партком секретаре.— Соңгы тапкыр мин аны санаторийда ашаган идем...

Менә сиңа табышмак! Чәчүен дә чәчәләр, уңышын да җыеп алалар. Гектарыннан унберәр центнер уңыш алган еллары бар. Карабодай өчен начар уңыш түгел. Кая куялар соң? Җавап та һаман шул ук: утлыкларга аударалар, терлекләргә ашаталар. Әмма шунысы кызганыч: мал-туар моның кадерен белми, хуҗалыкта терлекчелек тармагы бик нык аксый. Кырлар табыш бирә, фермалар зыянга эшли.

Нәрсәләр генә күзәтергә туры килмәде миңа тормышта? Кызарып пешкән алма өемнәре өстеннән трактор белән үтүләрен дә, кәбестә, кишер кебек яшелчәләр белән беррәттән, тәмам өлгереп җиткән карбыз, груша, помидор, саргылт-ал шәфталуларны фермаларга ташуларын һәм силоска салуларын да күрдем. Яшелчә, җиләк-җимеш тиз бозылучан, ичмасам, терлек ашасын! Аңлашыла. Ә менә амбарда ничә еллар буена ятса да бозылмый торган карабодайны терлекләргә ашатучы кешеләрне һичничек аңлап булмый.

— Нишлисез сез? Кайда сезнең оятыгыз? Диабет белән авыручылар, сугыш инвалидлары карабодай ярмасын талон белән генә алалар.

— Оятның монда ни катнашы бар? — Моңарчы колхоз председателе Мөлеков минем сүзләремне, башын иеп, тыныч кына тыңлап торган кебек иде. Хәзер ул кинәт кырысланып китте, күндәмлеге бөтенләй юкка чыкты.— Бөртекләләр буенча планнарыбызны үтәдек, карабодайны аерым сорамыйлар.

Сорамаулары, чыннан да дөрестер. Әмма ярма культураларын билгеләгән күләмдә сатмый торып, колхозлар һәм совхозларның дәүләткә ашлык сату планы үтәлгән саналмый, дигән күрсәтмә инде 1981 елда ук гамәлгә кертелгән. «Гвардеец» колхозы исә дәүләткә сатасы урынга, аны терлекләргә ашата, һәм сводкалар буенча, ул 1983 елда ашлык сату планын йөз дә тугыз процентка үтәгән булып исәпләнә. 1984 елда Татарстанда ашлык җитештерү буенча барган социалистик ярышта Зеленодольск районы җиңүче итеп танылды, аңа байрак тапшырдылар, премия бирделәр. Баксаң, бу район карабодай сату планын яртылаш кына үтәгән...

Законнарны, һәртөрле карарларны күпләп чыгарырга мөмкин. Әгәр җиренә җиткереп үтәмиләр икән, алардан ни файда? Бары тик үтәлгән закон гына — иң яхшы закон икәнлеген ник һаман онытабыз икән?!

* * *

Карабодай басуы өстендәге «кара болыт» ник шулай бик акрын тарала? Ныклабрак уйласаң, аннан акчалата зур табыш алырга була, өстәвенә терлекләр өчен күпме катнаш азык бирәләр!

Бу мәсьәлә турындагы беренче мәкаләмне мин Наталья Николаевна Петелина белән очрашканнан соң яздым һәм карабодай басулары белән бодай, арпа, кукуруз кырлары арасында бик зур аерма булуына, түбән уңыш бирүенең төп сәбәбе орлыкта, агротехникада, ашламада икәнлегенә чын-чынлап ышандым. Сәбәпнең дә сере бар.

Үзләренең тәҗрибә-производство хуҗалыгында күзәтүләр алып баручы кузаклы һәм ярма культуралары Бөтенсоюз тәҗрибә-тикшеренү институтында мондый мәгълү-

матлар бар. Алтмышынчы елдан алып сиксәненче елга кадәр булган дүрт бишьеллык дәвамында бөртекле культураларның уңышы өч тапкырга арткан һәм гектарыннан уртача утыз ике центнер тәшкил иткән. Сабан бодае — кырык биш, арпа утыз тугыз центнер уңыш бирә башлаган. Карабодайның язмышы башкачарак. Дөрес, җиденче бишьеллыкта әле азмы-күпме үсеш булган. Сигезенче бишьеллыкта да уникешәр центнер уңыш җыеп алынган. Шуннан соң торгынлык башланган. Унберенче бишьеллыкта да шул ук хәл. Бөтенесе фән кушканча, галимнәрнең даими күзәтчелеге астында эшләнгән тәҗрибә хуҗалыгында да нәтиҗәләр куандырырлык булмагач, аның уңышын күтәрү өчен, тагын нинди чаралар күрергә кирәк соң?

Бу мәсьәләдә галимнәр аңлатма бирүдән баш тарталар. Эш барышында бөтенесен дә искә алганнармы, табигать таләп иткән шартларны күздә тотканнармы, үзләренең мөмкинлекләрен һәртөрле стихияләргә каршы куярга теләп караганнармы — алар ни өчендер боларның берсе турында да сөйләми.

Саннар кешеләргә караганда төгәлрәк, диләр. Белмим, мин үзем, мәсәлән, башкачарак фикердә торам: иң төгәл саннарның да ялгыш нәтиҗәләр, уйланмаган адымнар ясарга этәрүе мөмкин. Ул саннарга нинди күзлектән чыгып карыйсың, аларны ничек аңлыйсың — хикмәт әнә шунда.

Бу урында шуны хәбәр итмәкче булам: Наталья Николаевна пенсиягә чыкты. Бик күп эшләр башкарды ул. Үзләренең ни өчен яшәгәнлекләрен, нәрсә хакына эшләгәнлекләрен белгән кочле, кыю йөрәкле, тәвәккәл кешеләр генә ялга әнә шулай тыныч күңел белән китәләр. Аның тагын дүрт сорты — «Сокуровская», «Троянда», «Прикамская», «Казанская крупнозерная» сортлары аттестация үтте. Хәзер ул читтән күзәтеп торачак — таралырмы ул сортлар, әллә «җирле әһәмияткә генә ия» ачыш булып калырмы?..

Бу карабодай турында минем дүртенче тапкыр язуым, аны күпмедер дәрәҗәдә йомгаклап куюым. Беренче мәкаләмне язганга инде дүрт-биш ел вакыт узды. Нәрсә үзгәрде, нәрсә яхшырды яки тагын да начарланды соң?

Менә хәзер инде үземнең фикеремне әйтә алам. Саннар — дөреслекнең бер өлеше генә, алар — меңләгән кешеләр башкарган эшнең нәтиҗәсе. Яхшы сортлы орлыкка мохтаҗлык, яңа ачышларын кулланылышка кертә алмыйча изаланган селекционерларның әрәмгә киткән тырышлыгы, чәчү әйләнеше кагыйдәләренә җавап бирмәүче телемтелем кишәрлекләр, түбән уңыш, аның да терлеккә ашатылуы — карабодайны харап итүче сәбәпләр әнә шулар. Аларны бер дә техник, агрономик чаралардан түгел, барыннан да элек кешеләрнең ваемсызлыгыннан эзләргә кирәк икән. Менә шул чакта гына беренче карашка бик кечкенә булып күренгән нәрсәләр дә зур гомумхалык бурычларын тормышка ашырырга ярдәм итәчәк. Сәбәпләрнең иң аянычы — буш сүз сөйләү. Ялкауларны, илтифатсызларны акылга утырта алмыйбыз, тырышларны, сәләтлеләрне тиешенчә бәяләмибез.

Азнакай осталары, гадәти күрсәткечләрне узып, карабодайдан, унбишәр-егермешәр центнер уңыш ала башлагач, хәзер ул якларга кемнәр генә йөрми? СССР авыл хуҗалыгы министрлыгы анда Бөтенсоюз семинары уздырды. Аннан соң шундый ук чара Россия Федерациясе масштабында үткәрелде. Татарстанда, биредәге карабодай басуларына күрсәтеп: «Менә карагыз, үрнәк алыгыз!» — дигән киңәшне ишетмәгән берәр райком секретаре, РАПО Советы председателе, колхоз-совхоз җитәкчесе калдымы икән?!

Азнакайның карабодай басулары, чыннан да, күпме карасаң да, карап-сокланып туймаслык искиткеч матур! Тирә-якта нефть сиртмәләре тирбәлә, кырлар ап-ак, чәчәкләр арасында умарта кортлары гөжли, бал исеннән башлар әйләнә. Монда уздырыла торган семинар-киңәшмәләрнең һәркайсында белгечләр карабодайның кирәклеге, файдасы турында ачык һәм аңлаешлы итеп сөйлиләр. Тоннасына дүрт йөз сум акча бирәләр. Фермаларга җаның теләгән кадәр катнаш азык кайта. Һәр йортның табынында — хуш исле бал, карабодай боткасы.

Ак чәчәккә күмелеп утырган басуларга килүчеләр агроном белән әңгәмә корганнан соң, зоотехникны эзләп табалар, аңардан фермаларны күрсәтүен үтенәләр һәм, әлбәттә инде, рацион турында сорашалар: терлек азыгына дөрестән дә муллыкмы? Кыр станында аш-су өстәлен күз төшерергә дә онытмыйлар: механизаторларны кибет токмачы белән тукландыралармы, әллә арпа ярмасы, яки карабодай боткасы беләнме? Һәм котмәгәндә карабодайның зарарлы сыйфаты турында да белеп алалар.

Районның данын бөтен союзга тараткан бу культура турында партиянең Азнакай райкомы беренче секретаре Октябрь Салихович Мөхетдинов:

— Карабодай — йөрәкне харап итә торган ризык,— дип әйтеп сала.— Инфарктка китерә...

Азнакай районында карабодай игү белән Мөхетдиновка чаклы ук шөгыльләнә башлаганнар, үтә кыю, тәвәккәл адым ясаганнар — вак-вак кишәрлекләр урынына ка-

рабодайны һәр хуҗалыкта өчәр-дүртәр, хәтта бишәр йөз гектар мәйданда чәчәргә керешкәннәр. Бер үк вакытта уңышны да арттыра барганнар.

Октябрь Салихович Мөхетдинов районда яшәп килгән кагыйдәләрне үргә алган. Еш кына шулай да була: яңа килгән җитәкчегә әле тегесе, әле монысы ошамый, бөтен нәрсәне үзенчә үзгәртергә тотына. Эшкә башкачарак карарга да мөмкин бит. Хуҗалыкның элекке уңай якларын ныклап өйрәнергә, аларны яңа казанышлар белән бәйләп, үстергәннән-үстерә барырга кирәк. Октябрь Салихович нәкъ шулай эшли дә. Сиксән өченче елда азнакайлылар карабодайга сигез мең гектар җир бүлеп бирәләр. Аны мондый мәйданга чәчәргә район түгел, бер генә өлкә дә, бер генә республика да батырчылык итми. Наталья Николаевна Петелина Татарстанга үзенең сортларын алып килгәч, эшне мең гектардан башлап җибәргән район карабодайның һәр гектарыннан унбишәр центнер уңыш җыеп ала. Һәм, әйтергә кирәк, моңа ул фәнни-тикшерену институтының һәм тәҗрибә хуҗалыкларының ярдәменнән башка ирешә.

Һәм менә көтмәгәндә азнакайлыларга Әлмәт чакыру ташлый. Шул сиксән өченче елда әлмәтлеләр ике план — җиде мең биш йөз алтмыш җиде гектар карабодай чәчеп, һәр гектарда тугыз центнер уңыш үстерәләр. Күңелгә коткы салырлык, көнләштерерлек күрше тезгенне үз кулына ала...

Октябрь Салиховичның сүзләренә гаҗәпләнеп сорарга мәҗбүр булдым:

— Ни өчен үзегезгә шундый дан китергән карабодайдан, йөрәкне харап итә, дип зарланасыз? Сәбәп нәрсәдә? Һава шартларының начар булуындамы?

— Һава шартлары — башка. Аңа әмер биреп булмый. Бөтен бәла — плановикларда. Алар иң элементар нәрсәләрне дә игътибарга алмыйлар.

Инфарктлар, стресслар, нерв какшау — болар начар нәрсә. Мәсәлән, шундый хәл. Дәүләткә карабодай тапшырган хуҗалыкларга бүләк рәвешендә өстәмә катнаш азык сатыла дидек. Менә урып-җыю чоры килеп җитә, ыгы-зыгы, ашыгу-кабалану башлана. Дәүләт алдындагы беренче изге бурычны кем тизрәк, алданрак үтәр? Кырларының уннан бер өлешенә карабодай чәчелгән хуҗалыклар да ашлыкны башка культураларны күбрәк игүче хуҗалыклар кебек бер үк тәртип буенча саталар. Башта бодай, арыш һәм арпа сатыла. Бүтәннәр инде ындыр табакларында эшне төгәлләп киләләр, фураж салалар, ә азнакайлылар әле карабодайны суктырырга гына тотына. Җыеп алынган уңыш — инде элеваторда, бер карабодай гына әзер түгел. Аны фуражга калдырырга ярамый, ничек кенә булса да дәүләткә сатып бетерергә кирәк. Менә шуңа күрә дә мондый хуҗалык катнаш азык белән тәэмин ителә. Гап-гади арифметика: катнаш азыкны никадәр күбрәк алсаң, терлеккә дигән бөртегең шулкадәр азрак кала. Карабодайны иң күп чәчкән, гектарыннан егермешәр центнер уңыш алып, аны сату планын ике тапкырдан артыграк үтәгән «Коммунизмга» колхозы 1983 елда кышны һәр терлеккә икешәр центнер гына фураж белән каршылый. Азык запасы апрель башына чаклы гына җитә. Бер ярым план күләмендә карабодай саткан Азнакай районы дәүләттән алты мең тонна өстәмә катнаш азык ала, әмма фураж белән кырык кына процентка тәэмин ителә.

Менә шуннан соң карабодай сату бәрабәренә бирелә торган катнаш азыкның файдасы турында сөйләп азаплан инде! Шулай итеп, карабодай белән әллә ни мактанып булмый, хезмәтләрен аңа багышлаган энтузиастларның табыны әллә ни мулдан түгел, карабодай боткасы да аларның өстәленә бәйрәм көннәрендә генә менә.

Карабодай сирәк, махсус культуралар исемлегендә йөри. КПСС Үзәк Комитетының һәм СССР Министрлар Советының, колхоз-совхозларда үткән биш елдагы уртача күрсәткечтән арттырып алынган уңышның бер өлешен шул эш кешеләренең үзләренә бүлеп бирергә, диган махсус карары бар. Чикләү бер генә: кеше башына бер тоннадан артмаска тиеш. Тонна — алтмыш пот, кечкенә сан түгел. Ләкин куркырга кирәкми, мондый бәхет дисталәгән еллар эчендә бер генә тапкыр елмаерга мөмкин.

Эшкә уңган, тырыш, чын мәгънәсендә талантлы Азнакай игенчеләре 1983 елда шундый зур күләмдәге өстәмә түләүгә хезмәтләрендә ирешкән күркәм уңышлары өчен лаек булдылар. Район бу культура чәчелгән җиде мең ике йөз гектар җирдән элеваторга, бергә кушып исәпләгәндә, Татарстанның биш районына караганда алты мең ике йөз тонна күбрәк карабодай озатты. Экономистлар карабодай игүдә катнашкан механизаторлар, басуларны серкәләндергән умартачылар, мастер-көйләүчеләр, агрономнар өлешенә сигез мең центнер өстәмә уңыш тия, дип исәпләп чыгардылар. Бу әле «артык» җыемның яртысы да түгел, дүрттән бере генә. Бүләк — шәп нәрсә, ләкин бит, ботка пешерер өчен, карабодайны ярмага әйләндерергә кирәк. Яргыч юк кына. Аны, көндез чыра яндырып эзләсәң дә, беркаян таба алмыйсың. Хәер, Татарстанда, Буа районының «Искра» колхозында шундый бер яргыч сакланып калган. Карабодай ярдырырга теләүчеләр бөтен Идел буеннан шунда агылалар.

Азнакайлылар үтенеч белән Татарстан икмәк продуктлары идарәсенә мөрәҗәгать тә иткәннәр:

«Район колхоз-совхозларының 1983 елгы промфинпланы буенча карабодайны эшкәртү һәм җәмәгать туклануы өчен файдалану каралган,— диелә ул үтенечтә.— Аны ярма итеп тарту, совхоз эшчеләре һәм колхозчыларның җәмәгать туклануына тоту өчен рөхсәт бирүегезне сорыйбыз».

Мин биредә бер нәрсәгә аеруча басым ясап узарга телим. Азнакайлылар тиешле булганның бары тик минимумын гына сораганнар: «...җәмәгать туклануы өчен» — дип ачык һәм аңлаешлы итеп язганнар. Ләкин аларның үтенече барыбер кире кагылган. Менә аларга килгән җавап: «Хәзерләүләр министрлыгының 1978 ел 15 февральдә расланган 55 нче күрсәтмәсе нигезендә, ашлыкны ярмага алыштыру тәртибендә кабул итү бары тик аны дәүләткә сату планын үтәгән совхозларга гына рөхсәт ителә. Бу күрсәтмә бары тик җәмәгать туклануы өчен бүленгән ашлыкка гына кагыла».

Әгәр, элеваторлар, заказчикларның ашлыгын яргыч аша үткәреп, аларның гадәти булмаган үтенечләрен канәгатьләндерсәләр, начар булыр идемени? Шул соравыма җавап эзләп әлеге идарәнең үзенә юл тоттым. Азнакай игенчеләренең үтенечен виза салырга тиешле идарә начальнигы Вәли Фәттахов миңа болай дип җавап бирде: «Кешеләргә шул чаклы карабодай бирү — акылга сыя торган эш түгел. Республика планны үтәми. Шәхси табыннар турында түгел, дәүләт байлыгы турында уйларга кирәк!» Мин аның белән бәхәскә кердем: берәүләрнең ялгышлары өчен икенчеләрне җәзага тарту дөрес булырмы? Дәүләт карарында күршеләрнең планы хакында берни дә әйтелмәгән. Анда, киресенчә, эшләгәне өчен, кешеләргә түләүне һичбер нинди тоткарлыксыз гамәлгә ашыру турында сүз бара. Һәркемгә — хезмәтенчә. Урта Азиядә кызыксындыру бүләген натуралата алучылар дөгене капчыклап та, олаулап та саталар бит. Кубаньда, мәсәлән, төп хезмәт хакына өстәп бирелгән хуш исле көнбагыш мае — шундый ук товарларның берсе. Ә карабодайга ни булган, ни өчен аңа гына киртәләр куелырга тиеш?!.

Бәхәс бик озакка сузылды. Ике яктан да берсеннән-берсе саллырак дәлилләр китерелде. Ниһаять, мин дәлилләремнең өстенлек алуына инандым. Монда миңа бүгенге фактлардан бигрәк, узган еллар тәҗрибәсенә таяну, артта калган хуҗалыклар, алай гына да түгел, бөтен район ашлык тапшыру планын үтәми торып, колхозчыларның хезмәт көненә тиешле икмәкне бирмәү очракларын мисалга китерү ярдәм итте. Җиңдем! Иңнәремә канатлар үскәнен тойгандай булдым. Сигез мең центнер карабодай ярмасы «яулап ал» әле син! Кәгазь буяп утыру гына түгел инде бу! Хәзер үк почтага ашыгырга, Мөхетдиновка телеграмма сугарга!

Ләкин минем шатлыгым кыска гомерле булып чыкты. Миңа тагын шул ук инструкцияне китереп тоттырдылар: «Ярамый. Рөхсәт ителми»...

Менә шул. Кәгазь, инструкция... Тимердән дә, бетоннан да катырак. Аны үзгәрткәнче маңгаеңны яру тизрәк. Мондый хәлдән чыгу өчен колхозлар нишләргә тиеш? Карабодайны бит алар чәчә. Әгәр аның бер өлешен гомуми казанга түгел, игенче гаиләләренә бирергә теләсәң, мәсьәләне ничек хәл итәргә? Моны чишәргә тиешле Хәзерләүләр министрлыгы һаман әле һәртөрле чикләүләргә «баетылган» инструкцияләр иҗат итә.

Гомумюридик кагыйдәләр күзлегеннән караганда, азнакайлыларны рәнҗетмәделәр, натуралата түләүне акча белән капладылар, аларның кулына өстәмә рәвештә тагын өч йөз утыз мең сум акча бирелде. Ләкин бәхет акчада гынамыни? Акчадан карабодай боткасы пешергәнне әле беркемнең дә күргәне юк.

* * *

Турысын әйтергә кирәк, бу мәкаләне язганда мин үземне нинди дә булса яңа ачыш ясаучы дип хис итмәдем. Икеләнеп калган чакларым да аз булмады, әмма бер нәрсәгә нык ышанып язам: һәрбер эштә тәртип, җаваплылык таләп ителә. Шушы мәҗбүри кагыйдәгә буйсынмый торып, беркайчан да уңышка ирешүне өмет итмә. Рекордлы саннар белән исәпләнгән күләмдә ашлык суктырган игенченең көн үтсенгә генә кыймылдап йөрүче, бригадирның чыбыркылап торуы астында гына эшләүче ялкауга караганда, хезмәт хакын да күбрәк алырга тиешлеге үзеннән-үзе аңлашыла. Авылның гарантияле түләүгә күчкәненә утыз елдан артык вакыт узды, соңгы нәтиҗәгә карап исәп-хисап ясау принцибы үз көченә торган саен ныграк керә бара.

Ә шулай да, кеше башкарган һәр матур эшнең нигезендә комсызлык, акчага хирыслык түгел, аны үтәп чыгудан туган горурлык хисе ята. Хезмәткә түләү — бер нәрсә, иң элек кешенең осталыгын, талантын күрә белергә, башкалар алдында аның абруен күтәрү турында уйларга кирәк.

Азнакай осталарының рекордлы уңышка өстәмә түләүгә бәйләнгән мәсьәләне күтәреп чыгулары һәм өч йөз утыз мең сум премия алулары белән генә мәсьәлә хәл ителми. Колхоз һәм совхоз, район һәм республика күләмендә генә түгел, бөтен

Союз күләмендә танылу турында уйлана башлыйлар карабодай игү осталары. Ә нигә? Күп сөт савучылар, мул ашлык суктырган комбайнчылар, җиләк-җимеш үстерү осталары олы мактауга лаек бит, күпме авырлыкларны җиңеп җыелган карабодай гына ни өчен читтә калырга тиеш? Бу эштә зур казанышларга ирешүчеләрне билгеләп үтү, аларны бүләккә нинди күрсәткечләр буенча тәкъдим итү турында уйланалар. Ләкин моның дөрес кенә бер юлын таба алмыйлар. Баксаң, унберенче бишьеллыкта карабодай буенча хәтта социалистик ярыш шартлары да кабул ителмәгән икән. Башка чара калмагач, унынчы бишьеллык таләпләрен нигез итеп алалар һәм бераүләрне Бөтенсоюз халык хуҗалыгы күргәзмәсенең — алтын, икенчеләрен көмеш яки бронза медаленә тәкъдим итәләр. Бу мәсьәләгә бик таләпчән киләләр, беркемгә дә берниндн ташлама ясалмый. Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү институты галимнәре карабодайдан иң югары уңышны егерме центнер дип санарга кирәклекне хәбәр итә. Ә азнакайлылар мондый күрсәткеч белән звено башлыкларын хәтта конкурска да катнаштырмыйлар, беренче турда ук төшереп калдыралар. Үзешчән осталар түгел, ярышка зур талантлар гына кертелә. «Авангард» колхозыннан Финус Рахманов звеносы — гектарыннан егерме җидешәр, Урманай совхозыннан Фәварис Галиуллин звеносы егерме өчәр центнер уңыш ала. Аерым бер кишәрлекләрдә генә түгел, йөзәр гектардан артык мәйданда бит ул! Исемлек шактый озын, башкаларга үрнәк булырлык эшләүчеләрнең саны йөз алтмыш кешегә җитә!

Отчетлар, гадәттәгечә, ноябрь аенда, уңыш җыеп алынгач, аны дәүләткә саткач, һәм орлыкка салып куйгач, киләсе ел уңышына нигез салынгач төзелә. Бүләккә тәкъдим итү турындагы кәгазьләр башкалага, тармакның баш штабына, Бөтенсоюз халык хуҗалыгы күргәзмәсенә җибәрелә. Җавап көтә башлыйлар. Басуларны кар каплый, кышкы зәһәр суыклар башлана, әче бураннар улый. Җавап юк та юк. Җибәрелгән кәгазьләрне җир йота диярсең!

Үз мәнфәгатеңне кайгыртуга караганда, кешеләр өчен, хак эш өчен йөрү җиңелрәк. Бу эш кайбер очракларда синең кичектермәс бурычыңа әйләнә. Көн тәртибенә килеп баскан мәсьәләнең очына чыгар өчен Мөхетдинов Мәскәүгә, авыл хуҗалыгы Министрлыгына кадәр барып җитә. Җибәрелгән кәгазьләр, канцеляриялардә буталып йөри торгач, бөтенләй югалган булып чыга. Алдынгыларга медальләр дә тапшырылмый, рәхмәт сүзләре дә әйтелми.

Мондый хәл кемнең генә күңеленә хуш килер икән? Карабодай турында барган сүзләрнең, кабул ителгән карарларның, язылган директиваларның иге-чиге, саны-хисабы юк. Барлык инстанцияләр әллә ниләр планлаштыра, таләп итә, бурычлар куя, эшкә килгәндә, шуларның берсен дә гамәлгә ашырмыйлар. Гаеплеләрне җавапка тартмыйлар, уңганнарны олыламыйлар. Элек ничек булган булса, карабодай әле дә үги кыз хәлендә кала бирә.

• • •

Азнакай комбайнчысы, Социалистик Хезмәт Герое Фәхразый Кәримов — карабодай игү осталарының берсе. Ул миңа нәрсә ди:

— Карабодайны башка культуралар белән чагыштыралар, уңыш бирү ягыннан аның бодайдан, арыштан, арпадан күпмегә калышуын билгеләү өчен һәртөрле зурлыклар уйлап чыгаралар. Көлке бит бу! Төп зурлык итеп карабодайны алырга, башка культураларның уңышын аңа карап билгеләргә кирәк! Белмим, ярыша алырлар микән? Карабодай басуында ике йөз центнер бөртек бирерлек ап-ак чәчәк бар — серкәләндер генә!

— Ә аның кайчан шундый үлчәү берәмлеге булып әверелүе мөмкин соң? — дип сорадым мин һәм моңа ирешү өчен күпме киртәләрне җимерергә кирәклеген күз алдыма китердем.

— Үзебез чын-чынлап эшли башлагач,— дип әңгәмәбезне дәвам иттерде Фәхразый Кәримов.— Әгәр үзенә тапшырылган эшне һәркайсыбыз намус белән башкарсак, моңа һичшиксез ирешәчәкбез.

Игенче хыялындагы саннар минем башыма сыймас кебек. Кәримов исә фикерендә нык тора:

— Бу һичшиксез шулай булачак! — ди...

Мин хәзергә, мәсьәләне тагын ачык калдырып, күп нокталарга гына таяна алам. Килачәктә карабодай файдасына хәлиткеч адым ясалуына ышанасы килә. Ул чагында мин бик рәхәтләнеп ап-ак чәчәкка күмелгән, чәчәкләрендә гөжләп бал кортлары очкан һәм мул уңыш биргән карабодай басуларына мәдхия язып чыгар идем. Бу — минем иң изге теләгем.



**Р. Ш. Шәмгунов,**

КПССның Түбән Кама шәһәр комитетының
беренче секретаре

# БОРЫНГЫ ЧУЛМАН БУЕНДА

Безнең район сугыштан соңгы елларда Кама аръягында берничә район составына кергән авыллардан оешты. Мәйданының төп өлешен исә үзәге Ширәмәт авылында булган шул исемдәге район тәшкил итте. 1960 елда аны икегә бүлгәннәр иде: төньяк өлеше Чаллы, көньяк өлеше Чистай районына кушылды. Тагын берничә елдан соң, нефтехимия комбинаты төзелә башлагач, район яңадан торгызылды һәм киләчәк шәһәренә нигез салган эшчеләр поселогы исеме белән Түбән Кама районы дип атала башлады.

Хәзер районның агропромышленность берләшмәсендә ун совхоз, ике колхоз, «Красный Ключ» һәм «Түбән Кама» исемнәрен йөртүче ике зур кошчылык фабрикасы бар. Алар 90 мең гектар чамасы җир били, шуның 69 мең гектары — сөрүлекләр. Мәйданыбызның 13 проценттан артыгын урманнар алып тора. Район авыл хуҗалыгының төп үзенчәлеге шунда — ул һаман үсеп, зураеп килүче яшь шәһәр ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә йөз тота. Мәсәлән, район агропромының «бәрәңге бакчасы» гына да 1823 гектар. Алты йөз гектарлап җирдә яшелчә: кәбестә, кишер, аш чөгендере, суган, кыяр һәм башкалар үстерелә.

Район хуҗалыкларында унике мең баш чамасы савым сыеры бар. Хуҗалыкларыбыз көн саен дәүләткә йөз һәм аннан да күбрәк тонна сөт сата. Кыш көннәрендә, савым кимегән чорда, шәһәргә Сарман районы ярдәм кулын суза.

Район терлекчелегенең тагын бер үзенчәлеге: тана һәм яшь үгезләр симертү өчен нигездә күрше районнарның махсус хуҗалыкларына озатыла. Тик колхозларда гына зур булмаган дуңгыз һәм сарык фермалары эшләп килә. Нәсел эшен яхшырту максатыннан «Октябрь бүләге» совхозында кара-чуар токымлы бозаулар үстерүне җайга салдык.

«Красный Ключ» кошчылык фабрикасы елына йөз миллион данәдән артык йомырка бирә һәм Түбән Каманы тулысынча тәэмин итеп кенә калмый, бу диетик ризыкны Казанга, Әлмәткә, Лениногорскига, Бөгелмәгә һәм республикабызның башка шәһәрләренә дә озата. «Түбән Кама» кошчылык фабрикасы исә тавык ите җитештерә. Шушы ике предприятие районга итнең 60 проценты чамасын бирәләр.

Район агропромышленность берләшмәсен үстерүдә тизләнеш күзгә ташлана. Соңгы елларда күпчелек совхозлар һәм колхозлар рентабельле эшли башлады. Шәһәр хезмәтчәннәренең якыннан ярдәме белән фермалар, остаханәләр төзелә, авыл урамнарында заманча йортлар күтәрелә, яңа кибетләр, ашханәләр, мәктәпләр, балалар бакчалары ачыла. Авыл хуҗалыгын экономик һәм социаль үстерүгә Зәй сугару системасы шактый уңай йогынты ясар дип көтелә. Ул ун мең гектардан артык җиргә Чулман иделенең шифалы суларын китерәчәк.

Юл төзүчеләр һәм шефлык итүче предприятиеләр эшчеләре ике елда уннарча километр юл һәм биш күпер салдылар. Әйтик, Ялантау авылы янында Чишмә елгасы ярларын тоташтыручы ике йөз метрлы күперне «Спецатоммонтаж» тресты эшчеләре һәм белгечләре бер ел эчендә диярлек салып бетерделәр. Ә мондый төзелешләрнең берничә елга сузылуы гадәти күренеш иде.

Районның ерак почмакларындагы Сосновка авыл Советына караган берничә авыл юлсызлыктан җәфа чигә иде. Элеккеге «Рассвет» колхозы «Нефтехим» берләшмәсенең ярдәмче хуҗалыгына кертелде. Хәзер нефтехимиклар анда юл төзү, производство һәм көнкүреш биналары салу белән мәшгуль.

* * *

Райондагы туган якны өйрәнү музейларында борынгы Чулманның түбән агымындагы бу җирләр турында байтак кызыклы мәгълүматлар саклана. Аларның иң байлары — Иске Чишмә һәм Ширәмәт мәктәпләрендә. Хәер, фәнни матбугатта да безнең районның үткәне, андагы борынгы Болгар шәһәрлекләре, тарихи истәлекләр турында материаллар җитәрлек. Тарихчы-археолог Равил Фәхретдинов, мәсәлән, «Ташлар моңы» китабында болай дип яза: «Чишмә елгасының түбән агымында, аның кушылдыкларының берсенең биек ярында болгар шәһәрлеге — хәрби кирмән калдыкларын таптык». Биредә сүз хәзерге Ачи авылы янындагы Оша шәһәрлеге турында бара. Зәй елгасы буендагы Кызыл Чапчак авылы тирәләрендә тагын бер шундый шәһәрлек калдыгы да археологлар игътибарын җәлеп итте. Болар — төбәктә бик борынгыдан болгар бабаларыбыз яшәгәнлеген раслаучы дәлилләр. Ничек кенә булмасын, бу якларда табигать искиткеч була: балга һәм җәнлек-киеккә бай урманнар, балыгын кул белән дә тотып алырлык күлләр һәм елгалар, сусыл үләнле болыннар... Тик сөрүлекләр генә азрак. Ут һәм балта белән аны урманнан яулап алырга туры килә. XVII гасырда — Болотников, XVIII гасырда Пугачев армияләренең калдыклары, патша нәфрәтеннән һәм үч алуыннан качып, Чишмә буйларына килеп чыга. Иске Чишмә (революциягә кадәр — Иске Шәһәр) акрынлап зур авылга һәм соңрак волость үзәгенә әйләнә. Аңа Ачи, Беляхча (атом электр станциясе төзелү уңае белән ул башка урынга күчерелде), Кама Аланы, Кушниково, Пироговка, Колмакчы, Ялантау, Суворовка, Кызыл Яр һәм исемсез ике авыл керә, алары революциядән соң Буденновчы һәм Свердловчы дип атала башлый. Якшәмбе көннәрне монда шаулап-гөрләп базарлар үтә, ә һәр елны 21 июльдә бөтен тирә-яктан халык ярминкәгә җыела.

Кышларын Иске Шәһәр кешеләре Чишмәнең икенче ярындагы Кызыл Яр авылының ир-аты белән йодрык сугышына чыгалар. Сугышлар, гадәттә, боз өстендә уза һәм «команда»ларның берсе качып киткәнчегә кадәр дәвам итә. Егылганнарга тимиләр. Шушында ук зур чиркәү эшләп тора. Октябрьгә кадәр анда погромчы монархистлар союзы члены Львов поп булып торган. Гражданнар сугышы елларында ул акларга җан-фәрман ярдәм итә, 1919 елда Чишмә бозы өстеннән чигенеп баручы кызылармиячеләргә атарга уңайлырак булсын өчен чаң манарасына үзе ук пулемет сөйрәп мәңгерә.

Ширәмәт — борын-борыннан һөнәрчеләр авылы. Анда чүлмәкчеләр, тиречеләр, күнчеләр, тимерчеләр, тегәрмәч ясаучылар һәм башка һөнәр осталары яшәгән. Бүгенге көндә дә ике катлы кирпеч йортта Кукмара мех берләшмәсенең филиалы булу очраклы түгел. Ул ат җигү дирбиясе һәм чүлмәк җитештерә. Авылда әле узган гасырда ук төзелгән йортлар, кибетләр, төрле башка биналар байтак. Янәшәдәге Смыловкада зур спирт заводы эшләп торган. Ул сугыштан соңгы елларда гына ябыла.

Крестьяннардан ашлык җыеп, аны Россиянең бик күп шәһәрләренә һәм хәтта чит илгә сату белән шөгыльләнүче Алабуга сәүдәгәрләре — Стахеевларның элеккеге дачасында ачылган «Красный Ключ» ял йортын республикабыздан читтә дә яхшы беләләр. 1918 елда Минзәлә өязе Советы монда Россиядә беренче техникум ачарга карар бирә. Дачаның таш бинасы 1920 елда балалар йортына бирелә. Соңрак «Красный Ключ» совхозы оештырыла. 18 дисәтинә җимеш бакчасыннан, дүрт ярым дисәтинә яшелчә бакчасыннан, сигез баш сыер һәм йөз илле баш умартадан башланып киткән хуҗалык зур предприятиегә әйләнде.

Совет власте тудырган шартлар Түбән Кама крестьяннарына матди байлык кына китереп калмады, аларның белемен күтәрде, мәдәни һәм рухи дөньясын баетты, аңын үстерде. Якташларыбыз Октябрь казанышларын яклап, Бөек Ватан сугышы фронтларында арысланнарча сугыштылар. Советлар Союзы Геройлары — И. П. Болодурин, Н. Ф. Каймачов, Г. А. Абызов һәм Д. К. Привалов исемнәре район тарихына мәңгелеккә кереп калды. Һәр колхозда, һәр совхозда Ватан азатлыгы өчен көрәшләрдә һәлак булган йөзләрчә якташларыбыз истәлеген изге ядкарь итеп саклыйлар.

Районның сугыштан соңгы үсеше, исеме һәм чикләре үзгәрүне искә алмаганда, Татарстанның башка авыл районнарыныкы шикелле үк. Түбән Кама җирендә тамырдан үзгәреш партия һәм хөкүмәтебез биредә нефть эшкәртү заводлары комплексы кору турында карар кабул иткәннән соң башланды. 1958 елның августында «Гипрокаучук» институты биредә нефтехимия комбинаты һәм яңа шәһәр төзү өчен әзләнү эшләре башлап җибәрергә алынды. Ә Мәскәүнең «Гипрогор» институтына бу шәһәрнең проектын әзерләү йөкләнде. Алгарак китеп булса да әйтим, архитектор Е. Кутырев җитәкчелегендә башкарылган бу эш соңрак СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең алтын медаленә лаек булды.

Төзелешне «Татнефтестрой» һәм «Лениногорскнефтестрой» трестлары башлап җибәрде. Ә инде 1963 елда, химкомбинат һәм шәһәр салырга килгән төзү оешмалары «Татэнергострой» идарәсенә берләштерелде. Аңа соңыннан Социалистик Хезмәт Герое

исеменә лаек булган Е. Н. Королев җитәкчелек итә башлады. Хәзер «Татэнергострой» илнең иң зур төзелеш идарәләреннән санала.

...1960 ел ахырының карлы, буранлы көннәре. 25 декабрьдә җәяүле буран басыла төште, күк гөмбәзендә сүрән булса да кышкы кояш күренде. Актүбә авылы кешеләре Биклән урманы артыннан килеп чыккан бихисап тракторларга һәм аларга тагылган вагоннарга гаҗәпләнеп карыйлар. Лениногорскидан чыккан чаналы-тракторлы поезд, йөз илле чакрымнан артык юл үтеп, Актүбә белән Олы Афанас авыллары арасындагы бушлыкта — Түбән Кама шәһәре салыначак урында туктап калды. Вагон ишекләре ачылды һәм калын кар көртенә яшь төзүчеләр — егетләр һәм кызлар сибелде. Шәһәр үзенә нигез салган, беренче казык каккан, тәүге йортларны корган төзүчеләрнең исемнәрен яхшы хәтерли. Алар — балта остасы З. М. Хәмидуллин, бригадир И. Я. Абросимов, асфальт һәм бетон җәюче Г. Ә. Әхмәтова, шофер Н. М. Косачев, диспетчер З. П. Златковская, 46 нчы төзү-монтаж идарәсенең производство-техник бүлеге җитәкчесе К. Х. Вәлиуллин, экскаваторчы Д. П. Булавкин һәм башка бик күпләр.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1961 ел, 19 апрель Указы нигезендә яңа эшчеләр поселогына Түбән Кама исеме кушылды. Аннан соң беренче мәктәп, беренче йорт, бәби табу йортында беренче нарасыйның тәүге авазы, беренче трамвай... Яңа калада «беренче», «беренче тапкыр» дип аталырлык вакыйгалар байтак.

1967 елның 31 июле исә нефтехимия комбинатының туган көне булып исәпләнә. Тагын өч елдан аз гына күбрәк вакыт үткәч Түбән Каманың беренче каучугы алынды. Бу — Бөтенсоюз удар комсомол төзелешенең генә түгел, бәлки Ватаныбыз нефтехимиясенең дә зур җиңүе иде. Комбинат белән янәшәдә генә шин заводы корпуслары күтәрелә. Ул тора-бара синтетик каучукны төп кулланучыга әверелачәк.

Без катлаулы, кызыклы чорда яшибез. Тормыш ритмнары һаман тизләнә бара. Заман белән бергә яңа кала — яшьлек шәһәре дә үсә, ныгый, адымнары торган саен ышанычлырак, кыюрак була бара. Әкияттәге пәһлеван сыман ул, җилкәсенә олы йөк күтәреп, киләчәккә атлый.

Континентта иң зурлардан саналучы нефтехимия берләшмәсе дәүләт планнарын һәм социалистик йөкләмәләрен үтәүдәге уңышлары өчен 1981 елда Ленин ордены белән бүләкләнде. Аның составында хәзер уналты завод бар. Аларның продукциясе туган илебездәге дистәләрчә төбәкләргә җибәрелә, унике чит илгә чыгарыла. Кайчандыр нибарысы 36 кешедән торган коллектив дистәләрчә мең эшчене, белгечне, фәнни хезмәткәрне туплаган куәтле организмга әверелде. 1963—1985 елларда Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәсенә җитәкчелек иткән Социалистик Хезмәт Герое Н. В. Лемаев СССР Нефть эшкәртү һәм нефтехимия промышленносте министры итеп билгеләнде.

Шин берләшмәсе дә тармакта иң зурлардан санала. Илдә чыгарыла торган һәр җиденче көпчәккә Түбән Кама маркасы сугылган. Биредә унҗиде меңләп эшче һәм белгеч эшли. Кама автомобиль берләшмәсе чыгарган «КамАЗ»ларга — тулысынча, җиңел һәм авыл хуҗалыгы машиналарының байтагына «Шин» берләшмәсе көпчәкләре куела, «Икарус»лар өчен шинны СССРда бары тик Түбән Камада гына ясыйлар.

Шәһәребезнең данын арттыручы оешмалардан «Татэнергострой» төзелеш идарәсен дә санарга кирәк. Унбишмеңле төзүчеләр коллективы производство һәм шәһәр объектлары кора, Менделеевскида һәм Татарстан атом электр станциясендә эшли. Идарә ел саен 140 миллион сумлык төзү-монтаж эшләре башкара, 150 мең квадрат метр торак сала.

«Камэнергостройпром» берләшмәсе Советлар Союзындагы байтак электр станцияләре төзелешләренә һәм чит илләргә җыелма тимер-бетон озата.

Бүгенге Түбән Кама — 186 мең кеше яши торган шәһәр. Аларның уртача яше егерме сигездән артмый. Бала туу ягыннан Россия Федерациясендә иң алдынгы урыннарда барабыз. Бүгенге нәни гражданнар — безнең киләчәгебез, таянычыбыз. Гүзәл йортлар, заманча заводлар алар өчен корыла.

Шәһәр партия оешмасы, халык депутатларының шәһәр Советы түбәнкамалыларның хезмәт, ял һәм көнкүреш шартларын һәрьяклап яхшырту өчен зур тырышлык куялар. Кунакларыбыз, гадәттә, транспортның төгәл эшләвен, автовокзалның бик уңайлы булуын беренче килүдә үк сизеп алалар. Шәһәр кварталларының яшәү өчен җайлы булуын әйтәләр. 21 нче микрорайондагы тугыз катлы йортларга карап сокланмый мөмкин түгел. «Ириска» дип аталган, зәңгәр күк төсендәге, яисә ачык яшел төстәге вак плитәләр белән тышланган өйләр күз явын алырлык булып, балкып тора.

Шәһәр халкы спорт белән яратып шөгыльләнә. Мөмкинлекләр җитәрлек. «Дружба», «Юбилейный», «Олимпия» спорт комплекслары, стадион, алтын комлыклар, урман, елга, күл буйлары — барысы да алар карамагында. Ял итим дисәң, яшьләр клублары, санаторий-профилакторийлар, ял базалары, пионер лагерьлары эшләп тора. Түбән Камадагы һәр икенче гаиләнең дачасы яисә бакчасы бар.

Шәһәр һәм район күпкырлы, бай тормыш белән яши. Үзешчән җырчылар, биюче-

ләр, артистлар, рәссамнарга талантларын ачу һәм сәләтләрен үстерү өчен мөмкинлекләр җитәрлек.

Биредә тарихка күз салу урынлы булыр. Бу якларда борын-борыннан хикмәтле сүзгә, аң-белемгә гашыйк кешеләр яшәгән. Кызыл Чапчак авылы мәдрәсәсендә, мәсәлән, XVIII йөзнең күренекле шагыйре, тарихчы Таҗетдин Ялчыголның укытканы мәгълүм. Байгыл авылында балалар язучысы Дәрҗия Аппакова дөньяга килгән. Галимнәр районыбыз авылларында әдәбиятыбыз җәүһәре — «Кыйссаи Йосыф» поэмасының ике борынгы кульъязмасын таптылар.

Бүгенге Түбән Камада язучылар, шагыйрьләр яши һәм иҗат итә. «Яшьлек» һәм «Нардуган» бию ансамбльләре бөтен республикага танылды. Язучы, публицист Рахмай Хисмәтуллин оештырган һәм озак еллар җитәкчелек итеп килүче «Кама таңнары» әдәби берләшмәсе, рус телендә көч сынаучыларның «Данко» берләшмәсенә йөрүчеләрнең иҗат үрнәкләре әледән-әле республика матбугатында басылып килә. Шәһәрдә генә түгел, бөтен республикада «Җидегән чишмә» әдәби-музыкаль берләшмәсен яхшы беләләр. Ул үткәргән кичәләргә, очрашуларга халык аеруча яратып йөри. Татарстаннан, күрше республикалар һәм өлкәләрдән танылган әдипләр, сәнгать осталары чакырыла. Иң куандырганы шул — бу игелекле эшкә техник интеллигенция вәкилләре дә тартыла, күп очракта алар башлап йөри. «Җидегән чишмә» берләшмәсе советы председателе сыйфатында күп еллар инде «Нефтехим» производство берләшмәсе генераль директоры урынбасары Мәсгут Сибгатович Сибгатов эшләп килә, аның урынбасары, техник фәннәр кандидаты Азат Зыятдинов зур тырышлык куя. Менә шунлыктан шәһәребездә һәм районыбызда халкыбызның әдәбияты, сәнгате, тарихы, теле белән кызыксыну арткханнан-арта бара. Бу үзенең уңай нәтиҗәләрен бирми калмый, әлбәттә. Рухи бай дөньяда яшәүче кешенең производствода да югары җитештерүчән эшләве күптән расланган нәрсә.

Татарстан атом электр станциясен төзүчеләр белән «Казан утлары» журналының рәсми килешүе нигезендә дусларча хезмәттәшлек 1983 елдан дәвам итә. Төзелештә «Әдәби пост» оештырылды. Журнал битләрендә иң яхшы төзүчеләр турында очерк-зарисовкалар, проблемалы мәкаләләргә киң урын бирелә. Бу эштә язучылар һәм журналистлар актив катнаша. Узган ел Кама Аланы поселогында «Болгар моңнары» исемле әдәбият-иҗат түгәрәге эшли башлады.

Бездә шулай ук татар һәм рус халык театрлары, «Әллүки» балалар театры гөрләп эшли.

Бөек Октябрь социалистик революциясенең җитмеш еллыгына багышлап үткәрелгән үзешчән сәнгать смотрында егерме меңнән артык кеше катнашты. Рәссамнарыбыздан В. Никольский, Ә. Фәсхетдинов, М. Яруллин, Г. Капитов, М. Минһаҗев иҗат күргәзмәләрен даими оештыралар, әсәрләрен Яр Чаллы, Казан һәм Татарстанның башка шәһәрләрендә, күрше республикаларда күрсәтәләр.

Әдәбият-сәнгать турында сүз кузгалган икән, без Түбән Кама район егетләре — М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисты җырчы Рафаэль Сәхәбиев, шагыйрь Разил Вәлиев исемнәрен телгә алабыз. Химиклар шәһәрендә Мөхәммәт Шәйхи, Фәтхулла Абдуллин, Мизхәт Хәбибуллин кебек яшь һәм башлап язучылар яши, Хәниф Хөснуллинның туган ягы да — Түбән Кама.

* * *

Түбән Кама пейзажы һаман үзгәрә, яңара бара. Татарстан атом электр станциясе һәм Кама Аланы поселогы да аңа үз төсмерләрен өсти. Узган елның август аенда поселокта ун меңенче кеше туды. Бу язма әзерләнгән көннәрдә бер миллион киловатт егәрлекле беренче реактор блогы бинасын кору дәвам итә. Ә алар АЭСта алтау булачак. Үткән җәйдә су юлы белән Даниядән гигант күтәрү кранының узеллары һәм механизмнары кайтартылды. Ул 240 тонна авырлыктагы әйберләрне илле катлы йорт биеклегенә күтәрә ала.

Кыска гына мәкаләдә түбәнкамалыларның бар эшләре, казанышлары, рухи тормышындагы яңарыш хакында сөйләп бетерү мөмкин түгел, әлбәттә. Ул турыда инде берничә китап язылды. Иң яхшысы, боларның барысын да үз күзләрең белән күрү. Поездлар һәм самолетлар, автобуслар һәм канатлы теплоходлар Түбән Камага көн саен йөзләрчә юлчыларны алып килә. Аларның шактые гүзәл Кама буйларын гомерлеккә тору урыны итеп сайлый. Ел саен шәһәрдә мең ярым туй үткәрелә, берничә балалар бакчасы һәм мәктәп ачыла. Ләкин аларга ихтыяҗ кимеми. Сөендерә торган мәшәкать бу! Бала күп туган җирдә кеше мәрхәмәтлерәк, хезмәтчәнрәк була, киләчәккә якты өмет белән яши.

## Флорид Әгъзамов

# АВЫЛ ХӘБӘРЧЕСЕННӘН БАШЛАНГАН ЮЛ

Моннан 70 ел элек, 1918 елның 12 мартында Казанда «Эш» газетасының беренче саны басылып чыга. Гражданнар сугышы елларында нигез салынган шушы газета соңрак «Татарстан хәбәрләре», «Татарстан» исемнәре белән дөнья күрә, акгвардиячеләр белән көрәшнең иң кискен чорларында, исемен «Кызыл көрәшче»гә әйләндереп, ул фронтта да таратыла. Аннан соң әле тагын берничә тапкыр исемен алыштыра: «Кызыл Татарстан», «Совет Татарстаны»... Хәзер инде егерме бер меңенче санын куып килүче бүгенге «Социалистик Татарстан» газетасының юл башы һәм үткәне әнә шундый.

Хезмәт ияләрен коммунистлар партиясенә, Ленин идеяләренә тугрылык рухында тәрбияләүгә, көрәшкә һәм хезмәткә туплауда армый-талмый эшләүче газетага — татар журналистикасы флагманына үз вакытында ялкынлы публицистлар Хәсән Урманов, Вәли Шәфигуллин, Галимҗан Ибраһимов, Фәтхи Бурнаш, Фатих Сәйфи-Казанлы, Галимҗан Нигъмәти җитәкчелек итә. Монда Г. Камал, Ш. Әхмәдиев, И. Кули, К. Тинчурин, Һ. Такташ, Ш. Усманов, Ш. Камал, К. Нәҗми, Г. Толымбайский, С. Фәйзуллин эшли.

Газета әдәбият-сәнгать, культура мәсьәләләрен һәрдаим күз уңында тота, эшчәнлегендә В. И. Ленинның культура, әдәби тәнкыйть бүлегеннән башка, әдипләрнең катнашыннан тыш газета чыга алмый дигән күрсәтмәсенә таяна. М. Максуд, А. Шамов, М. Җәлил, Г. Кутуй, Х. Туфаннарның танылган әдип булып үсеп китүләренә дә юлны нәкъ менә шушы газета ачты. «1922 елның ноябрь аеннан «Кызыл Татарстан» редакциясендә сотрудник сыйфатында хезмәт итәргә кердем. Бу миңа яшьтән үк әдәбият белән кызыксынуымны, журналларда, газеталарда әсәрләрем басылуын дәвам итү өчен шартлар тудырды»,— дип язды герой-шагыйрь, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил.

«Социалистик Татарстан» газетасының соңгы чирек гасыр эчендәге тарихы күп кенә фидакарь журналистлар исәбендә публицист һәм галим, аның җаваплы редакторы, Татарстан Журналистлар союзы идарәсе председателе булып эшләгән Шәмси Хамматов исеме белән дә бәйле. Түбәндә урнаштырылган язма аның турында.

• • •

Шау-гөр килеп Муса Җәлил елы да үтеп китте. 1986 елны күздә тотуым. Искә алу кичәләре, тантаналы җыелышлар узды, спектакльләр куелды, концертлар яңгырады, газета-журналларда әллә никадәр мәкаләләр дөнья күрде, телевидение-радио программаларында махсус тапшырулар булды, байтак китаплар басылып чыкты. Бу хакта иң элек М. Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлын бөртекләп өйрәнүчеләр кайгыртты. Шуларның берсе — соңгы елларда аеруча активлык күрсәтүче матбугат ветераны һәм галим Шәмси Хамматов булды. Шагыйрь-патриотның 80 еллыгын ул «Муса Җәлил, аның каләмдәшләре» дигән яңа хезмәт белән каршылады. Бу — авторның ялкынлы шагыйрь һәм журналист хакындагы өченче китабы. Беренче икесе 1982 һәм 1984 елларда татар һәм рус телләрендә Татарстан китап нәшриятында басылган иде. Шулар өстенә узәк һәм җирле матбугат, телевидение һәм радио аша дистәләрчә фәнни-популяр язмалар укучыларга, тыңлаучыларга барып ирешә. Хикмәт җәһәтлектә генә түгел, билгеле. Хикмәт күп санлы җәлилчеләр арасында үз

урынын табуда, бай иҗатның һәм гыйбрәтле язмышның яңа якларын ачуда Ш. Хамматов әлеге язмышның нәкъ менә башкалар кулы тимәгән сәхифәләрен ачты, фәнни әйләнешкә яңа документлар һәм материаллар кертте.

Хәтеремдә, 1979 елның көзе булса кирәк, Шәмси ага Курск өлкәсендәге «Марьино» санаторийеннан кәтмәгәндә-искәрмәгәндә дигәндәй, М. Җәлилнең сугыш башында политик работниклар әзерли торган курсларда укуы турында үтә кызыклы язма алып кайтты. Шул язмадан соң ул үзенә хас мавыгу һәм максатчанлык белән «серле йомгак»ның бер җебен эләктереп, шуны сүтеп алып китте. Җәлил иҗаты һәм тормышы белән кызыксыну бу иҗади җанга әллә кайчан ук салынып куелган булып чыкты.

Шәмси аганың үсмер-егет чакларында, Свердловск татар-башкорт педагогия техникумында укыган елларында, шигырь белән җенләнеп йөргәнен белә идем. «Әдәбият адымнары» исемле кулъязма журналда Ш. Хамматовның бер шигыренә дә юлыктым. «Постта» дип атала ул. Эпиграф итеп М. Җәлил шигыреннән бер строфа алынган:

*Сизәм*
*Бүген мин постыма*
*Җаным-тәнем белән бирелдем,*
*Һәм иртәгә*
*Тау-таш ярылса да*
*«Пост бөтен»,— дип,*
*Рапорт бирермен.*

Менә кайда икән инешнең бөркеп чыккан җире. Муса Җәлилнең патриотизм хисе белән өртелгән шигырьләре егет-җилкенчәккә өлге булган, димәк.

«Муса Җәлил — партия солдаты» исемле китапның керешендә китерелгән тагын бер факт дикъкатьне җәлеп итте: мәрхүм Гази Кашшаф Җәлилнең журналистлык эшчәнлеге турында хезмәт язарга Ш. Хамматовны кодалап йөргән.

«Социалистик Татарстан» һәм «Советская Татария» газеталары редакцияләрендә бергә эшләп йөргән елларда М. Җәлилнең тууына 60 ел тулу уңае белән республика матбугатында киң колачлы кампанияләр җәелдереп җибәргәндә (юбилейга багышланган әдәби сәхифәләрне «Бүгенге татар поэзиясендә Г. Тукай, М. Җәлил традицияләре» дигән фикер алышуларны күздә тотам) Шәмси аганың зур рухлану белән җилкенеп йөргәннәренең эчке бер мәгънәсен хәзер тагын да ачыграк аңладым.

Ә инде 1979 елда чыккан «Газета һәм әдәбият дуслыгы» исемле монографиясенең сугыш һәм аннан соңгы чорга багышланган бүлегендә М. Җәлил иҗатына зур урын бирелүе мәсьәләгә тагын да ныграк ачыклык кертә.

Ш. Хамматов, Г. Кашшаф эзләнүләрен дәвам иттереп, М. Җәлилнең гражданлык һәм поэтик батырлыгының тамырларын документаль нигездә тикшерә, шул чыганакларның иң көчлесе булган журналистлык эшчәнлегенә мөрәҗәгать итә. Җәлил эзләреннән Мәскәүгә, Новгород өлкәсенә, Оренбургка һәм башка төбәкләргә барып, бай материал туплый. «Муса Җәлил — партия солдаты» исемле китабында автор 40 тан артык яңа документны әйләнешкә кертте. Шулар өстенә әллә никадәр истәлекләр тупланды.

«Муса Җәлил, аның каләмдәшләре» исемле китабында исә Ш. Хамматов шагыйрьнең язмышында рус, татар һәм башка милләтләр классик әдәбиятының, шулай ук чордашларының, әйтик, А. Фадеевның, зур роль уйнавын һәм бер үк вакытта М. Җәлилнең, әдәби хәрәкәт үзәгендә кайнап, каләмдәшләренә ярдәм кулы сузуын, алар турында даими кайгыртуын, иҗатларын армый-талмый пропагандалавын җанлы фактлар җирлегендә ачып бирә.

Әйе, Муса Җәлил Шәмси Хамматовның иҗат эшчәнлегендә ныклы урын алды, аның яшәү мәгънәсенә әверелде. Ә бу мәгънәгә килеп җиткәнче күпме гомер аккан, күпме эшләр башкарылган, җилкәдән күпме йөк узган! Бөтен гомерен матбугат һәм әдәбиятыбызга, культурабызга багышлаган кешенең үз биографиясе дә бик гыйбрәтле.

Портретына кайбер штрихлар сызу нияте белән кулга каләм алгач, кайсы әдип китабыннандыр бер чагыштыру хәтердә яңарды. Кеше гомере ашкын елга кебек. Ике ярга кереп сыена да ага да ага ул. Яшьлеге — елганың бер яры, хәзерге көне икенче яры. Ярлар бервакытта да кушылмыйлар. Ләкин яшьлек, яшьлектәге канатлы хыяллар, ярлар елганың буеннан буена сузылган кебек, кешене гомере буе озата килә, гомер үзәнен билгели.

Шәмси Хамматовның хыяллары исә баштан ук әдәбият һәм журналистика белән бәйләнә. Моңа, күрәсең, эчке табигый хасият белән берррәттән, заманында «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаган, Тукай, Такташларны яттан белгән беренче укытучысы Хәким Галимовның йогынтысы да тигәндер.

Әлеге һәвәслек җиде класс тәмамлаган үсмерне Свердловскидагы татар-башкорт педагогия техникумына алып килгән. Утызынчы еллардагы яңаны төзү романтикасы, яңа культураны үстерү омтылышы каләм тибрәтеп килгән егетне үз кочагына ала һәм ул, бәхетенә, туган әдәбиятны, журналистиканы ихлас яраткан кешеләр мохитына эләгә. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мөхәммәт Усманов техникумда әдәбият түгәрәге оештыра, «Әдәбият адымнары» исемле кулъязма журнал чыгара, анда Шәмсинең шигырьләре дә урнаштырыла. Түгәрәк утырышларында ул чакларда танылып өлгергән шагыйрь Хөсәен Әминов еш була. Урал әдипләренең татар-башкорт секциясе җитәкчесе сыйфатында совет язучыларының I съездында делегат булып катнашкан бу кеше әдәбият-журналистика җене кагылган үсмерләргә рух бирә, язучылар съездыннан, М. Горький, А. Фадеев, М. Җәлил һәм башка күренекле әдипләр белән очрашулардан алган тәэсирләрен уртаклаша. Алгарак китеп әйтик, Шәмси Хамматов педагогия институтына читтән торып укырга керергә Казанга килгәндә Х. Әминев Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Ләбиб Гыйльмигә хат белән егетнең шигырьләрен дә җибәрә. Л. Гыйльми аларны Г. Кашшафка тапшыра һәм арадан яхшыларын сайлап алып җыентыкка кертергә тәкъдим итә. Ш. Хамматовның өч шигыре Рахман Ильяс редакторлыгында 1940 елда чыккан «Очкыннар» исемле җыентыкта дөнья күрә. Анда 28 авторның әсәрләре тупланган. Алар арасында Җ. Тәрҗеманов, Б. Рәхмәт, Ф. Басыйров, Әхтәм Әминев, Н. Гобәй шигырьләре бар.

Хөсәен Әминев техникум егетләрен, партиянең Свердловск өлкә комитеты органы — татар телендә чыга торган «Социализм юлы» газетасы белән бәйли. Анда шулай ук кайгыртучан абыйлар... Әнә Галим Рябков, киләчәктә «Кызыл Татарстан» газетасының редакторы буласы кеше, әнә сәләтле журналист Ким Биков... Соңрак аны «Кызыл Татарстан»да эшләгән җиреннән фронтка китеп яу кырында ятып калыр дип кем уйлаган!.. Журналистлык эшчәнлеген «Социализм юлы»нда башлап, алда аны шулай ук «Кызыл Татарстан» — «Социалистик Татарстан»да уңышлы дәвам иткән, озак еллар җаваплы секретарь булып торган, ару-талу белмәс журналист Зәйни Төхфәтуллин...

Техникумны тәмамлагач, 18 яшьлек егет күршедәге Шәкүр авылына кайтып татар теле, әдәбияты һәм тарих укыта, ВЛКСМның Түбән Серга райкомының беренче секретаре, аннары директор була. 1940 елда яшь коммунистны Свердловск өлкә партия конференциясенә делегат итәләр, ВЛКСМ өлкә комитеты члены итеп сайлыйлар. Бераздан партиянең район комитетында инструктор. Шул ук вакытта район һәм өлкә газеталарына күп санлы мәкаләләр яза. Аларда ул авылда яңа тормыш төзү тәҗрибәсен уртаклаша, кимчелекләрне камчылый.

Җитешсезлекләрне тәнкыйтьләү димәктән, Шәмси Хамматов бер эпизодны еш искә төшерә.

...Туган авылы Аккул халкының яртысы диярлек Хамматовлар. Колхоз җитәкчеләренең дилбегәсе дә алар кулында. Мактап язсаң, халык алдында уңайсыз. Ә инде кимчелекләрне тәнкыйть утына тотарга кирәк булганда... Колхозда урып-җыю эшләре сүлпән бара. Бригадир — туганнан туган агасы — көенәсе-пошынасы урында күңел ачып йөри. Тота да яшь хәбәрче фельетонга охшаш нәрсә язып «Социализм юлы»на җибәрә. Газетада басылган язманың авылда нинди хикмәтләр чыгарганын күз алдына китерсәгез икән! Хамматовлар, «җәнҗалчы» Хамматовлар белән көрешмәс булалар. Хәтта әтисенең дә — коммунист, Гражданнар сугышында катнашкан, взвод, аннары рота командиры сыйфатында Юденичларны кыйнашкан, Төньяк Кавказда төрле бандаларны туздырышкан, авылына кайтып колхоз оештырып, аның беренче председателе булган Хәбибулла агайның да — җен ачуы чыга. Әмма сүз куертып тормый.

— Алма агачыннан ерак төшмәсә, хәрам булыр,— ди дә кулын селти. Нишләсен — үзе шулай яшәргә өйрәтте ич. Кызык бер хәл: 1969 елның 29 мартында Свердловск өлкәсенең Түбән Серга район газетасында «Хөрмәтле иптәш» исемендә басылган очеркта 82 яшьлек Хәбибулла агайның, пенсиядә булуга карамастан, совхоз эшендә һаман актив катнашып йөрүе, файдалы киңәшләре белән ярдәм итүе, кимчелекләрне тәнкыйтькә тотуы хуплап язылган. Менә кайда икән ул активлыкның, башлап йөрүнең, принципиальлекнең оеткысы!

Соңрак Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә читтән торып уку. Олы әдәбият, гыйлем дөньясы белән очрашу. Мөхәммәтхан Фазлуллин, Хуҗа Бәдигый, Мөхәммәт Гайнуллин, Хатип Госманнарның эчтәлекле лекцияләрен тыңлау. Тулай торакта студентлар Шамил Әхтәмов, Бәян Гыйззәтләр белән әдәбият, журналистика, тормыш турында кайнар бәхәсләр...

Хәвефле сугыш еллары яшь егетнең иңнәренә авыр йөк булып ята. Аны янә мәктәп директоры итеп билгелиләр, колхоз партия оешмасы секретаре, ВКП(б)ның район комитеты члены итеп сайлыйлар.

1943 елда Свердловскидан бер төркем яшь коммунистлар Мәскәүгә Югары партия мәктәбенә җибәрелә. Алар арасында Шәмси Хамматов та була. Анда укыганда ул Үзәк Комитетның матбугат секторы хезмәткәрләре кушуы буенча төрле газета-журналларга күзәтүләр ясап тора. Мәктәпне тәмамлагач, 1945 елда аны «Кызыл Татарстан» газетасына редактор урынбасары һәм пропаганда бүлеге мөдире итеп



*«Социалистик Татарстан» газетасы редакциясендә очрашу. Алдагы рәттә (сулдан уңга)— С. Хәким, Р. Ишморат, Әминә Җәлилова, Р. Мөхәммәдиев, Ш. Хамматов; арттагы рәттә — Н. Юзиев, Р. Мостафин.*

билгелиләр. Шул рәвешле, Урал тауларыннан юл алган чишмә журналистика дигән олы елгага килеп кушыла. Иҗат дәрте ташып торган яшь кеше өчен киеренке хезмәт еллары башлана. Ул чагындагы редакция тормышын хәзергесе белән чагыштыра торган түгел. Газета чыгару тәүлек буе дәвам итә: көн белән төнне аеру юк. Редактор урынбасары төнге дежурдан иртән генә кайтып китә. Хикмәт вакытның тыгынлыгында гына булмый, билгеле. Төп кыенлык, марксистик-ленинчыл теорияне, партия политикасын тирәнтен өйрәнеп, шуны тормыш белән тыгыз бәйләп, халыкка җиткерүне оештыруда була. Ләкин һәрвакыттагыча өлкәннәр, тәҗрибәле иптәшләр ярдәм кулы суза. Партия өлкә комитеты хезмәткәрләре, редактор Ибраһим Үзбәков, редактор урынбасарлары Галим Рябков, Мөхәммәт Шәйми, Фәтхи Балыкчы кебек танылган журналистлар аны публицистлык осталыгының, оештыру эшенең серләренә төшендерәләр.

Марксистик-ленинчыл теорияне пропагандалау мәсьәләләре белән шөгыльләнү иҗтимагый фәннәр белән кызыксынуны көчәйтә. Нәкъ шул вакытта аңа КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясенә барырга тәкъдим итәләр. Ул анда «Беренче рус революциясе елларында Казан большевиклары оешмасы» темасына диссертация яклый. 1950 елны тарих фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала.

Соңрак Шәмси Хамматовның тикшеренүләре «Казан большевиклары оешмасы беренче рус революциясе елларында» (рус телендә, Казан, 1955) исемле монографик хезмәтендә гомумиләштерелә. Фән өлкәсендә байтак тәҗрибә туплап Казанга кайткач, «Кызыл Татарстан» газетасында янәдән редактор урынбасары. Бу елларда ул, оештыру эшләре белән бергәттән, публицистика жанрында күп санлы чыгышлар ясый, пролетариатның һәм партиянең революцион традицияләрен хезмәт ияләренә җиткерә, татар һәм рус телләрендә чыккан большевистик матбугатның героик сәхифәләрен җанландыра, партиянең ленинчыл милли политикасын пропагандалый.

1949 еллар башында аның пропагандистик мәкаләләре «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналы битләрендә дә күренә. Авторны журнал редакторы Кави Нәҗми рухландырып тора. Иҗат мәнфәгатьләре туры килү мәгълүм роль уйнагандыр, билгеле. Чөнки яшь тарихчы да Беренче рус революциясе чорын тикшерә, танылган язучы да татар халкының революциягә килү юлларын киң колачлаган «Язгы җилләр» романы өстендә илһамланып эшли.

Пропагандистик мәкалә жанрында актив эшләгән Ш. Х. Хамматовның хезмәтен «Правда» газетасы 1951 елның 1 июнь санында билгеләп үтә, аның «Кызыл Татарстан» газетасында басылган «Халыклар дуслыгы тантанасы» исемле мәкаләсен хуплап телгә ала.

1951 елның җәендә тарих фәннәре кандидаты Ш. Х. Хамматовны КПСС Өлкә комитетына мәктәпләр бүлеге мөдире итеп билгелиләр. Биредә ул җитди политик чыныгу мәктәбе үтә. Зиннәт Ибәтович Муратов кебек тәҗрибәле җитәкчеләр белән бергә эшләү, аны һәр мәсьәләгә партиячә якын килергә, һәркайда партия линиясен төгәл үткәрергә, кешеләргә һәм үзенә карата принципиаль таләпчән булырга өйрәтә. Республикада халык мәгарифен үстерү мәсьәләләре белән шөгыльләнү белән бергә, ул фәнни эшен дә ташламый. Аннары Ш. Х. Хамматов — СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында өлкән фәнни хезмәткәр буларак Татарстанда эшчеләр сыйныфының крестьяннар белән союзы проблемасын өйрәнүгә керешә. Кыска гына вакыт эчендә «Эшчеләр белән крестьяннар союзы турында» исемле хезмәт язып, 1957 елда Татарстан китап нәшриятында рус телендә бастырып чыгара.

1958 елда Ш. Х. Хамматов кабат журналистикага кайта — «Татарстан коммунисты» журналының баш редакторы итеп билгеләнә. Сугыш елларында тукталып торган журналны яңадан ачып, аның эшен җайга салып җибәрү мәшәкатьләрен күз алдына китерү кыен түгел. Һәр яңа эшкә дәртләнеп-канатланып тотынырга гадәтләнгән Ш. Хамматов бу мәшәкатьләрне дә уңышлы ерып чыга.

Аннары Ш. Хамматов КПСС Өлкә комитетының партия тарихы институты директоры була. Аның җитәкчелегендә институт Татарстан партия оешмасының тарихын өйрәнү буенча колачлы эш җәелдереп җибәрә. «Ленин һәм Татарстан» темасын эшләүгә нигез салына. Институт эшчәнлегенең иекенче төп юнәлеше В. И. Ленин әсәрләрен татар теленә тәрҗемәләү эшен дәвам иттерүдән гыйбарәт була.

1960 елның январь аенда Ш. Хамматов «Совет Татарстаны» газетасы редакциясенә әйләнеп кайта. 1963—1967 елларда «Советская Татария» һәм «Социалистик Татарстан» газеталарының берләштерелгән редакциясенә җитәкчелек итә. 1967 елдан 1983 елга кадәр ул — «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы.

Аның бу еллардагы эшчәнлеге берничә юнәлештә дәвам итә. Беренчедән, Шәмси Хәбибуллович публицистика өлкәсендә актив эшли. Бу бигрәк тә аның юлъязмалар жанрын үстерүендә ачык чагыла. Ул тормышны өйрәнү, андагы үзгәреш-яңарышларны үз күзе белән күрү өчен республикабызның бөтен районнарын гизеп чыга. Шул сәяхәтләрнең нәтиҗәсе буларак газета битләрендә, җыентыкларда заман сулышы бөркелгән публицистик мәкаләләр дөнья күрә. Республикабыз хезмәт ияләрен интернационализм рухында тәрбияләү максаты белән барлык социалистик илләр (Болгария, ГДР, Венгрия, Чехословакия, Польша һ. б.) турында диярлек зур-зур юлъязмалар язып бастыра. Болардан тыш, ул политик әдәбиятка, әдәбият фәненә караган китапларга әледән-әле рецензияләр язып тора.

Икенчедән, фән өлкәсендә дә активлыгын киметми. Аның гыйльми мәнфәгатьләре татар матбугаты тарихы, хәзерге заман совет матбугатының актуаль проблемалары белән бәйле. Ул, матбугат тарихын һәм хәзерге тәҗрибәсен гомумиләштерүче, күренекле журналистларның тормыш һәм иҗат юлын чагылдыручы 50 дән артык күләмле мәкалә язып, үзәк һәм җирле газета-журналларда, фәнни җыентыкларда бастырды. 1979 елда Татарстан китап нәшриятында аның «Газета һәм әдәбият дуслыгы» исемле монографик хезмәте дөнья күрде. Анда автор республика газетасының 60 ел дәвамында милли әдәбиятыбызны үстерүгә, рус һәм башка тугандаш әдәбиятларның казанышларын пропагандалауга керткән өлешен, художество культурасы өлкәсендә партия политикасын үткәрүгә ярдәм итүен бай фактик материал җирлегендә ачып бирде.

Ул редактор булып эшләгән елларда матбугатта художество культурасы проблемаларын күтәрүдә байтак яңалыклар барлыкка килде. Әйтик, 1960 нчы еллар башыннан «Социалистик Татарстан» әдәбият-сәнгать сәхифәләрен атнага бер тапкыр биреп баруны практикага кертте. 1980 елга кадәрге вакыт эчендә 1000 сәхифә дөнья күрде. Бу — 1000гә якын басма табак, ягъни уртача күләмдәге 160 том дигән сүз. Әлеге тәҗрибәне партия өлкә комитеты хуплады һәм башка газеталарга да күчерде. Озакламый «Советская Татария» газетасы да шундый сәхифәләр бирә башлады. Әдәбият-сәнгатьнең актуаль мәсьәләләре буенча бәхәсләр, проза, поэзия, театр сәнгате, музыка, тәрҗемә проблемаларына багышланган иҗади сөйләшүләр әдәбият-сәнгать тормышында сизелерлек эз калдырды.

М. Горькийның тууына 100 ел тулу якынлашып килгән көннәр иде. Әдәбият-сәнгать бүлеге хезмәткәрләрендә татар әдипләренең М. Горький хакындагы фикерләрен туплап бер сәхифә бирү уе туды. Бу фикер редакторга җиткерелде. Ул игътибар белән тыңлап торды да аяк өсте торып басты, күзләрендә очкын кабынды:

— Шәп идея бит бу! Тик, егетләр, мәсьәләне киңрәк итеп кую турында уйлашыйк әле. Әйдәгез, һәркайсыбыз шул хакта баш ватыйк та иртәгә җыелып гәпләшеп алырбыз.— Һәм ул нинди юнәлешләрдә уй йөртергә кирәклеген сөйләп китте.

Килешенгәнчә, тагын җыелыштык. Бу юлы сүз инде колачлырак, тасыллырак

мәсьәләләр хакында китте: Ленин һәм Горький. Горький һәм социалистик реализм. Горький һәм күпмилләтле совет әдәбияты. Горький һәм татар культурасы... Башлангыч идея тирәнәеп һәм киңәеп, сәхифәдән тулы санга үсте. КПСС Өлкә комитетында әлеге идеяне хупладылар, аны үстерү юнәлешендә файдалы киңәшләр бирделәр. Тиз арада М. Горькийга багышлап газетаның махсус саны чыгарылды. Үзәк матбугат аңа уңай бәя бирде.

Шәмси Хәбибуллович әдәбият-сәнгать мәсьәләләрен яктыртканда журналистларны республика белән генә чикләнеп калмаска, регион, союз күләмендә, хәтта дөнья культурасы күләмендә фикер йөртергә өнди. Күрше республикалар һәм өлкәләр газеталарының берләштерелгән саннарын чыгаруда да ул башлап йөрде.

Ш. Х. Хамматов яшьләрне үстерүгә, аларның иҗатына тиешле шартлар тудыруга даими игътибар итә һәм катгый таләпчәнлекне аталарча кайгырту белән бәйли. «Социалистик Татарстан»да эшләүче һәм эшләп киткән урта, яшь буын журналистларның күбесе хаклы рәвештә аны үзенең остазы саный. Ул Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә яшь кадрлар хәзерләүдә актив катнашты, доцент дигән гыйльми дәрәҗәгә лаек булды.

Ш. Х. Хамматов 1952 елдан башлап КПСС Өлкә комитеты члены, берничә тапкыр бюро члены, берничә чакырылыш Казан шәһәр Советы, дүрт чакырылыш ТАССР Верховный Советы депутаты, партиянең XXIII съезды делегаты. Бу вазифалар да аңа җаваплы эшләр йөкләде. Ул төрле комиссияләрдә, әйтик, Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, республика журналистларының Х. Ямашев исемендәге премиясе комиссияләре әгъзасы булды.

Партия һәм хөкүмәт Ш. Х. Хамматовның хезмәтләрен югары бәяләде: аны «Почет билгесе», «Халыклар Дуслыгы», Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр белән бүләкләде, РСФСРның атказанган культура хезмәткәре дигән мактаулы исем бирде. Ул — Х. Ямашев исемендәге премия лауреаты.

Бер уйласаң, безнең алда гадәттән тыш бер язмыш: ярлы крестьян малае авыл хәбәрчесеннән күренекле галимгә, ялкынлы публицистка, зур газетаның редакторына, җәмәгать эшлеклесенә кадәр үскән. Икенче караганда, бу — гадәти язмыш. Шәхескә үсәр өчен мөмкинлекләр тудырган, иҗат ирекен тәэмин иткән социалистик илнең гап-гади кешеләренә дә интеллектуаль яктан нинди югарылыкка күтәрүен дәлилләүче бу язмыш.

Шәмси ага Хамматов иҗат ниятләре белән янып яши. Ул әле генә М. Җәлил шәхесенең һәм иҗатының интернационализмын гәүдәләндерүче яңа китап тәгалләде. Алда — яңа язмалар, яңа эзләнүләр. Ул бөреләр дә тулы көченә ачылып мул җимешләр бирер дип ышанасы килә.

**Марс Шабаев**

# ТӨШСЕЗ ЧИКЛӘВЕКЛӘР...

*Сак булыгыз, гамьсез гулливерлар,*
*Лилипутлар килә шигырьгә.*

Шәйхи Маннур.

Шагыйрь Шәйхи Маннурның моннан чирек гасыр чамасы элек көрәзәлек итеп әйткән ачынулы сүзләре дөрескә чыкты: «гамьсез гулливерлар»ның (Х. Туфан, С. Хәким, Ш. Маннур, Ә. Давыдов һ. б.) туфрагы да суынып өлгермәде, шигъруят мәйданын «лилипутлар» басып ала башлады. Ш. Маннурның әлеге усал шигырьне язуы үзе үк күп нәрсә турында сөйли. «Гамьсез гулливерлар» асылда һич тә гамьсез түгел иделәр. Алар әдәбият өчен, әдәби алмаш өчен чын-чынлап янып йөрделәр. Кызганычка каршы, «зәңгәр күзле төрек»— Назыйм Хикмәтнең «Әгәр син янмасаң, әгәр мин янмасам, әгәр ул янмаса — әгәр без янмасак...»— дигән догага тартым сүзләрен еш кабатларга яратсак та, безнең арада янучылар калмады диярлек түгелме? Без ничектер әдәби мәнфәгатьләрне түгел, әдәбиятта үз мәнфәгатьләребезне күбрәк кайгырта башладык шикелле.

Илебез тормышында соңгы чирек гасыр эчендә тамыр җәйгән торгынлык, һәрнәрсәгә гамьсез битарафлык илнең экономикасына, промышленностена, авыл хуҗалыгына, сәүдә-көнкүреш хезмәтенә һ. б. һ. б. гына түгел, рухи дөньябызга да әйтеп бетермәслек зур зарар китерде. Безнең әхлагыбыз имгәнеп калды.

Әдәбиятка килгәндә исә бик күпләребез төшсез-төссез әсәрләр иҗат итте. Иҗаттагы төшсезлек-төссезлек үзара мөнәсәбәтләргә дә күчте. Без хәзер күбрәк фанилык белән мәшгуль, безгә туфанилык җитенкерәми. Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның бер шигырендә юкка гына:

*Кайсы өскә чыгар? —*
*Көрәшәләр*
*Туфанилык белән фанилык,—*

дип язылмаган.

«Син — миңа, мин — сиңа» принцибы белән яшәргә өйрәнеп киттек ләбаса.

Илдә зур үзгәрешләр бара. Ил корабының рулен үз кулларына алган тынгысыз, җегәрле яңа җитәкчеләр безне яңа офыкларга өндиләр. Халык үзгәртеп кору, демократия, ачыктан-ачык дөресен сөйләү рухы белән янып яши башлады. Сүнгән өметләр яңадан терелде.

Ниһаять, үзгәреш рухы, кыюсыз гына булса да, безнең татар әдәбиятына да керә бара. Бу җәһәттән күзгә күренерлек әдәби әсәрләребез әлегә бигүк юк-югын. Алары соңрак булыр. Әмма публицистик чыгышларда, әдәби тәнкыйтьтә билгеле бер җанлану сизелә.

Әнә, тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин әдәбияттагы үзгәрешләр өчен көрәшне «әлифтән» үк башламакчы була. Ул «яшь һәм башлап язучылар» проблемасын төрле яссылыкта өйрәнү-тикшерү мәсьәләсен уртага салып сөйләшүне башлап җибәрде.

Узган бер ел эчендә Р. Мостафин бу мәсьәлә буенча үзәк матбугатта да, республика матбугатында да үткен-үткен чыгышлар ясады. Аның Татарстан китап нәшрияты баш редакторы язучы Вакыйф Нуруллин белән әңгәмәсе иң әүвәл «За пробу пера — миллион...» дигән исем белән «Литературная Россия» әдәби атналыгында басылып чыкты (27 март 1987). Аннары шул ук әңгәмә, китап кибетләреннән репортажлар белән баетылып, Казан телевидениесе аша тапшырылды. Менә без аны «Казан

утлары» журналы битләреннән дә укыдык. Болар өстенә Р. Мостафин «Социалистик Татарстан» газетасында «Файдалы киңәшләр» дигән (26 май, 1987) әдәби фельетон белән чыкты. Кызганыч, үткен генә язылган бу фельетон, кемнең кем икәнен белеп бетермәү, ике шәхесне бутау аркасында, авторга — Р. Мостафинга булган ышанычны да, фельетонның иҗтимагый яңгырашын да шактый киметте. Аннары «Чаян» журналында (14 сан, 1987) Р. Мостафинның «Мүкләкләр» дигән әдәби фельетоны дөнья күрде. Моныңда инде ул бер конкрет фамилиягә дә тукталмыйча, гомуми нәтиҗәләр ясарга омтылган иде. «Литературная газета»дагы «Научимся ли уважать любителя?» дигән мәкаләсе белән (30 сан, 22 июль, 1987) Р. Мостафин «кырмыска оясын» тагын да ныграк болгатып ташлады. Шул ук санда рус шагыйре Николай Старшинов, аның белән бәхәскә кереп, «Графоману — графоманово...» дигән җавап мәкаләсе урнаштырды. Бу ике мәкаләне укучылар тарафыннан шул санның иң яхшы материаллары дип табылды.

Күрәсез, Р. Мостафин бик актив һәм нәтиҗәле эш алып бара. Аның бу мәкалә-фельетоннары зур кызыксыну белән кабул ителделәр. Шулай да кайбер моментларда Р. Мостафин аптыраштарак калган шикелле. Үзе әйтмешли, «йоклаган арысланны уятуыннан» үзе дә бер мәлгә югалыбрак калды бугай ул.

Р. Мостафин В. Нуруллин белән әңгәмәсен «аерым язучылар язмышындагы игътибар сорый торган мәсьәләләр»дән башлап китә. «Беренче китапларның дөньяга чыкканчы бик озак йөрүе» (әйтерсең, башка китаплар бик тиз басыла!), беренче китап авторларының барысы да «чыннан да яшьләрме», алар барысы да сәләтлеме, ни өчен сәләтле яшьләрнең «кульязмалары чират көтеп ятканда, йомшаграк икенче язмалар нинди юллар табалар һәм басылып чыгалар» кебек сораулар куя. Нәшриятны йомшаклык күрсәтүдә гаепли. Ни өчендер Язучылар союзына, аның яшьләр белән эшләү комиссиясенә, иҗат секцияләренә адресланган гаепләү сүзләре, үзтанкыйть күренми Р. Мостафинда.

Әйе, нәшриятлар эшендә ил күләмендә зур җитешсезлекләр бар. Бу хакта күп язалар, күп сөйлиләр. СССР Госкомиздатында да җитәкчеләр алышынды. Байтак кына өметләндергеч чаралар күреләчәге турында сүз бара. Кооператив нәшриятлар ачыла. Бездә дә, Ә. Кәримуллин кебек, бу эшнең энтузиастлары күренә.

Кооператив нәшрият кадәресе безнең Татарстан шартларында ничегрәк булыр — әйтә алмыйм. Әмма бер тәкъдимем бар: Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият һәм яшьләр-балалар әдәбияты редакцияләрен Язучылар союзына буйсындырганда яхшы булыр иде.

Безгә — язучыларга — Язучылар союзы эшендәге кимчелекләр турында күбрәк сөйләргә кирәк. Язучылар союзы битараф булмаса, нәшрият эшендәге Р. Мостафин белән В. Нуруллин телгә алган тискәре күренешләрнең дә байтагы булмас иде.

«Литературная газета»дагы мәкаләсендә Р. Мостафин Татарстан Язучылар союзы исемлегендәге сигез йөзләп яшь һәм башлап язучы проблемасын ничек хәл итәргә дип баш вата.

Кемнәр бар соң ул сигез йөз кешелек исемлектә? Әдәбиятның ышанычлы алмашы — резервымы? Әллә күпчелеге, Р. Мостафинча әйтсәк, «үзешчән авторлар» гынамы? Әллә соң, аннан да яманрагы, болар бары тик «мүкләкләр», графоманнар гынамы? Безнеңчә, барысы да бергә. Күбрәге — төшсез чиклавеклар... Иң аянычы: ышанычлы алмаш булырдай сәләтле яшьләр сигез йөздән (сигез йөздән!) бармак белән генә санарлык.

Бер карыйсың, Р. Мостафин «мүкләкләр»дән ничек котылырга белми, «калəм сынаган өчен — миллион сум...» дип аһ ора. Икенче карыйсың, шул ук Р. Мостафин «үзешчәннәрне хөрмәт итәргә өйрәнербезме?» дип йөз сиксән градуслы борылыш ясый. «Үзешчән авторлар» өчен уңай шартлар булдырырга — бөтенсоюз конкурслары оештырырга, махсус әдәби журнал ачарга чакыра (Татарстан язучыларының 30—40 ел йөреп тә яшьләр журналы булдыра алмаганнарын оныткан, күрәсең...).

Ачыктан-ачык сөйләшик әле. Мәскәүгә барып: «Бездә сигез йөз яшь язучы бар!» — дип күкрәк какканда, кемнеңдер: «Сигез йөз яшь язучымы... әллә графоманнармы?» дип мыскыллы соравын безнең иптәшләр ишетмәмешкә салынып кайтсалар да, бу сорау баш өстендә балта булып эленеп тора бит. Мәскәүдә мактанып кайттык, мактадылар-хупладылар. Ярый, хуш... Шуннан соң Татарстан язучыларының соңгы съездында «яшь язучыларыбыз»ның уртача яше 45—48 тирәсе икәне фаш булды. Президиумда утырган Сергей Михалков белән Николай Доризоның аптырашлы кыяфәтләре әле дә күз алдында: «Менә сиңа сигез йөз яшь язучы!» Бу күз буяу кемгә кирәк иде? Яшь язучылар белән эшләргә тиешле (эшләүче дияргә тел әйләнми) кайбер иптәшләргә генә түгелме?

Язучылар союзының рәсми белешмәләренә караганда, төрле төбәкләрдә күп санлы әдәби берләшмәләр гөрләп эшли, район күләмендә дисеңме, республика күләмендәме яшь язучыларның әдәби семинарлары, конференцияләре даими үткәрелә килә.

Казаннан нәртеп алып барып булса да, кайберәүләрне Союзга членлыкка да тәкъдим итәләр. Ә чынлыкта әдәбиятны «лилипутлар» баса, «мүкләкләр» баса. Язучылар союзы бүлмәләрендә яшьләр белән эшләргә тиешле 4—5 кеше хезмәт хакы алып утыра. Аларның кайсыларыдыр Союз аппаратында, кайсыларыдыр ВЛКСМ Өлкә комитеты штатында саналалар. Ә сәләтле яшьләр үз язганнарын укытырга адәм рәтле язучы таба алмыйча тинтерәп йөри. Танылган прозаик яки шагыйрьне коридорда аулый, өенә шалтырата... Үзенә остаз эзли.

Сәләтле яшьләр нәшрият темпланнарында 4—5 ел буена урын ала алмый (Р. Мостафин В. Нуруллин белән әңгәмәсендә шуңа борчылуын белдерә), ә теге ямьсезлеге чыккан исемлектәге кайбер агайлар шул 4—5 ел эчендә өчәр-дүртәр китап та чыгарып өлгерә.

Мисаллар кирәкме? Р. Мостафин әңгәмәсендә телгә алынган авторларга өстәп мин узган әдәби ел йомгакларында берничә исем өстәгән идем. Рәхим итеп, менә тагын бер-ике исем. Р. Рәкыйповның шул ук биш ел эчендә дүрт җыентыгы дөнья күрде. Бу «яшь шагыйрьгә» быел 52 яшь тула. Язганнары эпигонлыктан узмаган бик тә уртакул бу «үзешчән автор»ны, безнең арада туган-тумачалык, кода-кодагыйлык, әшнәлек тамыр җәймәсә Язучылар союзына член итеп алыр иделәрме? Отставкадагы хәрби хезмәткәр Р. Шәфиев та, Шәүкәт Галиев редакция мөдире вакытта, тавыш-тынсыз гына аллы-артлы ике китап чыгара алмас иде. Мисалларны дәвам итеп торырга кирәкме икән?!

Безнең Язучылар союзы идарәсе боларны «күрми», әдәби тәнкыйть исә андый күренешләрне «тәнкыйтьтән түбән» дип саный. Ул арада «тәнкыйтьтән түбән китап» авторлары мыштым гына Язучылар союзына үрмәлиләр... Кайбер язучыларыбыз ул мыштымнар фонында үзләрен ничектер күтәрелебрәк, күренебрәк торгандай итеп тоя.

Мин бервакыт Язучылар союзына кабул итү комиссиясе члены Аяз Гыйләҗевтан (ул хәзер шул комиссиянең председателе) бер ханымны ни өчен, нинди әсәрләре белән Союз членлыгына кабул итүләрен сораган идем. Аяз Гыйләҗев үзенә генә хас бер көлемсерәү белән көлемсерәде дә: «Алмасагыз — асылынам!» дип куркытты ул безне, парин»,— дип җавап бирде.

Берсенең асылынуыннан куркабыз (асылыныр, көт!), икенчесенең абыйсыннан, өченчесенең югары оешмаларга язган жалобаларыннан... Нәтиҗәдә әдәбиятыбызның дәрәҗәсе төшә, язучы һөнәренең абруе җуела бара...

Вакыйф Нуруллин «нәшрият ел саен уртача ун-унбиш яшь авторның китапларын бастырып килә» дип сөйли. Азмы бу, әллә күпме? Кирәкме шулай юмартлану? Кемнәр ул «яшь авторлар»? Нәшриятның темпланнарын игътибар белән актарып карасагыз, күрерсез: «ун-унбиш»нең бер-икесе чынлап та яшьләр булса (булса әле!), калганнары әлеге дә баягы «мүкләкләр» түгелмени? В. Нуруллинның «алар, авторлар буларак, безнең өчен барысы да яшьләр» дигән сәер фикере белән дә килешәсе килми. Сезнең өчен, бәлки, шулайдыр да, әдәбият өчен алай түгел шул. Баш редакторның «Язучылар союзының иҗат секцияләре тәкъдименнән башка нәшрият авторларның беренче китапларын планга кертми» дигән сүзләре югарыда китерелгән мисаллар белән үк кире кагыла, минемчә. Секцияләрнең тәкъдиме әйбәт чара, әлбәттә. Анысы да бар. СССР Госкомиздаты үз вакытында нәшриятларга шундый күрсәтмә биреп бик дөрес эшләгән иде. Ул күрсәтмәнең тәгәл үтәлмәве генә эшне пошыра. Әмма секцияләр соңгы елларда бик начар эшлиләр. Аларның абруе юк дәрәҗәсендә. Исемле язучылар секция утырышларына йөрмиләр. Килсәләр дә битарафлар. Теләсә кемгә яхшатланырга гына торалар. В. Нуруллин бик дөрес әйтә: «алар... ни матди, ни әхлакый җаваплы» түгелләр. Шунлыктан, дип тә өстәр идек без, нәшрият байтак китапларның язмышын үзбашына гына хәл итә. Таләпчәнлек, контроль бөтенләй юк, дисәк тә, ялгышмабыздыр шикелле. Нинди-дер «мүкләк»нең ниндидер китабы чыкса ни дә, чыкмаса ни?! Әнә бит узган елгы әдәби ел йомгакларында җитәкчеләребездән берәү: «Өч-дүрт начар китап күпмени ул!»— дип, безне юатып та куйды. Юкса, ул бер чыгышта телгә алынган ташкүлчим китаплар гына өч-дүрт икәнен, саный китсәң, аларның хәтсез икәнен, соңгы елларда андый китаплар чыгуга бернинди киртәләр куелмаганын гына белми идеме?

Рус шагыйре Николай Старшинов Р. Мостафинга җавап мәкаләсендә «үзешчән авторлар» язмышы иң әүвәл әдәби берләшмәләрдә хәл ителергә тиеш дигән фикер үткәрә. Бик дөрес фикер. Сәләтле яшь автор, һичшиксез, әдәби берләшмәдә канат ныгытырга тиеш. Язучылар союзының әдәби консультантлары, иҗат секцияләре яшьләрне әдәби берләшмәләргә үзләре юнәлтсәләр, нинди яхшы булыр иде.

Әмма... әдәби берләшмәләрнең үз хәлләре хәл шул хәзергә. Бу җәһәттән бер генә гыйбрәтле мисал китереп үтәм.

1986 елда Әлмәт Язучылар оешмасының ул чактагы җитәкчесе Әхәт Гаффар Татарстан китап нәшриятына «Татарстанның нефть төбәгендә иҗат итүче яшь һәм баш-

лап язучылар җыентыгы» төзеп тапшыра. Бу җыентык — шул еллардагы сигез әдәби берләшмәнең коллектив иҗат җимеше. Ул шулай ук Әлмәт язучылар оешмасының иҗат яшьләре белән ничек эшләвен күрсәтүче көзге дә. Багыйк шул көзгегә, күрик: нинәрсәләр белән куандыралар икән безне?

Җыентыкта сигез әдәби берләшмәдән 37 авторның иҗат үрнәкләре бирелгән. Әлмәттән — 11, Бөгелмәдән — 9, Лениногорск, Азнакай, Баулыдан — 4 әр, Җәлил белән Мөслимнән — 2 шәр, Сарманнан 1 автор. Сорау туа: бу әдәби берләшмәләргә шулай бик аз кеше йөриме икәнни соң? Алайса ни өчен алар «берләшмә» дип, зурдан кубып, әле җитмәсә «Моңсар», «Гөлстан», «Тукай моңнары», «Җәлил чаткылары» кебек купшыялтыравык исемнәр белән дә аталалар. 37 автордан телгә алып сөйләрлек 2—3 сәләтле иптәш бар. Шулай булгач, кайда инде ул Тукай моңнарын эзләргә дә Җәлил чаткыларына карап куанырга?!

Безнең заманнарда гади генә әдәби түгәрәкләр булыр иде, анда йөрүчеләр саны, аз дигәндә, 20—30 кеше булыр иде, күпчелеге 15—25 яшьләрдәге егетләр-кызлар, ә инде утыздан өстәге берән-сәрән иптәш булса, аларга сәерсенеп карарлар иде. Ул тыйнак әдәби түгәрәкләр әдәбиятыбызга бик күп язучылар бирде.

Хәзер без колачларны киң җәйдек: гади генә дуңгыз фермасы да — комплекс, авыл-район культура учаклары да — комплекс, ашханәләр исә — туклану комбинатлары, кечкенә генә тегү фабрикасы — производство берләшмәсе (генеральный директорлар!) һ. б. һ. б.... Бу гигантомания, шапырынып күз буяу сиздермичә генә әдәбиятка да үтеп керде. Язучылар союзының әдәби консультанты да хәзер идарә председателенең яшьләр белән эшләү буенча урынбасары дип атала. Янәсе, престижлы исемдәрәҗә!

Әйе, һәр районда — әдәби берләшмә, һәр районда — халык театрлары... Тик нигәдер яңа Тукай-Такташлар, Кариев-Мутиннар гына күренми...

«Нефть төбәгендә иҗат итүче яшь һәм башлап язучылар» конкрет алганда кемнәр соң? Менә алар: А. Маннанов (55 яшь), Р. Шәрифҗанов (53 яшь), К. Батыров (44 яшь), Н. Хәмитов (48 яшь), Ә. Фәтхетдинов (46 яшь), Р. Сәлимов (52 яшь), А. Кәли (60 яшь), М. Усманов (63 яшь), Р. Вәлиуллин (51 яшь), И. Мәрданшин (51 яшь). Бу агайларның берсе үзенең бер шигырендә төпчек улын тартып йөрүен яза да, аңардан: «Оныгыңмы шушы?» — дип сорыйлар. Агай: «Олы яшьтә хатын кызык итте»,— дип куана...

Инде яшәү дәртләре сүрелгән, күбрәк тыныч картлык турында уйлаштыра торган бу агайлар әдәбиятка нинди яңа сүз алып килерләр икән? Шушыларммы Әлмәт язучылар оешмасының әдәби алмашы — киләчәге?

Әлеге дә баягы, безнең заманнарда яшь цензы бар иде: әдәби семинарларга, конференцияләргә яше 35 тән артмаган, чынлап та яшь язучыларны чакыралар иде. Шул яшьтән өстә булса, ул яки соңлап ачылган талант (Г. Афзал кебек) булыр иде, яки аны «әйдә, килсен, тыңласын, бәлки, ничек язмаска кирәген аңлап китәр» дип кенә чакыра иделәр.

Бәлки, бу агайлар да, Г. Афзал кебек, соңлап килгән талантлардыр? Ах, кана, шулай булсачы! Юк бит... Берсенең бер юньле-башлы язган нәрсәсе юк. Булса да уртакулга тартып-сузып китерердәй язмалар...

Ә. Гаффар әйткән иде: әдәбиятта үзешчәннәр, һәвәскәрләр буламы? (Бу сораубызны тәнкыйтьче Р. Мостафинга да юллыйбыз). Әллә әдәбият профессиональлек таләп итәме? Берәр төрле мавыгуы булган кешеләр күп тормышта. Алар арасында үзешчән җырчылар биючеләр, көй чыгаручылар, рәсем ясаучылар да байтак. Ләкин аларның берсе дә иҗат союзларына омтылмый. Чөнки аларның төп һөнәрләре башка. Ни өчен әдәбиятка килгәндә эш башкача торырга тиеш? Ни өчен әле юк эшне бар итеп күрсәтергә теләгәннән генә, казна хисабына чиле-пешле «әсәрләр»не китап итеп чыгарырга кирәк? Чынлап та талантлы яшьләр юк икән, эзләп таба алмыйбыз, үстерә белмибез икән — нигә көчәнергә?

Шулай да әлмәтлеләр ике авторга аерым игътибар итсеннәр иде. Алар — Баулы егетләре Сәгадәт Әхмәтшин белән Сәгыйть Әхмәтҗанов. Беренчесе — шагыйрь, икенчесе — прозаик. Боларның һәр икесенең тормышны үзләренчә күрә белүләре, күргәннәрен-кичергәннәрен үзләренчә язарга омтылулары бар. Кыскасы, үз тавышлары ярып килә кебек. Әлбәттә, һәр икесенә күп эшләргә, күп өйрәнергә кирәк әле. Бу иптәшләр әдәби мәктәп үтәргә тиеш, алар остазларга мохтаҗ. Әлмәт язучылары аларны ярдәмнәреннән калдырмаслар, күз уңыннан ычкындырмаслар дип уйлыйбыз.

Әлмәт якларындагы бу аяныч хәл башка төбәкләрдәге әдәби берләшмәләргә дә хас. Ул берләшмәләрдә мәчет картлары шикелле агайлар өстенлек итә. Сәләтле яшьләр алар арасында буталып йөрергә кыенсыналар. Димәк, берләшмәләр мәсьәләсе, аларның статуслары һ. б. яклары турында уйланасы, эзләнәсе бар. Бирегә дә үзгәртеп кору таләп ителә.

Ә инде әдәби берләшмәләрдән үсеп, Язучылар союзына членлык мәсьәләсенә килгәндә... Бу үзе аерым сөйләшүне сорый торган зур проблема. Мин шуны гына әйтеп үтәр идем. Без бер дә алай күп санлы язучылар үрчетерлек шартларда түгелбез. Александр Блок бугай, кайсыдыр елгы әдәбиятка күзәтү ясый да: «Бер елда дистәдән артык шигырь җыентыгы дөнья күргән. Күп түгелме бу?»— дип шөбһәләнә. Бу — рус поэзиясе хакында! Ә без ни эшләргә тиеш?

Кемнәрдер: «Әнә кыргызлар фәлән хәтле, казахлар төгән хәтле...» дип чагыштырырга ярата. Фәлән хәтле, төгән хәтлене тәэмин итәрлек әдәби мәйданың да булырга тиештер бит әле. Менә сезгә кыргызлар, казахлар һ. б. турында бер белешмә (әдәби журналларын санамый гына): Кыргызстан, Таҗикстан, Төрекмәнстанда — 3 әр, Казахстанда — 6, Үзбәкстанда — 8 китап нәшрияты (1978—1980 елгы саннар). Балтыйк буе республикаларында: Эстония белән Литвада — 4 әр, Латвиядә — 5 китап нәшрияты. Болар союздаш республикалар. Аларның статусы да, мөмкинлекләре дә башка. Автономияле республикалар арасында бары тик Дагстанда гына ике нәшрият бар: Дагстан китап нәшрияты һәм Дагучпедгиз. Соңгысы 7 телдә дәреслекләр бастыра, матур әдәбият һәм яшьләр-балалар әдәбияты да нәшер итә.

Ә безнең бар карап торганыбыз бер Татарстан китап нәшрияты. Бердәнбер булганга да без аңа сүз әйтергә базмыйбыз — һәммәбезнең дә китап чыгарасы бар. Язган әсәреңне китап итеп чыгару өчен күпме «кан түгәргә» кирәклеген һәр язучы яхшы белә.

Мәйданың җитәрлек булмагач, булган кадәресендә дә профессиональ язучыларга да, «мүкләкләр»гә дә бер чама тигезләү чарасы (уравниловка) кулланганч, кая барып чыгарга тиеш соң безнең әдәбият? «Үзешчәннәр» хисабына ишәя барган Язучылар союзында санның һич тә сыйфатка әйләнгәне сизелми әлегә.

Р. Мостафинның «үзешчән авторлар» дигәне, аның аларны графоманнардан аерып куярга тырышуы аңлашыла. Шул ук вакытта ул графоманнарны яшь һәм башлап язучылар белән буташтырып та җибәрә.

Минем яңадан әлеге «сигез йөз»гә әйләнеп кайтасым килә.

Ни өчен без ул «сигез йөз»нең иҗади мөмкинлекләренә чын-чынлап әдәби барлау үткәрмибез? Ни өчен 20—30 ел (арада хәтта сугышка кадәр яза башлаганнары да бар!) язып йөреп тә ни он суы, ни тоз суы чыкмаганнарыннан котыла алмыйбыз? Ни өчен сәләтле яшьләргә сарыф ителәсе көчебез, шул исәптән материаль мөмкинлекләр дә, шуларга сарыф ителә? Ни өчен аларны, өметсез икәннәрен белә торып, семинар-конференцияләргә, язучылар съездларына кунакка чакырабыз? (Кайберләре, шундый чаралардан соң атна-ун көн буена айный алмыйча, Язучылар союзы коридорларында буталып йөри, өенә кайтып китә алмый. Ә без күрмәмешкә салышабыз — үзебезнең кунак бит!)

Әлеге «сигез йөз»не барлау үткәргәндә, шартлы рәвештә өч төркемгә бүләргә мөмкин булыр иде: бик аз санлы сәләтле яшьләр, сәләтләре «үзешчәнлек»тән артмаган күпсанлы һәвәскәрләр һәм графоманнар. Безнең бурыч — сәләтле яшьләр белән эшләү. Мин бүген бик рәхәтләнеп шул сәләтле яшьләр (әйтик, Р. Зәйдуллин, Г. Моратов, Р. Газизов, Н. Акмалов һ. б., һ. б.) хакында сөйләшер идем. Аларның һәркайсысы индивидуаль ярдәмгә мохтаҗ. Әмма... һәвәскәрләр һәм графоманнар мәсьәләсен ачыклап бетерәсе бар!

Графоман атамасын Р. Мостафин мыскыллау кушаматы («обидно-унижительное прозвище») дип саный. Барысы да һәвәскәрләр бит, ди. Аныңча, һәвәскәр җырчылар, рәссамнар, композиторлар дәүләт кайгыртуы һәм игътибар белән уратылган да, ә менә «үзешчән авторлар» (үзешчән рәссам яки композитор, әйтерсең, автор түгел) андый игътибар-хөрмәттән мәхрүм. Ә шул ук өф-өф итеп йөрткән «сигез йөз», аларга тотылган чыгымнар, әдәби берләшмәләр, консультация бүлекләре, күмәк җыентыклар — кыскасы, «каләм сынаган өчен — миллион сум...»? Болар дәүләт кайгыртуы, игътибар-хөрмәт түгелме? Әнә нәшрият яңарак кына «Туган як җыры» дигән күмәк җыентык бастырып чыгарды. Күләме — 10 табак. Шул ук «үзешчән авторлар»: агайлар, апалар иҗаты... Укып караган кеше әйтсен: я, берәр ачыш булырлык исем бармы? Ул 10 табак кәгазьне чынлап та сәләтле өч яшь шагыйрьгә биргәндә, игътибар-хөрмәт булмас идеме? Шул ук вакытта талантлы урта буын шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинның менә дигән ун табаклы кульязмасы да чират көтеп ятып калды нәшриятта... Р. Мостафин аңлавындагы «үзешчән авторлар»ны халык гади генә итеп «язу җене кагылганнар» дип атап йөртә. Ярар, без үзешчән диикме, һәвәскәрме — эш исемдә түгел, җисемдә.

Графоманны язучыдан талантсызлык аера, дибез икән, аларны башка әдәбиятларда авыз тутырып графоман дип йөртәләр икән, нигә әле без генә ул сүздән тайчанырга тиеш соң? Дөрес, бездә шигърияттә мөтәшагыйрь дигән сүз дә бар. Әмма ул киң таралмаган. Аннары графоманнар башка жанрларда да тулып ята. Графоманнар үзләре бу атаманы мәсхәрәләү, мыскыллау дип кабул итәләр икән — анысы алар эше.

Безнең өчен графоман — әдәби термин. Ул барлык белешмәләргә дә кертелгән. Графоман сүзен рәсми әдәби термин итеп кулланган өчен безне бераү дә судка бирә алмый.

Ә инде һәвәскәрлеккә килгәндә эш башкачарак тора, минемчә. Һәвәскәрлек — сәләтле кешеләргә хас күренеш ул. Сәхнәдәге үзешчәннәр сәләтле түгелмени? Алар, төп һөнәрләреннән аерылмыйча, җаны теләгән, күңеле тарткан шөгыль белән шөгыльләнәләр. Бу аларга рәхәтлек-шатлык бирә. Ә Р. Мостафинның «үзешчән автор» дигәннәренә бер карау белән аларның бәхетсез җаннар икәне күренә. Р. Мостафиннан аермалы буларак, әдәбиятта да һәвәскәрлек сәләтле кешеләргә карата гына кулланылырга мөмкин, дип әйтер идек.

Шагыйрь Гомәр Баширов, шагыйрь Фатих Хөсни, шагыйрь Гариф Ахунов... Сәерме? Ә Гомәр ага Башировның халыкка киң таралган «Җидегән чишмә» җыры, Фатих ага Хөснинең «Кошлар тынды, урман йокыга чумды...» (исеме «Аерылышу» булса кирәк) җыры, Гариф Ахуновның көн дә иртән торуга дога-ырым итеп кабатларлык «Якты көн» җыры — болар яхшы мәгънәдә һәвәскәрлек, минемчә. Шагыйрь Хәсән Туфан исә оста һәвәскәр сәгать төзәтүче иде... Ахыр чиктә, тәнкыйтьче Р. Мостафин үзе дә һәвәскәр: ул «Вечерняя Казань» газетасында матур-матур лирик парчаларын бастыра.

Әйе, һәвәскәрлек профессиональ иҗатчыларга да хас. Чөнки алар иҗатларының башларында барысы да һәвәскәрләр булганнар. Аннары югары уку йортларында укыпмы, үзлегеннәнме, төпле әдәби белем алу, үз рухына туры килгән билгеле бер әдәби йогынтыда үсә-үсә әдәби мәктәп үтү, язу тәҗрибәсе арту, булган сәләтне үстерә белү, өзлексез эзләнү — иҗат газабы кичерү — нәтиҗәдә, югары профессиональлек. Чын язучыларга әнә шул сыйфатлар хас.

Р. Мостафинның бер карасаң — «мүкләкләр», икенче карасаң — «үзешчән авторлар» дип атап йөрткән кешеләре кемнәр? Алар да кайчандыр яшь һәм башлап язучылар булганнар. Әмма, сәләтләре чамалы булганлыктан, яки бөтенләй булмаганлыктан, үсеп китә алмаганнар. Шулай да алар һаман язалар, йөриләр, таләп итәләр... Чөнки аларның исем-фамилияләре теге «сигез йөз» арасында. Бу аларга ниндидер хокук бирә шикелле. Нәшрият киштәләре аларның кулъязмаларыннан сыгыла, төрле инстанцияләрдә аларның аһ-зарлы жалобалары... Дистә еллар шулай дәвам итә. Алар картаялар, пенсиягә чыгалар, әмма барыбер язудан туктамыйлар — графоманнарга әйләнәләр. Аларның язганнары ара-тирә матбугат битләрендә күренгәләп китә, әдәби альманахларда, күмәк җыентыкларда урын алгалый. Китаплары да чыга. Боларның нинди алымнар белән эш иткәнен В. Нуруллин бик белеп яза. Газета-журнал редакцияләре, нәшрият бу «сукыр черкиләрдән» шул рәвешле котылып тормакчы, бераз тын алмакчы була. Һәм бик каты ялгыша. Ни өчендер күбебезнең яхшатланасы килә, әдәбиятны чүпләү, түбән төшерү хисабына, укучыларның эстетик зәвыгын бозу хисабына, ахыр чиктә дәүләтнең «миллион сумнары» хисабына яхшатланабыз...

Берничә конкрет исемгә тукталасым килә.

Әлмәтлеләр җыентыгында инде телгә алынган бер исем. Ул — Разим Вәлиуллин. «Туган як җыры» дигән күмәк җыентыкта исә аның басылырдай саналган бар булган иҗаты җыеп бирелгән. Нәшрият: «Без иптәшнең күңелен күрдек, бәлки, шуның белән канәгатьләнер», — дигәндер. Нәтиҗә шул: күмәк җыентык чыгып җитәр-җитмәстән Р. Вәлиуллин нәшриятка яңа кулъязма юллый.

Менә Р. Вәлиуллин иҗатыннан бер мисал. Өтеренә дә кагылмыйча бары тик җөмләләрне сузып салып кына китерәм:

«Хәнҗәр йөзе буйлап барды язмыш юлым. Тынгысыз. Борчулы. Тәвәккәллек сорый һәр адым. Аяк асты тулы афәтләр. Ул хәнҗәрне яны белән салып, юл ясадым хәзер. Такыр. Иркен. Юл читләре — хәнҗәр йөзе — дошман өчен хәтәр. Очының юнәлеше — кыйбла. Инде юлдан ничек бару түгел, нәрсә алып бару булып туа мәшәкатьләр».

Я, нәрсә бу? Кем аңлый ала бу абракадабраны? Һәм кемгә кирәк бу? Ә бит авторның кулъязмасы тулаем диярлек әнә шундый томанлы бушлыклардан тора. Сүзләр томаны артында — бушлык.

Янә нәшриятка юлланган берничә кулъязма һәм аларның авторлары хакында берничә сүз әйтәсем килә. Чөнки аерым авторлар мисалында гомуми тенденцияләр дә ачыграк аңлашылыр шикелле.

Әхәт Гайнуллин әле Казанда яшәгәндә үк, илленче еллар башында, эшче яшьләр әдәби түгәрәгенә йөреп каләм тибрәтеп караган кеше. Сугыштан соңгы елларда поэзиядә генә түгел, әдәбият-сәнгатьнең барлык тармакларында нык тамыр җәйгән, соңыннан лакировка дип, тормышны бизәп-буяп күрсәтү дип яманаты чыккан бер әшәке шаукымның дулкыннарында йөзәргә тыпырчынып караган күпсанлы яшьләрнең берсе иде ул.

Бу яшьләр тора-бара үз юлларын таптылар: иҗади мөмкинлекләре булганнар әдәбиятта-сәнгатьтә яңача юл саптылар, бер ишләре журналистикага авышты, кемнәр-

дер галим-голәма булды, кемнәрдер үзен бөтенләй башка өлкәдә тапты. Бик азлар гына, заман үзгәрешләрен сизмичә, һаман да иске урыннарында таптанып калдылар. Аларның кайсыберләре, аеруча сәләтсезләре, беркая да юньләп эшли алмыйча, бар дөньяга үч-ачу тотып, төрле югары оешмаларга жалобалар язучылар булып киттеләр.

Ә. Гайнуллин андыйлардан булмады. Ул үз бәхетен эштә — КамАЗ төзелешендә тапты. Мин инде аны язуын бөтенләй ташлагандыр дип йөри идем. Инде яше алтмышка җитеп килгәндә, нинди шигырь ди ул тагын?! Бигрәк тә шигъри сәләтең булмаган килеш... Юк, икән, ташламаган икән, яза икән. Кызганычка каршы... Алай гына да түгел, язганнарын әнә нәшриятка да юллаган. Ни өчен шулай эшләгәнме? Минемчә, соңгы елларда шулай озаклап язып йөрүче кайберәүләрнең коймак калынлыгы гына булса да китаплары чыгуы этәргән аны мондый кирәкмәгән адымга. Чүлмәкчедән күрмәкче, дигәндәйрәк инде... Күрәсез, «үзешчән авторлар»ның китапларын талымсыз чыгаруның мондый зыяны да бар икән...

Берәү ак каенга карый да: «Чыгарылыш кичәсеннән таңда очынып кайтып килгән кызлар күк, ак каеннар йөгерә...» — дип соклана, каеннарда шигърият күрә. Икенче берәү исә: «Юләр! Каеннар йөгерә димени? Менә утынга киссәң, кышын шәп яна инде ул каен!» — ди. Бу кеше дә нормаль кеше, әмма ул күңеле белән шагыйрь түгел. Аның рифмалап шигырь язып йөрүе дә ихтимал әле. Ни хикмәт: менә шундый кеше, күңел төбендә яткан «каен утыны шәп яна» дигән фикерне әчкәрәк яшерә дә, шома гына ритм-рифмасын табып, каенны яратуы хакында тезмә сырлый. Шуны бастырып чыгаруны таләп итә башлый. Әхәт Гайнуллин андый ук дәрәҗәдәдер дип әйтмим мин. Аның «Каен» дигән язмасында: «Ул яшәреп киткән шатлыгыннан, тирәнгәрәк җәел тамырын»,— дигән ясалма, ялган пафослы юллар бар. Нәрсәгә шатлана каен? Табигатьне кырып-җимереп «яңа җирдә яңа шәһәр калыкканга», тимер-бетон арасында, таш-асфальтта машина төтене сулап үскәненә шатлана. Каен тамырына балта чаптың ни дә, шигырь тамырына ялган белән чаптың ни — икесе дә һәлакәткә илтә...

Ике табак күләмендәге кульязмада бу «Каен» әле кулга алып сүз йөртерлек җирлеге булган язма. Андый язмалар тагын бер-ике бар. Һәм шуның белән вәссәләм!

Ә. Гайнуллин шигырь техникасын үзләштергән. Аның әдәби түгәрәкләргә йөрүе бушка китмәгән, күрәсең. Ритм-рифмада ул традицион калыптагы юлларны тәгәрәтә генә. Асфальт юлдан чапкан машина кебек юргалый бу тезмәләр. Әмма күңелдә бернәрсә дә калмый. Чөнки шигырь юк. Бар рифмаланган лозунглар, бар купшы сүз уйнатырга тырышулар, бар чик-чамасыз декларатив штамплар... Шигырь юк.

Ә. Гайнуллин өлкән яшьтәге кеше. Үз буыным вәкиле буларак, аның язмышына мин битараф кына карый алмыйм. Безнең буын иртә өлгерде, тормыш тәртәсенә иртә җигелде. Күп язмышлар үкенечле булды... Күпләр үзләрендә яшеренеп яткан сәләтләрне ача алмый калдылар. Әйе, тарихның безнең иңгә салган кулы каты һәм авыр булды... Әмма без бирешмәдек. Үз юлыбызны табарга тырыштык. Илне күтәрдек, гаиләләр кордык, балалар үстердек. Сугыш кырларында ятып калган әтиләрдән соңгы тормышны без бар иттек. Безнең миссиябез шул иде. Һәр буынның, һәр шәхеснең үз язмышы. Беркемгә үпкәләргә дә урын юк. Шуны аңлап яшәргә дә кирәк безгә.

Гайсә Гатауллин исеме дә матбугат битләрендә сирәк-мирәк кенә очраштыргалый. Ни өчен сирәк кенә? Ник иптәш ачылып-күтәрелеп китә алмый? Нәрсә җитенкерәми? Моның асылына төшенү өчен авторның язганнары белән тулырак танышу кирәк, әлбәттә.

Г. Гатауллинның «Аккошлар белән саубуллашу» дигән кульязмасы белән танышып чыккач, әлеге «җитенкерәмәгән нәрсә» ачыкланды. Язучылык эшенә, аерым алганда шигъриятькә җитди караш җитенкерәми икән Г. Гатауллинга. «Үзешчән авторлар»га бик тә хас күренеш бу.

Бездә хәзер шигырь язу куәсе, шигъри тоемы булган затлар шактый күбәйде. Бу — табигый күренеш: белемле кешеләр ишәйде. Әмма, «шигырь сырлый» белүчеләр ишәйсә дә, аларның бик сирәкләренә генә газаплы бәхет — шагыйрь булу бәхете елмая.

Ә. Гайнуллин кебек, традицион формаларда язып өйрәнгән «үзешчәннәр»дән аермалы буларак, Г. Гатауллин һәм башкалар бер «авыру» белән авырыйлар. Алар шигырьнең төзелешенә, аның язылыш техникасына, формасы-калыбына бөтенләй игътибар итмиләр диярлек. Каләм ничек сырласа, шулай яза бирәләр алар. Бу — әлеге дә баягы җиңел караштан. Г. Гатауллин язмалары арасында традицион шигырь калыбы да, ак шигырь яки ирекле шигырь элементлары да очрый. Ләкин алар барысы да бердәй ватыла, бердәй изелә. Традицион дигәне чиле-пешле рифмалар, ритм чатаклыклары белән бозыла, ак шигырьгә кирәкмәгәндә рифма килеп керә яки ритм бөтенләй прозага әйләнә, ирекле шигырь исә катканаклы-кантарлы юлдан тәгәрәгән арба кебек дыңгырдарга тотына. Шигырьгә мондый безалаберный, рәтсез-юньсез мөнәсәбәтне берничек тә акларга мөмкин түгел. Ул бары тик Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Радиф Гатауллиннардагы ак шигырь һәм ирекле шигырь үрнәкләренә эпигоннарча ияру нәтиҗәсе.

Һәр яшь шагыйрь үзе язганын үзе сүтеп карасын, көче җитмәсә, әдәби берләшмәләрдә шул эш эшләнсен иде. Шул чагында яшьләр аңлар иделәр: шигырь алай җиңелдән генә язылмый икән, күп көч түгүне сорый икән! Ә профессиональ язучының уртача айлык кереме СССРда нибары җитмеш сум тәшкил итә... Әллә бу мәшәкатьле һәм иписез эшкә алынмау хәерлерәкме икән? «Үзешчәннәр» шул хакта уйлансалар да зыян итмәс иде!

Сүзне түгәрәкли төшеп, тагын бер язмышка тукталасым килә. Монда инде бөтенләй башка мөмкинлекләр... Дөресен әйтергә кирәк, Рәшит Мозаффаровның шигырьләрен Илдар Юзеевның «Социалистик Татарстан» битләрендә «профессиональ дәрәҗәдәге шигырьләр» дип тәкъдим итүе, тәкъдим ителгән шигырьләрнең бик тә инде уртакул гына булуы күңелне суыткан иде. Җитмәсә, авторга 54 яшь! Бу яшьтә алга таба нинди перспектива көтәргә мөмкин? Үз бәясендә бик юмартланмадымы икән Илдар Юзеев?

Менә Р. Мозаффаровның «Зәңгәр һавада туган җыр» исемле кульязмасы. Беренче шигырьне ачабыз. Аңа инде кемдер «минус» тамгасын салган, икенче шигырь, өченчесе...— буш әйберләр. Тамгалар төшереп, кайбер ризасызлык фикерләрен теркәләп баручының кулыннан таныла: нәшриятның баш редакторы Вакыйф Нуруллин кулы икән. Ул шул рәвешле Р. Мозаффаровның бер егермеләп шигырен укып чыккан, өмет күренмәгәч, ташлаган. Янә берничә бит укыса, баш редактор бәлки «Дусларым» дигән шигырьгә килеп төртелгән булыр иде. Халык җырларына ияреп язылган булса да, бу шигырьдә нәрсәдер бар. «Балтачларда көмеш балта» дигән бер юл да шигъриятнең әле исән-сау икәнлеген искәртә.

Ни хикмәт: авторның үз профессиясенә — очучылык һөнәренә кагылышлы шигырьләре йомшак, баналь-буш әйберләр булып чыкканнар. Автор да, җыентыкны үз редакциясендә чыгарырга өстенә алган шагыйрь Илдар Юзеев та андый характердагы әйберләрне кульязмага күпләп кертеп, бигрәк тә шулар белән җыентыкны ачып җибәреп, ялгышканнар, минемчә. Кульязма китап булып чыккан сурәттә, укучы беренче берничә шигырьне укып карар да, нәкъ баш редактор эшләгәнне эшләр: калганнарын укып тормас. Ә бит Р. Мозаффаровта укырлык әйберләр бар һәм байтак.

Бу авторның күңелендә, әлбәттә, шигърият ята. Ул моңа кадәр ачылып кына китә алмаган. Аның шигырьгә барасы юлларын бала чагыннан ук сугыш серемнәре каплаган... Аннары сугыштан соңгы бик авыр еллар... Безнең буын шуңа күрә дә әдәбиятка соңлабрак килде, аз килде. Килгәннәрнең дә кайберләре инде, ачылып та җитә алмыйча, китеп тә бардылар... Мин шуны гына әйтә алам: Рәшит Мозаффаров, үз вакытында тиешле шартларга тап булган булса, хәзер шигъриятта шактый күренекле урыннарның берсен били алыр иде.

*Бу — бала кыш. Ни әйтәсең,*
*Әллә ни эшләр әле.*
*Яңа җәйгән ак җәймәсен*
*Кат-кат юешләр әле.*

Ах, шушы матур шигырьдәгечә итеп, Рәшитнең дә балачагын, яшьлеген кайтарасы иде! Өйрәнчек шигырьләрен «юешли-юешли» үрмәләсен иде шигърият үрләренә! «Урманда көз» дигән шигырендә ул: «Көмеш каенга алтын бөркелгән»,— ди. Каеннарга алтын бөркелә, ә безнең чәчләргә инде көмеш кенә дә түгел, янган гомерләребезнең көле бөркелгән шул, кордаш... Икенче бер шигырендә: «Язның күзләре шикелле бөреләр ачылдылар»,— дип яза Рәшит Мозаффаров. Аның озак еллар күмелеп, йоклап яткан шигъри бөреләренең дә шулай ачылуын теләр идем мин. Бар микән аның шундый җегәре, калдымы икән потенциаль көче? Инде алтмышка җитеп килгәндә укучылар алдына беренче китабың белән чыгасың икән — ул китапны йөз кызартмаслык итеп, намуслы хезмәт белән яуланган абруеңа күләгә төшмәслек итеп чыгарырга кирәк бит...

Рәшит Мозаффаров «очар кошның очасы киләдер шул...» дип яза. Безгә «үзешчән авторлар» арасыннан әнә шундый «очар кошлар»ны аралап ала белергә кирәк. Ә без күбрәк, Хуҗа Насретдин шикелле, төшсез чикләвекләрне «бусына тимәгән, бусына тимәгән» дип сайлау белән мәшгуль әлегә.

Сүз бик озынга китте шикелле. Ә бит әлеге «сигез йөз»нең мин бик азын гына телгә алдым. Аларның һәркайсы хакында конкрет сөйләшергә, кабатлап әйтәм, әдәби язмышларын ачыкларга тиештер без.

Бары тик шулай эшләгәндә генә Язучылар союзының да, китап нәшриятының да ничәмә-ничә еллардан бирле җыелып килгән бу авыр йөктән — балласттан арына алуы мөмкин. Ул балласт урынына чын-чыннан сәләтле яшьләр килер дигән өметтә калыйк. Аларны эзли, таба белергә генә кирәк. Р. Мостафин талап иткән игътибарга, хөрмәткә алар лаек, алар мохтаҗ.

**Рүзәл Юсупов,**

филология фәннәре докторы,
профессор, КДПИ ректоры

# СӨЙЛӘШҮ ӘДӘБЕ

Сөйләм культурасы ул — гомуми культураның мөһим өлеше. Үзен югары культуралы итеп тәрбияләргә теләгән кеше, һичшиксез, сөйләм культурасына да ия булырга, ягъни гомум халык тарафыннан кабул ителгән кагыйдәләргә таянып сөйли һәм яза белергә тиеш.

Кызганычка каршы, татар телендә сөйләүче һәм язучы барлык кешеләрнең дә сөйләм культурасы тиешле дәрәҗәдә түгел. Ещ кына кайберәүләрнең татарча сөйләгәндә бер дә кирәксезгә *город, школ, собрание, значит, можно, тоже, зав. фермой, переводить итү* кебек һәм башка йөзләрчә рус сүзләре һәм әйләнмәләре һәм уңышсыз калькалар (*Мәскәү астындагы сугыш, парта артында утыру, җаваплылык алып бару, дәвалау үткәрү* һ. б.) кулланалар. Шунысы бигрәк тә аяныч: кирәксезгә алынма сүзләр һәм калькалардан файдалану аерым кешеләр сөйләмендә генә түгел, китап, газета-журнал битләрендә, радио-телевидение тапшыруларында да шактый еш очрап тора.

Бер генә мисалга тукталыйк. Узган елның 6 июлендә телевизор аша Сарман районындагы бер җитәкче белән әңгәмә алып барылды. Мин телевидение хезмәткәренең сорауларына бирелгән җавапларны язып калдым. Менә алар:

— Зәй районы безгә обмен опытом күрсәтте...

— Медалистлар башта кала, аннары институтларга поступать итеп бетә...

— Кайда мәктәп бар, анда авыл бар.

— Яшьләр җавап бирсен әле вопроска! (Монысы инде телевидениедә эшләүче әдәби хезмәткәр сүзләре! Р. Ю.).

— Бүген какраз телевизион передача булгач та...

— Отложить итеп киләләр.

— Бүгенгә хәтле конкрет задача юк.

— Хаклы куркалармы или юкмы? (әдәби хезмәткәр соравы Р. Ю.)

— Юк, конечно!

— Задачалар хәл ителеп бара пока. Объектлар арта. Әле полный гарантия юк. Түлке халык соравын гына обеспечить итәбез...

Бу мисалда татар телендәге сүз байлыгыннан да, җөмлә төзелеше кагыйдәләреннән дә тупас рәвештә артка чигенү бик ачык күренә.

Кызганычка каршы, мондый мисалларны газета-журналлардан да, язучыларыбыз язган мәкаләләрдән дә, хәтта әдәби әсәрләрдән дә табарга мөмкин.

Телдәге мондый ялгышлар фәндә интерференция күренеше дип атала. Аның нигезендә ике тел белән эш иткән кешенең бер телгә генә (бу очракта — рус теленә генә) хас чаралы, уйлап-нитеп тормыйча, икенче телгә (бу очракта — татар теленә) күчерү ята. Бу хәл туган телнең үз хәзинәләреннән тулысынча файдалану мөмкинлеген чикли, ана теле кагыйдәләрен бозуга китерә һәм сөйләм культурасының дәрәҗәсен түбәнәйтә.

Аерым сүзләр кулланылышына бәйле ялгышлар, күбесенчә, икенче тел сүзләрен кабул итү принципларын белмәүдән килеп чыга. Мәгълүм ки, алынма сүзләр куллану кайчак җитди бәхәсләр тудыра яки башбаштаклыкка сәбәп була.

Кайсы очракта алынма сүз кулланырга ярый, кайсысында юк? Ни өчен, мәсәлән, татарча сөйләмдә лампочка сүзен куллану ялгыш саналмый, ә *кружок* сүзен куллану туган телне бозу итеп карала? Монда төп кагыйдә шуннан гыйбарәт: тиешле төшенчәне белдерү өчен иң беренче чиратта туган телнең үз чаралары файдаланылырга тиеш. Яңа төшенчәне белдерү зарурлыгы туганда, моңарчы кулланылышта булган сүзләргә

яңа мәгънә өстәлә, сирәк кенә очракларда диалектизмнан файдаланырга мөмкин яки морфологик, синтаксик юл белән сүз ясала. Бу чараларның берсе дә кирәкле төшенчәне белдерә алмаса гына, икенче бер тел сүзеннән файдаланырга ярый.

Кайчакта безнең кайбер тәрҗемәчеләр, журналистлар, татар теленең үз сүзләрен эзләп табу өчен көч сарыф итеп тормыйча, һич кирәкмәгәндә дә рус сүзләре кулланалар. Мәсәлән, соңгы елларда чыккан тәрҗемә китапларында, газета-журнал битләрендә, радио-телевидение тапшыруларында *занятие* (татарча *дәрес, уку* дип әйтергә була), *обстановка (хәл), допрос (сорау алу), кругозор (караш, белем), номер (сан), геройлык (батырлык), констатацияләү (билгеләү, әйтү), прием (кабул итү, алым), реализацияләү (гамәлгә ашыру, сату), средство (чара), ствол (көпшә), правление (идарә), сфера (өлкә), парус (җилкән), помещик (алпавыт), секрет (сер), платина (ак алтын), учет (исәп), иго (изү), рубеж (чик), корректива (төзәтмә), шрам (җөй), художество (сәнгать), водопровод (сүүткәргеч), период (чор), полномочие (вәкаләт), функция (вазифа), уполномоченный (вәкил), мятеж (фетнә), регистрация (теркәү)* кебек һәм башка шуларга охшаш бик күп сүзләр очрый.

Безнең каләм ияләрендә икенче чиккә ташлану күренеше дә сизелә. Эш шунда: кайберәүләр татар телендә урынлы, законлы кулланылган күп санлы рус сүзләрен, интернациональ сүзләрне күреп шөбһәгә төшәләр һәм, телебезне «чистарту» нияте белән халык тарафыннан инде күптән үзләштерелгән алынма сүзләрне татар, гарәп, фарсы сүзләре белән алыштырырга омтылыш ясыйлар. Матбугат битләрендә, кайбер дәреслекләрдә, матур әдәбият әсәрләрендә *политик* сүзе урынына *сәяси* сүзен куллану, *классны* (мәктәп баласын) — *сыйныф, экскаваторны — җир соскыч, сборны* (пионерлар сборын) — *җыен, сводканы — җыемта, отвертканы — терәп боргыч* дип язу — шуның ачык мисалы.

Халык телендә, шулай ук әдәби телдә нык үзләштерелгән рус алынмаларын, интернациональ сүзләрне, тел сафлыгы өчен көрәшәбез дип, халыкка аңлашылмый торган уңышсыз ясалма сүзләр, инде күптән кулланылыштан төшеп калган гарәп һәм фарсы сүзләрен яки иске төрки сүзләр белән алмаштыру һич кенә дә максатка ярашлы була алмый. Болай эшләү халык теләгенә дә, заман рухына да туры килми.

Без бу юнәлештән китсәк, халыкның сөйләм телен әдәби телдән ераклаштыру юлына басар идек. Аңлашыла ки, мондый ике варианттагы (әдәбияттагы һәм халыктагы) телнең беркемгә дә кирәге юк.

Интернациональ сүзләрне уңышсыз тәрҗемә итәргә маташу бервакытта да уңай нәтиҗә бирми. Интернационализмнардан ахмакларча котылырга азаплануның һич кирәксез һәм зыянлы эш икәнлеге турында үз заманында Ф. Энгельс: «...Лассаль үзенең речьләрендә һәм пропаганда өчен язган брошюраларында башка тел сүзләрен куллануданбик үк тартынмаган, минем белүемчә, моңа карата артык зарланмаганнар да, ә ул заманнан бирле безнең эшчеләр тагын да ихласрак һәм системалырак рәвештә газета укыйлар. Шуның аркасында башка тел сүзләренә ияләшәләр,— дип язган.— Мин бик үк кирәк булмаганнарын бетерү белән чикләндем. Ләкин кирәк булганнарын калдырдым һәм аларга тәрҗемәләр ясаудан баш тарттым... Тәрҗемә итү аларның мәгънәсен боза гына, ачыклау урынына буталчыклык кына кертә.»

Халыкларның фән-техника прогрессы казанышларын үзара алмашуы, шулай ук политика, экономика, культура, сәнгать өлкәсендәге хезмәттәшлекнең һәръяклап ныгый баруы телләрнең бер-берсеннән сүзләр алуына да уңай шартлар тудыра. Мондый закончалыкка үз чорында В. Г. Белинский да игътибар иткән: «Чит төшенчәләрне тәгъбир итү өчен үз терминнарыңны уйлап табу бик кыен,— дип яза ул.— Шуңа күрә бер халык икенчесеннән төшенчә белән бергә ул төшенчәне белдерә торган сүзнең үзен дә ала. Бу эш гаделлеккә корылган: бер халык тудырган төшенчә өчен, аңа рәхмәт йөзеннән, башка халыкларга ул төшенчәне белдерә торган сүз дә күчә».

Туган телнең үз сүзе була торып та, кирәксезгә, чит тел сүзе кулланып хаталануны аңлау һәм аңардан котылу чарасын табу һич тә катлаулы эш түгел. Ә менә сүзләре татарча булып та рус теленә хас алымнар белән сөйләшү яки язу очракларыннан арыну шактый кыен. Бу төр хаталар сүзләрне ялгыш мәгънәдә куллану, төшенчәне тиешле сүз белән белдермәү аркасында килеп чыга.

Икенче тел тәэсирендә ана теле сүзләрен ялгыш мәгънәдә куллануны ныклабрак ачыклыйк әле! Икетеллелек күренеше тәрҗемә процессы белән тыгыз бәйләнештә тора. Ике телдә сөйләшүче кеше һәр телне дә идеаль рәвештә яхшы белеп, ул тел системаларын бер-берсенә бер дә керештермичә һәм катнаштырмыйча эш иткән очраклар бик сирәк була. Чынбарлыкта ике телдән дә даими файдаланучы кеше (билингв) еш кына, теләгән фикерен белдерү өчен, икенче тел чарасына да мөрәҗәгать итә.

Гадәттә билингв, туган телен яхшы белеп, икенче телне начаррак белгәнлектән, фикерне икенче тел чарасы белән белдергәндә, теге яки бу сүзне туган телдән тәрҗемә итеп ала.

Татар-рус икетеллелеге шартларына шул нәрсә хас: татар кешесе, үз телендә сөйләгәндә яки язганда, күп кенә төшенчәләрне рус теленнән тәрҗемә итеп ала. Бу хәзерге вакытта яңа төшенчәләрнең, гадәттә, башта рус телендә тәгъбир ителүенә һәм рус теленең милләтләр аралашу теле буларак барлык халыкларда актив кулланылуына нигезләнә. Кыскасы, билингвка ике тел сүзләрен даими рәвештә үзара мөнәсәбәткә кертеп, алар арасында тәңгәллекләр табып торырга туры килә.

Әйтергә кирәк, билингвлар сөйләмендәге, ягъни нәкъ менә безнең сөйләшүдәге ялгышлар барыннан да бигрәк телләрнең лексик-семантик үзенчәлекләрен исәпкә алмау, аларга хас аерымлыкларны белмәүдән килеп чыга. Андый үзенчәлекләр исә бик мөһим: төрле телләрдә сүзләр исәбе төрлечә, күп очракта сүзләрнең мәгънә күләме дә төрле. Сүзлекләргә теркәлгән тәрҗемәләр, күбесенчә, төшенчәләрнең эквивалентлары түгел, бәлки мәгънәви яктан якын торган сүзләр генә, шуңа күрә аларда оригиналның (төп нөсхәнең) мәгънә һәм эмоциональ төсмерләре тулысынча чагыла дип уйларга ярамый.

Дөнья күләмендә танылган телче Л. В. Щерба телләрдәге бу үзенчәлекне болай аңлата: «...дөнья, бөтен җирдә дә бер төрле булып калып, төрле телләрдә төрлечә үзләштерелә».

Сүзләрнең мәгънә күләмнәре бер-берсенә туры килмәү катлаулы мөнәсәбәтләр китереп чыгара. Мәсәлән, төп сүзе горячий булган мәгънәви төркем берәмлекләре татар теленең *кайнар, кызу, кечле, ялкынлы, мәшәкатьле* һ. б. ш. лексемалардан төзелгән төркем сүзләре белән өлешчә нисбәткә керә: *кайнар чәй* (горячий чай), *кызу (канлы) кеше* (горячий человек), *көчле теләк* (горячее желание), *мәшәкатьле көн* (горячий день). Бу семантик төркемнәрнең сүзләре исә рус телендәге башка семантик төркемнәрнең төрле сүзләре белән нисбәткә керә ала. Мәсәлән, *көчле* сүзенең төрле мәгънәләре, югарыда күрсәтелгән *горячий* сүзе белән килгән пардан тыш, башка семантик төркемнәрнең элементлары белән нисбәти пар төзи: *сильный, мощный, могучий, крепкий, бурный, тяжкий* h. б. Бу сүзләрнең һәркайсы үз чиратында татар телендәге башка семантик төркемнәрнең төрле лексик берәмлекләре белән нисбәти парлар ясый. Һәм шулай чиксез дәвам итә. Төрле тел сүзләренең мәгънә күләмнәрендәге аерма башка төрле юнәлешләрдәге охшаш төркемнәр китереп чыгара. Аларның саны геометрик прогрессия буенча арта бара. Бу хәлдә лексик тәңгәллекләрнең берничә төре аерылып чыга. Аларны тирәннән өйрәнү һәм белү сөйләм культурасын күтәрү, тәрҗемәләребезне яхшырту, шулай ук мәктәпләрдә туган телне һәм рус телен укыту методикасын камилләштерү өчен бик мөһим.

Инде рус-татар телләре өчен аеруча әһәмиятле һәм шул ук вакытта сөйләмебезне хата юлга кертеп җибәрүче ике очракка игътибар итик.

1. Рус сүзенең төрле мәгънәләренә татар теленең төрле семантик төркемнәрендәге сүзләр туры килгән очраклар бар.

Мәсәлән: *убрать* 1)— *җыештыру* (бинаны җыештыру — убрать помещение); 2) *урып-җыю, җыеп алу* (игенне җыеп алу — убрать урожай); 3) *бизәү* (бүлмәне чәчәк белән бизәү — убрать комнату цветами); 4) *көрәү* (кар көрәү — убрать снег) h. б.; *острый* — 1) *үткен* (үткен пычак — острый нож); 2) *очлы* (очлы сәнәк — острые вилы); 3) *үткен, зирәк* (үткен күз — острый глаз); 4) *ачы* (ачы тел — острый язык), 5) *көчле, каты* (көчле ис — острый запах, каты авыру — острая болезнь); 6) *кискен, чиктән тыш, киеренке* (киеренке хәл — острое положение) h. б.

2. Рус телендәге төрле семантик төркем сүзләренә татар теленең күп мәгънәле бер сүзе туры килә: 1) *знать — белү* (много знать — күп белү), 2) *уметь — белү* (уметь читать — укый белү); 1) готовить — әзерләү (готовить пищу — ашарга әзерләү), 2) делать — әзерләү (делать уроки — дәрес әзерләү).

Һәр сүзнең мөстәкыйль мәгънәсе булса да, аның һәр конкрет өстәмә һәм кучерелмә мәгънәсе, нигездә, бары тик башка сүзләр белән бәйләнештә, ягъни контекстта гына ачыла. Контекстны тәгәл исәпкә алу зарурлыгы бигрәк тә тәрҗемә иткәндә ачык чагыла. Күренекле тәрҗемә теоретигы А. В. Федоров әйткәнчә, «...тәрҗемә бервакытта да оригиналның билгеле бер сүзенә тәңгәллек буларак сүзлекләрдә (хәтта иң тулыларында да) теркәлгән элементлар арасыннан сайлап алу белән генә чикләнми. Тәрҗемә эшендә күп очракларда сүзлектә исәпкә алынмаган сүзләрдән файдаланырга туры килә».

Бу фикер русчадан татарчага тәрҗемәләрдән алынган мисаллар белән дә ачык раслана. Берничә мисал.

Я юнкер, а теперь представлен — Юнкер мин, тиздән офицер итәчәкләр (Л. Толстой) (представить — офицер итү).

С начала учебного года в нее записалось 370 человек — Уку елы башында 370 кеше укырга кергән иде (записаться — укырга керү).

Девочку он помог поднять — Кызны үстереште ул (помочь поднять — үстерешү).

Кайбер рус һәм татар сүзләре арасында тәңгәллекләрне бары тик контекстта гына табарга мөмкин. Мәсәлән, татарча «хатын» сүзе русчадагы «жена» мәгънәсен дә, «женщина» мәгънәсен дә белдерә. Рус телендәге «брат», «сестра», «идти» кебек сүзләрне татарча биргәндә дә шул ук хәл.

Ике тел белән эш итүчеләр еш кына әнә шундый үзенчәлекләрне исәпкә алып тормыйча, рус сүзен туры, төп мәгънәсендә генә аңлап, аның татар телендә аеруча киң кулланыла торган тәңгәллегеннән генә файдаланалар һәм хаталануга юл ачалар.

Мисаллар:

«Рейган,— диде ул шул ук программа буенча ясаган чыгышында,— мондый хәрәкәтләр өчен шәхси җаваплы, һәм ул аларны туктатырга тиеш» (газетадан). Бу җөмләдә «хәрәкәт» сүзе дөрес кулланылмаган. Ялгыш менә ни өчен килеп чыккан. «Действие» сүзенең берничә мәгънәсе бар. Шуларның берсе — кешенең эшчәнлеге, эшләре. Икенчесе — физик җисемнәрнең, кеше әгъзаларының, бөҗәкләрнең һ. б. ш. төрлечә хәрәкәтләнүе, нинди дә булса энергия сарыф итүе. Беренче мәгънә татар телендә эшләү, эш сүзләре белән, икенчесе хәрәкәтләнү, хәрәкәт сүзләре ярдәмендә белдерелә. Әле китерелгән мисалда да «действие» беренче мәгънәдә — кешенең аңлы эшчәнлеге мәгънәсендә кулланыла, һәм аны татарчада эш сүзе белән (...мондый эшләр өчен) бирергә кирәк иде.

«Саран миллиардерның соңы» («Конец скупого миллиардера») (газетадан). Монда «конец» сүзенең туры мәгънәсе кулланылган. Чынында исә бу очракта, «конец» дип, «үлем» турында сөйләнелә, һәм аны татарчада «Саран миллиардерның үлеме» дип алырга кирәк иде.

Тәрҗемә әсәрләрдәге кайбер хаталар бер генә телгә хас сурәтләү чарасын (тропны) ике тел өчен дә уртак итеп санау аркасында килеп чыга.

Рус телендәге «орел» һәм татар телендәге «бөркет» — төп мәгънәләре белән тәңгәл сүзләр — ике телдә дә бер үк төрле күчерелмә мәгънә — батыр, кыю кеше мәгънәсен белдерәләр.

Әмма рус телендәге «пиявка» күчерелмә мәгънәдә башкалар исәбенә яшәүче, паразит кеше мәгънәсен белдерсә, татар телендә «сөлек» икенче төрле күчерелмә мәгънә — сылу, таза, матур кеше яки ат мәгънәсен белдерә. Димәк, ике телдәге бу тәңгәл сүзләр күчерелмә мәгънәләре белән үзенчәлекле күренеш тәшкил итәләр.

Туры мәгънәләре белән бердәй сүзләрнең дә күчерелмә мәгънәдә кулланылышлары төрлечә була. Мәсәлән, рус кешесе, энәнең җеп тага торган тишеге белән колак арасында охшашлык күреп, колак исемен энә тишегенә күчергән (игольное ушко), татар кешесе исә, шул ук энә тишеген күзгә охшатып, күз исемен күчергән (энә күзе).

Ике тел белән эш итүче кеше мондый үзенчәлекләрне яхшы белергә тиеш.

«Кислота разъедает одежду» дигән җөмләдә «разъедает»ның күчерелмә мәгънәсе татарчада да ул сүзнең туры тәңгәллеге белән белдерелә ала: «кислота киемне ашый». «Дым есть глаза» дигән җөмләдә исә «ест» сүзенең күчерелмә мәгънәсе беренче җөмләдәгедән үзгә һәм аның татар телендәге тәңгәллеге «ашый» бу күчерелмә мәгънәне белдерә алмый: татарча «төтен күзне ашый», димиләр, «төтен күзне ачыттыра», диләр.

Хатын-кыз матурлыгын тасвирлау өчен кулланыла торган кайбер чагыштырулар игътибарга лаек. Татарларда чибәр йөзне — алмага, алсу иренне — чиягә, кара күзне — шомыртка тиңләү бар. Русларда алай түгел. Аларда исә сөекле кызның чәчләрен арыш көлтәсенә охшаталар (татарлар өчен бу сәер тоела), матур күз билгесе итеп зәңгәр төс санала (татар поэзиясе өчен бу да гадәти түгел). Яраткан кешегә татар телендә «хөрмәм, алмам, былбылым» дип, ә рус телендә «голубка» дип эндәшү гадәткә кергән. Шушы күренешкә нигезләнгән сурәтләү чарасын бер телдән икенче телгә әйләндереп кенә тәрҗемә итсәң, телнең сәнгатьлелек-сурәтлелек нормалары бозылыр иде. Әйтергә кирәк, кайбер тәрҗемә китапларда русчаның «голубушка»сы урнәгендә татарча «күгәрченем» дип язалар. Бу дөрес түгел, әлбәттә. Руслар өчен сылу кызны топольгә тиңләү табигый булса, татар поэзиясенә кызның нәфислеген, сылулыгын тал белән чагыштыру хас.

Практика күрсәткәнчә, безнең телдә рус теле үрнәгендә күп кенә яңа сурәтләү чаралары төзелә. Татар язучыларының әсәрләрен тәрҗемә итү процессында рус телендә дә татар теле троплары өлгесе белән яңа чагыштыру, метафора, эпитетлар ясала. Бу — телнең образлылык чарасын төп мәгънәсендәге төгәллеге ярдәмендә тәрҗемә итү (калькалаштыру) юлы белән башкарыла. Мәсәлән: гүзәл яшь туташ, җиңел күләгә кебек, күрешәсе урынга якынлашып килә иде (как легкая тень, красавица приближалась к месту назначенного свидания — Пушкин); сөт елгалар, кисәл ярлар (молочные реки, кисельные берега); сары мыеклы яшь ай (молодой желтоусый месяц — Шолохов).

Ләкин һәрвакытта да тропларның һәр сүзен дә бер телдән икенче телгә төп мәгънәсендәге тәңгәллекләре белән генә күчереп булмый. Сурәтләү чарасы икенче телдә табигый яңгырасын өчен, еш кына аның образ төзүдә беренче дәрәҗәдә әһәмиятле булмаган кайбер сүзләрен үзгәртергә, төшереп калдырырга, яңа сүзләр өстәргә туры килә. «Странная мысль наклевывалась в голове, как из яйца цыпленок» дигән чагыштыруны, һәр сүзен дә татар теленең стилистик нормаларына зыян китермичә, төп мәгънәле тәңгәллекләре белән генә тәрҗемә итеп булмый. Шуңа күрә «как из яйца цыпленок» дигән тәгъбирне, татар теленең үзенчәлекләренә яраклаштырып (берничә сүз өстәп), шул ук вакытта оригиналның күчерелмә мәгънәсен һәм образлылыгын саклап, берникадәр үзгәртергә туры килә: «Күкәй эчендәге чеби кабыкка борыны белән төрткәндәй, ниндидер бер сәер фикер тернәкләнә башлады».

Әмма русчадан татарчага тәрҗемә иткәндә кайчак иҗади эшләү җитеп бетми. Сүзгә-сүз, хәрефкә-хәреф принцибы белән эшләү нәтиҗәсендә әдәби телдә уңышсыз сурәтләү чаралары барлыкка килә: күчерелмә мәгънәләр аңлашылмый, тиешле дәрәҗәдә образлы булмыйлар, туган тел өчен сәер тоелалар һәм укучыга сәнгатьле тәэсир итә алмыйлар. Нәтиҗәдә телебезнең образлылык системасы үстерелми, баетылмый, киресенчә, аның лексик-семантик һәм сурәтлелек-сәнгатьлелек нормалары бозыла.

Уңышсыз тәрҗемә итүнең кайбер очракларын карап китик.

Еш кына, механик рәвештә тәрҗемә итү аркасында, сүзләрнең бәйләнеш нормалары бозыла. «Он мог разломать ее, как игральную карту» (Горький) дигән җөмләне «Ул аны уен картасын сындырган кебек сындыра ала» рәвешендә тәрҗемә итүне дөрес дип әйтеп булмый, чөнки татар телендә «карта» һәм «сындыру» сүзләре бергә килә алмый. «Курганы в степи — как переспелые арбузы...» дигән чагыштыруның тәрҗемәсендә «карбыз» белән «пешкән» сүзләре гадәти бәйләнешкә керә алмый. Карбыз «пешми», «өлгерә».

Сурәтләү чараларындагы кайбер сүзләрне механик рәвештә тәрҗемә итү уңышсыз, аңлашылмый торган троплар барлыкка китерә. «Малейшее нарушение советского порядка есть уже дыра, которую немедленно используют враги трудящихся.— Совет тәртибен бик аз гына бозу булды исә, хезмәт ияләренең дошманнары моны үзләренә ачык тишек итеп файдаланалар. «Дыра» дигән метафораны «тишек» сүзе белән тәрҗемә итү уңышлы түгел.

Кайчак сурәтләү чарасы һич урынсыз гадиләштерелә: Очи, как ясные звезды, горят (Горький)— Күзләре йолдыз төсле яна. Чагыштыруны төзүдә әһәмиятле роль уйнаган «ясные» сүзен тәрҗемәдә төшереп калдыру образны нык ярлыландыра. Күзләре якты йолдыз төсле яна дип тәрҗемә итәргә кирәк иде. Сурәтләү чарасы белән бирергә мөмкин була торып та, образсыз гына тәрҗемә итү очраклары шактый еш очрый. Мәсәлән, «Кулларың җылысы» дигән фильм сценариеның тәрҗемәсендә «пустомеля» «буш сүз сөйләүче» дип бирелгән. Аны оригиналга туры килерлек метафора белән «бушбугаз» яки «коры куык» дип алырга мөмкин һәм кирәк иде.

Без бу мәкаләдә сөйләмгә игътибарлы, җитди, сак караш җитмәү һәм үзара мөнәсәбәттәге телләрне яхшы итеп белмәү аркасында шактый зур хаталар хөкем сөрүен күрдек. Тел нормалары бозылу хәлләре монда күрсәтелгәннәр белән генә чикләнми. Алар шактый күп һәм, ихтимал, бу турыда башкалар да үз фикерләрен әйтер әле. Ләкин шунысы бәхәссез: сөйләм культурасы мәсьәләсе бүгенге көн тәртибендә торган җитди мәсьәләләрдән санала, һәм аның уңышлы хәл ителүе, сөйләм культурабызны тиешле югарылыкта тоту өчен көрәш даими рәвештә киң җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгендә торырга тиеш.

# ХӘСӘН ТУФАН ХАТЫ

1956 елның июнь ае. Хәсән ага Туфан Новосибирск өлкәсенең Устарка районындагы Покровка авылында тора. Бу авылда алар — бирегә җибәрелгәннәр — барысы 25 кеше. Араларында югары белемле физиклар, агрономнар, биологлар, химиклар, фән кандидатлары, атаклы галимнәр бар. Хәсән ага әйтмешли, Фәннәр академиясенең филиалын ачып җибәрсәң дә була.

1955 елны аларның күбесе реабилитация алып туган якларына кайтып китә. 1956 ел башына биредә нибары биш кеше кала. 1956 елның 19 мартында СССРның Генеральный прокуроры карары белән Туфан да гаепсезгә утыртылган дип табыла, тулысынча аклана һәм иреккә чыгарыла. Бу карарны аның кулына 9 апрельдә тоттыралар. Әмма нәкъ шул чакны Покровка авылында һәм бөтен районда карантин игълан ителә — дуңгызчылык фермасында ваба (чума) авыруы башлана.

Хәсән ага өзелеп-өзелеп туган ягын сагына, бәргәләнә, суккалана. Әмма карантин бик кырыс — справкага кул куймыйлар. Справкасыз исә ул бер адым да читкә атлый алмый. Әнә шул вакытта шагыйрьнең кызы Гөлүстән адресын белеп, каләмдәшләреннән беренче булып Туфанга аның күптәнге дусты Габдрахман Минский хат яза. Хәзер укучыларга тәкъдим ителә торган бу хат шуңа җавап рәвешендә язылган.

Хат Туфанның иҗат лабораториясенә үтеп керергә мөмкинлек тудыра. Монда безгә күптән таныш булган, хәзер инде классика дәрәҗәсенә күтәрелгән шигырьләрнең беренче варианты китерелә. Яңа, безгә бөтенләй таныш булмаган юллар да бар.

Билгеле булганча, Хәсән ага иң авыр шартларда да иҗат итүдән туктамый. Ләкин аның иҗат активлыгы һәрвакытта да тигез түгел. Мәсәлән, 1947 елгы күтәрелештән соң аның иҗат активлыгы түбәнәя бара. 1953 елны ул бары берничә шигырь яза. 1954 елны — берне дә язмый. 1955 елның башында абыйсына язган хатында ул әдәбияттан читләшүе, бер юл да язалмавы турында ачынып хәбәр итә. Әмма берничә айдан ул яңадан канатланып, илһамланып яза башлый. Иҗат активлыгының иң югары ноктасы — 1956 елның язына, ягъни иреккә чыгып, Покровкада яткан чагына туры килә. Бу вакытта Туфан үзенең иң көчле, иң җитди, әдәби яктан иң камил әсәрләрен яза. Шуңа да Туфан иҗатындагы бу чорны Пушкинның Болдино көзе белән чагыштырырга мөмкин (Пушкин да бит карантин аркасында авылда калырга мәҗбүр була). Хат шул чордагы Туфанның кичерешләрен, аның дөньяга карашын, уй-фикерләрен күз алдына китерергә мөмкинлек бирә.

Бу хатны миңа Габдрахман ага Минский үзе исән чакта биреп калдырган иде. Аның оригиналы язучының шәхси архивында саклана.

**Рафаэль МОСТАФИН**

Бу ни хәл, Минский, аптырадым инде: йөрәк катнаша торган берәр хатны язарга утырдым исә, ә йөрәк катнашмаганын яза да алмыйм,— әллә кайдан шунда, көтмәгәндә, уйламаганда (миңа шулай тоела), тота да берәр туасы шигырьнең аккорды яңрый.

Аны, билгеле, шул хәлендә тотып калырга кирәк, югыйсә бераздан бөтенләй югалуы, шул табигый хәлен югалтуы,— эхо рәвешендәге ерак, тонык яңгыравы гына калуы мөмкин.

Хат языласы кәгазьгә шуны теркәргә керешәм, күп вакытта ул аккорд хәлендә генә калмыйча, үзенең янына бүтән кисәкләрен җыя, бөтен хәлгә килә. Димәк, хат өчен билгеләнгән вакытны үзенә тартып ала.

Кичә менә сиңа язарга утырган идем, тагын шундый хәлгә очрадым:

*Кем ул шакый*
*зиндан әлифбасын?*

*Бу мин — Тарих —*
*Сиңа ни кирәк?!*

Мин моны кичә төнлә Казан урамнарында йөргән чагымда үз авызымнан ишеттем. (Хәзер һәр көнне шулай хыялда Казан урамнарында йөреп кайтам инде). Шул юллардан башланды да китте. Һәм ул каралама хәлендәге бөтенлеккә килгәнче, шул хәерсездән аерыла алмадым.

Хаттан аеруы өчен җәзалыйм мин аны — менә шул ук хәлендә сиңа кайта торсын:

*-...Давыллар да җирдә, сугышлар да,*
*Әйтерсең лә берни булмаган:*
*Варфоломей төнендәге сыман,*
*Битараф ай тыныч, тын һаман.*
*Нур сибә ай куйга һәм бүрегә,*
*Бар да инде яхшылар гүя,*
*Моабиттә асып үтерелгәннәр*
*Яшрен гүрдә ятмыйлар гүя!..*
*...Ай болытлар арасына керде...*
*Утлар сүнде. Тормыш йокыда.*
*Кыр ягыннан шәһәргә җил килә,*
*Юлда тузан туздырмый гына.*
*Урмандагы чәчәкләрдәндерме,*
*Җил мәйданга бал исе ташый.*
*Соңга калган юлчыдырмы, кемдер,*
*Тын шәһәрнең диварын шакый...*
*Ишетелер дип шакыйдыр ул, бәлки,*
*Берәр утлы-уяу кешегә.*
*Шакый һәм ул күптән түгелдәге*
*Таныш хәлне искә төшерә...*

*— Кем ул шакый зиндан әлифбасын?*
*Кем ул анда! Сиңа ни кирәк?*
*— «Бу ди ул,— мин, Тарих, мин, чордашым,*
*Улларымны йөрим мин эзләп...»*
*Исемнәрен атый:— Гали, Вәли...*
*Кече Галим, Олы Галимҗан...*
*Берәрегездә берәр хәбәр, бәлки,*
*Сәлам бардыр алар ягыннан?..*
*— Тормыштан син, Тарих, артта ласа,*
*Капканы син белми кагасың:*
*Хаклыкны ич инде мәйданнарда!—*
*Ил алдында яклый аласың!*
*Ташла, Тарих, хәтәр әлифбаңны,*
*Диварларда шакынып йөрүне:*
*Халык инде тотты, асты аны,—*
*Улларыңны упкан Диюне!*
*Ә Ай белми: мәктәп һәм төрмәләр,*
*Гүя бар да яхшылар инде,*
*Әйтерсең лә яшерен каберләрдән*
*Алтын ирләр кайттылар инде!*

Сиңа сөйлисе, язасы сүзләр күп, төрле, озын, чиксез, Минский. Берничә кат язарга җыенып карадым. Языласыларның һәркайсы үзенә урын алырга тели һәм барысы берьюлы кузгалып, хәтерне чолгап ала. Ә аларны һичбер юл белән хат эченә сыйдырып бетерерлек түгел. Ә кыскартырга, Энгельс әйтмешли, кыска язарга, вакыт юк, вакыт аз. Менә шуңа бу хатны, язарга теләгәннәремнең сайланмасы итеп түгел, күңелдәге чиратта алданрак урын алып өлгергәннәренең кайберләре рәвешендә генә язам. Бу хатка урнаша алмый калган өлешен үзем белән бергә — сиңа йөрәктә алып кайтам.

Язасы сүзләрнең күп булуына, әдәбият мәсьәләләре буенча бередә фикер алышыр кешем юклыгы, 6 елдан бирле, гомумән, ана телендә сөйләшер кешегә очрый алмавым кебек якларның да катнашы бардыр.

Әгәр миңа: «Нинди ихтыяҗың бар, сиңа беренче буларак ни кирәк?»— дисәләр:

— Яхшы шигырь кирәк!.. Җан азыгы булырлык шигырь укыйсым килә!— дияр идем. Мин шул «озын» еллар эчендә бары берничә генә яхшы, чын мәгънәсендәге яхшы шигырьләргә очрадым.

Аларның берсе — син аны юрый алмассыңдыр — М. Максуд шигыре! Сугышның Кырымнан китүе күренешләрен чагылдырган шигырь. Күптән инде, лагерьларның берсендә, үтеп барышлый гына күздән кичергән идем. Сугыш чорындагы шигырьләребезнең иң яхшысы тойгысын калдырган иде.

Бу язда Җәлилнең ике томы килде. Моабит дәфтәрләрендәгеләрнең күпчелеге — җан азыгы. Безнең кечкенә Җәлил нинди зур үскән ул шигырьләрдә!

Безнең поэзиядә әле тагын нинди югары сыйфатлы алмазлар бардыр! Мин өйдә түгел, чорымдагы әдәбиятыбызның 5 процентын гына да күздән кичерә алганым юк әле минем. О, алда мине нинди зур шатлык көтә: менә зур, матурлыгы белән зур парк-бакча. Анда безнең туган җирнең бөтен агачлары, куаклары, чәчкәләре, гөлләре бар.

Мин анда 16 елдан бирле булганым юк. Менә шул озын чордан соң аның эченә керәм! Анда миңа танышлар калган иде. О, алар ничек зурайган, үскәннәр инде! Менә бу төштә проза туйралары, проза элмәләре, карамалары һәм юкәләре үсә иде. Туйралар инде имәндер, алар инде үскәндер. Ә бу төштә шигырь каеннары-усаклары, алмагачлары, сәрвиләре, сиреньнәре һәм шомыртлары калган иде. Алар инде ничек күкрәп чәчәк атадыр. Ә бу якта тәнкыйть, сатира-юмор миләшләре, баланнары һәм өрәңгеләре дә тамыр җәйгән иде. Алар инде ничек ныгайгандыр!

Ә яңалар!.. Мин кайтып күрә алмый йөргән чакта күтәрелеп үсеп чыккан, әле мин күрмәгән яшьләр-яңалар!

Минем, билгеле, аларның барын берьюлы кочаклыйсым килер, һәм трибуналлар аша үткәндә корычланган күңел бәлки йомшарыр... Ә ни өчен соң шундый озак күрми тордым мин сезне, туганнар!.. Һәм, бәлки, җырлыйсы килер минем.

*...Дөньяның мин күрдем урманнарын,*
*Далаларын, чүлен, Себерен...*
*Тик күрмәдем, Илем,*
*Күрмәдем мин җирнең синнән бүтән*
*Сагынмаска мөмкин түгелен!*
*Кимсетмәде мине, читләмәде*
*Җир йөзенең һичбер имәне...*
*Тик берсе дә миңа сезнең кебек,*
*Улым! Бәгърем! Бәбекәм!— димәде.*
*Карагаен күрдем тайгаларның,*
*Усакларын күрдем Усаның...*
*Тик синең күк сагындырганны мин*
*Күрмәдем бер илдә, күрмәдем бер җирдә,*
*Күрмәдем бер кайда, Усагым!*

*Каеннар бар бөтен урманнарда,*
*Каеннар бар бөтен кырларда...*
*Бер кайда юк ләкин сездән битәр*
*Сагындырган каен, бер кайда!*
*Кайда барсам, гөлләр үз итәләр,*
*Ят кеше бу — брамат — димиләр.*
*Тик сезнең күк алар җылы итеп:*
*— И абыкаем минем, браматым,*
*Җанкисәгем, дия белмиләр!..*
*Арыды инде сезне сагынып йөрәк,*
*Арыды инде газиз башкаем,—*
*Яшел шәлең белән куләгәләп,*
*Яла иттер бер, сеңлем Аккаен.*

Шактый кырысланган күңел, әле моннан берничә еллар элек кенә, Алексей Максимовичның (Горькийның) чиксез йомшак күңеллелегенә нигә инде шул тикле йомшак!— дигән төстә, елмаебрак карый идем. Да, Минский

*...Бу чиге юк озын мәңгелектә*
*Бер генә кат яшибез ләса!*

Парк-бакча турындагыларымда иллюзия дә шактыйдыр, бәлки. Ләкин, беләм, яшьләргә карата реаль ягы да аз түгел.

Өйрәнү яки өйрәтелү белән генә беркайчан да һәм беркем дә,—әгәр анда талант дигән потенциал юк икән,— яхшы (кирәкле) оста, әдәбият-сәнгать остасы була алмый. Әгәр дә берәүдә әдәбият-сәнгать эше өчен кирәк булган потенциаль көч — талант — чынлап та бар икән[1], бу аның, әле бөтенләй йөри белмәгән беренче адымнарында ук ачык, хәтта ап-ачык сизелә.

Әйтик, менә бер кытыршы шигырь, күпчелек өчен анда, аны уку азабыннан, бер нәрсә дә юк кебек. Әгәр ул «шигъри» иҗат потенциалы бар кеше тарафыннан тудырылган икән — ул потенциал кайбер кисәгендә генә булса да чагылмыйча кала алмый. Тик аны күрә белергә генә кирәк.

1939 елда бугай Башкортстанның бер шигыре очрады. Бригадир, кыяр һәм башкалар турында. Авторы — Мостай (бу исем колакка кергәне бар, тик укыганым юк иде). Шул шигырь кисәгендә ап-ачык бәрелеп тора: бу — язачак! Башыннан сөясе, «әйдә, икеләнмичә әйдә!» дип хат язасы килгән иде. Шуннан бирле аны бүтән укыганым юк иде. Үткән ел рус әдәбиятында кайбер (тәрҗемәдәге) әйберләрен күрдем. Алар минем ялгышмаганымны (боже мой, нинди озын сүз!) раслыйлар.

Безнең поэзиядә дә шундый хәлгә юлыктым. Моннан дүрт еллар элек «Совет әдәбияты»ның 1949—51 еллардагы берничә санын кулга төшергән идем. Анда мине бик нык кызыксындырган яңа исемнәр — Ә. Давыдов, С. Шакир, З. Мансур һәм тагы берничә шактый өметлеләр бар иде.

Ә. Давыдов «Безнең авыл» һәм «Москвада»сында ирекле шигырьгә тәҗрибә ясый. Ритм — кытыршы. Ләкин бу шигырьләрдәге оригинал поэтик фикерләр, тойгылар эчендә, һичшиксез, шагыйрь, ерак бара алачак шагыйрь барлыгы ачык күренеп тора иде. Раз, шундый матур (шигъри) уйлый белә, димәк, кытыршылыкларны җиңәчәк: шул ритмик тәҗрибаләр дә ул шагыйрьгә лазим булган музыкаль сизгерлеге яхшы икәне чагылып тора.

С. Шакир һәм З. Мансур да шундый ук — талантлы яшьләр дигән — шатлыклы эзләр калдырганнар иде.

Алар өчесе дә шул беренче адымнарында ук инде, үз тавышлары (үзенчәлекләре) булачакны сиздерә иделәр. Шуннан бирле аларга — шигырьләренә очрый алганым юк.

Тик, күптән түгел, «Сов. Татарстаны»ның миңа килеп җитә алган кайбер саннарының берсендә З. Мансур белән күрештем, аның «Ташчы егет хикаясе» белән. Үскән, шельма, да еще ничек үскән! Менә бу — җан азыгы! Ачыккан саен укырга була: укып туймаслык! Эчталекне чын шигырь халендә чагылдыруга ирешкән. Эчталек белән форманы шулкадәр матур берләштергән ки, гадәттә 4 юллы булырга тиешле строфага тагын бер рифмаланмаган юл өсти. Бу юлның артыклыгы (гадәттәгедән) һәм хәтта рифмасызлыгы, кыскасы, бу юлның барлыгы бөтенләй сизелми.

[1] Бу — тумыштан мәгънәсендә түгел, ә тормыштан — алдагы буыннарның тормышта тапкан үсешләренең дәвамы мәгънәсендә алына (Туфан искәрмәсе).

ягъни уңайсызлатмый. Эчтәлекнең — мәгънәнең логик агышы өчен нәкъ шулай кирәк булып тоела!

*Янда Ленин бар —*
*Какшамас көч бар.*
*Бар, димәк, анда*
*Туганнар, дуслар —*
*Терәк бар, димәк.*

Яхшы, бик яхшы!

«Сов. Тат» да өметле яшьләрнең (миңа бар да — үзләрен күргән юк — яшьләрдер булып тоелалар) берсе булып дияргә ярый бугай — Р. Гәрәйнең «Онытылмас көн»е бар. Шигырьдә, ничектер, Такташ авазы, Н. Баяндагыча түгел, ә яхшы мәгънәсендәге Такташ авазы ишетелә.

Жыйнак, ачык, шигъри әйтелгән урыннар аз түгел. Тик шигырьнең логикасы, төп фикере дөрес түгел: яшьлек, янәсе, ак каеннар яфрак ярганда түгел, ә райкомолда билет алганда гына канатлана. «Ак каеннар яфрак ярганда» дигән сүз бу шигырьдә шартлы мәгънәдә — бөтен органик табигать һәм аның белән бергә барлык нормаль кешеләрнең (кешелекнең) яз белән рухланган чагында мәгънәсендә алынган.

Ләкин шагыйрь оныта: ак каеннар өстендә тургайлар җыры бар. Бу җырның музыка шагыйре Глинка йөрәге аша дөньяга бүләк ителгән, хәтта ташны җанландыра алырлык варианты бар. Каеннар ягында даһи Бетховенның «Ай сонатасы» һәм бу сонатаның азмы тапкыр канатланып — җан җиме табып тыңлаган Ильич бар.

Ә усаклар яфрак ярганда яшьлек канатланмыймы!? Әгәр алар синең хыялыңда «шаулый-шаулый яфрак ярмасалар, карт имәннәр калмый синең арттан, кайда барсаң озата бармасалар» (райкомолга барганда да) мондый пролеткультча кысыр, коры яшьлекнең райкомол өчен, совет әдәбияты өчен беренче чиратта — кыйммәте дә шундый гына ласа! Бу шигырьдә (шулай язарга ярыймыни!) комсомоллар яшьлегенең, чын мәгънәсендәге комсомоллар яшьлегенең кешелек дөньясындагы иң гармоник, иң югары, бай, поэтик яшьлек икәне онытылган. Бәлки ул инде үзе дә мондый әйберне биргән көнне, шул шигырьне язган көнне оныту яхшырак икәнен төшенәдер.

«Сов. Татарстаны»ның берсендә Хуҗиның Җәлил турындагысыннан өзек бар. Бу аның мин 3—4 еллар элегрәк күздән кичергән ике шигырен искә төшерде: «Халисә», «Чын күңелдән...» Тирән дулкынлану белән, чынлап та, чын күңелдән язылганнар. Аның бу «Чын күңелдән»е миндә «Во весь голос» (Маяковский) тудыра ала торган тәэсирне калдырды (тудырды). Үз сүзе белән әйткәндә, үзен безнең поэзиянең рядовое итеп санаган Хуҗиебыз тыйнак адымнар, артка чикми торган кырыс адымнар белән генераллыкка табан бара.

Җәлилгә багышланганында үзгәртергә, тулыландырылырга тиешле урыннар бар. Шуларның берсе — Җәлил образының кайбер фактик дөреслеген бирүдә: шигырьдә Мусаның күзенә яшь килү турында әйтелә. Беренчедән, бу фактик дөрес түгел: үлемгә хөкем ителгән кеше,— әгәр ул аны теләгән тәкъдирдә дә,— җылый алмый, аның җаны инде берниндн югары температурада да эреми торган металлга әверелгән була. Җылау, гомумән, атылу алдындагы истерика — типик булмаган вак җанлы, куркакларда гына очравы мөмкин. Икенчедән, Җәлилнең кичереше, үлем көткәндәге хәле, күзгә яшь килүгә караганда мең кат авыррак булырга тиеш, бу фактик шулай. Шул хәлгә күз яше кертү — аның типиклыгын боза. Җәлилнең страшно көчле, водород бомбасы кебек искиткеч көчле шигырьләренең берсендә — «Алман иләндә» шигырендә — аның бу типик кичерешләре бөтен тулылыгы, трагик көчлелеге белән чагыла. Җәлил инде бу чорда, нормаль кешегә хас булган барлык яхшы сыйфатлардан сөю, сагыну, юксынулардан бик күп югары күтәрелгән — геройлыкка хас типик сыйфатларга күтәрелгән. Кыскасы, — бу «кыскасы»ны Җәлил үзе әйтә:

*— Кая соң сез, Гейне һәм Марксны*
*Тыңлап үскән батыр егетләр!?*
*Вильгельм Телль, Энгельс кебекләр?*
*Арагызда кем бар Цеткин улы?*
*Тельман егетләре кайсыгыз?*
*Төрмәләрне безнең ачыгыз!*

Теле генә дә ни тора моның! Төрмәләр ачылгач та әле Җәлил сагынулар, өйгә кайтулар турында түгел, ә:

*...Күтәрелсен Тельман трибунага,*
*Маркс, Гейне кайтсын иленә!*

— не эшкә ашыру турында уйлаячак. Менә типик Җәлил образы шунда.

Хуҗиның ул өзегендә шуны тулыландыра торган яхшы яклар аз түгел.

Җәлил безнең поэзияне бөтен дөнья күләмендәге мәйданга алып бара. Шул мәйданны искә алып, аның шигырьләреннән рус һәм татар телләрендә җыйнак, сыйфатка юмарт, санга саран сайланма җыентыгын чыгарырга кирәк иде.

С. Батталның «Олы юл буйлап» поэмасын укыган идем. Бу — чынлап та Батталныкы.

Безнең поэзия өлкәсе (прозада да шулайдыр ул, бәлки) учет эшләре рәтләнеп җитмәгән хуҗалыкны хәтерләтә иде (хәзергесен белмим). Менә Баттал. Оригиналь шагыйрь. Байтак шигырьләр астына теләсәң кайсы уртакул (урта дәрәҗә) имзаны куярга мөмкин. Ә Баттал шигыре астына — бары Батталны гына: аның һәр, хәтта вак шигыре Батталныкы икәнен кычкырып тора.

Ә безнең поэзия хуҗалыгында үзен табып җиткерә алмаган Батталга, аны табышырга ярдәм, тиешенчә ярдәм ителгәне юк бугай әле. Баттал үзендә (шигырьдә) ике капма-каршылыкны: гүзәллек һәм дорфалык, ягымлы елмаю һәм кырыслыкны берләштерә. Ул шигырьдә — аю!— Ләкин барабан һәм контрабастта түгел, ә скрипкада һәм флейтада уйный белүче аю. Фикерләре мәкаль, афоризм кебек шома, пөхтә, ә әйтелеше кытыршы, чатак.

Еракта еракта, Минский, мин менә шундый уйлар, сагынулар эчендә яшим. Бәлки анда — Казанда — мин уйлаганнан бик күп мәртәбәләр яхшыдыр безнең туган өлкәбез булган әдәбият. Шулай булсын иде!

Алда нинди матур көннәр: аерылып тору никадәр озын һәм авыр булса, күрешү шулкадәр зур һәм матур — кызык.

Артык авыр сәгатьләрдә «нигә бер ярты гасыр соңрак тумадым икән» дигән чакларым булды. Ә чынында, безнең бу — кабатланмас чорның — дөресе, гасырның — тарихта беркайчан да булмаган бөек вакыйгаларга бай, титан гасырның бер яшәүчесе (жителе), шаһиты һәм солдаты булуымны чиктән тыш зур бәхетем итеп исәплим. Моны, бәлки, түбәндәгеләр тулырак итеп әйтә алырлар:

*...Байракларда — кырлар, гөлләр исе,*
*Киемнәрдә — поход тузаны...*
*Сугышларын, давылларын кичеп*
*Үтеп киттек иске дөньяны.*
*Туры килде безгә көн итәргә*
*Кешелекнең олы юлында.*
*Халыкларны бәхет илләренә*
*Алып килгән ирләр чорында.*
*Бу еллары, ахры, юлыбызның*
*Истә калыр күпкә, озакка.*
*Кайтасыбыз килер күбебезнең*
*Киләчәктән, бәлки, бу чакка.*
*Кайтарасы, бәлки, кардәшләрем,*
*Кабатлыйсы килер бер көнне,—*
*Яшь гомернең зәңгәр чәчәкләрен*
*Кабатлыйсы килгән шикелле!*
*Илтмәсә дә безне бу көннәргә*
*Тагын бер кат юллар яңадан:*
*Без төзегән бөек һәйкәлләрдән*
*Йөрәкләргә күчеп бу заман*
*Ашкындырыр тыныч походларга*
*Безне дәвам итүчеләрне!*
*Бу гасырның аргы якларына*
*Бездән сәлам илтүчеләрне!*
(«Киләчәккә китеп барышлый»дан)

*Нигә шулай ашыгасың, йөрәк?*
*Юлны күбрәк үтәр өченме?*
*Киләчәккә җитәр өченме?*
*Бөек көннәр ягына күз төбәп*
*Кайда шулай ашыга соң йөрәк?*
*Бәлки аның гомере кыскадыр...*
*Ашкынадыр алгы көннәргә...*
*Ул баш куйган зәңгәр гөлләргә*
*Кара елан, бәлки, поскандыр.*
*Бәлки аның гомере кыскадыр.*
*Кара, күзем, түйганчы кара:*

*Һәрбер көннең — аерым төсе бар! —*
*Һәрбер көннең — алтын эзе бар! —*
*Һәр яңа көн — бүтәнчә яңа!*
*Кара, күзем, туйганчы кара!*
*Мәңгелекнең шушы төшендә*
*Аерым төстә балкып һәр иртә*
*Алтын эзләр калдырып китә*
*Безнең бөек юлыбыз өстендә,—*
*Мәңгелекнең шушы төшендә.*

*Җилләрендә аның гөлләр исе,*
*Гөлләрендә — Кешегә сәламе.*
*Матдә монда кеше хәленә ирешеп,*
*Дәвам итә үсүдә һаман.*
*Матдәдәге мәңге үзгәрешнең*
*Алга китү чиксезлегендә,*
*Яшәү, Җирдә килеп җитте инде*
*Коммунистлык биеклегенә.*
*Матдә үзенең чиксез биеклеген*
*Бездә — җиргә яңа ашыра!*
*Нинди артта Җирдән Кояш меңкен,*
*Нинди ярлы бу җир каршында!*
*Бу материя күтәрелде җирдә*
*Безнең Җәлил батырлыгына*
*Һәм аларны дарга алып килгән*
*Фидаилык матурлыгына!*
*Мәңгелекнең берәр кояшының*
*Безнең җир күк бүтән җирендә,*
*Егерменче гасырын җир шарының*
*Күптән үткән берәр илендә,*
*Бер матдәдән туган туганнарым*
*Безнең җирне күзәтәләрдер,*
*Безнең туган илләр турындагы*
*Карталарын төзәтәләрдер.*
*Вак кварталлар бер-бер гаиб булды*
*Яшел зона — тоташ бер тигез...*

*Төн ягында яңа канал туды...*
*Уртадарак — яңа бер диңгез...*
*Телескоплар янындасыңдыр син,*
*Бер матдәдән туган туганым?*
*Ничек итеп, ничек тапшырыйм мин*
*Сәламнәрен сиңа бу җанның?..*
*Галилейча үтеп гомер юлын,*
*Хәйямнардан — Ленинга таба,*
*Минем җаным кайнар сәлам булып*
*Кешелеккә кушылып кала.*

Җитәрдер, пожалуй, аргансыңдыр инде, син боларны укый-укый. (уртаклашасы килә бит). Болар белән сиңа әйтергә теләгәнем. Минский: «... матур да соң тормыш! О, нинди бөек эш бу — яшәү! Яратам, үлеп яратам тормышны! Кайчан миңа расстрелның 10 ел белән алмаштырылганын укыдылар... минем аша гүя яшәү-тормыш үзе кычкырды:

— Хет 100 ел! — бары яшим генә!

Рәхмәт аңа — тормышка: диамат белән коралланган хәлдә уйларга гына түгел, хәтта хис итәргә дә өйрәтте. Һәм тормыш үзе моны, үзенең кешедәге бу сыйфатны, әллә ничә тапкыр инде раслады. Икенче сугышны бездә Көнчыгыштан көтәләр иде. 1936 елда мин аны (безгә каршы) Көнбатыштан башланачагын язган идем (Г. Иделле төзегән әдәби очерклар альманахында. Типографиядә өлгергән булса да, чыкмый калды). Ун елдан бирле инде... Икенче бөтендөнья сугышының җир йөзендәге зур сугышларның соңгысы икәне турындагы фикердә мин: капитализм (хәзерге империализм) Өченче сугышка чыгарга соңга калды инде (Кореядагы маташулары да шуны күрсәтте).

Такташ әйтмешли, бер генә көнгә миңа Министрлар Советын бирсеннәр иде. Беренче эшем буларак, Җир йөзендә яшәүче Кеше туганнарыма, Өченче сугышның булмаячагын һәм барлык кораллы көчләрне тыныч хезмәткә кайтарачагым турында кычкырыр идем. Ә менә шул диалектик хакыйкатьне шигырьдә, әйтик, әйтеп кара! Нинди катлаулы ул — тормыш!

2-3 еллар элек «Правда» Американың элекке 3 кат президенты Гуверның бер чыгышын урнаштырган иде. Кыскартып алганда, беләсең, ул нәрсә ди: «Коммунизм ягының (ул реаль термин куллана) 800.000.000 халкы бар. Коммунизм ничә дивизия, коры җир армиясе хәзерли ала?! Ә без барыбыз бергә аның яртысын да хәзерли алмыйбыз. Коммунизмны бары корыдан гына алып була. Ә без бу армиябез белән корыдан керә алмыйбыз. Коммунизм безне ватачак. Димәк, аны алу (юк итү) мөмкин түгел. Безнең Европа эшләренә катнашуыбыз (Маршалл планы) чепуха. Күрдегез, Кытайда ничә миллиард доллардан колак кактык! Юл бер генә: изоляция. Тын һәм Атлантик океаннарында коммунизмнан оборона сызыгы төзү, Американы күпмегә булса да коммунизмнан крепостьлау».

Бу ата капиталист үзенең бу зирәк сүзләре белән, минем аларны укудан байтак еллар элек сызгаланып куелган фикерләрне раслады. Аның белән бер (коммунизмны җиңү мөмкин түгел) фикердә булуымнан аз гына да ятсынмыйм.

*Бөтен юллар Римга илтә иде*
*Цицероннар исән чакларда.*
*Римнар хәзер сәфәр итә инде*
*Ал байраклар дәшкән якларга!*
*Кыргый чорын үзенең, коллык чорын,*
*Феодолизм чорын уздырып,*
*Пентагонның «Зигфрид сызыкларын»,*
*Доллар зоналарын туздырып,*
*Тормыш кила, барлык юллар буйлап,*
*Римга түгел, безнең кырларга!*
*Ерак түгел моннан, юлдашларым,*
*Ерак түгел тыныч елларга!*
*Кырыс сафлар җыя яңа Спартак,*
*Теге Спартак ауган җирләрдә.*
*Мөмкин түгел инде икенче кат,*
*Мөмкин түгел аны җиңәргә!*
*Океандагы, утрау җирләрдәге,*
*Крепостьланган капитал иле:*
*Котылгысыз ярык җилкәндәге*
*Коткаргысыз «капитан» инде!*
*Җырлап тормыш үзенең яшьлек җырын,*
*Ничек гуман җимерә барын,*
*Империализмның фашистлыгын*
*Һәм фашистлык империяларын!*
*Идея белән яулап ала тормыш*
*Һәр Парижны, һәр баш шәһәрне!*

*Котылгысыз кырыс язмышыңны*
*Мә, рәхим ит, Молох әфәнде!*
*Бәлки алтын синең таянычтыр,*
*Бәлки атом синең яклыдыр?..*
*Эт күк, бәлки, әрсез сакчысыдыр?*
*Сары шайтан булып сине алтын*
*Һәлакәткә этәрмимени?!*
*Кешелекнең бөтен ачуын атом*
*Сиңа каршы күтәрмимени!?*
*Кем сүндерә ала бу ачуны:*
*Базың? Чумаң? Танкың? Тупларың?*
*Таверналарыңда буталучы*
*Сукбайлардан төзегән полкларың?!*
*Тарих көтә*
*Дөньяң түбәсенә*
*Яшь байракчы менәсе көнне,—*
*Менәр! Элер!— Берлин гөмбәзенә*
*Кызыл байрак элгән шикелле!*
*Әй, мамонтлар, мастодонтлар сыман,*
*Җирдә нәселе бетәсе нәсел! —*
*Коммунизм алмый кала торган*
*Ныгытмалар бармыни хәзер!?*

Авторитет кечкенә безнең Минский. Рус теле аркылы башка халыкларга да барасы иде. Бер иң актуаль һәм иң чатак мәсьәлә. Тукай һәм Такташның русчаларын күздән кичергән идем. Тукай да юк анда. Такташ та юк. Хәтта рус иптәшләр арасында «Болар безнең классиклар» дип әйтергә ояласың. Гүяки аларның бөтен ароматлары җилгә очырылып, бөтен яктылары сүндерелеп, бөтен матурлыклары иләнеп, тәрҗемәгә кертелми калдырылганнар.

Нигә бу шулай? Чөнки тәрҗемәчеләр оригиналның үзенчәлекләрен тота алмаганнар. Нилектән? Чөнки оригиналның телен белмиләр. Әйтик, менә югарыдагы (31 биттәге) шигырьнең подстрочник хәлендәге эчтәлеген кулына алган тәрҗемәче иптәшкә булышырга телим ди: стих — жаркий ключ души от всего сердца, трибунный, ритм — стремительный, компактный, язык — сугубо лаконичный, суровый и т. д. Әгәр дә ул иптәш татар телен белми (бәс оригиналның рухын тотып ала алмый) икән, барыбер шул Тукайлар тәрҗемәсенә охшаган нәрсә генә мәйданга киләчәк.

Безнең бу тәрҗемә өлкәсенә, Г. Мөхәммәтшинның «Правда» да басылган шигырьләрен тәрҗемә итүдә зур уңышка ирешкән Евгения Гинзбург кирәк. Ул татарча белүенә үзенең тәрҗемәчелек талантын да өстәп, оригиналның рухын, барлык үзенчәлекле байлыгын тулысынча тотып ала белә иде. Менә шул апа безнең шагыйрьләр өчен иң кирәк кеше. Табарга, әгәр ул исән кала алган булса, кайтару чарасын күрергә кирәк иде.

Белмим, Галим Мөхәммәтшин бармы, юкмы? Аны да беренче чиратта кайгыртасы иде: разве ул халык алмазының үз иле алдында гаепле булуы мөмкин!?

Нигә мин шулай сиңа бөтенләй читкә китеп, хат жанрына керми торган нәрсәләр турында язам? Такташны, Кутуйны, Гомәр Галине эзлим, киңәшер кешемне эзлим!

Бу хатка җае чыккан саен шигырьләрдән өзекләр кертүемне дә шулай аңла син. Мин кайтуга киңәшләрең әзерләнә торсын өчен шулай итәм. Бу — бүтенге Казан кыйбласын ачыкларга теләвем. Минем билгеле шартлы хакыйкатька (относит. истинага) ияреп кенә түгел, ә тормыш законнары буенча абсолют хакыйкать ягын күрсәтә торган «Компасым» бар-барын. Тик, ансыз да туры юлда ласа мин, дигән ышаныч, «Компас»ка карап торуны күбесенчә кирәксез итеп саный. Күптәнме без «кыйбла» итеп йөзне шәхес культы ягына юнәлдергән идек.

Кайбер классик бабайларга күз саласың да шаккатасың: аларның бишәр гасыр, унар гасыр алдан күрә алган бөекләре бар.

XX съезд билгеләгән алдагы юл миңа бөек бер поэма, эпос сыман булып тоела. «Образлы итеп әйтсәк,— ди ип. Хрущев,— без инде коммунистик җәмгыятька бару юлында киң горизонтлар ачык күренә торган биеклеккә күтәрелдек»...

Гүяки XX съезд трибунасында безнең Такташ та бар:

*Башларыннан инде сез яшагән*
*Коммунизм кыры күренә!..*

Мокамайның (Такташның) бөеклеген күрсәтә торган тагын бер актуаль факт, сер рәвешендәге факт бар. Әгәр ул факт бу көннәрдән 3-4 еллар элек (Берияләр исән чорда) сер булуын югалткан булса, Такташ бары халык күңелендә генә исән калган булыр иде. Мин ул серне, моннан 20 еллар элек минем белән уртаклашкан бер

дусыбызның киңәше һәм рөхсәтенә кадәр, ябык хәлдә калдырам. Бәлки ул иптәш исәндер, исән калгандыр, бәлки ул Такташ образы алдында:

*Җаным белән ышыклап алып чыктым*
*Һәлакәтләр аша мин сине,*

— дип үзе әйтә алыр.

Язучының миссиясе сафта, сафның алдынгы сызыгында бару гынамы? Алай гына түгел: сафны — аның разведчигы хәлендә диимме,— алдан каршыларга да кирәк ич?! Әллә кирәкмиме?

Әйтик менә, Өченче сугышка каршылык идеясе безнең өчен, коммунизмның Җир шары күләмендәге хаклы тантанасы өчен кирәк, бик кирәк. Әле коммунизм илләре ягына керeп җитмәгән халыкларны турыдан-туры өндәү көне иртә әле. Без алар йөрәгенә сугышка каршылык идеяләре аша керәбез. Коммунизм идеясен алып керәбез. Капитализмның яңа сугыш турындагы лыгырдавын актуаль нәрсә итеп алабыз. Бу — бер чара. Ә бу чараны безнең максатыбыз һәм гуманизм, йола, аралый, билгеле.

Ә бит мин Җир йөзе тормышыннан (ул инде үзенең диалектик үсеше юлында мәңгелекнең менә шушы төшенә — XX гасыр уртасы дигән төшенә килеп җиткән тормышның) бер кешесе, бер шагыйре ласа! Уйлый торган матдәнең (материянең) — кешелекнең һәм аның тормышының инде кайда җиткән һәм иртәгә кайда булачагын, аның реаль хәлен ачык күрә алмасам, тотынып, иярeп кенә барсам (бу бик җиңел), минем кыйммәтем дә шундый гына ласа! Ә реаль хәл сызыгында тору — җаваплы һәм авыр. Диаматны белеп җиткермәгәндә уңай иде,— әзергә хәзер буларак рифмала да рифмала!

Ә минем җан — акыл, алдан каршылауга килгәндә, күбрәк, ераграк, алгарак та чыга. Нишләтим соң мин ул хәерсезне!

Нәкъ шунда сине Гегель сагалап та ята, ә аның артынды сине, цитатачы-догматчылар көтеп утыра. Гегель ягында ук иканең күрү белән, ике арада һичбер берләшә, кушыла алмый торган ара барлыгын шәйләп-нитеп тормыйча, «Фаш» итү бәхетен көтеп яталар: «Караул! Идеализмга керде!» янәсе.

Сезне — үзеңне һәм Сәлимәне[1] — искә алып, сагынып гомер кичердем. Сезнең йөрәгегездә җанны җылытыр урын барлыгына ышанып яшәдем. Синең бу хатың миңа шул җылыларны алып килде.

Минем сезне котлыйсым, рәхмәтлисем килә. Ни өчен? — Сез икегез дә табигатьтәнме, тормыштанмы, нәселдәнме (дәресләрен әзләргә иренгәнгә шулай күп сүзләр белән әйтәм) кайсыннандыр, бәлки барысыннан бергәдер,— дөньяга матур җан, матур йөрәк, алып килгән өчен!

Бәлки мин бераз эгоистмындыр да: мине — югалтылган кешене, югалтмаганнарның йөрәкләрендә сакланган эзләр буенча гына күз алдына китерә алган яшьләр (Гөлүс[2] һәм аның яшьтәшләре) каршында горурлана алам: күрәсез, минем якыннарым, дусларым, юлдашларым нинди кабатланмас әйбәт кешеләр!

Кадерле хатларны укуда мин уйланылмаганча эш итәм: хатны уку бәхетен озынайту өчен (дөр бу бәлки) беренче ноктагача укыйм да, торып китеп йөренәм, уйланам. Алдагы (әле укылмаган) җөмләнең эчтәлеге турында юранам. Шул арадагы кайбер кичерешләрнең эзен дәфтәргә төшерәм.

Шул рәвештә хат гүяки искиткеч бер мавыктыргыч әсәргә, сюжетлы әсәргә әверелә. Хатыңның беренче җөмләсе: саумы, брамат!

Таныш аваз — Мокамай (Такташ) авазы! Мин менә яңадан безнең күтәренке, язлы, тирән дуслыклы, гадилеге белән биек (Такташка карата әйткәндә биек кенә түгел, ә бөек тә булган) яшьлегебезнең давыллы, дискуссияле, хәтта тантаналы әдәби кичәләре уртасында! Шул кичәләр арасындагы җылы очрашулар, укышулар, киңәшүләр өстәле әйләнәсендәге юлдашларым, чордашларым янында!

Берничә минут эчендә гүя бер тулы роман аша үтеп чыгып, соңгы күрешүләргә — Бакудан килгәнендәге очрашуларга барып җиттем.

Әгәр син, Минский, (миндә син, ничектер, исемең белән түгел, фамилияң белән яшисең) шул беренче җөмлә астына кул куеп, хатыңны шул ике сүз белән генә тәмамлаган булсаң да,— (мин моны шаярусыз әйтәм) барыбер синнән зур, тулы бер хат килгән итеп хис кыла алган булыр идем! Син бит бу урында, гадәттәгечә, әйтик, кадерле Туфан, дию белән генә дә чикләнә алган булыр идең — һәм бу сүз миңа әле бер нәрсә дә әйтә алмаган булыр иде. Менә бу — безгә кирәк нәрсәне тагын бер кат раслый: шаблон ничек көчсез! Оригинал — ничек бай! Ә оригинал ул

---

[1] Сәлимә — Г. Минскийның хатыны.
[2] Гөлүс, Гуля — Х. Туфанның кызы.

уйламаганда, экспромт рәвешендә, туачак бөтеннең лейтмотив хәлендәге бер кисәге булып туа. Безнең — иҗат көче дигән нәрсәбез аны уйлап тормыйча, тота да, гүя көйнең төп, нигез аккордын игълан итә, яңа әсәргә юл ачып җибәрә. Кайбер вакытта ул аккорд хәлендә генә калмыйча, шул ук вакытта бер бөтен халгә килә. («Козырь туз» зур шигырь язып утырганда, кайдандыр килеп чыгып, берничә минут эчендә, эш арасында туган иде).

Хәтерлисеңдер Такташны: минә аның «борын салынган» чоры кинәт юкка чыккан. Ул күтәренке, уйный, шаяра, шаркылдый. Бүлмәләргә, урамнарга сыймый йөри. Димәк, тиздән дөньяга яңа бер шигырь киләчәк. Ул инде иң якыннары белән уртаклаша: туасы шигырьнең кайсыдыр бер төшеннән (бер вакытта да мин аның беренче строфасыннан башлаган чагына очрамадым) күбесенчә уртасыннан, кинәт туган аккорд хәлендәге бер-ике юлын яки строфасын укый (күңелдән, кәгазьсез), уртаклаша, киңәшә. Аның шул беренче юллары гына да безне канатландыра, шатландыра һәм безнең бу хәл аның үзен ныгыта, рухландыра иде.

Такташ белә иде: бу чакта коры башлар, цитатчылар белән уртаклашырга ярамый: алар шигырьне туганчы ук ботарлый башлаячаклар, буачаклар. Ике-өч көн шул күтәренкелек белән йөргәннән соң, Такташ инде язарга утыра.

Исеңдәдер, аның һәрбер яңа шигыре ул чордагы Казан әдәби тормышында матур бер вакыйга хәленә әверелә иде.

Тагын шундый бәхетле хәлләр кабатланса, яңа Такташлар туса иде!

Син минем күз алдымда һаман шул яшьлек көнебездәге образыңда басып торасың: төз, чандыр, җиңел хәрәкәтле егет, пальто, кепка (кыш), ак туфлидә. Ачык, ярым елмаюлы йөздә — тыйнак, җитди акыл чагыла.

Син безгә безнең сәнгать-әдәбият өлкәсенең кадрларга уңышлы үсә торган төбәгеннән — Оренбург-Әстерхан төбәгеннән килдең.

Без сине оныталмадык: безнең әдәби гаиләнеке, безнең туган, безнең юлдаш икәнеңне бер караштан, ярты сүздән хис иттек (ә бу ерак көннәр, кабатланмас көннәрдәге хәл, әйтерсең, әле дәвам итә. Гүлянең сине һәм Салимәне беренче тапкыр күргәндәге хәле — шул ук — беренче караштан тану түгелмени? Бу бит, Минский, мин — Туфан, Гүлядә дәвам иткән Туфан!)

Әгәр берәүне безнең кадерле сизгеребез Такташ кулы оценить иткән икән, әдәби «булгариннарның»[1] — Такташлы чор телендәге шартлы мәгънәсендә әйткәндә — тугыз кат мосагыйдерәге[2] дә бу туганлык хисен сүндерә һәм үтерә алмый иде. Һәм, күрәсең, заман шаһит — сүндерә алмады.

Син бәхетле: халыкның үзе белән бергә сугышта булгансың. Мин була алмадым. Берничә кат сорап та карадым, җавапсыз калды.

Ахырда бу «тылсымлы (заколдован) божра»дан чыгар өчен, калган 6 елга якын срокны ихтыярлы (добровольный) үлем белән алмаштыруны сорап яздым (башкарган вакытта үлми калу һич мөмкин булмаган берәр иң мөһим хәрби яки фәнни-гыйльми заданиене — идарә ителә торган торпедада яки аэростат, ракета һ. б. үтәү эшенә җибәрүне). Җавап килмәде:

— «Тормыштан отыш белән, яхшы исем белән китәргә телисең? Без сине каралабызын...

дык, шул кара көеңдә кал: синең аклану — безне гаепләү булачак» дип уйладылар. Аларның кемнәр икәне ул чорда ачык түгел иде әле (Хатның дәвамы). Бу бит буш калган. 45 нче биттән бирегә күчтем. Язып бетерә алмадым әле, Минский. Хәзергә шунда өзәм, дәвамын икенче хатка калдырам. Бусы бара торсын. Мине бик кызыктырган яңа бер шигырьгә тарыдым. Ул башны тагын хаттан аерды.

Мин инде 1 нче июньнән бирле колхоздагы эш белән саубуллашкан хәлдә, тик үз эшләрем белән генә вакыт үткәрәм.

Июньнең 10 нарында юлга чыгарга тиеш идем. Ләкин Покровка көтмәгәндә карантинга дучар булды. Чума. Хайваннарда (дуңгыз фермасы кырыла). Кеше өчен куркынычлы түгел. Карантин җитди, кырыс: чуманы Покровкадан чыгармау чарасы күрелә. Район гына түгел, область та катнаша. Мәсьәләнең иң читен ягы — Гүләне ничек тынычландырырга? Белмим. Исәнлек яхшы. Ферманың һәлакәте күңелсез, кызганыч, тик төшенкелеккә бирелмибез. Үлем камерасындагыча. Аерма тик шунда: без бүтән кешеләр — совет кешеләре, теләкләр-идеяләр бүтән. Үзеңә һәм Салимәгә сәлам, билгеле. Саф, сау, чумасыз сәлам белән Туфан.

*18.VI.56.*

[1] Булгарин — XIX гасыр рус язучысы, реакцион рухы белән дан алган шәхес.
[2] Ф. Мосагыйть — татар танкыйтьчесе (30 еллар).

# ТЫРЫШЛЫК КАНАТЛАРЫНДА

## САИМӘ ИБРАҺИМОВАГА 60 ЯШЬ



Саимә Ибраһимова, язучылар сафына аяк басып, СССР Язучылар союзы членлыгына рәсми төстә кабул ителгәнче, гаять катлаулы хезмәт юлы үтә. Гомумән, аның һәм тормышындагы, һәм иҗатындагы җиңүләренең һәр карышы җаны-тәне белән бирелеп, тир түгеп яулап алынган. Безнең халыкта андый затлар турында, чәче белән җир себерә, дигән гыйбарә йөри. Саимә ханым — шундыйлар токымыннан.

Аның юлында, алтын баганалардай, фидакарь хезмәтенең нәтиҗәләре балкып утыра: авыл мәктәбендә рус теленә һәм инсафлыкка өйрәтелгән балалар, Татарстан китап нәшриятында дистәләгән авторларның редакцияләнгән әсәрләре, сугыштан соң кабат сафка бастырылган «Азат хатын» журналында башкарылган оештыру эшләре һәм төн йокламый язылган уннарча мәкалә-очерклар, «Яшь ленинчы» газетасын кабаттан чыгара башлау юлындагы бихисап мәшәкатьләрне җиңү һәм шул редакциядә чирек гасыр дәвамында төрле вазифаларны үтәү...

Саимә Ибраһимованың «Яшь ленинчы»дагы тырышлыгы, югары белемле педагог буларак, авыл мәктәпләрендә башкарган эшләренең җиңүчән дәвамы кебек. Монда ул бик күп нәни хәбәрчеләргә, яшь журналистларга һәм язучыларга остаз буларак та танылa. Редакциядә эшләп иҗат иткән яшьләр өчен Саимә Ибраһимованың күркәм сыйфатлары, эш алымнары, күпмедер дәрәҗәдә, өлге булмый калмагандыр. Һич югында, татар әдәби теленә кагылышлы бәхәсләр вакытында Саимә апаларының: «Әй, егетләр, болай булмый бит инде!» — дип куюын алар еш искә алалардыр.

Хезмәтенә соң дәрәҗәдәге таләпчәнлек, иҗадилык, туган тел белән мөнәсәбәттә саклык һәм төгәллек Саимә Ибраһимованың тәрҗемәләрендә бөтен тулылыгы белән гәүдәләнә. Күрәсең, төрле юнәлешләрдә алып барылган эш аеруча шушы максатка омтылган. Вак чишмә-инешләрнең киң сулы тирән елгага килеп чыгуы кебек.

Аның тәрҗемә итү алымындагы уңай яклар турында «Казан утлары» журналында моннан ун еллар элек (1976 ел, 4 нче сан) язылган да иде инде. Мәкаләнең авторы филология фәннәре докторы Г. Ахунҗанов Саимә Ибраһимова хезмәте турында: «...моны тәрҗемәдәге иҗадилыкның бер чагылышы итеп бәяләргә мөмкин,— дип белдерә.— С. Ибраһимова тәрҗемәсендә гамәлдәге сүзлекләребезгә теркәлмәгән күп кенә мәгънәләр... аерым алып тикшерелүне көтәләр...»

Үзенең тәрҗемәләре турында хуплаулар ишетелгән бу елларда ул әле язучылар сафына кабул ителмәгән иде. Алда әйтелгәнчә, хезмәт юлында яңа бер баскычка күтәрелгәнгә кадәр, ул иң әүвәл тау кадәре эш башкарырга өйрәнгән. Бу очракта да шул ук хәл. Союзга тәкъдим ителгәнче Саимә Ибраһимова дистәләрчә зур күләмле, жанры, тел һәм форма үзенчәлекләре ягыннан күп төрле әсәрләр тәрҗемә итте.

Бу хезмәте дә аның ике юнәлештә барды: татарчадан — русчага һәм русчадан татарчага тәрҗемәләде. Татар әдәбиятының кайбер үрнәкләре — рус һәм рус теле аша, башка милләт укучыларына да барып ирешүе өчен (Г. Бакир, А. Алиш, А. Әхмәт,

Д. Аппакова әсәрләре күздә тотыла) без Саимә Ибраһимова иҗатына да рәхмәтлебез.

Илленче еллар ахырыннан башлап ул, нигездә, русчадан тәрҗемәли. Монда аңа рус теле аша Көнбатыш Европа язучыларының әсәрләренә мөраҗәгать итү мөмкинлеге дә ачыла. Татар укучысы А. Зегерс, Р. Стивенсон, Я. Козак әсәрләрен, мәсәлән, аның тырышлыгы нәтиҗәсендә генә үз туган телендә укый алды. Рус язучыларыннан А. Чехов, М. Шагинян, А. Исбах, С. Григорьев һәм башкаларның әсәрләрен тәрҗемәләгәндә дә ул һәр сүзне энә күзеннән үткәрә. Әйтерсең лә туган телебезнең җимеш бакчасына тугрылыклы сакчы итеп куелган!

Әдәбиятыбызның шушы фидакарь затына инде 60 яшь тула. Бу бәйрәмен дә ул яңа иҗади эзләнүләр һәм табышлар белән каршылый, моңарчы тәрҗемә ителмәгән әсәрләрне мөмкин кадәр татарчарак иттереп укучыларга ирештерү теләгендә яна.

Саимә Ибраһимованың изге омтылышларында уңышлар юлдаш булсын!

**Кояш ТИМБИКОВА.**

# БИЛӘР

Татар халкы күңеле түрендә онытылмас изге бер хатирә, җанга якын тарих хәзинәсе булып саклана торган кадерле истәлекләрнең берсе — Биләр шәһәре.

Борынгы Болгар җирләре аша агып уза торган матур Чирмешән суы ярында дәүләтнең нәкъ үзәк бер өлешендәге Биләр шәһәре зур тормыш белән гөрләп, чәчәк атып яшәгән. Ул Болгар илендә генә түгел, хәтта урта гасырлар дөньясында да иң зур шәһәрләр рәтенә кергән. Аның шөһрәте һәм даны еракларга таралган. «Болгар урынына Биләр исеме XII гасыр башында билгеле була инде»,— дип яза Әбү Хәмит әл-Гарнати. Ул Болгар һәм Биләр дигән шәһәрләр исемнәренең мәгънәләре, халыкның гореф-гадәте турында яза, борынгы риваять-легендаларны китерә. Бу мәгълүматларны ул Болгар казые Ягъкуб бине Ногманнан ишетеп, аның «Болгар тарихы» исемле китабыннан алганлыгын әйтә.

Биләрнең тарихи аренада яшәү чоры X—XIII гасырлар, ягъни 922 елдан алып 1236 еллар дип күрсәтелә. Тарихи чыганаклар һәм нумизматика мәгълүматларында ул Биләр, Бүләмәр, рус елъязмаларында Олуг шәһәр формасында кулланылган һәм Болгар дәүләтенең башкаласы да булып торган. Биләр Шәрык илләрендә, Европада матур, экономик яктан нык, сәүдә алга киткән, гыйлемлек зур үскән шәһәр булып искә алына. Бу калада акча да сугыла. Ә. Мөхәммәдиев әлегә кадәр табылган хәзинәләрнең XIII йөзгә караганнары арасында Биләрдә сугылган аноним акчалар булуын яза. Мондый тәңкәләрнең алгы ягында Сиккәтүн Биләр, ягъни «Биләрдә сугылган акча» дип язылган. Акчаларның датасы юк, ләкин алар XIII гасырның 60—80 нче елларына хас булган авырлык нормасы буенча сугылганнар. Харәзм яки Сарайның аноним акчалары кебек үк, Биләр тәңкәләре дә XIII гасырның 80 нче елларында сугылган булса кирәк. Биләрдә тагын 1290—1293 елларда сугылган аноним акчалар билгеле.

Бабаларыбыз Биләрне зур һәм матур итеп, яшәү өчен уңайлы шартлар тудырып, эстетик яктан зур зәвык белән, йорт һәм административ биналарны бизәп, шәһәр эченә шәһәр торгызып (үзәк, эчке һәм тышкы кала), килгән яуга каршы торырга уңайлы булган урынга салганнар. Шәһре Болгардагы кебек, Биләрдә дә таштан һәм кирпечләрдән зур-зур пулатлар төзегәннәр. Биләрдә патша сарае урнашкан. Анда хан, аның вәзирләре, сакчылар һ. б. яшәгән. Кирпечтән салынган җамигъ мәчет, ишегалларына хуҗалык кирәк-яраклары өчен корылган келәт, амбар һ. б. шуның ише каралты-курасы булган байлар торган кирпеч йортлар тезелеп киткән. Яртысы җиргә иңдереп корылган амбар һәм келәтләрдә күмерләнгән орлыклар табылуы бабаларыбызның авыл хуҗалыгы белән дә бик яратып шөгыльләнүе турында сөйли. Эчке шәһәрнең үзәк өлешендәге утыздан артык кирпеч һәм таш йортларда Биләр байлары яшәгән. Шушында ук һөнәрчеләр бистәләре дә урнашкан. Шәһәрлек хәрабәләре арасыннан табылган һәм җыйналган әйберләр Биләр халкы тормышының таза һәм нык, халыкның эш сөючән, һөнәрләренең төрле-төрле булуы турында сөйлиләр. Бу шәһәр халкы тормышының мул-иркенлеге, тирә-юнендәге җирләрнең уңдырышлы һәм күплеге уртагасыр галим-географлары әсәрләрендә дә еш искә алына. Монда күп сандагы керамика фрагментлары, бакыр савыт-сабалар табылган. Хайван сөякләре, сөяктән эшләнгән эш һәм сугыш кораллары, таш, кирпеч ватыклары, кирпеч яндыру өчен мичләр, көнкүреш өчен кирәкле җайланмалар, җиз-бакырдан коелган сәнгать әйберләре һ. б. очрый. XVIII гасыр галиме Н. П. Рычков Биләр шәһәрлегендә хуҗалык өчен кирәкле булган тимер төреннәр, борау, аркылы балта, бәләкәй пычкы, чакма таш һ. б. тапкан, монда яшәгән халыкның элек-электән бик тырыш,

эшчән икәнлеген, йортларның бик матур булып, югары сәнгать осталыгы белән төзелүен язган. Кайбер йортлар үзәк җылыту системасы белән ягылган һәм аларда суүткәргечләр дә булган. Металлургия шәһәр яши башлаудан алып җимерелүенең соңгы көннәренә кадәр эшләп торган. Сөяктән әйбер эшләү һөнәре дә бик нык алга киткән булган. Тимерчеләр һәм чуен коючылар бистәләрендә эш кайнап торган. Пыяладан әйбер ясау алга китүне шәһәрлектә табылган пыяла шлак, пыяла әйберләр ватыклары һ. б. күрсәтә. Биләр шәһәрендә сәүдә дә нык алга киткән булган. Базар киштәләре товар белән тулган. Биләр халкы Көнчыгыш, Шәрык һәм Европа илләре, рус кнәзьлекләре һ. б. белән сату-алу мөнәсәбәтләренә кергән. Эчке шәһәр берсе артыннан берсе урнашкан ике вал белән ныгытылган булган. Тышкы шәһәрдә һөнәрчелекнең чүлмәк ясау төре алга киткән. Тышкы шәһәр берсе артыннан берсе урнашкан өч рәт ныгытма белән әйләндереп алынган булган. Биләр шәһәренең берничә кат төзелгән көчле ныгытмалары алдында, чәчәк атып утыра торган калаларны җимерүдән һәм җир белән тигезләүдән тәм тапкан Аксак Тимернең дә йөрәгендә соклану кебек хис тумыйча булмагандыр... Биләр халкы Болгар дәүләтенең башка шәһәрләрендәге һәм урта гасырларның төрле җирләрдәге зур үзәкләрендәге кебек үк ярым шәһәр кешесе, ярым крестьян, өлешчә һөнәрче һәм вак сәүдәгәр булган. Шуны әйтергә кирәк, мәчет булган урында мәдрәсә булмый калмый. Биләрдә дә мәдрәсәләр булган. Болгардагы кебек, Биләрдә дә укымышлы кешеләр, галимнәр яшәгән, Болгардагы кебек үк әдәбият һәм сәнгать үскән.

Биләр шәһәре исеме татар халык иҗатында аерым урын тота, риваятьлегендаларда да еш кабатлана. Биләр җимерелү уңае белән чыгарылган риваятьтә Аксак Тимернең күп санлы гаскәре белән шәһәр капкасы янына килеп туктаганын күргән халык Биләр ханына бу гаскәргә каршы сугышыргамы яки сугышмаскамы дигән мәсьәләне үзенә хәл итәргә куша. Хан бер акыл иясенә мөрәҗәгать итә. Акыл иясе, меңләгән гаскәрне күреп, сугышмыйча гына шәһәр капкаларын ачарга киңәш итә. Биләргә капкалар ачып кертелгән илбасарлар халыкның күбесен кырып бетерәләр. Шәһәр алынган төнне Тимер икенче киемнәр киенә һәм халык ни сөйли икән дип тыңлап йөри. Күп кеше «шәһәребезне бары тик Аксак Тимер генә җимерде»,— ди. Шунда тол калган бер морза хатыны: «Әгәр безнең булдыксыз остазларыбыз һәм тәңре булмаса, Аксак Тимер үзе генә ни эш эшли алыр икән?» — дип әйтә. Икенче көнне Тимер бу хатынга һәм аның бөтен туганнарына азатлык бирә, кая теләсәләр, шунда китеп урнашырга рөхсәт итә, имеш.

Биләргә атап, шагыйрьләребез шигырьләр язган, композиторларыбыз матур җырлар иҗат иткән. Ярына борынгы шәһәр Биләр салынган Чирмешән суы да бик күркәм.

Республикабыз җирендә Биләр сүзе белән шактый гына атамалар очрый. Бу күренеш, билгеле тарихи сәбәпләр нәтиҗәсендә болгар-биләрләрнең төрле урыннарга сибелеп урнашуларын күрсәтә. Таныш һәм җанга
үз шәһре Биләр исеме белән, шулай итеп, башка география берәмлекләре
дә аталган. Арча районындагы Татар Кадрәге авылын тирә-яктагы халык
Биләр иле дип йөртә. Бу авыл зиратында XVI йөзнең беренче яртысына
карый торган кабер ташлары да бар. Күрәсең, биләр кабиләләренең бер
өлеше, Биләрне монгол яулары җимергәч, урман белән капланган тынычурыннарга, Каманың уң ягына, аерым алганда, Татар Кадрәге дигән авыл-
урыннарга, Каманың уң ягына, аерым алганда, Татар Кадрәге дигән авыл-
га килеп утырганнар. Бу авыл, рус елъязмалары Яңа Болгар дип атаган
Иске Казаннан ерак түгел генә урнашкан. Соңыннан Татар Кадрәге авылы
кешеләре Балтач районындагы Ор авылын нигезләгеннәр. Чөнки Ор авылы
кешеләре «Сезнең авылыгыз кем тарафыннан салынган?» — дигән сорауга:

*Казиленнән килеп казык каккан,*
*Биләрдән килеп биләгән,*

— дип җавап бирәләр. Ор сүзе Татарстан топонимиясендә сакланган болгар
сүзе дип карала. Бу авыл Казан ханлыгы чорында була. Арча районындагы
Түбән Оры һәм Югары Оры авыллары атамалары составында да ор ~ оры
сүзе бар. Түбән Оры авылында XVI—XVIII йөзләргә караган кабер ташы
язмалары табылган. Мөслим районында Мари Бүләр һәм Татар Бүләр,
Октябрь районындагы Биләр күл исемендәге күл һәм авыл атамалары да
борынгы болгар шәһәре Биләргә мөнәсәбәтле. Республикабызның көнчыгыш

районнарында яши торган һәм шулай ук монда типтәр дигән атама белән билгеле булган халыкның да шәҗәрәләре, М. И. Әхмәтҗанов язуынча, монголлар чорына кадәрге Биләр шәһәре һәм болгарларга барып тоташа. М. Г. Госманов һәм Ф. С. Фәсиев, XVIII йөз татар тарихчысы һәм шагыйре Таҗетдин Ялчыголның үз шәҗәрәсен болгар шәһәре Биләр белән бәйләгәнлеген язалар. Бүләр~Биләр сүзе кергән географик атамалар борынгы болгар дәүләте белән чиктәш яисә аның политик һәм экономик йогынтысы астында булган регионнарда: Урал-Оренбург тирәләрендә, хәзерге Мари республикасында, көньяк Украина (Кырым) һ. б. урыннарда очрый. Шунысы кызыклы, тарихи чыганакларда венгрлар арасында да мөселман биләрләр булу турында мәгълүматлар бар. Алар Венгриядәге Пешт шәһәрен нигезләгәннәр. Биләр дигән сүз Скандинавия халыклары сагаларында да чагылыш таба.

Монгол яуларына Биләр калкан кебек каршы тора. Әмма көчләр тигез түгел, дошманнар шәһәрне җимерәләр, халкын тар-мар итәләр, кырып бетерәләр. Мөһим сәүдә юлларыннан читтә урнашкан Биләр монгол яуларыннан соң үзенең әһәмиятен югалта. Соңыннанрак ул бушап кала. 1654 елда Биләр шәһәре урынына стрелецлар килеп урнаша. Бу урында инде рус авылы үсеп китә һәм ул русчалаштырып Биляр, Билярский дип йөртелә башлый. Рәсми рәвештә Биләр дип атала торган авыл хәзер дә бар. Элек ул Биләр районының үзәге булган. Районнарны эреләндергән чорда ул Алексеевский районына кушылган. Нугай юлы өстенә урнашкан бу авылның Казан ханлыгы чорында булуы мәгълүм. Шунысы игътибарга лаек, хәзерге Биләр авылын җирле, күрше-тирәдә яши торган халык Биләр дип түгел, ә элекке болгар шәһәре яңгырашында Бүләр дип йөртә. Биләр каласыннан калган хәрабәләр турында иң беренче мәртәбә XVIII гасырның атаклы рус галиме В. Н. Татищев язып чыга.

Шәһре Биләр халкыбыз тормышында һәм күңелендә тирән эз калдырган, халык хәтеренең түр почмагында сакланган.

**Фирдәүс ГАРИПОВА,**
филология фәннәре кандидаты.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Үткән елның 22 декабрендә язучыларның әдәби алмаш тәрбияләүгә багышланган ачык партия җыелышы булып узды.

Язучылар союзының әдәби консультантлары М. Галиев һәм Ә. Мушинский отчетыннан соң фикер алышуда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, әдипләр Н. Дәүли, Г. Ахунов, И. Юзеев, Р. Харис, М. Хәсәнов, Н. Беляев, К. Латыйп, Р. Хафизова, М. Әгъләмов һәм яшь язучылар катнашты.

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР БЕЛӘН ЭШЛӘҮ КОМИССИЯСЕНДӘ

16 декабрьдә Татарстан Язучылар союзының яшь язучылар белән эшләү комиссиясендә республика әдәби иҗат берләшмәләре җитәкчесе Н. Гыйматдинова отчеты, комиссиянең эш планы һәм оештыру мәсьәләләре каралды. Тикшерелгән мәсьәләләр буенча фикер алышуда Ш. Галиев, И. Юзеев, М. Галиев, С. Маннапов, К. Каримов катнашты.

## ФӘННИ-ПРАКТИК КОНФЕРЕНЦИЯ

1—3 декабрьдә Казанда «КПССның XXVII съезды карарлары һәм мәктәп реформасы таләпләре яктылыгында татар теле һәм әдәбиятын укытуның актуаль мәсьәләләре» дигән темага республика фәнни-практик конференциясе булып узды. Анда Татарстан АССР мәгариф министры Р. А. Низамов доклад белән чыкты. Галимнәр, язучылар, композиторлар, Татарстан районнарыннан һәм РСФСРның егерме төбәгеннән килгән татар теле һәм әдәбияты укытучылары тел-әдәбият укытуны тагын да камилләштерү буенча тәҗрибә уртаклаштылар, мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында булдылар.

## К. ТИНЧУРИНГА БАГЫШЛАНГАН КИЧӘ

14 декабрьдә Мәскәүдә А. А. Яблочкина исемендәге Үзәк актерлар йортында, татар әдәбияты классигы Кәрим Тинчуринның тууына 100 ел тулуга багышланган кичә булды.

Кичәне кереш сүз белән Татарстан Театр эшлеклеләре союзы идарәсе председателе Р. Җиһаншина ачты. Күренекле драматургның иҗаты турында сөйләшүдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры, СССРның халык артисты М. Сәлимҗанов, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин катнашты.

Г. Камал исемендәге академия театры артистлары К. Тинчурин пьесалары буенча куелган спектакльләрдән төзелгән тамаша күрсәттеләр.

## ӘХСӘН БАЯНОВ ЮБИЛЕЕ

8 декабрьдә Казанның Актерлар йортында күренекле язучы, шагыйрь һәм драматург Ә. Баяновның 60 еллыгына багышланган юбилей кичәсе булды. Әдипнең иҗат һәм тормыш юлы турында язучы Г. Ахунов сөйләде.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, әдипләр Г. Ахунов, Ә. Еники, Р. Харис, Г. Рәхим, В. Нуруллин, А. Әхмәдуллин, Р. Миңнуллин һәм якташлары юбилярны котлап, уңышлар теләделәр.

Соңыннан Ә. Баянов шигырьләр укыды, сорауларга җавап бирде. Татарстан сәнгать осталары язучы иҗатына багышланган концерт күрсәттеләр.

## ФӘРИТ ЯРУЛЛИН ИСТӘЛЕГЕНӘ

Татар совет композиторы Фәрит Яруллин утызынчы еллар башында Казан сәнгать техникумында (хәзерге Казан музыка училищесында) укый. 18 декабрьдә шушы бинага композитор истәлеген мәңгеләштерү уңае белән мемориаль такта куелды. Анда: «Бу йортта 1930—1933 елларда композитор Фәрит Яруллин укыды» дигән сүзләр язылган.

## ОРЕНБУРГТА ӘДӘБИ КИЧӘ

22 ноябрьдә Оренбург шәһәренең Х. Ямашев исемендәге китапханәсендә Бөек Октябрьнең 70 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Кичәне китапханә каршындагы әдәбият-сәнгать берләшмәсе әгъзасы Л. Рафыйкова алып барды. Өлкән укытучы М. Рахимкулова тормыш юллары һәм иҗатлары Оренбургка бәйле, культурабыз тарихында билгеле эз калдырган әдипләр, сәнгать эшлеклеләре турында үзенең истәлекләре белән уртаклашты. Берләшмә җитәкчесе З. Шакиров бүгенге татар әдәбияты турында сөйләде.

## М. ҖӘЛИЛ ӘСӘРЛӘРЕ — ӘФГАНСТАНДА

Әфганстан Язучылар союзының «Җавандун» журналы дари һәм пуштун телләрендә герой шагыйрь Муса Җәлилнең шигырьләрен һәм портретын бастырып чыгарды. Шунда ук Р. Вәлиевнең шагыйрь турындагы мәкаләсе урнаштырылган.

# УКАЛЫ ЯПМА

Борынгы Болгар шәһәрендә археологик казынулар вакытында алтын белән укалап чигелгән әйбер калдыклары табылды. Болгар дәүләте илчеләренең бүләкләре арасында, шулай ук халыкның көнкүрешендә укалы тукымалар булу хакында борынгы язма истәлекләр сакланып калган. Болар барысы да алтын-көмеш белән чигүнең татар халкында гасырлар түреннән килүче традицияләре турында сөйли.

Бабаларыбыз элеккерәк чорда алтын җепле бизәкләрне күнгә төшергәннәр. Соңрак күнне эшләү өчен уңайлырак тукыма алыштыра. XVI—XVII гасырларда җепләрне алтын йөгертелгән көмештән, яки бакырдан да эрли башлаганнар.

Борынгы заманда йола әйберләрен, ашъяулык, җәймә, кашага, чыбылдыкларны да алтын белән укалап чиккәннәр. Бу хакта халык авыз иҗаты чыганакларында телгә алына.

Татарстан сынлы сәнгать музеенда саклана торган укалы ашъяулык шуның ачык мисалы. XVIII гасыр ахырында — XIX гасыр башында эшләнгән, бизәкләре белән борынгы композицияләргә тартым бу әйберне чигү осталарының иң зур казанышларыннан берсе дияргә мөмкин. Анда алтынлап чигүнең структур яктан ювелирлык сәнгате белән бер тамырдан булуы ачык күренә. Әрфиядәй җиңел ак ефәккә алтын-көмеш җепләр белән төшерелгән катлаулы бизәкләрне Урта Азия, Кырым, Кавказ халыкларының чигү үрнәкләре белән чагыштырып карасак, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан аңа тиңнәр булмавын күрербез.

Үзәктә урнаштырылган йолдыз һәм ярым ай төшкән квадрат тирәсенә гарәп хәрефләре белән матур итеп бизәкләп билгеле бер эзлеклелектә «китап» дигән сүзләр тезелгән, югары сәнгать камиллегенә җиткереп эшләнгән бу әйбер татар көнкүреше өчен традицион булган, халыкта гадирәк вариантлары еш очрый торган китап япмасы. Мондый япма илебезнең башка музейларында юк, ул бердәнбер.

Бу япма 1970 елда Оренбург өлкәсенең Сакмар районы Татар Каргалысы авылында табылган иде. Аны эшләүче яки эшләтүче бик мәгърифәтле, китап культурасын һәм Көнчыгыш илләрендә киң таралган каллиграфия сәнгатен яхшы белгән кеше булгандыр дип фараз итәргә нигез бар.

Каргалы авылы — XVIII—XX йөзләрдә татар халкының зур культура һәм мәгариф үзәкләреннән берсе. Биредә тирә-якта даны таралган мәдрәсә эшләгән, галимнәр, әдипләр, шагыйрьләр яшәгән. XVIII гасыр шагыйре Г. Утыз-Имәни шунда укыткан, XIX гасыр шагыйре Әбелмәних Каргалый шунда туып-үскән. Китап күчерүче осталар булган. Биредә хөкем сөргән рухи атмосфера әлеге затлы сәнгать әсәренең барлыкка килүе, кулланылуы өчен бик тә уңай мохит тудырган.

Рухи культура предметы булган «укалы япма» — белем чишмәсе, зирәклек чыганагы булган китапны хөрмәтләү, аңа баш июнең, зурлауның гәүдәләнеше ул. Халкыбызның тарихи һәм географик урыны, культура-интеллектуаль йогынтыны сеңдерергә һәм трансформацияләргә искиткеч сәләтле булуы әнә шулай, җирле традицияләр нигезендә, Көнчыгыш һәм Көнбатыш сәнгатенең шигъриятен үзенә җыйган органик сәнгать әсәре барлыкка китергән.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
Татарстан сынлы сәнгать музее
фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казанның Актерлар йорты.

**Ю. ФИЛИМОНОВ фотосы.**

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)